# казан утлары

10.2003





РИЗА ИШМОРАТ
1903–1996

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2003*

# 10

**(972)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Диләрә Максутова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Факил САФИН. Саташып аткан таң. Роман ... 5
Әхсән БАЯН. Яңа гасыр. Шигырьләр ... 55
Әдхәт СИНУГЫЛ. Фәрдләр ... 59
Мәдинә МАЛИКОВА. Мендем биек тауларга. Повесть ... 63
Әхмәт РӘШИТ. И заман!.. Шигырьләр ... 119
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Ел әйләнә гүзәл булу. Шигырьләр ... 122

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Йолдыз ХӘЛИУЛЛИН. Дипломат язмалары ... 124

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рәдиф ГАТАШ. Шагыйрь турында замандашлары ... 133
Хуҗи МӘХМҮТОВ. Шигъриятнең тирән тамырлары ... 139

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Ринат СОЛТАНОВ. Ханлык чорында Казан шәһәренең фортификациясе ... 143

**ФӘН**

Раушания ШӘФИГУЛЛИНА. XX гасыр татар әдәбиятында йорт-нигез образы һәм милли эстетика ... 150

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Таһир ГЫЙЛАҖЕВ. Онытылырылган әсәрләр ... 156
Флүс ЛАТЫЙФИ. Тылсымлы ачкыч ... 163

Коръән татар телендә ... 166

**ХӘТЕР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Авылдаш ... 174

Безнең календарь ... 177

«Казан утлары» архивыннан ... 178

**ЮМОР-САТИРА**

Талгать НӘҖМИЕВ. Саба мәзәкләре ... 180

Укучы сүзе ... 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 188

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Роман Ф. САФИНА «Мнимый рассвет», повесть М. МАЛИКОВОЙ «Взошла я на гору высокую»; стихи А. БАЯНА, А. СИНУГУЛ, А. РАШИТА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Публицистика»: статья Ю. ХАЛИУЛЛИНА «Записки дипломата».
«Литературная критика»: статьи Р. ГАТАША и Х. МАХМУТОВА о книгах, посвященных творчеству Равиля Файзуллина.
«К 1000-летию Казани»: статья Р. СУЛТАНОВА «Фортификация г. Казани в период ханства».
«Наука»: Р. ШАФИГУЛЛИНА. Образ «дома» в татарской литературе XX века».
«Книжное обозрение»: статьи Т. ГИЛЯЗОВА «Забытые произведения», Ф. ЛАТЫФИ «Волшебный ключ».
«Коран на татарском языке».
«Память»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА о поэтессе З. Башировой.
Наш календарь.
«Юмор-сатира»: Т. НАЗМИЕВ. «Забавные истории».
Из архива журнала.
Слова читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: мечеть Кул Шариф; писатель Д. Гарифуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

«Prose and poetry»: F. SAFIN'S novel «Seeming dawn», M. MALIKOVA'S story «I climb on high mountain»; the verses of A. BAYAN, A. SINUGUL, A. RASHIT, E. SHARIFULLINA.
«Journalism»: U. HALIULLIN'S article «Diplomat's notes».
«Literary criticism»: articles of R. GATASH and H. MAKHMUTOV about books devoted to creative works of R. Faizullin.
«Commemorating the millennium of Kazan city»: R. SULTANOV'S article «Fortificotion of Kazan city in Khan period».
«Science»: R SHAFIGULLINA. «The house image in Tatar literature of XX century».
«Book review»: T. GILYAZOV'S article «Forgotten works», F. LATYFI'S article «The magic key».
Koran in Tatar language.
«Memory»: R. FAIZULLIN'S articles about poet Z. Bashirova.
Our calendar.
»Humour and satire»: T. NAZMIEV «Funny stories».
Readers words.
The diary of social and cultural life.
On our covers: Kul Sharif mosque; writer D. Garifullin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.09.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7031 . Заказ Я—641
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.



## Факил Сафин

# САТАШЫП АТКАН ТАҢ

РОМАН

**Өченче китап**

I

Казан капкасын кыш җиле кага...

Мең тугыз йөз утыз җиденче елның егерме тугызынчы ноябре. Еракта уйнаклаган кызгылт таң нурлары офык түренә катлы-катлы өелгән кара-кучкыл тыгыз болытларны көчәнә-көчәнә ермачлап дөньяга яна көн туып килүен хәбәр иттеләр. Кар сибәләп алды. Казан урамнары суыктан бөрешеп калган, әллә тагын кыш беренче генә мәртәбә килә бу җиргә—бөтен шәһәр көтелмәгән мөшкел хәлгә тарыгандай пошаманда иде.

Алемасов, сәерсенүле карашын машина тәрәзәсеннән алмыйча, шактый барды. Аның җанын нидер талкый, изә кебек. Шушы халәтенә җавап тапмый иде ул, югыйсә, әле берничә минут элек кенә барысы да әйбәт, барысы да тәртиптә иде бит. Иртәсе дә башка көннәрдәгедән әллә ни аерылып тормый. Көз белән кыш алышынган мәлләргә хас гадәти салкынча иртә. Кәефне исә җен алыштырдымыни—кисәк кенә кара болыт сарды күнел күгеп. Каты авырудан айный алмый җәфаланучы бетәшкән карт та болай ук яшәү тәмен җуймас.

Кремльгә җитәрәк, Спасс манарасы янындагы капка төбендә сакчылар шәйләнә башлагач, шоферына күз дә салмый, кисәк кенә:

—Туктат әле, машинаны!—диде, аннан тирәннән кубарылган төксе тавыш белән өстәп куйды.—Җәяүләп кенә барам...

---

Факил САФИН *(1954)—прозаик, шагыйрь, публицист. "Соңгы көз", "Тузганак чәчәге", "Гөлҗиһан" һ. б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*
*Романның беренче китабы журналның 2001 елгы 8-9 саннарында, икенче китабы 2002 елның 4-6 саннарында дөнья күргән иде.*

Шоферның мангаена салкын тир бәреп чыкты. Кая бара, ни өчен җәяүгә күчте?.. Алай анын шоферлык эшенә тел-теш тигезерлек түгел сыман, хафаланырга урын юк та кебек. Шулай да тынычлыкны бозды хуҗаның бу кыланышы. Баш миен бораулап сораулар кайнашты. Аңа нишләргә хәзер? Хуҗа артына тагылып барыргамы, әллә, аны узып, өлкә комитеты ягына җилдерергәме, әллә соң шушы туктаган җирдә кыймылдамыйча, бераз көтеп торыргамы? Тегеләй дә, болай да килешеп бетмәс, ахрысы. Ни булса—шул, сабыр итәргә, көтеп торырга кирәк тә, хуҗадан йөз-йөз илле адым калыбрак алга шуышырга булыр.

Җәяүләп китәргә ашкынган Алемасов исә алга атларга ашыкмады. Дуамалрак кыланып кабинадан сикереп төште, шапылдатып ишекне ябып куйды. Монарчы анын үз кулы белән ишек япканы юк иде кебек. Нәрсәгә холыксызлана хуҗа, нәрсә ярамады? Ир уртасына җитсә дә, яшьләрчә шома йөзле, шактый сөйкемле күренгән шоферның янә тәненә тараканнар йөгереште.

Хуҗа җиргә төшкәч, ике-өч адым атлады да, кемдер озын күн пәлтәсенең чабуыннан эләктергәндәй, шып туктап калды. Шушы мәлдә аңа ышаныч кайтты, ул беренче мәртәбә күргән шикелле Казан урамын, тирә-юньдә караеп торган йортларга күз салды. Күпчелек тәрәзәләрдән сүрән ут саркый, шушы утлар урамга аз булса да җанлылык өсти; ниндидер шәүләләр күзгә чалына—эшкә, белем эстәргә, сәфәргә җыенып вокзалга, тагын кайларгадыр ашыгучы күшеккән бәндәләрне үчекләгәндәй, урамны ду китереп җил йөгереп үтте.

Алемасов тәмам тынычланды. Кыяфәтенә тәкәбберлек инде, ни өчен болай төшенкелеккә бирешүен аңламаса да, үзенең шушы җирдә нык басып торуына куангандай, һавалы йөз белән янә тирә-якка күз ташлады. Сизмәстән, итеге белән аяк астын капшап алды. Нык, бик нык басып тора ул бу җиргә, шушы чуер таш җәелгән урын убылып, каядыр аска очарга тиешле кеше түгел Алемасов, ул үз биеклеген, дәрәҗәсен, мөмкинлеген чамалап эш йөртүче үтә сак адәм. Ә бит имеш-мимешкә караганда, Казан асты тоташ дип әйтерлек урау-чурау юллардан тора икән. Теләсә кайда, теләсә кайчан аска мәтәлүең бар. Моны аңа Николай Ежов Казанга китеп барыр алдыннан әйткән иде, ничектер кисәткән сыман, сүзләренә күп төсмер салган мәгънәдә. Әйе, уйларга, һәр адымны исәпләп атларга кирәк бу калада! Иң сәер ялкаулык—уйларга иренү, башка ишелгән күп бәлаләр шунын аркасында. Уйларга ирентән кешенең яшәве төссез була.

Уйласаң уй җитәрлек анысы. Нигәдер монарчы үз язмышы, тормышы хакындагы уйлардан качарга теләи иде ул. Бүгенге иртәдә әнә шул күнел төбендә кузгалмый яткан хисләр кубарылды, җаны шуна тынгысызланды бугай. Болай җибәп калу, хәтта ул минутлык кына булса да, һич ярамый. Алемасов беркемгә дә ышанмый Казанда, үзен дошманнар камалышындагы бер кеше сыман хис иткән чаклары да күп була. Тик бу хакта беркем дә белергә тиеш түгел, хәтта ки якын күреп йөргән кешеләргә тулысынча түгел, өлешчә дә чишелергә ярамый. Дус дип йөргән кешен ун дошманнан куркыныч булуы ихтимал. Казан—ул Казан! Беркемне дә аямый, беркемне дә кызганмый торган, дөньясына, иленә ачулы, үчлекле шәһәр; Казан диварларына бәрелеп күпләрнең мөгезләре сынды инде. Әмма Алемасов Казанны алачак, дошманнарны сытып-изеп узачак, анын бу шәһәрдәге язмышы бәхетле булачак. Ул Казанга шундый ышаныч белән килде, шундый ышаныч белән эшкә керeште һәм бу, хәтта әйтергә ярыйдыр—сәер ышаныч—әлегә аны алдамый иде. Бөтен сәерлек шунда—анын ышанычы фәкать үз-үзенә ныклы инануга корылган иде. Кемгә дә булса ул ышанмый да, ышана да алмый, башкаларга исәп тотып та яшәми.

Казанга килеп оттымы, оттырдымы ул? Каядыр эшкә билгеләнү, шул нигездә каядыр килеп урнашу, кайдандыр китеп бару мәсьәләләре анын үзенә генә бәйле түгел, әлбәттә. Кузбасста, Томскида, аннан Украинанын

Кирмәнчек калаларында фирка эшендә чарланган, каты куллы, дошманнарга аяусыз утыз биш яшьлек ир-егет ул. Әле япь-яшь килеш, егерме бише тулыр-тулмас җитәкчелек эшенә керешеп, ун ел дәвамында печтеки дә абруена тап төшерер гамәл кылмады, фирка алдында йөзе ак. Ежов аңа Татреспубликаның НКВД халык комиссары вазифасын тәкъдим иткәч тә, риза булмасын сиздереп, кискен каршы төшсә, баш тартса, аның белән кабат сөйләшеп торырлар идеме Үзәк Комитетта? Моңа кадәр, турысын әйткәндә, инде хәзер үзләре дә "дошман" булараk, юк ителсәләр дә, Татарстан НКВДсын нык куллы комиссарлар җитәкләгән. Күзгә күренерлек эшләре бар. Өлкә комитеты рәисләре Хатаевич, Разумовлар да дошманнар белән көрәшне сүздә генә калдырмаганнар. Оеткы әйбәт салынган. Ләкин көрәшне тагын да кискенләштерергә, Татарстанны дер селкетерлек бер "эш" оештырырга кирәк иде һәм моның өчен кармавычка өлкә комитеты беренче сәркәтибе постында шактый эш күрсәтергә өлгергән, башкала алдында абруе тотрыклы күтәрелә барган Лепаны эләктерүдән башка чара юк иде. Алемасов күреп торды—Альфред Лепа, Казанга Ежовның иң ышанычлы кешеләренең берсе килүен чамалап, баштагы көннәрдә югалып та калган сыман иде, аннан үзен кулга алып, Алемасов белән мәчелетычканлы уйнарга да маташты маташуын, әмма үзе өчен тыныч көннәрнең бетүен танып, хастаханә юлларын таптарга кереште, партия-совет эшендә алсыз-ялсыз эшләп, өч тиенлек тә сәламәтлеге калмаган, имеш. Болай гына котылмасын аңлагач, Алемасов белән ачыктан-ачык сөйләшергә дә омтылды. НКВД халык комиссары аны ярты сүздә бүлдерде:

—Әгәр Совет илендә бармак белән санарлык ышанычлы өлкә комитеты җитәкчеләре бар икән, аның берсе—Альфред Лепа!—диде ул Беренченең күзләренә туп-туры карап.—Шуңа күрә һич хафаланасы түгел, матур барган эшегезне дәвам итегез, без исә Сезгә һәрьяклап булышлык күрсәтербез, безләрне Үзәк Комитеттан шуның өчен җибәрделәр дә бит инде.

Лепаның күзләре дымланды бу сүзләрне ишеткәч, әмма күңеле урынына барыбер утырып җитмәде һәм башка терәкләр эзләвен дәвам итте, тик өлгермәде...

...Алемасов үзе Казанга килеп төшкән пыскак яңгырлы җәйге көнне яхшы хәтерли. Шунда ук, каршы алырга килгән НКВД хезмәткәрләренең берсе озатуында, өлкә комитетына, Альфред Лепа янына юл тотты. Беренче янына керергә чират көтеп торучылар шактый булса да, аны тиз үткәреп җибәрделәр, күрәсең, Беренчегә алдан кисәтеп куйганнардыр, тегесе исә "кунакның" килеп җитүен түземсезлек белән көтеп торгандыр. Алемасов бүлмәгә үтеп, берничә адым атлауга туктап калды. Юк, бүлмәнең шактый зур булуыннан да, зәвык белән җиһазланган булуына да шаккатмады ул, моның ише генә кабинетларны күп күрде, аны кабинет хуҗасы кызыксындыра иде. Ул очлы күз карашын озын өстәл артында тарала төшеп утырган Лепага төбәп, юри шулай аптыраулы халәттә катып калган булды. Шушы ике-өч секунд вакыт җитте—Лепаның үз-үзенә шулай ук нык ышанган булуын тойды яңа НКВД башлыгы, әмма киеренкелектән Беренченең озынча саргылт яңагындагы мускулларның уйнаклавын да абайлады. Димәк, шикләнә, димәк ки астыртын көрәшергә өметләнә һәм, күренеп тора, тиз генә бирешмәячәк бу карт төлке. Карт төлке димәктән, Алемасовтан бары биш-алты яшькә генә зуррак Альфред Карлович шактый өлкән күренә. Тар кысалы күзлек кигән, чәченә чал йөгергән, төз борын астында, җирән булса да, үзенә ятышып торган килешле мыек, кысылган иреннәр. Фирка яклавына өмет итүе, авыр чакларда аңа таянырга исәпләве урынлы—Ригада хаккый һөнәр мәктәбендә укып йөргәндә, ат биржасы хуҗасы малае булуына карамастан, яшьтән революция эшенә керешеп китә, 1914 елда ук, Бөтендөнья сугышына каршы гамәлләре өчен кулга алынып, Себергә сөргенгә озатыла, кача, тотылгач, төрмәгә тыгып куялар. Революциядән соң Уралда фирка эшендә, гражданнар сугышында Дутовка, Колчакка каршы сугыша.

Кыскасы, чыннан да утны-суны кичкән кеше иде ул һәм аңа каршы көрәштә сак, хәйләкәр булу кирәклеген тиз төшенде Алемасов.

Лепа, НКВД комиссарын каршыларга үзенчә ярыйсы әзерләнгән иде: хәтта, тактик адым ясарга маташып, Алемасовның озын бүлмә аша үтеп, өстәл турысына килеп җитүен күн урындыгына шулай ята төшебрәк кәтеп алмакчы иде дә, каршысында дип әйтерлек нык бәдәнле, итләч иренле, шома йөзе кояшта янган, кырыс карашлы, гәүдәгә үзеннән һич калышмаган һәм шул ук вакытта, ыспай киенгән Мәскәү "кунагы" пәйда булгач, сизмәстән урыныннан сикереп торды, өстенә кигән хәрби тукымадан тегелгән яна кәчтүненең түшенә тагылган гражданнар сугышында бирелгән орденын калкыта төшеп, колачын җәеп аның каршысына китте. Нигәдер Лепа ун якка салулап, алга иелә төшеп атлый иде... Кул биреп күрешкәндә Лепа тоеп алды—Алемасов каты куллы, бер тотса, ычкынырмын димә... Каберең якын булмасын моның ише НКВД комиссарына.

Тыштан караганда җылы, бик җылы каршыладылар аны Казанда. Әмма Лепа белән беренче очрашуда ук каһәр суккан "кем-кемне" дигән сорау ике арага зөлкарнәй кылычыдай кереп ятты. Кереп ятты дию генә дөрес булмас, үткеннән үткен кылыч аларның икесенә дә бертигез янап, баш очларында асылынып тора башлады. Алемасов өчен барысы да шома гына барды дип булмый, вакыты-вакыты белән кылыч аның баш очында да эленеп торгалады, бигрәк тә Лепа үзенең капкынга эләгүгә таба баруын тойган беренче мәлләрдә шулай булды. Беренченең Мәскәүдәге танышлары, сугышчан дуслары аша Ежовка, Үзәк комитеттагы җаваплы работникларга чыгарга омтылыш ясарга маташуларын белеп торды НКВД комиссары, аның үзен дошман ясап, "фаш" итәргә азаплана иде Лепа. Әмма Ежов үзе җибәргән кадрга жил-янгыр тигезмәде.

Кылыч җәй азакларында тулаем Лепа өстендә асылынып тора башлады. Беренче, тәҗрибәле җитәкче, эшнең кая таба барганын сизеп, капкынга эләккән киек шикелле бәргәләнде, тик кылыч күзгә күренмәс җептән ычкынып, латыш егетенен киләчәге шактый матур күренгән язмыш юлын сиздерми-нитми кисеп үтте. Лепа Казан белән хушлашмыйча аерылышты, кире кайтырына өмете бөтенләй үк киселеп бетмәгән иде бугай. Тик киткәннәрнең кире кайта торган, киләп-сарып йөрү заманнары үткән иде инде. Кайтуын болай кайтты, әмма башкача... Ул Мәскәүгә барып, Сталинның үзенә керергә ирешмәктә җан-фәрман тырышлыклар куйса да, даһи юлбашчы аның ише пешкалар белән вакланып торуга, шулай ук күптән нокта куйган иде инде. Андыйлар бер Альфред Лепа гына булса ярый да бит. Мәскәү тарафына хаклык эзләп күпләр китә тора, "хаклык"ны чыннан да тиз табып бирәләр анда. НКВД камераларында берничә көн изалангач, хаклык хакында уйларга да курка башлый адәм баласы... Мәскәүнең гаделлеге башка аның.

Иртәнге йокыдан теләр-теләмәс уянып азапланган Казан урамына ничектер борынын җыера төшеп карап торды Алемасов. Кремль ягына борылды. Шушы мәгърур кальганы татарлар төзегән дип лаф оралар бит, ачуын да бер килмәгәе. Имеш, Астрахань, Тубыл, Мәскәү, Бөек Новгород һәм башка шәһәрләрдәге кальгаларны да Казан осталары өешкән. Әйе, татарлар тарих ясарга ярaталар, тарихлы буласылары килә боларның, үзләрен цивилизацияле халык итеп таныткмакчылар, моны һәрдаим сиздереп торалар, әлеге карашларны үҗәт татарның аныннан ныклап, яңадан искә килмәслек итеп кысып, сыгып чыгарасы бар. Ул башын гаярь рәвештә югары чөеп катып калды. Тарихны ясарбыз анысы, әмма аны Алемасов теләгәнчә, Үзәк Комитет установкасына туры китереп ясау мәслихәт булачак. Татарда күп үрчегән тарихчылар, менә аларын инде чүплеккә себереп түгәргә вакыт җитте. Ул вәкарь рәвештә тора бирде, ни өчен шулай кылчыклана—моның сәбәбен ул үзе дә аңлата алмый иде әле. Их, шушы урында һәйкәл булып

калкып чыгарга иде! Аның күңеле кымыржып алды. Дәүләт диләр татарлар, дәүләт кирәк аларга, димәк ки, патша да кирәк. Шәп нәрсә икән ул патша булулары, акылга сыймаслык хәл, ул—Алемасов Александр Михайлович, көннәрдән бер көнне тулы бер республикага патша булды да куйды, моны язмышның тантанасы дими ни дисең?.. Аның йөзенә елмаю җәелде. Күптәннән бирле үзе турында уйланып, хисләнеп алганы юк иде. Бүген иртә шушындый каршылыклы җилкенүдән башланды. Хәерле булсын.

Шулай да яктылык җитми Казанга, җитми яктылык! Ничек җитсен ди инде—ничә еллар корткычлар тырнагында тартыша кала. Милләтчеләрнең бөтен төрләрен, оппортунистларның һәр төстәгесен үрчетеп яткан бит ул үз казанында. Исеме җисеменә килә бу яктан караганда. Ә менә тарих мәсьәләсенә килгәндә...

Казанга юлга чыгып китәр алдыннан Ежов аны кат-кат кисәтте: бүре базы буш булмас, тезгенне азга гына да бушатма, диде. Гаярь җайдак хәлендә булсаң да, кистәнең кулыңнан төшсә, аны иелеп алырга форсат калмаска да мөмкин дип, бераз шүрләтеп тә куйды. Ул шулай бизәкләп сөйләргә ярата. Юкка гына "Хәтбәче Колька" дип йөртмәгәннәр аны Казанда. Кулыннан китап төшмәгәнгә, телендә гел китап сүзе булганга ябышып калган исем ул. Сталин янында булып, Татреспубликага НКВД халык комиссары булып раслангач, Ежов Алемасовны кабат үз бүлмәсенә дәште, тиз генә үз яныннан чыгарып җибәрмичә аталарча киңәшләрен тезде генә. "Сезнең халыкның бер кимчелеге бар—укырга иренәсез,—диде тимер куллы нарком, көяз рәвештә кабинеты буйлап йөреп. Кылтаеп диярлек, сыңар кулын ялтырап торган бил каешына тыгып, каршысына килеп басты, үзе өчен махсус тегелгән шәп хром итегенең биек үкчәсенә күтәрелә төшеп дәвам итте.—Укырга кирәк булачак, кадерлем, Казан наданнар шәһәре түгел. Патша галиҗәнапләре тәүге университетларның берсен тикмәгә Казанга китереп утыртмаган. Бер хикмәте бар моның. Казанның тарихын бел, татарның холкын өйрән, шунсыз Казанны алу кыен булачак.—Мин сөйләгәнгә колак сала микән дигәндәй бер кавым тын торды. Алемасовның керфек тә кагарга кыеп аны тынлавына инангач, ирененә канәгать елмаю кунды.—Казан урамнарының һәр ташы—тарих ярчыгы. Кемнәр кемнәр, әмма татарлар үз тарихларын яхшы беләләр. Каннарында ул тарих аларның, без белмәгән, белгән кадәресен дәшми торган, онытылырга тиешле тарих! Ә тарих исән, тарих яши... Безнең өчен бик куркыныч бу хәл. Күрәкараучылык НКВД эшендә гафу ителмәслек нәрсә. Бу хакта сиңа кадәр эшләгән иптәшләргә дә,—"иптәшләр" дигәч, төртелеп калды, кисәк читкә атлады, күзен чепиләндереп, каршысындагы кешегә караш ташлады, йөзе агарып чыкты.—Аларның "халык дошманнары" буларак фаш ителүенә биш былтыр, сабак өчен әйтүем...—Шул чагында Ежовның гаять куркак бер бәндә икәнен сизде Алемасов. Бөтен кыланмышы, көязлеге шушы куркаклыгына ширма иде бугай.—Әйе, мин ул хәшәрәтләргә аз тәкърарламадым, татарлар хәтерле, хәтәр халык дидем, тик алтындай сүзләргә колак салучы гына булмады. Шул наданлыклары аркасында, бәлки үзләре дә сизмәстән, дошманнар тегермәненә су коя башладылар. Этне ияртсәң—сукма, кадрларны кая гына җибәрсәм дә, якларга тырышам. Мәскәүдән торып, төбәктә сезнең кыланганнар өчен җавап тоту җиңел түгел. Ышанам, моннан соң Казан ягыннан яман хәбәрләр килүдән туктар. Дошманнарны фаш итүдә безнең тарафтан берниндн дә чикләү юк. Эрерәк кошларны каптырырга тырыш. Корт анасын тотып умартага кертеп япсаң, бөтен күч аның артыннан ояга кереп тула.—Ежовның күзе тоныкланып калды.—Төбәкләрдә эшнең очыкырые күренми, кемгә карама—сату, кемгә бакма—сатылу. Урындагы түрәләрнең наданлыгы, күрәкарау, дусны дошманнан аера белмәү—шул харап итә Совет илен. Кабатлап әйтәм, синең өчен Татреспубликада буй җитмәслек кеше юк. Обстановкага карап хәрәкәт ит. Билгеле, аеруча мөһим моментларны безнең белән килештереп. Әйтик, мәсьәлә Лепага килеп кагылды, ди... Ул латыш мина нигәдер ошамый... "

Ежов белән булган шушы очрашу, тимер наркомның киңәшләре баштарак Алемасовка тынгылык бирмәде. Лепаның язмышы хәл ителгән санарга була, монысы өчен баш ватасы юк, ә менә наданлыкны ничек җиңәргә? Яна урынга авыр ияләшә ул. Болай да сак кеше, баштагы мәлләрдә кеше белән бөтенләй аралашмый иде диярлек. Ә монда алай эшләргә мөмкин түгел. Мәскәү икенче көнне үк хисап сорый башлады. Күпме дошман кулга алынган, күпмесенә эш кузгатыла, шуларның күпмесенә— атылу... Бу саннар разнарядканың ничә процентын тәшкил итә, дошманны фаш итү планы ни өчен үтәлеп җитми, сәбәпләрен аңлатыгыз... Менә шушы халәттә тарих укып ятып буламы? Сорау алуларда үзе турыдан-туры катнашып, хәшәрәтләрнең телен чиштерүдә үз алымнарын (бигрәк тә тотакның башына кыршау кигереп кысу, җенес әгъзаларын келәшчә белән сыту, кумаклы (күселе) базга төшерү "нәтиҗәле" булды) куллана башлагач кына, Мәскәү алдында йөзе яктыра төште. Кәефе күтәрелгән бер көнне ярдәмчесе аша Казан тарихына багышланган китаплар соратып алды. Әүвәл Гайнетдин Әхмәров, Газиз Гобәйдуллин, Һади Атласи, тагын бүтән татарларның үз арасыннан чыккан галим кисәкләренең китапларын, урысчага тәрҗемә кылынган мәкаләләрен укып матавыкланды. Җанына ятышлы эш түгел иде бу. Татар тарихын өйрәнүгә караганда, берәр тотакның теле чишелерлек "хәлгә китерү" мең мәртәбә саваплы һәм канәгатьлек хисе бирер иде. Татарлар үз кавемен ничек тә купайтырга, зур тарихлы итеп күрсәтергә омтылалар. Дәүләтле халык булганнар янәсе, шәһәр культурасына нигез салганнар, мәгърифәткә ия имеш алар. Ачуы килеп, өстәлендә яткан бар китапны җыеп, чүп савытына томырды. Янә, вакыт табып, Карл Фукснын казан татарлары турындагы хезмәтләрен караштыра башлады. Бусы да ошамады. Немец нәрсә дип Казанны, татарны күтәрергә тырышкан, акылга сыймый иде. Анынча, татарлар затлы, белемле, тәрбияле кавем. Юк, тарихны үзләре язганча түгел, урыслар теркәп калдырганча өйрәнү муафыйк булыр. Алар инде халык аңын саташтырырлык нәмәрсәләр язып куймаслар. Кул астындагы "Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар" дигән китапны укый башлагач, бөтенләй шартлар чиккә җитте, атна буе җенләнеп йөрде. Михаил Худяков, чеп-чи урыс кешесе язган иде ул китапны. Ничекләр кулы күтәрелгән болай язарга?.. Һәм ни хакы бар—бер генә сүзенә дә ышанырлык түгел бит монын. Әгәр дә монда язылганнар дөрес булса... Уйлап кына кара—тарихчы үзенең сүзен "Казан ханлыгының чәчәк атуы" дип башлый. Дәүләтле, мәгърифәтле халыкны урыслар гына харап иткән икән. Баксаң, урыс кнәзләре, хәтта Дмитрий Донскойның варислары да, тәхет өчен бәхәскә килеп терәлгәч, артык даулашмыйча, Казан ханы Олуг Мөхәммәткә баш иеп килгәннәр икән. Хәл итеп бир, атакай, янәсе. Тегесе вәкарь белән генә боларны тыңлап, мәсьәләне гадел генә хәл итеп тә биргән. Каршы килүче юк, сүз куертучы юк, бүре дә тук, сарык та исән, берсенең башыннан ник бер чәч өзелсен. Барысы да риза, барысы да рәхмәт укый Олуг Мөхәммәткә. Вәт заманнар булган икән, ананны оргыры. Ул гынамы, Мәскәү патшасы Василий Казан ханында әсирлектә яткан икән, көч-хәл белән үзен кире акчага сатып алып, кире Мәскәүгә кайтарганнар. Анысы да Казан ханына рәхмәт укып йөргән ди. Бер җүнле ханнары булган, Шаһгали исемле, анысы күнеленә охшады Алемасовның. Һушлы кеше булган, Явыз Иван ягына чыгып, кыйраткан гына Мәскәүгә каршы төшәргә маташкан карулы татарның акыллы башларын. Чыккан бит шушы китап басылып. Укыган бит шуны халык. Урысы да укыган, татары да. Һм... мондый тарихларны әвәләп чыгара башласаң, татар кайчандыр югалткан дәүләтчелеген кире кайтару хыялыннан мәнге ваз кичмәячәк. Юкны югалтып булмый, барны юк итү җинел. Югалтканны эзләп йөрү—мәзәк тә, гыйбрәт тә. Әнә, НКВД подвалында яткан һәр татар милләтчесенен "эше" "бөек Туран дәүләте" дигән коточкыч сүзләр белән башлана. Инде яшәрлеге калмаганын аңлаганнары, чын-чынлап шушы хыялнын дөрес-

леген раслап, фәлсәфә саталар. Ну мәкерле халык, ә?.. Урысны баскынчылар диюдән дә тартынмаучылары бар. Кем диген, инде үлем ягасына килеп терәлгән, имгәнеп, сытылып, изелеп беткән әрвахлар шулай сөйләнеп азаплана бит.

Ул үзенең урынбасары Михайловка тиз арада Худяков дигән галим кисәген табып, каршысына китереп бастырырга кушты. Ежов хаклы булган, укуның зыяны тими икән кайбер чакта. Худяков бүгенге көндә илнең кайсы почмагында яшәсә дә, аның урыны Казан, "Черек күл" подвалы.Татарнын астына җитмешкә бөгәрләнеп кереп яткан бит, мөртәт. Сенерен сеңергә аерып, ботарлап бетерәчәк аны Алемасов, үз куллары белән ярачак, әмма язганнарыннан ваз кичтерми, тәүбә иттермичә калмаячак. "Урыс Шаһгалие" диде ул тешләрен шыгырдатып, Худяков дигән тарихчының аяк астында аунап ятуын күз алдына китереп, йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Ләкин аның куанычы кыска гомерле булды, Худяковны Ленинградта үткән ел кулга алып, "халык дошманы" буларак, тиз арада хөкем итеп, теге дөньяга озатканнар иде. Ә бит андагы чекистлар ашыкмаса, Алемасов Мәскәүне һушын китәрерлек бер эш оештыра иде. Хәер, Питер берчакта да Казан белән санлашмый инде, хәтта монда хәбәр дә итеп тормаганнар, ахры. Хәлбуки, андый кәгазьнең Алемасов кулына килеп кергәне булмады. Шуннан соң тарих укудан бизгән иде бизүен, менә бүгенге иртәдә шул укыганнар искә килеп йөдәтә генә, каһәрен.

Кремльгә карап алуга, башында тарих китапларында укыганнар бөтерелә башлады. Менә ул басып торган җирдән Казан ханнары үтеп йөргәндер. Ул көмеш кораллы җайдакларын әйт, ул алар менгән дөлделдәй атларны әйт, ул гаскәрне каршы алырга чыккан кызларның, хатыннарның сылулыгын, гүзәл тыенкылыгын әйт—йөрәкләр иләсләнеп китә болар хакында уйласаң. Атларнын корыч дагалары ташларга бәрелеп очкыннар чәчри, урамга чакматашны нәкъ шуның өчен юри җәйгәннәрдер әле! Тояк астыннан ургылып чыгып чәчелгән очкын гаскәрнең куәтен, какшамас рухын күрсәтеп торырга тиеш булгандыр! Булган бит андый дәверләр, булган. Казан дәүләте ни дип сорасалар, ул—гөлгә күмелгән калалар, киекләр уйнаган матур аланлы калын урманнар, балыклар мыжлап торган көмештәй елгалар, тук башаклар чайкалып утырган басу-кырлар иле; бөтен Ауропаны таң калдырырлык таш калалар төзегән осталар, игенчеләр, һөнәрчеләр иле; дөньяның иң бай илләре белән сәүдә итүчеләр, кая барып чыкса да тылмачсыз аралашкан акыл ияләре иле! Тарихчылар шулай яза. Ничек мондый дәүләтчелекне кайтару турында хыялланмасын башында акылы булган кеше! Мондый дәүләткә хан, патша булу да ярый торган эш, ананны корт чаккыры. Бүген дә Татреспублика төшеп калганнардан түгел. Хан булмаса да, Алемасовның биләмәсе бу, ул хаким монда, аның рөхсәтеннән башка Татарстан дигән җирдә яфрак та селкенми һәм шушы хакимлек хисе аны ләззәтле кичерешләргә дучар итте, бу хис шундый татлы-рәхәтлектә оета, күнелдәге бая уянып өлгергән авыр ташларны эретә, инсәне баскан йөк каядыр тирән бер чонгылга очты кебек, барысы да әйбәт, һәммәсе шәп, шуны раслагандай бөтерелә-бөтерелә ак кар ява башлады. Казан кары Мәскәүнеке түгел инде, анда әрсезләнеп ярма коела өскә, монда ак канатлы күбәләкләр бөтерелә һавада. Алар талгын гына иннәргә килеп яталар, сак кына биткә бәрелеп иркәлиләр, керфекләрне сыйпап үтәләр. Әх, яшәү шәп! Менә шулай, татарларым. Түт-тү сезгә дәүләтчелек, түт-тү сезгә тарих! Тарихны сезгә Алемасов алтын тышка төреп үзе китереп тоттырыр, җәме!.. Иң дөрес тарих, иң яңа тарих, тузан кунмаган тапсыз тарих булыр ул, иеме?!. Кысыр хыялларны баштан чыгарып атыгыз да, эшкә, эшкә, шайтан алгырлары!

Ул җәяү атларга ниятен онытып, җәһәт кенә машинага кереп утырды...

...Шундый хыялый хисләргә бирелүенә бераз эче пошып, Алемасов кәнәфигә чумгач эченнән үз-үзен битәрләп алды. Кемдер аның уйларын укып, барысын да язып барган шикелле тоела иде. Бигрәк тә үзен хан

урынында күрәсе килү тойгысы тилелек дәрәҗәсендәге нәрсә. Ни дип кирә андый уйлар башка!? Арудан инде ул, җүнләп ял күрмәгәннән.

* * *

Чыннан да, бирчәеп каткан җанны җылытырлык мәлләр аз булды бу көннәрдә.

Бүгенге иртәдә исә көндәлек мәшәкатьләрдән шадраланып-җөйләнеп беткән җаны хискә бирелеп, җепшенде дә куйды. Их, гел менә шундый рәхәт хиссияткә йотылып кына утырасы иде... Шулай уйлап бетермәде, өрфиядәй җиңеләеп, пәрәвездәй тартылып үтә нечкәлек чигенә житкән нәзберек күңелен яньчеп, сытып телефон чылтырады. Кабинет хуҗасының йөзенә чиләге белән салкын су бөркеделәрмени—битенә ямьсез тимгелләр йөгерде, карашы каешланды, нииндидер шомлы хәбәр көткәндәй муенын таушалган кәчтүн эченә җыера төшеп, каударланып трубкага үрелгән иде, кисәк үзенең кемлеген, кайда утырганын исенә китереп булса кирәк, йомшак күн утыргычының артына авып, вәкарь генә каш астыннан киң һәм иркен кабинетын айкап алды. Аннан тәмам үз халәтенә кайтып, иртә таңнан телефон чылтыравын туры үзенә юллаган, шул сәбәпле татлы уеннан бүлдергән ахмак сәркәтибенә җен ачуы чыгып, инде яртылаш трубкага үрелгән кулын, кискен хәрәкәт белән читкә селтәп җибәрде. Бармак очы тиеп, җай яткан трубка аппарат өстеннән чак очып төшмәде—сәер шыңгырдау авазы чыгарып кире үз урынына кунды. Газаплы аваз кебек тоелды аңа әлеге сулкылдаган тавыш, ни сәбәптер күңеленә рәхәтлек таралды. Шулай да сәркәтибенә кабынган ачуы сүрелмәде.

Кабинетына керә-керешкә үк йокысыннан айныр-айнымас утырган сәркәтипкә:

—Мин юк!..—дигән иде бит инде. Нәрсә җитми тагын? Бу сүзләрнең ни-нәрсә аңлатканын белмиме сөрхәнтәй?! Ул бар, әмма ул юк. Татарлар әйтмешли, Хозыр Ильяс кебек, ягъни... Исең китәр өлкә комитетында эшләүче бу татар түрәчекләренә. Бер сүз сөйли башласалар, һичшиксез, мәдрәсәдә укыган дини китапларыннан мисал китереп, сүзләренең асыл максатын ассызыклап кыланган булалар. Имеш, алар буш сүз сөйләми, борынгыдан килгән акылга таянып фикер йөртәләр. Имеш... Төптән уйлап эш өертә татарлар, һәр сөйләшүдән соң үзеннән аларга караганда, һәм белем ягыннан сайлыгын чамалап, һәм тормыш итү тәҗрибәсенең житенкерәмәвен сизеп, котырыр чикләргә килеп терәлгән вакытлары аз булмый. —Ишәк...—диде ул теш арасыннан, ярсуын тыя алмыйча янә сәркәтипкә ябырылды.—Бүген үк артына тибәргә кирәк бу агач бүкәннең.

Ял итәргә вакыт юк инде аңысы. Шулай да җаны теләгәнчә итеп гомер үткәрүләр булмый түгел. Менә үткән төнне дә нинди матур сәхифә язылды аның гамәл дәфтәренә! Ширә булмаса нишләр иде ул, ә? Бөтен борчуы, җанын талкыган көндәлек мәшәкать, кысыр хәсрәтләрдән шушы бөтерчек кызый гына аралап ала бит. Аны уйласа, шундук тәне кызыша башлый. Фәкать мәхәббәт, сөю, сәгадәт өчен генә яратылган бу кызыйны дисталәгән чибәрләр арасыннан сайлап үзенеке итә алуына бик тә канәгать иде ул. Сөешү мәсьәләсендә татар кызларына беркем җитми икән! Ул татлы киерелеп куйды. Үзләре куркак, үзләре йомшак, хисләре кабынып китсә дә, акылларын югалтып бетермиләр. Инде хатын-кыз затын күрмәде түгел, күрде, әмма Ширә башка инде! Кайчандыр үзенең күңеленә кереп калган кыз-кыркыннарны шушы татар кызыкае белән чагыштырып карый да, башын чайкап куя. Җир белән күк арасы. Тегеләр соң, бераз үзләшеп кенә алсыннар, минуты белән барлык чикләрне җимереп ыргыталар. Ихахайлап өстенә ташланучы, оятсызларча шашынучы, хайвани дәрт белән бәргәләнүче сары чәчле Наташа, Марья, Ниночкалардан шушы татар кызының тыйнак яратуы мең мәртәбә артык шул. Шуна күрә Разумов Татарстаннан бик авыр кубарылгандыр да. Китәргә теләмичә шактый карышып маташкан диләр бит.

Татарлар һәр якка да булган халык икәнен, республикага эчке эшләр халык комиссары итеп җибәрелгәнче үк ишетеп белә иде, инде менә үз күзләре белән күрде, тәне белән дә татып карады.

Ширәне ул җәй көне, комсомол өлкә комитетында үткән бер җыелышта күрде. Кайсыдыр заводтан комсомол активисткасы буларак чыгыш ясауны аңа тапшырганнар иде. Кыз трибуна артына каушап чыкса да, кәгазьгә карамыйча диярлек, әйтәсе килгәннәрен җиренә җиткереп сөйләп чыга алды. Чыгышны әзерләүчеләр нык тырышканнар, кыз социализм төзүгә комачаулык итүче "халык дошманнарын", урындагы пошмас житәкчеләрнең тетмәсен тетеп ташлады. Кызның төс-кыяфәтен күрүгә үк президиумда утырган Алемасов, сизмәстән, чыгыш ясаучының исем-фамилиясен алдындагы кесә дәфтәренә теркәп тә куйган икән. Хәбипова Ширә, эшче-комсомолка, яшь стахановчы.

Җыелыш бетүгә өлкә комитеты секретаре Мөхәммәтҗановны эзләтеп таптырды һәм икеле-микеле сөйләшүгә юл калдырмыйча, кызга чыгышны кем язып биргәнен белешергә кушты. Мөхәммәтҗанов, гомердә булмаганча, ни сәбәптәндер, бер мәлгә югалып калды, бераз уйланып торганнан соң, ныгый төшеп:

—Чыгышны кем язганын әйтә алмыйм, әмма тезисларын эшләүне Дәүләтъяровка тапшырган идек,—дип, ярып салды.

Алемасов сизенде, Мөхәммәтҗанов шомарып баручы партия работнигы, югары даирәдә уеннарның ничек оештырылганын яхшы аңлый, республикада үз позициясен ныгыту ягын да кайгырта килә—тирәсенә белемле, тыңгысыз, әмма сүздән чыкмый торган яшь кадрларны туплый. Татреспубликада егетнең абруе көнләп түгел, сәгатьләп үскән чаклары да булган. Моны Алемасов яхшы белә, ник дисәң, Лепаны Татарстан өлкә Комитетыннан алып ыргыткач, Мәскәүдә Мөхәммәтҗанов кандидатурасына тукталырга да уйлаганнар берара. Моны Алемасовка Маленков сер итеп әйтте. ҮК утырышында политбюро әгъзаларыннан кайсыдыр Мөхәммәтҗанов фамилиясен ычкындырган, имеш... Әмма Сталин орлыкны кибәктән яхшы аера. "Татарстанда ӨК беренче секретаре һәм эчке эшләр халык комиссары булырлык милли кадрлар үсеп житмәде әле,"—диган ул бу фикерне ишетүгә, кырт кисеп.—Совет властеның беренче елларында шушы мәсьәләгә ныклы фирка позициясеннән торып якын килмәгәнгә авызны пешердек тә бит. Кайбер иптәшләр шушы мөһим нәрсәне оныттылар булса кирәк..."—дип, кабат Мөхәммәтҗанов фамилиясен атамаслык иткән.

* * *

Кибәк дисәң дә, кем кем, әмма Мөхәммәтҗанов кибәк баш түгел, Алемасовның чибәр Хәбипова хакында юкка гына сорашмавын чамалый иде. Чыгышына караганда, кызның үзен охшатты бу әрсез Мәскәү әрләне. Шулай да чыгыш та охшады Алемасовка, киресе булса, яңа түрәнен Хәбипова турында сорашканда йөзе балкып торыр идеме? Мөхәммәтҗанов уенның җеп очы үз кулында икәнен аңлады. Әлеге моментны үз позициясен ныгытуга файдаланып кала алмаса, аннан тавык көләр иде. Шуңа күрә, икеләнмичә, Дәүләтъяров фамилиясен атады. Югыйсә, Ширә Хәбипованың үзен дә, өлкә комитетында аның чыгыш ясарга тиешлеген дә соңгы айларда гына "Кызыл Татарстан" газетасының җаваплы редакторы итеп расланган Әхмәтсафа Дәүләтъяров белмәгән дә иде. Әмма форсатны ычкындыру гафу итмәслек хәл иде. Хәбипованы Мөхәммәтҗанов яхшы белә, комсомолка-ударник, чор идеалларына ышанып, үзе кебек бер активист егеткә уңышсыз кияүгә барып кайткан яшь хатын иде. Гаилә тормышы барып чыкмау сәбәпле, язмыш тарафыннан йөрәкләренә яра ясалган яшь хатыннардан хезмәт алдынгысы, җәмәгать эшлеклесе, активистка ясау кулай. Билгеле, мондый типтагы активисткалар үзләреннән ни-нәрсәләр таләп ителгәнен чамалый алырлык акылга да ия иделәр. Хәбипова акыллы кыз иде. Җые-

лышта Алемасов катнашачагын, инде анын Лепа урынына беренче секретарь булырга тиешлеген яхшы күзаллаган Мөхәммәтҗанов Хәбиповaны бик вакытлы уенга кертеп җибәрде һәм теләгенә иреште дә. Кыз хакында сорауны ишеткәч, аптырап, югалып калу галәмәте күрсәтүе анын кыланып маташуы гына булса да, моны Алемасов табигый кабул итте.

—Дәүләтъяров?..—диде Алемасов күптән көтелгән исемне ишетүенә куанган сыман.—Беләм, Бауман райкомы конференциясендә ясаган чыгышын дикъкать белән укып чыктым, хәзерлекле иптәш күренә...

—Әйе, райком секретаре Разживинга әлекте ул чакта безнең егеттән.—Мөхәммәтҗанов "безнең" сүзенә басым ясап әйтте һәм Беренченең күзенә туры карап алды.

Алемасов Мөхәммәтҗановны аңлады кебек...

## II

Утыз җиденче елның маенда үткән Бауман партия оешмасы конференциясендә ясаган бу чыгышны Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров оештырганнар иде. Үзәк комитет көн саен "халык дошманнары"н фаш итүдә җирле партия органнарының сүлпән эшләвен күрсәтеп торганда, беренче секретарь Альфред Лепа белән халык комиссарлары советы рәисе Кыям Абрамов әлеге мөһим чараны тормышка ашыруда югалып калдылар шикелле. Дөресен әйткәндә, Лепа белән Абрамов ҮК кубарган вакытлы шаукымга бирелеп, кадрларны харап итмик диебрәк эш йөртергә исәп тоттылар булса кирәк. Мөхәммәтҗановның нияте башкарак иде. Әгәр шушы сәяси кампаниядә үзен күрсәтмәсә, киләчәктә нәрсәгә өмет итә алачак ул? Әйтүе кыен. Шуна күрә саклык белән генә эшкә кереште. Форсаты да чыгып тора—районнарда конференцияләр башланды. Беренче нәүбәттә иң мәртәбәле саналган райком җитәкчеләренең берсе Разживинны селкетеп алу начар булмас иде дип уйлады ул һәм ялгышмады. Дәүләтъяровны чакырып ныклап сөйләште. Йоклап калсак, таптап үтәчәкләр безнең өстән дип тә кисәтте, мисаллар исә җитәрлек иде—кичә генә кул бирешеп, хәл-әхвәлләр сөйләшеп торган дустың саналган кешенең икенче көнне "халык дошманы" булуын ишетеп өнсез каласың. Башны кибән астына тыгып ятар чак түгел. Акылны эшкә җигеп, һөҗүмгә күчәргә кирәк.

—Җитәкчеләр нинди фикердә?—дип сорады Әхмәтсафа, әңгәмәдәшенең үзен гайре эшкә тартып кертергә чамалавын аңлап.

—Нинди җитәкчеләр?—диде сорауны аңламаганга сабышып Мөхәммәтҗанов. Аннан Әхмәтсафаның колагына пышылдады,—Лепа белән Абрамовны әйтсәң, алар инде үтелгән этап. Сәясәт икеләнеп торучыларны яратмый. Әзиләрнең (үзеннән өлкәннәргә дә, яшьрәкләренә дә мишәрчәләп "әзи", ягъни абзый дип эндәшергә ярата иде ул) җырлары җырланды булса кирәк, шулай сизенәм. Безгә мөстәкыйль хәрәкәт итәргә кирәк, әмма алныартны бик нык уйлап. Без өчәү—син, мин һәм... Әхмәров... Вакыйгаларны кирәккәндә хәрәкәткә китерә алырлык, кирәксә туктатырлык рычаг безнең кулда булырга тиеш. Шушы юнәлештә эш алып бара башларга вакыт. Калганын Әхмәров белән серләшерсез.—Мөхәммәтҗанов кинәт колак төбенә үк иелде.—Безнең бүгенге сөйләшүне кабергәчә сер итеп сакла!

Чыгышның караламасын әзерләү Әхмәровка йөкләнде. Мөхәммәтҗанов үзенә тиңнәрне сайлауда дөрес юлда иде, Дәүләтъяров монарчы Минзәлә, Кызыл Йолдыз районнарында эшләп чыныгу алган җитәкче, тормышны яхшы белә, докладта күтәрелгән һәр мәсьәләнең төбенә төшми торып, трибуна артына чыгып басмаячак иде. Оренбур Каргалысында туып, балигъ булган егет белән Чүпрәле районына кергән Татар Бизнәсе авылында туып-үскән Галим Мөхәммәтҗановның серләре килеште. Галим кискенрәк холыклы, дуамалланып, таякны артык бөгеп ташларга ярата, ана эшнең

нәтиҗәсе тиз күренсен, ни гамәл кылса да шауларгарак ярата. Әхмәтсафа исә тыныч, сабыр кеше, кайбер кыенлыкларны уен-көлке белән дә үткәреп җибәрә белә. Галимгә нәкъ менә шундыйрак егет кирәк тә инде. Әхмәтсафага таянырга була. Ул—аспирантурада белем алган, югары уку йортларында студентларга сабак биргән коммунист, сыйнфый көрәштә чыныккан большевик. Бераз киреләнсә дә, ныклап карышыр җае юк. Чөнки Дәүләтъяровны Казанга кайтартуда Галимнең дә өлеше бар.

...ТКУда укыганда танышканнар иде алар. Татарстандагы җитәкче работникларны, белгечләрне берәм-берәм “дошман” ярлыгы тагып чүпли башлагач, кадрларга кытлык килеп туды. Китап нәшриятында сәяси әдәбиятны тәрҗемә итү эше аксый башлады. Бу өлкәдә тәртип урнаштыруны, нәшриятны яшь кадрлар белән ныгытуны өлкә комитеты Мөхәммәтҗановка йөкләде. Тәрҗемә эшендә Әхмәтсафаның азмы-күпме тәҗрибәсе бар, шуны искә алып, Дәүләтъяров белән күзгә-күз карап сөйләшү өчен махсус рәвештә Кызыл Йолдыз районына сәфәр чыкты Галим Мөхәммәтҗанов. Алдан киләсен хәбәр итүен итте, ләкин Дәүләтъяров аны райком бинасында көтеп тормаган булып чыкты. Ул көч-хәл белән басудан эзләп тапты Әхмәтсафаны. Райкомның икенче секретаре кулында—тәрәзә рамына охшаган нәмәрсә. Хатын-кызлар урак ура, Дәүләтъяров җитди эш башкарган кыяфәттә әле бер, әле икенче кишәрлеккә килеп, урылган мәйданга шушы раманы болгап ыргытып җибәрә. Агач рама кайда барып төшсә, (аның төгәл күләме—бер квадрат метр иде) шуның эчен җентекләп тикшереп карыйлар, коелып калган башак юкмы, булса, ничә бөртек? Котлы Бөкәшнең колхоз басуында иде бу хәл һәм ул елларда киң таралган контроль ысул—районнан килгән вәкилләр урак уручы хатынның бер квадрат мәйданда башак калдырукалдырмавын тикшереп йөриләр иде. Сыңар башак табыла калса, шунда ук чарасы да күреләүнмаган бичә өенә кайтмый ул көнне, караңгы төшеп, эш тукталгач колхоз идарәсе базына ябып тотылырга тиеш иде. Шул рәвешле сыйфат өчен көрәш тормышка ашырыла, уракган арып-талып кайткан хатынкайлар базда бераз “тын алгач”, төнгә өстәмә эшкә чыгарылалар. Бер башак өчен—бер төн өстәмә эш, ике башак өчен—ике төнне йокламый эшләргә тиеш, инде башак саны өчкә җитсә, кырда ук аңа суд ясалып, ике-өч ай төрмәгә дә ябылырга мөмкиннәр иде. Бу вакытта бичара хатынның бала-чагасы, гаиләсе нишли—анысын уйлап та тормыйлар иде.

Эссегә чыдар әмәл юк. Яңгырлар озак яумый торып, шактый өлкәләргә ачлык килү куркынычы яный. Украина инде бүгеннән үк чаң суга башлады. Кайберәүләр утыз алтынчы елны егерме беренче елгы ачлык белән дә тиңлиләр. Шуңа күрә әрәм-шәрәм итүләргә каршы кискен көрәш башланды. Котлы Бөкәш басуларында, шөкер, уныш бөтенләй үк юк түгел. Галим машинадан төшкәч, балачактан ук калган гадәт буенча, кояш астында әлсерәп утырган нәзек буынлы, кыска башаклы арыш учмасын алып, кулында уып мәшәләнде. Шулай да, коры эсселек нәкъ балавыз чагында китереп сугып, бөртекләрне куырып өлгергән икән. Әкрен җил сабакта нык утырган арышын, бодаен каядыр алып китмәкче булып куалый да куалый. Бу якта басулар иркен, офыкка кадәр таралып яткан кырлар, җилгә карышмыйча, корылыктан котылырга теләп, каядыр еракка талпыналар кебек. Кама яклары энгергә төренеп, әлеге әлсерәүле халәтне көчәйтеп кенә җибәрәләр.

Дәүләтъяровның үз янына килеп җитүен сабырсызланып көтеп алды комсомолның өлкә комитеты секретаре. Ул Әхмәтсафага караганда өч яшькә кечерәк, әмма үзен аның алдында иркен тота. Ни әйтсәң дә, ВКП(б) өлкә комитеты әгъзасы, аңа өмет баглыйлар, үзе дә сынатмый, ышанычлы рәвештә алга атлый иде.

—Ну килештерәсең дә инде, Дәүләтъяров, нүжәли райкомда гына утырып булмый инде, ә?.. Кичә телефоннан ачык сөйләшкән идек ләбаса!

—Иптәш Вәлиев райком составын тулысынча колхозларга таратты.

Мөхәммәтҗановны каршы алырга кирәк дип, әйтеп караган да идем, үзем булам райкомда, диде.

—Анысына рәхмәт, каршы алды, синең янга озатырга кешесен дә тапты, тик мина үзең булса яхшырак буласы иде...

Галим райком секретаренең бөтен эшен ташлап, кулына шәкелтмә—агач рама тоткан булып, партия установкасын башка кешеләргә ышанмый, шәхсән үзе генә үтәп йөрүен килештереп бетермәде. Дәүләткүләм мөһимрәк тә эшләр бар бит, мондый пүчтәк нәрсә белән шөгыльләнү өчен аспирантура тәмамлау кирәкми, колхозның үз активистлары беткәнме, ачуың бер килмәгере. Билгеле, Дәүләтъяров та бу эшкә атлыгып тормый, әмма Вәлиев, райкомның беренче секретаре, Казаннан киләчәк кунаклар алдында нәкъ менә аның агач рама тотып йөрүен таләп иткәч, нишләмәк кирәк? Ул елларда сыйфат мәсьәләсе дигән булып, колхозчыларны җәберләүнең әллә нинди ысулларын, махсус "тәрбия" методлары куллану киң җәелгән иде. Авыл баласы булган Мөхәммәтҗанов моны да өнәмәвен сиздерәсе итте.

—Кыз-хатыннар артына тагылып йөргәнче, колхозларның техник куәтен арттыру турында уйларга кирәк, электрны эшкә җигәргә...

—Уйламаган кая инде, иптәш Мөхәммәтҗанов. Өлгереп буламыни. Житмәсә, быел бугаздан корылык дигән җаһил эләктереп алды. Әрәм-шәрәм итүдән куркып, булган ургычларны да чыгармадык. Кул белән генә урырга туры килә.

Галим дәшми генә тынлый биреп, янә басу эченә атлады. Кызыл Йолдыз районына килүенең максаты басу-кыр эшләре белән генә танышу түгеллеген, сәбәпнең тирәндәрәк булуын Дәүләтъяровка иплән кенә аңлатырга кирәк иде. Ул республика күләмендә үз урынын ныгытырга омтыла, мондый чакта янында таянырга ныклы дуслар булуы шарт, картлар әйтмешли, этсез куян тотып булмый, дусларны барларга, читтәгеләрен Казанга жыярга, тупларга дип йөргән көннәре. Урындык өчен көрәш гаҗәп нәрсә ул, аяусыз, миһербансыз көрәш, көрәштәшләр кирәк аңа. Искәрткәнчә, Котлы Бөкәшкә нәкъ менә Әхмәтсафаның кылларын тарткалап карау нияте белән килеп төшкән иде һәм ялгышмады.

Дәүләтъяров Казанга кайту турында сүз кузгалгач, уйланып торды да:

—Шуның өчен генә килдегезме Котлы Бөкәшкә,—дип, Галимгә сынаулы караш ташлады.

—Гаҗәпме?.. Минем тәкъдимне бөтен яктан да исәпләп карасаң, вактөяк эш артыннан килмәвемне үзең дә төшенерсең, брат.

—Сәяси әдәбиятны тәрҗемә кылу никадәр мөһим эш икәнен яхшы беләм мин, сүзем ул хакта түгел—Казанга кайту минем теләктән генә тормый бит әле. Иң авыр вакытта районны ташлап киттең, димәсләрме?

Галимнең коргаксыган иреннәренә елмаю кунды.

—Аптырама, брат, Мөхәммәтҗанов алынган икән, андый сүзләргә тиз заслон куярбыз. Миңа синең фикерне белү кыйммәт иде. Каршылыгың юк икән, бер атнадан юлга жыена башла. Балаларыңа—бакча, хатыныңа да эш табылыр.

Әхмәтсафаның йөрәге жилкенеп типте.

—Мин риза...—диде ул хискә бирелеп. Ни өчен жанында хисләр давылы уйнавын, бик үк аңлата да алмас иде. Жан тартмаса, кан тарта диләр, Казанга тартылу да борынгыдан килгән бер теләк, табигый бер хистер инде ул.

Галим Әхмәтсафаны кочаклап алды. Аның исәбе гади—үзен колхоз тормышыннан аралап Казанга чакырып кайтарткан кешене Әхмәтсафа тиз онытырга тиеш тә түгел. Ул игелеккә игелек белән жавап бирә белә торган инсафлы егет. Моңа Галимнең иманы камил иде һәм соңга табан әлеге исәп тулысынча акланды.

...Әхмәтсафа Казанга кайтуга яңа вазыйфага жиң сызганып кереште. Югалып, жебеп калмады, тирәсенә сәләтле кешеләрне жыя башлады, яңа

дуслар тапты. Таттосиздат директоры Әхмәров белән ул чорда аеруча якынаеп киттеләр. Әхмәровны озакламый Мөхәммәтҗанов үз янына, өлкә комитетына алдырды. Инде чират Дәүләтъяровта. Оста оештыручы буларак танылу алган бу акыллы, күндәм егетне Мөхәммәтҗанов мөмкинлек чыккан саен югарырак күтәрә торды. Әхмәров өлкә комитетына күчкәч, Дәүләтъяров Таттосиздат партия оешмасын җитәкли башлады.

Мөхәммәтҗанов Дәүләтъяровның һәртөрле яңалыкларга, шаукымнарга сак каравын яхшы белә. "Халык дошманнарын" фаш итү мәсьәләсенә дә шулай сакчыллык күрсәтә кебек. Галим бер яктан егетнең уйлап эш йөртүен хупласа да, нигездә, Әхмәтсафаның әкрен кыймылдавына эче поша иде. Аны ничек тә алгы позициягә чыгарасы килә, сәләтле кадр итеп таныйтасы килә. Шунсыз аны тиешле югарылыкка "тартып" менгезеп булмаячак дип саный иде.

Яз көне Таттосиздатта ВКП(б) ҮК нең февраль пленумы карарлары буенча җыелыш үткәрелгән иде. Ә карар, ныклап уйласаң, йөрәкләргә шом салырлык. Совет илен тыштан да, эчтән дә дошманнар сырып алган, тыштагы дошманга караганда эчке дошманнар мең мәртәбә мәкерлерәк тә, куркынычрак та. Шуңа күрә эчке дошманнар белән көрәштә коммунистик ныклык үрнәген иптәш Сталин үзе күрсәтеп бирде. Аның Тухачевский кебек иң явыз корткычларны фаш итә алуы гына да ни тора. Явыз Тухачевский шанлы Кызыл армиянең алтын баганасы булган кавалериягә ябырылды бит. Әйтергә генә ансат, аның сүзенә алданып, кавалерияне сан ягыннан киметеп, алгы сафка иләмсез, котсыз танк дигән нәмәрсәне чыгарсаң, илне бөлгенлеккә төшереп, бар көчне шушы тимер шайтанны эшләүгә тартсаң, кая барып чыгар иде Совет иле? Ярый әле Сталин янында Ворошилов, Буденный кебек какшамас рухлы каһарманнар бар, алар Тухачевскийның илне как таякка калдыруга юнәлдерелгән сәясәтен тиз фаш иттеләр. Бер танк йөз атны алыштыра, имеш. Алыштырыр бар, атны үрчетү өчен чыгым кирәкми дә диярлек, теләсәң менләп-менләп үрчи ул, айгырларың гына чыдасын. Ризык дисәң, печән, салам ягына килгәндә Рәсәй, шөкер, беркайчан да кытлык кичерми. Көньякта корылык булса, себер ягында күкрәп үсә печән, Идел буенда уңмаса, Кавказ ягында җитәрлек табып була. Ә танкка кәрәчинен тап, тимер-томырын ясап өлгер. Корткычлар танк эшли торган заводта диверсия ясап ташласалар, шымытыр башын тотып калырсың! Шул рәвешле ҮК пленумы дошманның никадәр мәкерле, астыртын икәнен күп мисаллар белән раслады. Инде урындагы дошман элементларны аяусыз фаш итәргә, идән асты тараканнарын якты дөньяга чыгару эшенә дәррәү күтәрелү кирәк иде.

Өлкә комитеты кушуы буенча, Таттосиздатта да арадагы дошманнарны ачыклау эшенә керештеләр. Тәүге җыелышларның берсенә көн тәртибенә язучы Гомәр Галине тикшерү мәсьәләсе куелды. Җыелыш протоколын үзе алып карады Мөхәммәтҗанов, хәтта ки ныклап өйрәнде, шунысы мәгълум булды, бу документка карап фикер йөрткәндә, Әхмәтсафаны һич тә югарыга "төртеп" булмый иде әле. Кара инде, дошман тегерменәнә су коеп яткан Гомәр Галине вәч-бәрәмәч китереп бетерер иде берәү булса, ә Дәүләтъяров кызган коммунистларны суытып кына утыра. Фактлар җитәрлек, тетмәсен тетә алалар иде Гомәр Галинең. Җыелыш шул рухта башланып та китә әнә.

Коммунистлар турыга яралар.

–Гомәр Гали Такташның сайланма әсәрләрендәге кереш сүздә Троцкийга унай бәя бирде, моны иң явыз "халык дошманы" гына эшли ала!..

–1925 елда Берлинда контр Галимҗан Идриси белән очрашуын искә алыгыз, иптәшләр. Тапкан очрашыр кеше. Нәрсәләр сөйләде микән Гали бу немец шпионына?..

—Кайсы якка китереп басмасын, Гомәр Галинең аяк асты яна. "Халык дошманы" Гыйлемдар Баимбетов белән дус булуы гына да аның "дошман"лык дәрәҗәсен ачык раслый...

Гомәр Галинең хаталары ачылганнан ачыла, ә Дәүләтъяров ләм-мим.

Бу эштә кемгә таянырга соң? Гомәр Толымбай да Дәүләтъяров кебек саклык күрсәтә. Йә инде, шул да булдымы фаш итү?! Толымбайга сүз бирелгәч:

—Гомәр Гали ялгышларын үзе дә белә, төзәтү җаен да табарга тиеш,—дип, авыз эченнән ботка пешерә дә, шыплап урынына утыра.

Галинең ялгышларын санап, төзәтү юлларын кем әйтергә тиеш соң? Кызыл профессор сүзләреме бу? Исхак Рәхмәтуллинга рәхмәт, ул бераз кыдрачланып алмаса, җыелыш бөтенләй тешсез үтәр иде.

—Гомәр Гали белән Вәли Шәфигуллин уң группада катнашучылар,—дип күрсәтә ул—Шәфигуллин үзенең гражданнар сугышындагы заслугаларын пәрдә итеп куймакчы иде. Ярый әле органнар йоклап ятмый, тиз фаш ителде бу корткыч. Мәсьәләгә тагын да ачыклык кертик, Гомәр Галинең "Безнең юл" да Татарстан белән Башкортстанны кушарга кирәк дип язып чыкканын онытмадыгызмы? Даһи Сталинның милли сәясәтен Галичәләп тар-мар итәргә талпыну түгелмени бу пычрак адым? "Халык дошманы" Фатих Сәйфине яклап чыкканын исегезгә төшерегез. Йөрәк өши бит, иптәшләр, йөрәк өши... Мәхмүт Галәүнең әсәрләреннән өзек бастырып чыгарырга маташуы, инде дә килеп 1934 елда "Хисаметдин мулла"ны бастырыйк дип шаулап йөргәнен дә хәтерлибез, болар барысы да аның сәяси хаталанучы гына түгел, ә "халык дошманы"на әверелеп баруын күрсәтеп бирүче фактлар.

Дәүләтъяровның йомшаклыгы аркасында тәки җыелыш ныклап Гомәр Галине төзәтү юлына бастырмый, мәсьәләдән читләшә.

—Иптәшләр, фактларны ныклап тикшереми торып, карар кабул итү урынлы булмас...—дип бу мәсьәләне тикшерүгә нокта куя.

Нур Баянның Фатих Кәримгә каршы авыз ачып сүз әйтүе була, Дәүләтъяров, тегене шып туктатып, мәсьәләне бытовизм сазлыгына кертеп батыра. Имеш, Фатих Кәрим соңгы вакытта гонорарны мул каерган, шуңа кылтая, шуна инициативасыз йөри. Акчасы беткәч активлашыр әле, янәсе... Ә бит Фатих Кәрим "халык дошманы" буларак фаш ителеп, эшсез калгач, аңа кесә тутырып гонорар бирүче Дәүләтъяров үзе булып чыккан. Шулай инде, колхоз басуыннан килеп кергән кешене шәһәрдә тамыр җибәргән дошман элементларын тиз генә танырга өйрәтеп булмый торгандыр. Шамил Усманов та ныклы сыйнфый позициядә тормый икән. Аны гаепләп бер сүз әйтми. Ныклап уйланырлык фактлар бар—коммунист Җамал торып баса да җыелыштагыларга:

—Вәли Шәфигуллинның хатыны иренең халык дошманы булуына ышанмый, алай гына да түгел, "кулга алынганнарның барысы да гаепле түгел", дип сөйләнеп йөри,—ди.

Шартлау булырга тиеш иде бу сүзләрдән соң. Бу бит соңгы вакытларда колакка чалынып киткәләгән: НКВД бер гаепсез кешеләрне кулга алып, дошман ясый дигән контр сүзләрнең йөз процентка раслануы. Раслаучы бар, гаеплесе күрсәтелгән, бу фикергә таянып, җыелышның накалын алга үстерүче хет берәү табылганмы? Табыламы соң! Шушы сүзләргә каршы адәм рәтле сүз әйтүче юк, чынлыкта җыелыш, "халык дошманнарына" каршы көрәшне көчәйтәсе урынга, әлеге әһәмиятле чараны үткәрүче партия органнары эшчәнлегенә шик белдергән формада үтә. Менә бит ничек. Әгәр Дәүләтъяров кебекләрне активлаштырмасак, бу вазгыятьтә кемгә таянырга? Шуларны искә тотып, Дәүләтъяровтан кыю-кыю адымнар ясатырга кирәк иде. Ә егет зиһенле, тәҗрибәсе бар, кул астына алып, иренмичә тәрбия итсәң, файдалы кадр булачак.

...Бауман районында үтәчәк конференциядә чыгыш ясарга дигәч, Дәүләтьяров каршы килмәде. Караламаны Әхмәров әзерләгән иде, аны янадан кат-кат карадылар. Әхмәров бер төнне Әхмәтсафаларның өенә үк килде. Төнгә кадәр һәр сүзне, өтерне тикшереп чыктылар. Кайбер чакта бәхәсләшеп, кызышып та киткәләделәр.

Абдулла Әхмәров яңа гына өлкә комитетының пропаганда бүлеген җитәкли башлаган кеше, Мөхәммәтҗанов алдында һич тә сынатасы килми иде. Шуңа күрә чыгышта саллырак фактлар алынырга, кырыс фразалар тулып ятарга тиеш дип саный, Дәүләтьяров исә йомшаграк тон сайларга маташа.

Ниһаять, чыгыш "тәртә арасына" кергәч, Әхмәров кайтып китте. Әхмәтсафа хатыны янына килеп утырды. Аның йокысы качкан иде.

Рабига йоклап китә алмый ятты, бәхәсләрне ишетеп торды, шуңа күрә җаны тыныч түгел иде. Иренең күңел халәтен аңлап, үзе дә торып утырды.

—Ник йокламыйсың, Рәбуш?—дип, Әхмәтсафа хатынын кочып, күкрәгенә кысты. Рабиганың җылы тәне әллә нинди рәхәтлек бирде.

—Куркам мин, Сафа. Нәрсәдер булыр кебек безнең белән...—Рабига аһылдап иренең күкрәгенә капланды.—Туйдым мин Казаннан, Котлы Бөкәштән кайтмасак...

—Җүләр сүз сөйләмә. Илдә көрәш бара. Аяусыз көрәш... Моннан бер генә кеше дә читтә кала алмый. Котлы Бөкәштәме мин, Базарлы Матактамы, Минзәләдәме, көрәшнең алгы сафында булырга тиешле кеше.

—Кем белән көрәшергә инде? Бөтен танылган язучылар "дошман"га әйләнеп беттеләр.—Рабига балалар Үзәк китапханәсендә эшли иде.—Кайчан гына Садри Җәләл, Сәйфи-Казанлы китапларын чыгарып яндырган идек, кичә Кави Нәҗмигә чират... Кави Нәҗми кызыл командир дип йөрдек. Аны да "дошман" диләр. Ахыры бармы бу эшнең?.. Минем баш җитми монда.

Әхмәтсафа хатынын тынычландырырлык сүз эзләп, бераз тын торды. Иплән кенә, кечкенә балаларга аңлаткадай сүз башлады:

—Беләсең бит, социализм ныгыган саен, сыйнфый көрәш отыры көчәя генә бара. Иптәш Сталин шулай дип өйрәтә...

—Син шуңа ышанасыңмы? Социализм тулысынча җиңде бит инде, әйеме?

—Әлбәттә, җиңде...—Рабиганың саксыз сүзләр ычкындыруын өнәмичә, аны кочагыннан ычкындырды.—Ятыйк булмаса, таң ата озакламый.

—Мине тынлыйсың килми инде синең...—диде, Рабига үпкәләгән сыман.—Акыллы булгач әйт алайса, ил тулы "халык дошманы" шартларында ничек җиңеп чыга алган соң социализм.

—Үзең үк әйттең ич, "җиңеп чыгу" диден. Фәкать көрәштә, аяусыз көрәштә яуланган җиңү бу. Син шуны хәтереңдә сеңдер һәм... мингерәүләр сүзен сөйләп йөрмә! Андый сүзләр ишетелгәли ул, дөрес бәя бирергә кирәк.

—Башка кешегә үз уйларымны чишә торган хатын түгеллегемне беләсең!—Рабига юрган астына кереп чумды. Соңгы сүзләрен чак кына ишетеп калды Әхмәтсафа.—Әхмәровларга да ышанып бетмә, диюем. Менә сез кемнәр хакындадыр тозлап-борычлап чыгыш ясамакчы буласыз. Кайдадыр кемдер синең турыңда шундый чыгыш хәзерләп утырса?

—Минем турыда? Ни өчен?—диде гаҗәпләнеп Әхмәтсафа.

—Белмим шул...—Рабига ыңгырашып, стена ягына борылып ятты.—Куркам мин. Синең өчен, балалар өчен куркам...

Иртүк торгач, Әхмәтсафа чыгышны тагын бер мәртәбә карап, төзәтеп чыкты. Рабига белән булган төнге сөйләшү һич тә хәтереннән китми җәфалады.

Беренче мәртәбә тезисларын карагач, Мөхәммәтҗановның җен ачулары чыгып, Абдулла Әхмәров белән Әхмәтсафаны сүгеп ыргытты.

—Яхшы...—диде ул ачулы тавыш белән. Аннан кабынып ук китте.—Монда язылганнарны трибунага чыгып сайрадың ди инде, син, иптәш Дәүләтъяров. Шуннан соң нәрсә буласын беләсеңме?—диде кызарып-бүртенеп торган эшем ияләренә үтләрне сытарлык итеп карап. Шулай да бөтенләй чишелеп, теленә ни килсә, шуны әйтеп ташлаудан да тыела төште, әмма тәнен яндырып үткән ярсуын бөтенләй үк басып бетерә алмады.—Ни тозы, ни күзе юк бу чыгышның! Кемнәр язган моны? Укып чыкканчы өч мәртәбә исәңгерәп, хәл алдым. Шундый төче, ясалма чыгыш. Хет икегезнең берегез, шундый югары трибунадан торып ни сөйләргә тиеш икәнлегегезне чамалый алмадыгызмы? Менә сиңа ике коммунист, ике журналист. Сезнең ише тәти егетләрнең "безнең илдә ал да гөл, фәлән дә төгән" дип сөйләнеп йөрүләренә ышанып торсаң, шымытыр башы тоттырып китәрләр дошман элементлар. Ә бит тирә-якта, кая карама—контрэлемент, милләтче, алар тегермәненә су коючы сөрсеп беткән надан мыжлап тора. Барысы да караңгы бүлмәдә кара мачы кумакта. Ә сез? Йә, иптәш Дәүләтъяров, шушы бишек җырын көйләгәннән соң сиңа нинди караш булачак?—Мөхәммәтҗанов бөтен гәүдәсе белән каршысында утырган Әхмәтсафа белән Әхмәровка сузылды һәм тавышын кысып,—Әх-ти, егетләр, моменттан файдалана белмисез, тимер торыклы корыч коммунистлар түгел сез, салам сыйраклы агач коммунистлар!—дип, нигәдер күз кысып алды. Бу сүзләрнең төбендә зур сер ятканын аңлатырга теләгәндәй, өстәп куйды.—Җитәкчелеккә яшь көчләр кирәк, кулга-кул тотынышып эшләрлек ышанычлы иптәшләр кирәк. Бармы алар? Күп түгел, әмма бар. Сезнең белән мин шул күзлектән чыгып эш итәм. Иң югары постларда эшли алырлык яшь көчләр тәрбияләү җиңел түгел. Шулай да ара-тирә күзгә чалынганнарын мин җентекләп күзәтеп барам. Әлегә мин сезгә таянам. Ничек күрсәтерсез үзегезне иң кирәкле чакта, монысы вакыт эше. Аң булыгыз, гражданнар сугышы вакытында, аннан соңгы чорда түргә үрмәләгән надан, сатлык, тормыш диңгезе төбеннән мыштым гына өстәге хәлләрне күзәтеп ятучы сыңар күзле камбала мисле чиновниклар чоры үтеп бара! Мәскәү Татреспубликага туктаусыз кадр әзерләп ятмаячак, бер заман ул ачыктан-ачык ярып салачак: "Җитте, туганкайлар, кадрларыгызны үстерер өчен никадәр мөмкинлек бирдек, үз өегездә үзегез эш оештырырга өйрәнегез, кая кадрларыгыз, кая яңа буын җитәкчеләр, монарчы нишләп яттыгыз?"—диячәк ул. Шулай бит? Диячәк! Шул чагында аркаларыннан этеп, без кемне алга чыгарырга тиеш булабыз?—Мөхәммәтҗанов йөзендәге серлелекне зәррә кадәр дә җуймый, көлеп җибәрде.—Бүгенгә җитеп торыр... Башыгыз булса, калганын үзегез дә төшенерсез. Ә хәзер, әйдәгез, Дәүләтъяровның чыгышы хакында сөйләшик. Көрәш бара, рәхимсез көрәш бара,—диде Галим Мөхәммәтҗанов, ике кулы белән өстәленә нык итеп таянып.—Кем кемне? Сорау шундый итеп кискен куелган ки, башка әллә нинди уйлар килеп, тәннәр чымырдап китә. Сез фамилияләрне атамаска тырышасыз, томанлы фразалар белән сөйләргә азапланасыз, имеш, исемнәр атап, төзәтә алмаслык ялгыш китмәсен. Әйе, бу позиция сезнең өчен дөрес, ләкин мин әйткәнне колакка ныклап кертегез—тегермән әйләнә, ул беркемне дә аямый. Мин күрсәткән фамилияләрне трибунадан кычкырып әйтәсез икән, димәк, инде ул кешеләрне тарих чүплегеннән генә эзләргә кирәк дигән сүз. Йә инде алар кулга алынган, йә көннәре санаулы калган. Сезне аңлыйм, егетләр, кеше язмышы белән шаяру ярамый, тик безгә килеп терәлгәч, безне аяп торучы булыр микән?..—Галим күзен кыса төшеп бүлмә почмагына карап торды һәм арган тавыш белән дәвам итте.—Чыгыштагы бер генә сүз дә ике уйларга урын калдырырга тиеш түгел. Хәер, сезгә дә аңлау килер, тик соң булуыннан куркам...

Әхмәтсафа үзе дә бу хакта күп уйлана. Әмма сөйләшер, уйлашыр кешесе генә юк. Кемгә ышанып авыз ачып, сыңар сүз әйтергә белмәссең. Кешеләр торган саен эчләренә йомыла баралар. Кичә генә җир җимертеп эшләп йөргән кеше хакында иртәгесен гәҗиттә әллә нинди гөнаһларда

гаепләп мәкалә кисәге килеп чыга. Күпчелегенең авторы да, язганнарының мантыйгы да юк. Тисә тияккә, тимәсә ботакка кебегрәк. Ләкин шул мәкалә басылган гәжитне кешедән кешегә күрсәтеп чабулап йөрүче бер хөрәсән табыла. Сүз тарала башлый: утсыз төтен чыкмый ул, диләр... Күр син аны, эт койрыгыннан төз булып йөридерие, панимаешь, эче тулы б... булган икән. Иртәгәсен ул бичара хакында сөйләүче дә, үзен кабат күрүче дә табылмый инде. "Халык дошманы" булган икән теге кабахәт, япун шпиуны. Ярый әле арада бер уяу кеше табылып, тиз арада фаш итеп өлгергәннәр. Юкса, күрәселәребез булган икән. Һи, мәлгунь! Менә хәзер сиңа күрсәтәчәк сәвитнең гадел хөкеме! Теге гәжиттә мәкалә бастырган фидакарь затны эзләп табып, орден бирергә иде дә бит, безнең татар халкы тыйнак шул. Дошманны фаш итте, үзенең кем икәнен дә белми калдылар. Менә бу чын гражданин, чын сәвит кешесе, ичмасам. Бу инде хәйлә—акча белән теләсә кемне сатып алырга, теләсә кемгә яла ягып иманыннан яздырырга мөмкинлекне раслап маташкан, киләчәктә туачак үз ишләренә калын–калын инструкцияләр язып калдырган аксак Каратун ярчыгы түгел, ә чын намуслылык үрнәге, яңа чор кешесе! Дәшми, тынмый, үз эшен эшли бирә. Гәжитләрдә генә түгел, төрле дәрәҗәдәге җыелышлар да менә шундый "патриот"ларны үсендерү, бер-беренә яла ягу кебек түбәнлекне яңа чор әхлагының матур үрнәге дәрәҗәсенә күтәрү отыры көчәя бара. Мондый "җилкендерү" эзсез калмый, әлбәттә, бер-берсен сату, арадан "дошман элементлар"ын эзләү, фаш итү көннән көн кинрәк колач җәя.

Икәү генә калгач, Абдулла Әхмәров аңламаган рәвештә башын боргалап, сорау бирде:

—Нәрсә бу, Әхмәтсафа? Нинди җен котыртты сине?.. Безнең төне буе чәкәләшеп-тарткалашып язган чыгышның сөяк-санаклары гына калган димме сон? Ай-һай подводить иттен, малай. Бу кадәресен көтмәгән идем.

Әхмәтсафа дәшмәде.

* * *

Галим дөрес әйтә, Әхмәтсафа белеп бетермәгән нәрсәләр дә байтак. Иман сатарга өйрәткән аксак Каратуннар сафы ишәя, бигрәк тә халык җанынданиләр кайнавын киң гавамга ишеттерергә тиешле язучылар белән "эш" итәргә, алар арасына "Шома", "Пеләш", "Анакай", "Калайчы", "Күгәрчен", "Чыпчык", "Тузбаш" кебегрәк кушаматлар ябыштырылган яшерен агентлар җибәрелә тора. Шундый агентларның кайбер әләкләрен Мөхәммәтҗановка элекке НКВД халык комиссары Рудь күрсәтеп өлгергән иде. Үзенең астына су керә башлавын сизенгәч, Мөхәммәтҗановка никтер бер ачылган ул. Йә Хода, бу агентларның җитмәгән җирләре, ишетмәгән-күрмәгән нәрсәләре юк икән. Галим бу сөйләшүдән соң берничә көн ашаудан калып йөрде. Әйе, янында үзеннән дә ышанычлы кешеләр булмаса, авыз ачып сүз әйтерлек түгел икән бу илдә. Кем ышанычлы да, кем сатлык икәнен исә бер Ходай гына беләдер. НКВД монда да татардагы булган аерым сыйфатларны дөрес тотып алып, үз кирәгенә эшләтеп җибәрә алды.

Әйе, алар акчаны эшләп ала дисәң дә дөрестер. Максатларына ирешү юлында, үзләренә кирәк бәндәләрне меңнәр арасыннан тиз һәм оста табып алдылар.Теләсә кайда сөберелеп йөри торгач, ни туган нигезеннән колак каккан, ни якты иҗаты булмаган, өч-дүрт иргә, дүрт-биш хатынга җитеп, ахырда, гаилә җылысыннан коры калган, баласын тәрбия кыла алмаган, оныкларын багудан мәхрүм, әмма үзен дөньяның шәрә кендеге итеп тоюдан ләззәт чиккән, һәм "бер мин генә бөек, калганнар чүп, шуңа күрә мине генә күрегез, мине генә мактагыз, минем хакта гына языгыз, миңа исән чакта ук музейлар ачыгыз, минем кулым кагылган, артым чүмәшкән һәр нәрсәне җыйнап, туплап шунда тутыра барыгыз, киләчәктә чит илләрдән килгән пролетариат делегатларына революциянең башыннан-ахырына кадәр трибунадан төшмәгән, тиндәшсез талантын революция идеалларына исраф

иткән, үзе тамагы ач булган тәкъдирдә дә авызына бер бөртеген алмый саклап калдыра алган ниндидер сәер җонләпәч фиркави орлыкларны аягы кая басса, шунда чәчеп, аларның үсеп җитүен күрә алмыйча зар-интизар кылучы бер даһи татар язучысының ни дәрәҗәдә гади һәм скромно яшәп, иҗат иткәнен күрсеннәр, белсеннәр, телдән дә төшермәсеннәр иде" дигән вәсвәсәле бөеклек чиреннән рак авыруы гына котылдырса котылдарачак үчлекле, көнчел, хөсет бәндәләр барлыкка килүен күрү белән, аларны азындыра, ирәйтергә тотындылар, алар ярдәме белән дөньяга чыккан һәр сәләтле яшь әдипне төрмә ишеге артына озату әмәлен таптылар НКВД хезмәткәрләре.

Төрмәгә эләккәннәрне үземезнең татар егетләре—НКВДга керәп оялауларына шатланып-сөенеп бетмәүче, акылга саерак, әмма астыртын гамәлләр кыларга гаҗәп оста дистәләгән Хәйрулла, Баян, Миргазиян, Миңнулла ише "тикшерүчеләр", сексот вазыйфасын төп эшләреннән дә артык күрүче дистәләрчә вактин-вак бөҗәк мисле елак Ариф, хатынша Миңнечәмил, тынкыш Дакиретдин ише хаста җанлы бәндәчекләр ярдәме белән колак ишетмәгән, аң сыештыра алмаган эшләр оештыра башладылар һәм теге мәхбүсләргә бу ялалар шундый шәп килеп ябыштылар ки, якты дөньяга кире чыгу алулары мәңге ирешмәслек хыял гына булып калды.

Менә ни өчен борчыла Мөхәммәтҗанов. Менә ни өчен бәргәләнә. Ләкин боларның барысын да башкаларга ничек аңлатырга? Ул гаҗиз иде...

## III

Дәүләтъяров илдәге хәлләрне тойса да, бу эшләрнең төбендә ниләр ятканын аңлап бетерми иде. Илгә, халыкка, халыкның рухи дөньясына шушы өер китергән афәтне кем дә булса, кайчан да булса тулысы белән ачып сала алырмы?

Кая карама—фаш итү, кая карама—дошман, дошман... Якты көнгә ышаныч бетә бара. Күршедә яшәүче бер яхшы танышын әле кичә генә шактый югары пост биләп утыра иде, "Керәп чык, чәйләп алырбыз,"—дип, иркен эш бүлмәсенә кунакка да чакырган иде, баксаң, аның "халык дошманы" булуын ачыклаганнар, төннә килеп алып киткәннәр, ябып та куярга өлгергәннәр икән инде. Бусы чеп-чи немец шпиуны икән. Урам себерүче Кылый Бикә хәбәр итеп өлгергән. Сонга калса, ниләр булып бетәрие микән бу ил? Бичара илнең тышы тулы дошман, эче тулы дошман. Бөтен ышаныч—әнә шул элек атаклы фахишә булып йөргән, бүген элекке "хезмәтен" файдаланып, алдынгы пролетарка саналган Кылый Бикә ишеләрдә—алар йоклап ятмый, бәхеткә каршы, җин сызганып НКВДга, ягъни совет властена хезмәт итәләр... Бикә кебекләр исем яшереп тормыйлар. "Билдән түбән үземә дә ышанмыйм, берерсенә шигем генә төшсен, төн уртасында да чыгып чабам энкеведегә. Ичмасам, анда кайнар чәй эчереп җибәрәләр, өйгә машина белән китереп куялар. Бармас җирдән барырсын кабат",—дип, мактана икән Бикә үзе кебек урам себерүчеләргә. Моны Рабига ишетеп кайтып, кухняда кайнашканда шыпырт кына, әмма бик борчылып сөйләп алган иде...

Әхмәтсафаның да төсе үзгәрде. Кылый Бикә аларның ишек алдын да себерә бит, сак булырга кирәк...

* * *

Докладны әзерләп бетереп, икенче очрашканда Галим инде бераз тынычлана төшкән иде. Әхмәров белән Дәүләтъяров икесе дә ябыгып киткәннәрме соң, йөзләре суырылган, болай да аз сүзле кешеләр, бөтенләй тыңлап торуга гына күчтеләр. Теге чакта Мөхәммәтҗанов әйткәннәр хакында ныклап уйланганнар, эшнең никадәрле җитди икәнен аңлаганнар сыман иде. Күптән түгел генә өлкә комитетының икенче секретаре булып сайланган

Галим Мөхәммәтҗановның авыз ачып каласы килми, НКВД кармагына эләкмәү чарасын алдан ук күреп өлгерергә тырыша иде.

Кем кемне? Бу сорау Әхмәтсафага башта сәер тоелган иде, әмма вакыйгалар эченә тирәнрәк кергән саен, аның асылына төшенә барып, май аенда булып үткән партиянең Бауман райкомы конференциясендә ныклап ук аңлады.

Майның уночендә өлкә комитетының беренче секретары Альфред Лепа, Халык комиссарлары Советы рәисе Кыям Абрамов катнашкан әлеге партконференциядә Татарстан дәүләт нәшриятының баш редакторы һәм берүк вакытта анда партком секретаре да булып эшләгән Әхмәтсафа Дәүләтьяровны Мөхәммәтҗанов "тырышлыгы" белән президиумга тәкъдим иткәннәр иде. Казанга килеп эшли башлагач беренче мәртәбә дисәң дә була, аның исеме шундый зур җыелышта яңгырады.

Әхмәтсафа санау комиссиясе хисабын тыңлаганда үзен жайсыз хәлдә хис итте—бер сүз белән генә әйткәндә, фиркадәшләре аны "тәгәрәткәннәр" иде. Бу нәрсә дигән сүз? Районнар дәрәҗәсендә Мөхәммәтҗановның абруен какшатырга, аның белән санлашмаска азапланумы, әллә Дәүләтьяровны "обойма"га алырга иртә әле дигәнне аңлатамы? Әллә Лепа, Абрамовның фатыйхасы белән Мөхәммәтҗановка каршы хәзер үк уен-муен оештыра башлаумы? "Тәгәрәүгә" Әхмәтсафа артык әһәмият бирмәгән дә булыр иде, әмма тәнәфестә аны Мөхәммәтҗанов үзе эзләп тапты һәм бер читкә алып китеп, кайнарланып сөйли башлады:

—Күрдеңме, иптәш Дәүләтьяров, ниләр майтарып яталар? Коточкыч хәлләр монда тирәннән уйласаң...

Әхмәтсафа аны тынычландырырга омтылды.

—Мине әлегә күпләр белеп тә бетерми. Казанга кайчан гына кайттым бит. Сәбәбен шуннан гына күрәм...

—Сине белмиләрме? Җүләр булма, залда утыручыларның туксан проценты синең белән ТКУ да укыган, яки эш буенча яхшы танышларың. Сәбәп башкада—мин тәкъдим иткән бердәнбер кандидатураны "тәгәрәтү" сәяси мәсьәлә ул, брат.—Галим кайнарланып, йодрыгына йөткереп алды.—Миңа каршы килү бу, "кара шар" салып карадылар разживинчылар. Моның ахыры хәерле бетмәячәк.—Мөхәммәтҗанов әңгәмәдәшен читкәрәк сөйрәде. Аңына сеңсен дигәндәй, өзеп-өзеп сөйли башлады.—Чыгыш ясаганда нык бул, җебеп торма! Күрәсеңме, район ни хәлдә? Сәяси башбаштаклык хөкем сөрә райком аппаратында. Барысын туздырып ташларга! Бу сиңа партия директивасы. Разживинны он-талкан итәргә кирәк. Күр әле, керфек тә какмый, өлкә комитеты секретаре тәкъдимен аяк астына салып таптадылар диген, ә?.. Таттосиздатның фактик җитәкчесе, партком секретарен президиумга үткәрмәсеннәр инде! Лепа белән Абрамовны күзәтеп тордым, синең исем сызылганда балкып утырдылар, сизденме? Разживин алар булганга масая, имеш, таяныр кешеләре бар. Булмый торсын әле. Кем кемне, вот в чем вопрос?!. Ил алдында, партия алдында торган сорау менә ничек бөтен кискенлеге белән килеп басты алга... Ә син һаман малай-шалай кебек тотасың үзеңне. Алай булмый ул, брат, безнең эштә вак-төяк юк!

—Кандидатлар регламенттта каралганнан артык иде бит, кемдер төшеп тә калырга тиештер инде. Һәрхәлдә, мин моңа ул кадәр үк әһәмият бирү кирәк түгелдер, дип уйлыйм. Конференция эшлекле булырга охшаган.

—Кабатлап әйтәм, җүләр булма! Бүгенге көндә марксизм-ленинизм әдәбиятын тәрҗемә итүне үз кулында тоткан коммунистны, өлкә комитеты раслаган китап, брошюраларны дөньяга чыгару белән шөгыльләнгән зур оешманың партия комитеты секретарен санга сукмау—политик хата, хәтта җинаять ул! Йөз туксан тугыз кешенең илле тугызы сине яклаган, үзең уйлап кара, акыл иясе, өлкә комитеты позициясен райондагы партия әгъзаларының өчтән бере генә яклый дигән сүз бит бу. Калганнары ни уйлый, аларга нинди установка бирелгән? Лепа белән Абрамов үткән көн, аларга

ышыкланырга тырышу ахмаклык, безгә бүгенге хакында уйларга кирәк. Әйдәле, чыгышынны тагын бер мәртәбә карап чыгыйк, Разживинны үз урынына утыртмасак, бәябез сукыр бер тиен дә тормаячак. Безнең әле вакыт бар, синең чыгышны иртәгәге утырышка күчерттем.—Ул Әхмәтсафа кулыннан инде ким дигәндә ун мәртәбә төзәтелеп, ун мәртәбә кабат акка күчереп язылган чыгышны алып, ашыга-ашыга китеп барды.

Икенче көнне вакыйгалар нәкъ Галим Мөхәммәтжанов уйлаганча булып чыкты.

Әхмәтсафаның усал чыгышын Разживин күтәрмәгән иде булса кирәк, ул сөйләгәндә үзен шулкадәр уңайсыз хис итте ки, хәтта моны яшерер көче калмыйча, жинелчә калтыранып, яшелле-зәңгәрле булып утырды.

Дәүләтъяров чыгышында сүз райкомның дәүләт нәшрияты белән җүнле-башлы җитәкчелек итмәве, шуның аркасында киткән идеологик хаталар турында барды. Әхмәтсафа санап үткән фактлар инде берничә мәртәбә партия җыелышларында тикшерелеп, үзенчә чаралар күрелсә дә, Мөхәммәтжанов аларны трибуна артыннан кабатларга кирәк дип тапты. Хәлнең мондый борылыш алуы Разживин өчен генә түгел, хәтта Лепа, Абрамов кебек коммунистлар өчен дә үтә куркыныч иде. Чөнки шушы ук гаепләүләрне ике дә уйламыйча өлкә пленумына да өстерәп кертергә мөмкин иде Мөхәммәтжанов. Лепа белән Абрамов—карт бүреләр, Дәүләтъяров дигән яшь егетнең үз белдеге белән чыгып, трибуна артында шулай очынмавын яхшы аңлыйлар иде...

Бер Мөхәммәтжанов кына тыныч тотты үзен, чөнки ул бу постка күптән түгел сайлап куелган иде һәм Дәүләтъяров сөйләгән җитешсезлекләр аның өчен бөтенләй яңалык сыман, гел алга ята төшеп, үтә бер кызыксынган кыяфәт белән тыңлап утырды, ара-тирә алдында яткан кәгазьгә нидер язып маташты. Лепа берничә мәртәбә янында утырган Галимнең касыгына нык кына төртеп аласы килсә дә, бар ярсуын басып, тыелып калды. "Их, җүләр малай, тинтәк баш. Шундый катлаулы вакытта Ленин—Сталин әсәрләре тәрҗемәсендәге сәяси хаталар хакында сүз йөртәләрмени? Башкайларны себер җибәрәсең, агач чырай."

Әхмәтсафаның мондый уенда беренче һәм соңгы катнашуы, әмма бу чыгыш аның язмышын тамырдан үзгәртәсен ул әлегә күз алдына да китерми иде. Ул кәгазьгә язылганны сиптерә бирде:

—Татгосиздат барлык әдәби һәм марксизм-ленинизм әдәбиятын дөньяга чыгару белән шөгыльләнә,—дип сүзен дәвам итте Дәүләтъяров трибунаның ике канатына нык таянган хәлдә.—Әмма районның партия оешма секретарьлары Разживин һәм Долотказин моңа бөтенләй әһәмият бирмиләр. Культура фронтының бу направлениясендә алар инде бүген үк тулысынча тар-мар ителгән дип саналырга хаклы. Әле 1932 елда ук НКВД органнары иң беренчеләрдән булып Татгосиздатта Шәфигуллин һәм аның тарафдарлары булган контрреволюцион төркемне фаш итеп, кулга алулар һәм чистарту үткәрде. Ул чакта ук нәшрият сагидуллинчыларның оясы иде.

"Шәп,—дип куанды Мөхәммәтжанов,—беренче җөмләләре белән үк кадаклап куйды тегеләрне. Лепага кадәр җыерыла төште әнә. Абрамов, Байчурин ише "карт гвардия" моннан соң яшь көчләр белән санлашмыйча карасыннар инде! Дәүләтъяров тыйнаклык кына күрсәтә, асылда, аны Казанда яхшы беләләр. ТКУ каршындагы аспирантураны тәмамламас борын аны марксизм-ленинизм әдәбиятын тәрҗемә итү эшенә җигүләре үк әлеге фикернең нигезле булуын күрсәтә.

Ул чакта бу эшкә ни рәвешлерәк тартып китерүләрен Дәүләтъяров ана үзе сөйләгән иде.

Бер көнне аны өлкә комитетының пропаганда бүлеге мөдире Габдуллин чакырта һәм, җүнләп исәнлек тә алмастан, елардай булып Әхмәтсафаның борын төбендә бер китапчык болгап сөйләнә башлый:

—Күрәсеңме, нәрсә эшлиләр! Ни бу?! Зариф Насыйбуллин белән

Исмәгыйль Рәми, Мөхәммәт Галиләрне өчесен бер ботакка күкәйләреннән асып куярга кирәк! Эзләп табам, үз кулларым белән асам шул җирләреннән. Яшәрлекне калдырмадылар бит, җыен паразит. Совит акчасын ашап, бүксә бүрттереп яткан хәчтрүшләр.—Ул сүгенүеннән кисәк туктап, капылт Әхмәтсафа алдына килеп баса.—Беләсеңме син аларны? Гомумән, шушы китаптан чыккан сасы аркасында Татарстан өлкә комитеты нидн хәлдә калганын беләсеңме?

Мондый "һөҗүм"не көтмәгән Әхмәтсафа аптырап, дәшмәүне хуп күргән. Габдуллин санап үткән кешеләрне ничек белмәсен? Типография директоры урынбасары булып эшләүче Зариф Насыйбуллинны гына яхшылап белми. Ә Исмәгыйль Рәми белән Мөхәммәт Галине кем белмәсен ди? Берсе—танылган журналист, икенчесе—билгеле язучы.

—Беләсең, пычагым,—дип кызганнан-кыза бара икән Габдуллин, егетнең уйларын укыган кебек.—Менә кара, нинди китап чыгарып таратканнар бит халыкка, әдәм көлкесе. Мәсхәрә инде, мәсхәрә, партия каршында хур булдык.—дигән ул бераз сүрелә төшеп..

Сүз Тимофей Владимировның "Христиан дине—нәрсә ул?" дигән китабы хакында бара икән. Тышлыктагы ат башы кадәр хәрефләр белән ярылып яткан "Дин өчен көрәш—социализм өчен көрәш" дигән шигарьне укыгач, Әхмәтсафа көлеп җибәрә язган. Габдуллинның ярсуын аңларга була: әлеге китап өчен эләксә, иң беренче чиратта аңа эләгәчәк булган шул. Китапның редакторы Исмәгыйль Рәми, тәрҗемәчесе Мөхәммәт Гали икән.

—Тәрҗемәчеләр кирәк...—дигән Габдуллин йончыган тавыш белән.—Советча белемле тәрҗемәчеләр кирәк. Мәдрәсә сабагы алган Мөхәммәт Гали, Рәмиләр безне агач атка атландыралар болай булса. Сине чакыруның сәбәбе шул—җаваплы эш тәкъдим итәбез. Поповның "История ВКП(б)" һәм иптәш Сталинның "Вопросы Ленинизма" дигән китабын тәрҗемә итәргә кирәк. Партия заданиясе, ашыгыч эш.

—Үзем генә... башкарып чыгып булырмы. Бу эштә тәҗрибә бөтенләй юк бит... Үзегез күреп торасыз—эшләмәгән эштән шайтан көләр, ди.

—Эчемне пошырып торма әле, япь-яшь башың белән!—Габдуллинның сөйләшүен Мөхәммәтҗанов яхшы хәтерли. Хатын-кыз чәпчүен хәтерләтә иде кызып китсә.—Әнә, тәҗрибәле кешеләрнең кәлҗемәсен авыз иттек инде, җитеп торыр,—дигән Габдуллин Әхмәтсафаның икеләнеп калуын өнәп бетермичә.—Аң бул егет, бу бер яктан җаваплы, саваплы хезмәт булса, икенче яктан бәхет эше. Сталин әсәрен тәрҗемә итәргә кеше табылмас дисеңме? Табылыр, әлбәттә. Әмма без сиңа тапшырырга булдык бу эшне. Башкалар да ярдәм итәр. Ике мәртәбә килә торган форсат түгел, кадерен белеп кал.—Ул яңадан теге китапны алып баш өстендә җилпеп алган.—И-и, адәм страмы, иптәш Ярославскийга барып ирешсә бу хәбәр, кем... ничек... ничекләр җавап тотар? Кем булсын, мине җибәрәләр инде иптәш Ярославский хөкеменә, миңа күрсәтеп кайтара инде ул "кузькина мать" дигән хикмәтле әйберне... Хараплар иттеләр башкайны, иблис токымнары, ил белән "атеизм бишьеллыгы"на хәзерләнеп ятканда, мондый тома сукырлыкка барып җит инде. Билләһи газыйм, юри эшләтсәң дә, кыландырып булмас иде болай итеп. Кирәк бит, Татарстанның данын сатарга, республикада барган матур эшләргә шакшы коярга. Өчесен дә арестовать иткән ГПУ, менә хәзер җавап бирсеннәр инде. Алар белә кемне кайсы җиреннән асып куярга.

—Ялгышлык була инде ул...—дип сүз башлаган Дәүләтъяровны Габдуллин кырт кисә:

—Мондый эштә ялгышлык булмый, вредительлек кенә була, иптәш Дәүләтъяров!

Мөхәммәтҗанов ул чакта көлә-көлә тынлаган иде Әхмәтсафаны. Хәтта үзенә әйтеп тә куйды:

—Син бик яхшы хикәяче икәнсең. Тот та кәгазьгә төшер сөйләгәннәреңне!

Онытылып китүен аңлап, Мөхәммәтжанов игътибарын чыгыш ясаучыга юнәлтте. Дәүләтъяров накалны киметмәгән иде.

—Разживин кайчан күрсәң дә үзен эшем иясе кебек тота. Киңәшкә килсәң, ярым-йорты гына тыңлый. Ишетәсе килмәгән сүзгә күчсәң, әңгәмәне икенчегә бора, утырган урынында кыбырсый, чәбәләнә, кирәкмәгәнгә жикеренә башлый, шулай итеп гади генә мәсьәлә дә чишелә алмаслык төенгә әйләнә. Кузгатылган мәсьәләнең төбенә төшү турында уйлап та карамый. Колагына алдан кем нинди ялган пышылдап өлгерә, аның өчен ин дөресе шул. Контрреволюцион троцкийчы Рәхмәтуллин, Гыймранов, Шәфигуллин, Гомәровларга яна партия билетлары биреп чыгарганда кем сүзенә колак салган икән? Ә "халык дошманы" Шәфигуллин узган елның август урталарына кадәр Таттосиздатта партия оешмасы секретаре булып торган. Разживин кайда йөргән? Болар бит пүчтәк сораулар түгел, боларга жавап бирми хәле юк Разживинның.

Альфред Лепа янә бер мәртәбә ачу белән Мөхәммәтжановка караш ташлады. Галим, уйларына йотылып, борын очын сыпыргалап утыра иде.

—Без соңгы чорда нәшрият чыгарган китап продукциясен тикшереп, утыз дүрт исемдә дәреслекне чүпкә озаттык.—дип дәвам итте Дәүләтъяров.—Гомуми суммасы—жиде йөз мең сум. Мәсәлән, Сәлах Әтнәгулов редакторлыгында чыккан Бадыйков язган дәреслекне алыйк. Унжиденче битне ачып укып карыйк: "Карл Маркс, Сталин, стандарт, крахмал, крах, Марксизм, старик, Энгельс, элемент һәм башка шундый янәшә торырга һич тиеш булмаган төшенчәләр, аңлатмалар, төрләндерүләр белән шыплап тулган бу бит. Балаларның аңын бутау өчен моннан да кулай юл юктыр. Икенче бер дәреслектә "жете кызыл тиз уңа", "авызын ачса, үпкәсе күренә" дигән, әллә кайчан тарих чүплегенә очарга тиешле мәкальләр урын алган... Без мондый юл белән бара алмыйбыз!

Дәүләтъяровның чыгышы хупланды. Гөрләтеп кул чабулар астында ул үз урынына ничек килеп утырганын да сизмәде. Каушау галәмәте булдымы, ул инде башка чыгышларны ишетмәде. Хуплавын хупладылар чыгышын, әмма трибунадан төшеп, бераз утыргач, күңелен авыр уйлар биләп алды. Ярамаган эш кылган төсле хис итте үзен. Күз алдында исә Мифтах хәлфәнең томанлы шәүләсе йөзә, таягын күтәреп Әхмәтсафага табан селки-селки килә кебек, үзе көйгә салып бер үк сүзләрне кабатлый: "Алай түгел бит инде, болай түгел бит инде, үзегез чокыр казыйсыз, үзегез төшеп бетәсез бит инде!"—Әхмәтсафа Мифтах хәлфәнең:—"дөрес, әмма алай түгел ул," дигән сүзләрен шулкадәр ишетергә тели, түземсезләнеп көтә. Ләкин хәлфә һаман үзенекен кабатлый: "Алай түгел бит инде, болай түгел бит инде, үзегез казыган чокыр...Их!.."—диде дә Мифтах хәлфә каядыр юкка чыкты.

Залда жанлылык хөкем сөрә—тәнәфес игълан иткәннәр икән.

Аны бу сәер халәттән Мөхәммәтжанов сүзләре генә айнытып жибәрде:

—Шәп, егет, тегеләрнең саруы кайнарлык булды!

—Шулаен шулай да...—диде, аптыраулы тавыш белән Әхмәтсафа.—Чокыр бит тирән казыла, барыбызга да житәрлек...

Мөхәммәтжановның күзе мангаена менде.

—Син нәрсә сукалыйсың, брат? Хәзер үк тынычлан, акылыңа кил! Иң әйбәте—өенә кайтып ял ит. Нервың бирешкән, парин. Без бит юлның башында гына әле, болай тиз бирешү һич тә ярамый. Көрәшкә чыккансың икән—биленне бирмә инде. Ан бул—без дөньяга жинелү өчен килмәдек!

* * *

Конференциядән соң Әхмәтсафа шактый вакыт үзенә урын таба алмый йөрде. Әле ана кадәр үк, төшке ашка кайтканда, ишек алдындагы

бала-чаганың уйнаганнарына күз салган иде, имәнеп китте: сары чәче матур итеп тасмалап үрелгән кызчык дәү генә гәүдәле, таушалган кыяфәтле курчагының сыңар аягыннан эләктергән дә, дөньяның бер ай-һаена исе китмәгәндәй, эсседән куырылган сукмак буйлап каядыр бара. Ара-тирә курчагына зәһәр сүзләр ычкындырган була, ачуы килгән, ахры, уенчыгына. Әхмәтсафаның исен җибәргәне—кызчыкның уенчыгына болай миһербансыз кылануы гына да түгел иде, ә курчакның шундый төче елмаю белән тузанлы сукмактан өстерәлеп баруы иде. Анын бу халәтенә дә, кызчыкның энәле сүзләренә дә исе китми, алар әллә бар, әллә юк, һаман бер көйгә елмаеп тик бара. Шуның өчен дә курчак шул ул, җансыз курчак.

Курчак язмышы... Үз язмышын оештырудан мәхрүмлек... Сискәнеп китте—чынлыкта ул үзе дә кайбер кешеләр кулында курчак кына бит. Чарасызлык, һәр поручениене өлкә комитеты исеменнән бирелгән установка дип кабул итү күпмегә кадәр дәвам итәр? Кире чигенеп тә булмый.

Галим дөрес әйтә, уенга кергәнсең икән, җебеп утырма!

Конференциядән соң моны ул ачык сизде, бер генә кеше дә, Мөхәммәтҗановтан башка, әлбәттә, аны "шәп" чыгышы белән килеп котламадылар. Баштагы көннәрдә танышларның күбесе читләтеп тә үтәләр иде әле. Дәвере өчен табигый хәл—алар моның ахыры ни белән бетәсен көтteләр бугай. Ә бит аны икенче көнне үк НКВД "җыештырып" алып китәргә мөмкин иде... Уенга кергәнсең икән, кире чыгу турында уйлама, югыйсә нииндидер куәтле машина сине "эһ" итәргә өлгергәнче сытып кына узачак. Күз алдына Рабига, үсеп килүче уллары Марат белән Марлес килә дә, йөрәге кысылып куя. Курчак үзенең язмышы өчен көрәшүдән мәхрүм. Уенчык язмышы шуннан гыйбарәт. Ә ул, адәм баласы җәмгыятьттән аеры башка чыгып, илдә барган барлык вакыйгаларга кул селтәп, үзе өчен генә яши аламы, шушы катлаулы чорда үз язмышын оештыру хокукы бирелгәнме аңа?

Бер мәртәбә конференциядә чыгыш ясап, күзгә төртеп торган кимчелекләрне иптәшләрнең йөзләренә бәреп әйткәч тә, шыксыз үрдәк баласы булып йөр инде. Нәрсә бу? Акылга хилафлыкмы, тыйнаклыкмы, мокытлыкмы? Агымдагы сәяси хәлләрдән бихәбәр түгел ич—ил буенча шундый конференция-җыелышлар үтүен, аларның һәркайсында үзтәнкыйть, үзара тәнкыйть дигән нәрсә үзәктә булып, моңа инде җитәкчедән алып гади партия әгъзасына кадәр чыныгып, пешеп баралар иде. Тәнкыйть белән чыгучыларга үпкәләп, гаепкә санап йөрүчеләр бик аз була. Гадәттә, җыелышның ниндирәк тәнкыйди рухта үтәчәге беренче минутларда ук беленә, тонны үзтәнкыйть штыгы белән коралланган район яки өлкә җитәкчесе үзе үк бирә.

Җыелышлар исә дәвам итә. Татгосиздатта көн саен диярлек үткән партия җыелышлары да кайнарлыктан мәхрүм түгел, язучылар сүзләрне сайлап тормыйлар, Әхмәтсафага нигәдер Фатих Кәрим өчен нык эләкте. Бигрәк тә Нур Баян каныкты аңа. Имеш, халык дошманы Фатих Кәрим белән һаман бәйләнеш тота, җай чыккан саен гонорар бирдертә, очрашсалар, сөйләшеп сүзләре бетми...

Беркөнне язучылар йорты каршында Фатих Кәримнең моңсуланып, аптырап басып торуын күргәч, аның янына бармый кала алмады Әхмәтсафа. Керпе чәчле, һәркемгә хәерхаклы бу егетне үз итә иде ул. Әмма әле күптән түгел булып узган бер җыелышта аның бөтен иҗатын да, үзен дә туздырып ташладылар: контр, имеш, мулла малае булуын яшереп йөри, үзен массалар алдында фаш итми. Язганнары тулысы белән советка каршы икән. Менә шул чактан бирле аңа көн юк инде. Хәл-әхвәлләрне сорашкач, Фатих ачынып:

—Француз инкыйлапчысы дөрес әйткән, иптәш Дәүләтъяров, килә шундый вакыт, революция үзенең балаларын ашый башлый икән. Менә бит нинди хәлдә калдым, гаилә ишәя, торырга урын юк, балаларга ашарга тәгам ризык табып булмый, кесәдә сукыр бер тиен калмады. Кая барырга, кемгә баш иярга? Нинди гөнаһлар өчен диген?..

Әхмәтсафа "аңлыйм хәлләреңне" дигәндәй дәшми генә тыңлап торды да, Кәримне, иске кәчтүн җиңеннән сак кына эләктереп, үзе белән әйдәкләде. Бухгалтериядә аласы гонорары булган икән, "дошман" дип табылгач, бирми тотканнар, бар җавапчылыкны үз өстенә йөкләп, шул акчасын бирдертте.

Бу хәл көне-сәгате белән язучылар оешмасына барып та җиткән иде.

Бер җыелыштан соң Гомәр Толымбай Әхмәтсафага иплəп кенә:

—Баян белән җайлап сөйләш әле. Болай начар егет тә түгел, тик сүз алып чыгыш ясарга тотынса, артыгын бөгештереп җибәрүен сизеп тә бетерми, ахры. Араторлык галәмәте. Әйттем, шуның белән бетте-китте, дип уйлый, ә бит кемнәрдер аның сүзләрен усал якка файдаланырга мөмкиннәр. "Заман кемнеңзаманы дигәндәй", дәвер гади түгел, ныклап тикшерелмәгән фактлар белән уйнарга ярамый...

Толымбай әле кайчан гына Фатих Әмирхан кебек атаклы язучыларны "буржуа ялчысы" дип атап, әдипләрне һәртөрле гөнаһларда гаепләп, бөтен татар дөньясын шаулаткан тәнкыйтьче иде. Инде үзе башлаган шаукым касәфәте—аның да баш очына кара болытлар җыела...

Әхмәтсафа Нур Баян белән ныклап сөйләшеп алмакчы да иде, өлгерә алмый калды, июнь аенда Әхмәтсафа Дәүләтъяровны "Кызыл Татарстан" газетасының җаваплы редакторы итеп раслaдылар. Нәшриятның партия оешмасын типографиядән аерып, аның тәүге сәркәтибе итеп Нур Баян сайланды.

...Бу хакта кайта-кайта уйланды Әхмәтсафа. Ни өчен нәкъ менә аңа тукталдылар өлкә комитетында? Журналистикада ат уйнаткан кешеләр аз түгел иде бит. Белем ягыннан да, тәҗрибә ягыннан да, һөнәр иясе буларак та Фатыйх Сәгыйтов аннан кимме?

Эш бүлмәсенә чакырып, аны җаваплы редакторга "кодалаганда" бу хакта Әхмәровка ачыктан-ачык әйткән иде. Аңа кадәр эшләгән Ризванов, Рәмзи, Еникеевларның язмышы да күңелне тырнап тора. Барысын да "дошман" ясап бетергәч ни. Ул нәшриятта эшләсә дә, күбрәк хуҗалык йөген тартты. Монда исә иҗат белән бәйләнгән вазыйфа. Үзең җүнләп белмәгәнне башкаларга ничек өйрәтәсең дә, башкалардан ни рәвешле эш таләп итәсең?..

Әхмәров аны сабыр гына тыңлап торды. Чигенергә урын юк икәнен сиздерергә теләп, сүз башлады.

—Мөхәммәтҗанов белән бүген генә танышкан кеше түгел син, әйеме? Холкын яхшы беләсең. Синең кандидатураны чыгарган икән, димәк, уйланмыйча гына кылынган гамәл түгел бу. Бу хакта, хәтерем алдамаса, сиңа Галим Мөхәммәтҗанович элегрәк әйтеп-сиздереп куйган иде булса кирәк... Үзем дә "Кызыл Татарстан"ны беренче очраган кеше кулына тапшырырга теләмәс идем. Ут-сулар кичәрлек иптәш син. Сирәк хәзер андыйлар.

—Рәхмәт... Зурлыйсыз зурлавын да, ышанычны аклап булыр микән?—Ул кайчандыр Габдуллин белән сөйләшкәнен исенә төшерде: "Дин өчен көрәш—социализм өчен көрәш ул!" дигән хыйлафлык килеп чыкмасмы? Теге чакта Мөхәммәтҗанов "җаваплы редактор" дип сүз кузгаткан иде, әмма мин ул вакытта аны чынга алмадым, шаярту дип уйладым. Баксаң...

Абдулла Әхмәров, башын артка ташлап, көлеп җибәрде.

—Баксаң, без шаяртырга исәп тотмыйбыз. Синнән Исмәгыйль Рәмиләр җибәргән дәрәҗәдә сукырлыкны да көтмибез инде.—Көлүеннән кисәк туктап, җитди рәвештә өстәп куйды.—Эшне белмим дигәнеңә ышанып бетмим, син инде бу өлкәдә күп ууралдың. Кемнең ни эш майтарырга сәләтле булуын гына беләбез. Сәгыйтов кулына калсаң... ТКУда белем алганнарның бер начар гадәте бар—алар үзләрен башкаларга караганда өстен тоткан булалар. Янәсе, белемлерәк, дөнья агышын яхшырак күзаллыйлар. Аларда тәнкыйди рух көчле. Тик еш кына, сүз булмаганда, сүз булсын, ата казын күкәй саламы дигәндәй, тәнкыйтьләре тисә тиенгә, тимәсә ботакка килеп

чыга. Сәгыйтовның да эшенә караганда тавышы күбрәк. Синең холыкка капма-каршы кеше. Журналистлар арасында Сәгыйтов ишеләр күбрәк шул. Карышып, Мөхәммәтҗановның ачуын гына китерерсең. Бу синең файдага да түгел, минем абруйга да зыян килер. Алын син бу эшкә...

—Бер мәкалә дә язмаган башым белән...

—Язганнарың җитәрлек, районнарда эшләгәндә язмаларың чыккалап торды ич.

—Пәри башка, җен башка...

—Ярый, сүз бозау имезә, йә синтетик каучук төзелешәннән, йә икенче ТЭЦтан берәр язма әзерлә дә, бүген үк редакциягә илтеп бир. Мин хәзер сөйләшеп куям, язганыңны бүгенге номерга кертсеннәр.

—Әйтергә ансат. Ни турында язарга? Бөтенләй читен хәлгә куйдыгыз әле..

—Җебеп торма, Әхмәтсафа, сиңа килешми. Тот та профсоюзларның эшен тәнкыйть итеп яз. Аларны күпме сүксәң дә рөхсәт ителә, башкаларга гына кагылма. Ә инде бүген үк басылып чыгарырлар дигәнгә аптырама, яңа җаваплы редакторның беренче мәкаләсен инде көтеп тә торалардыр.

Әхмәтсафаның хәзер генә исенә төште. Күпме сүз куерттылар, сорарга онытып тора икән.

—Бәй, Еникеевка ни булган?.. Ярыйсы гына эшләп йөри иде бит.

—Син сорама, мин әйтмим,—диде Әхмәров, бу сүзләргә күп мәгънә салырга тырышып.

Әхмәтсафа, Мөхәммәтҗанов белән Әхмәровның теләгенә янә каршы төшәргә базмыйча, үзенә бераз таныш булган ТЭЦ төзелешенә чыгып китте. Анда прфсоюзларның еллык хисап җыелышлары үткәрелгәнен кемнәндер ишетеп калган иде...

...Нур Баян беренче эш көнендә үк Дәүләтьяров бүлмәсенә кереп, дустанә әңгәмә корып утырды. Чыннан да аның күңелендә явызлык юк, ә менә чор каршылыкларын бөтен катмарлыгын үзенә сендергән иде кебек.

—Син озак утырмыйсың монда, Сафа,—диде ул авыз чите белән саран елмаеп.—Ике юлың бар—берсе төрмә, икенчесе—ул бармагын өскә чөйде—тегендә, зур абзыйлар үз тирәләренә алырга чамалыйлар инде сине. Әле Сәгыйтов белән сөйләшеп тордык. Синең якташ. Әйбәт белә ул сине.—Ул янә дусларча елмайды һәм борын өстенә шуышкан күзлеген төзәтеп куйды,—булдыклы егет икәнлегеңне без дә беләбез. Сәгыйтов информациясе чүп ул безнең өчен, әйеме?! Югалтмаска иде синдәй егетләрне. Тик безнең язмышлар ничек булып бетәр бу мәхшәрдә, кайсыбызга ни язган—бусы әлегә карангы.—Ул авызына капкан папиросына ут элгән уңайга, астан сынап-сынап Әхмәтсафага карап алды.

—Синең белән нәкъ шул хакта сөйләшәсем килеп йөри дә иде,—диде Әхмәтсафа тәвәккәлләп. Ул Нурның көтелмәгәнчә ачылып китүенә сәерсенә төшкән иде. Ул, гадәттә, аерым сөйләшкәннәрдә бик сак тота иде үзен.—Синең кулда да, минекендә дә кеше язмышлары. Без кайбер чакта уйлап бетермибез бугай.

—Саклык кирәк...—Нур Баян үртәлгән кыяфәттә урынынннан торды.—Белеп булмый шул, туганкай, кем кайчан аркага пычак кадар?.. Бер сүздә булып эшләсәк ярар иде дә...

Җаваплы редактор бу сүзләргә каршы ни дип җавап кайтарырга белми калды, Нур Баян авыр атлап, чыгу ягына кузгалды.

Анламассың бу кешене, дип уйлап алды бүлмә хуҗасы, өстендәге йөкне алып ташларга маташкандай. Кешегә зыяны да юк, һәрхәлдә кыдрачланып сөйләнсә дә, аның әләге белән кемне дә булса "Черек күл"гә алып киткәннәрен хәтерләми. Шулай да кешеләргә тулысынча ышанып бетми, шул сәбәпле ихласлык та җитми. Тел төбендә ниндидер сер яткан кебек, нәрсәдер әйтергә теләп тә, әлегә әйтми калдырган сыман. Сүзен сөйли

башлап, ниндидер әһәмиятле ноктага житкерә дә, кинәт өзеп, китеп бара. Болар яна чорда житлеккән шагыйрьләр шул инде, ул белгән Такташ та, сирәк булса да очрашкалап торган дусты Муса да түгел. Бөтенләй башка кавем болар. Үзара бәхәс, тарткалашырга гына торалар. Бер карыйсың – яшь әтәчләр сугышкандагыдан битәр җоннар очыралар, икенче карыйсың, кочаклашып, Казан урамнарын ду китереп кәеф-сафа корып йөриләр. Өлкән буын да аларны өнәп бетерми кебек. Катлаулы бу әдәбият дөньясы, болай гына аңга сыешлы түгел.

...Беркадәр вакыт үткәч, Нур Баян Галимҗан Ибраһимовның иҗатын тәнкыйть итеп мәкалә күтәреп килде. Әхмәтсафа, хөрмәт иткән атаклы язучы иҗатын болай бәяләүне килештереп бетермәсә дә, каршы килергә җөрьәт итмичә, аны бастырып чыгарырга рөхсәт бирде. Ул бер караганда беркемгә яраклашмый, җайлашырга да уйламый, әмма кемгә дә булса ныклап каршы да чыга алмый торган ихтыярсыз кешегә әйләнеп барганын чамалады.

...Мифтах хәлфә тәрбиясеме, язучыларны ул изге, Ходай бәндәләре дип уйлый иде, ныклап алар белән танышып, аралашып яши башлагач бу матур уйларга нокта куелды. Тора-бара аларны үзе дә бик үк өнәми башлады. Астыртын, мәкерле, көнчел халык.

Исеме билгеле язучы белән бер яшь каләм иясе сөйләшеп торганына шаһит булды ул. Өлкән язучы яшь иптәшне нигәдер битәрләп азаплана. Тегесе аңыша алмыйча, кат-кат сорый:

—Ник мине ачуланасыз. Мин ни эшләгән?—дигән була.

Ахыр чиктә, өлкәненең тәкате бетте, ярып салды:

—Сине, энем, бу йортта беркем дә гафу итмәячәк, аңласаң аңла, аңламасаң, баш катырып йөрмә! Повесть күтәреп килгән, имеш, бирәү. Минзәләдән җәяү килгән, имеш. К... кычытса, әнә, Сахалинга ук сыптырт, гәүдән дә җиңеләер, бераз акыл да керер! Кемнән сорадың, өч тиенлек белемең белән повесть кадәр повестька тотынырга? Кем кушты сиңа моны, кем сорады? Әллә син язмасаң, татар әдәбиятында повесть язучылар беткәнме? Әүвәл, җыйнак кына бер хикәя алып кил син безгә. Шуның нигезендә синең талантың барлыгын-юклыгын тикшереп, зуррак әйбер язарга фатыйха бирсәк, бөтенләй икенче нәрсә булыр иде. Бар туган, йөрмә, вакытны бүлеп, авылыңа кайт та мин әйткәннәр хакында кат-кат уйлан. Бер-ике елдан соң хикәяңне кыстырып килеп чыгарсың, җәме!

Теге егет бу сүзләрдән исәңгерәп, озак торды Язучылар йорты коридорында.

Бәхеткә, кайдандыр яшь шагыйрь Газиз Мөхәммәтшин килеп чыккан иде, Әхмәтсафа егетне ана "тагып" җибәрде.

Ике-өч көн үтмәде авызын җырып килеп тә керде Газиз.

—Малай, талантлы егетне тапкансың бит син, әле педагогия институты белән сөйләшеп кайттым, егетне укытырга кирәк, язучы чыгачак аннан, иманым камил,—диде.

Икенче очрак та исеннән китми. Исеме яңгырый башлаган яшь язучыны әдип "дуслары" "өзлексез талап" йөрәк чиренә әйләндереп үтергәннәр иде, теге бичара вафат булгач, аны дөньядан вакытсыз китәргә мәҗбүр иткән каләм әһелләренең үз корбаннарын мактап калу өчен эткәләшеп-төрткәләшеп табуты янында чират бүлешкәннәрен күргәч, бөтенләй исе-акылы китте. Ничек оялмыйлар сүз әйтергә, үзләре талап вакытсыз кабергә керттеләр ич теге бичараны... Хәзер аһ-ваһ килгән булалар, иртә китте, әле нинди генә әйбәт әсәрләре белән сөендерәсе иде, дип канлы яшьләр түгәләр, мин сиңа әйтим.

Кечкенә улын күтәреп Җамал килеп керде. Улын яндагы урындыкка утыртып куйды да, иреннәрен нык кысып, Әхмәтсафага төбәлде.

—Эштә бер-бер хәл булдымы?—дип, сорамый түзә алмады бүлмә хуҗасы.—Малай ничек, бик көйсезләнмиме?

—Үсә...—диде Жамал, боек тавыш белән.—Менә синең хәлне белергә килдек әле, әйеме, бәләкәч коммунарым минем!

—Бәкәч, дисеңме?—Әхмәтсафа шаяртасы итте.

—Тозсызланып утырма инде, синең эштә болай сөйләшү килешми.—Жамал шыңгырдый башлаган улын кулына алды.—Әллә син аны әтисез үсә дигәч тә? Аның әтисе совет власте, шаярма абыйсы!..

Жамал бер вакыт бик каты мәхәббәт утларында янып алды. Егет хәрби заводта эшли иде, Казанның бер заводында бүлек мөдире вазыйфасын башкара. Техник әдәбиятка мөкиббән, еш кына Жамал эшләгән китапханәгә килә. Шунда танышып киткәннәр иде. Эш уеннан узып, Жамал үзенең авырга узуын әйткәч кенә, егет дигәннең инде өйләнгән, шулай ук бәби үстереп ятулары билгеле була. Жамал күтәрелмәде, бәрелмәде, язмышына төшкән чираттагы сынау гына дип кабул итте бу хәлне. Исән-сау бәби алып кайтты һәм берни булмагандай теге адәм белән очрашуын дәвам итә иде.

—Ныклап уйлап керештеңме бу вазыйфага?—Жамал сынаулы карашын Әхмәтсафага төбәде.

—Нәрсә дип әйтим инде. Уйлаган кебек идек тә...

—Уйлагансың, пычагым. Минем белән киңәшкән булыр идең, бөтенләй санлашмый башладың. Рабига белән сөйләшкәнсеңдер инде, ачуым бер килмәгәе, ул ни диде?

—Синеңчә уйлый...

—Ә мин ничек уйлыйм?!

—Каршы...

—Ничек риза булдың, егетем, бу эшкә?.. Күрмисеңме, сиңа кадәр эшләгәннәрне нишләттеләр? Куркам мин, Әхмәтсафа, хәзер һәрнәрсәдән куркам. Күнел түренә кереп оялаган да курку, көне-төне жанны талый. Шуңа килдем, чигенергә мөмкинлек булса, калдыр син бу эшне...—Жамалның тавышы калтырап чыкты.

—Без чигенсәк, менә бу коммунарлар ни уйлар безнең хакта?—Әхмәтсафа әнисе алдында тибенеп утырган сабыйны кулына алды.—Поезд үтте инде, чигенергә ярамый...

—Сак бул инде, бердк, мин бит сиңа карап торам. Минем өчен дә бердән бер терәк син. Үзем генә булсам ярый иде, инде хәзер шушы сабыем да булгач... Марат белән Марлес ничек матур булып үсеп киләләр. Сак бул, зинһар, ызгыш-гаугалардан ерак тор!—Жамал, Әхмәтсафага күтәрелеп карамыйча гына улына үрелде.—Без китик инде, эшең күптер. Ачуланма, турысын әйтми түзә алмадым...—хатын яшьле күзләрен яшереп, улын күкрәгенә кыса төшеп, чыгып китте.

...ТКУда аспирантураны тәмам кылгач, Әхмәтсафага берничә эш урыны тәкъдим иткәннәр иде. Ул үзенә таныш булган Минзәлә төбәген сайлады һәм аны МТС политбүлеге урынбасары итеп билгеләделәр. Моныcына кайгырмады Әхмәтсафа. Кешеләр белән эшләүне, тормышның үзәгендә кайнауны ярата иде ул. Казанга якын түгел түгелен, ләкин бит Бохара ягына китеп олагу да түгел. Инде ике улы—Марат белән Марлес үсеп килә. Рабигасы үз янында, тагын ни кирәк?

Анда ике еллап эшләгәч, 1935 елның язында, Кызыл Йолдыз райкомының икенче секретаре итеп Котлы Бөкәшкә, Казан ягына жибәрделәр. Житмәсә, мәгез дигәндәй, язмыш алар янына Жамалны да китереп кушты—аны ТКУдан соң райком инструкторы итеп өлкә комитеты Кызыл Йолдызга билгеләгән икән. Жамалның килүен барысы да шатланып каршы алдылар. Инде хатынның жилләнеп-дуамаланып йөрүе чигә төшкән, ул басынкыланып, сабырланып калган иде. Каршы төшми тыңлап утырсаң, һәр сүзендә тәжрибә, һәр сүзендә алтынга тиң акыл иде аның. Әхмәтсафа белән Рабига үзләре дә, балалар да Жамалга шул кадәр ияләшеп беттеләр, аның белән

кинәшмичә бер эшкә тотынмыйлар, аннан башка хуҗалыкта бер гамәл кылынмый иде. Әгәр Җамал кайтып житмәсә, ашарга да утырыш юк.

Шуңа күрә Әхмәтсафаны кабат Казанга, тәрҗемә эшенә нәшриятка кайтаргач, иң беренче эше шул булды, җаен-сәбәбен табып, Җамалны да янә шәһәргә чакыртты һәм китапханәдән эш урыны табып бирде.

Хатын күңелгә вәсвәсә салды. Үзенең нинди урында утырганын яхшы аңлый да ул, тик менә ызгыш-даулардан ни рәвешле читтә калып була? Бөтенесе бергә буталышып, укмашып беттеләр ич инде, уннан да, сулдан да урап үтмәле түгел каршылыкларны, күзне шар ачып нәкъ өстенә барырга туры килә.

## IV

Кабинет хуҗасы каршысында ашыга-кабалана хисап тотучы Маленковны, гадәттәгедән озаграк тыңлап торырга теле иде, ахры, йомшак тәрәкле урындыгына ята төшеп, трубкасын күгелҗем итләч иреннәренә кыстырып куйды. Күзләре кысыла язып бетте.

Маленковны һич тә булмаганча, түземсезләнеп көтте ул. Татарстан Солтангалиевләре, Сәгыйдулиннары, берсе өстенә берсе килеп төшкән әләк-жалобалары белән аның үзәгенә үткән иде. Монарчы җибәргән бер генә ӨК сәркәтибе дә аның өметен тулысынча акламадылар. Бераз эшләгән булып кыландылар да, дошман сафына кушылдылар. Казан күптәннән аның күзен кыздыра, Мәскәүдән кала, иң көчле бухаринчылар да шунда булырга тиеш, аңа калса. Менә шушы шикләрен куып таратырдай гамәл кылырга кирәк иде. Сталинның шәхсән күрсәтмәсе нигезендә, 1937 елның август ахырында Маленковның Казанга сәфәре махсус шуның өчен оештырылды. Ул урынга барып, "дошман" оясына төп удар ясарга, туздырырга, исән калган "дошманнар" өерен кыйратырга, Татреспублика җитәкчелеген тулысынча алыштырып, унга-сулга тайпылмаслык кадрлар белән ныгытырга, моннан соң Казан ягыннан вәсвәсәле хәбәрләр килмәслек итәргә тиеш иде.

Сизә, чынлап сизә Маленков Сталинның аннан нинди рәк доклад көткәнен. Август ахырында Казанда булып, өлкә комитетында берничә көн дәвам иткән пленумнан тәмам кайнарланып кайткан әнә. Татарстанга җибәрелгән махсус комиссияне җитәкләгән ҮК вәкиле Георгий Маленков юкка гына дәүләт ипиен ашамаганлыгын расларга тырыша, Казанда эшләрнең коточкыч таркау итеп күрсәтүдә сүзләрне җәлләп тормады докладында. Ярый әле иптәш Сталин, даһиларча алга карап эш итә, ярый әле Казанга башка беркемгә ышаныч күрсәтмичә, аны, Маленковны җибәргән юлбашчы. Ярый әле вакытында удар ясалды дошман өеренә. Соңга калынса, контр оясына әйләнгән Казанда ниләр булып бетәсен чамалавы да кыен. Болар Сталинның күңеленә хуш килде.

Маленков чыннан да Казанда үтә мөһим эш кырып кайтуын гамәли мисалларда оста һәм саллы итеп күрсәтергә омтыла, тырышуы шул чиккә җитте, инде ике битеннән шыбырдап тир ага, ул аны кульяулыгы белән сөртеп өлгерми, Сталин исә, торган саен йомыла бара, әллә бар Маленков, әллә юк, шулкадәр дәрәҗәгә җиткән контр оясын тузгытып кайтып, рәхмәт сүзен ишетмәсә ишетмәс, хет инде хуплауны белдергән сыңар ишарә эләктерү генә дә ни торыр иде бу мәлдә. Әмма Сталинны серле иткән сыйфатларның берсе шул—ул каршысындагы кешенең җаны табан астына төшеп, сыңар аягының чәнти бармагы арасында бәргәләнә башламыйча, ым да какмаячак. Маленков Казаны ние белән томанга кереп югалды сыман, юлбашчы исә бөтенләй икенче дөньяда йөзә кебек иде. Шушы уйдан мингерәгән хәлдә, Маленков кисәк туктап калды.

Бүлмәдә беразга гына урнашкан тынлыкны Сталинның салмак, ачык тавышы җимереп ташлады:

—Шулай да иптәш Маленков, әйт әле, Татобкомда кадрлар мәсьәләсе нинди рәк хәлдә?

Каударланып җавап тота башлады Маленков:

—Лепадан соң...

—Ул карт беләт хакында сөйләп тормасаң да була. Ежов егетләре кулында ул. Троцкийның артын ялап кабарткан корсагын тиз шиңдерделәр НКВДда... Яналар, булдыклылар, таянырлык иптәшләр бармы?

—Бу хакта, иптәш Сталин, көне-төне уйландым, үземә бирелгән вәкаләтләр кысасында кайбер карарлар да кабул итәргә туры килде. Татреспубликада контрларга каршы беренче, ләкин хәлиткеч удар ясалды дип исәплим, әмма эшне ахыргача җиткерү өчен нык көчәнергә туры киләчәк. Казан көндәлек игътибарда минем хәзер, эшне ярты юлда калдыру дөрес булмас иде. Бер генә кешегә—Алемасовка таянырга була. Эшне тарта алырлык, каты куллы җитәкче. Партия эшенә тугырыклы булуы һәр сүзендә чагыла. НКВД наркомы булып торган бер ай эчендә шактый эшләр майтарды. Тәҗрибәле иптәшләрнең сүзләренә караганда, яхшы якка үзгәрә хәл.

—Сүзләр дисең инде...

—Гамәлләр дә җитәрлек, иптәш Сталин. Кыска гына арада күпме халык дошманының койрыгына басты. Ялан кул белән генә эләктереп ала торган еланнар түгел алар. Абрамов, Байчурин, Лепа... Кыскасы, әгәр Алемасовка Казан уртасында Мисыр пирамидасы салдырып куярга кушасың икән, анысын да эшли ала торган кадр. Аның өчен вакыт та, чик тә юк. Башка сыймый, һәркайсы артель оештырып өлгергән башкисәрләрне нинди тизлек белән фаш итеп, сасып яткан караңгы ояларыннан якты дөнья йөзенә чыгарды ул?!.

Сталинның йөзе мәзәк төскә керде.

—Мисыр пирамидасы?.. Ә нигә кирәк ул анда?

—Болай гына әйтүем, иптәш Сталин. Уңышсыз мисал китердем, гафу итегез. Чыннан да Алемасовка ышанычым зур.

Сталин урыныннан калкына төште.

—Аңа ышанычны Үзәк комитеты күрсәтте. Ә пирамидага килгәндә... Кызык фикер бу...

Маленковның эченә җылы йөгерде, аяк бармаклары кызышып алдылар.

* * *

Александр Алемасовны Казанга 1937 елның җәендә НКВД наркомы итеп җибәрделәр. Аңа кадәр нарком булып эшләгән Петр Рудьны Татарстанда мыжлап торган контрреволюцион җитәкчеләрне фаш итүне үзагымга куюда, фаш ителгәннәрнең "телен" ачтыру эшендә йомшаклык күрсәтүдә гаепләп, җәй башында Мәскәүгә чакыртып алдылар һәм тиздән үзен үк контр ясап, атып та үтерделәр.

Рудь тырышмаган түгел иде, тырышкан да кебек иде болай үзе, әмма Мәскәү аның эшеннән канәгать булмады. Рудь акланып маташты. Эшгамәлләрен санады, тик бер "дошман" исемлегенә теркәлеп куйгач, аның "тырышлыкларына" артык игътибар итүче булмады. Рудьның күзгә күренерлек "эше" бар иде барлыгын.

Утыз алтынчы елның җәй-көз айларында Татарстан дәүләт китап нәшриятында контрреволюцион оешма "фаш" ителеп, Исхак Рәхмәтуллин, Салах Әтнәгулов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Зәки Гыйммранов кебек милли кадрларны "Черек күл"гә озатуын ул аеруча горурлык белән телгә ала иде. Ләкин аның бу эшне тиешенчә башкарып чыкмауда гаепләделәр. Милләтчеләрнең гөнаһлары конкрет ачылмады, ачылганы тиешенчә халыкка хәбәр ителмәде. Аларның эше Алемасов килгәч кенә ахырына җиткерелеп, "милләтче-контрреволюционерлар"ның арт сабакларын укыту, атулар башланды. Алемасовның каты куллы чекист булуына Сталин тамчы да шикләнми иде, инде бу хәлләрдән соң, бигрәк тә Маленковның нотыгыннан соң, аңа ышанычы тагын да арта төште. Александр Алемасов утыз биш яшьлек

ир-егет, зур эшләрдә үзен күрсәтерлек, өлгереп җиткән партия работнигы, инде ун ел дәвамында илнең төрле өлкәләрендә җаваплы постлар биләде. Себердә, Украинада партия эшендә үзен күрсәтә алган Алемасов, Сталин уенча, Казан өчен үтә кирәкле кадр иде. Дүрт ел дәвамында Татарстан партия оешмасында контрреволюцион төркемнәр үрчеп ятуын күрмәгәнсизмәгән ата ялкау песи Альфред Лепаны алыштыру өчен менә дигән кандидат иде ул. Шуңа күрә дәүләт куркынычсызлыгының өченче ранглы комиссары Алемасов кандидатурасы хакында сүз куера төшкәч, Сталинның йөзендә җинелчә генә яктылык пәйда булды.

—Алемасов ышанычлы дисең инде... Килешәм, әлегә безнең ышанычны аклый ул... Ә калганнары?

—Калганнары... Мина ӨКның икенче секретаре Мөхәммәтҗановның пленумда Вольфовичның тетмәсен тетүе охшады.

—Вольфович?—Сталин бу фамилияне ишеткәч, чыраен сытып куйды.—Үзәк Комитетның рекомендациясе белән китеп, Казанда бәдрәф сасысы чыгарган ул ишәккә тиешенчә отпор бирә алдыгызмы? Фиргавен! Менә кем анда тере килеш мумияга әйләнде. Ә син пирамида дисең!—Генсекның тавышында тимер катылыгы чагылып китте.

Бәхетсез башка тимер тарак. Каян килде телгә бу пирамида сүзе,ә? Маленковның күзендә яшь бөртеге елтырады.

—Бирелде, иптәш Сталин, ул ишәк... фиргавен... Вольфович тиешлесен алды дип уйлыйм. Башта, мин тынлап кына утырдым, сизеп торам—йомшак бара тикшерү. Халык шул кадәр инерциягә өйрәнгән. Җирле фирка башлыкларына мәсьәләнен төбен ныклап анлатырга туры килде, иптәш Сталин. Әгәр дә эш болай барса, моннан чыккан кеше булмаячак, пленумыгызны тулы составта НКВД кулына тапшырам, дип, революцион позициядә нык торуымны күрсәтергә туры килде, иптәш Сталин... Шуннан соң гына халыкның теле чишелде.

Сталин "сөйлә"дигәндәй, ияген кагып куйды. Ана пленумны тулы составта НКВД га озату идеясе охшады бугай. Йөзе яктыра төште.

—Егерме алтынчы августа үзем бик каты тордым, авыз эчендә ботка пешерүчеләргә бернинди пощады булмады. Әйтәсең икән, фикереңне кистереп әйт, йә төрмәгә юлың, йә партия көрәшчесе син. Шигарь шулай куелды. Кичке утырышта Алемасов егетлек күрсәтте. Өлкә комитеты әгъзаларын урыннарыннан кубарып, һәркайсысыннан Вольфовичка карата хөкем сүзләрен әйттерде. Эчке каршылыкны шулай бергәләп сындырдык... Алемасов, иптәш Сталин, аерым әңгәмә вакытында ышанычыгызны аклаячагын, кат-кат белдерде. Өлкә комитетның беренче секретаре итеп сайлануын да дөрес кабул итте.

—Башкалар ни уйлый?..

Әйтергәме-әйтмәскәме, дигәндәй, бераз уйланып торганнан соң, ул, тәвәккәлләп, дәвам итте:

—Постка Мөхәммәтҗанов ымсынган булса кирәк. Мин моны Казанга килеп төшеп, иптәшләр белән фикер алышуга ук тоеп алдым. Башта ләммим дәшмәдем Үзәк комитеты фикере хакында. Тел тегермәннәре тарта бирсен, ачылсыннар әле, мин әйтәм. Үзенчә эш тә йөртеп маташкан бугай Мөхәммәтҗанов, ләкин мин килгәч, бу хакта авыз ачып фикерен белдермәде. Югыйсә, тарафдарлары да булгандыр. Иптәшләрнең тел төбеннән шуны сиздем. Милли кадрларга юл ачарга кирәк, дип, әйтүчеләр дә булгалаган. Андыйларны, билгеле, мин килгәнче үк җыеп алып бетергәннәр иде. Ачыктан ачык эш йөртмәгәч, Мөхәммәтҗановка әлегә кагылмыйча тордык. Кемнәргә исәп тота, ачыкланып бетсен, дидем... Солтангалиевче булып чыкмагае дип тә уйлаучылар бар. Әмма, әйткәнемчә, әлегә андый егет кирәк анда, кагылмаска куштым. Тирәсенә берәр артель туплый икән, ул чагында барысын бер капчыкка тыгып, каталажкага илтеп бушату күпкә нәтиҗәле булачак.—Маленков Сталинга күтәрелеп карады, "халыклар атасы" аның

сүзләрен игътибар белән тыңлаган сыман иде. Инде иң мөһим хәбәрне дә әйтер чак житте.—Алемасовны өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайлау турында Сезнең тәкъдимне кертүкәч, кикриге шиңде пленумдагы татар малайларының. Алемасов тирәсендә бөтерелеп, чабышып йөри башладылар.

Юлбашчының йөзендә әллә ни үзгәреш сизелмәде. Шулай да Маленковның эш алымы күңеленә хуш килде шикелле, үз фикерен белдерүне дә кирәк санады.

—Бераз гына аларга юл биргән сыман кылансаң да зыян булмас иде... Милләтчелек бик оста яшеренгән, тирәндә яткан нәмәстә ул. Татарларның кылларын тарткалап, уйнатып алу кирәк ул андый чакта, кирәк...—Сталин трубкасын авызына кабып, Маленковка сынаулы караш ташлады.—Әйт әле, иптәш Маленков, Вольфович мәсьәләсе шул дәрәжәдә житди идеме?

—Житди, иптәш Сталин. Белгәнегезчә, Вольфович танылган галим санала, Татреспублика партоешмасының тарихын язуда төп фигураларның берсе. Әлеге мөһим эшне аңа тапшыру үзе дошманлык акты саналырга хаклы. Бу чын тарих булырак, иптәш Сталин, Сезнең житәкчелектә милли республикада социализмның тулысынча жиңүен һәрьяклап күрсәтергә тиешле саллы хезмәт булырга тиеш иде. Эш үзагымга куелган, ахырда нәрсә килеп чыга? Тарихны язуга ТКУ ректоры Вольфович "халык дошманнары"н тарткан һәм шулар позициясеннән чыгып язылган китап пәйда булган Татарстанда. Социализм төзелешендә Сез күрсәткән принципиаль платформасы бик тоныкшәйләнә.

—Карт алаша. Тәки акылга килмәде, кабәхәт...

—Шуңа күрә Лепа кебек контрреволюционерлар куенына елышкан да ул. Һәм бу өтек кысланы чиста суга чыгару эшенә турыдан-туры үзем житәкчелек иттем дә. Тарихчы Вольфович житәкләгән элекке Татар коммунистик университет лабораториясенә кереп оялаган "халык дошманнары"н, андагы жылы өннәреннән комсыз кумакларны өшкереп чыгаруга ирешү—Татреспубликада хәлләрнең рәтләнә башлавы дигән сүз, дигән карарга килде комиссия һәм төп удар шуңа күрә Вольфовичка ясалды да. Ул үзенең партия стажына сылтау ясап, белеменә, тәжрибәсенә таянып күпләрнең башын болгатып яткан Казанда. Дөресен әйткәндә, данлыклы Казан фән мәктәбен Вольфович үз тозагына эләктергән... Инде ул "фән мәктәбе" дип сөйләнүләр көлке дисәң дә ярый.

Бу мәсьәләдә Сталин үзенең төшеп калганнардан түгеллеген күрсәтәсе килдеме, авырыксынган кыяфәттә:

—Лобачевский чорыннан ук болгана Казанда фән мәктәбе,—диде ул, күзенә төтен кермәсен дигәндәй, керфекләрен түбән төшереп.—Казанда потенциал бар дип лаф орабыз оруын, ныклап карасаң, әйләнә-тирәдә гел буш куык булганнары ун, йә сул оппортунистлар. Чүбек чәйнәп май язучылар. Теләсә кемнең кубызына бию шуннан килеп чыга. Гомумән, илдә фән өлкәсендәге чуарлыкка түзеп тора алуыбызга шаккатам.—Аннан сүзне кабат төп темага борды һәм инде ничәнче кат бер үк төрле сорауны бирде,—Милли кадрлар мәсьәләсе Казанда ничек тора?

—Юк дисән дә дөрес булыр. Күбесе Вольфович кулыннан үткән, сөрсегән шәкертләр. Аерып әйтергә кирәк, Казанда Татар коммунистик университетын тәмамлаган яшьләргә шактый киң юл ачылган. Ә менә сыйнфый көрәшкә ныклы әһәмият бирелми. Татреспубликада бу мәсьләдә күп эшләргә туры киләчәк безгә.

Сталинның йөзендә караңгы күләгәләр йөгерешә.

—Кемгә?—дип сорады ул, кырыс тавыш белән.

Маленков төртелеп калды. Шулай да сүз башларга көч тапты:

—Беренче чиратта, әлбәттә, Алемасовка һәм өлкә партия оешмасына.

—Таянырлык иптәшләр бармы? Бигрәк тә яшь кадрлар белән ныгыту мөмкинлеге бармы республиканы? Хөкүмәтне кемнәр житәкли, ТатЦИК

кемнәр кулында? Алемасов дип кенә утырып булмый бит. Ана да таянырлык кешеләрнең булуы шарт.

Кулындагы папканы ачып, Маленков, тирән тын алганнан соң, сүзен дәвам итте:

—Иптәшләр белән сөйләшкәннән соң, берничә яшь кадрга туктал-дык.—Ул авырыксынып укый башлады.—Дәүләтъяров Әхмәтсафа Мостафа улы. Казанда, районнарда эшләп тәҗрибә туплаган. Политэкономист. Хәзер "Кызыл Татарстан" газетасында җаваплы редактор. Халык комиссарлары советы рәислегенә исәп тотабыз. Иптәш Мөхәммәтҗанов тәкъдим итә, Алемасов каршы түгел. Республиканы аның кебек яхшы белүчеләр сирәк дип уйлыйм.. Әлегә шәхси делосын тикшерү бара.

—Политэкономист... Сафсата куертучы гына булмасмы? Вольфовичка карашы ничек?

—Кызганыч, пленумда ул катнаша алмады, әллә командировкада, әллә авырып, ялга киткән диделәр. Әмма Вольфович Казанда контрреволюцион эшләр майтарганда, бу егет районда булган. Танышлыклары юк чамасында булса кирәк. Чөнки теге карт ишәкне энәсеннән җебенә кадәр тикшердек, Дәүләтъяров фамилиясе бер генә мәртәбә дә телгә алынмады.—Маленков мангай тирен сөртеп, дәвам итте.—Тагын Динмөхәммәтов дигән кеше бар. Ышанычлы диделәр иптәшләр. Татреспубликаның Үзәк башкарма комитетын җитәкләрлек тәҗрибәсе бар. НКВДны ныгытуны исә Алемасов үз өстенә алды. Анда инде ул тәртип урнаштыра башлаган. НКВДны әлегә ул үзе җитәкли, киләчәктә дә ул участокка милли кадрларны кую урынлы булмас дип уйлыйм. Казан бу мәсьәләдә куркыныч шәһәр, иптәш Сталин.

Маленков папкасыннан алып, Сталинга кәгазьләр сузды:

—Дәүләтъяров белән Динмөхәммәтовка кагылышлы мәгълүматлар, иптәш Сталин.

Генсек кәгазьләрне алып күз йөртеп чыкты да, әһәмият бирмәгән тавыш белән әмер бирде:

—Казан белән эшне дәвам итегез!

Бу—кандидатураларның "үтүе" иде. Маленков бүлмәдән чыкканда сөенеп куйды. "Ярый әле, бер-ике фамилияне әләктереп кайткан. Алдан күрүчәнлек дими ни дисең. Тотты да шартлатып ышанычлы милли кадрлар турында сорау бирде менә. Ык-мык итеп торса, бетә иде. Татарстанда Алемасовтан башка бер җитәкче сайламыйча кайткансың, дип, башынны кире кайнап торган Казанга олактырырга да күп сорамас бу Коба. Коба түгел, "кобра." Аннан шундый шайтани фикернең башына китереп бәрүеннән бөтен тәне белән калтырана-калтырана аргы яктагы бүлмәсенә ашыкты: Алемасовка бүгенге сөйләшү хакында кичекмәстән шылтыратырга кирәк иде.

## V

Казанга кайтканнан соң беренче мәртәбә ял итәргә форсат туган иде. Маленков катнашындагы пленум көннәрендә Әхмәтсафа Дәүләтъяров кыска вакытлы ял алып, гаиләсе белән Иделгә, Маркиз утравындагы дачага китеп барган иде. Әллә кирәк дип санамаганнар, әллә эзләп тә таба алмаганнар, (бераз тырышлык күрсәтсәләр аны Идел буеннан табу ул кадәр кыен да булмагандыр), әмма аны эзләп килүче булмады, бер ай-һайсыз дип әйтерлек, рәхәтләнеп ял итте алар монда. Дача хөкүмәт исемлегендә булганлыктан, ашау ягы да ярыйсы, ял итәргә дә мөмкинлекләр җитәрлек иде.

Мона Рабига сөенеп туя алмады. Уллары Марат белән Марлес көн-озын саф һавада, янында кадерле ире, Казанда барган хикмәтләр монда килеп ирешми дип әйтерлек, хатын-кыз тансыклаган тынычлык, татулык хөкем сөрә иде. Тагын ни кирәк үзенне бәхетле тояр өчен?! Берни дә кирәк-

ми, менә шушы көннәрнең ямен җибәрерлек хәлләр генә була күрмәсен! Яр буендагы аксыл комда, җылы рәхәтлектә оеп ятканда шулай уйлады Рабига. Шулай уйлап бетермәде, һич тә булмаганча, йөрәген нидер сызып үтте, күнелгә Казанда соңгы вакытларда һич ташлап китмәгән шом тәрелде. Кечкенәдән әнкәсе Хәлимәтти өйрәткән догаларны эчтән укый башлады. Күзендә яшь бөртекләре хасил булды, Рабига догалар пышылдавын кемдер сизеп-ишетеп тормасын дигән уйдан сикереп торып утырды. Көннең яме бераз кителде сыман. Нинди сәбәп бар, нигә болай тынгысызлана бүген? Бу хакта уйларга да тартына, бары тик йөрәге урынынан купты да куйды менә. Хәзер кичергән августның соңгы көннәрендәге иләс рәхәтлек янадан кире кайтмас шикелле тоелды аңа. Ул тирә-ягына каранды. Якында гына ике маржа кызынып ята, аларның бер кешедә кайгылары юк, йөзләренә гәҗит кисәге япканнар, сөйләшеп ардылар бугай, бар байлыкларын таратып ташлап, гырлап йокыга ук киттеләр, ахры. Рабига, тынычланып, карашы белән ярдан шактый ераклашып көймәдә йөзгән ире белән уллары эзләп тапты. "И Ходаем, шушы бәхетемне, гаиләм иминлегемне күпсенә күрмә!"—дип пышылдады ул ирексездән. Керфек очларына янә яшь эленде. Ул сикереп торды да, көймәдәгеләргә кул болгарга тотынды. Үзе һаман авыз эченнән: "Кайтыгыз, кайт, наныйларым, миңа монда ямансу, бер генә минут та сездән башка торасым килми,"—дип кабатлый иде.

Әхмәтсафа, хатынының ашыгып-ашыгып кул болгавын күреп, көймәне ярга табан борды. Марат көйсезләнеп, ишкәкләргә ябышты. Аның һич тә кире борыласы килми иде.

—Ярга борма инде көймәне, йөрик әле, әтием, тагын! Әй-һәй оста, безне алдау өчен генә көймәгә утыртып су эченә керде дә, кире чыгарга маташа. Яңа кердек бит Иделгә,—диде ул үҗәтләнеп.—Марлес, кил, мешайть итеш мина!—дип куркыбрак утырган энесенә әмер бирде. Бу Хәлимәтти сүзләре, ул үзенә булышам дип, эшенә кыенлык тудырып мәшәләнүче оныкларына көлеп: "Һи, улыкайларым, үсеп тә җиттеләр, миңа ныклап мешайть итешәләр бит,"—дия иде.

Мышкылдый-мышкылдый Марлес та икенче ишкәк сабына тотынды. Шулай көлешә-көрәшә ишә торгач, көймә борынын ярга китереп төртте.

Әхмәтсафа абайламый да калды, болан тизлегендә көймә эченә Рабига сикереп керде, үпкәләгән тавыш белән:

—Миннән башка гына йөрмәгез әле! Мине дә алып керегез Иделгә!—диде.

Хатынының күнеле тыныч түгеллеген сизеп алды кебек Әхмәтсафа.

—Нинди шөпшә чакты сине, карчык,—диде ул шаяртырга теләп.

Рабига эндәшмәде. Карашын Идел киңлекләренә төбәп торды, аннан алдында утырган Марлесның башына кояшта яна төшкән битен терәде һәм астан гына Әхмәтсафага күз сирпеде. "Берни дә сорама, иш кенә,"—дигән сыман иде бу серле караш.

Озак йөзделәр алар, төшке ашка кадәр Иделдән чыкмадылар. Ишкәк ишкән саен Әхмәтсафа үзендә көч артканын тоя, Рабига исә улларына сыенып утырган да иренең гайрәтле беләкләреннән күзен алмый. Ни уйлый ул, ни дип тынгысызлана болай, Әхмәтсафа һич аңлый алмады. Хәер, җан халәтен ана Рабига үзе дә аңлатып бирә алмас иде...

...Казандагы үзгәрешләр хакында аңа нәшриятның тәрҗемә бүлегендә эшләүче Сәхиб Мирзаханов әйтте. Сәхиб белән дуслар иде алар, серләре килешә иде. Мәгълүматларны кемнән ишеткәндер, бәлки Әхмәров пленумнан соң ук Сәхибне Әхмәтсафа янына махсус җибәргәндер, ярты гына көнгә, һава алырга килдем диде үзләре янына дачага килгән Мирзаханов. Алемасовның Беренче итеп сайлануына әллә ни исе китмәде аның. Эшләр шул якка барганын аңламас дәрәҗәдә түгел ул, ә менә үзенең шушы пленумда өлкә комитеты әгъзасына кабат "күтәрелүенә" гаҗәпләнде дисәң дә ярый. Бу биеклектә сакланып кала алуның астында нәрсә ята—аңа караңгы иде.

—Мине хәтта анда чакырып та тормадылар,—диде ул, Идел ярының аулак почмагында Сәхиб белән икәүләшеп сөйләшеп утырганда.—Минем өчен аптырарлык хәл дип әйтимме... Шундый катлаулы чор бит.

—Анысы инде мина карангы, дускай. Бары тик бу сыйфатта сине тәбрик кенә итә алам. Безне танымыйча китмәссең бит, очрашкан чакларда дим.—Сәхиб көлеп җибәрде. Ул тыйнак Дәүләтъяровның борын чөеп йөрүен үзенчә күзаллап карады ахры.

—Рәхмәт,—диде Әхмәтсафа саран елмаеп.—Үзең читкә карап үтмәсәң, без инде алай кеше танымас хәлгә житмәбез...

Сәхиб ничек тиз килсә, шулай озак юанмый китеп тә барды. Инде жанны тынычсызлык биләп алган иде. Икенче көнне Әхмәтсафа да Казанга әйләнеп кайтты. Рабиганы ул биш көннән соң гына килеп алды.

...Вакыйгалар агышына бәя биреп бетермәле түгел иде. Озакламый республикада иң абруйлы житәкчеләрнең берсе—Кыям Абрамовның "халык дошманы" икәнлеге "мәгълүм" булды, аның артыннан Гомәр Байчурин исемен телгә алмый башладылар. Ул да "дошман" икән.

Сентябрьнең унжидесендә, кичкырын аны Алемасов өлкә комитетына чакыртып алды. Көтмәгән иде, каушап килеп керде Беренченең бүлмәсенә. Анда Алемасов белән бергә Мөхәммәтжанов та утыра иде.

Кул биреп күрештеләр.

—Утыр, иптәш, Дәүләтъяров... Хәлләр ничек? Сөйләп җибәр.—Алемасов кемнәндер сорау алгандай тотты үзен.

Тәнендә жинелчә калтырану тойды Әхмәтсафа. Кабинетта салкынча, шунамы, тәненә каз жоннары тортеп чыкты. Ул ялт итеп Мөхәммәтжановка караш ташлады. Тегесе тыныч кына утыра иде.

—Рәхмәт, иптәш Алемасов. Редакция эшли. Партия установкаларын...

Алемасов аны кул хәрәкәте белән туктатты.

—Әйдә, ачыктан-ачык сөйләшүгә күчик. Без иптәшләр белән киңәштек монда... Алар каршы түгел...

Шунда гына Мөхәммәтжанов күтәрелеп Әхмәтсафага карады. Үзенне ышанычлы тот, дигәндәй, жинелчә генә күз кысып алды.

—Аңлап житмим, иптәш Алемасов.—диде Әхмәтсафа кыюлана төшеп.

—Менә мин дә аңлап житмим әлегә. Иптәш Мөхәммәтжанов, син үз фикереңдә каласыңмы?—Беренче, тапкыр сүз әйтүенә куанган төсле, авызын ерып алды.

Галим урыныннан сикереп торды.

—Әйе, иптәш Алемасов, мин Дәүләтъяров кандидатурасын яклыйм һәм аңа тулысынча ышанам.—Сүзен әйтеп бетермәстән, шап кире урынына да утырды.

—Алайса серне үзенә генә чишәргә дә ярый торгандыр. Сиңа, иптәш Дәүләтъяров, тагын да жаваплы вазыйфа тәкъдим итәргә булдык...

Әхмәтсафа куырылып куйды. Чигә төшкән баягы калтырау янә кайтты. Ул Беренченең дәвам итүен көтеп, тын да алмыйча утыра. Тынлык озаккарак сузылды. Әхмәтсафа кызарып чыкты. Тагын яңа эш, тагын күчену булыр микән инде?..

—Халык комиссарлары рәисе вазыйфасы буш тора. Син тарта алырсың дип уйлыйбыз...

—Кәнишне, тарта,—диде Мөхәммәтжанов,—Иң хәзерлекле кешебез ул безнен...

Үгетләп тору булмады. Яңа вазыйфага ризалык та сорап тормадылар. Бары, инде эш хәл ителгән дип санаган Алемасов, бер мәзәк сөйләп алуны кирәк дип тапты.

—Кирмәнчектә эшләгәндә бер иптәшне жаваплы вазыйфага кыстыйм. Ялындырып маташа. "Хатыннан сорап килим әле,"—дигән була. Күзләреннән күреп торам, урын жилле, эшне ычкындыру ярамый, егылып киткә-

нен дә белгертәсе килми. “Ярый,—дим,—бар, сорап кил,”—ачуланганны сиздермим тегеңә. Ялындырып торырга проститутка түгел бит инде. Мужик бул, хатыннан рөхсәт сора, имеш... Ике көннән соң килде. “Хатыныңнан сорадыңмы, нәрсә диде?”—дип каршы алдым. “Сорадым, хатын риза,”—ди инде бу. “Мин дә хатыннан сорадым синең хакта. Минем хатын риза түгел,”—дигәч, күзен шар итеп карап тора теге. Куып чыгардым кабинеттан.

Барысы да көлешкән булдылар...

...Беренче бүлмәсеннән ул ялгыз гына чыкты. Мөхәммәтҗанов Алемасов янында калды. Әхмәтсафа уйларын тәртипкә китерергә теләп, акрын гына нәшрият ягына атлады. Аңа бу сөйләшү хакында серне беркемгә дә чишмәскә кушылды, иртәгәсе көнне инде җаваплы постка рәсми рәвештә раслау булачак иде. Аның язмышына кагылышлы вакыйгалар шулхәтле тиз үзгәрә, яхшыгамы бу, яманга мы, чамалап та бетерми. Яңа эшкә тәкъдим итәләр, ул анда иҗләшеп тә өлгерми, тагын бер вазыйфа әзерләп куйган икән аңа Язмыш дигән абзый. Яңа эшкә билгеләгәндә сүз иң элек фирка исеме белән башланганга күрә, ул тәкъдимне кире кага алмый, рухы белән карышып, газаплана-газаплана риза була, тик эчке халәтен башкаларга сиздермәскә тырыша. Моны Рабига гына сизә, яңа эшкә күчәргә тиешлеген белгәч, ничектер, йөзенә курку билгеләре чыга. Ниндидер куркыныч хәлләрнең якынайганын сизенгән кебек, шомланып иренә карап тора. Рабиганың шушы карашын күтәрүе авыр Әхмәтсафага.

Өлкә комитетыннан чыгып, редакциягә әйләнеп кайтканчы күз алдыннан соңгы елны янә тулысынча үткәреп алды. Язмыш кайсы якка әйдәкли аны?.. Тырышып шушы сорауга җавап эзләде, әмма җавап таба алмады. Барысы да шома, чиста барган сыман, хәвефләнерлек сәбәп тә юк кебек. Шулай да гадәти чорда яшәмәү һәрдаим үзен сиздереп тора. Ниләр кичерде соң ул Казанга кайтканнан соң?

...Үткән елның гыйнварыннан—май аена кадәр ул Татарстан дәүләт китап нәшриятында сәяси әдәбиятны тәрҗемә итү бүлегендә эшләде, озак та үтми Татгосиздатның баш редакторы һәм партоешмасы сәркәтибе итеп билгеләнде. Аны бу эшкә Галим Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров димләгән иде. Нәшриятта эшләгән һәм соңыннан “халык дошманы” буларак кулга алынган Исхак Рәхмәтуллин, Сәлах Әтнәгулов, язучы Сәйфи-Казанлы, өлкә комитетында пропаганда бүлеген житәкләгән Зәки Гыймрановлар да аны яклаганнар иде. Нәкъ шушы кешеләрне ”халык дошманы“ дип кулга алып, төрмәгә утырттылар. Ул көннәрдә Әхмәтсафаның йокысы качты, һәркөн диярлек күрешеп, хәл-әхвәлләрне сорашып йөргән кешеләр, үзара гәп корганда нинди генә сүзләр ычкынмый авыздан, кем уйлап тора аны, шушы уйнап-шаярып сөйләшүләрдән кемдер дошманлык китереп чыгарса?..

ТКУда, аспирантурада үзенә белем биргән профессорлар Николай Эльвов, Тимофей Ищенко, Василий Слепков кулга алындылар. Өлкә комитетының икенче секретаре Бари Абдуллин да ”халык дошманы“ булып чыкты. Аның урынына Галим Мөхәммәтҗанов сайлангач, элекке ”яшьләр комиссар“ы, башкаларның гыйбрәтле язмышын кабатламаска омтылып, тиз арада үз даирәсен ныгыту эшенә тотынды, ягъни бу шомлы елларны исән-имин хәлдә үткәреп җибәрү нияте белән ныклап уйланылган чаралар күрә башлады.

Кулга алынган кешеләр истән бер генә көнгә дә чыкмый дисәң дә була. Әхмәтсафа әлеге кешеләрнең намуслы, тырыш журналистлар, булдыклы хезмәткәрләр икәненә дә иманы камил, әмма шундый көннәр килеп житте—һәркем үзенең шәхси куркынычсызлыгы хакында гына уйлый. Беркемнең беркемдә эше юк—кулга алалар, булдыклы кадрларны эштән, партиядән куып чыгаралар, гаебе бармы бу кешеләрнең, юкмы, уйлап торырга вакыт юк, бер-берсе белән ярыша-ярыша аларның өстенә ләгънәт белән пычрак коялар, әле кичә генә дуслашып, кунакка йөрешкән кешеләрнең шулкадәр ямьсезләнүләрен Әхмәтсафа инде аңлый да аңлата

да алмый. Сталинның "Социализм чорында сыйнфый көрәш тагын да көчәя",—дигән сүзләрен дога итеп ятлаган эреле-ваклы түрәләр, калдыкпостык интеллегенция әһелләре (зыялы дип хөрмәт белән телгә алырдай олут затлар күптән кулга алынып сөрелгән, юк ителгән, йә исә төрмә шулпасы хисабына җан асрауда иде) кем күпме булдыра ала, шуның кадәр сыйнфый көрәш учагына үз утынын ыргытып калырга, шуңа бәрабәр үзенең тормышын сакларга тырыша иде.

Әхмәтсафага НКВД тозагына эләккән кешеләрне төрлечә газаплаулары, җәзалаулары хакында да хәбәрләр ишетелгәли. Билгеле, бу хәбәрләр иң ышанычлы кешеләргә, үтә аулак урыннарда сер итеп кенә әйтелә, ишеткән кеше бу серне күңел сандыгына бикләп куя да, керпе кебек җыелып, үз эчендә бикләнеп, курку-шом белән яшәвен дәвам итә. Тоткыннарга физик тәэсир итү яки, гади генә әйткәндә, җәзалаулар үзәк комитетның яшерен күрсәтмәсе нигезендә алып барылганын да белә ул. Күпләр белә, әмма беркем дә дәшми. Дәшмәү—алтын, дигәнне тулысы белән аңлый башлады халык.

Беркөнне Әхмәтсафа өенә кайтып чишенеп өлгермәде, каршысына Рабига атылып килеп чыгып колагына пышылдады: " Бүрәнә башы тишек!" Үзе күзен-кашын уйнатып, әлеге сүзләрнең мәгънәсен аңлатмак була. Түргә үтсә шул билгеле булды, йомыш табып күрше хатыны килеп кергән икән дә, кайткан унайга ире әллә нәрсәләр такылдап ташламасын дип, Рабига аны кисәтергә чыккан икән.

Ил өстендә шом, һәркемнең баш очында кара болыт шәүләсе, һәркем үз янәшәсендә ниндидер күләгә әйләнгәләп-тулганып йөрүен белеп, тоеп тора. НКВД үрмәкүч пәрәвезе сыман бөтен яшәешне чорнап алды. Аз гына селкенсәң, күзгә күренмәс җеп тартылып куя, тирә-юньдә ниндидер шикле хәрәкәт барлыкка килүен сизеп, тын кысыла, йөрәккә суык йөгерә.

"Кызыл Татарстан" газетасына җаваплы редактор билгеләнгәч, аны Галим Мөхәммәтҗанов чакыртып алды. Әхмәтсафаның бу эшкә авырлык белән риза булганын яхшы белгән Галим аны үгетләргә теләде булса кирәк.

—Хәзер телим-теләмим дигән сүзләр, партия тәкъдиме хакында озаклап уйланулар, тәкъдимгә каршы төшү кебек күренешләр бетте бит ул, иптәш Дәүләтьяров,—диде ул яңа редакторга сүрән карап.—Бармак очы кемгә килеп төртелә, шул минутта бу бәндәнең язмышы да хәл ителә. Йә—ул дус, йә—дошман.—Мөхәммәтҗанов сүзен әйтеп бетермәде, кабинет түренә элеп куелган Сталин сурәтенә борылып карап алды һәм корыч тавыш белән сөйләвен дәвам итте.—Әйе... Кадрларны нығыту, булдыклы кешеләрне барлау, аларга җаваплы эшләрне ышанып тапшыру кебек мөһим мәсьәләләр хәл ителә бу көннәрдә. Кадрлар барысын да хәл итә! Син безнең кадр, иптәш Дәүләтьяров, партия солдаты.—Ул урыныннан торып, Әхмәтсафаның каршысына килеп басты.—Беләм, беләм, син дә йоклап ятмыйсың. Информация житәрлек синдә.—Галим сер сөйләгәндәй, пышылдауга күчте.—Яшермим, синең кандидатура жиңел генә үтмәде. Бигрәк тә Абрамов белән Байчурин каршы килделәр. Журналист түгел дип, аяк терәп карыштылар, ну мин булдыра алганча аңлаттым. Ризалашмый хәлләре юк. Беләләр минем мәңге икенче булып йөрмәсемне.—Ул күз кысып, Әхмәтсафаның җилкәсенә кулын салды.—Алда эшләрнең очы-кырые юк, унны-сулны карамыйча алга, алга! Девиз шул безнең. Киләчәк, ышанып әйтәм, безнең кулда?—Ул уфтанган кебек әйтеп куйды.—Жәл, синең белән иркенләп сөйләшү иде теләгем, барып чыкмады, мине Беренче үзе көтә.—дип, ул ашыгып Әхмәтсафага кулын сузды.—Иптәш Ежовның сүзләрен онытма: "Безнең илдә население өч категориягә бүленгән—беренче категория—гаепләре ачылып, хөкем ителгәннәр, икенчеләре—тикшерүдәге тотаклар, өченчеләр—шиклеләр"—ди ул. Шәп әйтә бит, ә?!. Менә бу коммунистларча! Турыдан яра тимер нарком. Минем уемча, без өченче категориягә якын кешеләр... Суга кергәч,

коры чыгып булмый, аңлыйсың. Без инде суның уртасында. Нык куллы бул, җебеп торма!

1937 елның егерменче июнендә Татарстан партия оешмаларының унсигезенче өлкә конференциясендә Әхмәтсафа Дәүләтъяров өлкә комитеты әгъзасы итеп сайланды. Исемлектә ул егерменче кеше иде...

Конференция бигрәк тә матбугат эшен оештыруга әһәмият биргән карар чыгарды.

"Партия җитәкчеләренең матбугатка кырын карауларын тәмам бетерергә, матбугатта партия җитәкчелеген яхшыртырга.

Газеталарның идея-политик дәрәҗәләрен югары күтәрергә, партия тормышы һәм партия төзелеше мәсьәләләрен яктыртуны көчәйтергә, газета битләрендә үзенне тәнкыйтьләүне генә җәелдерүне тәэмин итәргә, масса белән бәйләнешне көчәйтергә, редакциядән тыш автор кадрлар белән эшләүне оештырырга кирәк".

Конференциядә катнашучылар еш кабатланган "Политиканы хуҗалыктан аерырга ярамый. Без политикадан китә алмаган шикелле үк хуҗалыктан да китә алмыйбыз",—дигән даһи фикернең асылын аңларга тырышып, илаһи бер әсәрләнү кичереп утырдылар. Бу сүзләр Сталинныкы иде һәм бу кадәр дә катлаулы нәрсәне гениаль дәрәҗәдә гади итеп ул гына әйтә ала иде.

Конференция Альфред Карлович Лепаны кабат өлкә комитетының беренче секретаре, "халык дошманы" буларак кулга алынган Бари Абдуллин урынына Ленин-Сталин юлыныннан тайпылмый баручы Галим Мөхәммәтҗановны икенче секретарь итеп сайлады һәм икенче көнне үк Әхмәровка Дәүләтъяровны чакыртып, газетаны аның кулына тапшырырга боерды.

Утыз җиденең егерме икенче июнендә "Кызыл Татарстан" газетасының йөз дә кырык икенче санына инде җаваплы редактор тамгасын Әхмәтсафа Дәүләтъяров салды. Мона кадәр җаваплы мөхәррир вазыйфасын башкарган Исхак Еникеевны ул күреп тә өлгермәде...

Нинди көннәр иде ул!

...Илдә бер яктан карасаң шом, шик-шөбһә тулып ята, икенче яктан алсаң—иләслек, күтәренкелек хөкем сөрә—шушы көннәрдә генә Мәскәү—Төньяк Котып—Америка Кушма Штатлары маршруты буенча туктаусыз очыш төгәлләнгән иде. Үзе беренче мәртәбә кул куеп чыгарган газета тулаем дип әйтерлек шушы очышта катнашучыларны зурлауга корылган иде. Беренче битнең башына зур хәрефләр белән: "Бөтендөньяны таңга калдырган геройларыбызга—Чкалов, Байдуков, Беляков иптәшләргә ялкынлы большевистик сәлам!"—дип язылган сүзләргә Әхмәтсафа озаклап карап торды.

Шунысы сәер—күнелендә соклану хисе юк иде. Җанын нидер бимазалый. Берәр ялгыш китмәгәнме, беренче эшеннән үк гаеп, хата табып, адәм хурына калдырып редакциядән куып чыгармаслармы? Күнелдә шушы сорау, күз алдында үзен кая куярга белми бәргәләнүче Габдуллин...

Газетаның бу саны басылган төнне ул типографиядән чыкмады да. Басу машиналары тавышы, буяу исе торган саен аны исәңгерәтә, менә хәзер генә нидер килеп чыгар да, бөтен эш туктап калыр, барысы да аңа бармак төртеп—"Дошман, дошман...—" дия-дия такмакларлар кебек. Типография эшчеләре яннарына килеп баскан яңа редакторга кырын карап алалар, Әхмәтсафа мондагы кешеләрнең бер-берсенә ышанычларының тәмам югалганын, беткәнен аңлап, тәненә суык йөгерде. Ерак Бохарада, чит-ятлар арасында йөргәндә дә бу кадәр ялгыз тоймады ул үзен. Бүген исә ул ялгызлык хисенең нәрсә икәнен үз җанында татыды. Барысы да хата-мазар китмәсен дип курка монда, инде хата китеп, ул дөньяга фаш була икән, җавап бирүче берәү булачак: ул кеше—Әхмәтсафа Дәүләтъяров... Котыпчыларны юлбашчы Сталин, аның тугрылыклы дуслары Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Жданов, Ежов, Микоян, Андреев котлаган. Аларны укый-укый күзләре

талды Әхмәтсафаның, инде газетаның сынау саны кулга кергәндә, күз алдында хәрефләр биешеп, ни укыганын аңламас хәлгә житеп килә иде. Бераз ял итеп алгач, янә бер мәртәбә укып чыкты, хаталар юклыгына ышангач, тынычланып калды, иң мәзәге шул, хәтта бер заман иңнәренә канат үскән сыман булып, шушы геройлар белән бер чорда яшәвенә сөенеп туймыйча, үзен бик-бик бәхетле итеп сизә башлады.

Өенә таң алдында гына кайтып житте ул. Аны Рабига куркулы караш белән каршы алды... Хатынының күзендә чагылган курку Әхмәтсафаның төшенә керә башлады. Рабиганың вакыт-вакыт нindидер өметсезлеккә бирелүе һич тә охшамый иде аңа.

* * *

Жаваплы редактор вазыйфасына керешкәч, кулына килеп кергән беренче истәлекле хат Мәскәүдән, Муса Жәлилдән иде.

Муса газетаның жаваплы редакторы итеп Әхмәтсафаның билгеләнүен белсә дә, хатны артык рәсми язган. Күрәсең, моннан алдарак, ягъни август башларында газетада чыккан Сәгыйтов хаты аны шактый хафага салган һәм бу хатның дөнья күрүендә яшьлек дусты Әхмәтсафаның да гаебе бар сымаграк хис иткән.

"Иптәш редактор!

Шушы хатны газетада басып чыгаруыгызны сорыйм:

"Кызыл Татарстан" газетасының 1937 ел, 10 августта чыккан 183 нче номерында Ф. Сәгыйтовның ( хат авторының фамилиясе үзгәртелеп бирелә. Автор) "Татар операсы студиясе турында" дигән мәкаләсе чыкты. Бу мәкалә нигездә Татар опера студиясенең эшләрен дөрес тәнкыйть итә һәм житәкчелек тарафыннан жибәрелгән хаталарны, житешсезлекләрне төбендә дөрес фаш итә. Шунлыктан студиянең эшен янабаштан коруда, аның житешсезлекләрен бетерүдә бу мәкалә уңышлы роль уйнаячак.

Ләкин мин мәкаләдә минем исемем белән бәйләп язылган кайбер юлларга карата түбәндәге төшендерүне биреп үтәргә үземне бурычлы саныйм:

Ф. Сәгыйтов үзенең мәкаләсендә минем тарафтан язылып ята торган кайбер әсәрләр турында: "М. Жәлил иптәш "Алтынчәч", "Балыкчы кыз" ны яза, ләкин... алар бүгенге көн сорауларына жавап бирерлек булмыйлар",—ди. Аннан: "... аның (Төхфәтуллинның—М.Ж.) биргән темалары да үзләренең исемнәре һәм эчтәлекләре белән бераз уйга калдыралар",—ди дә, шул әсәрләр арасында "Балыкчы кыз" белән "Алтынчәч"не күрсәтеп, түбәндәге юлларны өсти:

"Болар бүгенге көн продуктлары булудан бигрәк, совет эшчеләр сыйныфы тарафыннан жимерелгән иске тормышның үлем алдында, актыккы сулышларын алганда хыяллану нәтижәсендә туган "жимешләре"нә ошыйлар".

Башлап балыкчы кыз турында:

"Балыкчы кыз" әле минем тарафтан язылып беткәне юк. Шунлыктан беркая да тапшырылганы да, бер жирдә дә укылганы да, тикшерелгәне дә юк. Бары үткән ел студия каршындагы бер киңәшмәдә аның планы гына тикшерелде һәм төбендә темасы, сюжеты яраклы табылды. Ләкин бу әсәрне язу өчен минем бер оешма белән дә договор төзегәнем һәм акча алганым юк. Аны язу минем ижат планына керсә дә, төрле сәбәпләр белән әле язып бетергәнем юк. Шулай булгач, Ф Сәгыйтов бу әсәр белән бөтенләй таныш түгел. Тик аның исемен генә ишетеп белә.

Бу әсәрнең темасы шуннан гыйбарәт: 1933 нче елда Каспий һәм Волга буйларындагы балыкчы колхозларында сыйнфый дошман калдыклары чираттагы путинаны өзәргә, балыкчы ударникларны коралсызландырырга маташалар. Ләкин батыр балыкчы колхозчылар, аларны фаш итеп, путина планын ударникларча үтиләр.

Минем беләсем килә: ни өчен балыкчы колхозларындагы сыйнфый дошман калдыкларына каршы көрәшне чагылдырган әсәр "бүгенге көн соравына җавап бирми" һәм ни өчен аны язу: "җимерелгән иске тормышның үлем алдында, актык сулышларын алганда хыяллану нәтиҗәсендә туган "җимешләре"нә ошый" икән? Кайчаннан бирле совет язучысы өчен балыкчылар колхозындагы тормышны чагылдыру хурлыклы, оятлы эшкә әйләнде?

Билгеле, Ф. Сәгыйтов монда әсәрнең исеменә карап кына хөкем йөртә. "Балыкчы кыз" дигән исем аның күңелендә шик тудырган да, ул әсәр язылмас борын алдан җавапсыз чыгыш ясап, авторга политик ярлык ябыштырырга тырыша.

Инде "Алтынчәч" турында. Бу әсәр ханнарга каршы үзенең ирекле йорты өчен көрәшкән халык батыры турындагы борынгы халык әкиятенә нигезләнгән. Дөрес, либреттоның беренче вариантында күп кенә кимчелекләр бар. Аларны рецензент иптәшләр дөрес күрсәттеләр. Ләкин аның турында бер җирдә дә бөтенләй кире кагып карар чыгарылганы юк. Киресенчә, аны төзәтергә куштылар. Ашыгыбрак язылу аркасында, анда тарихи чорларны саташтыру, образларны җанлы һәм тирән эшләмәү, халык (масса)ның ролен ачык күрсәтмәү, либретто өчен артык озын язу кебек кимчелекләр киткән. Аларны төзәтеп, ныклап эшлисе бар. Әсәрнең язылу процессында (беренче вариантларында) бик эре хаталар булырга мөмкин. Иптәшләрчә тәнкыйть һәм рецензияләр шуларны төзәтергә, әсәрне тулы, дөрес язып тәмамларга ярдәм итәләр.

Ләкин ни өчен халык батырлары турындагы халык әкиятләрен (гомумән халык әкиятләрен) тема итеп алып эшләү совет язучысы өчен хурлыклы булырга тиеш? Кайчаннан бирле безнең өчен халык иҗаты, халык әдәбиятының бай, матур темалары ят һәм дошман булдылар? Бу бит ачыктан-ачык авербахчы-таппчыларның күптән читкә кагылган "сулагай" карашлары!..

Монда да, билгеле, Сәгыйтовка исем ошамаган. Ул халык әкиятенең исеменнән үк өркеп, тизрәк РАПП "тәнкыйтьчеләр"енчә ярлык тагарга ашыккан. Болай булгач, Ф. Сәгыйтов совет язучысы Алексей Толстойның "Петр I" дигән романының исеменә ничек түзә икән? Патшаның исеме ләбаса!

Казакъ, грузин, үзбәк музыка театрлары Мәскәүгә килеп, үзләренең борынгы фольклорына нигезләп язылган "Кыз Жефәк", "Даиси", "Әбүсәлам һәм Этери", "Фәрхад һәм Ширин" кебек матур әсәрләрен күрсәттеләр һәм хөкүмәт членнары, Мәскәү хезмәт ияләре тарафыннан алкышлап каршы алындылар. Борынгы халык әкиятләренә, тарихи темаларга, матур исемнәргә "сулагай" кизәнергә ярата торган безнең "тәнкыйтьче" бу хәлгә ничек чыдап тора икән?..

Шул ук мәкаләдә тагын: "хәзер "Югалган шатлык"ка язылган музыкага яңа эчтәлек язу директор тарафыннан М. Җәлил иптәшкә тапшырыла..." диелгән. Бу шулай ук нигезсез гайбәт. Мин "Югалган шатлык"ка яңа эчтәлек бирергә һич җыенганым юк. "Югалган шатлык" турында минем фикерем тиешле документларда әсәр кулга төшкән моментта ук әйтелгән.

Мин һәм композитор З. Хәбибуллин атаклы шагыйрь М. Гафуриның "Кара йөзләр" дигән әсәрен либретто итеп эшләү турында уйлаштык һәм рецензиягә тәкъдим ясадык.

Һәркемгә билгеле, М. Гафури белән Ф. Бурнаш икесе ике кеше (бәлки моны Сәгыйтов кына белми торгандыр). "Кара йөзләр" дигән әсәрнең тик Бурнашка һич бер төрле мөнәсәбәте юклыгын һәркем белә. (Директорның миңа беркайчан да тема биргәне юк.)

Мин уйлыйм, һәрбер либреттист һәм композиторның атаклы совет язучыларының танылган әсәрләрен музыкага яраштырып эшләргә хаклары бар.

Ф. Сәгыйтов бу мәсьәләләрдә тикшермичә, нигезсез һәм җавапсыз чыгыш ясап, безнең алдагы эшебезгә кара ыргыта.

Югарыда күренгәнчә, Ф. Сәгыйтов мәкаләсенең бу өлешен тикшермичә, коры гайбәткә, ишеткән сүзләргә һәм исемнәргә таянып язган. Мондый җавапсыз "тәнкыйтьләр" язучыга һичтөрле файда бирмиләр. Мәкалә төбендә опера студиясенен хаталарын һәм житешсезлекләрен дөрес тәнкыйтьли һәм, һичшиксез, мин, студиянең бер җаваплы эшчесе булу сыйфатым белән, ул хаталар, җитешсезлекләр өчен үземне җаваплы саныйм.

Сәлам белән: М. Җәлил."

...Сәгыйтов зур эшләгән кыяфәттә аның алдына "Татар операсы студиясе турында" дигән нигездә тәнкыйть рухында язылган һәм бигрәк тә Муса Җәлилнең иҗатына тап төшерү нияте әллә каян күренеп торган мәкаләсен җаваплы редакторның эш өстәленә кертеп салган көнне яхшы хәтерли Әхмәтсафа.

Эше тыгыз чак иде. Сәгыйтовның һич чыгып китәргә җыенмавын сизеп:

—Утырып тор дисәм, хәзер типографиягә йөгерәм, кайтып кергәнемне көт дисәм...—дип сүз башлаган иде, аны Сәгыйтов кырт туктатты.

—Мәкаләне хәзер үк укып чыгуыңны көтәм, иптәш Дәүләтъяров. Эшем чикләвеге булып кыланмасаң да була. Газета язмышы без—журналистлар кулында ул. Синең чабулап йөрүеңнән әлләни өре чыкмас, ә мин сиңа монарчы күтәрелмәгән тема алып кердем. Тиз генә күз йөртеп чык та, әллүр, сангa урнаштыру чарасын тап. Мәсьәлә үтә дә мөһим, көтеп торышлы түгел, сүз яңа татар сәнгатенә хас кимчелекләрне вакытында күрсәтеп, ул житешсезлекләрне кичекмәстән төзәтү турында бара!—дип кайнарланып, чәпчеп алды.

Сәгыйтовтан болай гына ычкынып булмасын аңлаган Әхмәтсафа мәкаләне ашыкмыйча укып чыкты һәм бертын уйга калды. Сәгыйтов үз амплуасында—талантлы чордашларын фаш итү белән шөгыльләнә.

—Житди... нәрсә бу... Муса нәрсә дияр бит...—диде көттереп кенә Дәүләтъяров.

Сәгыйтов канәгатьләнеп урындык артына ава төште.

—Минем юк-бар язмаганга инде биш быелтыр, Сафа. Муса, башында акыл булса, рәхмәт әйтер. Миңа нәрсә, язган, беткән, калганы аның үзеннән тора. Обыватель баткаклыгыннан чыга алса—кеше булыр, көченнән килмәсә, яңадан андый мөһим әйбергә кагылмаслык итәрбез... Сиңа яңалык бу кәнишне. Ләкин безнең һөнәр шуны таләп итә. Ну, эш барышында үзең дә аңларсың. Муса бүген дус, иртәгә чуртым белсен—кем ул? Вакытында кисәтеп кую зарар итми безнең эштә.

—Муса хакында алай уйларга ничек батырчылык итәсең, Фатыйх. Безнең белән бергә үскән, язмышның бар җәберен кечкенә иңнәренә күтәреп тә, бирешмәгән, тырышлык, иҗтиһат итү аркасында мәртәбәләргә ирешкән дустыбыз ич ул.

Сәгыйтов калын иреннәрен чалшайтып, аның сүзен бүлдерде.

—Шыттырма, иптәш Дәүләтъяров, Муса белән дә, башкалар белән дә дус булмадым. Мин һәр нәрсәгә сыйнфый күзлектән карыйм. Үземә җавап тота торган кеше мин, башкалар өчен җавап тотып, тинтерәп йөрисем килми.

—Шулайдыр, тик мәкаләне ашыктырмыйк. Мусага, яңа аяк басарга азапланган татар опера студиясенә болай кизәнү... Ахыры хәерле бетмәскә дә мөмкин бит, нинди чорда яшәгәнне онытма!

Сәгыйтов сикереп торды, ачулы күзләренә кан йөгерде.

—Нинди чорда яшибез димәкче әле син? Син, нәрсә, минем белән малай-шалайлы уйнап утырган буласың? Мин Татарстанның әйдәп баручы журналистларыннан берсе.—Сынар кулының бармакларын уйната-уйната Әхмәтсафага сузды.—Без менә күпме андый абруйлы, журналистиканы тотып торучы каһарманнар, аңладыңмы? Ике-өч и обчелся. Син гәзит эшен-

дә әлифне таяк дип белмисең. Артыннан тәртеп йөрүче булгач... утырасың инде җан көеге булып. Бу синә, Дәүләтъяров, Иске Байсар авылы идарә йортыннан кулак бичәләрен куып тарату түгел, катлаулы мәсьәлә. Моңа башың җитми синең, шуңа куркасың бастырып чыгарырга. Ашыгыргамы, ашыкмаскамы, анысын сиңа караганда мин яхшырак беләм.

—Энәдән дөя ясама, Сәгыйтов! Мин әле журналистларга тел-теш тигезгәнем юк.

Әхмәтсафа сабырлыгын җуймаска тырышып, бу чик-чаманы белмәүче бәндәне акылга китерергә азапланган арада, Сәгыйтов өстәлдә яткан мәкаләсен шатырдатып тартып алды да, каты басып чыгып китте.

—Беләм мин сине...—диде Сәгыйтов, чыгып барышлый үчлекле тавыш белән.—Ясалма рәвештә минем эшне тоткарламакчы буласың. Сәбәп эзлисең. Барып чыкмас! Өстеңнән таптап узам мин синең. Контр сазлыгына тәгәрәгән Муса Җәлилов ишеләрне яклап маташасың. Өлкә комитетына барам, моннан соң һәр мәкаләмне өлкә комитеты раславы белән тапшырачакмын, каршы килеп кара!

Сәгыйтов сүзендә торды, өлкә комитетында да аңа каршы төшәргә җөрьәт итүче табылмаган, ахры. Махсус резолюция салдыртып китергәч, мәкалә икенче көнне үк дөнья күрде. Шуның аркасында Муса белән Әхмәтсафаның арасы шактый суынды, аны җылытырга кабат форсат булмады инде... Язмыш аларны бер-берсеннән коточкыч тизлек белән ерагайта, моны алар үзләре генә сизмиләр иде әле...

## VI

Яна вазыйфасына баш-аяк чумып бетмәсә дә, Сәгыйтов ишеләр белән шактый тарткалашырга өйрәнеп килгән вакытта Әхмәтсафа Дәүләтъяров тормышында яңа борылыш хасил булды.

"Кызыл Татарстан" газетасы 1937 елның унсигезенче сентябрендә Татарстан АССР унынчы чакырылыш Үзәк Башкарма Комитетының җиденче сессиясе карары белән Әхмәтсафа Мостафа улы Дәүләтъяровның Татарстан Республикасы халык комиссарлары советының рәисе итеп билгеләнүен хәбәр итте.

Мөхәммәтҗанов бөртекләп үз тирәсенә туплаган яшь көчләрне мәйданга чыгарыр вакыт җитте. Кайберәүләр: "Мөхәммәтҗановка көн килде"— дип тә уйладылар бугай. Аның тирәсендә бөтерелүчеләрнең кисәк күбәеп китүе моны ачык дәлилли иде булса кирәк.

Мона кадәр халык комиссарлар советын җитәкләгән Кыям Абрамов белән Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Гомәр Байчурин инде "халык дошманы" буларак кулга алынып, "Черек күл"гә озатылганнар иде.

Әхмәтсафа эш буенча Кыям Абрамов белән очрашкалаганы булды. Донбасс шахталарында күмер чапканда, ташкүмер астында калып сул кулын өздергән чулак Абрамовның яраткан җыры да шул шахтада үткән бәхетсез үсмер чакларын искә төшереп, күзләрдән яшь китергән "Шахта" җыры иде.

Әле җәй урталарында гына, Лепа тәкъдиме белән бөтен өлкә комитеты белән берлектә Идел буена ял итәргә чыккан иделәр. Галим Мөхәммәтҗанов Лепа белән бер төркемдә утыра, нидер сөйләп көлдереп тә ала бугай, аңа рәхәт, ә менә Әхмәтсафа бу кадәр җитәкчеләр арасында үзен кыен хис итә, шуңа күрә бер кырыйдарак йөрүне хуп күрде. Кисәк каршысына Кыям Абрамов килеп чыкты. Нигәдер "Чулак Абрам"нан шүрли иде Әхмәтсафа. Буй-сынлы, чәче дулкынланып тора, чибәр бу кеше яшьли фирка эшендә чарланып, үз сүзен турыга ярып әйтә, һәрвакыт нидер исәпләп йөргән кебек. Шунадырмы, кырыс күренә. Үзара гәпләшкәндә, Мөхәммәтҗанов аны яшьләргә ышанып җитми дип, еш кына тиргәп тә ала иде. Әхмәтсафага да ул өстәнрәк караган төсле тоелган иде. Кыям Абрамов аптырабрак калган Әхмәтсафаның иңсәсенә дусларча кагып алды:

—Ник аптырап йөрисең, канәт?..

Дустанә эндәшүгә ни дип тә җавап бирергә белми, Әхмәтсафа авыз эченнән ботка пешереп алды:

—Район тормышыннан соң, шәһәргә ияләнеп җитеп булмый бугай...

—Бәй, кит тә бар кире районга, анда булдыклы егетләргә кытлык...—Абрамов шаркылдап көлде.—Юк инде, канәт, җибәрмибез сине кире авылга. Безгә кирәк күренәсең... Әйдә, Идел буена барып килик әле...—Җавап көтмәстән, биек ярга табан атлады. Ирексездән, Әхмәтсафа да аңа иярде.

Кыям Абрамов янында басып торган егеткә игътибар итмәстән, Идел киңлекләренә карап, моңсу тавыш белән сузды:

Шахталарга мин төшәмен,
Җырлап күмер кисәмен.
Гомрем булып, таш басмаса,
Ташламам җан кисәгем...

Идел өстеннән искән дымсу, салкынча җил тәнгә рәхәтлек бирә иде. Абрамов күзен кыса төшеп, көмештәй ялтырап аккан су өстенә карап торды да, яр читенә үк килеп утырды.

—Адә, канәт, утыр. Шышы ямьне ничек ташлап китәсе, ә?

Әхмәтсафа ни дип җавап бирергә белмәде. Сорау аңлашылмый иде. Ни өчен китәсе, кайда китәсе, кайчан?..

—Думави дөрес әйткән, Дәүләтьяров, "хөрмәтле яшь гомерем"—дип язган бит ул, әйеме... Андый шагыйрьне ишеткәнең бармы?—Җавап көтеп тормый, сүзен дәвам итте.—Уйлап баксаң, никадәр тирән әйткән бит: сөенече дә, үкенече дә шул сүзләргә сыйган. Шыңа шагыйрь халкын особый диләр дә инде. Хөрмәтле яшь гомеркәйләр үтте-китте менә. Сезгә кала дөнья, бездән сезгә... Бик гади дә кебек, югыйсә, килү бар, китү бар. Барыбыз да бертөрле киләбез дөньяга, китүләр генә төрлечә... Мөхәммәтҗанов ашыга, каударлана ул. Шуңа Байчурин белән мине өнәп тә бетерми. Яндырасы килми егетне, утка кергәнен сизми, бөтен бәла шунда. Без яшь, белемле, милли кадрларга каршы түгел, үсеннәр алар, ишәйсеннәр, көч тупласыннар, бер-берсенең кадерен, кирәген белсеннәр, төзесеннәр без төзеп җиткермәгән иркле Татарстанны,—дип аңлатмак булабыз, шул позицияне егеткә сеңдерергә тырышабыз. Ә ул...—Абрамов ачынып, сыңар кулын читкә селтәп алды.—Их, чурту, янмаска иде дә...

Көчле, кыю, туры кешенең кинәт "халык дошманы" булуына ничек ышанырга?.. Буа районы иске Тинчәле авылы егете, Альфред Лепадан бер генә яшькә кече, әле җин сызганып эшләп йөргән көннәре иде. Июльнең соңгы көнендә кулга алганнар дигән хәбәре ирешә: гәҗиттә кереп китәсе бөтен мәкаләләрдән Абрамов фамилиясен алып ташларга боерык килеп төште.

Гомәр Байчурин исә Саба ягыннан, Мишә елгасы буенда үскән ир-егет. Лепа белән Абрамовка караганда күпкә өлкән, тормышны яхшы белә, шуңа аның белән исәпләшәләр, киңәш-табыш итеп эш йөртәләр иде. Базык, әмма нык гәүдәле, кара чәчле, куе мыеклы, күп сөйләшергә яратмый иде. Ул да Кыям Абрамов кебек яшьли шахталарга төшеп күмер чапкан, патша армиясендә хезмәт итә, гражданнар сугышында катнаша, Арча районында Татарстанда беренчеләрдән булган Колай совхозын оештыра. Егерменче еллар уртасында ул Минзәлә кантонында эшли, шуңа күрәдерме, очрашкан чакларда, Әхмәтсафага—"Саумы, якташ!"—дип, күрешергә кул суза иде. Ул сак астында икән, аның фамилиясен дә Әхмәтсафа үзе карап торып гәҗит битләреннән алып ташлаттырды...

Лепаны бераз соңрак, сентябрь аенда Мәскәүдә кулга алып, Казанга озаттылар.

Галим Мөхәммәтҗанов бу этапта үзенең Беренче була алмавын да чамалап алгач, үзен кая куярга белми йөрде. Курыкканы—аның да Лепа

артыннан "Черек күл"гә озатылу мөмкинлеге. Алемасовны Беренче итеп сайлап куйгач, берара югалып калган булса да, бу халәттән айныгандай булды. Вакыйгаларның барышы аңа бөтенләй үк кире дә түгел сыман. Маленков та, Алемасов та миңа ышаналар, мине саклап калырга тырышалар, ахры, дигән уйдан бераз тынычлана төште һәм һәр адымында шушы ышанычны акларга әзер икәнен күрсәтергә омтылып, эшкә ябышты. Болай уйларга сәбәп тә бар—Алемасовка республиканың дилбегәсен тоттырган көнне үк, Маленков үз янына нәкъ менә Мөхәммәтҗановны чакырды.

Галим каушап, ни уйларга да белми кергән иде Мәскәү вәкиле янына, аннан кош тоткандай чыкты.

Маленков, Сталинга охшарга тырышып, Мөхәммәтҗановның барлыгын да искәрмәгән кыяфәттә, ишекле-түрле йөрештереп алгач, сынаулы караш ташлап, Мөхәммәтҗановка карап катып калды. Аннан арган төс белән сорау бирде. Әйтерсең бу сорау аның җанында өч атна йөреп, үтенә тигән дә, хәзер генә якты дөньяга чыгарырга форсат туган:

—Татреспубликада абруйлы, белемле, яшь, шул ук вакытта халык комиссарлары рәисе йөген дә тарта алырлык тәҗрибәле милли кадр бармы?..

Галимнең башына шаулап кан йөгергән кебек булды. Нәрсә дияргә? Әгәр үзенең кандидатурасын күрсәтсә? Бәлки Маленков аннан шундый җавап көтә торгандыр. Алай дисәң, кайчан гына өлкә комитетының икенче секретаре итеп сайланды ул, җаваплылыктан кача кебек булып чыкмасмы? Көттереп кенә Галим үз сүзен әйтте:

—Бар андый кеше, иптәш Маленков. Дәүләтъяров фамилияле бик төпле егет бар,—дип җавап бирде.

—Аңа Алемасовның карашы ничек?

Галим сәяси уеннарда шактый чарланып килә иде, хәйләгә күчте.

—Иптәш Алемасов вакытында сәяси аренага чыкты ул. Моңарчы аңа юл бирмәделәр...

—Шәхси делосын туплап бирегез, мин аны Мәскәүгә алып китәм,—диде Маленков.—Тагын берничә кандидатура уйлап куегыз. Монысы үтмәве дә мөмкин.

...Болай да борчулы көннәр үткәргән Галим Мөхәммәтҗановның башына янә бер кайгы төште: Дәүләтъяров белән янмасмы, черт возьми. Бәхетенә, Мәскәүдән өстәмә кандидатура сораучы булмады. Әмма тынычланып та булмый, иң нык үткә тигәне—Дәүләтъяров хакында Югары Совет сессиясе булачак көн җиткәнче Алемасов ләм-мим бер сүз әйтми йөрде. Сессия көнне иртән генә, кисәк Мөхәммәтҗановны үз янына чакырып:

—Рәислеккә без тәкъдим иткән кандидатураны Үзәк Комитет хуплый, Дүләтъяров белән сөйләшеп алсаң да була...—диде.

"Без" дигән сүзне ишеткәч, Мөхәммәтҗановның эченә җан керде. Димәк, Алемасов белән аның борчагы пешәчәк! Кайбер катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә Алемасовка ышыкланырлык, "без" исеменнән сөйләрлек бераү кирәк булуы аңлашылмаслык нәрсә түгел, бигрәк тә бүгенге вәзгыятьтә. Куркып, шикләнеп йөрүдән туктарга вакыт! Үзенең республикада реаль властька ия икәнлегенне белдерер көннәр житте, дип куанды ул. Бу минутта ул үзен капкыннан ычкынган затлы киек итеп хис итте.

Халык комиссарлары рәисе итеп Әхмәтсафа Дәүләтъяровны бертавыштан расладылар.

Бу хәлләргә, исән булса, Гомәр агасы, ягъни агабыкай ничегрәк бәя бирер иде икән? Әле Урта Азиягә китеп, җаваплы вазыйфаларга билгеләнгәч тә, аның әйткән сүзләре исеннән китми. "Биек меңдең, үз сукмагың белән менденме, әллә эткәләп-төрткәләп торучылар булдымы?—дигән иде ул, аңа акыл биргән тавыш белән.—Үз сукмагың белән менсәң, ярый торган эш ул күтәрелү. Этеш-төртешкә калса, андый нәрсә алдаучан була. Тиз түбән очарга мөмкин адәм баласы, андыйлар, күп очракта, аякларына яңадан

баса да алмыйлар инде, имгәнеп, зәгыйфьләнеп калалар." Соңгы очрашуда, инде үләр алдыннан монсуланып ул Әхмәтсафага сәер сүзләр әйткән иде. "Адәм баласы тешен кыса-кыса дөньядан китмәс өчен тырыша-тырмаша. Минем менә яшәргә җан тырмашып ятасым килми. Китәргә, тизрәк дөнья белән алыш-бирешне өзеп, Ходай хозурына җитәсем килә.—Аптырап калган Әхмәтсафага кызганган шикелләрәк карап торды да, сүзләренә ачыклык кертте.—Ике нәрсә үлемемне үкенечле итми, беренчесе— карчыгымнан ятим калгач, мина яшәүнең тәме, мәгънәсе, яме китте; икенчедән—минем сез төзегән денсез тормышта бер генә көн дә торасым килми. Аллаһ дисәң, җанга рәхәт, аны куйсаң, тәнгә рәхәт... Борынгылар сүзе. Тән рәхәте белән генә булмый шул, җан рәхәтеннән аермасын Ходай. Сез тән рәхәтенә баш куйдыгыз. Афәтнең төбе шул. Мин әүвәлге хозурлыклар, иманлы дәверләр хакында уйланып көннәр, төннәр үткәрәм, шул арада гомерем шәменең мае кимүенә сөенеп ятам." Агабыкайның истә калган соңгы сүзләре шул булды.

Утыз дүртенче елда аның үлү хәбәре килде. Тормышның мәгънәсен үзенчә аңлатып, төшендерүче изге затның китүен Әхмәтсафа эш-мәшәкатьләр белән артык хафасыз гына үткәреп җибәргән сыман тоелса да, Гомәр ага һич көтмәгәндә искә төшеп, йөрәкне нидер яндырып үткәндәй була. Өлкәннәрнең акыллы сүзләренә, киңәшләренә адәм баласы һәрчак мохтаҗ икән шул, алар исән булганда гына кадерләрен белеп бетермибез, китеп баргач, күпме генә үкенмә, алар инде кайтмыйлар. Хәтердә терелеп, истәлекләрдә генә яши Гомәр агай. Яңа тормыш дигәнне аңламады ул. "Бә-әк катлаулы итеп төзисез яңа тормыш дигәнегезне... Тормышны катлаулы-катмарлы итеп бетерү өчен акыл күп кирәкми аңа. Яшәүдән хозурлык таба алырлык булсын ул, гади, аңлаешлы итеп төзеп карагыз сез аны. Кеше иреген чикләми төзегез. Вәт булырсыз блач! Мөселман мөселманча яшәүдә ирекле булсын, носарилар үзләренчә ирекле булсыннар, бер-берсенә теш кайрамый яшәсеннәр, тормыш корсыннар. Сез ничек төзисез соң? Кешеләрне бер-берсеннән читләштерәсез, аерымлыйсыз, сәбәпсез дошманга чыгарасыз. Ходайдан узып, кешеләр язмышына хуҗа булмакчысыз. Илне кулга алырга була ул. Халыкны көтү мисалына калдырып булмый. Кайчан да булса тарала ул халык дигән көтү. Язмыш дигәнең бит меңгә төрләнә, үзгәрмәс бер генә нәрсә бар, ул—кеше күңеленә ана сөте белән кергән Иман. Сөт калыр, Ватан китәр... Сөт калыр, Ватан китәр... Алтын тавы өстендә утырган Рәми хәзрәтләрен ачтан үтерде яңа блач, мин яшәп азапланам әлегә. Ни кызыгы, ни яме мондый яшәүнең? Сәер кешеләр сез, сәер тормыш корасыз..."

Ул вакытта Гомәр агайның әлеге сүзләрен һич тә тыңлап торасы килмәгән иде, баксаң, дөрескә чыгып бара бит картлачның сүзләре. Инде аны туктаусыз өскә күтәрәләр, җаваплы вазыйфалар йөклиләр, ә менә шушы хәлгә күңелдә аз гына да сөенү хисе юк. Сәер түгелмени?!.

Гомәр агай вафатыннан соң аны үткәннәр белән бәйләп торган соңгы җеп тә өзелгән шикелле булды. Аны кая барса, ни эшләсә кемдер күзәтәдер, гамәлләренә бәя бирәдер дигән тойгы юкка чыкты, ул инде бер кем алдында да җавап тотмый, мондый җавапның кемгә дә булса кирәге дә юк, барысы да үз иркендә, барысы да үз җае белән барырга хаклы иде кебек.

Үзен халык комиссарлары советы рәисе итеп сайлап куйгач, саран (элекке кебек һәр уңышны рәхәтләнеп билгеләп, бәйрәм итүләр бетеп бара иде инде. Беркем дә иртәгәсен үзе белән нindirәк хәлләр буласын белми. Ил буенча тоташ кулга алулар бара...) котлаулардан соң, комиссарлар Советы рәисе бүлмәсенә кереп, күн кәнәфигә килеп утыргач, башында уй туе бөтерелә башлады. Эчен нәрсәдер яндырып алгандай булды, урыныннан сикереп торып, тәрәзә янына килде. Казансу ярында буш көймәләр чайкала. Хуҗалары бер мәл эчендә каекларын калдырып, үзләре каядыр китеп барган сыман. Инде хәтер буйлап Мифтах хәлфәнең шәүләсе йөгереп үтте. Хәер

шәүләсе дә түгел, сүзләре бәгырен яндырып алды: “Һай син татар, һай татар, син бит кичә бар булдың, син бит бүген юк булдың!... Заман синең заманмы, Дәүләтъяр оныгы? Дәвер синең дәверме, Дәүләтъяр оныгы?.. Азамат ир тормышың, ничек ил-көн кормышың?.. Ихтыяр тезгенең учыңа уралганмы, әллә ул башкалар кулындамы? Ни кормак буласың да, ни кырмак буласың, балакай?.. Ил-йортыгыз үчлектән жимерелгән, яңа нигезегез ялганнан корылган.” Мифтах хәлфә менә шулай уйнатып, чалулатып, фикер жебен чуалтыбрак сөйли иде. Бу сүзләр Әхмәтсафаның бүгенге халәтенә бәйләнешле дә кебек, юк та кебек, әмма жан урыныннан купты, тынгысызлык йөрәкне талкый, ул дөньядагы һәрнәрсәгә ышанычы югалган хәлдә бөкрәя төшеп кабат зур өстәл артындагы күн кәнәфигә кереп чумды. Үз уйларына күмелеп, оеп утырырга шәп икән ул кәнәфи дигәннәре. Кисәк урыныннан купкан күңеле бераз тынычланды. “Тезген безнең учта булыр, башкача булыр шикелле түгел ул!” Ул эченнән генә Мифтах хәлфә белән бәхәскә кереп алды. Мин монда икәнмен, димәк Дәүләтъярныкы дәвер. Абынмаска, егылмаска гына иде беренче айларда ук. Әлегә буыннар сыек, әмма ныгыр алар, көч тә куәт тә арта төшәр, азамат ир яшендә генә ич әле ул. Барысы да алда әле! Монда утырган һәркем Кыям Абрамов язмышын кабатламас бит инде. Димәк, Кыям абзый үзе дә гаепле шундый хәлгә төшүендә, димәк, алдын-артын карап бетермәгән... Кешеләргә артык ышанып, кирәкмәгән сүзләр дә ычкындыргандыр әле. Кешеләр янында булырга, алар белән гәп сатарга һәвәс иде ул. Бер дә, бер дә гөнаһсыз алып китеп япмый торганнардыр инде “Черек күл”гә? Сәбәп булмаса, һәркемнән, һәрнәрсәдән кем генә дошманлык эзләп йөрер икән...

...Озак та үтми яңа вазыйфаның “жимешләрен” дә татый башладылар.

Иң элек халык комиссарлары рәисенә тәгаенләнгән яңа фатирга күченделәр. Эшләр идарәсеннән махсус жибәрелгән йөкчеләр, элекке фатирдагы әйбер-караны эһ дигәнче машинага төяп Гоголь урамындагы егерме бишенче йорт, беренче фатирга китереп бушаттылар. Шәһәрнең нәкъ уртасында, аулак урында, иркен фатирга күчеп килгәч, бүлмәдән-бүлмәгә йөргән Хәлимә әбинен куанычы эченә сыймады.

—Шушы йортта бәхетле гомер уздырырга язсын, оланнар,—дип, теләк тели-тели һәр бүлмәгә кереп дога кылып чыкты.

Әнисенең сөенечтән нишләргә белми, туктаусыз дога укып йөрүен килештереп бетермичәме, Рабига Әхмәтсафаны ишек алдына өстерәде:

—Әйдәле, бер нәрсә күрсәтәм,—диде ул аяк арасында уралган Маратың читкә этәрә төшеп. Марат исә агач кылычын әтисе бүләк итеп алган әкият китабындагы юлбасар кыяфәтендә болгап, кычкырып жырлап жибәрде:

Бог создал вора,
А черт прокурора. Эх...

Рабига Маратның колагын нык кына борып алды. Йөзе кызарып чыкты. Кеше ишетсә... Урамда ни күрсәләр, ни ишетсәләр, хәзер күнелләренә сендереп тә өлгерәләр бит болар. Маратны инде әйтәсе дә түгел. Хәерсезләр, бу малайларны тәрбияләүне әнисе—Хәлимә абыстайга гына тапшырып, ерак китеп булмас. Яхшырак балалар бакчасына урнаштыру жаен карарга кирәк...

Әхмәтсафаның башы әйләнгән чак, Маратның шуклыгына артык әһәмият биреп тормады, хатынына берсүзсез буйсынып, ишек алдына чыкты.

—Нәрсә, жанаш?—диде ул Рабиганың беләгеннән эләктереп.—Әллә тегендә чакырасыңмы?—дип, мут елмаеп, ишегалды түрендәге таш сарайлар ягына ым какты.—Канның уйнаган чагы, карчык, кыздырма болай...

—Ну сине!..—дип, Рабига ирен читкәрәк төртеп жибәрде.—Юк-бар турында гына уйлыйсың. Ишеттеңме, Марат нинди урам жырлары өйрәнеп кайткан? Марлесы ана иярә. Ике хулиган үстереп ятабыз. Эш-эш дигән

булып, балаларны әни өстенә ташладык та, вәссәләм. Беренче сүзем шул иде. Аларны яхшырак бакчага урнаштырасы иде. Синең мөмкинлек белән...

—Бәй, сина әйтмәдеммени әле?—дигән булып, Әхмәтсафа сынар кулы белән Рабиганың биленнән эләктереп алды.—Бу мәсьәлә хәл ителгән инде, менә сина ике юллама, Марат белән Марлесны иртәгә үк шушы адреста күрсәтелгән бакчага йөртә башлыйсың.—Икенче кулының ике бармагын жәһәт кенә күлмәгенең түш кесәсенә шудырды һәм аннан алсу кәгазь тартып чыгарды.

Рабига юлламадагы бакча санын күргәч, кулларын чәбәкләп алды.

—О-о, элитный бакча бит бу, Сафа жаным. Безнең балаларны кертерләрме?

Әхмәтсафа сүз куертмады, борчылма, дигәндәй Рабиганы үзенә кыса гына төште. Инде шаяртудан туктап, сорасы итте:

—Икенче серең нәрсә иде, анысын да яшермә инде, шул кадәр каударланып ишек алдына өстерәдең, башка мең төрле шик керде.

—Тышкы яктан тәрәзәләрне сана әле. Ничәү?—Чыннан да Рабиганың тавышында серлелек бар иде.

Әхмәтсафа сәерсәнеп китте. Йортны ашыгып әйләнә-әйләнә тәрәзәләрне санап чыкты.

—Сигезәү, карчыгым. Ә нигә кирәк булды бу?

—Шуңа,—диде Рабига пышылдап диярлек,—Эчке яктан санадым, жиде генә тәрәзә чыга. Күзләремә ышанмыйча, өч мәртәбә санап чыктым. Менә бу уртадагы челтәр корганы тыштан гына шулай тәрәзә кебек, баксаң, ялган ул, эчке яктан такта белән кадаклап, сылап-буяп куелган. Ялган тәрәзәле йортка китереп керттеләр безне. Хәерлегә булсын...

—Йә, Рәбуш, юк-бар сөйләмә әле. Хорафатлар чоры үтте. Тү-тү инде алар. Бу йорт хан заманында салынган. Кемнәр ничек кенә үзгәртеп бетермәгәннәрдер. Әйдә, әнә Марлес еларга азаплана, керик.

—Марат үрти инде аны. Һич тиктормас булды шул малай. Үзенә охшаган...—дип, Рабига өйгә йөгереп кереп китте.

Әхмәтсафа папирос кабызып, ап-ак челтәр корылган ялган тәрәзәгә озаклап һәм сәерсенеп-гажәпләнеп карап торды.

## VII

Һәр яна эшкә Әхмәтсафа ал-ял белми ябыша. Эшеннән мәгънә табып, булсын дип йөргәч, нәтижәсе дә көттерми, кешеләр арасында абруе арта, аның тирәсенә булдыклы егетләр жыела, шау-гөр килеп серләшәләр, кайчак, чаманы онытып, бәхәскә дә кереп китәләр һәм еш кына бу бәхәсләрдә Дәүләтъяровның дәлилләре көчлерәк, ышандырырлык була, аның белән килешергә туры килә. Бәхәс артыкка китеп, тәртип кысалары бүселеп, әңгәмә күнелсез рәвеш ала башласа, Әхмәтсафаның салмак, ләкин көчле тавышы ишетелә:

—Дөрес, әмма алай түгел ул!—ди ул Мифтах хәлфә кебек уң кулының күрсәткеч бармагын өскә чөеп.—Китап менә болай ди!—Елмая төшеп, әле генә очы-кырые күренмәгән бәхәскә китереп тергән мәсьәләнең чишелү юлларын санап күрсәтә башлый. Зирәк акыл, тимер мантыйк, тәжрибә һәм белем өскә чыга, бәхәскә нокта куела.

Ул халык комиссарлары советына килү белән жентекләп Татарстанда хужалык үсеше перспективаларын өйрәнде. Билгеле, монда аңа яңа нәрсә юк. Минзәләдә, Кызыл Йолдыз районында эшләгәндә, Таттосиздат яки "Кызыл Татарстан" белән житәкчелек иткәндә дә айга бернечә мәртәбә өлкә күләмендәге жыелыш-кинәшмәләрдә катнаша торды, берсенә берсе охшаш чыгышларны тыңлап туеп беткән иде, әмма үзе төп эшкә—ХКС рәисе вазыйфасына алынып, һәммәсен яңадан күздән кичерә башлагач, көтмәгәндә "өченче күз"е ачылды—бәй, алга барабыз дип сөйләнгән булабыз, чынлыкта, бер урында таптанып гомер үтә икән ич! Хужалыкны дәвергә яраклаштырып,

ныклы платформага куям дисәң, акыл казаны—һәр яңа идеяны үстерерлек, көч-куәт бирерлек Үзәк юк икән бит Татарстанда. Сәнәгатьнең төп моторы—электр энергиясе, әмма зур-зур җитәкчеләр дә электрны фатирларда чекрәеп янган лампа диеп аңлаудан ерак китмиләр. Ярым-йорты белемгә ия надан түрәләргә энергетика куәтләрен үстерми торып, алга китеш булмаячагын ничекләр генә аңлатырга? Үзен Алланың кашка тәкәсе санаучы надан түрә башкаларны ничек эшкә дәртләндерсен?.. Эшкә төптән җигелеп тарта башлагач кына, Мөхәммәтҗановның туктаусыз: "Кадрлар, кадрлар кирәк!"—дип өзгәләнүен аңлады. Яңаларны үстерү авыр эш, булганын да саклап калу кыен.

Әхмәтсафаның иң үзәгенә үткәне—туктаусыз кулга алулар. Инде бер тармакка булдыклы, белеме, тәҗрибәсе булган кешене табып куясың. Икеөч атнадан ул "юкка" чыга, баксаң "халык дошманы" икән, кулга алынып, "Черек күлгә" озатылган, имеш. Белгечләрнең җитмәве һәр адымда сиздерә. Күр инде син, Казанда гөрләп барган ТЭЦ төзелешен Алемасов ни өчендер әһәмиятсез дип табып, туктатырга әмер хәзерләргә кушкан икән.

Октябрь урталарында Дәүләтъяров бу төзелеш хакында материаллар туплап, Алемасов янына керде.

"Беренче" башта Әхмәтсафаны битараф кыяфәттә тыңлый башлады. Ничек инде ул кабул иткән карарны кире кагарга мөмкин? Ник кирәк ул икенче ТЭЦ Казанга? Кемгә хаҗәт ул? Берәү бар, шул бик җиткән. Татарлар көне-төне электр яктысы астында яшәргә маташамы? Ул бер селтәнүдә сүзне өзеп, яңа рәисне кабинеттан куып чыгарырга ниятләп кәнәфиеннән күтәрелә төшкән иде, нindидер көч кире урынына кадаклап куйды.

Дәүләтъяров һәр җөмләсен мисаллар белән ныгытып, шундый дәлилләр китереп сөйли бирде, аны туктату өчен ахмакның да ахмагы булу кирәк иде. Ә Алемасов ахмак түгел, җилнең кай тарафка искәнен тиз төшенде. ТЭЦ төзелешен аның боерыгы белән туктату, гомумән, төзелешне икенче планга калдыру—үлемгә бәрабәр икән ләбаса. Тиз арада ТЭЦ төзелеп, электр куәте бирә башламый икән, Казан төпсез чуманга утырып калачак, дип расլый Дәүләтъяров. Бүтән төзелешләр дә графиктан чыгып, Татарстан адәм көлкесенә калачак. Куркыныч сүзләр бит бу, шайтан алгыры! Мәсьәләнең җебен дөрес эләктергән татар малае, әгәр тиз арада Мәскәү күзенә хуҗалык үсешендәге үзгәреш, алгарышлар белән чалынып алмасаң, сиңа кул селтәргә дә күп сорамаслар. Вакыт уза, күлмәк туза. Барысын да "халык дошманы"нарына аударып кына да котыла алмассың. Алемасов яхшы белә, хәлләр шундый тизлектә куера ки, көннәрдән бер көнне үзеңнән дә дошман элементы ясарга күп сорамаслар. Энергетика куәтләрен сафка кертмичә, республикада сәнәгатьне алга җибәреп булмаячак. Авыл хуҗалыгына ышаныч юк, яңгыр вакытында яуса—иген уңа, корылык килсә—ачлык. Икмәк Ходай кулында. ТЭЦ төзелешен кичекмәстән беренче чираттагы эшләр исемлегенә кертергә, бу хакта шаулый башларга, эш күрсәтү инициативасының Беренче кулында булуын һәрчак искәртеп торырга кирәк. Ни генә димә, Татреспубликадан бер орден булса да эләктерү фарыз... Әнә, үзәк гәзитләр Мәскәүдә "халык дошманы"нарын кыйраткан прокурорларны орденнар белән бүләкләү турында саннан санга язып торалар, ул, Алемасов, Казанга килеп күпме корткычның башына җитте, эше күренсен дип, әле сентябрь башында гына бер төркем милләтчеләргә, татарны күккә чөйгән ялган тарихчыларга беренче категория бирдертергә ирешде. Аларны көнендә үк чыгарып аттылар. Бу хакта Ежовның турыдан-туры үзенә хәбәр юллап тора, әмма "тимер нарком" һаман дәшми. Шулай да сентябрь башында булган бер сөйләшүдә Татреспубликада өч-дүрт мең контрны җыеп алырга разнарядка бирергә җыенуын белдергән иде Ежов, зуррак "асыл кошлар"ны эләктереп булмасмы дип тә сорады. Мәдрәсә шәкертләре тәмам туйдырды, андый эшләрнең кызыгы да үтеп бара дип, шелтә дә белдергәндәй итте.

Алемасов комиссар Усманов "эше" белән ныклап кызыксына башлавын әйтеп куйды. Бу инде ничарадан бичара, үзенең дә кайбер телгә алырлык

эшләре булуын искәртү өчен сөйләнеп азаплануы иде. Усманов Мәскәү өчен никадәр кирәктер, ләкин Казанда аның абруе искиткеч зур. Усманов турында сүз чыккач, Ежов кайнарланып, Алемасовның кулын кысып алды.

—Ниһаять, ниһаять...—Ежов мәкерле елмайды.—Еланның иң агулысы синең кулда икән. Солтангалиевтән соң икенче дәрәҗәдәге дошман ул, Александр Михайлович. Бу бәндәне чиста суга чыгарырга күптән вакыт. Белеп тор, Усманов—игелексез нәрсә, "Татреспубликада радионы беренче булып мин оештырдым,"—дип мактанып йөри икән. Халыкны ышандырып бетергән шушы ялганга. Бу хакта материал килеп кергәнгә байтактан, инде Усмановның яз көне үк кулга алынуы турында хәбәр иттеләр, ә результат күренми.

—Житешеп булмый, иптәш Ежов. Бер милләтче—контрреволюционерның телен ачу өчен генә күпме көч сарыф ителә. Татарлар кадәр кире, үҗәт халык...

—Халык түгел, ерткычлар! Мин сине аңлыйм, әмма ялганга чик куярга кирәк. Беләсең килсә, иптәш Алемасов, әле мең тугыз йөз егерме беренче елда ук мин Казанда беренче радио түгәрәкләре оештырган кеше. Моны исәпкә алмый, радио оештыру эшен Усманов исеме белән бәйләү, ахмаклык кына түгел, иң зур сәяси хата, күренекле Совет җитәкчеләренең хезмәтләрен таптау!—Ежов түшен киереп куйды.—Усманов—милли армия төзим дип Троцкий алдында шуышып йөргән кеше, сөяген сөяккә аерыгыз, әмма кирәкле фактларны каерып алыгыз үзеннән. Аның һәр күзәнәге шпионлык информациясе белән тулышып, шартлар дәрәҗәгә җиткәндер инде. Сез, беркатлыланып, теле ачылуын көтеп, төрмә ипие белән симертеп ятасыз. Вак-төяк шакаллар белән вакыт сарыф итәсез, ата дошманнарга кулыгыз җитми! Солтангалиевне дә Татарстан карамагына бирәбез, Галимҗан Ибраһимов... Менә эш фронты сезгә! Һәркайсы йөз милләтчегә торырлык эшләр болар... Кирәклесен сыгып чыгара алсагыз, тырышлык тиешенчә бәяләнер. Әлегә эш күренми, мактыйсы бик килә, әмма....әмма... Минем тарафтан сиңа йөз процент ышаныч, алга, иптәш Алемасов!

Дәүләтъяровның ТЭЦ төзелеше турындагы сүзләреннән соң бер тын калып, шулар хакында уйланды, аннан кинәт күтәрелеп, бу тынлыктан соң ни буласын, ни ишетәсен белмичә тилмереп утырган рәискә күз ташлады да, ниндидер саңгырау тавыш белән сорау бирде:

—Усманов хакында беләсеңме, Дәүләтъяров?

—Шамил Усмановнымы?

—Димәк, беләсең...

Комиссар Усмановның кулга алынуы хакында хәбәрдар иде. Мондый очракта нәрсә диярге?.. Сорауның юктан гына бирелмәвен яхшы аңлый Әхмәтсафа.

—Беләм дип әйтү өчен, кеше белән бер пот тоз ашарга кирәк, иптәш Алемасов. Гражданнар сугышы чорында, аннан соң бер-ике мәртәбә очрашырга туры килде аның белән.

Алемасов җавапны тыңлап тормастан, Усманов хакында ничек көтмәгәндә сүз кузгатса, шулай ук тиз туктатты да.

—ТЭЦ дисең инде син. Төзелешне җанландыру өчен нәрсә эшләргә кирәк беренче чиратта?

—Кадрлар юк, иптәш Алемасов. Шунсыз зур төзелешне хутка җибәреп булмаячак.

—Кадрлар кая соң алар? Булганнары кая киткән дим.Тиктомалдан төзелеш корып җибәрмәгәннәрдер бит?

—Булдыклы кадрлар... кулга алынган...

—"Халык дошманнарын" булдыклы кадрлар дип атарга ничек телең әйләнә, Дәүләтъяров? Үз акылыңдамы син?—Алемасов кызып китте, чөнки ТЭЦтагы күп инженерларны нәкъ менә ул килгәч кулга алганнар иде.—НКВД бер генә кешене дә гаепсезгә кулга алганы юк. Кулга алынган икән, димәк гаепле! Беләсең килсә, аларның һәркайсы үз гаепләрен таныдылар инде,

авырлык белән, таш-тимер каршылыклары күрсәтәләр, әмма таныйлар. Шуның өчен дә дошманнар дип атала алар... Гаепне тану—исбатлауның патшасы!

Дәүләтьяров чыгып киткәч, Алемасов янә уйга калды. Кемнәр бөтерелә аның тирәсендә, беренче ударны кемнәрдән көтәргә? Өлкә комитетында, халык комиссарлары советында, ТатЦИК та вазыйфа башкаручыларның һәркайсын кат-кат күздән кичерде. Әмма ике кеше генә әлегә саруын кайната иде—берсе, икенче секретарь, әле ике-өч ай гына Беренче урынына дәгъва кылып йөргән Галим Мөхәммәтҗанов, икенчесе—нык ихтыярлы, белемле, күзгә туры карап сөйләшүче халык комиссарлары советы рәисе Дәүләтьяров. "Егетне ныклап өйрәнергә кирәк! Мөхәммәтҗанов белән Дәүләтьяров аның кешеләре түгел. Ул аларны белми, үзе үстергән кадр дип тә әйтә алмый. Болар, яшь булсалар да, теге буыннан калган мирас, аларның микроблары белән туенып өлгергәннәр. Җай чыккан саен аларның җырын җырлаячаклар..."

Алемасов телефонга үрелгән иде, секретарь кабул итү бүлмәсендә Мөхәммәтҗановны көтеп торуы хакында хәбәр итте.

—Керсен,—диде беренче секретарь, нигәдер сөенгән шикелле.

Мөхәммәтҗанов кабинет буйлап йөгереп кенә үткән шикелле тоелды. Аның йөзендә ризасызлык билгеләре ярылып яткан кебек. Алемасов астан гына аңа күз төшереп алды да, ниндидер кәгазь кисәген укып-өйрәнгән булып утыра бирде.

Икенче секретарь сүз башларга җыенып, тамак кырды.

—Ни бар, Мөхәммәтҗанов?

—Нәрсә дип әйтим, иптәш Алемасов?.. Дәүләтьяров белән киңәштем дә...

—Кайчан өлгердең? Дәүләтьяров әле генә миндә утырып чыкты. ТЭЦ төзелеше хакында кызыклы фикерләре бар. Кстати, минем фикергә каршы килмиләр алар. Төзелешне кичекмәстән беренчел эшләр исемлегенә куярга кирәк.

—Шуңа кердем дә, иптәш Алемасов,—Мөхәммәтҗановның йөзе яктыра төште.—Хәтерегездә булса, мин дә бу хакта сүз кузгатып караган идем... Төзелешне туктату урынлы булмас, дип.

—Сүз кузгату гына җитми, иптәш Мөхәммәтҗанов, дәлилләр, масштаблы фикер кирәк! Онытма, минем ТЭЦ төзелешен туктатам дигән чагым булмады. Каян килде бу сезнең башка? Дәүләтьяров белән икәүләшеп мәгънәсез нәрсә уйлап тапкансыз. Чүбек чәйнәп, май ясаучы осталар! ТЭЦ төзелеше пүчтәк нәрсә түгел, иптәш Мөхәммәтҗанов. Куәтле энергетика базасына ирешми торып, республиканы индустриаль төбәккә әйләндереп булмаячак.—Алемасов ХКС рәисе сүзләрен кабатлап утыруын абайлап, шып туктап калды.

—Дөрес әйтәсез, иптәш Алемасов.—Мөхәммәтҗанов "нәкъ безнең шикелле үк" димәкче иде, бәхәскә кереп китүнең ни-нәрсә белән бетәсен чамалап, тынып калды.

—Ну сез, татарларны!—Алемасов җинел генә урыныннан торып, Мөхәммәтҗанов каршысына килде.—Эгоизм чире көчле сездә. Берегез чак кына эш күрсәтсә, хәзер аның түбәсенә дегетле чиләк каплап куярга омтылыш башлана. Дәүләтьяров ТЭЦ төзелеше турында уйлаганын әйтеп, чыгып китәргә өлгермәде, инде син дә нәкъ шушы ук мәсьәлә белән минем янга килеп кергәнсең. Ничек аңларга моны?

—Дәүләтьяров белән без фикердәшләр... Аңа карата бернинди каршылыгым да юк. Сез ни өчен алай уйлагансыздыр?..

Алемасов авыз чите белән елмайды. Усал елмаю иде бу.

—Әлегә каршылык юк, диген... Алдагысын күрербез. Шулай да Дәүләтьяров өчен Байчуриннар белән "сугышып" йөрүеңне онытма син.—Әлеге сүзләрдә дә киная бар сыман тоелды.—Вәзгыять тиз үзгәрә, иптәш Мөхәммәтҗанов. Кадрларны сайлап алу бер нәрсә, аларны тәрбияләү, эшчәнлекләрен анализлап тору икенче нәрсә. Менә бер көндә Дәүләтьяровка кагылышлы өч хат килеп керде. Шулар белән таныштым да...

—Кая сон ул хатлар? Кемнәр яза, ни турында язалар?

—Әйтәм ич, Дәүләтъяров хакында язалар, причем, ышандырырлык итеп язылган ул хатлар. Татарча булгач, тәржемә итеп бирделәр. Хатларның эчтәлеге белән танышып чыккач, җанның тынычлыгы китте, фактлар кызыклы гына. Берсен Кәрим Хәрәмуллин дигән кеше яза—ул Дәүләтъяровның авылдашы, аның сәүдәгәр малае булуын хәбәр итә. Анкетада Дәүләтъяров үзен батрак дип күрсәтә. Алдашу на лицо, иптәш Мөхәммәтҗанов. Икенче хат—аноним. Хат язучы дәлилләп Дәүләтъяровның күрә торып милли кадрларга өстенлек бирергә маташуын күрсәтә. "Кызыл Татарстан"да эшләгәндә тәнкыйть материалларын бирдертми үзәкләренә үткән журналистларның. Мона да мисаллар бар. Өченчесе—Минзәлә, Буа якларында партия эшләрендә кайнаган Шәмтиев дигән иптәштән. Ул Дәүләтъяровның коллективлаштыруга ышанмавы, аңа каршы булганлыгы хакында хәбәр итә. Життеме?.. Нәрсә, тагын Абрамов, Байчурин чорына кайтабызмы?..

Мөхәммәтҗанов исәңгерәгән хәлдә тора бирде. Әлеге мәсьәләгә үзен дә шартлатып бәйләп куярга мөмкин икәнлекләрен яхшы белә иде ул.

—Нәрсә дип әйтергә дә белмим. Фактларны тикшерергә кирәктер башта, иптәш Алемасов. Ашыгып, тастагы су белән баланы да тышка чыгарып түкмик.

—Ничек белмисең?—Алемасов тантана итә иде.—Фикердәшләр дисең ич. Фактлар раслансамы?! Син ни карадың, үзеңнең кадр бит, сорау синнән булачак!

Мөхәммәтҗановның тәне кызыша иде. Ул карашын идәнгә төбәде.

—Нишлибез, иптәш Алемасов. Минем өчен көтелмәгән хәл булды. Әллә ничек...

—Оялмыйча миннән сорап утырасың. Нишлибез, имеш. Хатларны Михайловка тапшырам, тикшерсен! Ә син бу сөйләшү хакында шым бул. ТЭЦ икән ТЭЦ, эшләрбез, юкка борчыласың, Мөхәммәтҗанов!

Михайлов күптән түгел генә НКВД наркомы итеп Татарстанга җибәрелгән, Тулада халык дошманнарын фаш итүдә гаять тырышлык һәм өлгергәнлек күрсәткән кеше. Мөхәммәтҗановның астына су кергәнен сизенеп, кызара-бүртенә әлеге вәзгыятьтән чыгу юлын эзләп азаплануын күзәткәндә, Алемасовның уенда бер генә нәрсә иде—разнарядкадагы өч-дүрт мең дошманның икесен ул инде төгәл белә, калганын вакыт хәл итәр...

## «Казан утлары» елъязмасы
(октябрь)



65 ел элек (1938) **Абдулла Алишның «Сер тотмас үрдәк»** әкияте,

60 ел элек (1943) **Таҗи Гыйззәтнең «Даулы көннәр»** драмасы, **Салих Батталның «Шинель»** шигыре,

55 ел элек (1948) **Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»** романының дәвамы, **Әмирхан Еникинең «Кояшлы иртә»** хикәясе,

50 ел элек (1953) **Мирсәй Әмирнең «Ялантау кешеләре»** романының дәвамы, **Нури Арсланның** шигырьләре,

45 ел элек (1958) **Юныс Әминевнең «Гөлчәчәк»** драмасы,

40 ел элек (1963) **Сибгат Хәкимнең** яна шигырьләр циклы,

30 ел элек (1973) **Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап»** повестеның дәвамы,

25 ел элек (1978) **Рәфкать Кәраминең «Очар кошлар белән янәшә»** исемле повестеның азагы укучыларга барып ирешкән.

# Şiğriət
# Шигърият



## Әхсән Баян

### Яңа гасыр

Кан эчендә тудың, яңа гасыр,
Кар төсендә өмет яуганда.
Артык шатлык китермәде аклык
Чын азатлык көткән заманда.
Яңарышмы, афәт димме сине,
Ничек атыйм рәвешең, төсеңне?
Яңа ел таңында аваз салды
Дөньяга бер сабый... Ул синме?

Ак бантиклы кыз мәктәпкә бара,
Бәхет, белем җыя ул көн дә.
Ә икенче бала, кулын сузып,
Хәер көтә базар читендә.
Кем капитал, дан, дәрәҗә туплый,
Кемдер шешә җыя чүплектә.
Арысланнар зебра тотып ашый...
Сабыйларны, безне ни көтә?

Өскә яуган еллар каралыгын
Күмә алмадылар ак карлар.
Тәкърарланды "без йотасы" ирек,
Ителә язды шулай ул тар-мар.
Таптап, изеп, террор сәбәпләрен
Тик шәхесләр эзләп йөрделәр.
Кыйраттылар Әфган һәм Гыйракны,
Аркылыга, буйга сөрделәр.

Дөнья—чиксез, анда юк кем генә.
Ни күрәсең килә, бары да бар.
Матурлык бар, әмма ул коткармый,
Бәхет тә бар, әмма урыны тар.
Саның—егерме бер. Беләм, сиңа
Шул сан белән исем куелды.
Безне, Җирне кая илтәсең син?
Ниятеңне белмим, уеңны...

### Мин—кешелек!

Минем эзләр килә чал тарихның
Саны саналмаган чагыннан.
Ыругъ, каганлык һәм ханлыкларда
Урдаларым минем кабынган.
    Чорлар кичкән ялкын уклары—
    Якты чәчкән урда утлары.

---

Әхсән БАЯН (1927)—*шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм рус телләрендә күпсанлы ("Елларга ышаныгыз", "Елларга сәяхәт", "Заман сурәтләре" һ. б.) китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Эзләремне минем табып була
Кырлар, сулар, чүлләр кичкәндә.
Табып була, күрсәң, һәр аймакта,
Җирне бераз казый төшкәндә.
Теләгәннәр әле дә күрерләр—
Көйрәп тора кузлар-күмерләр.

Таулар, чүлләр аша чал шәрекътан
Яшь мәгърибкә эзләр җиткәннәр.
Алтай өсләреннән карлы Карпат
Түбәләрен алар кичкәннәр.
Вакыт, киңлек гизгән эзләрем,
Алар белән йөргән сүзләрем.

Минем сүзләр ишетелеп торган
Һәр төбәктә, барча кыйтгада.
Тәүге кабат яңгыраган исемем
Монголия белән Кытайда.
Үз иткәннәр минем сүзләрне
Байкал, Хазар, Азау күлләре.

Радио авазларын тыйган кебек,
Минем тарих, минем тормышны—
Сүз һәм эзләремне—кара көчләр
Кырып юк итәргә тырышты.
Эзләремә бетә киртәләр,
Җиһан буйлап сүзләр китәләр.

Планета—безнең уртак бина,
Төзек кенә булсын, Илаһым.
Бу бинада, аның БМОсында
Килә минем әгъза буласым!
Кәнәфи бит анда табылыр?
Килер ул көн, килер барыбер.

Планета тормый бер милләттән,
Бар өлешем! Мин дә—Кешелек!
Кемнәр каршы, кемгә бу дөнья тар,
Мин-татарның анда эше юк.
Мәйдан—уртак, барам шул таба,
Аңлар дөнья, кыен булса да:
—Мин дә—Кешелек!

## Сак белән Сок

Кичәге дуска ябылды ишек...
Сак белән Сокның тавышын ишет.

Ни ул бердәмлек, нәрсә ул дуслык?
Белдекме элек, әллә оныттык?

Ике күз—бер иш, бер төсле урын,
Аларны мәгәр аера борын.

Тырышсаң да бик, күрә алмыйсың,
Сак белән Сокның ишет тавышын...

Бераү—биектә, син төшер тартып.
Аста булганчы, булмавың артык.

Хөсет, үч—яман, бик тә беләсең,
Ә үзең һаман көнли бирәсең.

"Җиңелсен күршең, илең җимрелсен!"—
Тәкъдир каргаган бер дә юк өчен...

Таркалган илләр кушылмый ник соң?
...Ишет тавышын Сак белән Сокның.

❦

"Без—көчсез зат"—диеп, син кимсенмә,
Син ир-аттан хәтта көчлерәк.
Синең белән ул һич ярышалмас,
Анда булса гәрчә өч йөрәк.

Ихтыярда бәлки ул өстенрәк,
Бусы калсын, әйдә, бәхәскә.
Күтәрелсә йодрык, мөмкин сиңа
Кайтармаска җавап, дәшмәскә.

Илләр арасында гаскәр, гаскәр
Ташланганда берсе-берсенә,
Ил бирешсә, ашык, кил ярдәмгә,
Ташла нәгъргә дошман өстенә.

Ишетерләр тавышың ил уллары,
Чигенсәләр, кинәт туктарлар.
Туктарлар да, борылып алга, кабат
Илбасарга чәчәр ут алар.

Беләк-күкрәктәге көчләр, бәлки,
Атлар куәтеннән ким булмас.
Гүзәллек дип исемләнгән бөек
Тылсымыңа ләкин тиң булмас.

Мылтык түгел, хәнҗәр түгел көчең,
Ул төсеңдә, буең-сыныңда.
Күзләреңдә... Куллана бел әмма,
Кирәк чакта, тиеш урында.

Быел тагын сары күбәләкләр
Каршылады минем язымны.
Пар күбәләк булгач, кала өмет:
Сагышларым булыр аз инде.

Күбәләкләр юрадылар быел
Ялгыз узмас диеп көннәрең.
Җавабымда үзләренә мин дә
Матур, тигез җәйләр теләдем.

Сезгә бәхет, шатлык юравымны
Онытмасын ялгыш берегез.
Күбәләкләр, парлы күбәләкләр,
Ышанычым аклый күрегез.

Исән булыгыз...

Эшләдек тә игелек, суга салдык,
Шатлансыннар әле балыклар.
Бәлки хәбәр таратырлар, безнең
Юмартлыкка хәйран калыплар.

Балыкларга азык булып, суда
Җыйналгандыр безнең байлыклар.
Койрык болгап, балыкчыга гына
Рәхмәт әйтәмени балыклар?

Су төбеннән ишетелер аваз...
Иелеп тыңлый, көтә таллыклар.
Төптә—төпсез тынлык. Юк бит ымлык.
Ник эндәшми һаман балыклар?

Чү, тыңлыйк...

Киләчәктән сөю көтмим инде,
Эзләр чакның беләм узганын.
Яшь көннәргә кайтып, икенче кат
Гашыйк булам бер үк кызга мин.

Гашыйк булам ике, өченче кат,
Вакыт үтмәгәнгә исәпләп.
Карарга да базмый, бүгенгемә
Алып кайтам аны җитәкләп.

Рәнҗешләрдән, йөрәк, чикмә газап,
Бу тормыштан көтмә һич шәфкать.
Миһербансыз, карак бу гасырда
Гаделлекләр юк дип ярсынма.
Монафыйклар чакма-уклар белән
Чаккан чакта, җавап син дә тап:
Чәчрәсен ут—син таш булып кат.


## Гомер башы, гасыр башы...

*Иянсәрем Камиләгә—*
*ускәч укыр өчен.*

Кем белгән бакча юлының
Болай җайсыз булырын.
Сөенеп йөгергән чакта,
Абындың да егылдың.
Кем белгән нәкъ шул урында
Хәерсез таш торырын.
Бәрелдең дә кырлы ташка,
Яраланды борының.

Дөнья буйлап киткән чакта,
Бу зур яраң—беренче.
Яшәүнең нәрсә икәнен
Белә башлау билгесе.
Алда—зур фән, беркем аны
Өйрәнмәс синнән башка.
Ул өйрәтер абынмаска,
Егылсаң—еламаска.

Ул фәндә мин—дәү әтиең—
Белемсез булдым бигрәк.
Син, зинһар, бул белемлерәк,
Зинһар, бул зиһенлерәк.
Гомер башы, гасыр башы...
Бергә бара икегез.
Яңа гасырга җитегез,
Миннән сәлам илтегез.



# Әдхәт Синугыл

## Фәрдләр

Батырга кыюлык уртак.
Ялганчы булыр гел куркак.

Кунакчыл өй гел кешеле,
Бик белмәс аның ишеге.

Коралсыз булганда аучы,
Ач бүре күләр бик ачы.

Баксаң кешегә һавалы,
Мәдәнилегең чамалы.

Бер чыкса адәм юлыннан,
Чыккандай хәнҗәр—кынынннан.

Кемнең кулында дилбегә,
Бары да аңа бил бөгә.

Кычкырган адәм буш куык,
Мыштым адәмнән син курык.

Кимсетсәң туган телеңне,
Кимсетәчәксең Илеңне.

Сүзләрең булса да дару,
Артыкка киткәндә—агу.

Белсә дә кеше бик күпне,
Белмәгәннәре дә күпме!

Вакытында яңгыр яусын,
Кыз балага килсен яучың.

Туганнарың булганда бай,
Күренә күзгә кояш-ай.

Күңел күп теләсә дә бик,
Кулыңнан гөнаһ тарта бит.

Эч-сереңне түгел ятка,
Хатынга да чишмә хәтта.

Әдхәт СИНУГЫЛ—*шагыйрь, "Ефәк кәрваннар", "Иман гасыры" һ. б. китаплар авторы. Симферопольдә яши.*

Үзеңә ярамаганны
Ятка да юрама аны.

Курыксаң яман күзеннән,
Яманлык кылма үзеңнән.

Кулың эшләгәнгә гелән
Җавап бирерсең баш белән.

Юл алып барса да алга,
Тел илтеп җиткерә анда.

Калса кала атаң малы,
Калмый сиңа атаң даны.

Сукыр, чукрак йә телсез бул,
Яшисең килсә тыныч гел.

Мәче дә арыслан була,
Тычкан төшергәндә кулга.

Күп кыз сайлаган кияүгә
Гел пеләш кызлар эләгә.

Үзенә кагылганда сүз,
Ишетер саңгырау да тиз.

Батырайса хатын өйдә,
Куркакка әйләнә ир дә.

Чылбырга этне бәйләмә,
Ул холыксызга әйләнә.

Курыксаң, әйтмә сүзеңне,
Әйтсәң, кыю тот үзеңне.

Акны була ул каралтып,
Караны кара агартып!

Сагаласа да утыз теш,
Курыкмый алардан тел һич.

Сатып алмасаң үгезен,
Саварсың сыер мөгезен.

Чәчәк исе озак тормый,
Озак торган—кунак булмый!

Сугышырга батыр шашмый,
Сугышуны куркак башлый.

Үтмәсләнсә кылыч—аны
Яуга кайрак кайрый тагы.

Кулындагы шәмен сизми,
Нигәдер һаман ут эзли.

Бер кулы сукса анаңның,
Икенчесе сыйпар аның.

Кадакларын калган саклап,
Дагасын югалткан, ахмак.

Бакыр эзләп тиргә баткан,
Көтмәгәндә алтын тапкан.

Тәңренең эше фәрманда,
Бәндәнең эше дәрманда.

Сөртенгәнче телең гелән,
Сөртен син аягың белән.

Балтаның суксаң йөзенә,
Каны буялыр үзеңә.

Ир-ат бәхете Ил белән,
Хатын бәхете ир белән.

Ут йотканның авызына
Кайнар күренер бозы да.

Балдак күрке түгел бармак,
Бармакның күрке ул балдак.

Авыздагы сүз синеке,
Авыздан чыкса—мирнеке.

Кылый булса да күз бит—күз,
Аксак булса да кыз ул—кыз!

Чыккан җирендә агуын
Туктату җиңел агымның.

Ярканат күрмәгән өчен,
Кояштан алмыйлар үчен.

Авызыңны ачканда гел,
Күзеңне дә син ача бел.

Батса, бирә балтасын да,
Котылса, җәлли сабын да.

Эндәшмәсәң, диләр: телсез,
Дәшсәң, алдый, диләр, юньсез.

Кыз кайгысы ясмык кадәр,
Хатынныкы ястык кадәр.

Багны юк киртәләүчеләр,
Кәҗәне күп тиргәүчеләр.

Малны тотсалар мөгездән,
Кешене тоталар сүздән.

Бер үгездән ике тире
Тунап алыр фәкать тиле.

Дуслар эзләсәң гаепсез,
Торып калырсың бер дуссыз.

Җир оҗмахын күрү шатлык,
Исеме булса Азатлык.

Бүрек астында да өйдә
Бүрене булмастыр димә.

Булганда халык хәтерсез,
Гомергә булыр кадерсез.

Ирга тиенсәм дә, анам,
Итеген салдыру яман.

Базарыбыз белән бергә
Мазарыбыз да бер җирдә.

Кафия түгел бизәк сүз,
Шагыйрьләр өчен үзәк сүз.

Сөтне аз бирүче сыер
Өзлексез мөгерәп торыр.

Вак халыклар шуңа усал,
Хокуксызлык аны кысар.

Кәҗә, мәлгунь, тозга килә,
Егет-җилән кызга килә.

Ук барып җитмәгән җиргә
Кылычың кизәнә күрмә.

Баг алсаң, кыш ал син багны,
Баг сатсаң, җәен сат аны.

Татар бик тынгысыз халык,
Әйтерсең судагы балык.

Йөк тартып арыган атка
Үз койрыгы авыр хәтта.

Оешмаган халык—көтү,
Аны һәрчак кирәк көтү.

Заман синга бакмаса да,
Заманга үзең баксана.

Шагыйрь кешенең йөрәге—
Дөньяның кайнар үзәге.

•

**Күңел күзе—уй диңгезе,**
**Сугыш күзе—кан диңгезе.**

•

**Ярыш бар җирдә яныш бар,**
**Эшләгән җирдә ялгыш бар.**

•

**Тел докторлары барын бар,**
**Телне дәвалый алмыйлар.**

•

**Ишәк углы булмый ишәк,**
**Кем булсын соң, көн-төн эшләп?**

•

**Җир ярасы—Ир ярасы,**
**Ир ярасы—ил ярасы.**



## Мәдинә Маликова

# МЕНДЕМ БИЕК ТАУЛАРГА

ПОВЕСТЬ

*ПРОЛОГ*

— Сикер! Сике-ер!

Кинәт яңгыраган бу тавыш кичке тынлыкны бозып, Идел кинлеген сискәндереп җибәрде. Шәфәкъ нурларында кургаш кебек тонык ялтырап яткан елга уртасында, әллә ишкәк белән әкрен генә йөзеп барган, әллә бөтенләй туктап калган кечкенә көймәдә берәү тураеп баскан да, ике учын авыз тирәсенә куеп, ярга карап кычкыра:

—Сике-ер-р!

Су читеннән күренеп җитми, алай да яшь егет булса кирәк, көчле, чиста тавышында малайларча үчекләү һәм шаярту сизелә.

—Сикер-р!

Рәшидә комлык белән су очрашкан сызыкта басып тора. Кояшта янган тыгыз тәне коену киеменең дымыннан, елгадан килгән җиләслектән кызыша, тынгысыз, ашкынулы дәрт белән яна. Ул әле генә әнә шул кинлектән, баеп килгән кояшның алтынсу-кызгылт нуры сузган юл буйлап йөзеп килде. Әле генә аның баш очында үрсәләнеп акчарлаклар чәрелдәште. Бик түбәннән очтылар, әйләнеп килгән саен, үткен канатлары белән телеп алырга теләгәндәй, аңа атылдылар. Рәшидә судан чак кына калкып торган озын агач кәүсәсенә якынлашкан иде шул, ә анда канат ярган кош балалары тезелеп утырган. Акчарлаклар шуларны саклый, якын килгән һәр җан иясенә ярсып һөҗүм итә... Рәшидә көлә-көлә аларга кизәнде: “Нәрсә, балалар

---

Мәдинә МАЛИКОВА—*язучы, «Кар сулары», «Янар таулар яктысында», «Басып сайрар талы бар», «Шәфкать», «Алтын ятьмә» һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

газизме? Алар дигәндә үз башыгызны кызганмыйсызмы? Тотып ашыйм бит хәзер!"

Яр буена чыгып баскач та, ул әле һаман Идел өстендә ыгы-зыгы килеп, тавышланып очкан кошларга карап тора иде. Һәм менә кинәт сискәндереп яшь тавыш өн салды. Рәшидә башта моны үзенә дип кабул итте. Аны күргәннәр, шул ераклыктан да дәртен-талпынуын аңлаганнар! Үз итәләр, шаяртып үчеклиләр!

Бу чакыруны җавапсыз калдырып булмый... Сикерергә кирәк. Ләкин яр ягасында, комлыкта су бик сай, теләсәң дә сикерерлек түгел. Тик нигә соң әле бу дәртле тавыш, бу үчекләү аны ашкындыра гына түгел, җанны кузгата, бәгырьне кисә?

Ул каерылып артына борылып карады. Анда, сулга таба, тар комлыктан арырак, яр текә булып өскә күтәрелә. Су агымы аны астан уеп кергән, үр битеннән умырылып төшкән таш түмәрләрен агартып юган. Кыяның иң өсте—маңгае алга чыгып калган, ул ниндидер кодрәт белән генә әлегә ишелеп төшмәгән. Түбәсендә каралып күренгән нарат кына аны тамырлары белән беркетеп торадыр, мөгаен. Ләкин озакка түгел, чөнки анда, биектә, агачның тамырлары елга ягыннан шәрәләнгән, җил-яңгыр аларның туфрагын сыдырып алган, әнә, шәфәкъ нурыннан кызарган болыт фонында тырпаешып торалар. Җил көчлерәк исеп куйса, давыл бәрсә, кәкрәеп, уралып үскән бу нарат урыныннан кубарылып авар, ярның чыгынкы маңгае белән бергә аска, ташлар өстенә убылып төшәр. Моның өчен, бәлки, Идел өстендә яңгыраган шушы көчле, хисле тавышның тибрәнүе дә җитәр.

—Сике-ер!

Җылы, тыныч, рәхәт җәйге кичтә йөрәкне җилкендереп тә, әрнетеп тә яңгыраган бу өндәү Рәшидәгә түгел икән бит... Әнә, кыя өстендә, ялгыз нарат янәшәсендә бер кара шәүлә калкына башлады. Әллә бөркет инде?

Юк икән лә... Әнә ул күтәрелә, биегәя... Менә, нарат янында егет сыны пәйда булды. Нечкә билле, киң җилкәле. Кулларын киң җәеп өскә күтәргән. Менә-менә талпыныр да, аякларын кыя түбәсеннән аерып, өскә, утта янган болытларга омтылыр шикелле.

—Сикер!—диләр көймәдән.

Әллә чыннан да сикермәкчеме? Ләкин аста, кыя итәгендә, су тирәнлеге түгел, таш түмәрләре!

Бу уй Рәшидәнең йөрәген өтеп алгандай итте. Кыя түбәсендә, кулларын алга сузып, аның ин газиз кешесе басып тора иде. Идел яры—тау кыясы түгел, ләкин астан караганда ул, ярты күкне каплап, биниһая биек булып күренә, аның өстендә шәфәкъ утыннан кызарган болытлар дәһшәтле яна иде...

Рәшидәнең сулышы киселде, тез буыннары йомшарды, зиһене чуалды. Таныш, бик таныш иде бу биеклек, бу чакыру, бу курку. Җир шарының икенче ягында, Кариб диңгезе буенда, текә таш кыяның түбәсендә, кистереп, бәреп искән, тыгыз, кайнар тропик җилендә бер тапкыр кичергән иде Рәшидә бу хисне. Анда да нәкъ менә шулай ерактан, шушындый ук көләч, гамьсез тавыш шаярып, чакырып, үчекләп кычкырган иде:

—Сике-ер! Пры-ыга-ай!

Кыя түбәсендә басып торган егет, шул чакыруга җавапсыз кала алмас, саксызланып алга атлар да, упкынга атылыр, дип курыккан иде Рәшидә. Дәшсәм, сискәнер, җайсыз борылып, җилдән авышып китәр, дигән уйдан авыз суы кибеп, орынсам, тайпылыр да авар, дип шомланудан чарасыз калып, һушын җуяр дәрәҗәгә җиткән иде...

Тагын, менә тагын шундый ук хәл кабатлана түгелме? Әллә бу—шул хәлләрнең дәвамымы?

Нигә менде Рәшидә ул биек тауның башына, никләр генә басты ул кыяның ташына?

Сөю, мәхәббәт алып менде аны чит җирнең ят тауларына, каршы куйды тропикларның көчле, утлы җилләренә.

* * *

Ә бит барысы да бик гади, табигый башланган иде. Жир шарының теге ягына барып чыгу да ул чакта да әлләни шаккатарлык хәл түгел иде. Егерменче гасырның сиксәненче елларында Куба белән СССР дус ил булып саналалар, "Куба—минем мәхәббәтем"—"Куба—любовь моя" дигән җырны ишетмәгән кеше, Фидель Кастроның гайрәтенә сокланмаган, аңа охшарга тырышмаган егет булмагандыр. Башка илләрне карап кайтырга теләүчеләргә күп чикләүләр куелган ул заманда, Кубага бару шактый җиңел булды. Чөнки, ерак һәм ят җир булуына карамастан, аңа кызыгучы аз иде. Ник дисәң, Куба, барлык социалистик мәмләкәтләр кебек үк, хәерче ил, барлы-юклы акчаңа тауар алып кайтып, юл чыгымнарын аклап булмый. Шулай булгач, океаннар кичеп, болганып йөрүдән ни мәгънә? Күпчелекнең фикере шундый иде. Ләкин менә сәясәт күзлегеннән караганда, ул ил белән бәйләнешларны ныгытырга кирәк, дип саналды. Шуны күздә тотып, хөкүмәт күпләрне анда бушлай йөртеп кайтара иде. Барсыннар гына. Кариб диңгезенең теге ягындагы Сэм агайга йодрык селкеп, үртәп-үчекләп торган сакаллы батыр Фидель Кастроның СССР белән дуслыгын тагын бер тапкыр раслап кына кайтсыннар. Шушы максаттан чыгып, хезмәт алдынгыларына бу илгә бару өчен түләүсез юлламалар бирелә иде.

Шундый бер юлламаны яшьләр гәзитенә дә тәкъдим иттеләр.

Баш редактор, барлык хезмәткәрләрне үз бүлмәсенә чакырып, җирәбә салырга киңәш бирде. Кәгазь битен ваклап кискәләделәр , берсенә "Куба" дип яздылар һәм һәр кисәкне аерым бөтереп, редакторның кара бүрегенә салдылар.

—Андыйга минем бәхет юк инде... Күпме лотерей билеты алып, бер тапкыр да отканым булмады,—дип сөйләнде Рәшидә үз чиратында бүректән кәгазь бөтеркесен капшап алганда.

Шырпы хәтле генә бөтерке эчендә өзелеп сөю, мизгелләр белән саналган бәхет һәм озак елларга, бөтен гомергә сузылачак сагыну, сагышлану ятканын кем белгән соң ул чакта?

Өлешенә тигән кәгазь кисәген турайтканда, Рәшидә бер дә дулкынланмады. Шәмәхә белән язылган "Куба" сүзен күргәч тә битараф калды. Башкалар кызыгып һәм көнләшеп аны аркасыннан каккканда, кулын кысканда да очынып куанмады. Чөнки бара алмый иде ул анда. Хаста ирен ташлап кая китсен? Аннан соң хикмәт юлламада гына түгел бит әле, такыр кесә белән ерак юлга барыбер кузгалып булмый, ә ире чирләп яткан соңгы айлар гаиләне тәмам такка таяндырган иде.

Ләкин тәкъдирдә язылган юлдан киртәләр ансат алына икән.

—Редакторга гариза яз син, матди ярдәм сора,—диде Зилә.

Алар икесе бер бүлмәдә утыралар, бер-берсенең хәлен бик аңлыйлар иде.

—Кит инде! Чит илгә барырга нинди матди ярдәм ул?

—Ә син чит илгә дип сорама. Иреңнең авырганын, үзеңнең күпме вакыт хаста карап, түләүсез ялда утырганыңны яз. Профсоюз кул куя, бирми кала алмый.

Зилә моны ышанып әйтте, чөнки редакциянең профсоюз җитәкчесе ул үзе иде.

—Яхшы булыр микән?—диде Рәшидә.—Миннән мохтаҗраклар бар...

—Акчаның яхшысы-яманы булмый, йә бар ул, йә юк, фәкать шул гына. Мә кәгазь, мә ручка, яз!—диде Зилә.

Шулай итеп, сәгать эчендә диярлек акча мәсьәләсе дә хәл ителде.

—О-о, Рашель иркәм, бик әйбәт булган бит бу!—диде Рәшидәнең ире Евгений бу хакта ишеткәч. Аннары, хатыны кичке аш хәстәрләп йөргән арада, киштәдән "Зур совет энциклопедиясе"нең кызыл тышлы, калын, авыр китаплары арасыннан сыртына "14 нче том" дип язылганын алды да, "Куба" дигән битне ачып укыды.

—Ерагын ерак инде,—диде.—Мондагы масштабка караганда, ун мең

чакрым чамасы. Кызыклы ил дә түгел, бернинди тарихи урыннар юк,— дип нәтиҗә ясады аннары.—Крокодиллар белән фахишәләр карап кайтсаң гына инде, иркәм. Барсыннан да зуррак экспонат—Фидель Кастро үзе бар барын. Ләкин син аны күрә алмассың, мөгаен. Әнә, гәзиттән укыдым: узган митингка да сонарып, ялындырып кына килгән. Тропик кояшы астында, ачык мәйданда басып торган йөз меңләгән халыкны өч сәгать көттергән! Син инде аны күрәм дип ашкынмассың. Димәк, анда-монда чабарга туры килмәячәк. Бигрәк әйбәт. Океан ярында, мәшһүр Варадеро курортының назлы комында бер ваемсыз, гамьсез ятарга була. Ял кирәк сиңа.

—Ә син, Женечка?! Нишләрсең берүзең?

—Ашарга пешерермен. Кибеткә чыгармын. Әллә булдыра алмас, дисеңме? Врачлар айдан артык ни өчен тырышты, мине шуңа да яраклы итмәгәч? Әллә син совет медицинасына ышанмыйсыңмы? Ә әни? Мине ялгыз калдырамы соң ул!

Рәшидә ирен шаярадыр дип уйлады, ышанып җитмәде. Ышанырлыкмыни? Атна буе хастаханәдән чыкмый ире янында утыру, аннары ай буе иртә-кич, эшкә барганчы һәм кайтканда авыру янына чабулар тәмам Рәшидәнең көчен алган, үз-үзен карау-кайгыртудан биздергән, теләкләрен сүрелдергән иде.

Һәм менә иренең сүзләре әкренләп күңелнең кыршавын бушандыргандай итте, алгысытып җибәрде. Куба! Тропиклар! Хыялый дөнья! Ничек инде ул кызык булмасын? Океаннар өстеннән очып, Бермуд өчпочмагын кичеп, кыш уртасыннан эссе җәйгә барып төшү!

Ләкин... мөмкинме бу? Тиешле кәгазьләрне язып, кирәкле урыннарга барганда, башын томан саргандай, әйле-шәйле йөрде Рәшидә. Хастаханә юлларыннан, дару исеннән, иренең саргайган ябык йөзеннән, нурсызланган күзләренең гаҗиз карашыннан котылып торырмы ул? Әйе-әйе, кайчандыр Рәшидәнең хәлен алган, тәкатьсез иткән, үзләренә буйсындырган көчле куллар инде хәлсез, аны нурга коендырган, яндырган-көйдергән зәңгәр күзләрнең карашы тоныкка, керфекләре коелган, күз төпләренә шәмәхә капчыклар бүлтәеп чыккан... Иреннәре нечкәреп, күгәреп эчкә баткан. Бит очынларындагы сөйкемле уемнарны, гомер сулары юып, озын, тирән бураэналарга әверелдергән. Йомшак сары чәчләре химиотерапиядән соң коелып, шома башы электр уты яктысында елтырый. Элегрәк чәч астында күренми иде, баш сөяге берничә урыннан кантарланып чыгып тора икән...

Бала чакта, авылда, Рәшидәнең "җен алыштырган" дигәнне күп ишеткәне булды. Гадәттә моны ямьсез, көйсез балалар турында әйтәләр иде—ягъни ул әйбәт булган үзе, ләкин аны, өлкәннәр күрмәгәндә, җен алып киткән, урынына үзенең хәшәрәт баласын утыртып калдырган... Хәзер бу әкият бик еш искә төшә торган булды: карасана, балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә җен алыштыра икән бит!

Авыл әкиятләре игелек белән сугарылган: аларда кешеләрнең пәри балаларын үзләренекеннән дә кадерләбрәк карау-тәрбияләүләре хакында сөйләнә. Чөнки гарипләрне ныграк кызганалар бит. Рәшидә дә шулай. Ирен терелтү өчен әллә ниләр эшләргә әзер, әгәр мөмкин булса, чирен урталай бүлеп, яртысын үзенә алырга риза иде. Кызгана иде ул аны.

...Евгенийның исә күзләре нурсызланса да үткенлеген саклаган иде. Ул хатынының кичерешләрен сизә-тоя, хәлсез-көчсез калып, аның өстенә йөк булып төшүенә йөрәге әрни иде. Менә хәзер чын ир-егет икәнлеген яхшылык белән исбатлыйсы килде, сүзен өзеп әйтте:

—Карышып торма, Рашель. Барасың булгач, барасың. Ял итеп кайтасың. Дәшмә, иркәм. Юлга җыен.

Рәшидә каршы әйтмәде. Эчтән исә чыгып китәренә һаман ышанып бетә алмады. Иренең хәле начараер яисә җибәрәсе килмәс, кире уйлар, дип икеле-микеле йөрде.

Ә бер кичне, ул аш бүлмәсеннән тәлинкәләр тотып чыгып килгәндә, Евгений диванда юка гына бер китапчык тотып утыра иде.

—Рашель! Кил әле. Кара, монда ни язганнар,—диде елмаеп һәм шаяргандай итеп.

—Нәрсә?

—Хатыннар кырыкка житкәч чыннан да өр-яңадан яшәреп китәләр икән ләбаса. Мәкаль бар бит әле: "В сорок пять баба ягодка опять". Халык белми әйтмәс! Инде фән дә шуны раслаган.

—Каян алдың әле аны?

—Синең китаплар арасыннан килеп чыкты!

Рәшидә гәзиттә медицина һәм әхлак бүлеген алып бара, шул хактагы китапларны шактый җыйган иде.

—Ну, Женчик, тапкансың,—диде ул кашын җыерып.—Бозык ирләр сүзен сөйләп утыру килешми сиңа.

—Билгеле бер яшьтәге хатыннар яшь егетләргә гашыйк булучан, дигәннәр монда.

—Ирләрнең шул булыр инде, башларында һаман бер уй, авызларында һаман шул бер сүз. Аша әнә, ашың суына.

Үзе эчтән куырылып килде: "Менә сылтау тапты. Кире уйлар, мөгаен. Җибәрмәс. Каян күреп алган китабын да!"

Евгений исә аның ачуын әллә сизмәде, әллә сизмәмешкә салышты, кулына кашыгын алды да, үзалдына карап, шаярткандай:

—Син кара анда, Рашель, сак бул! Онытма дөньяда мин барын. Башың әйләнеп китмәсен!—дип куйды.

—Шуның кайгысы гына, ди, монда!

Әйе, яшьләр житкәч кырыкка бетә икән кызыклар, дип үзен дә, ирен дә ышандырырга тырыша иде Рәшидә. Тормыш иптәше бар, ә менә чын-чынлап ир дигәне... анысы инде байтактан юк, дияргә була. Ләкин өлкәнәеп килгәндә яшьләрчә сөешеп-назланышып яшәүче парлар күпме генә икән соң алар? Ансыз-акылсыз хатын түгел, дөнья хәлләрен бик белә... Шуңа күрә, тыштан караганда ирле булып, чын мәгънәсендә исә ярым тол хәлендә яшәргә үзен күнектергән иде инде. Калган гомерем дә шулай узар, дип исәпли иде.

Ә иренең бүтәнчә уйлавы дә ихтимал бит. Көнләшә башласа? Бер сәбәпсез бәйләнә торган булып китсә?! Әнә, китабын да табып алган бит!

Шул көннән соң, эштән кайтканда Рәшидәнең күнелен курку баса иде: иренең хәле авырайгандыр йә юри хастага сабышкандыр да, аны ташлап чыгып китеп булмас, дип хафалана иде ул.

Ләкин вакыт үтә торды, тиешле кәгазьләр тутырылды, китәр көн килеп житте—Евгенийның хәле начарланмады. Ир ирлеген итте, сүзендә торды, әйткәненнән кире кайтмады. Саубуллашып, ишектән чыккач, инглиз йозагының чык иткәнен ишеткәч тә әле Рәшидә туктап, тыңланып торды: ишек артыннан тавыш ишетелер, ире кире чакырыр кебек тоелды. Ләкин юк, тын иде, гөрс-гөрс итеп күкрәк куышында йөрәк кенә бәргәләнде.

Ул кулындагы чемоданының авырлыгын, кышкы пальтосының чабулары тубыгына бәрелеп җайсызлаганны да тоймыйча, сигезенче каттан баскыч буйлап аска томырылды, тышка, саф һавага, гыйнвар суыгына ашкынды.

* * *

Унбиш яше тулар-тулмас Рәшидә авылыннан, аркасына биштәр асып, житмеш чакрым ераклыктагы калага тузанлы-чокырлы юл буйлап җәяү чыгып киткән иде. Шуннан соң нинди генә юллар үтелмәде. Машиналарда, пароходларда, очкычларның иң кечкенәсеннән алып иң зурысына кадәр. Студент чакта авыл белән шәһәр арасында, аннары, журналист булып эшләгәндә—илнең төрле тарафларына.

Ләкин бу юлы бинһая зур, ике катлы очкыч-аэробус аны җир шарының икенче ягына гына түгел, язмышының кискен борылышына илтә, дип кем уйлаган?

Очкыч Ирландиядә төшеп утырды, анда аэропортта әфлисун суы белән сыйладылар. Казанда чатнама суык, ә бирегә аэропорт тирәсендә болыннар хәтфә булып җәйрәп яталар. Канадада тагын бер тукталыш булды,

очкычның канаты астыннан яфракларын коеп бетермәгән агачлар, вак күлләр белән чуарланган сазлыклар шуып үтте. Кыш бабай безнең якларда гына иркенләп, хуҗа булып йөри икән. Газитләрдә шомлы дип язылган атаклы Бермуд өчпочмагын узганны сизми калдылар—төн иде.

Гавананың аэропорты кара тәнле кешеләре, аңлаешсыз теле, сулышка кабар дәрәҗәдә эссе һавасы, утлар яктысында тастымал-яфракларын салындырып утырган пальмалары белән каршы алды. Ят дөнья, чит кешеләр, бөтенләй икенче яшәеш.

Гадәттә туристлар төркемендә егерме-утыз кеше була. Ләкин Казаннан унлапны гына җибәргәннәр, арада Рәшидәнең күз күргәне юк иде. Мәскәүдә аларны Үзбәкстаннан килгән төркем белән берләштерделәр. Ни хикмәттер, Казаннан да, Үзбәкстаннан да берәр генә хатын-кыз булып чыкты. Кунакханәләрдә бүлмәләр икешәр кешелек бит инде—ике хатын-кызга бергә яшәргә, гел бергә йөрергә туры килде. Бәхеткә, утыз биштән узган тулы гәүдәле әрмән хатыны Зара ачык, җайлы кеше булып чыкты. Кыскасы, гамьсез ял итү өчен шартлар бик әйбәт иде.

Ял итү дигәннән, аның да үз җае бар. Мул тормышта рәхәт яшәүчеләр моның рәтен бик белә. Бушка вакыт уздыруны шундый итеп кора ки, кинәнә, ләззәтләнә. Ә менә безнең татар хатыннары бу мәсьәләдә шыр надан. Эшсез-шөгыльсез тора белмиләр. Авылда чакта Рәшидә күреп тора иде: апалар, ат арбасына утырып басуга уракка барганда да кулларын тик тотмыйлар, оекбаш-бияләй бәйлиләр, бармак араларында биш инәләре елык-елык итеп биешә. Шул арада җырлап та алалар: монысы шул күңел ачу, ял итү була инде. Рәшидә шундый мохитта үсте һәм шәһәрдә дә шул рух, тәртип белән яшәде. Көндез редакциядә эш, кичен гаилә, ир, бала. Аның өстенә журналистның эше үзеннән калмый, ияреп кайта—иң уңышлы язмаларын аулакта, тынычта, ягъни өендә иҗат итә ул. Рәшидә кебекләр өчен андый вакыт—төн уртасы, андый урын—аш өстәле.

Эшсез торырга күнекмәгән кеше өчен вакытны бушка уздыру—үзе бер җәза. Гаванада узган беренче көннәрдә Евгенийның, Кубада карар нәрсә юк икән, дигән сүзләре искә төшкәләде, вакытны кая куярга белмичә эч пошкан чаклар да булгалады. Калай яфраклы пальмаларга, кара-чутыр мулатларга бер карыйсың, ун карыйсың, унберенчесендә туйдыра да башлый. Экскурсияләргә аз йөрттеләр, биредә Европадагы кебек тарихи шәһәрләр, чиркәү-соборлар да, борынгы хәзинәләр белән шыплап тутырылган музейлар да юк икән. Дөрес, бер көнне автобус белән Гаваналы күрсәтеп йөрделәр. Тәэсире әлләни булмады: шәһәрнең уртасы гына төзек, читрәк урамнары Казандагы Нариман урамы кебегрәк икән: йортлар иске, караусыз, күрексез, һәркайда фәкыйрьлек, күңел төшенкелеге хөкем сөрә.

Инде килеп, туристларның хөкүмәт рөхсәте белән иленнән алып килгән утыз доллар акчасы бар бит әле. Чит илләргә чыкканда, иң нык баш катырган нәрсә шул утыз доллар була: аңа мөмкин кадәр күбрәк нәрсә юнәтергә кирәк. Үзенә күлмәк-туфли алырга да җитсен, кайткач туган-тумача, дус-ишнең күңелен күрерлек тә булсын. Әмма биредәге кибетләрдә, СССР дагы кебек үк, социалистик бушлык хөкем сөрә икән. Акчаны соң кая куярга? Моның җаен шулай тапканнар: туристлар килеп төшүгә, варьетеларга билет тәкъдим итәләр. Берсе-берсе унар доллар. Совет кешесенең үз илендә андый нәрсә күргәне юк бит инде, татарлар да, үзбәкләр дә икешәр билет сатып алдылар. Беренчесенә, даны дөньяга таралган "Тропикана"га бергәләшеп бардылар. Һәм монарчы күз алларына да китермәгән хикмәтләрне күрделәр.

Варьетега керү юлы зур бакча аша уза, андагы пальмалар яна ел чыршылары сыман төрле төстәге ут тезмәләренә уралган иде. Мәйдандай иркен залда рәт-рәт утыргычлар түгел, ресторандагы кебек өстәл-урындыклар куелган. Иркен сәхнә алга таба ярым түгәрәк ясап чыгып тора. Ике як диварлар киртләп-киртләп, баскычлар рәвешендә ясалган.

Озатып йөрүче гид—Рауль исемле мулат, туры муенлы, серле карашлы егет, залдагы ак костюмлы берәү белән сөйләште дә, татар-үзбәк төркемен

иң арыга, сәхнәнең артына ук диярлек, иң кырыйдагы өстәлләр янына илтеп утыртты. Шундук һәр кешенең алдына биек стаканнар китереп куйдылар, аларга аз гына ром салып, эре-эре боз шакмаклары тутырылган иде.

Шуннан башланды... Күнелне җилкендерә торган хисле музыка уйнап җибәрде, сәхнәгә, дулкын-дулкын булып, бер-бер артлы төркем-төркем сылу кызлар агылды... Алар күз күрмәгәнчә болгана-боргалана, эчләренә сөяк урынына шарнир куйганнармыни. Баш түбәләрендә тавис койрыгы кебек каурыйлар җилпенә, тубыкларына-беләзекләренә эленгән озын-озын ялтыравык тукымалар җирдән сөйрәлә. Ә гәүдәләренең өч ноктасы гына капланган.

Рәшидәне шунысы гаҗәпләндерде: бу шәрә кызлар көтүе һәм алар янындагы ак чалбарлы биюче егетләр арасына ара-тирә ак чәчле абзыйлар да чыгып баса. Болар инде дипломатлар кебек киенгәннәр: ап-ак күлмәк, кара костюм. Ә кызарынган чырайларында шул кадәр очыну, рухлану, дәрт! "Йа алла, бу бабайлар соң нишләп йөри монда?"—дип аларны кызганып куйды Рәшидә. Хәер, монын бит үзенә бер мәгънәсе бар! Картлачлар тамашачыларга, узган гомерләрегезне санап, кимсенеп, кыенсынып утырмагыз, күзләрегез күргәндә, тез буыннарыгыз тотканда, ләззәт алып калырга тырышыгыз, дигәнне аңлаталар иде.

Ара-тирә ике яктагы киң баскычларга да кызлар чыгып тезелә, анда да боргалана-сыргаланалар. Шунысы гаҗәпләндерә иде: нәрсәгә бу хәтле шәрә биюче? Аларның барысын да күреп булмый бит! Башыңны кайсы якка борырга, кайсын карарга белмисең. Гомерләрендә андыйны күрмәгән социалистик хезмәт алдынгылары хәйран да вәйран... Алар инде үзләрен оҗмахка кергәндәй, һәрберсе җитмешәр хур кызына ия булгандай хис иткәннәрдер. Кул гына сузасы. Эчләрендә ниләр кайныйдыр, тән тамырларын кыздырып нинди утлар йөгереп узадыр да ничек чыдап утыралардыр... Әнә бит, сәхнәдәге ак башлы бабайлар гүзәлләр арасында йөзеп йөри, димәк, безгә, корсагы мендәрдәй күпергән абзыйларга да фарыз!

Алай да ошбу урын—җәннәт түгел, җир бит әле. Ә бу җиһанда беркайчан да, беркайда да дөньяның түгәрәк булганы юк. Биредәге рәхәтнең дә китек җире табылды: урыннарның иң кадерсез, караңгы төштә икәнлеге анга килеп иреште. Тамаша сәхнәнең алгы өлешендә бара, хур кызлары сәвит кешеләренә арт якларын куеп, залның уртасына карап, шундагыларга елмаеп бии. Анда исә өстәлләр буш диярлек, тамашачы берән-сәрән генә.

Безнекеләр баштарак уңны-сулны абайламыйчарак, дигәндәй, мингерәп утырдылар. Бераздан, стаканнардагы бозлар эреп, ром исе килгән салкын суны эчеп куйгач, муеннар турайды, башлар күтәрелде. Ирләр, бигрәк тә үзбәкләр шаулаша башладылар. Нишләп болай? Нигә безне, санга сукмыйча, бу төшкә китереп тыктылар? Әйбәт урыннар буш торганда!

Биш-алты кеше урыннарыннан сикереп торды, Раульне уратып алдылар, күчереп утыртуны таләп итә башладылар. Арада иң яше, моңарчы бер дә тавыш-тыны ишетелмәгән бер чандыр егет бигрәк тә нык кызган иде. Башы артка чөелгән, иреннәре кысылган, йодрыклары йомарланып, беләкләрендә кан тамырлары бүртеп чыккан.

Анын кыяфәтен күреп, Рәшидә көлеп җибәрде.

—Нәрсәсе көлке?—дип сорады анын янәшәсендә утырган Зара кашын җыерып.—Алар хаклы. Зал буш була торып, безне монда китереп тыктылар. Гарьлеге ни тора!

—Гарьлеге шул без түләгән ун доллар тора. Гарьлек булмастай урыннар, мөгаен, иллешәр доллардан да ким түгелдер,—диде Рәшидә.—Аннары ул урыннар занятый бит.

—Ничек занятый? Кем занимать иткән?

—Әмрикәннәр урыны ул!

—Кая нинди әмрикән булсын монда?! Кастро аларны Кубага утыз ел инде якын китерми ләбаса!

—Нәрсә Кастро. Анын да власте чикле,—диде Рәшидә.—Ил-җиренә кертмәс кертүен. Ә менә халыкнын күнел түреннән әмрикәннәрне беркайчан

да куып чыгара алмаячак. Кастро белән бер-бер хәл булса, икенче көнне үк бу зал шыгрым тулыр. Бу варьетеның хуҗалары да, биючеләр дә әмрикәннәрне сагына, алар килгәнне көтә, шул көннәргә әзерләнеп бии, репетиция ясый.

—Әйттең сүз! Бу кызларның күбесенә егерме биш тә юк. Алар әмрикән күргәнме!

—Долларлы кесәләрне сагыну ана сөте белән сеңә ул.

—Әмма Куба безнең белән, СССР белән дус! Без бергә шул дуслыкны ныгытыр өчен килдек. Юллама бирер алдыннан сезгә моны аңлатканнардыр бит?

—Аңлаттылар. Ләкин сүз нәрсә? Дуслыкны байлык, акча ныгыта. Әйтегез егетләрегезгә, өстәлләрен буш тотмасыннар, егермешәр долларлык кына булса да закускага заказ бирсеннәр. Минутында СССР белән Кубаның дуслыгы ныгып китәчәк, үзбәкләрегез сәхнәнең каршына ук барып урнашачак. Шулай түгелме?

Зара кара йөзем төсле күзләре белән Рәшидәгә текәлеп, сынап карады да елмаеп башын чайкады.

—Кая инде! Ләкин син уйлама, үз илләрендә такыр кесә белән йөрүчеләр түгел болар.

—Беләм инде, беләм. Барысы да хезмәт алдынгылары, рационализаторлар, абруйлы кешеләр. Орден-медальләре бар, җыелыш саен макталалар. Бәйрәм демонстрацияләрендә бәгъзеләренең портретларын күтәреп йөриләрдер әле?

—Алай да булгалый.

—Биредә дә күтәреп алырлар, дип уйлаганнардыр. Чит илләргә беренче тапкыр чыгуларыдыр шул. Күнекмәгәннәр әле. Моннан ары белерләр: хәерченең урыны—бусага төбендә. Ә сәвит кешесе—дөнья йортының ишек төбендә таптанучы фәкыйрь ул.

—Кубада безгә мөнәсәбәт шушындыйдыр дип, башыма да китермәгән идем,—диде Зара.—Күпме ярдәм итәбез без аларга!

—Әйе. Бомбалар, танклар бирәбез, нефть ташыйбыз. Ягъни, кулына күсәк тоттырабыз. Иң якын күршесе белән кара дошманлыгын арттырырга тырышабыз... Ә аларның әмрикәннәр белән дус яшисе килә. Ял итәргә күпләп-күпләп килсеннәр, долларларын унга-сулга туздырсыннар. Ул чакта монда көн саен бәйрәм булыр, кибетләр мал белән тулыр... Син кара әле, кара уртадагы кызга! Ах, шайтан! Тәне бии генә түгел, җырлый! Адәм баласы түгел, еландыр бу! Әйдәгез, алга барабыз да аягурә басып карыйбыз!

—Юк,—диде Зара.—Кая билет алсам, шунда утырам. Йә куып җибәрерләр!

—Әрле-әрле әрләнгәнче әрсез ашап бетергән, диләр бездә. Минем бергә бүтән киләсем юк, җай чыкканда бөтен тәмен татып калыйм әле. Яратам балетны!

Ул арада өч-дүрт официант дәгъвәче егетләрне кире үз урыннарына китереп урнаштырганнар иде инде. Кызарынган-бүртенгәннәр мескеннәр, варьете тамашасының бер рәхәтен тоймас дәрәҗәгә җитеп ярсыганнар. Рәшидә кузгалды да, алар турыннан узып, залның уртасына таба китте.

Ул уртада, иң якты урынга, буш өстәл-урындыклар арасына барып басты да, сәхнәгә текәлде. Ыспай гәүдәсенә сыланып торган, киң балаитәкле, вак чәчәкле, билле ак күлмәге, шома маңгаенын уң ягын дулкын булып каплаган кара чәче, барыннан да бигрәк түгәрәк ак йөзендә балкыган соклану катыш елмаю бу минутларда аны бик яшь итеп күрсәтә иде.

Әгәр күләгәдә калган юлдашларына күз сирпегән булса, ул теге чандыр егетнең үзенә текәлгән утлы карашын сизми калмас иде. Егет кузгалып, ана таба юнәлгән иде инде. Ләкин Рауль аркылы төште, кулларын болгап, тәртип сакларга өнди башлады. Ул арада Зара, дәгъвәнең зурга китүеннән куркып, урыныннан сикереп торды да, егетнең кулыннан эләктереп, урынына илтеп утыртты.

Рәшидә исә боларның берсен дә күрмәде, ул сәхнәдәге тамаша белән сихерләнгән иде.

* * *

Ике көннән төркемне җирнең оҗмахына, элек-электән әмрикәннәрнең иң яратып ял итә торган урынына—Варадерога илтеп урнаштырдылар. Ил башына Фидель Кастро менгәннән соң, бу курорт та бушап калган, шул сәбәпле совет кешеләренә килергә мөмкинлек туган икән.

Рәшидәне диңгез бик сагындырган иде. Евгений авырып киткәнче, көньякка ялга баргалыйлар иде. Ләкин соңгы елларда андый мөмкинлек бетте.

Ул кайчандыр Кара диңгез суларында юылып, яшел төсе уңып киткән, аякка кия торган арзанлы пластик йөзгечләрен үзе белән алып килгән иде. Инде менә Атлантик океанга шуларны киеп кереп китә дә сәгатьләр буе йөзә торган булды. Комлык тирәсендә, биек корылмалардан күзәтеп торучы коткаручылар күренми, берәү дә мегафоннан: "Әй, яшел башлык! Кире борыл!"—дип кычкырмый. Читтәрәк, яр кырыенда берничә ак көймә тора торуын, ләкин алар коткару вазыйфасын үтәмиләр, ахрысы, кем кая йөзеп китсә дә кузгалмыйлар.

Ярдан караганда океан суы эчкә таба биегәебрәк киткән кебек тоела. Ул киң тасмаларга аерылган сыман: зәңгәрсу, яшькелт, тагын зәңгәрсу булып күренә... Шуларны аркылы кисеп үтә-үтә, эчкә үк кереп киткәненне сизми дә каласың. Рәшидә белән янәшә ике-өч ир кеше генә шулай ерак йөзеп керәләр иде.

Монда су бигрәк назлы, йомшак, җылы, ышанычлы, ул сине бишектәге кебек тибрәтә...

Шулай гамьсез йөргәндә, өченчеме-дүртенчеме көнне, комлык артындагы пальмаларга карап яткан Зара, судан чыккан Рәшидәгә:

—Кеше куркытып йөрисең,—диде.

—Кая, кем курыккан?

—Әнә, безнең Аззян, әллә ничә тапкыр килде инде, синең өчен борчыла, батарсың дип курка.

Рәшидә комлыктан китеп барган егеткә, аның калак сөякләре беленеп торган кара-кучкыл какча җилкәсенә, чем-кара чәчле арт чүмеченә гаҗәпләнеп карады.

—Кем дисең?

—Аззян.

Рәшидә бу егет белән танышып өлгермәгән иде әле. Зара да әрмән өчен сәер исемне бозып, авыз эчендә әвәләп әйтә, шунлыктан кат-кат сорарга туры килде:

—Аңламыйм.

—А-зи-зян, дим бит.

—Ә-ә, Газизҗан!.. Исеме шулаймыни ул малайның?

—Булыр сиңа малай. Ике баласы бар инде.

—Ничә яшьтә соң ул?

Зара үз группасында җитәкченең ярдәмчесе булып йөри, мөгаен, КГБ дан да шактый нәрсәләрне өйрәтеп-аңлатып җибәргәннәрдер, һәр кешенең анкеталарын җентекләп укыган, кемнең кемлеген бик яхшы белә иде. Шуңа күрә шартлатып җавап бирде.

—Егерме алтыда.

—Шул яшендә ике бала булдырганмы?

—Син аның яшенә карама, алар бездә иртә җитлегә. Чәченә, әнә, чал кергән инде.

—Ә нишләп минем өчен борчыла ул?

Зара гамьсез көлеп куйды:

—Шундый сәер бит инде ул безнең Аззяныбыз...

—Һөнәре буенча суда батучыларны коткаручымы әллә ул?

—Каян килеп тагын! Үзбәк судан курка ул! Заводта мастер булып эшли.

—Кара син аны! Коллектив әгъзасы дип әйтмәссең дә үзен. Бер дә кеше белән аралашмый шикелле.

Чыннан да татар-үзбәктән укмашкан чуар төркемдә бу кеше чит сыман, үзенә бер аерым булып тоела иде. Яше кырыктан узып, тәненә шактый май-мая җыйган башка ир-атлар арасында ыспай-җыйнак гәүдәсе белән генә түгел, табигате белән башка иде ул. Гел арттан йөри, сүзгә кушылмый, чырае җитди. Рәшидә исә, журналистларга хас гадәт буенча, алда, җитәкченең, экскурсоводның авызына гына карап тора.

Хәер, теге көнне, "Тропикана"да, тавышы бик чыкмаса да, ярсу кыяфәте күзгә ташланган иде һәм көлке тоелган иде.

Ул егетнең Рәшидәдә ни эше дә, ни гаме бар соң? "Нечкә күңелле, беркатлы малай, күрәсең",—дип эчтән генә үзенчә нәтиҗә чыгарып куйды Рәшидә һәм, зур йөнтәс сөлгесен җәеп, Зара белән башын-башка куеп ятты. Сүз икенчегә күчте, Аззян-Газизҗан шундук онытылды.

* * *

Икенче тапкыр, бусында инде Варадерода, варьетега барганда, төркем икегә бүленде: татарлар "Пиратлар алачыгы" дигәненә, үзбәкләр "Национал"гә билет алдылар. Арадан берсе сырхаулап киткән дә, Зара Рәшидәне шуның урынына үзләре белән барырга күндерде...

...Кешенең язмышы күп очракта менә шундый юк-бардан тора бит ул—бер үзбәкнең пылауга күнеккән корсагына Кубаның банан боламыгы килешмәгән, имеш. Рәшидәнең исә кич буе бүлмәдә ялгызы каңгырап утырасы килми иде. Зарага ияргергә булды.

"Националь" дигәне "Тропикана"га җитми иде җитүен, алай да эчтәлеге шул ук: өстәлләрдә һәркемгә бирәр стакан бозлы ром, сәхнәдә—тәненең өч төшенә матур каплавычлар ябыштырган озын торыклы кызлар. Ләкин мондагының үзенә бер кызык ягы бар икән: тамаша тәмамланганнан соң, залдагы лампаларны сүндерделәр, бер кабынып, бер сүнеп, озын тасмалар булып, шуып-узып торган төрле төстәге утларны кабыздылар һәм теләгәннәрне сәхнәгә менеп биергә чакырдылар. Дәртле-ярсу латин америкасы көйләреннән, ромнан, ярым-шәрә кызларның ымсындыргыч биюләрен күзәтүдән тәмам кызган ир-егетләр хатын-кызларны әйдәкләп кузгата башладылар. Рәшидә янәшәсендә утырган юан корсаклы Абдрахман да торып басты. Биергә чакырды. Ә нигә биемәскә? Мондый кич гомердә бер була!

Алар җитәкләшеп сәхнәгә күтәрелделәр. Абдрахман аны биленнән тотып үзенә таба тарткан иде, корсагы Рәшидәгә килеп терәлде. Рәшидә нишләгәнен аңлап та житкермичә, аның кулыннан ычкынды да, бөтерелә башлады...

Куба биюләренең шәригате кин: телисең икән, егетенә тотынып йә бөтенләй сарылып, аның ихтыярына буйсынып хәрәкәтләнәсең, телисең икән, ана бөтенләй орынмыйча, каршысында гына бөргаланып сикергәлисең. Әнә, анда, сәхнәдә, ни генә кыланмыйлар! Һәм Рәшидә, үзе теләгәнчә биеде...

Заманында бию кичәләрендә аны уздырган булды микән?! Иң оста биюче егетләр белән дәртле көйгә әле унга, әле сулга бөтен залны иңләп бөтерелгәндә, танго, вальс-бостон ритмына басканда, күпләр аңа сокланып һәм кызыгып карап тора иде. Ул чорда хәрәкәтләрне ипле-салмак, матур ясатып, сынны сылу күрсәтә торган зыялы биюләр онытылмаган иде әле. Шул ук вакытта, буги-вуги, рок-н-ролл да модага кергән иде инде, аларын да Рәшидә иң беренчеләрдән булып өйрәнде...

Биюдән гомер буе туймас, туктамас кебек иде ул. Ләкин... Ләкин... Аның инде күптәннән дәртле музыка уйнаган, гамьсезлек һәм күңел күтәренкелеге хөкем сөргән залларга кергәне юк...

Менә кинәт ул яшьлегенә кайтып, андагы кичәгә барып кергәндәй булды. Талпынып, очынып, кулларын әле җәеп җибәреп, әле баш очына чөеп, үз тирәсендә бөтерелде. Аның бөтен барлыгын яшәү куанычы биләп алган иде. Кеше ихтыярына буйсынмый торган, үз вакыты белән кабына торган тормыш тантанасы, барча тереклек ияләрендә, гомернең бер чорында кузгала торган ургу иде бу. Мондый дәрт, тыелгысыз көч яшь боланнарны яшел дала буйлап уйнаклатып чаптыра, гөлләрне чәчәк аттыра, кошларны сайрата. Шул ук вакытта монда тәннең, һәр хәрәкәттән ләззәт алып,

талпынып янаруы, күңелнең ашкынуы гына түгел, үзенә бер ачы-татлы хис тә бар иде. Ул—нидер көтү, зарыгу иде. Һәм бу тойгы үзәкне сызландырып, сызып-сызып алды.

Әлбәттә инде, сәхнәдәге һәркем шушындый хыялый бер халәттә дип әйтү дөрес булмас иде. Кояшлы, җылы көннәр күп, әмма һәр гөл үз вакытында гына чәчкә ата. Күнел чәчкәләре керфекләрен ачып, җанында былбыллар сайраган, шушы минутларда Рәшидә, бәлки, бердәнбер булгандыр. Ә башкалар җинелчә күнел ачу, бер җилләнеп, гамьнәрне таратып, ял итеп алу минутларын гына кичергәндер...

Дөньясын онытып шулай күпме биегәндер Рәшидә. Берзаман күзен ачкан иде, ни күрсен: ул ялгызы калган лабаса! Әйе, биючеләр һәммәсе парлы-парлы, ул гына бер сыңар. Әле генә каршысында таптанган Абдрахман юкка чыккан. Һәм башкалар да, юри кылангандай, аннан читләшкәннәр, әйләнәсендә бушлык хасил иткәннәр. Нишләргә инде хәзер? Ялтйолт килеп торган биек сәхнәдән ялгызы төшеп китәргәме? Өч-дүрт баскыч аска атлыйсы... Өстәл артыннан күзәтеп утыручыларның, Зараның карашы астында... Оят, валлаһи! Аннары ул биеп туймады, дәрте почмакланмады бит әле! Аның биисе килә!

Шунда читтәрәк, парлар арасында берәү күренде. Ул да парын югалткан, ялгызы таптана... Үзбәкләрнең берсе... Теге арттан йөри торган малай... Аззян-Газизҗан...Уйлап тора торган җир түгел, бөтенесе шуклык-шаяру белән эшләнә—Рәшидә әйләнеп-бөтерелеп аның каршына барып басты.

Утлар алар өстеннән шуып узды да, карангыда калдырды. Алар тагын шуып килгәндә Рәшидә аның кочагында иде инде. Егет тә онытылып очыну, җилкенү кичерә, аның да бәгырь түрендә нидер көтү, сызлану, зарыгу бар иде, күрәсең. Икесенең күнелендә күтәрелгән дулкын аларны бер-берсенә ташлаган иде. Егетнең тәненнән ялкын бөркелгәндәй булды, нык, көчле куллары Рәшидәне үзенә буйсындыргандай итте. Сулышы белән битне өтеп алды һәм шашып-шашып үбәргә кереште. Нәрсә бу?! Ничек алай? Дөрес, башка кайбер парларның да ут сүнеп торган арада үбешкәне сизелгән иде инде... Ләкин Рәшидә... Анын беркайчан да болай кыланганы юк!

Әмма бу минутта ул үз ихтыярында түгел иде... Ниндидер өермә аны бөтереп алган, сулышын кыскан, хәлен бетергән иде. Һәм бу көчсезлек, буйсыну татлыдан-татлы, ләззәтледән-ләззәтле иде... Утлар аларның өстеннән шуа да уза, шуа да уза, дәртле көй янгырый да янгырый, Рәшидәнең аягы җиргә тими дә тими иде...

... Иртәгесен ул, әлбәттә, айныган иде инде. Ашханәгә барганда, кеше күзенә ничек күренермен, дип пошаманга төште. Алар Зара белән алданрак кереп, гадәттәге урыннарына утырдылар. Менә ишектән үзбәкләр керә башлады. Ашханәдә туристлар гадәттә күнегелгән тәртип белән утыралар. Рәшидәнең сулында Зара, уңында Абдрахман була торган иде. Әмма бу юлы абзый өлгерә алмый калды, алданрак Газизҗан килеп керде. Рәшидәне ялкын теле өтеп алгандай булды. Егет туп-туры ана таба юнәлде.

—Хәерле иртәләр. Ничек ял иттегез?

Башын ия төшеп, кечелек күрсәтеп, нәзакәтле итеп әйтте ул моны. Кичәге хәлләргә ым белән дә, кыска, куе керфекләрен тибрәндереп тә ишарә ясамады. Һәм ышанычлы, салмак хәрәкәт белән янәшә урындыкка утырды. Әйтерсен лә, аның монда тулы хокукы бар, әйтерсең лә, аның гадәтләнгән урыны шушы иде.

Рәшидә, башын күтәрми генә, сиздермәскә тырышып, каршысында утырган ирләрне күздән кичерде. Беркем дә аңа карамады, кинаяле көлемсерәмәде. Егетләрнең һәркөн кабатлана торган бер борчуы бар: монда авыз тутырып ашарга ипи җитми, булганы да саргылт күбек кебек бәрәкәтсез иде. Үзбәк абзыкайлар ак яльяпкычлы мулат кызларының игътибарын бушап калган ипи савытына җәлеп итү җаен эзлиләр иде.

Рәшидәнең исә ашауда гаме юк. Аның җаны уң ягыннан килгән җылы, йомшак, тылсымлы бер дулкында тирбәлә иде. Бу агым—яшь, сәламәт тәннең күзгә күренмәс, хуш исле, көчле нурланышы, аурасы иде. Рәши-

дәнен күптән инде мондый нурланышны тойганы, дөресрәге бөтен тән күзәнәкләре, җаны белән теләп, көтеп кабул иткәне юк иде. Хаста иренең тәненнән килгән ис, аннан саркыган күңелне изгеч хис бөтенләй башка-бүтән төрле шул!

Рәшидә башын бормыйча, астан гына Газизҗанның кул хәрәкәтләрен күзәтте. Егет зәңгәр спорт күлмәгенең җиңен терсәккәчә сызганып куйган. Кояшта янган беләкләре шома, чиста, башка күп ирләрнеке кебек төкле түгел. Юка тиресе астында мускуллары уйнаганы сизелеп тора. Ул кыска саплы пычак белән әфлисунны шундый җайлы әрчи, теге үзе чишенә шикелле. Озын, сизгер бармакларының очлары, балаларныкы кебек, арткарак каерылып тора, тырнаклары ахактай алсу-ак, ювелир ясагандай пөхтә, матур. Кинәт бәгырьне яндырып: "Бу бармакларның һәркайсын аерым-аерым үпсәң иде..."—дигән теләк туды, һәм Рәшидә, ике битенең уттай янып чыкканын тоеп, башын тагын да түбәнрәк иде.

—Рәхим итегез.

Газизҗан сузган кызгылт-сары әфлисун бүлемтекләренә кабыгыннан калган нәзек-нәфис алтынсу ефәк җепселләр сарылган иде.

—Минамы?!

—Сезгә, сезгә. Алыгыз!

Рәшидәнең тамагына нәрсәдер тоелгандай булды, керфек очларына тамчылар эленде. Ул, борыны мышкылдаганны сиздермәскә тырышып, тешләрен әфлисунга батырды. Йа алла, дөньяда мондый да татлы җимеш булыр икән!

* * *

Аларга күз салучы булмады кебек югыйсә, әмма кайберәүләр һәммәсен күреп, кемнең ни уйлаганына-кичергәненә кадәр сизеп-белеп тора икән. Ашханәдән чыгып, тук корсакка атлар-атламас торак бинага таба барганда, Абдрахман Рәшидәне туры китереп:

—Сиңа ничә яшь?—дип сорады.

Тозсыз һәм урынсыз сорау иде бу. Астыртын мәгънә белән әйтелгән иде. Янәсе, кемлегеңне бел, яшьләргә темиеңне сузма. Кирәк икән, үз ишләрен житәрлек.

Рәшидә бер мизгелгә генә югалып торды. Борылып, кап корсаклы абзыйның йөзенә туп-туры карады да:

—Утызны тутырдым быел,—диде.

—Ала-ай икә-ән,—диде абзыкай сузып.—Безнең Зара утыз алтыда, димәк, син аннан алты яшькә кечерәк буласың инде?

—Димәк, шулай булам инде,—дип көлеп куйды Рәшидә. Көлү аңа килешә, чыннан да бер ун яшькә яшәртеп җибәрә.

Тагын шунысы да бар: эре сөякле, авыр бәдәнле, киң чырайлы Зара янында ул чыннан да бөтенләй башка. Дөрес, буйга алар бер чамадыр, йөз алтмыш сантиметр тирәсе. Тик Рәшидә нечкә сөякле, җыйнак. Балачакта аның кушаматы да "Чыпчык" иде. Тынгысызлыгы, гел биеп-сикергәләп йөргәне өчен шулай үртәделәр. Турист походларында, ипле басып, житез атлап, армый йөргәне өчен "Монгол аты" дип тә атаганнары булды. "Шешә муен", "башың кечкенә синең" дигәннәрен дә ишеткәләргә туры килде. Ләкин инде болары якын итеп, яратып, җинелчә үчекләп яисә бераз көнләшеп әйтелгән сүзләр. Аның гәүдәсе борынгы грекларның мәрмәр сыннарын хәтерләтә. Тәне ак, ләкин кояшта тиз янып карала.

Дөрес, йөз чалымнарын бик үк камил дип әйтеп булмый. Борын кинчәрәк, иреннәр калынрак. Эскәк тимәгән куе кара кашлары астында якты яшькелт күзләр. Туп-туры карасаң, түгәрәк битендә бераз тәңгәлсезлек—ассиметрия барлыгы сизелә: юка борын яфракларының уңы сулыннан киңрәк, маңгай сызыгы уң якта таррак. Ияге дә уңгарак авышкан кебек. Әмма болар аны бозмый, киресенчә йөзен хисле, ачык, мөлаем итә иде. Игътибар белән карасаң, уң колак яфрагында нәни генә кирт барын да күрәсең. Галәттә аның колакларын чәче каплаган була, тик юлга чыгар

алдыннан ул чәчен кыскарак итеп кистерде, колак яфраклары күренеп тора. Башы ике түбәле, ягъни, чәче түбә өстендә генә түгел, уң як маңгай өстендә дә бөтерелеп үсә, шунлыктан тыңлаусыз, эре дулкын ясап, уңга төшә. Судан чыккач та, Рәшидә башын селкеп кенә җибәрә, чәче шундук күпереп үз көенә урнаша.

"Кечкенә эт—үлгәнче көчек",—ди урыс мәкале. Билен югалткан, көньяк хатын-кызларына хас булганча, авыз читендә сырлар уела башлаган Зара янында Рәшидә һич тә өлкәнрәк булып күренми иде.

Дөрес, ул беркайчан да үзен әлләни матурдан санамады, шул ук вакытта төс-битеннән гаеп табып кимсенмәде, чибәрләрдән көнләшмәде. Аның тышкы кыяфәте, килешле, уңайлы кием кебек, холык-табигатенә, үз-үзен тотышына бик ярашып тора һәм шуңа күрә бу хакта бөтенләй уйламаска була иде. Соңгы елларда исә моның кайгысы бөтенләй юкка чыккан иде.

Ләкин менә хәзер, ашханәдән кайткач, Зара ваннада юынган арада, ул стенага эленгән көзге каршына урындык китереп куйды да, шуңа менеп басып, үзен карады. Вак бизәкле, киң балаитәкле, аклы күлмәгенең билен кысып буып куйды. Кин кырлы эшләпәләр аңа килешми, шуңа күрә ул тропик эсседән башын күлмәгенә иш кыекча белән генә каплый. Бу аңа яшьлек мөлаемлыгы өсти иде.

"Ә нәрсә, миңа утыздан артык түгел лә!"—дип уйлады ул.

Ул үзендә гаҗәеп бер җинеллек, очыну сизде. Унөч-ундүрт яшьләрендә ул, караңгы төшкәч, шомырт чәчәгенең аклыгына һәм исенә күмелгән аулак авыл урамында берүзе биеп йөри торган иде. Хәзер дә шулай рәхәт иде аңа, тизрәк диңгез буена барасы, йөзгечләрне болгап, йомшак ком өстеннән йөгерәсе, океан суында дельфиндай йөзәсе килә иде.

Шул ук вакытта бу ашкыну-талпыну унөч яшьлек кыз баланың очынуы кебек кенә түгел иде. Кызган комлыктан йөгергәндә дә, сунын яшел-зәңгәр тасмаларын аркылыга кисеп, ярсып-ярсып, янәшә йөзеп барган ир-егетләр белән узышканда да, судан чыккач, иелеп йөзгечләрен салганда да ул Газизҗанның карашын тоя иде шикелле. Зур йөнтәс сөлгене юеш тәненә борынгы грекларның туникасына охшатып ураганда да, башын уңга янтайтып, артка каерылыбрак кыска чәчләреннән океан тамчыларын аксыл-саргылт комга сыпырып төшергәндә дә—ул боларның һәммәсен аның өчен эшли иде.

Әмма ул никадәр генә еракка йөзеп китеп, суда күпме генә булса да, егетнең теге көндәге кебек борчылганы сизелмәде. Комлыкта да ул шактый читтә, башка абзыйлар белән янәшә ята, хатыннар тарафына башын борып бер күз сирпегәне дә сизелми иде. Ник алай? Ниләр уйлый ул? Теге кичтә, варьетеда булганнар өчен Рәшидәне гаеплиме, җиңел акыллыга саныймы? Әллә башка берәр сәбәп бармы? Бу сорауларның берсенә дә җавап юк һәм мондый аңлашылмаучылык бәгырьне талый иде.

Алай да көндез, әле океан суында суынып, әле кояш астында кызып, онытылып торасың. Йөрәкнең бер өметләнеп җилкенүе, бер гаҗизләнеп сызлануы бигрәк тә кичләрен, кояш баеп, тирә-юньне караңгылык баскач көчәя иде.

...Кубада йөрәкләр көчле янса да, электр көчсез икән. Океан ярындагы комлык читендә басып торган дүрт катлы бинаны кичләрен ямансулык аралаш караңгылык төреп ала. Сирәк-мирәк сураеп утырган пальмалар да, тастымал яфракларын талчыккан куллар кебек салындырып, каралып-моңсуланып басып торалар. СССРдан килгән туристлар яши торган бу бина, канадалылар яши торганнан аермалы буларак, койма белән уратылып алынган. Капкадан кергән-чыкканны күзәтеп-тикшереп кенә торалар. Куба кызларына кичләрен бирегә керергә рөхсәт юк. Хәер, алар үзләре дә бу тирәне читләтеп уза, чөнки Фидель абзагыз, чит ил кешеләре белән бәйләнгән өчен өч ел төрмәгә ябарга, дип закон чыгарттырган. "Куба—мәхәббәтем!" дип, сәхнәләрдә, мәйданнарда бугазыңны киереп теләсә күпме җырлый аласың, ә "Куба кызы—минем сөйгәнем!" дия алмыйсың. Гыйшык-мыйшык хәлләре СССРдан килгәннәрнең үз арасында гына булуы мөмкин.

Бу нисбәттән Евгенийның сүзе расланмады—фахишәләрне күрергә туры килмәде.

Ярый әле, көн аралаш диярлек туристлар өчен бию кичәләре оештыралар. Алар торак бинасыннан беразчиттәрәк урнашкан ашханәнең аскы катында, яртылаш диярлек җир астына кертеп эшләнгән кечерәк кенә залда үтә.

Залга керә торган ишек төбендә, чирәмлектә, кечкенә генә бетон мәйданчыкта бер әкәмәт сын бар. Дон Кихот Ламанчскийның нәкъ кеше зурлыгында итеп, атка атландырып ясалган сыны бу. Әкәмәтлеге шунда—абзыкай үзе дә, арык алашасы да сүс баудан ишеп ясалган. Әлбәттә инде эченә агач куелгандыр, анысы күренми. Ә менә Дон Кихотның өстендә берни дә юк, бик тәфсилләп укмаштырылган ирлек бизәгенә кадәр күз алдында. Әмма рыцарь ялангачлыгын сизми, күңеле куктә: башын югары чөйгән, сүс өзәнгегә басып, коргаксыган озын, нечкә гәүдәсе белән алга, биеккә омтылган, агач сөңгесе белән ниндидер явызлыкка кизәнгән... Кыяфәтеннән көлми түзәрлек түгел. Испан язучысы Сервантесның героен бирედә бик яраталар, күрәсең. Хәер, Куба халкы үзен испаннар белән бертуган дип саный һәм испаннар аларны шулай ук бик якын күрәләр. Бу нәрсә сирәк кенә булса да совит газитләрендә дә чагылып уза.

"Испан телен белсәң иде дә рәхәтләнеп сөйләшсәң иде,—дип уйлады Рәшидә бу сынны беренче күргәч үк.—Нинди гөлләр чәчәк ата икән мондагы халыкның күңел түрендә?.. Бу рәвешле шаяра белгән кешеләр гади булмас... Моның янында карточкага төшәргә кирәк әле. Кайткач, Женяга күрсәтеп, менә бит, истәлекле урыннар бар анда, дип мактанырга".

Ләкин, эчкә кергәч, йөздәге елмаю ирексездән сүрелә. Залны, берберенә абынмаслык итеп, тычкан күзе кебек утлар белән генә яктырталар. Электрга экономия ясыйлармы, әллә инде биючеләр җаннары теләгәнне кылансын дип шулай эшлиләрме, алла белсен. Дүрт яктагы ачык ишекләр баз авызлары шикелле каралып тора. Бинада үтәли җил йөрсен өчен махсус шулай ясыйлар... Дәртле музыка уйнап торуга да карамастан, күңелгә кереп оялаган ямансулык хисе кечерәйми дә, таралмый да.

Хәер, анысы инде Рәшидә өчен генә шулайдыр, бәлки. Чөнки ул музыканы ишетми, биючеләрне күрми дә кебек. Аны карашы каралып торган ишекләрнең берсеннән икенчесенә күчеп йөри. Ул спорт костюмы кигән, аякларын идәнгә беркетеп баса торган берәүне көтә.

Тик Газизҗан нишләптер ашыкмый, Рәшидәнен кичергәннәре аның өчен читтер, күрәсең. Инде бөтенләй өмет өзелеп, йөрәкнең сыкрануы сулышка каба башлагач кына, караңгылыкның үзеннән аерылып чыккандай, килеп керде ул. Һәм әкрен атлап, зал аркылы килә башлады. Ана, Рәшидәгә таба.

Монда инде халык безнеңчә, совитчә, әдәп саклап бии. Газизҗан дә үзен зыялы кавалер кебек, сакланып кына, ике арада бушлык калдырып тота. Ә биюен яхшы бии—адымнары музыка көенә коеп куйгандай сызылып бара, тәненең һәр хәрәкәте анык, җайлы, ипле, җанлек хәрәкәте шикелле. Биергә дә биергә иде...

Ләкин хуҗаларның үз гаме—алар башка бөтән җиргә, акчалырак кешеләр янына ашыга. Куба кешесе төнлә йоклап ятмый, төнлә бии-бии яши ул! Ә йокыны, әнә, урыслар симертсен. Һәм сәгать ун тулганчы ук музыка тынып кала, залдагы тычкан утлары берәм-берәм сүнә башлый. Газизҗан да, баш иеп, Рәшидә янынннан китә, аргы ишекнең караңгылыгында эреп юкка чыга...

* * *

Бүлмәдә дә ярымкараңгы—түшәмнән асылынган тимер абажурдагы кырыклы лампочканың яктысы түгәрәк өстәлдән читкә төшми диярлек. Тын. Монда океан бик ипле икән, әллә елның бу фасылында гына шулаймы, дулкыннарның ярга бәргәне дә ишетелми. Хатыннар төнге күлмәкләрен кигән, урыннарын җәйгән. Рәшидә караваты кырыенда утыра, аның күзеннән йокы качкан.

—Зара!—дип урыныннан торып басты ул кинәт.—Мин харап булдым, Зара!

—Ни булды ул кадәр?

—Никләр мин монда килдем? Никләр генә аны күрдем? Эчем тулы ут! Гашыйк булдым мин, Зара! Уйларымда да, күз алдымда гел ул гына! Ул гына! Ә ул миңа борылып та карамый!

—Ничек карамый? Әле генә бергә биедегез бит!

—Син күрдеңме?

—Абдрахман мине йокы алдыннан һава сулап керергә чакырган иде. Узып барышлый залга күз салып чыктык. Биеп азаплана идегез.

—Хак дөрес әйттең, Зара. Азаплана иде. Әйе, ул минем белән азапланып кына биеде! Кызганудан гына!

Рәшидә читлеккә эләккән җәнлектәй ишекле-түрле йөри башлады.

—Йа раббым! Ничек бу газаптан котылыйм? Әллә ни булды миңа! Андый кешене очратканым юк иде минем!

—Нинди кешене?!—дип чиктән тыш хәйран калып сорады Зара.—Тапкансың! Кем әле ул шулхәтле!

—Аһ, Зара, син аңа игътибар белән карамыйсыңдыр! Ул бит... ул бит... Бик сизгер, нечкә күңелле... Ләкин мин аңа лаек түгел, Зара! Кызганып кына берәр җылы сүз әйтсә инде... Яшь аермасы гына ни тора...

—Анысына бер дә исең китмәсен. Тыштан караганда ул синнән яшь күренми. Тумас борын картайган нәмәрсә. Урыслар да кайчакта бик дөрес әйтә шул,—диде Зара үзалдына сөйләнгәндәй.—Чыннан да: любовь зла, полюбишь козла. Козел диярлеге дә юк бит ичмасам үзенең. Шул йолкышка күңел җәүһәрләреңне түгәргә!

Ләкин Рәшидә аны рәтләп тыңламый иде.

—Ә беләсеңме, башкаларның мондый хәле минем үземә дә көлке тоела иде,—дип сөйләнде ул.—Безнең авылда күрше апабыз үзеннән егерме яшьләргә кече егеткә гашыйк булган иде. Авыл башында нефтяниклар вышка куярга килделәр, теге егет шулар белән иде. Менә шул апабыз, кичкырын төенчек күтәреп гел шул вышкага таба йөри торган булды. Авылда сүз тиз тарала, артыннан да чыш-пыш сөйләп йөриләр, чыраена карап та әйтәләр. Ә аңа сүз керми. Кич саен әрәмәлек арасыннан вышкага таба илтә торган сукмакта аның ак яулыгы чагылып үтә, күрше-күлән, "тагын китте, тилергән тәмам", дип карап кала торганнар иде.

—Ирле хатын идеме?

—Юк, күптән тол иде. Уллары үсеп җиткән иде инде. Аның кыланмышлары миңа да көлке тоела иде. Ә менә хәзер минем хакта ни сөйлиләр икән? Башка үзбәкләр, Абдрахман ни әйтә? Карт түтәйнең бер малайга гыйшкы кабынган, диләрме? Син үзең дә шулай уйлыйсыңмы?

—Гел сине генә күзәтеп йөрмиләр инде анысы,—дип сузыбрак, икелемикеле җавап бирде Зара.—Үз гамьнәре дә җитәрлек.

Рәшидә аны әллә ишетте, әллә юк. Янә үз сүзен дәвам итте.

—Беләсеңме, юлга чыгар алдыннан ирем әйткән иде миңа. Олыгая башлаган хатыннарның кайсылары яшь егетләргә гашыйк була икән, дигән иде. Китапта да шулай язганнар.

—Ирең нининдирәк кеше соң синең?—дип уйланып сорап куйды Зара.—Сиңа иркәләү-наз җитмидер. Ничегрәк яшисез?

—Ярата ул мине,—диде Рәшидә бераз тынып торганнан соң.

—Ә син?

—Мин дә... аңа яратып чыктым...

—Анысы ул чакта. Ә хәзер соң ничек?

"Абый белән сеңел кебек",—дип җавап бирәсе иде. Ләкин ул бу сүзләрне кычкырып әйтмәде. Акланырга маташу шикелле булыр, дип уйлады.

Сүз җебе өзелеп китте, Рәшидә ятагын рәтләштергәндәй итте. Зара торып, лампочканы сүндерде. Караватын каты шыгырдатты, күрәсең, җайлабрак ятты. Рәшидә дөм караңгылыкта, тынлыкта калды. Күңелен шом

басты. Ул бу карангыда уй-кичерешләре белән ялгыз калырга теләми, аның сөйләшәсе килә иде.

—Зара, сөйлә әле, ирең белән ничек таныштыгыз, ничек кавыштыгыз,—диде ул.

Заранын да йокысы качкан иде бугай, бүлмәдәшенә таба борылып ятты.

—Гадәттәгечә инде,—диде.

—Ә ничек ул—гадәттәгечә? Сезнең якларда әле хәзер дә кызларны кияүгә димләп-кодалап бирәләр, дип сөйлиләр. Дөресме шул?

Зара көлеп куйды.

—Дөп-дөрес,—диде.

—Сине дә димләп бирделәрме әллә?

—Ә нишләп димләмәсеннәр? Кешедән ким түгел лә мин!

Зара моны ничектер күтәренке тавыш, эчке бер куаныч белән әйтте. Кызларнын иң асылларын кияүгә димләп бирәләр, дигән кебек иде бу.

Рәшидә исә югалып калды. Ничек була инде бу? Кызларның рәтлесе димче килгәнне көтеп утыра димени? Үзенә парны үзе таба ул! Әгәр яр таба алмаган икән, димәк, ана егетләр карамаган. Кешедән ким, дигән сүз.

Башыннан чагылып узган уйларын Рәшидә йомшартып әйтергә тиеш тапты—бүлмәдәшенең хәтерен калдырудан сакланды.

—Безнең якта хәзер димләп кавышучы парлар сирәк бугай,—диде.—Һәрхәлдә, минем ишеткәнем юк. Шуңа әйтүем. Аннары замана егетләренең кайсы гына ата-анасынын авызына карап тора икән? Алар үзләре баш, үзләре түш, үзләренә үзләре димче. Сез дә, мөгаен, алдан үзара аңлашып килешеп куйгансыздыр да, ата-аналарыгызның күңеле булсын өчен генә димләү юласын үтәгәнсездер. Бездә дә кайберәүләр шулай итә.

—Кая! Минем аны күргәнем дә юк иде. Егетне чит шәһәрдән димләделәр миңа. Без яшәгән җирләрдә әрмәннәр сирәк бит.

—Ничек алай? Сина ничә яшь иде сон?

—Егерме бер тулган, институтны тәмамлап килә идем инде.

—Һәм шунарчы гашыйк булмадын, бер егет белән дә йөрмәденме?

—Эчемдә җаным юкмы әллә минем? Йөрдем, ник йөрмәсен.

—Әрмән егете булгандыр инде?

—Урыс иде. Курсташым.

—Син әрмән, ул урыс... Яратыша идегезме?

—Ансыз була димени...

—Яратышкач... Вакыты да җиткән булгач... Өйләнешү турында хыялланмый булмагандыр бит?

—Бер-беребездән башка яши алмас кебек идек. Күзләрне күзләрдән алалмый, кулларны куллардан аера алмый торган кичләр бар иде... Ул инде диплом алуга өйләнешәчәгебезгә тәмам ышанган иде.

—Ә син?

—Ә мин әти-әнинен риза булмасын белә идем бит. Алар мине фәкать әрмән егетенә генә бирәчәкләр иде. Егетем, өйләнешеп кайтып, икәү бергә аякларына егылсак, гафу итәрләр, дип кенә җибәрә иде. Ә мин аларнын һичкайчан фатиха бирмәсен яхшы аңлый идем.

—Ләкин бу—синең тормышың! Син хәл итәргә тиеш мәсьәлә. Шулай түгелмени?

—Шулай түгел, Рәшидә. Һич тә шулай түгел. Тормыш кору, нәселне дәвам итү хис белән генә хәл кылына торган мәсьәлә түгел ул.

Монысы Рәшидәгә бөтенләй аңлашылмый иде. Мәхәббәт турында күп китаплар укыды ул, шигырьләр ятлады, җырлар тыңлады һәм үзе дә җырлады. Аларнын һәммәсендә сөю-сәгадәт, ә сөйгәненнән аерылу олы бәхетсезлек, фаҗига, диелә.

Әйе, "Галиябану"да да, "Ромео белән Джульетта"да да, "Ләйлә белән Мәҗнүн"дә дә—мәхәббәт кыйссаларынын бик күбесендә ата-баба юласы, борынгыдан килгән кагыйдәләр, өлкәннәрнен фикере яшьләрнең саф мәхәббәтенә каршы чыга. Сөю утында янган йөрәкне—богауларга, хыялларны—

тышауларга, киртә белмәгән күңелне читлеккә бикләргә кушалар алар. Әгәр буйсынмасаң, мәҗбүри аералар, кара бәхетсез итәләр, кайчакта һәлакәткә китереп җиткерәләр. Аларга каршы торып, баш бирмәү, үз мәхәббәтеңне яклау, саклау, сөйгәнеңә тугры калу—үзе бер батырлык, бәхеткә ирешү түгелмени?

Бу дөньяда саф сөюдән, мәхәббәтеңә тугры булудан югарырак бер нәрсә дә юк. Рәшидәнең белүенчә, яшьләрнең һәммәсе дә шулай уйлый, шуна омтыла. Бигрәк тә кызлар...

Зара да, Рәшидә кебек үк, сәвит мәктәбендә белем-тәрбия алган, шундый ук китаплар укып, шул ук киноларны карап үскән кеше... Ничек соң әле ул, сөйгәненнән аерылып, башка-бүтән белән тормыш коруы хакында болай җиңел генә сөйли ала?!

—Ярынны ташлап, димләгәнгә чыгу турында бездә менә болай җырлыйлар:

Рәшидә кыска көйгә әкрен тавыш белән җырлап алды:

Агыйделне киң диләр,
Аны диңгез димиләр,
Сөйгәнең кала, димиләр,
Сөймәгәнгә димлиләр...

Аннары җырның мәгънәсен урысчага авыштырып бирде дә:

—Бик ямансу җыр бу,—диде.—Синең ничек булды соң? Мәҗбүр иткәннәрдер инде.

—Беркем дә мәҗбүр итмәде. Үзем хәл кылдым.

—Сөюең чын булмаган, димәк...

—Мәхәббәтнең чынлыгын нинди бизмән белән үлчиләр соң? Күпме төннәрем йокысыз үтте, күпме кайнар яшем түгелде. Үзем генә белдем. Ләкин мин әти-әниемне дә яратам шул. Аларны кара кайгыга салып, үзем ничек бәхетле булыйм? Ике ут арасында калдым шулай.

—Сөйгәнеңә чыксаң, бәхетле булыр идең. Әти-әниең синең бәхетеңне күреп юаныррлар иде.

—Тиң түгелгә чыгып, ничек гомер буе бәхетле булып бетим инде мин?

—Ничек тиң түгел?

—Әйттем ич инде, урыс иде ул. Урыс әрмәнгә тиң була димени?

Менә инде ни дияргә дә белгән юк иде. Без бит туганнан бирле, адәм балалары һәммәсе бертигез, дип, кешене кешедән милләтенә карап аеру тиеш түгел, дип өйрәндек ләбаса! Азмыни, бер-берсен сөешкән, кавышкан, гомере буе тигез-бәхетле гомер кичергән төрле милләт кешеләре! Мәхәббәтне саклый белергә генә кирәк!

Шулай уйлады Рәшидә, ләкин тагын дәшмәде. Ул әйтергә теләгәнне, әлбәттә, Заранын мең тапкыр ишеткәне, укыганы бар, кабатлап торуның берниндн хаҗәте юк. Әңгәмәдәше аны сүзсез дә аңлады булса кирәк, бераз тынып торды да, дәвам итте:

—Берзаман мине туйга чакырдылар. Шунда кече җиңги минем игътибарны Давид исемле егеткә юнәлтте. Бер ел элек кенә институт тәмамлаган икән... Өйләнмәгән. Мин шундук сиздем инде туган-тумачаның ниятен.

—Ә егет чибәр идеме?

—Башта аның чибәрлеге дә күзгә күренмәде.—дип куйды Зара көлеп.— Сөйгәнемнән бүтәнгә күз дә саласы килми иде, алтынга манчылган булса да. Ләкин кардәш-ыру алдында тәртәгә тибеп булмый, әти-әнинең күңелен кырмас өчен генә дә теге егет белән кашны-күзне җыермыйча сөйләшергә, парлашып биергә туры килде. Сизеп торам: ул да мине күрүгә егылып китмәде, хәле шулай ук шәптән түгел. Аны мина димләгән кебек мине дә аңа димлиләр. Алай да өлкәннәрнең сүзен орып-бәреп аяк астына салып булмый, әдәп сакларга туры килә. Сабыр итәргә. Соңрак, иплэп кенә үз фикеребезне әйтербез. Димләү бар нәрсә, әмма көчләп кияүгә бирү юк бездә. Күзләребезгә туры карадык та бер-беребезнең хәлен аңладык.

—Алай да... тиз аңлаша башлагансыз икән...

—Аны гына аңлашмаска! Икебез дә әрмәннәр ич без!—диде кинәт нык

итеп Зара. Аның монарчы йомшак, ямансу яңгыраган тавышында кискенлек, какшамас бер ышаныч ишетелде. Ул, шиксез, үз милләте белән горурлана һәм гомумән әрмәннәрне башкалардан аерым, биегрәк урынга куя иде.

Зарага әрмәнлеге белән горурлану рәхәт. Әрмәннең союздаш республикасы бар, алар турында борынгы, данлы, мәдәниятлы халык дип язып, тукып торалар. Атаклы китапларны туплаган Матенадараны бар аларның, дан казанган коньягы, гомере буе СССР нын ин зур житәкчеләреннән саналган Микояны, шахматчы Петросяны, маршал Абрамяны бар. Ахыр чиктә мәзәкләре белән танылган "әрмән радиосы" гына ни тора. Боларны СССР нын һәр кешесе бик яхшы белә.

Ә менә татарны Зара кем дип, нинди дип белә? Күп китапларда язылганча, "басурман" дип, "поганый татарин" дипме? Берәр кайда "мин татар" дип мактанып буламы?

Тамырларга әйләнеп карасаң, татарның мактанырлыгы баштин ашкан югыйсә. Атаклы галим Лев Гумилев әйтүенчә, "дөньяны тетрәндергән төркиләр" кавеме бит без. Безнең бабабыз Атилла Европаны тезләндергән, халкын чалбар кияргә өйрәткән, коллыктан ваз кичтергән. Татарларның бабалары Европаны таң калдырырлык гүзәл шәһәрләр төзегәннәр, беренчеләрдән булып корыч койганнар, күн эшкәртеп, итек киеп йөргәннәр, үз язуларын булдырганнар. Хәер, нигә ерак китәргә: икенче бөтендөнья сугышында Герой исемен алучылар, халык саны белән чагыштырганда, татарлар арасында барысыннан да күбрәк булган. Тик боларны Зара да, башкалар да белми шул. Чөнки ул хакта дәреслекләрдә язылмаган, телгә кертеп тә сөйләнми.

Бу уйлар Рәшидәнең уенда мизгел эчендә чагылып узды, ләкин аларны кычкырып әйтеп булмый, жае ул түгел иде.

—Мәсьәлә жинел хәл ителгән алай булса,—диде ул салкын гына.

—Кая жинел булсын! Йөрәк бит ул законнарга буйсынмый! Яна да яна! Тик анын ялкынын тышка чыгарырга ярамый иде. Без, Давид белән шулай сүзсез килешеп, туган-тумача каршында, артистлар кебек, спектакль уйнарга мәжбүр булдык. Безне әле тегеләргә, әле боларга кунакка чакырып очраштыралар, театр-концертларга алып баралар. Ул арада каникул житте, яраткан егетем төзелеш бригадасына ялланып, акча эшләргә читкә чыгып китте. Ә бу Давид һаман күз алдында. Уенга тәмам кереп бетте бу, очрашуга чәчәк тотып килә башлады. Елмаешып күрешәбез, ачылып сөйләшәбез. Шулай күрешә-сөйләшә торгач, эчемне бик пошырмый торган булды. Яхшы кеше бит, туганнар миңа яманны сайламас.

—Шулай булмый ни,—диде Рәшидә ачы көлемсерәп.—Тыштан кыланган әкренләп эчкә үтеп керә бит ул. Син яраткан булып кыланасын гына шикелле. Ләкин шулай уйный торгач, тора-бара чынлап ярата башлаганыңны сизми дә каласың...

—Алай жинел генә булса икән,—диде Зара уйланып.—Инде ярәшү турында сүз кузгалды, ә минем күнел риза түгел!..

—Ә сон теге сөйгән егетен? Вәгъдә бирешмәгән идегезмени?

—Кем ярәштерсен мине анын белән...

—Үзегез...

—Ничек үзебез? Ярәшү өчен ике яктан кардәш-ыруны жыеп, зур табын корып, балдаклар алышып...

—Сон алайса ярәшмичә генә өйләнешергә...

Зара хәтта яткан жиреннән калкынып, торып басарга омтылгандай итте. Карангыда күзләре очкынланып киткәндәй булды.

—Әрмән кызы ярәшмәгән кешегә кияүгә чыкмый,—диде ул, "кеше жиргә ике аягы белән басып йөри", дигән сыман итеп.

—Ләкин башкалар чыга. Загска барып язылышалар да бетте китте. Дөрес, анда уйларга бер ай вакыт бирәләр бирүен. Шул ярәшү була инде.

—Бер ай аз. Безнен туй сигез айдан булды. Анда бит егет белән кызның бер-берсен белүе генә житми. Кардәш-ырунын, нәсел-нәсәпнең кемлеген, ниндилеген ныклап белешергә кирәк.

"Бу ничек килеп чыга инде? Селекция, ягъни, нәсел яңарту дигән сүз түгелме? Терлек-туарның токымын яхшырту турында сүз барамыни! Монда мәхәббәтнең ни катышы бар?"

Ләкин Рәшидә монысын да теленнән ычкындырмады. Зараның хәтерен саклаганнан гына түгел, сәбәбе бар иде. Аның үз тормышын фаҗигагә китергән сорау иде бу...

Зара аның уйларын аңлады, ахрысы. Гомумән, Рәшидәдән шактый яшь булуына карамастан, бу сөйләшүдә ул фикеренең ныклыгы, үз дигәненә ышанычы белән күпкә өлкәнрәк, акыллырак тоела иде. Хәер, укытучы бит ул, дип үз-үзенә аңлатты моны Рәшидә. Укытучылар үзләрен, балаларга гына түгел, гомумән халыкка бердәнбер, катгый, мәңгелек хакыйкатьләрне алып килүче дип саныйлар. Бу аларның һөнәренә хас сыйфат. Ә журналист... ул һәрвакыт төрле фикерләрне, капма-каршы якларны тыңлый, икеләнә, эзләнә, уйлана...

—Кече җиңгигә серемне сөйләдем,—дип дәвам итте Зара.—Йөрәк түремдә башка-бүтән, Давидка күнелем тартмый, дип зарланып еладым. Сөйгәнем белән кавышырга хокукым юкмыни минем, дидем. Кемне сөйсәм, шуныкы булам, үз тәнемә үзем хуҗа, дидем... Ә ул болай диде: "Мәхәббәт—тансыклаган ризыкны ашау дигән сүз генә түгел. Әгәр син ашның мондыен түгел, тегендиен теләсәң, мин үзем сиңа пешереп бирер идем. Ләкин монда бөтенләй башка бит. Кара син үзеңә... Нинди чибәр син, нинди акыллы, нинди хисле... Бу буй-сын, бу нурлы йөз, якты күзләр, бу акыл, зиһен, ялкынлы йөрәк каян килгән сиңа? Аларны сиңа ата-бабаларыбыз әллә ничә буыннан саклап, кадерләп, кайгыртып алып килгән. Син шуларның һәммәсен, зәгыйфьлек, гариплек кертмичә, нык-таза килеш балаларыңа бирергә бурычлы. Аларның язмышы синнән тора. Нинди кавем-ырунын уллары-кызлары булырлар... ни төсле... Сәламәт булырлармы? Озак яшәрләрме? Һәммәсе нәселгә бәйле. Син соң сөйгән егетеңнең кайдан, кем баласы икәнен беләсеңме?" Бу сорауга мин җавап бирә алмадым. Чөнки егетемнең әти-әнисен дә, туганнарын да белми идем.

—Аларын тикшерә башлагач, сөю буламыни ул?—диде Рәшидә.

—Җиңги миңа тагын болай диде: "Ышанычлы, күркәм бер ирмән егете тапмаслыкмыни син? Давид ошамый икән, башкасы очрар. Күңеленә хуш килгәне табылыр. Тик шуны онытма. Язмышыңны башка берәү белән бәйләгәндә, киләчәктән мөлдерәп карап торган сабыйларның бәхетен җимерә торган булмасын... Алар үз-үзләрен яклый алмый... Син якларга тиеш..."

Бу сүзләрдән Рәшидәнең күз алдында яшен уйнап узгандай булды. Әллә... Зара аның башыннан узганнарны белеп сөйлиме?.. Каян белгән? Кешенең уйлаганын уку сәләте бармы әллә анда?

Әйе, алар бер-берсенең гаилә хәлләрен сорашканнар иде инде. Зараны өендә ире, улы-кызы көтеп калган, Рәшидәне—ире... Ә балалар турында сораганны яратмый ул. Андый очракта йә "юк" дип кенә куя, яки унҗиде яшьлек улыбыз бар, дип җавап бирә. Урынына, сораучысына карап. Тик, җавабы ничек кенә булса да, үзеген өзеп, бозлы җил исеп үткәндәй була. Гаилә хакында сөйләшкәндә аның эчтән тартышып куйганын Зара тоеп алды, күрәсең, артык сорау бирмәгән иде. Хәзер менә, бер-берсенең йөзен-күзен күрмәгәндә, юри сөйли, ахры, ул бу бәгырьне телә торган сүзләрне...

Рәшидә сулышы кысылганын сиздермәскә тырышып, тыныч тавыш белән:

—Барыбер дә яшьли сөйгән ярың искә төшеп, үзәкләрең өзелгән чаклар буладыр?—диде.

—Булмый димени... Андый вакытта балаларга карарга кирәк. Балаң килеп бер сарылса, сагышлар шундук басыла... Аннары Давидны сынадым. Ялгышмадым. Алай да туйга кадәр күңелем белән ныклап хәл кылып бетермәгән идем әле. Менә-менә нидер булыр, туйга әзерләнү ыгы-зыгылары тукталыр кебек иде. Тик һәммәсе үз чираты белән эшләнде. Көне килеп җитте, ике яктан да кунаклар җыелды...

Һәм ул туеның ике каланы иңләгән бәйрәмгә әверелүе, кунакларның

очкычлар, машиналар белән килүе, кәләш күлмәгенең затлылыгы, бүләккә бирелгән бриллиант кашлы йөзек-алкаларның күплеге, яшь гаилә өчен алдан әзерләнеп куелган йортның яме турында сөйли башлады. Ә Рәшидә каршылыклы хисләр өермәсендә чайкала, бүлмәдәшенең тавышы ана томан аша килеп ирешкәндәй генә тоела иде.

Якут ташлар, бриллиантлар... Шушы яшенә җитеп Рәшидәнең бриллиант алка да, йөзек тә кия алганы юк әле...

Ә Зара сөйли дә сөйли. Тавышы йомшак, ягымлы. Шул ук вакытта анда олы апа өстенлеге, горурлык сизелеп тора. Ләкин аның үзен өстен куярга бернинди нигезе юк! Үз мәхәббәте өчен көрәшмәгән, димәк, чынлап сөя белмәгән кеше бит ул. Язмышын үзе хәл итәргә көче җитмәгән, тормышын борынгы кануннар буенча картлар кушканча корган. Шул булдымы горурланыр нәрсә! Яшьрәк чакта Евгений белән Рәшидә андыйларга, ягъни гаиләсен саф мәхәббәткә нигезләп түгел, акыл белән чамалап, аркылысын-буен үлчәп, нәселнәсәбен тикшереп корган кызларга, "самка" дип кенә карый торганнар иде...

—Ә сездә ничек ярашӓләр? Туйларны ничек үткәрәләр?—дип сорады Зара.— Кешенең гомерендә өч туе була, диләр. Тугач, өйләнешкәндә һәм үлгәч—җеназасы. Беренчесе белән соңгысын кеше үзе белми дә кала. Никах туенда гына табын түрендә үзең утырасын. Кызык бит бу, ә?

—Кызык...—диде Рәшидә.—Ләкин минем башкача булды...

—Ничек ул башкача?

—Минем янда туган-тумача юк иде...

—Ничек алай? Син Татарстанда яшәмәдеңмени?

—Татарстанда.

—Шулай булгач, кардәш-ыруың күптер бит. Безгә менә кыен ул. Үзбәкстанда, чит халык арасында яшибез.

—Мина өйдән иртә чыгып китәргә туры килде. Унбишем тулмаган иде әле.

—Унбиш яшьтәнме? Нишләп алай? Ятимәме әллә син?

—Ничек дип әйтим... Авыл халкы, крестьяннар Русиядә тулаем ятим алар, Зара.

—Бөтен халыкмы?

—Әйе, бөтен халык ятим. Моннан утыз ел элек Русия авылларында халыкның ничек яшәгәнен күз алдына китерәсеңме син?

—Бик томанлы,—диде Зара.

—Син, мөгаен, ул еллардагы колхоз тәртипләрен белмисеңдер? Авыл халкының хәле мәктәп дәреслекләрендәге крепостнойлар кебек иде. Аларга хәтта паспорт та бирмәгәннәр. Шәһәргә чыгып качмасыннар өчен. Бушка диярлек эшләткәннәр, шуна өстәп бик күп салымнар түләткәннәр.

—Эш хакы булмагач, нинди салым соң ул?

—Хуҗалыктан. Сөт тапшырткannар, ит, йон, йомырка... Әтием сугышта булып, ике аягы да яраланган иде, әнием колхоз эшендә сәламәтлеген җуйган. Мин сугыштан соң өченче, төпчек бала булып туганмын. Дүрт почмаклы бүрәнә өйдә яшәдек без. Түрдә сәке, бер якта зур мич, казан. Электр юк та юк инде, радио да юк хәтта. Лампага керосин табу мең бәла. Кышларын мич арасында бозау, сарык бәрәннәре үсә, каты салкыннарда шул ук өйгә буаз сыерны кертеп, җылытып чыгарабыз. Язга таба сәке астына бәбкә чыгарырга каз кереп утыра. Ягарга утын юк. Авыл тирәсендә кайчандыр урманнар булган диләр, ләкин аларны күптән кырып бетергәннәр иде инде. Кышка ягулыкны тирестән әзерли торган идек: елгадан су ташып, чылатып, яланаяк белән басабыз да калыплап чирәмгә тезеп, кояшта киптереп, ишек алдына өеп куябыз. Тирес кирпечләрнең җылысы аз, төтене ачы була.

—Безнен якларда шулай итеп саман кирпечләр ясыйлар,—диде Зара.

—Без үскән заманда авылда балалар аз, элекке җидееллык мәктәпне башлангычка калдырганнар иде, ун яше тулган балалар күрше авылга йөреп укырга тиеш иделәр. Өч чакрымга. Язын саз ерып, кышын буран кичеп. Аның киеме рәтле булса иде ичмасам! Тишек итекләр, ямаулы бишмәтләр.

—Ай-яй, ничек чыдап бетә алдыгыз,—диде Зара.

—Чыдап бетә алмаганга чыгып киттем дә инде. Училищеда стипендия түлиләр иде. Үз тамагымны үзем туйдырырмын дип уйладым.

—Стипендиягә яшәп була димени!

—Гаиләгә җиңелрәк бит инде барыбер. Безнең авыл шәһәрләрдән дә, тимер юллардан да бик ерак. Сигезьеллыкны тәмамлагач, җитмеш чакрым ераклыктагы шәһәргә барып училищега кердем.

Рәшидә боларны иң беренче чиратта үзе өчен сөйли иде кебек. Ул үзенең үткәннәрендә-кичергәннәрендә тормыш фаҗигасенең чыганакларын, сәбәпләрен эзли иде.

—Мин китап укырга бик ярата идем,—дип дәвам итте ул.—Аларда тасвирланган тормышка хәйран кала идем. Безнең кебек хәерчелектә, тирес арасында тырмашып җан асрау беркайда сурәтләнмәгән. Җирдә бөтенләй башкача яшәү рәвеше бар. Анда зур, мәһабәт, якты заллар, матур киемнәр, тәмле ризык... Музейлар, театрлар... Күңел шунда ашкына, кош кебек, канат ярып, еракларга очасы килә иде. Өстемә әни тегеп биргән бишмәтне кидем дә, аркама биштәр асып чыгып киттем шулай. Бишмәт кесәсендә стипендиягә хәтле яшәр өчен җитмеш тәңкә акча—аны әни күршеләрдән әҗәткә алып бирде. Биштәрдә өч ипи, каты пешкән йомыркалар, бер оек борчак.

—Шуның белән укыдыңмы?

—Иң читене акча белән ризык кытлыгында түгел иде. Иң кыены урыс телен начар белүдә булып чыкты. Укытучылар минем белән аерым шөгыльләнделәр хәтта. Училищедан каникулга кайткан чакларымда әнинең тезенә ятып:“Их, әни, урысларның үзләре кебек итеп урысча сөйләшергә өйрәнсәң иде!”—дип уфтана торган идем. “Син тотынсаң булдырырсың, кызым”,—дип башымны сыйпый иде әни.

—Булдыргансың да.—диде Зара.—Мин сине башта урыс хатыны дип уйлаган идем. Исемеңне ишеткәч аптырап киттем әле.

—Училищены тәмамлагач, тагын да ераккарак киттем. Башкалабыз Казанга. Анда институтның рус теле факультетына кердем. Студент чакта урыс гәзитләре белән язышa башладым. Тик менә ничектер шулай килеп чыкты, укуны тәмамлаганнан соң, татар гәзитендә эшләп киттем.

—Үз каның тарта шул ул!—диде Зара ышаныч белән.—Ә ничек кияүгә чыктың?

—Гадәттәгечә. Сөештек. Кавыштык.

—Кайда таныштыгыз? Ничек кавыштыгыз?

—Студент чакта. Икебез дә үзешчәннәр идек. Сәхнә артында таныштык.

—Татардыр бит?

—Урыс.

Зара югалып калды бугай. Тынлык урнашты.

—Затлы, нык нәселдәндер, шуңа кызыккансыңдыр инде,—диде. Мохтаҗлыкта үскән кешенең байлыкка кызыгуы, анынча, табигый хәл иде, күрәсең.—Ә туйны кайсы якта үткәрдегез? Нинди йола буенча: урысчамы, татарчамы?

—Сәвитчә,—диде Рәшидә.—Загска бардык та язылышып кайттык.

—Ничек бардыгыз? Кая кайттыгыз?

—Тәпи-тәпи бардык,—диде Рәшидә. Аннары тавышланып иснәп куйгандай итте.—Арылган бүген. Озаграк йөзгәнмен, ахры.

—Соң шул инде. Тыныч йокы!—диде дә Зара тынып калды.

Ә Рәшидәнең шар ачык күзләре тәрәзәдәге тасмалы пәрдә—жалюзи аркылы чак кына саркыган аксыл яктылыкка төбәлгән иде.

Туй? Чын туе булдымы соң аның?! Әгәр дә ул, ачылып китеп, үзенең башыннан кичкәннәрне сөйләсә, Зара аның хакында “самка” дип уйламас идеме?

* * *

Хәер, нәрсәгә чагыштырырга! Алар икесе ике бакчада үскәннәр. Зара—тау битендәге бакчада, эссе кояшта кызынып үскән мандарин агачыдыр...

Ә Рәшидә юл читендә, давылларда-бураннарда бәргәләнгән миләштер...

Дөрес, гомерлек юлдаш сайлар чакта алар охшаш хәлдә булганнар—икесенең дә сөйгән яры чит милләт кешесе, икесенең дә ата-аналары моңа каршы.

Ләкин, йөрәк эти-әни кушканча гына тибәмени?!

Евгенийны беренче күргәч үк Рәшидәнең йөрәге сулкылдап куйды. Егетне тулай торакка бүлмәдәш кыз Рита алып килгән иде. Бик матур җырлый иде ул, концертта чыгыш ясар өчен үзенә шәп аккордеончы тапкан, имеш. Рәшидә шул ук концертта украин биюен башкарырга әзерләнгән иде. Аккордеончы аңа да уйнарга тиеш булды.

Сәхнә артындагы бер бүлмәгә кереп, икәүдән-икәү генә ашык-пошык репетиция ясап алдылар. Тиз аңлаштылар... Уенчының көе белән биюченең сикергәләве бик ярашты, килеште. Йөрәкләргә үк барып иреште дә, ике арага ефәк җеп сузып куйгандай итте.

Эчендә җаны булган кыз андый егеткә битараф кала аламы? Бер килмәгән җире дә юк иде шул Евгенийның... Шәһәр егете, музыка училищесында укый, тәрбияле, ипле, тора салып ябыша торган түгел. Буй-сын, кыяфәт ягыннан аның белән ярышырлык егет сирәк—бию кичәләренә барып керүгә, озынча, ак йөзе, барсының өстеннән калкып, әллә каян күренеп тора. Рәшидәне күрүгә, чыраендагы битарафлык галәмәтләре юкка чыгып, күзләрендә, иреннәрендә сөенеч чаткысы кабына торган иде. Мондый егетнең мәхәббәтен яулау, әлбәттә, зур горурлык иде. Ә милләтләр төрле булуга килсәң, урыс татардан кимме әллә?

Тулай торак бүлмәсендә бәйрәм кичәләре үткәргәндә, Рәшидәне музыкаль өлеш өчен җаваплы итеп куялар. Евгений елкылдап торган аккордеонын алып килә. Аһ, ул аккордеон! Килешә дә иде инде егеткә! Аның янында Рәшидә үзенең дә бер матур бизәк икәнен белә, чөнки аккордеончы әледәнәле аңа таба борылып, зәңгәр күзләрен бәхетле кыса төшеп, елмаеп куя торган иде. Егет уйный, кыз җырлый, кушымталарында ике тавыш бергә үрелә, бераздан кызларның да йөрәге түзми, алар да кушыла.

Бер җырны бигрәк яратып, йөрәк түреннән өзеп, олы бер мәгънә салып җырлыйлар иде. Рәшидә аны татарчага да тәрҗемә итеп куйды: ул үз телендә, егет үзенчә аралаштырып җырлаганда, карап торучыларның күнеленә бигрәк тә хуш килә иде.

Үтсен еллар, гасырлар,
Җирдә бөек бер көч бар:
Океаннардай даулы ул,
Йөрәкләрне яулый ул.
Шәрабләрдән татлы ул,
Якутлардан затлы ул,
Бар нәрсәдән бөек ул,
Мәхәббәт ул, сөю ул.

Бу җырны алар үзләренең сөю гимны дип атадылар .

Андый кичәләрдән соң, Рәшидә егетен тышкы ишектән озатып кергәч, табын җыештырып йөрүче кызлар дәррәү борылып аңа карыйлар иде.

—Моның ахыры ни белән бетәр икән инде?—дип куя шунда берәр кыюрагы.

Рәшидә сорауның ни хакта икәнен аңлый. Елмаеп, шаярган сыманрак итеп:

—Йә Евгенийга барам, йә бөтенләй кияүгә чыкмыйм,—ди торган иде.

Мондый чакта күңеленнән ул үзен Ләйләгә, Джульеттага тиңли, мәхәббәт өчен көрәштә, алар кебек үк, җанын фида кылырга әзер кебек иде!

Ләкин нинди генә җырлар җырланып, нинди генә вәгъдәләр бирелсә дә, эти-әни фикере белән исәпләшми булмый иде. Ә алар кияүләре урыс булуны күз алдына да китерә алмыйлар иде.

Һәммәсен бер мизгел хәл итте. Дөресрәге карлы яңгыр сибәләгән күңелсез, шыксыз көзге көн иде бу. Ул кич хәтергә бөтен төсмерләре белән сеңеп калды, гүяки Рәшидәнең туе шундый төсләргә манылган иде. Сәгать

өчләрдә үк шәһәрне көчектергеч, сыланчык, салкын томан каплады. Кала үзәгендәге калкулыкта биегәеп утырган финанс интитутының аксыл-саргылт бинасы түбәсе белән болытларга тоташкан иде. Пычракка баткан машиналар фараларын кабызганнар, өскә шакшы су сибеп узып китәләр. Рәшидә, нишләргә белмичә, Кольцо дигән җирдә туктап, бөрешеп басты да, үксеп елап җибәрде. Кереп кунар урыны юк иде аның. Институт тәмамлагач, редакциягә эшкә алдылар, ләкин торак бирмәделәр. Көзгә кадәр ул, элекке гадәт буенча, студентларның тулай торагында яшәп торды. Хәзер инде аннан да чыгарганнар иде. Бар милке редакциянең өстәл тартмасында, ә үзе кичләрен урамда. Кая барып баш төртергә, ничек төн уздырырга? Шулкадәр ялгыз, беркемгә кирәксез дип хис итте ул үзен! Ә бит сөйгән яры янында, янәшәсендә биегәеп басып тора иде!

Егет, нишләргә белми таптангалады да, иелеп кулъяулыгы белән аның битен сөртте:

—Ник без үзебезне үзебез шушы хәтле газаплыйбыз?—диде. Әйе, "син" димәде, "без" диде. Рәшидә кичергәннәрне ул үз йөрәге аша уздыра иде.

—Әйдә безгә кайтабыз,—дип аның салкын бармакларын кайнар учына алып кысты аннары.

Рәшидә карышмакчы булды, ләкин Евгенийның учыннан килгән җылы, йөрәк аша саркып, телдән өзелеп төшәргә торган сүзләрне эретеп юкка чыгарды. Көзге томан, чарасызлык, үзенең күз яшьләре ихтыярны йомшарткан иде.

Евгений аның кулыннан кысып тоткан килеш, үзәк урамдагы капкаларның берсеннән сасы ишегалдына, кыйшайган, ямьсез өйнең ишегенә таба алып китте. Ул шунда, хан заманыннан бирле кеше кулы тимәгән йортта туып үскән, шунда яши иде...

Бер атлагач, кире борылып булмый торган чаклар бар. Биек кыядан сикергән кебек... Тәбәнәк түшәменнән керле шәрә лампочка асылынып торган өйалдына барып кергәч, Рәшидә шундый хис кичерде.

—Әни, киленеңне кабул ит,—диде Евгений эчке ишектән чыккан, таушалган чырайлы, юан гәүдәле, чуар халатлы хатынга.

Түтәйнең йөзендәге ризасызлык чалымнарын күргәч: "Юк!"—дип каршы төшәргә, кире атларга була иде әле.

Ләкин әниләр ерак, көзнең яңгырлы шыксыз киче ишек артында сагалап калды, ә янәшәдә күптән кадерлегә әйләнгән сөйгән кешесе тора иде. Егет зур, нык, кайнар учына кызның тетрәнгән салкын бармакларын йомарлап тоткан, аның кулыннан бөтен тәнгә рәхәт җылы белән бергә җан тынычлыгы, ышаныч та агыла иде. Болар Рәшидәне тәмам эретте.

Хәер, милләтләр төрле дип артык хафаланырлык та түгел иде кебек. Катнаш никахлар шәһәр тулы. Бик гадәти күренеш ләбаса ул. Инде гомерен авылда уздырып, заманнан артта калган ата-анага да күзләрен ачып тирә-якка карамый, дөнья хәлләре белән килешми булмас. Күңелне тырнап узган шик-шөбһәне менә шундый уйлар куды да җанны тәмам тынычландырды.

* * *

...Зара белән Рәшидәнең тормышын башлап җибәрүе арасында нинди зур аерма! Аларны алда көткән язмышның, аларга төшкән йөкнең төрлечә булуы бер дә гаҗәп түгел шул.

...Шулай итеп, Рәшидә, туйлар ясамый гына, ата-анасын, нәселыруын мәшәкатьләми генә килен булып төште. Ул барып кергән гаилә, башка милләттән булуы өстенә, бик фәкыйрь дә булып чыкты.

Евгений үзе музыка училищесының соңгы курсында укый, сеңлесе—мәктәп укучысы, әниләре җыештыручы булып эшли, әтиләре вафат иде.

Рәшидәнең хезмәт хакы казанга салган тоз кебек эреп юкка чыга барды. Хәер, хөкүмәт иҗат әһелләренә беркайчан да кешечә яшәрлек хак түләмәде. Бер язучының көлеп әйткәне дә бар: "Каләм ияләрен күп ашатырга ярамый. Симерсәләр язмый башлый алар". Рәшидә башка гәзит-журнал-

ларга да мәкаләләр яза, вак-төяк тәрҗемәгә дә алына иде. Ләкин җитми, җитми. Ай саен бурычка керергә туры килә.

Ул үскәндә, авылда ир-ат аз, сугыш чорында тол калган хатыннар тормыш йөген уртага җигелеп тарталар иде. Мәктәпләрдә дә, хатын-кызлар бар яктан да ирләр белән бертигез, алар хезмәттә ирешкән уңышлары белән мактала, дип туктаусыз тәкърарлап тордылар. Шундый мохитта тәрбияләнгән кызның кемгә дә булса салынырга уенда да юк, үзе җан-фәрман тырыша иде. Әмма барыбер, эчке бер сиземләү белән, хатын-кыз буларак үзенең көче чамалы икәнлекне аңлый, гаилә арбасын бер ялгызы өстерәп бара алмаячагын белә иде. Иренең бик тә ярдәм итәсе килә иде үзе. Ләкин студент нишли ала соң?

Йөрәк кушуы буенча, саф мәхәббәт белән башланган тормыш менә шундый булып чыкты. Җитәкләшеп урамнарда йөргәндә, музыка, китап турында бик мәгънәле сүзләр сөйләгәндә, аулак урынга посып кочаклашып үбешкәндә, акча турында, кышка җылы итек, җәйгә яңа күлмәк кирәклеге хакында кем уйлаган?

Ләкин уйламаганы бу гына булса икән! Аннан мөһиме, аннан аянычы бөтенләй исәпкә алынмаган, башка килмәгән икән...

Баштарак, әкренләп кенә, тормыш җайлануга таба барды. Евгений укуын тәмамлап, пионерлар сараена эшкә керде. Бала туар чак җиткәч, редакциядән бер бүлмәле фатир бирделәр. Эре панельле йортның беренче катыннан. Соңрак мондый йортларны мыскыллап, "хрущовка" дип атадылар атавын, әмма үз вакытында аларга күчү бик күпләр өчен оҗмахка керүгә тиң иде.

Рәшидәнең әнисе дә: "Дүрт бүлмәле бит бу! Дүрт бүлмәле!"—дип, ванна бүлмәсеннән аш бүлмәсенә кереп, аннары колач җәйсәң ике кулың диварга терәлә торган алгы бүлмәгә чыгып, куанып йөрде.

Алдан хәбәр бирми-нитми, һич көтмәгәндә килеп төшкән иде ул. Евгений эштә иде, бусагада әнисен күргәч, Рәшидә бер мизгел үз күзләренә үзе ышанмыйча, зиһенен туплый алмыйча торды.

—Исәнме, кызым! Әллә танымадың инде?! Бала туганын ишеткәч, җаным түзмәде, авылдашларга ияреп килдем менә,—диде Мәрхәбә.

Рәшидә исә куанычыннан телсез калган иде: "Килгән! Димәк, ачу сакламый, гафу иткән!"

Мәрхәбә, ваннада озаклап тәһарәт алып, догалар укыганнан соң гына сабый янына килде.

—Сөбханалла, күз тимәсен! Борыны да, авызы да гел синеке төсле икән!—диде.—Үзебезнең нәсел! Исем куштыгызмы инде?

Соңгысын әйткәндә, тавышы дулкынланудан нечкәреп киткәндәй булды.

—Марат дип торабыз,—диде Рәшидә.

—Әлхәмделиллаһ, татар исеме икән! Безнең авылда да Маратлар бар. Рәхмәт инде кияүгә. Хакмыдыр инде, кияүнең үз исеме бик үк матур түгел, диючеләр бар... "Евгений"ны бәләкәй чакта Женә диләр, ә "женә" сүзе арт санны да аңлата, диләр.

—Затсыз бәндәләр сүзнең иң матурын да пычратырга җай таба,—диде мона каршы Рәшидә.—"Ана" сүзен, әнә, нишләтеп кенә бетермәгәннәр. Урысы-татары бер иш.

—Безнең авылга Әндриләр, Василиләр килеп эшләделәр. Исемнәреннән көлүче булмады... Фамилиясе ничек соң баланың?

—Горюхин.

—Гөрухин?!—Мәрхәбә каушап диванга утырды, башы белән бәйләнгән ак яулыгының читен алга тартып, битен-күзен сөртте.—Хәсрәт дигән сүздән түгелме соң ул, кызым? Хәсрәтов буламыни инде безнең балабыз?!

Мәрхәбә урысча бөтенләй диярлек белми иде, ләкин, ни хикмәттер, бу сүзнең мәгънәсен шундук тотып алды. Үзе ничектер шомланып киткәндәй булды.

Ләкин нигә? Бу нинди хорафат тагын? Кайгы-хәсрәт фамилиягә карап килә димени?

—Син дә Гөрухина инде алайса...—диде Мәрхәбә төшенке тавыш белән.

—Юк, мин Галимова булып калдым. Фамилиямне алыштырмадым. Әмма бу да ананы юатмады.

—Балаң белән икең ике фамилиядә булу яхшы түгел ул,—дип куйды моңаеп.—Чит-ят кешеләр булып йөрерсезмени?

—Дипломнарны, бөтен документларны алыштырып азапланасы килмәде,—дип акланды Рәшидә.—Аннары газит-журналларда да шактый мәкаләләрем чыкты бит инде. Мине Галимова дип белүчеләр күп...

—Ул Гөрухиннарның нәсел-нәсәбе нindirәк соң? Туган-тумачасы белән йөрешәсездер, хәлләрен белешеп торасыздыр бит? Буыннары нык микән? Чәрексез нәсел түгелдер бит?—дип сорады Мәрхәбә бик мәгънәле итеп.

—Бик аралаша алмыйбыз. Вакыт та җитми, хәлдән дә килми әле...—дип җавап бирде Рәшидә.

—Маратыбыз исән-сау була күрсен, бәхете-тәүфигы белән үссен, йа раббым!—диде дә, учларын кушырып дога укырга кереште Мәрхәбә. Шулай итеп, кызына ризалыгын, балага фатихасын бирде.

—Бала хәсрәте күрергә язмасын, кызым!—диде ахырда.—Аннан да авыры юк. Ходай тәгалә шунысыннан сакласын!

Әйе, монысын иң тирәннән суырып алып әйтте Мәрхәбә. Сугышка хәтле туган дүрт баласын бер-бер артлы җирләгән ана иде шул ул. Ул чорларда авылларда балаларны рәтләп дәвалаучы булганмыни соң! Әле кызамыктан кырылганнар, әле чәчәк чиреннән. Шуңа күрә әнисенең бу сүзләрен Рәшидә карт кешенең бер да дә юкка хафалануы диебрәк кабул итте.

—Хәзер медицина көчле бит, әни,—диде.—Балаларны бик карыйлар, саклыйлар.

—Алла диген, кызым. Алла, диген!

Рәшидә "алла" димәде, елый башлаган баласын кулына алды. Әлегә үзенең Хәсрәтов икәнен белмәгән, аннан бернинди хәбәре булмаган Марат Евгеньевич Горюхин, рәхәтләнеп, кинәнеп, иреннәрен чупылдатып имәргә кереште.

...Рәшидәнең әтисе оныгын күрә алмады, бала туган елны вафат булды. Евгений белән бергәләп, Маратны күтәреп, авылга кайтып, башларны иеп, ата кешенең бәхиллеген дә, сабыйга фатихасын да алырга өлгермәделәр. Бусы йөрәккә тагын бер яра салып калдырды.

Дөрес, еллар узгач бу яралар төзәлер, үкенечләр бетәр, җан тынар иде. Әгәр һәммәсе дә теләгәнчә генә барса, яралар өсте-өстенә тырналып, канап тормаса.

...Марат Евгеньевич Горюхин алты яшенәчә бик матур булып үсте. Ул чакта балаларны музыкага укыту модада иде, безнеке кешедән ким булмасын дип, тотылган пианино алып куйдылар. Алтынсу ефәк чәчле малай, иң беренче эш итеп, шул пианино өстенә менеп, өстәлгә сикерергә өйрәнде. Шундый да тере, бер минут тик тормас, шук бала иде.

Көннәрнең берендә баланың күзе кылыйланганын сизделәр. Шуннан китте болгану, хәсрәт касәсенең ачысыннан ачысын эчү. Сырхауханәдән клиникага, бер табибтан икенчесенә, аннары профессорга, Казаннан Мәскәүгә. Үлемгә хөкем итү кебек сүзне Мәскәү врачлары әйтте дә инде. Сабыйның баш миенә яман чир ябышкан булып чыкты.

Күңел монын белән ризалаша алмады. Суга батучы саламга тотына, Рәшидә дә аз гына юаныч бирерлек сүзләрне, имеш-мимешләрне йотлыгып тынлый торган булды.

Берәүнең таныш умартачысы, шифалы үсемлекләрне балда-майда кайнатып, бик шәп дару ясый икән... Даны еракка таралган, чөнки күпләргә файдасы тигән, хәзер инде Германия хәтле җирдән килеп алучылар бар икән... Кемнеңдер таныш шоферы, ашказанына рак ябышканны белгәч, әҗәл көтеп ятканчы, тизрәк үлим ичмасам, дип, ярты стакан "тормоз сыекчасы" эчкән дә, сузылып урын өстенә яткан. Бераздан уянып китсә, үтереп карыны ачканны сизгән бу! Шуннан торып киткән, рак чире бөтен-

ләй юкка чыккан!.. Берәүләр "болиголов" дигән агулы үләнне аракыда төнәтеп эчкән, шуннан файда тапкан, имеш.

Мондый кыйссалар кул кушырып утырырга ирек бирми, каядыр барырга, нинди дер үләннәр жыярга, кем белән булса да киңәшергә ашкындыра иде. "Болиголов" дигән үләнне озак эзләде Рәшидә. Авыл хужалыгы институтының шәһәр читендәге "Икенче ферма" дигән бүлегенә барып, андагы галимнәрдән шул үләнне күрсәтүләрен ялынып сорады. Каяндыр табып, корыган сабаклар күрсәттеләр, фәнни белешмә китабын ачып укып бирделәр. Шунда бер нәрсә ачыкланды: болиголов—сазламыкта үсә торган ифрат агулы үсемлек булып, аннан тычкан исе килә икән. Рәшидә аны шәһәрдән унбиш чакрымдагы бер авыл янындагы сазлыктан эзләп тапты. Төнәтмәсен ясап, башта үзе эчеп карады, аннары тамчылап сабый авызына салды. Аңа өстәп умартачы бабай ясаган шифалы майны эчерде...

Әмма бала шәм кебек эри иде..

Гәзиттә "Өметләр өзелмәсен" дигән мәкалә күзгә чалынды. Түбәндә бер халык табибы эрбет ылысы белән себер үләннәре катнашмасыннан дару ясый, шуның белән яман чирне дәвалый, врачлар тәмам кул селтәгән хасталарны да аякка бастыра, дип язылган иде анда. Рәшидә шундук акча юнәтә башлады. Юлга чыгар алдыннан гәзитне табиб Николай Михайловичка да күрсәтте. Аның белән сөйләшү ничектер хәтергә аеруча нык уелып калды.

Алар зур тәрәзәләрдән җәйге кояш тулган якты, чиста бүлмәдә каракаршы утырып торалар иде. Табиб гәзитне тезенә җәеп салды да башын игән хәлдә шактый вакытка сүзсез-хәрәкәтсез калды. Әллә укыды, әллә юатырлык сүзләр эзләп, үзалдына уйланды.

Олы гәүдәле, ак халатлы, ак йөзле, ак бүрек кигәндәй күперенке чәчле табиб бу минутларда балачак хикәятләрендәге әүлияга охшап калган иде. Хәсрәтләре баштин ашкан чакларда адәм баласына табигать—болын, урман, бакча—җиңеллек, ял бирә. Күрәсең, бу кешедә дә табигатьнең шундый тылсымы бар иде. Юк, ул кемнедер юатам дип, буш сүзләр сөйләми, дөресен әйтә, тик тавышында, үзен тотышында шундый нечкәлек, хәлгә керү бар ки, аның теленнән өзелеп төшкән аяусыз хакыйкать бәгырьгә таш булып ятмый, монсулык булып ягыла иде.

—Мондыйлар Казанда да шактый,—диде ул гәзиттән баш күтәрми генә.—Бу арада бездәге бер монах турында да гәзитләрдә күп яздылар. Күрми генә калгансыздыр. Көнбагыш маена спирт кушып эчерәм дә, рактан үләргә яткан хасталарны бер ай эчендә аякка бастырам, дип мактана.

—Ә бәлки, шундый очраклар булгандыр?—дип калкынып куйды Рәшидә.

—Күпмегәдер дәртсенеп китүләре дә ихтимал,—дип, маңгай астыннан аксыл кашларын сирпеп, күз атып алды табиб.—Үсемлек мае белән спирт катнашмасы наркоз кебегрәк тәэсир итә, сызлануны киметә. Ә авыруның терелүгә ышанасы килә. Тик ахыр чиктә барыбер безгә килеп егылалар... Фәннең көче җитмәгән һәр өлкәгә шарлатаннар ияләнә шул инде, нишләтәсең. Безнең илдә генә түгел, бөтен дөньяда шулай. Яман чирне дәвалый торган яңа дарулар исемлеген туплап, Америкада ел саен калын бер китап бастырып чыгаралар. Ләкин озак та үтми, ул даруларның берсе дә шифа бирмәгәнлеге ачыклана... Сез акыллы хатын, югары белемле. Йөрмәгез моның ишеләр тирәсендә.—Ул ак, юан бармагы белән гәзиткә төртте.— Вакытыгызны да, акчагызны да әрәм генә итәчәксез. Кешеләрнең бәхетсезлегеннән файдаланып, баеп ятучы мошенниклар алар. Акланмас өмет белән сату итәләр. Һәм бик кыйбат сорыйлар!

—Аларга бармас идем дә, сез соң аның урынына нәрсә тәкъдим итәсез?..—диде Рәшидә сызланып.

—Сез мине каты күңелле, шәфкатьсез дип уйлыйсыздыр, бәлки, мина үпкәлисездер,—диде табиб куе, йомшак тавышын гадәттәгедән дә әкренәйтеп. Һәм тирән итеп көрсенде.—Минем дә күңелем таш түгел, яхшы буласым, сезне өметләндерәсем бик килә. Ләкин ялганлый алмыйм. Соңыннан сез мине каһәрләячәксез. Без әлегә көчсез. Монда хикмәт

геннарда, нәселдә. Фән исә хәзергә геннарны төзәтү ысулларын тапмады әле.

—Ә бәлки... тагын беразга гына сузсак... Бик зур ачышлар кайчак көтелмәгәндә ясала...—дип буталып сөйләнде Рәшидә.

—Илнең бөтен көч-куәте бомбалар да ракеталар ясауга китә бит, фәнгә акча калмый,—диде табиб башын чайкап.—Бәс шулай булгач, безгә кирәк дарулар тиз генә табылмас шул әле. Ә хәзергә күп язмышларны табигать хәл кыла. Нихәл итәсең, сезнең улыгыз нәсел чылбырының иң йомшак бөжрасына туры килгән шул... Безгә, врачларга, газапларны киметергә тырышу гына кала. Ә яшьләргә, яна тормыш башлаганда, бераз гына булса да бер-берсенең нәсел тамырларын искә алырга, булачак балалар турында уйларга...

—Аның өчен... шпион булырга кирәк! Сөйгән кешең артыннан шпионить итәргә...

Рәшидә, нишләгәнен аңлап җиткермичә, гасабиланып кеткелдәп куйды.

—Нәрсәгә шпион булырга? Күзне ачыбрак карау да җитә. Колакны бераз торгызу да зыян итми. Мәгъшугыңның сөю җыры гына түгел, халык сүзе дә керсен.

—Гавам гайбәтен җыеп йөрергәме?!—дип бик гаҗәпләнде Рәшидә.

—Кирәклесе үзе чынлап тора. Әйтик, менә фамилия. Ул бит күп очракларда кушаматтан алынган. Ә кушаматны халык тага. Кавемнең төп сыйфатын белеп тага. Әтәчләнүче нәселгә—Петухов, кире кавемгә—Козлов...

“Һәм... һәм... хәсрәт эчендә гомер кичергән кавемгә— Горюхин... Хәсрәтов...”—дип табибның сүзен үз эченнән тәмамлап куйды Рәшидә.

—Игътибар иткәнегез юкмы әллә?—дип дәвам итте Николай Михайлович.—Хәер, сез бу хакта уйламагансыздыр, бәлки. Татар фамилияләре, кагыйдә буларак, кеше исеменнән алынган. Габдуллиннар, Бариевлар, Сабировлар... Ни дигән сүз дип сораша башласаң, йә атасының йә бабасының исеме булып чыга. Шуңа күрә нәсел сыйфатын белдермиләр. Ә бездә, русларда, башкачарак. Армиядә безнең белән бергә хезмәт иткән татар егетләре бик гаҗәпләнә торганнар иде: “Карале, кара,—диләр,—сафның башында Большаков тора, ә иң ахырдагысының фамилиясе—Меньшов. Ничек алай туры килгән ул?”

Ә Рәшидәнең хәтерендә яп-якты булып әнисенең мөлдерәгән карашы һәм ничектер эчке бер сагаю белән хафаланып сораганы күз алдына килде: “Нәсел-нәсәпләре ниндирәк икән Гөрүхиннарның? Чәрексез түгелдер бит?.. Туган-тумачасының хәлен белешеп торасызмы?” Татар авылында гомере үткән авыл карчыгы белән урыс милләтеннән булган тәҗрибәле галим-табибның фикер-теләкләре бер иде!..

Әйе, Горюхиннарның хәлен белде Рәшидә. Баласы чирләгәч... Баксаң да күрсәң, бу ыруда иллегә җиткән ир-атлар бөтенләй юк икән. Һәммәсе яман чирдән китеп баралар. Евгенийнең әтисе дә, ике ел буе җәфаланганнан соң, бик интегеп, тәмам кеше кыяфәтен югалтып, кырык дүртен дә тутырмыйча гүр иясе булган.

Ләкин алты яшьлек бала... Ни өчен бер гөнаһсыз сабый шушындый газапларга дучар ителде? Халыкта, кылган явызлыкның җәзасы кешенең үзенә булмаса, балаларына килә, дигән сүз бар. Әллә бу җәза балага Рәшидәнең кылган гөнаһлары өчен бирелдеме?!

...Еллар буе газаплаган бу сорау менә хәзер, җир шарының икенче ягында, ике кешелек тын бүлмәдә, төн караңгылыгында, күзгә күренмәс кайнар бавы белән сулышны бугандай итте. Сикереп торасы, Зараны төрткәләп уятасы, аның янына башны куеп, сулкылдап елыйсы һәм барысын-барысын да сөйләп, эчне бушатасы килде.Монда күңелне ахырынача ачып була. Зара бит ул очраклы юлдаш. Атна-ун көннән, Мәскәүдән юллар аларның икесен ике якка алып китәчәк һәм беркайчан да бүтән очраштырмаячак. Мондый кешегә серьнең һәммәсе сыя, беркайчан да чәчелми!

Ләкин Рәшидә андый юанычтан да мәхрүм иде. Чөнки, алдан ук белеп тора: бүлмәдәше аны аңламаячак, ә бәлки, гаепләячәк тә әле. Әйе, баласының үлемендә гаепләячәк аны Зара.

Рәшидә чалкан ятты да, карашын чак кына агарып торган түшәмгә текәде, үз-үзенә читтән, очраклы юлдаш булган шушы әрмән хатыны күзеннән карагандай булды. Тормышын элек-электән куелган тәртип буенча, алдан уйлап, ата-ана, нәсел-ыру белән санашып, күңелле бәйрәм итеп башлаган, ипле, тәртипле яшәүче һәм таза-сау балалар үстерүче хатын күзе белән карады ул үзенең үткәннәренә.

Аныңча уйласаң, Рәшидә—зиначы! Гадәт-йолалар белән исәпләшмичә, өлкәннәрнең фатихасын алмыйча, матур итеп туйлар ясамыйча, никах укытмыйча, "син сөясең, мин дә сөям, мин синеке, син минеке, бүтәннәрнең бездә эше юк", дип кенә кавышучылар әдәп-әхлакияләренә, мөгаен, шундый—зина кылучы булып күренәдер. Гәрчә паспортларына загс мөһере суктырган булсалар да...

...Барча диннәрнең нигезендә катгый тыюлар ята: урлама, алдама, кеше үтермә, зина кылма... Тукта, тукта... Урласаң, алдасаң, кеше үтерсәң, башкаларга авыр зыян саласың... Ләкин "зина кылма"! Ник? Икәү кавыша икән, аннан кемгә зыян? Кем аннан нинди каза күрә? Адәм баласы үз тәненә үзе хуҗа түгелмени?! Әгәр хисләргә бирелеп, онытылып китеп, җан сөйгәнең белән яшерен рәвештә генә кавышкансың икән, шәригать кануннары буенча яшәүче илләрдә моның өчен нигә үлем җәзасы бирелә?! Җәзаның да аяусызы, газаплысы, бөтен нәсел-ыру өчен хурлыклысы... Бар гавамның күз алдында таш бәреп үтерәләр...

Ни өчен ул мәмләкәтләрдә зина кылучыларга бернинди рәхим-шәфкать, кызгану юк?!

Хәзер инде Рәшидә бу сорауга җавапны белә. Бу аяусызлыкка олы бер нигез бар. Ул да булса—икәү кылган зина өченче берәүгә зур зыян сала. Ул өченче—шушы кавышудан яралачак, дөньяга киләчәк җан иясе... Бер гаепсез сабый...

Менә ни өчен каты борынгыдан килгән кануннар! Алар туачак җанны кайгырталар...

Әйе, Рәшидә моны белә хәзер.

Ләкин яшьлегендә, теге чакта, Евгений аның кулыннан кысып алып: "Әйдә, кайтабыз!"—дигән көнне ул моны белми иде шул.

Хәер, белми дип әйтү дөресме? Балачакта гаиләсе, әнкәсе иман-әхлак, әдәп кагыйдәләрен сеңдермәдемени аңа? Авылда яшьләрнең ничек гаилә корганын, туйларның ничек узганын күреп үсмәдемени ул?

Әйе, болар һәммәсе аның күңел төбенә салынган иде. Тик алар өстенә бик күп яңа катламнар өстәлде шул. Мәктәптә, китаплардан, кинолардан... Дөрес, алар да начарлыкка өйрәтмиләр иде. Кеше кешегә дус, туган илең өчен яшәргә кирәк, кебек хакыйкатьләр күп тукылды. Шул ук вакытта элеккедән калган гореф-гадәтләр, Аллага ышану—бик начар нәрсәләр, аларга каршы аяусыз көрәшергә кирәк, дигән фикер дә нык сеңдерелде. Әйе, сәвит мәктәбе, коммунистик тәрбия комганны, сөннәтне, намазны, никахны, иманны салып таптады гына түгел, яшь буыннан таптатты.

Ишеткән-укыганнарны тормыш мисаллары да раслап тора иде. Ходайга ышанып, намуслы, ипле яшәгән кешеләр, әнә, авылда, тирес арасында, таш гасыр шартларында михнәттә гомер сөрә. Дингә ышанмаучылар өскә калка, рәхәт яши. Көн саен күзгә кереп торган чынбарлык шуны раслый иде: иманны белү алга илтми, урыс телен белергә кирәк. Үзең урыс булсаң тагын да яхшырак... Зур шәһәрләрдә татар булу кимлек саналды. Күп кенә кызлар-егетләр үзләренең исемнәрен русчага көйләп үзгәрттеләр.

Туган йортыннан буыны да, рухы да ныгып җитмичә чыгып киткән үсмернең шушындый тәрбия тәэсиренә бирелүе гаҗәпмени? Бер дә гаҗәп түгел. Рәшидәне бик тә аңлап буладыр.

Ләкин аклап була микән?.. Тулай торакта аның белән бер бүлмәдә яшәгән кызларның икәве генә урыска кияүгә чыкты. Калганнар, үз тиңнәрен табып, туйлар ясап кавыштылар.

Әгәр дә теге салкын, шыксыз кичтә әнисенең сүзләрен исенә төшергән булса, нишләр иде ул?

Ничек кенә булса да, ашыкмас иде. Икенең берсен сайларга кирәклеген белеп, топтән уйланыр иде: яки син мәхәббәтеңне яклап, сөйгәнең белән кичекмичә кавышасың, яки кавышуны чигереп, озаклап, җентекләп, туачак балаларың турында уйлыйсың. Рәшидә бу хакта уйламады. Шул рәвешле үзен олы бер хокуктан—икенең берсен сайлау хокукыннан мәхрүм итте.

Әгәр моның өчен аның үзен таш бәреп үтергән булсалар, гаделрәк җәза булыр иде... Ләкин ник бер гөнаһсыз сабый җәзалана?!

Шундый үкенечле уйлар талады Рәшиданең бәгырен. Сабыеның әкренләп сукырайганын, аннары кибеп корыганын күреп торган анага, бала хәсрәте өстенә, вөҗдан газаплары да өстәлде. Шушы көннәрне күрмәс өчен, шушы хәсрәтләргә дучар ителмәс өчен, үз гомерендә булган барча шатлык-куанычларны, бәхетле минутларны бирмәс идемени ул?

Кешелекнең мең еллардан килгән үгет-нәсихәтен санга сукмаган замана баласы, башына кайгы төшкәч, томана, надан сихерче-тылсымчыларның быдырдавын мөкиббән китеп тыңлады, тырнак асларына кер каткан куллардан "гаҗәеп шифалы дарулар" алып, соңгы сумнарын сонды. Төмәнгә дә барды Рәшидә, аннан алып кайтканнарны балага эчерде, тәненә сылады, башына сөртте, урын-җиренә сипте...

"Әнә бит, ишек төпләренә күпме халык тезелеп чиратка баскан,—дип юанды.—Күбесенең кыяфәтеннән зыялы, белемле икәнлекләре күренеп тора. Бик ераклардан килүчеләр бар. Бер дә юкка йөрмиләрдер, кемнәрдер шифа алып, сихәтләнгәндер... Миннән берсе булса да терелгәндер. Ә бәлки, шул меңнән-миллионнан бер бәхетле язмыш минем балам өлешенә тияр..."

...Вакыт җәрәхәтләрне, шул исәптән күңел яраларын да дәвалый, диләр. Тик Рәшидә өчен алай булып чыкмады. Баланы җирләп, бер ел узуга, Евгенийда шеш таптылар. Дөрес, бу юлы чирне вакытында белеп алдылар, операция уңышлы узды. Дәвалаучы врач, Рәшидәгә шыпырт кына: "Тагын биш ел тыныч яши аласыз",—диде. Бервакыт шеш икенче җирдән килеп чыгачак, дигән сүз иде бу.

Һәртөрле чирнең нервыдан килгәнен исәптә тотып, Рәшидә ирен мөмкин кадәр яхшырак тәрбияләргә тырышты. Аларның өендә теге "мәхәббәт гимны" сирәк булса да, җырлана әле:

"Үтсен еллар, гасырлар... Җирдә бетмәс бер көч бар...Бар нәрсәдән бөек ул... Мәхәббәт ул, сөю ул..."

"Рашель иркэм!"—дип дәшә аңа Евгений. "Женчик-Женечка, золотое темечко!"—ди Рәшидә аның алтынсу чәчен сыйпап.

Дөресрәге, ди иде. Хәзер сыйпарга алтынсу чәчләр юк инде. Женчик-Женечка дигәндә тавыш йомшак ишетелсен өчен дә нык тырышырга туры килә...

Яман чир янадан җиде елдан соң килеп чыкты. Тагын операция ясадылар. Бусы да уңышлы узды.

—Мондый авырулар шактый озак яши,—диде врач Рәшидәгә.—Әзер торыгыз, сезгә көч күп кирәк булачак әле.

—Озак дигәнегез... күпме була инде ул?..

—Ел ярым-ике ел. Хәер, сезнең тәрбия белән озагракка сузылуы да бик мөмкин.

Алда Рәшидәне олы хәсрәт көтә. Елларга сузылган мәшәкать һәм кайгы. Ире белән бу хакта ачыктан-ачык сөйләшмиләр—йөрәк яраларын актарырга ярамый. Евгений үз хәлен чамалый, хатынына көч күп кирәк буласын белә. Шуңа күрә аны ял итәргә җибәрде дә. Ә Рәшидә аның көннәрен озайту өчен һәммәсен эшләячәк.

Ә аннары? Аннары—ялгызлык һәм бушлык. Табигать тарафыннан һәр хатын-кызга бирелгән иң зур бәхеттән—балалар үстереп, шуларга куанып яшәү бәхетеннән ул мәхрүм. Ахыр чиктә җирдә бернинди эз калдырмыйча китеп барачак. Ничек диде әле Зара? Тәнебез, җаныбыз безгә узган буыннардан килгән. Киләчәк буынга без аларны зәгыйфьлек кертмичә тапшырырга тиеш. Ә менә Рәшидә зур хата ясады, шуның аркасында нәсел чылбырының

ана тоташкан тармагы өзелде. Бу хатасы өчен бирелгән җәза Рәшидәнең бөтен гомеренә җитәчәк.

Ләкин нишлисең... Башны ташка орып булмый... Нәрсәнедер үзгәртергә соң инде.

Тик нигә соң күңел ашкына? Ни өчен язмыш аны Газизҗан белән очраштырды? Яралы йөрәккә ник ут салды?

...Бер чаткыдан авыллар, шәһәрләр, яхшы атлар белән кичеп булмаслык урманнар янып көл була, диләр. Әгәр алар корылыктан кипкән булсалар... Әгәр очкын төшкән минутта җил купса...

Ә Рәшидәнең җанына күптән, шактый еллар буе шифалы яңгырлар яуганы юк иде шул инде... Кечкенә генә очкыннан янгын чыгуы гаҗәпмени?

Аһ, моны гыйшык хәлләрен үз башыннан кичергән кешеләр генә аңлар! Күпме риваятьләрдә сөйләнгән, җырларда җырланган аның татлылыгы һәм аянычлыгы. Әйтик, шәригать кануннары хөкем сөргән илләрдә яшьләр гыйшык сөременнән исереп башны югалтырга, ата-баба йоласын ташларга ярамаганын кечкенәдән белеп үсә, зина кылуның иң зур җинаять икәнлеген, аның өчен дөньялыкта бөтен халык каршында таш бәреп үтерәчәкләрен, бакыйлыкта мәңге тәмуг утында яндырачакларын яхшы аңлый. Әмма... шуны белә торып та, нигә соң кайберәүләр моңа бара?!

Чөнки гашыйк кеше акыл белән эш итә алмый. Ә инде кеше үз акылына буйсынмаса, башкаларның киңәшенә колак салмаса, әгәр ул фәкать хисләр кушуына гына бирелсә... бу—акылдан шашу бит инде. Борынгы греклар акылдан шашуны ничек бәяләгән?! "Әгәр Аллалар адәм баласын җәзаларга теләсәләр, алар аның акылын алалар... " Иң каты җәза—акылдан язу. Хисләр шаукымына бирелеп, зиһене томаланган адәм баласының рухи бизмәне бозыла. Ул нәрсә өчен ни хак түләячәген чамалый алмый. Ул бер көнлек бәхет өчен үз-үзенә гомерлек газап, нәсел-ыруына хурлык, газиз баласына иртә үлем китерәчәген уйлый алмый.

Тик нигә соң адәм баласына, аның һәр күзәнәгендә ялкын булып урләрлек итеп, сөю сәләте бирелгән? Акылын томаларлык итеп, үз-үзен, алдагысын онытырлык итеп? Бер минут ләззәт өчен дөньялыктагы иминлеген, ахирәттәге оҗмах рәхәтен бирерлек итеп? Моның ярамаганлыгын аңлаган хәлдә, нигә шул шашкын хисне җиңәрлек ихтыяр көче табалмый үзендә адәм баласы?!

"Мин үземдә бу көчне табарга тиеш!—дип тәкърарлады Рәшидә үзүзенә.—Хискә артык бирелүем аркасында болай да бик күпне күрдем бит инде... Күп газапландым... Тыелырга кирәк... Уйламаска..."

* * *

Рәшидә бию залының почмагында, башкалардан артта басып тора иде. Караңгылык бөркелгән ишекләрнең берәрсеннән Газизҗан килеп кергәнне котте ул. Тик егет күренмәде.

Биюләр ныклап кызып китәргә дә өлгермәде, музыканы туктаттылар. Халык тарала башлады. Рәшидә моңаеп кына торак бинага таба китте. Кинәт аның янында Газизҗан пәйда булды, гүяки караңгылыктан куеланып укмашты. Алар бераз сүзсез генә янәшә бардылар. Ишеккә җитәрәк:

—Яр буеннан әйләнеп килергә теләмисезме?—дип сорады егет.

—Була ул,—диде Рәшидә шаяргандай, битараф күренергә тырышып.

Алар капкадан чыгып, бер ягына пальмалар тезелеп баскан сукмак буйлап киттеләр.

—Бүген кичәне иртә тәмамладылар,—диде егет.

—Ике көннән карнавал булачак бит, шуна әзерләнәселәре бардыр. Канада туристларының күңелен күрергә.

—Нишләп канадаларның гына? Ә без?

—Безнең акча калмады бит инде. Карнавалга барып булмас. Ә канадаларның кесәсе калын. Әмрикәннәр килмәгәч, мондагыларның бөтен өмете шуларда.

Бу сүзләр егетнең авырткан җиренә тиде бугай—ризасызлыгы, хәтта

ачуы кабарганы сулыш алуыннан ук сизелгәндәй булды. Кешедән ким булып йөрисе килми иде аның. Рәшидәгә исә, ни сәбәптәндер, аны чеметтереп алу рәхәт иде.

Комлык аша узып, океан ярына барып бастылар. Тропикларда эңгер-меңгер бөтенләй диярлек булмый. Кояш баюга, гүяки, күк гөмбәзеннән җиргә катлы-катлы кара өрфия пәрдә ишелеп төшеп, бар дөньяны урап-төреп куя. Шул пәрдәне тишкән кадаклар кебек, нурын тирә-якка чәчмичә, туп-туры төбәп, эреле-ваклы, саргылт, зәңгәрсу, яшькелт йолдызлар күзгә төртелә. Океан шуларга карап юашланып калган, кара юрган астында тып-тын ята. Яр кырындагы су гына күкселләнеп күренә, сизелер-сизелмәс шуышып, комны ялаштырып ала. Һава рәхәт җылы, тыныч. Каяндыр, ерактан оркестрның, ә бәлки магнитофоннындыр, дәртле көй уйнаганы ишетелә.

Бу тынлыкта, караңгыда, вакыт агышы туктаган мәлдә нindидер бик мөһим, зур мәгънәле сүзләр әйтелергә тиеш иде. Әмма Газизҗанның соравы гади булды:

—Сез язучымы?

—Журналист мин. Гәзиттә эшлим.

—Нинди гәзиттә?

—Яшьләр гәзитендә. Безнең һәр сан ярты миллион тарала,—диде Рәшидә ихтыярсыздан горурланып.

—Ярты миллион! Андый бүтән юктыр да.

—Бүтән юк. Без татар телендә бердәнбер яшьләр гәзите.

—Сезнең кебекләр ничәү анда?

—Бүлек мөдирләреме? Бишәү.

—Бөтен халыкка бишәү... Аңлашыла-а,—дип сузды Газизҗан.

—Нәрсә аңлашыла?

—Сез шәһәр кызы бит. Күренеп тора: затлы гаиләдә үскәнсез. Зур урыннарда таныш-белешләрегез күптер...

Рәшидә көлеп җибәрде.

—Армиядә разведчик булып хезмәт иттеңме әллә син?

—Ә нигә?

—Минем бөтен биографиямне белеп алгансың.

—Нәрсәгә разведчик? Десантник мин. Ә сезнең кемлегегез маңгаегызга язылган.

—Шәһәр кызы икәнлегемме?

Газизҗан дәшмәде.

—Әгәр беләсең килсә, шәһәрне мин мәктәпне тәмамлагач кына күрдем. Синең янында гап-гади авыл кызы басып тора.

Караңгыда ачык кына күренми иде, әмма Газизҗанның иреннәре кысылып, кашлары җыерылганын тоеп алды Рәшидә.

—Кем урнаштырды соң сезне андый эшкә?—диде егет аптырагандай.

Рәшидә тагын көлде.

—Редакциягә кешене урнаштыралар димени? Иҗат эше бит ул. Яза белгәннәрне үзләре чакырып алалар.

—Сезне дә чакырдылармы?

—Әлбәттә. Мин студент чакта ук яза идем.

—Сез—гениальный кеше!—диде кинәт Газизҗан әкрен тавыш белән, әмма бик нык итеп. Рәшидә хәтта югалып калды.

—Бернинди терәксез, ярдәмчесез шундый югары җиргә урнашкансыз,—дип дәвам итте егет.— Һәр сүзегезне ярты миллион кеше күтәреп ала...

—Укучыларыбыз миллионнан артадыр, китапханәләрдә гәзитләрне теткәләп бетерәләр.

—Миллион кеше укырлык итеп язар өчен, бик талантлы, акыллы, белемле булырга кирәк. Зур кеше сез!

Монарчы да мактаганнары бар Рәшидәне, әмма мондый ук татлысын ишеткәне юк иде. Эченә җылы дулкын бәреп кергәндәй, үсеп киткәндәй булды ул.

Газизҗан тирән итеп сулыш алды да:

—Минем хакта хикәя языгыз сез,—диде.

" Аһ, нинди бәхетле сабый икәнсең син!"—дигән уй чагылып узды Рәшидәнең башыннан.

—Ләкин мин синең хакта берни дә белмим бит. Сөйлә алайса, ничек яшәдең, кайларда йөрдең, ниләр күрдең...—диде ул, көлемсерәгәнен сиздермәскә тырышып.

Газизҗанның тавышы күңелнең иң түреннән чыккандай ихлас, бераз саңгыраурак, куе. Урыс сүзләрен ул, ялгышудан курыккандай, сагаебрак, сайлабрак әйтә. Башыннан узганнары исә бик гадәти икән: мәктәптән соң —техникум, аннары армия. Кайткач, классташына өйләнгән.

Бик тәртипле тормыш иде бу, ир кеше нәкъ шулай яшәргә тиеш тә. Һөнәр алырга, армиядә хезмәт итәргә, эшләргә, өйләнергә, балалар үстерергә. Әлбәттә, һәркем тормышында үзенә генә хас вакыйгалар, ниндидер нечкәлекләр була, әмма аларын егет әйтмәде. Шулай да, сүзләре дә, аларның мәгънәсе дә бик гади булуга карамастан, тавышында эчке бер дулкынлану сизелә һәм аны тыңлау искиткеч рәхәт иде.

Кызганычка каршы, егетнең кыйссасы, эш урыныннан алынган автобиография кебек, бик кыска булды.

—Син нәкъ тиешенчә яшисең икән бит,—диде Рәшидә сөекле энесе белән сөйләшкәндәй якын итеп.—Ходай сине бәла-казадан саклаган, жил бәреп екмаган, су агызып китмәгән. Үзең дә башкитәрлек хаталар ясамагансың. Закон бозмагансың, нәсел-ыруыңның гадәт-йолаларына каршы чыгып, тәртәгә типмәгәнсең. Ә хикәяләр, кагыйдә буларак, гадәттән тыш хәлләр турында языла. Ни дә булса гажәпләндерсә, тетрәндерсә, дулкынландырса.

Тынлык урнашты. Суның комны ялмап шуышканы гына аермачык ишетелеп торды. Әллә үпкәләде инде егет?

—Әдәби әсәр язылсын өчен, иң элек сюжет кирәк, вакыйга,—дип дәвам итте Рәшидә.—Әйтик, безнең зур язучыбыз Галимҗан Ибраһимов романнарының берсен, "Фәхрине үтереп ташладылар", дип башлый. Яки менә Гогольнең "Ревизор"ыннан беренче җөмлә: "Мин сезне, әфәнделәр, бик күңелсез хәбәр әйтергә чакырдым: безгә ревизор килә". Бу әсәрне мәктәптә өйрәтәләр, беләсеңдер.

Соңгысы ничектер наданлыкта гаепләү кебегрәк яңгырады. "Алай ук кирәкми иде, ялгыш ычкынды",—дип уйлап куйды Рәшидә. Аларның икесен дә каршылыклы хисләр биләп алган иде. Бер-берсен аңлыйлар, уйкичерешләренең уртаклыгын тоялар, шул ук вакытта тартыну, сагаю да бар. Океанда йөгерәсе дулкыннар алар күңелендә айкала иде кебек.

—Үзегез турында яздыгызмы соң?—дип сорады Газизҗан.

—Юк... Минем язмыш та бик гадәти бит. Үстем, укыдым, эшлим... Безнең редакциягә күпме кеше килеп үткәннәрен сөйли, минем башымнан узганнар бер китапка сыймаслык, диләр. Бигрәк тә өлкәннәр, шулай ди. Ә тыңлый башласаң, һәммәсендә бер үк сүз: авыр хезмәт, хокуксызлык, сугыш, ачлык, ялангачлык.

Тагын тынлык урнашты.

—Димәк, минем тормышым бер хикәя язарлык та түгел икән,—диде бераздан Газизҗан уйланып.—Шулай булгач... җирдә яшәвемдә ни мәгънә соң? Ник яшим мин?

Рәшидәнең күңеленә кинәт кенә салкын җил өреп кергәндәй булды. Ул ышыкланырга теләгәндәй, ашыгып:

—Яшәүнең мәгънәсе хикәя герое булудамыни?!—диде.

—Ә нәрсәдә?.. Хәер, хикәя генә түгел, роман герое булсаң да... Аннан ни мәгънә? Китаплар да юкка чыга. Җир йөзендә бер нәрсә дә мәңгелек түгел. Җирдә генәме әле? Әнә, йолдызлар... Миллионлаган еллар буе яналар. Йолдыз үзе сүнгәч тә яктылыгы галәм буйлап меңләгән еллар буе оча, диләр. Ләкин ахыр чыкта ул да сүрелә. Ә аннары нәрсә?! Ни була аннан соң?!

Егетнең әкрен әйтелгән сүзләре шулкадәр бәгырь түреннән актарылып чыкты, алар гүяки галәмнең салкынлыгын, аяусызлыгын, аның каршында адәм баласының чарасызлыгын сыйдырган кебек иде.

— Галәм каршында кеше нәрсә соң ул?—дип дәвам итте Газизҗан.— Миллиардлаган күк җисемнәренең берсенә ябышкан тузан бөртегеннән ни аермасы бар аның?!

Рәшидә кинәт упкын каршына килеп баскандай булды. Менә ничек... Бу егет гомернең бер чорында һәркем кичерә торган кризис—тормышның мәгънәсезлеге турында уйланулардан күңел төшенкелеге кичерә икән бит... Мондый кичерешләрне иң якын кешеләрең белән дә уртаклашу авыр. Чөнки синдә—кризис, ә кешенең гаме бөтенләй башкада...

—Мин бу хакта беренче тапкыр җиденче класста укыганда уйлана башладым,—диде Рәшидә.—Антон Чеховның “Алтынчы палата” исемле хикәясен укыгач. Шул хәтле олы кайгыга салды ул мине, гомергә онытасым юк. Менә нәрсә ди бит ул: “Ah, ник кеше үлемсез түгел икән? Нигә аңа баш мие, күрү сәләте, сөйләү куәсе, күңел нечкәлеге, гакыл? Ахыр чиктә һәммәсе дә җиргә күмелергә, туфракка әверелергә һәм, ниһаять, җир шарының кабыгы белән бергә боздай суынып, миллион еллар буена бер мәгънәсез һәм максатсыз кояш тирәли әйләнеп-тулганып йөрергә тиеш булгач, нәрсәгә алар?”

—Әйе, нәкъ шулай,—диде Газизҗан.—Бик дөрес язган.

—Боларны укыгач, минем күңелне коточкыч курку биләп алды. Мин дә үләрменме? Балчыкка әверелерменме? Аннары ни булыр?.. Мин бөтен серләремне әниемә сөйли торган идем. Бусын да сөйләргә тырышып карадым. “Адәм баласының башы житә торган түгел бу, кызым,—диде.— Ходай кушкан булыр. Тәкъдирендә ни язылса, шул килә кешегә”.

—Өлкәннәрнең сүзе кайда да бер,—диде Газизҗан.—Минем әби дә шулай. Үзен әйләндереп алып, сызык сызып куя да, шул түгәрәкнең уртасына утырып, догалар укый.

—Аятелкөрси укый,—диде Рәшидә.—Янына шайтаннар кермәсен өчен.

—Ә минемчә, түгәрәкне ул үзе өчен сызып куя, үзен шулай чикли. Сызыкның тышкы ягына карамас өчен һәм андагыларны уйламас өчен. Шулай итеп, дөнья хәлләрен, үзенең бүгенгесен, киләчәген Ходай кулына тапшыра да шуның белән җанын тынычландыра. Ә мин уйларымны алай гына чикли алмыйм. Минем еракта гыларны күрәсем килә...

—Ә еракка карау җан тынычлыгын ала... Әниемнең сүзләре ул чакта миңа юаныч бирмәде. Коточкыч бер уй зиһенемне чуалтты: ул да үләчәк, гүргә керәчәк! Моннан һичкем котыла алмый!.. Чеховның хикәясен ахырынача укып бетерә алмадым, киштәгә кыстырып куйдым. Ләкин ул күзгә чалынган саен, бәгыремне ялкын өтеп алгандай итә иде. Әйтерсең лә, күзгә күренмәс радиация чыга иде аннан...

Рәшидә, тавышы киселеп, тынып калды. Әйе, яшәүнең мәгънәсе, мәңгелек турындагы караңгы уйлар кешенең ихтыярын сындыра, кулыннан эшен төшерә... Газизҗанны бөтен йөрәге белән аңлый иде Рәшидә, аның төшенке уйларын таратасы, күңелен күтәрәсе килә иде.

—Бу—галәмнең дә, яшәешнең дә нигезен тәшкил иткән иң зур сер шул әлегә,—дип дәвам итте ул.—Бер гәзиттә атаклы академикның каравыл кычкыргандай өзгәләнеп язган мәкаләсен укыган идем. Ул да шушы сорауга җавап эзли: “Ни өчен кешелек үлем белән ризалашып яши? Бөтен көчне әҗәлгә каршы көрәшкә салырга кирәк! Бу эштә бар халыклар, илләр берләшергә тиеш...”

—Бик дөрес!—диде тавышын күтәрә төшеп Газизҗан. Зур галим белән фикер уртаклыгы аның уйларын җиңеләйтеп җибәргәндәй итте.—Шулай эшләргә кирәк тә!

—Галимнәрнең әйтүенә караганда, адәм баласы җирдә йөз илле ел яши ала,—дип дәвам итте Рәшидә.—Кешелекнең тәҗрибәсе, фән казанышлары моңа мөмкинлек бирә. Киләсе гасырда фән, бәлки, гомерне тагын да озайту чараларын табар иде... Ләкин бу булмаячак.

—Нишләп?!

—Беләсеңме, җирдә күпме генә кеше әҗәлне чигендерү өчен тырыша, ә күпмесе, киресенчә, Газраилгә хезмәт итә?

Газизҗан югалып калды бугай, дәшмәде.

—Газраилнең хезмәтчеләре күп төрле шул алар,—дип дәвам итте Рәшидә.—Кемнәрдер тамак хакына танк ясый, пуля коя. Икенчеләре кешеләрне күпләп-күпләп үтерә торган агулар, зарарлы микроблар булдыра. Өченчеләре сугышуны гомерлек һөнәре итеп сайлый. Дөньяда болай да афәтләр баштан ашкан бит югыйсә! Көннән көнендә әле анда, әле монда туфан купкан, җир тетрәгән, янгын чыккан, дип ишетеп торабыз. Миллионлаган адәм балалары чир-чордан вакытсыз китеп бара. Күпме сабыйлар һәлак була, үлә! Шуларны коткару чараларын эзләү урынына, кешеләр бер-берсен үтерүнең көннән-көн хәтәррәк ысулларын уйлап чыгаралар. Бер бомба белән зур шәһәрне юк итеп була!

—Бомбаларны да наданнар түгел, академиклар уйлап чыгара...—диде Рәшидәнең сүзен дәвам иткәндәй Газизҗан.

—Әйе шул. Галимнәрнең иң талантлылары сугыш кораллары ясый. Әгәр дә алар яман чирдән дәва табу өчен генә тырышсалар да, күпме гомерләрне озайтырлар иде!..—Рәшидәнең тавышында өзгәләнү ишетелде. Ул чайкалып китте.

—Ни булды сезгә?

Газизҗан Рәшидәгә таба атлап, терәлеп диярлек басты да, кулын тотып алды. Күзләренең яктысы, галәм карасын тишкән тропик йолдызлардай, зиһенне чорнаган томан аша үтеп керде. Нык кулы, чаманы онытып, Рәшидәнең бармакларын артык нык кыскан иде, никах балдагы уелып кереп, каты авырттырды. Тик бу әрнү ләззәтле иде, айнытып җибәрде, тәнгә хәл кертте.

Алар борылдылар да, яфракларын салындырып, каралып, оеп утырган пальмаларга таба киттеләр.

—Мин үзем өчен нәтиҗә чыгардым инде,—диде Рәшидә.

—Нинди нәтиҗә?

—Мин теге академикның чакыруына кушылам. Бар булган көчемне үлемгә каршы көрәшкә бирәм.

—Ничек итеп?—Газизҗанның тавышында гаҗәпләнү чагылды. "Үз урынында зур кеше булса да, үлем хәтле үлем белән көрәшерлек нинди көче, чарасы булсын бу кечкенә хатынның?"—дип уйлады, күрәсең.

—Язганнарымны укыган һәркемдә матур хисләр тудырырга, игелек кылу теләге уятырга тырышам. Минем укучыларымнең берсе дә Газраилгә хезмәт итмәсен иде!

—Сез идеалист икәнсез,—диде Газизҗан.

—Ләкин, минемчә, башка юл юк. Явызлык өстенлек алса, кешелек үзен үзе юкка чыгарачак... Әллә син башкача уйлыйсыңмы?

Егет моңа җавап бирмәде.

* * *

Көннәрнең берендә аларны Куба утравының икенче ягына, Плая-Хирон дигән җиргә алып киттеләр. Алтмыш беренче елны бирегә Америка ягыннан кораллы отрядлар һөҗүм иткән, өч көн дәвам иткән сугышта Куба гаскәрләре җиңүгә ирешкән икән.

Кариб диңгезе култыгының куаклы яр буйларын, камышлы сукмакларны күрсәтеп, кайда нинди бәрелешләр булганын, күпме дошман үтерелгәнен сөйләп йөрделәр. Аннары музейга алып керделәр.

Бер катлы, тәрәзәсез музей залларының стеналарына бик нык зурайтылган фоторәсемнәр ябыштырылган иде. Аларда автоматлар тоткан, берет кигән, сакаллы гайяр егетләр сурәтләнгән, иң алда, әлбәттә инде, Фидель Кастро. Озатып йөрүче мулат Рауль, урыс сүзләрен вата-сындыра, ахак тырнаклы карасу кулы белән фотоларга ишарәләп, Кастроның батырлыклары хакында сөйләде. Ничек итеп ул кечкенә генә отряды белән хөкүмәт гаскәрләренә һөҗүм иткән. Җиңелгәч, кулга алынгач та бирешмәгән. Хәрби трибунал каршына баскач, диктатор Батистаны, аның хөкүмәтен гаепләп: "Тарих мине аклаячак",—дип ялкынлы чыгыш ясаган. Бөтен халыкның

аны яклавы нәтиҗәсендә, төрмәдән азат ителгән, көрәшен дәвам иткән, ахыр чиктә җингән, дәүләт җитәкчесе булган. Хәзергә тикле Америка хәтле Америкага каршы тора...

Музей үзбәкләрдә әлләни кызыксыну уятмады, алар тизрәк чыгу ягын карадылар. Зара да алардан калмады, ишегалдындагы агач күләгәсенә басып, салам эшләпәсе белән җилпенергә тотынды.

Рәшидә музейга кире керде. Газизҗан анда, озын киштәләргә, өстәлләргә тезеп куелган сугыш кораллары янында басып тора иде.

—Болар СССР дан китерелгән кораллардыр инде,—диде Рәшидә.

—Менә болары безнеке, болары Американыкы,—диде Газизҗан салмак хәрәкәт белән кулын киң җәеп.—Трофейга алынганнар.

Рәшидә аларның кайсы револьвер, кайсы пистолет, кайсы автомат, кайсы пулемет икәнен дә аермый. Томаналыгыннан түгел, бу нәрсәләр анын күнелендә һәрчак чиркану, курку, шом тудыра, шуңа күрә беләсе дә килми.

Газизҗан исә, киресенчә, үсеп, ныгып киткәндәй иде.

—Менә бусы—кул гранатометы, аны менә болай итеп инбашыңа куясың да, менә шушылай атасың...—дип аңлатырга кереште ул. Рәшидә исә өстәлдә сузылып яткан озын, юан тимер көпшәгә коты очып карады. Я хода, Газраил бу тимердән ничә тапкыр очып чыгып, күпме кешенең җанын алды икән? Әллә хәзер дә шунда посып ятамы?

—Бу соң эшкә ярыймы?—дип сорады ул.

—Нигә ярамасын? Берни булмаган ич аңа. Карарга, тазартырга да заряжать итәргә була.

Әнә ничек ансат икән. Тазартырга да заряжать итәргә. Аннары инбашына куясын да, Газраилны очырып җибәрәсен...

Күп музейларда булды Рәшидә, кеше үтерү өчен ясалган җайланмаларның төрләрен күрде. Аларга караган саен, күнелендә ризасызлык кабынды. Кешелекнең талантлы, зирәк, унган уллары корал ясаудан ничек тәм таба икән? Әйе, ләззәт алалар, чөнки бик нәфис сырлар уелган, алтын-көмеш, асылташлар белән бизәлгән кылычлар, мылтыклар зур музейларның мактанычы санала. Җаннарны сафландырырга, чистартырга, игелек тәрбияләргә тиешле музейларның!

Әлбәттә, Рәшидә тарихның канлы икәнен дә, илне саклау тиешлеген дә белә. Әмма кеше үтерү чараларының матурлыгын күрә белми, аңлый алмый.

Көндез чыра яндырып дигәндәй, электр лампочкалары белән генә яктыртылган, җанны изә торган заллардан чыккач, зур тәрәзәле, якты бүлмәдә аларга үз фикерләрен журналга язарга тәкъдим иттеләр. Газизҗан өстәл янына утырды да зур, калын кенәгәне үзенә таба тартты. Аннары борылып, астан өскә Рәшидәнең йөзенә текәлеп карады. Аның күзләрендә ризасызлык чагылды. Ләкин нигә? Мондый журналларга гадәттә хуплау-мактау сүзләрен бөтен төркем исеменнән язалар һәм бу эшне, кагыйдә буларак, каләмле кеше, әйтик Рәшидә кебек журналист башкара. Чөнки кыска булса да оста итеп язарга кирәк. Башкалар ахырдан имзасын гына сала.

Ләкин нишләп соң әле бу эшкә Газизҗан үзе теләп алынды? Юлдашлары белән киңәшеп тормады, кул куярга да чакырмады. Ул гына да түгел, Рәшидәгә дә "кит" дигән сыман бик салкын карап тора.

Әһә, хикмәт менә нәрсәдә: егет Фидель Кастрога гашыйк, йөрәге түреннән өзеп, аны олылау, соклану сүзләрен язарга җыенган. Һәм моны берәүгә дә күрсәтәсе килми. Сөйгәненә хат язучы мәгъшукмыни!

Рәшидә аңа комачауламаска кирәген аңлады. Ишегалдына чыгып, алсу чәчкәләргә төренгән куакларга карагач, тирән итеп сулыш алды. Әйе, матурлык белән дәһшәт һәрчак янәшә шул!

Бераздан анын янына Газизҗан чыгып басты.

—Кастроның үзе белән очрашырбыз, дип уйлаган идем мин,—диде.—Кубага килүемнең төп максаты да шул иде.

Рәшидә аптырап китте.

—Аны бер күрер өчен океан кичтем, дисең инде алайса. Тәмам мөкиббән икәнсең!

—Мин генә түгел. Аны миллионнар ярата,—диде Газизҗан.

—Миллионнардан сорап булмый, син менә нәрсә өчен яратасың?

—Егерме биш яшендә халыкны диктаторга каршы коралль көрәшкә күтәргән кем бар тагын? Көрәшкән, җиңгән һәм хәзер дә илнең башында тора. Ул бердәнбер!

Сүз шунда өзелде, автобуска утырырга чакырдылар.

Кайтыр юлда диңгез ярындагы бик матур урында, гөлбакча уртасындагы җыйнак бинада төшке ашка тукталылар. Биредә Канададан килгән туристлар ял итә икән. Яр буенда ак көймәләр, комлыкта ипле ятаклар... Бина янында зәп-зәңгәр сулы мәрмәр бассейн, аңа торбадан шарлавык булып су коя... Тирәсендә иркен кәнәфиләр, шунда ук эчемлек-кабымлык тезелгән өстәл. Урыс туристлары яши торган җирдә боларның берсе дә юк, билгеле. Рәшидәне иң шаккатырганы—бакча уртасындагы мәйданчыкта уйнап утырган биш-алты кешелек оркестр булды. Тыңлаучы гына түгел, күз салган кеше дә юк. Ләкин мулатлар туктамый уйнавын дәвам итә, чөнки... бай туристлардан, мөгаен, акчасы алдан алып куелган.

Ах, доллар-доллар! Адәм баласын ниләр генә эшләтмисең син!

Кайткан уңайда тагын да бер тукталыш ясап алдылар. Сөзәк калкулыкның чирәм баскан күкрәгендә рәт-рәт итеп ак мәрмәр ташлар бастырып куелган. Һәркайсына бертөсле итеп сары язу уелган. Урыс хәрефләре белән. Исем-фамилия һәм туган-үлгән вакыты.

Алтмыш беренче елны һәлак булган совет солдатларының каберлеге булып чыкты бу. Югыйсә, экскурсиядә дә, музейда да совет солдатларын телгә алмаганнар иде. Хәер, анысы аңлашыла: аларның сугышта катнашуын әмрикәннәр бик яхшы белсә дә, СССРның үз халкыннан сер итеп саклана. Хәлбуки, Кастроны яклап кан күп коелган—зират шактый зур, калкулык итәгеннән караганда, аргы чиге күренми...

Рәшидә, татар фамилияләре юкмы икән дип, рәт араларыннан китте. Кайткач, газиткә язарга кирәк булыр. Хәтәр бар җирдә татарсыз булмый—монда да берничәү табылды. Унсигез дә унтугыз яшьлекләр.

Автобуста алар янәшә утырганнар иде. Кузгалып киткәч, Рәшидә тирән итеп көрсенде дә:

—Нинди кызганыч!—диде.

—Нәрсәне әйтәсез?

—Биредә яткан солдатларны әйтәм. Туган илләренә дә кайтармаганнар ичмасам, монда гына күмеп куйганнар.

—Мәетләрне самолет белән ташу артык кыйммәткә төшә.

—Аның бәясен кем билгели соң? Ата-аналарыннан сорап карарга иде!

—При чем ата-ана? Солдат—хөкүмәт кешесе!

Бу шундый катгый әйтелде, Рәшидә хәтта югалып калды.

—Шулаймыни-и?—диде.—Ә мин тагын хөкүмәт беренче чиратта халыкны якларга, үз иленең һәр кешесен кайгыртырга тиеш, дип уйлый идем. Ә солдатлар үз илен сакларга тиеш, дип.

Тагын тынып тордылар.

—Син аларның кайсы елгылар икәненә игътибар иттеңме?—дип сорады Рәшидә мөмкин кадәр йомшак итеп.

—Ә нәрсәгә?

—Кырык икенче, кырык өченче елгылар ята монда. Ул чорда балалар бик аз туган, чөнки әтиләр сугышта булган. Тол калган әниләр улларын җир тырмашып үстергәннәр. Бөтен ил өчен, халык өчен бәһасез егетләр алар, беләсең килсә! Менә шуларны, буй җитүгә, монда китереп, ут эченә тыкканнар. Теге, музейда яткан кара тимер көпшәләрдән аттырып үтертер өчен... Бер карчыкның шәһәр уртасындагы бетон һәйкәлне кочаклап елаганын күргән идем мин. Гомер онытасым юк. Һәйкәл ватан сугышында һәлак булганнарга куелган, аңа йөзләрчә исем язылган. Күрәсең, шуларның берсе—аның улыдыр. Утыз ел узган, ә карчыкның хәсрәте кимемәгән, ачыргаланып елый да елый. Күз яшьләрен газиз улының каберенә түгәргә дә мөмкинлеге юк мескеннең... Биредә яткан солдатларның аналары нинди

ташларны кочаклап яшь түгә икән? Ни хакына түгелгән кан бу? Ни өчен түгелә аналарның яше? Бу утрауга Кастро хуҗа булсын дипме?

—Америка хуҗа булмасын өчен,—диде Газизҗан бераз гына уйланып торгач.

—Кариб кризисы турында ишеткәнең бармы? Алтмыш икенче елда безнекеләр Кубага атом бомбалары китереп куйдылар. Шуның аркасында Америка белән сугыш башлана язды. Соңгы сәгатьтә акылларына килеп, ракеталарны кире алып китмәгән булсалар, без бүген биредә йөрмәс идек, Кубада гына түгел, үз җиребездә дә тереклек бөтенләй калмаган булыр иде, мөгаен... Минем өчен Кастро—Газраил хезмәтчесе ул!—дип кинәт ачу белән тәмамлады Рәшидә.— Нихәтле көчле, талантлы булса, шулхәтле куркынычрак! Безнең халык аңа күп корбаннар китерде инде. Аның аркасында үз илебездәдә күпме кеше вакытсыз үлгәндер, беркем санамаган!

—Ничек безнен илдә?

—Безнең күпме көч, күпме байлык китә монда? Шуларны үз халкыбызга бирсәләр!.. Күпме хасталарны дәвалап, күпме кешенең гомерен озайтып булыр иде! Мондагы халык безне барыбер кешегә санамый. Әнә, канадалар өчен тырыша, шул ук әмрикәннәрнең килгәнен көтә!

Газизҗан өчен нәкъ менә соңгысы үтемле булды. Ул иреннәрен кысып, башын тәрәзәгә борды. Бу илдә үзенә кимсетеп карауны һич кенә дә кабул итә алмый иде егет. Кастроның үзе белән күрешеп сөйләшергә өметләнгән, ә биредә аны карнавалга да чакырмыйлар!

Анысы шулай шулаен. Ләкин ир кеше бит әле ул! Хатын-кыз сүзенә карап, монарчы бөек дип санаган Фидельгә аркасы белән борылсынмы?

Ир-ат гадәттә хатын-кызның өстенлеген кичерми һәм гафу итми. Рәшидәнең нотыгын яратмаганы Газизҗанның бөтен кыяфәтенә чыккан иде. "Синең белән сүз көрәштереп, вакланып торасым да килми!"—ди иде аның салкын карашы.

Алай да ул үзен тәрбияле тотарга тиеш тапты. Автобус капкадан кереп туктагач, алдан сикереп төште дә, ярдәм тәкъдим итеп, Рәшидәгә кулын сузды.

* * *

...Социалистик илләрдән килгән туристларны дөньяның иң матур курортларыннан берсе булган Варадерода бер атнадан артык тотмадылар. Утрауның икенче очына, Кариб диңгезе буена озатачакларын әйттеләр.

Йокы бүлмәсеннән чемоданын күтәреп чыккач, Рәшидә баудан ишелгән атлы рыцарь сынына карап, көрсенеп куйды. "Моның янында карточкага төшми калынды инде",—дип уйлады.

Китүчеләр ашханәнең болдырына чыгып басканнар, чемодан-сумкаларын бер урынга тезеп куйганнар. Газизҗан читтәрәк тора, ул гадәттәгечә зәңгәр спорт костюмын кигән, уйчан кыяфәттә. Аяклар ничектер үзеннән-үзе аңа таба атлады. Чемоданны куярга җайлы урын аның янында, имеш.

—Хәерле иртә.

—Хәерле иртә,—диде Рәшидә.—Кәефләр ничек соң? Ямансу түгелме?

—Ә нәрсәгә? Илне күбрәк күрербез.

—Ә миңа ямансу. Чөнки минем бер теләгем үтәлми кала.

Рәшидәнең егет белән мөнәсәбәтләрне җайлыйсы килә иде.

—Ничек алай?—диде Газизҗан салкын гына.

—Шулай. Үзем генә булдыра алмыйм. Менә син ярдәм итсәң...—Бу сүзләрне әйткәндә, Рәшидә шаярып елмайды.

—Автобус килгәнче өлгерсәк...—диде егет икеләнеп.

—Безне калдырып китмәс әле.

—Ярый,—диде егет бик җитди кыяфәт белән.—Әйдәгез, үтик теләгегезне.

Һәм гадәттәгечә сыгылмалы, иплe адымнар белән торак бинага таба атлады. Рәшидәнең иң яшерен теләген белә иде ул, бик белә иде. Шуңа күрә һич икеләнмичә бара иде.

Ләкин арттарак калган Рәшидә, баудан үргән Дон Кихот янында туктады да:

—Монда, монда!—диде. Һәм сумкасыннан фотоаппаратын алды.— Шушының янында фотога төшәсем килә.

Рәшидә аны, шаркылдап көлеп җибәрер, дип көткән иде. Ләкин Газизҗан башын игән килеш фотоаппаратны алды да көйли башлады. Дәшмәде, шаяруны кабул итмәде. Баласыту дип аңлады, ошатмады.

...Аларны "Ту-114" очкычына утыртып, илнең көнчыгышындагы Сантьяго-де-Куба шәһәренә, аннан "ЛАЗ" автобусы белән Кариб диңгезе буена алып киттеләр.

Бирелә, Дайкири дигән җирдә, социалистик илләрдән килгән туристларның хәерче акчасына арзанлы ял итү урыны булдырганнар икән.

Асфальт юлның бер ягында, диңгез яры буйлап, беркатлы такта бараклар тезелеп тора. Юлның икенче ягында—куак үскән үр. Бу сәер урам шактый озын булып, аның бире башында ашханә, икенче очында—коену урыны икән. Аңа шактый барасы һәм үрдән аска төшәсе. Бирелә, ике тау арасындагы киң генә аралыкта, су төбе керпе-кабырчыклардан махсус тазартылган, шунда гына коеныгыз, дип баруга кисәтеп куйдылар.

Тору урыны комлык янында булган Варадеродан соң бу шактый уңайсыз булып тоелды. Шуның аркасында беренче көнне үк күңелсезлек булып алды: берничә егет, барак янындагы ташлы ярдан диңгезгә төшеп, су кермәкче булганнар. Берсенең табанына су керпесе кадалган. Ә аның энәләре орынган саен сынып тора, тартып алып та булмый икән. Ахыргача аксап йөрде бичаракай. Шуннан соң тәртипкә керделәр, комлыкка йөри башладылар.

Яр буенда халык шактый, Украинадан, Чехословакиядән килгәннәр. Арада хатын-кызлар да җитәрлек, танышып алдылар, сөйләшәләр, җырлашалар. Тик үзбәкләр генә, иртәнге якта килеп, яр эргәсендә бераз пычтырдап алалар да кире китеп баралар. Рәшидә гадәтенчә йөзгечләрен киеп ала да икешәр сәгать судан чыкмый. Йөзгән көйгә кычкырып җырлап җибәрә. "Авыл" көен дә, "Шахта"ны да.

Кичке якта, кояш Америка ягына таба батып барган чакта, су буенда хатын-кызлар гына кала. Форсаттан файдаланып, ялангач коеналар. Аннары судан чыккач, яр буен яңгыратып, җырлап кайталар. Украин хатыннары җор күңелле, ачык, җырга оста. Берничә тавышка сузалар. Рәшидә сүзләрне үз җаена, татарчага авыштырып җырлый:

Оча казлар, китә казлар ераккарга,
А-ай, җан сөйгәнем, бәгырькәем, син кайларда?
Китте ярым, китте парым Бохарага,
А-ай, авыр икән, читтә булгач сөйгән ярлар.
Иртәсен дә, кичләрен дә көтәм һаман,
А-ай, өзелә үзәк, яна йөрәк, яшем тама...

Зураеп, кызарып баеп барган кояш нурларында алтынланып ялтырап яткан су буеннан, юеш комлыкка яланаяк басып, бергәләп җырлап кайтканда рәхәт аныһы.

Кичләрен читен. Монда биюләр оештыру юк. Бик иртә йокыга ятарга туры килә. Бүлмәдә һава тынчу, ят исле. Әле дивардан, әле түшәмнән шыбырдау ишетелә. Озын койрыклы, бүлтәйгән корсаклы вак кәлтәгә охшаган җанварлар—игуаналар шулай чабыша. Зарарсыз диделәр үзләрен, көндез, кояш яктысында аларны кызыксынып күзәтәсең генә. Ә менә төнлә аларның шыбырдашуы шомландыра, күзләр зур булып ачыла, йокы кача. Хәер, игуаналар сылтау гына, йөрәгә тынгы бирми Рәшидәгә.

Менә өч көн узды инде, аның Газизҗан белән икәүдән-икәү калып, иркенләп сөйләшә алганы юк.

Нигә читләшә ул? Кастро турында әйткән сүзләрен гафу итмиме? Әллә теге "Куба" сурәте янында шаяртканы өчен үпкәләгәнме? Серкәсе су күтәрмәгәне сизелгән иде бит инде, уйлап сөйләшергә кирәк иде. Их, белсән иде, нинди уйлар кайный икән егетнең күңелендә!

Нишләргә? Нишләргә?

"Тыелырга кирәк! Сер бирмәскә! Эчтәгене тышка чыгармаска!"—дип кат-кат ант итә, үз-үзенә әмер бирә Рәшидә.

Ярый әле, монда да анда-санда экскурсияләргә алып баралар икән.

...Менә Рәшидә кояшка күмелгән яшел чирәмдә, ун-унбиш адым ераклыктагы пальмага карап тора. Агачка яланбашлы егет менеп бара. Зәңгәр костюмының җиңнәрен дә, балакларын да сызганып куйган, кроссовкаларын салган. Күксел киезгә төрелгәндәй кытыршы кәүсәне сыгылмалы беләкләре, нык аяклары белән кысып кочаклаган, талпынып-талпынып, житез хәрәкәтләр белән өскә үрмәли. Газизҗан бу. Кокос пальмасының чикләвеген алырга менә. Әнә, тастымал яфраклар турына ук менеп житте, алар төбендә эленеп торган йомры кабак хәтле чикләвеккә үрелде, бәреп төшерде. Аннары тагын берне...

Иртәнге якта алар крокодил фермасына килгәннәр иде. Зур, иркен читлекләр эчендәге имәнеч, чирканыч җанварларга озак-озак карап тордылар. Бер дә куркыныч кебек түгел үзләре, черек агач кәүсәләремени, өнсезтынсыз яталар. Алай да рәшәткә аша кул сузарга яисә башкача борчырга ярамый икән. Рауль әле күптән түгел генә булган вакыйганы сөйләп алды: бер турист, тере түгелдер бу хәшәрәт, катыргыдан укмаштырып куйган карачкы гынадыр, дип шикләнгән һәм тикшереп карарга ниятләгән: озын баулы фотоаппаратын читлекнең өстеннән болгап, крокодил сыртына тондырган. Шул минутта фотоаппаратыннан колак каккан—теге хәшәрәт аны һап итеп йотып та куйган. Ярый әле ахмак турист фотоаппаратының бавын кулыннан ычкындырып өлгергән, юкса бау белән тартылып, үзе дә крокодилның авызына убылыр иде.

Аның урынына бу җанварларның балалары бик елгыр икән. Камышлы суда күз иярмәс тизлек белән бөтереләләр, бер-берсенә ташланалар. “Менә, Евгенийның тагын бер сүзе расланды,—дип уйлады Рәшидә.—Крокодилларны да күрдем. Өч фаразның берсен үтәп булмый, икенчесе үтәлде. Тагын берсе бар бит әле...”

Төшке ашны шул ук фермада, чыбыктан кораштырган алачыкта көйләгәннәр иде. Алачык янында пальмалар үсә, аларда вак кабак зурлыгындагы чикләвекләр салынып тора. Түзмәде егет, менеп китте... Төшкәч, чикләвекләрне чирәмнән алды да, туп-туры Рәшидә янына килде һәм бер сүз дә әйтмичә берсен аңа сузды.

Дайкирига килгәннән бирле аның сүз кушканы да юк иде әле. Рәшидә кызарынып чыкты.

Алар ашханәгә барып кергәндә, башкалар бер-берсенә терәп куелган өстәлләр янына тезелеп утырганнар иде инде. Зара Рәшидәгә урын алып калган икән, үз янына чакырды, Газизҗан аргы башка китте.

Ризык гадәттәгедән мул, төйгән бәрәңге янындагы карасу сум ит калҗасы алагаем зур иде. Хәер, Рәшидәгә ни булса да барыбер , ашады—тәмен тоймады. Соңыннан гына Зараның кул тимәгән тәлинкәсенә сәерсенеп күз салып алды алуын, тик моның хикмәтен аңламады.

Автобуста кире кайтканда Зара көлеп сорап куйды:

—Крокодил итеннән фотоаппарат тәме килмәдеме?

Рәшидә сискәнеп китте:

—Ничек, крокодил ите идемени ул?

—Рауль әйтеп куйды бит.

—Мин ишетми калдым...—диде Рәшидә.—Сонарып кердем бит.

“ Ник аны миңа әйтмәдең?”—дип тә сорамакчы иде дә, тыелды. Болай да аңлашыла: кәмит ясамакчы булган аннан Зара! Укшыр, косар, дип уйлагандыр. Рәхәтләнеп көләрмен, дип өметләнгәндер. Әнә, каршы рәттәге утыргычта Абдрахман да бу тарафка борылган, авызы ерык, күзләре кысык. Рәшидәнең хәшәрәт ите ашаганын күзәтүчеләр тагын булгандыр...

Ләкин юкка кәмит көтәләр... Аны фәкать берәүнең генә фикере борчый... Рәшидә башын каерып, артта утырган Газизҗанга күз салды. Егет тәрәзәгә караган да үз уйларына чумган. Көлгәне сизелми...

Туристлар монда да вакыт уздыруның җаен алганнар иде инде. Караңгы төшкәч, болдырдагы утны кабызып, кечкенә өстәлдә кәрт сугалар.

Абдрахман думбрасын алып килгән, шуны чиртә, алар ягыннан вакыт-вакыт "Ялла-ялла, ялла-ялла",—дип җырлаганнары ишетелә.

Зара ир-егетләрне кайгырта—чәй кайнатып бирә. Электрның көчәнеше 127 вольт икән, урыс кайнаткычлары исә 220 вольтлы. Ярты литрлы банкага берьюлы ике кайнаткыч тыгып куйсаң да, озак көтәргә туры килә.

—Быкырдап кайнап чыкканын көтмәсәң дә була, күбекләнсә житкән,—диде Рәшидә.—Житмеш градуста микроблар үлеп бетә. Затлы шәрабларны да шуңа кадәр генә җылыталар да бөкеләп куялар. Гасырлар буе саклыйлар, берни булмый.

Һәм өстенә вак күбекләр чыга башлаган суга учлап Заранын яшел чәен салды.

Чәйне алырга ирләр иң яшь кеше буларак Газизҗанны җибәргәннәр иде.

—Сез һаман бүлмәдә дә болдырда,—диде аңа Рәшидә.—Ничек туймыйсыз?

—Ә нишлик соң?

—Әнә, тауга менәр идегез ичмасам. Заманында, партизан чагында, Фидель Кастро качып яткан таулар бит ул. Землянкасы да, бәлки, шушында гынадыр әле.

Кастро дигәнне ишетүгә, егетнең йөзе үзгәреп китте..

—Әйдәгез, иртәнге якта тауга экскурсия ясыйбыз,—диде Рәшидә.—Иптәшләренә әйт анда.

Иртәгесен Зара, Рәшидәнең күксел чалбар белән ак кофта киеп, кроссовка бауларын ныклап бәйләгәнен күзәтеп торды да:

—Курыкмыйсынмы?—дип сорады.

—Нәрсәдән куркыйм? Крокодил ашаган кеше лә мин.

—Тагын кемнәр менә?

—Газизҗан барам диде. Бәлки, тагын берәрсе иярер.

—Иярер, дисенме?

Заранын ирен читендәге җыерчыкларыннан астыртын көлемсерәү чагылып узды. Бик яхшы белә ул: мондый эсседә үз теләге белән үргә үрмәли торган ахмак үзбәк дөньяга тумаган әле. Аннары соң икәү янына өченче булып кем тагылсын? Бер ир белән бер хатынның куаклы тауга ник менгәнен белмиләрме әллә?..

Әйе, Зара өчен моның җавабы көн кебек ачык иде..

Рәшидә аның ни уйлаганын аңлады, әмма ниятеннән кире кайтмады. Жирнен аръягына чыгып, урманын күрми каламы соң! Ә инде икәүдән-икәү генә булуга килсән, андый хәлләр журналист өчен бик табигый. Чөнки аның хезмәте табиб хезмәтенә охшаш. Аерма шунда: табиб үзенә килгән кешенең киемен чишендереп, тәнен ялангачландырып карый. Ә журналистның эше—адәм баласының җанын чишендереп, күнел түрен ачып карау. Ә мондый эшләр гавам алдында эшләнми, күлмәгенне салу өчен дә, күнеленне ачу өчен дә икәүдән-икәү генә булу кирәк. Рәшидәнең бик күп тапкырлар ирләр белән аулакта күзгә-күз калганы бар: өйләрдә, фатирларда, кунакханә бүлмәләрендә, капка төпләрендә, урман эчләрендә, куышларда... Моны читтән карап торган кеше ни әйтер иде, ләкин беркайчан да андый очрашулар вакытында, бозык кешеләр күз алдына китергәнчә, кем беләндер артык якынаеп китү булмады, мөнәсәбәтләр бер-беренне ихтирам итүдән узмады.

Шуна күрә бу юлы да ул Заранын кинаясен сүзсез генә үткәреп җибәрде.

...Асфальт читеннән тауга бормалы агач баскыч алып менә икән. Илле метрлап күтәрелгәч, ул култыксалы мәйданчык белән тәмамланды. Анда басып, ялтырап яткан диңгезгә карап, беркатлы биналарнын яссы түбәләрен күреп була иде.

Алар бераз тын алдылар да, өч тарафка бормаланып куаклар арасына кереп киткән сукмакларның берсеннән өскә атладылар.

Зәңгәр спорт костюмы, ипле кроссовкалар кигән Газизҗан, тау кәҗәсе кебек елгыр һәм житез иде.

Өскәрәк менгән саен, куаклар тәбәнәгрәк, чәнечкелерәк, сукмаклар ташлырак була барды. Сулыш алу авырайды. Урыны-урыны белән тау бите шундый текә, дүрт аяклап үрмәләргә туры килә иде.

Шунысы гаҗәпләндерде: куаклар арасында җәнлек-мазар, кош-корт, хәтта бөҗәкләр дә очрамады. Астан караганда бик матур күренгән, яшеллеккә төренеп, үзенә чакыргандай ымсындырып торган бу таулар асылда шыксыз, кырыс булып чыкты. Монда партизаннар кая поса алдылар икән дә ничек яшәделәр икән? Бичара Кастро! Әйтәм аны, бөтен халкы хәерчелеккә калган... Оҗмахка тиң дип саналган, кышны-карны белми торган мәңге җылы бу илнең табигате ярлы, туфрагы игелексез икән лә! Безнең чыршынарат урманнары, каенлыклар белән чагыштырырлык та түгел!

Хәер, бу хакта уйларга вакыт юк, Рәшидәгә җәлт-җәлт атлаган юлдашы артыннан калышмаска кирәк иде. Ул, сулышына кабып, йөрәгенең дөпелдәвен тыярга тырышып, куллары белән чәнечкеле ботакларга ябышып, өскә үрмәләвендә булды.

Ниһаять, тауның аргы ягы күренде. Анда авыл, кишәрлекләргә бүлгәләнгән басулар икән.

Тау түбәсенең читендә кечкенә өстәл кебек яссы таш булып, аның кырыйларында кәкре-бөкре кәүсәле, исемнәре Рәшидәгә билгесез агачлар тырпаеп тора. Әле генә бөркү иде, эссе мунчадагы кебек тыгыз һава сулышка каба, тын юлларыннан авырлык белән генә үтә иде. Бирегә менеп, сынын турайтуга исә Рәшидә егыла язды—монда көчле җил икән. Агачларның тырпаешкан кыска ботакларында вак яфраклар сибелеп бәргәләнә.

Газизҗан яссы ташка басып, күкрәген җилгә каршы куйган, зәңгәр костюмы аның тыгыз тәненә сыланган. Бөтен торышында кинәнү, омтылу, талпыну сизелә. Кыядагы бөркетләр, канат җәяр алдыннан, шулай алга тартылалардыр. Ә алда, ике адымда—бушлык. Тау биниһая зур балта белән чапкандай киселгән, аста уйсулык, агачлык, унда, диңгез ярында туристлар коена торган иркен комлык. Кинәт астан:

—Сике-ер!—дигән тавыш яңгырады.

Комлыкта кызынып яткан украин туристлары тау башындагыларны күреп алганнар. Берсе үчекләп кычкыра.

Газизҗан кулларын баш очына күтәреп болгады, тагын бер адым алга атларга омтылыш ясады. Шунда Рәшидәнең бөтен тәне тартышып килде. Чөнки белә бит: диңгез ягыннан бу тау текә кыя булып күренә—аның асты киселеп эчкә уелып кергән. Ялгыш атлап куйсаң, бу ташның кыр-кырыена ябышкан кәрлә агачлар белән бергә, аска убылуын көт тә тор. Җил ныграк бәреп куйса, атларга да кирәк булмас...

Рәшидәнең күз аллары томаланды, тезләре йомшап сыгылды. Курккалардан түгел югыйсә. Турист походларында, аркасына биштәр асып, Каф тауларын кичкәне бар. "СССР туристы" дигән значогы бер генә түгел, ике. Парашют белән дә сикерде.

Ләкин кыя читендә, җил иркендәге таштa газиз кешеңнең басып торганын күрү, аның очарга җыенган бөркет кебек, бөтен тәне тартылып алга омтылганын тою—бөтенләй башка икән...

Менә-менә Газизҗан чайкалып китәр йә, чыннан да, алга атлар, аны туктатып та, тотып калып та булмас. Орынсаң, ябышсаң, тайпылып куюы бар... Очам дигән кошны тотып калырга маташсаң, ни була... Рәшидә хәтта дәшәргә дә курыкты, тавыш дулкыны кылдай тартылган гәүдәне этеп җибәрер кебек иде. Ә астан кычкыралар:

—Сикер-р!

Ә егет кычкыручыны үчекли кебек, ташның кырыена ук басмакчы... Йа алла, тауларда саксызлык аркасында күпме турист-альпинистлар һәлак була бит! Әле күптән түгел генә гәзиттә яздылар: бик тәҗрибәле альпинист, сөзәк тауда болай гына ял итеп йөргәндә, упкынга егылып һәлак булган. Аяк астындагы зур таш убылган...

Рәшидә егетне күз карашы белән, бөтен күңеле белән тартып алырдай булды. Чигенсен генә иде... Бер-ике генә адымга...

Газизҗан аңа күз салганчы күпме вакыт узгандыр, Рәшидә ничек һушыннан язмый калгандыр. Ниһаять борылып карагач, егетнең йөзе үзгәреп китте:

—Ни булды? Башыгыз әйләнәме әллә?

—Ә нәрсә? Берни юк!—диде Рәшидә елмаерга тырышып.—Эссе бит... Аннары җил...

Һәм башын иеп, кыекчасын рәтләп бәйләгәндәй итте. Бармаклары бит очына тигән иде, пешеп киткәндәй булдылар.

...Аска төшкәндә, Газизҗан шулай ук бик җитез атлады. Рәшидә аның артыннан калышмаска бөтен көченә тырышты. Әйе, тау—диңгез түгел, монда егет хуҗа, көчле, гайрәтле иде.

Агач баскычтан төшкәч, икесе ике якка киттеләр—Газизҗан туп-туры баракка таба борылды.

—Коенырга бармыйсыңмыни?—дип аптырап сорады Рәшидә.

—Юк, душта юынып алам да ял итәм әле.

—Су керергә яратмыйсың, ахры, син.

—Мин үзебезнең күлләрне яратам.

—Күлне диңгез белән чагыштырып буламыни?

—Булмый. Бездәге Шаһимәрдән күлләре мондагыдан мең мәртәбә яхшырак. Берсе салкын, икенчесе кайнар, теләгәнеңә чумасың...

Һәм ул җитез атлап китеп барды. Рәшидә диңгезгә юнәлде.

—Ни булды сиңа?—диде аның чөгендердәй кызарган битенә карап Зара.

—Өскә үк мендек...

—Ай-яй чаптырган сине бу маңка! Ат булсаң янып үләр идең!

Рәшидә тизрәк суга керергә ашыкты.

* * *

...Иртәнге аштан соң Зара:

—Бүген дельфиннар карарга барабыз,—диде.—Автобусның кечкенәсен биргәннәр. Уникешәр кеше генә сыя. Икегә бүленергә туры килә. Без иртәнге якта барырга булдык.

"Без" дигәне үзбәкләр иде.

—Газизҗан дамы?—дип сорады Рәшидә.

—Ул да безнеке бит.

—Алайса мин төштән соңга калам.

—Аннан качмакчы буласыңмы? Ну-ну!

Әйе, Газизҗаннан ераграк йөрергә кирәк Рәшидәгә. Алдагы көнне тауга менгәненә дә үкенә иде ул. Нинди хәлдә калды бит. Җебеп төште, егет артыннан өстерәлеп йөрде. Моннан ары үзен андый хәлгә куймас!

Шулай уйлады да, коенырга төште. Әмма бу юлы йөзүенең рәхәтен тапмады. Кире кайтты. Бараклар янында ак чәчле арык негр иелеп, җайсыз итеп, чирәм кыркып азаплана иде. Рәшидә аның кулындагы урак кебек кәкре, балтадай авыр сәер коралга гаҗәпләнеп карады. "Мачете бит бу! Шикәр камышын чаба торган пычак-балта!" Ишарәләр белән абзыйдан сорап алып, сирәк-мирәк тырпаеп торган нечкә үлән сабакларына селтәнде. Урмый да, кисми дә, каты үләнгә теше үтми икән мачетеның. Йа хода! Мондый да мәгънәсез эш белән шөгыльләнүчеләр да булыр икән!

Кара чыраенда аерата ак күренгән тешләрен балкытып елмаеп торган абзыйга бәләкәй генә кучтәнәч бирергә кирәк иде дә бит, әмма илдән алып килгән вак-төяк кәнфитләр өләшенеп беткән иде шул инде. Рәшидә бүлмәсенә кереп, аклы күлмәген киде дә, урамның икенче очына китте, алсу чәчкәгә күмелгән хуш исле зур агач төбендәге эскәмиягә утырды. Каршыда иксез-чиксез диңгез ялтырап ята. Әнә, эчтәрәк су астыннан, карасу сыртлары чак кына калкытып, ниндидер җан ияләре йөзеп бара. Баштарак туристлар аларны акуламы әллә дип уйлаганнар иде. Юк икән, су төбеннән матур кабырчыклар эзләүче егетләр икән.

Ике негр егете ашханә тирәсен җыештырып йөри. Әнә берсе, елтырап торган шәрә инбашына телем-телем уелган пальма яфрагын салып, ары

китеп бара. Аның артыннан, шактый ара калдырып, икенчесе, шундый ук бер яфракны күтәреп, салмак кына атлый. Ашыгыр җирләре юк, күрәсең. Безнең урыс илендәге кебек, җеннәре ертылганчы тартышмыйлар.

"Дөнья матур, яшәү рәхәт. Мин бәхетле, мин ял итәм",—дип тәкърарлады Рәшидә үз-үзенә. Оҗмах, мөгаен, шушындыйдыр. Бәхет өчен ни кирәк тагын?!

Әмма кеше дигәнең оҗмахка тиң җирдә дә үзен бәхетсез итә белә... Шушы гүзәллектә, гамьсезлектә мәңге түгел, бер сәгать тә утырасы килми иде Рәшидәнең!

"Оныт син аны, уйлама!—дип үз-үзенә тәкърарлады ул.—Гашыйк булу—үз-үзеңне икенче бер адәм баласына коллыкка бирү, дигән сүз бит ул! Ирекле баштан! Гел аны уйлыйсың, аңа ярарга тырышасың, аның күзенә генә карап торасың! Аны алла урынына күрәсең!.. Рухи коллык бит бу! Ник син үзеңне үзең шундый хәлгә куясың, ә?" Ләкин җан тынмый, йөрәк әйткәнне тыңламый, сыкрый да сыкрый, һич туктамый! Уйда гел ул гына, ул гына...

Көн уртасы җитеп, автобусның кайтканын көчкә көтеп алды ул.

Төшке аш вакытында Рәшидәнең уң ягына тагын Абдрахман килеп утырды. Хәлне бик яхшы белә—юри шулай кылана. Ә Газизҗан арырак, каршы якта. Ул көнне бер вакыйга булып алды: ашау вакытында аларга концерт куйдылар. Мулат егет ишек янындагы пианинода уйнады, кызыл күлмәкле, кап-кара тәнле хатын, бик мул арт санын боргалап, дәртләнеп җырлады.

Рәшидә чәнечке белән банан боламыгын тырнаштырып, каш астыннан Газизҗанны күзәтте. Дөресрәге, аның музыка көенә өстәл өстендә тыпырдаган бармакларына текәлде. Шундый сизгер, матур иде аның куллары...

Җыр тәмамлангач, Абдрахман бушап калган тәлинкәсен Газизҗанга таба этеп җибәрде.

—Нишлисез сез? Хезмәтчеме әллә ул ?!—диде нишләгәнен үзе дә аңлап җиткермичә Рәшидә.—Сезнең артыгыздан шакшы җыярга!

Абдрахман борылды да, көлеп җибәрде:

—Нәрсә, кызганасыңмыни? Аны кызганырга кирәкми! Басмач бит ул. Басмач! Аңлыйсыңмы!

Басмач? Мәктәп дәресләкләрендә бу сүз бандит дигәнне аңлата иде бит! Шуннан артыгын Рәшидә белми дә, чөнки алар хакында бүтәнчә сүзне ишеткәне дә, укыганы да юк.

Ул Газизҗанга борылды. Ә егет карашын читкә төбәгән, дәшми.

Ашханәдән алар ничектер бергә чыктылар.

—Хәзер без дельфиннар карарга барабыз,—диде Рәшидә.—Автобуста буш урыннар бар. Әйдә безнең белән!

Туктале... Ул бит иртәнге якта гына үз-үзенә ант иткән иде... Алай гына түгел, Зарага да әйткән иде... Газизҗаннан читтәрәк булырга... Хәзер соң ник чакыра?.. Бу сүзләрне, аны тыңламыйча, аның ихтыярына буйсынмыйча, теле әйтте!.. Рәшидә бурлаттай кызарып чыкканын тоеп, башын иде.

—Ярый,—диде егет тыныч кына.

Дельфиннарны дингездән бүлеп алынган зур-зур сулыкларда асрыйлар икән. Су өстеннән озын-озын басмалар салынган. Андагы хезмәткәрләр, Газизҗанны күрүгә, кул болгап, үзләре янына чакырып алдылар. Егет чыннан да Куба кешесенә охшаган, аны якын итәләр иде. Ул, мөгаен, шуңа күрә икенче тапкыр әйләнеп килгәндер дә...

Кичен Газизҗан, гадәттәгечә, алар болдырына чәй алырга килде. Кружка бер генә иде, егет ике барак арасын кат-кат әйләнде. Суның кайнап чыкканын да көтәсе булды. Ахырда үзеннән-үзе шулай килеп чыкты—алар икесе урам якка чыктылар, караңгы урам буйлап комлыкка таба киттеләр.

—Әйт әле, Газизҗан, Абдрахман нишләп сине басмач ди ул?

—Аны тыңласаң... Теленә салына шунда.

—Ләкин син аңа каршы әйтмәдең.

—Ахмак белән сүз көрәштермиләр.

—Сезнең якта ничектер, бездә басмач сүзе бик начар бит.

—Мин үзем дә белмим әле: яхшы кешеме мин, начармы.

Газизҗан моны бик тыныч тавыш белән, бер дә исе китмәгәндәй әйтте. Рәшиденең исә башына китереп ордыларммыни.

—Әллә син... үтерер дә идеңме?

—Кирәк булса, нигә үтермәскә?

—Ничек алай?!

—Мина күсәк белән кизәнгәндә, мә, сук, дип, башымны иеп торыйммы? Нәрсәгә андыйны кызганырга?

Алар комлыкка төшә торган сукмак янына килеп җиткәннәрен сизми дә калганнар икән. Туктадылар.

—Кешеләр бер-берсенә күсәк күтәрергә тиеш түгел,—диде Рәшидә.

—Сез хатын-кызларча сөйлисез,—диде Газизҗан. Аның тавышында өстенлек сизелде.

—Минем фикер түгел бу,—диде Рәшидә.— Антуан де Сент-Экзюпери дигән язучыны укыганың бармы?

Җавап булмады. Ләкин егетнең кызыксынганы сизелде.

—Аны берничек тә йомшак, җебегән дип булмый,—дип дәвам итте Рәшидә.—Хәрби очучы. Африкада, Латин Америкасында очкан, фашистларга каршы сугышкан. Һәм кырык дүртенче елны һәлак булган. Аның "Кешеләр планетасы" исемле әсәрендә шундый бер вакыйга тасвирлана. Самолет ватылып, чүлгә барып төшә. Очучылар исән кала. Алар кояш чыгышына таба җәяү китәләр. Атнадан артык баралар. Бер тамчы сулары калмый, сусап үләр дәрәҗәгә җитәләр. Инде бөтенләй өметләре өзелгәндә, кәрван күренә. Кемнәр алар, дусмы, дошманмы, очучылар бу хакта уйламыйлар да. Кешеләр белән очрашу бу минутта алар өчен әҗәлдән котылуны аңлата. Һәм шулай булып чыга да. Ком гарәпләре бу французларны күреп алалар, яннарына киләләр, су бирәләр, дөягә утыртып, үзләре белән алып китәләр. Газраил кулыннан тартып алалар, дияргә була.

—Бу шундый бер очрак инде,—диде Газизҗан.

—Ә минемчә, кагыйдә. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Барлык халыкларның даһилары меңнәрчә еллар буе тукып тора моны. Кеше кешегә кешелекле булырга тиеш. Үтермәскә! Үтермәскә! Бик аңлаешлы, гади бит югыйсә.

—Артык беркатлы уйласаң гына шулай гади тоела ул, —диде Газизҗан. Моның белән килешми мөмкин түгел иде.

—Син хаклы,—диде Рәшидә.—Бу канунны адәм балаларының һәммәсенә сеңдерү—бик авыр мәсьәлә. Мин болай дип күз алдына китерәм: яшәеш үлчәвенең бер як тәлинкәсенә яхшылык, икенче ягына яманлык салынган. Ике якка да кешеләрнең гамәлләре өстәлеп тора. Берәүләр ана игелеген куя, икенчеләр явызлыгын сала. Явызлык торган саен кимрәк салынсын—фәкать шул гына.

—Үгет-нәсихәт белән генә мона ирешеп булмый. Явызларны юк итү өчен шул ук күсәк кирәк. Бомба,—диде Газизҗан.

—Махатма Гандины беләсеңме син? Ул һәртөрле көч куллануга каршы булган, әмма шуңа карамастан илен азат итүгә ирешкән!.. Корал тотып түгел, сугышып түгел. Тыныч юл белән!

Рәшидә ерак Һиндстан вакыйгаларын сөйли башлады.

—Син Неруның "Бөтендөнья тарихына бер караш" дигән китабын укып кара...

Ул очынып-очынып сөйли, чөнки Газизҗанның суга сусаган гөл кебек йотылып тыңлаганын сизә иде. Күп уйлана, күпне белергә тели егет, тик иркенләп, ачылып сөйләшергә дуслары, тынгы бирмәгән сорауларына җавап алырлык мөмкинлекләре юк иде, күрәсең.

...Аннан соң да алар берничә кич очраштылар. Рәшидә, мең дә бер кичәдәге Шәһризадә кебек, сөйләде дә сөйләде. Иллярдән-илләргә, романнардан картиналарга һәм сыннарга, аннары симфонияләргә, балетларга күчте ул. Эзлекле бер тәртип сакламады, әмма төрле төстәге пыяла кыйпылчыкларыннан зур бер картина ясап булган кебек, аның кыйссаларыннан да яшәешнең киң манзарасы хасил була иде. Дөньяның, тормышның үзе

кебек чуп-чуар һәм һәрчак үзгәрүчән бу манзараның дулкынланып караучысы, тамашачысы бар—ул Газизҗан иде.

Китапларда, картиналарда, сыннарда кеше язмышы, аның күңелендә шаулаган давыллар чагыла. Ул давылларны янар тауларга тиң сихри, кодрәтле көч—мәхәббәт кузгата.

Рәшиданең хикәятләре дә әледән-әле мәхәббәткә барып тоташты.

Ах, ул романнарда, җырларда тасвирланган сөю хәлләре! Күп очракта фаҗигале тәмамлана шул алар!

—Менә, мәсәлән, адмирал Колчакның мәхәббәте шундый.

—Адмирал Колчак?—дип гаҗәпләнеп сорады Газизҗан.

—Әйе шул, адмирал Колчак. Бездән соң аны белүче сирәк булыр. Ул онытылыр. Ә менә саф сөю калыр.

—Ничек алай?

—"Гори, гори, моя звезда" дигән җырны ишеткәнең бармы синең?

—Урыс халык җыры бит ул.

—Юк шул, халык җыры түгел. Аның сүзләрен адмирал Колчак язган. Нәкъ менә Себердә советларга каршы сугышып йөргән елларында. Көчле шәхес булган ул. Белсәң, син аңа сокланыр идең, мөгаен. Кызылларга каршы сугышып, Казанга бәреп кергән, андагы банктан тугыз мең пот алтын төяп алып киткән. Шул алтынга алынган корал белән сугышып, уннарча мең кешенең һәлакәтенә сәбәпче булган. Ахырда җинелгән, большевиклар кулына төшкән һәм атылган. Мәктәптә безгә Колчакны надан, канлы дошман дип сөйлиләр иде. Ә менә аның җыры чын сөюнең бөеклеге турында сөйли. Ул большевиклар төрмәсенә ябылгач, сөйгәне аны бер күрү өчен үз ихтыяры белән төрмәгә кереп утырган.

—Ничек алай?

—Килгән дә, мине дә ябыгыз, дип таләп иткән. Шундый мәхәббәт... Алар күптән дөньяда юк инде, ә җыр яши. Мәхәббәт йолдызы турында... Күрәсең, һәркемнең үз йолдызы буладыр... Булырга тиештер...

Гори, гори, моя звезда, звезда любви приветная,
Ты у меня одна заветная, другой не будет никогда...—

дип әкрен генә тавыш белән җырлап та бирде Рәшидә.

* * *

Кояш баеган, урамда караңгы. Үрдән түбәнгә, ашханәгә берәү төшеп бара. Атлап түгел, йөгереп түгел, тротуардан юлга, юлдан кире тротуарга кушаяклап сикергәләп. Рәшидә әллә каян таный—Газизҗан бу.

"Әллә мин булдыра алмыйммы? Көч җитәрлек әле!" Шактый ара калдырып, Рәшидә дә нәкъ шулай сикергәләп китте. Караңгыда күрүче юк, ә аңа үзен сынарга кирәк, берәүгә тиң икәнен үз-үзенә исбат итәргә. Һәм ул моны булдыра да!

Бүген туристларның соңгы көне, шуны истә тотып, ашханәнең өске катындагы ачык верандада бию кичәсе оештырганнар. Караңгыда танып бетереп булмый, килгәннәрнең күпчелеге чехлар, украиннар иде бугай. Менә бер почмакта гына лампочка кабызып куйдылар да, магнитоланы уйнатып җибәрделәр.

Рәшидә, әлбәттә, Газизҗан белән биюне өмет итә иде. Соңгы кич бит бу, соңгы сәгатьләр!

Ләкин менә бер көй озак кына уйнап туктады, аны икенчесе, "Мучаме" алыштырды. Ә Газизҗан күренмәде. Әле генә сикергәли-сикергәли шушы тарафка киткән иде бит югыйсә!

Рәшиданең каршына ак күлмәкле берәү килеп башын иде. Теге көнне яр буеннан тауга карап: "Сикер!"—дип кычкырган украин егете иде бу. Рәшидә баш тартмады. Бәлки, Газизҗан аны күрми генәдер, дип уйлады. Уртага чыккач, күрми калмас. Икенче биюгә чакырыр... Ләкин менә салмак биеделәр, аннары кызу көйгә тыпырдадылар, ә Газизҗан юк та юк...

Кичәнең кызыгы бетте. Музыка туктап торган арада Рәшидә кинәт кенә борылды да, баскычтан аска томырылды, йөгереп бүлмәсенә кайтып китте.

—Йә, ничек анда?—диде Зара.

—Бииләр әле. Кеше күп түгел, озакка сузмаслар. Әйдә, йөреп киләбезме?

Музыка тавышы ишетелеп тора, ләкин халык тарала иде булса кирәк, каршыга көлешеп-шаулашып килгән төркемнәр очрады. Бию залы ерактан ук яктырып күренде, анда өске утларны кабызганнар иде. Бер егет кырыйдагы өстәлләрне җыештыргалый, уртада исә икәү—биленә алъяпкыч бәйләгән мулат кыз белән бер егет бииләр иде. Рәшидә барган җиреннән сөртенеп туктап калды: биюче егет Газизҗан иде.

Рәшидәнең башын утлы томан басты, иреннәре кипшенде.

—Нишли ул? Бу ни дигән сүз?—дип сөйләнде ул үзалдына.—Юри кылана... Миңа үч итә... Минем йөрәккә ут салуы...

Зара аның беләген сыйпады, кызганды, күрәсең.

—Ташла! Берни уйламый ул! Кубача биергә өйрәнә, бары шул гына. Исең киткән икән! Әйдә, китик моннан.

Ләкин Рәшидә баскан урыныннан кузгала алмады.

—Әйдә инде!—дип аның беләгеннән тартты Зара.—Төкер! Бала-чага булма.

Кире кайтканда Рәшидә бертуктаусыз сөйләнде.

— Нинди бәхет: иртәгә без китәбез. Котылам бу газаптан!

— Гашыйклар шундый була шул: бер-берсен чеметтереп алырга ярата,—диде Зара.—Сез дә әнә, әле бер-берегезне яклашасыз, әле үртәшәсез. Ни кыланганыгызны үзегез дә белмисез

—Ул дамы?

—Икегез бер иш!

—Ә син каян беләсең?!

—Аны да күрмәскә, фил булырга кирәк!

—Иртәгә хәтле генә түзәсе... Таң атканчы гына...—дип сөйләнде Рәшидә.

Бүлмәгә кергәч, ул әрле-бирле йөренде дә, коену киеме өстеннән халатын киде, йөзгечләрен алды.

—Син кая?—дип сорады мендәрен кабартып азапланган Зара.

—Диңгез белән саубуллашып киләм.

—Акылдан шаштыңмы әллә?—дип башын чайкады Зара.—Бу караңгыда диңгезгә керәләр димени? Анда хәзер эт тә юк!

—Кичен диңгездә коенуым беренче генә түгел.

—Төнлә акулалар ярга якын килә, дип кат-кат кисәткәннәрен оныттыңмы әллә?

—Юри генә әйтәләр.

—Үзеңне генә җибәрмим,—диде Зара һәм яланаягына сандалларын элде.

Алар якты болдырдан урам караңгысына чыктылар. Зара кинәт туктап калды да:

—Сөлгемне алмадым бит,—диде.—Минем дә чыланып аласы килер. Чыннан да соңгы тапкыр бит, Кариб диңгезен бүтән күреп булмас. Бер генә минут көтеп тор, хәзер әйләнеп чыгам.

Һәм барак почмагыннан борылып, кире кереп китте.

Шактый гына көттерде. Коену киемен кия торгандыр, дип уйлады Рәшидә.

Ниһаять чыкканда, Зара ялгызы түгел, Газизҗан белән иде.

—Мин барып йөрмәм инде. Әйбер-карам да җыелып бетмәгән... Хәерле кичләр.

Шулай диде дә борылып кереп китте. Рәшидә белән Газизҗан каракаршы басып калдылар.

—Коенасыгыз килә икән,—диде егет сузыбрак.—Әйдәгез соң.

Алар озын урам буйлап сүзсез бардылар. Аяк асты бөтенләй күренми,

ә үрдән комлыкка төшә торган сукмак тигезле-тигезсез, чокыр-чакырлы иде, Рәшидә абынып китте. Газизҗан аны беләгеннән нык итеп тотып алды.

Яр тирәсендә беркем юк, тәрәзәләреннән саран яктылык сирпелгән бараклар да өстә калды, түбәннән караганда күренмиләр. Озын дулкын салмак хәрәкәт белән шаулап ярга ишелә дә, аксыл күбеген комга җәеп, кире чигенә.

Яр буеннан суга керә торган урынның комлысы бар, ташлысы бар. Рәшидә караңгыда чамалап бетермәде, ташлы урынга эләкте. Салмак, көчле дулкын—накат аны эләктереп алды да, эчкә сөйрәде, аннары төпкә китереп бәрде.

Рәшидә яр читендә каралып басып торган юлдашы янына чыкты.

—Монда ташлы, уңайсыз,—диде.—Арырак керергә кирәк. Эчтә дулкын каты бәрми, тирбәтә генә. Син борчылма, озак йөзмәм.

Егет аны аңлап җиткермәде, йөзен якын ук китереп:

—Нәрсә дисез?—дип сорады.

—Эчкәрәк керәм, дим. Күренми торсам, борчылма.

Газизҗан каты итеп аның кулыннан тотып алды.

—Юк. Беркая да кермисез. Мин сезне җибәрмим.

—Ничек инде... ничек син мине тыя аласың?

—Тыям. Җибәрмим.

Бу шундый нык итеп әйтелде, егетнең үз сүзен итәчәге көн кебек ачык иде. Аның белән сугышып булмый бит инде! Хәер, әдәп саклау тиешлеге генә туктатмас иде Рәшидәне. Егетнең ныклы сүзен ишетү, аның ихтыярына буйсыну рәхәт иде аңа.

—Җибәр, халатны киим...

Егет шаулап ярга бәрелгән озын дулкыннарга караган килеш басып торды, Рәшидә коену киемен салып, халатын киде.

Алар кире үргә менделәр дә, бер ягында бараклар тезелгән, икенче ягында тау каралып торган урам буйлап киттеләр. Менә унда өскә менә торган баскыч шәйләнде. Газизҗан туктады да:

—Әйдәгез, тауга менәбез,—диде.

Рәшидәнең йөрәге кысылды. Дингез аңа үз, якын, төнлә коенуы да беренче тапкыр түгел. Чит җирнең төнге тавы исә шомландыра, куркыта иде.

Ләкин... Газизҗан белән бит!

Ул, суга чумарга әзерләнгәндәй тирән итеп сулыш алды да, баскычның беренче басмасына басты.

Алар өске мәйданчыкка менделәр дә, култыксага тотынып, дингез ягына борылып бастылар.

Төннең кара пәрдәсе җиһанның һәммә ваклыкларын—баракларны, комлыкны, куакларны, ашханә өстендәге веранданы—яшергән. Алда төрле төстәге , меңләгән, миллионлаган очлы күзләре белән караңгылыкны тишеп, керфек тә какмыйча, кыймшанмыйча, туп-туры аларга Галәм үзе карап тора иде. Нинди хәбәр китерәләр, нәрсә турында сөйлиләр ул йолдызлар? Кайларга әйдиләр алар безнең күңелләрне?

Тәңгә көч-кодрәт иңгәндәй булды. Син галәмне күрәсең, аның галилеген тоясың. Үзеңне дә шушы йолдызлардай итеп тоясың. Бу караңгылык артында дингезләр, таулар, чүлләр, далалар, урманнар, зур калалар, авыллар барлыгын сизәсең. Күпме сер, гаҗәеп могҗизалар җирдә һәм галәмдә! Бар, күр, соклан, үзгәрт!

Рәшидә Газизҗан турында уйлады. Ул тынгысыз җанлы, көчле, тәвәккәл. Бик күпне беләсе, күп нәрсәне аңлыйсы, колач җәеп, очынып-талпынып яшисе килә. Һәм аның моңа мөмкинлеге дә бар: гомере алда әле. Ә адәм баласы теләсә, тырышса, омтылса, күпкә ирешә ала.

Рәшидә кулы белән киң хәрәкәт ясап:

—Болар һәммәсе сезнеке, хуҗа булыгыз!—диде.

—Нигә без генә? Ә сез?!

Менә ничек! Рәшидә үзен аннан аерып куйганын сизми калган икән. “Тормыш ярминкәсеннән кайтып килеш шул инде безнең. Ә сез барып

ятасыз. Шул юлда кара-каршы очрашуыбыз гына бу безнең",—дип шаяртып җавап бирәсе килде Рәшидәнең. Тик ул тел очына килгән бу сүзләрне йотты, кыска гына итеп, сагышлы көлеп куйды.

—Мин мондагы йолдызларның берсен дә танымыйм,—диде, сүзне икенчегә борып.—Болар, күрәсең, безнең яктан күренмидер.

—Ә мина кайберләре таныш,—диде Газизҗан.—Әнә, тегендә "Җиде бертуган" дигән йолдызлык. Менә болай карагыз әле.

Ул Рәшидәне иненнән кочып алды да, битен-биткә терәп, сул кулын йолдызларга сузды... Теге чакта, "Националь"дәге кебек.

Рәшидә битен ике кулы белән каплады да:

—Күптәннән сорыйсым килә,—диде.—"Националь"дә... син мине гаепләдеңме?

—Нәрсә өчен?

—Беләсең бит инде...

—Ә сез "Тропикана"ны хәтерлисезме?

—Ләкин монда "Тропикана"ның ни катышы бар?

—Сез бит анда бездән көлдегез. Аерата миннән...

—Ничек?! Син каян белдең?

—Безнең яннан узып киткәндә нинди караш ташлаганыгызны оныттыгызмыни? Без утырып калдык, ә сез сәхнә каршына барып бастыгыз. Бөтен тамаша гүяки бер сезнең өчен барды. Ә безгә барыннан да ачыграк булып, яктырып сезнең йөзегез генә күренә иде.

—Һәм шуннан соң миннән үч алырга ниятләдеңме?

—Үч? Мин сезгә соклandым. Ә инде "Националь"дә...

—Әллә ни булды мина,—диде Рәшидә.—Күптән инде җырлаганым юк иде. Соңгы вакытта җырлыйм да җырлыйм... Җырлыйм да җырлыйм...

—Синең кебек минем тормышымда башка-бүтән булмаячак,—диде Газизҗан.—Син берләнбер. Синдәй юк бүтән...

—Синең янда гына шулай мин,—дип пышылдады Рәшидә. Аның куллары егетнең муенына сарыла, иреннәре аның йөзен пешерә, ләкин ул үзе моны аңлап житкерми, тик бөтен тәнен сарган эсселек зиһенен көйдергән иде.—Синең өчен генә... Синең белән генә...

Үткәнне-киләчәкне, булганны-булачакны—һәммәсен галәм караңгысы йотып алган, мәңгелек каршында, йолдызлар яктысында, кыргый тау башында алар икәү, фәкать икәү генә иде. Һәм бу икәү шушы минутларда үзләрен бер җан, бер тән, мәңгелеккә бара торган бер йолдыз дип хис итәләр иде.

* * *

...Иртәгесен көн яктырганчы ук, татарларны аерым, үзбәкләрне аерым автобусларга утыртып, аэропортка алып киттеләр. Анда таможняга чират торганда да, паспорт контролен узганда да Рәшидә белән Газизҗан берберсенә якын килмәделәр. Нииндидер оялу, кыенсыну тыйды. Самолетка Газизҗан алдан кереп китте. Рәшидә аның артыннан барырга кыймады, алгы утыргычларның берсенә утырды...

Мәскәү аэропортындагы ыгы-зыгыны тасвирлап торуның кирәге бар микән? Кырмыска оясындагы кебек халык арасында озак болгандылар, чөнки киткәндә кышкы киемнәрне, капчыкларга тутырып, сакларга куйганнар иде, шуларны алырга да чират торасы булды.

Аэропорттан чыгып, автобуска утырганда, караңгы төшкән иде инде. Шофер эчтә утларны кабызмаган, Рәшидә керде дә, артка узды. Газизҗан аның янына килергә тиеш иде. Һәм ул килде.

Күңелдәгене әйтеп булмый, юк-барны сөйләшәсе килми иде. Рәшидә юл буе Газизҗан ишетерлек кенә итеп, әкрен тавыш белән җырлап кайтты. Дәртле пионер җырларын җырлады ул. "Яшь бөркет", "Юллар буйлап, үрләр буйлап", "Яле, шаулап, җырлап җибәр, шаян җилкәй..." Студент чакларында пионер лагерьларында шактый эшләде, андый җырларны күп белә. Ә менә Газизҗан белми икән...

Кунакханәгә урнашу гадәттәгечә матавыклы булды: кемдер нәрсәнедер исәпкә алмаган, күпмедер урын бушамаган, фәлән сәгать көтәсе...

Инде, ниһаять, бүлмәләргә таралышканда Газизҗан:

—Сез ничәнчедә буласыз? Мин иртән сәгать алтыда керермен,—диде. Шулай килештеләр.

Кунакханә бүлмәсе ике урынлы, Рәшидә барып кергәндә, түр караватта берәү йоклый иде инде.

...Ул Газизҗанның килгәнен алдан ук сизде. Әмма йөгереп барып ишекне ачмады. Кат-кат шакыганнан соң, күрше кузгалды. Утны яндырмыйча гына ишекне ачты. Аннары кире керде дә, йокыдан карлыккан тавыш белән Рәшидәгә:

—Сезне сорыйлар,—диде.

Рәшидә ванна бүлмәсенә кереп китте. Юынырга керешде. Газизҗанга ямьсез күренәсе килми иде. Бер ышкып юды тешен, аннары тагын бер тапкыр... Чәчен тарады... Инде чыгам дигәндә генә, күлмәгенең сул ягын кигәнен сизеп алды...

Озак көттергәнен дә аңлый, тик артык каушаган, ашыга алмый... Мәскәү иртәсенең саран яктылыгында аның күзенә туры караудан нигә шулай курыкты икән ул?..

Ниһаять, ул ишекне ачканда, коридор буш иде... Баскычтан аска карады... Тынлык, бушлык. Кизү хатын да каядыр киткән, эчке бүлмәсенә кереп, черем итәдер...

Аның каршына үтүк тотып бер ир кеше килеп чыкты. Рәшидә пальтосының капчыкта ятып бөгәрләнгән икәнен исенә төшерде.

—Үтүк кирәкмисе сезгә бүтән?—диде.—Биреп торыгыз миңа. Дежурныйга үзем тапшырырмын.

Кулы калтырап, зиһене чуалып, озак азапланды. Ниһаять очына чыгып, үтүкне илтеп тапшырганда, кизү хатын, нидер исенә төшкәндәй:

—Ә-ә, сезмени әле ул егерме алтынчы бүлмәдән,—диде.—Бая сезне бер кеше сорап килгән иде. Аска төшсен, мин администратор тәрәзәсе янында көтеп торырмын, дип әйтергә кушты.

Рәшидә пальтосын кулына тоткан килеш сигезенче каттан аска томырылды. Администратор тәрәзәсе каршына чират тезелгән, ләкин Газизҗан юк иде.

Ул кире йөгереп бүлмәсенә керде, ашыгып телефонны алды, Зарадан Газизҗанның бүлмәсен белеште, шылтыратырга керешде. Ләкин трубкадан җавап ишетелмәде.

Йөрәктә нәрсәдер өзелде...

... Казан вокзалында башкаларны кочак җәеп каршы алдылар. Рәшидә башын иеп, күңелле гөрләшкән төркемне әйләнеп узды да, ялгызы трамвайга таба китте. Аның йөзенә туган якның карлы җиле бәрде.

—Нигә шылтыратып хәбәр итмәдең? Каршы алган булыр идем!—диде Евгений.— Син кайтуга чәч үстереп куйдым әле менә.

Һәм хатынының кулын алып, баш түбәсенә куйды. Чыннан да, язын тишелгән үлән шикелле йомшак булып, чәче үсә башлаган икән. Әмма иренең йөзе тагын да арыграк, күзләре элеккедән дә сагышлырак булып күренде, тавышы хәлсез, бөтен кыяфәте кызганыч тоелды.

Рәшидә өстен алыштырып кухняга кереп китте. Өстәл юылмаган савыт-саба белән тулган. Кранны ачты. Алюмин кастрюльгә, суга кушылып, кайнар яшьләр тамды, үксү тавышын су шавы басты...

* * *

"Син кайларда, газизем, җаным? Бу минутларда ниләр эшлисең икән? Заводларның төрлесендә булганым бар. Сине шундый цехларның берсендә, тимер чыңы янгыраган, очкыннар чәчрәп торган биек, котсыз бинада, комбинезон кигән кешеләр арасында күз алдыма китерәм дә, йөрәгем кысылып куя.

Мин редакциядә, ишекнең тышкы ягына: "Борчымагыз, корректура укыйбыз!"—дип игълан элеп куйдым да, хат язарга утырдым.

Син яшәгән шәһәр турында берни дә белми идем. Энциклопедияне ачып укыдым. Сездә мамык игәләр, ефәк кортлары үстерәләр, цемент житештерәләр икән. Театр бар, музей... һәм Шаһимәрдән күлләре—берсе кайнар, икенчесе салкын. Синең өчен Атлантик океаннан һәм Кариб диңгезеннән матуррак күлләр...

Бу урында мине бүлдерделәр, ишекне ачтырдылар. Редактор керде. Кичә язган зур гына мәкаләмне укып чыккан, бик ошаткан. Язу—минем һөнәрем. Мин жиргә орлык сипкән бакчачы кебек: ак кәгазьгә орлык итеп хәрефләр тезәм, укыган кешенең күнелендә тамыр җәеп тишелерләр, гөл булып үсәрләр һәм чәчкәгә күмелерләр, дип өметләнәм. Минем җанымда балкыган асыл гөлләр шикелле. Ул гөлләр шушы хатыма сибелгән хәреф-орлыклардан тишелеп, синең күнелеңдә дә гөл булып үссен иде...

Уйлап карасаң, искитәрлек: безнең арада меңнәрчә чакрымнар, безнең тирәдә меңнәрчә кешеләр... Чакрымнар гына куркыныч та булмас иде—безне вакыт—яшәгән елларыбыз аера. Аһ, нигә без бер чорда, бер авылда тумадык икән! Тик мин чакрымнарны сизмим, арабыздагы кешеләрне күрмим, ике арада яткан елларны тоймыйм. Бу җиһанда минем өчен син генә, тик син генә! Әйе, мин мәхәббәт турында гәзитләрдә күп мәкаләләр яздым. Кемне нәрсә өчен ничек яратырга икәнен өйрәттем, чөнки әхлак бүлеген җитәклим. Бер галимә белән икәүләшеп бу хакта брошюра да язып чыгардык хәтта. Ләкин менә хәзер, үзем сөю дигән җәннәт бакчасына барып кергәч, сукмак табалмыйм. Гөлләр арасында адаштым.

Тормыш менә нинди икән һәм сөю менә нинди икән бит!"

—Син аның белән хат алышмакчы буласыңмыни?—дип башын күтәреп, коңгырт күзләре белән Рәшидәгә текәлде Зилә һәм өстәлендә яткан кәгазь битен сыйпап куйды.

Ярый әле, ул бар, һәммәсен сөйләп, серләшеп, юаныч табып була. Менә, язган хатларын да аңа укыта Рәшидә.

—Их, аңламыйсың!—диде ул.—Мин язмый булдыра алмыйм шул!

—Ләкин аның гаиләсе бар. Синең хатың аркасында дәгъва чыкса? Мин, мәсәлән, Фәритемә мондый хатлар килүен бер дә теләмәс идем.

—Дәгъва чыкмас,—диде Рәшидә.—Мин аның адресын белмим бит. Сөйләдем ич инде, без иртәнге якта очрашырга тиеш идек, аймылыш булдык, дип. Их, Зилә, шунда йөгереп чыккан булсам, күзләренә соңгы тапкыр тутырып караган булсам!

Һәм ул, күз яшьләрен тыярга тырышып, йөзен читкә борды.

—Өстәл тартмаңа салып куяр өчен язасыңмыни?

—Җибәрәм мин аны.

—Кая?

—Ферганәнең үзәк почтасына. Хатларны сорап алучылар бүлегенә.

—Сез шулай сөйләшкән идегезме?

—Өлгермәдек дим бит.

—Каян белеп почтага барыр соң ул?

Рәшидә бүлмәдә ишекле-түрле йөренде.

—Минем хат язасымны белә бит ул.

—Каян белә?

—Ничек белмәсен инде? Менә мин үзем үзәк почтага баргалыйм. Миңа хат юкмы, дип сорыйм. Ул да минем хакта уйлыйдыр.

—Бер кешенең башы икенчесенеке кебек эшләми, Рәшидә.

Зилә бүлмәдәшенә кызганып карады.

—Әйе, ул, бәлки, теге иртәне мине юри чыкмады, дип уйлагандыр,—диде Рәшидә.—Үпкәләгәндер. Ләкин тора-бара барыбер аңлар, кичерер. Уйлар-уйлар да почтага барыр. Мин конвертка кире адресны да язмыйм.

—Ник? Барып житүен-житмәвен белеп торыр иден ичмасам. Почтада аларны бер ай гына саклыйлар. Килеп алучы булмаса, кире җибәрәләр.

—Җибәрмәсеннәр! Калсын шунда! Аның шәһәрендә, аңа якынрак булырлар! Их, Зилә! Җырларга гына калды инде миңа, җырларга!

Һәм ул җырлап җибәрде:

Мендем биек тауларга,
Бөркетләрне карарга,
Бөркет булып очар идем
Ярым йөргән якларга.
Мендем тауның башына,
Бастым җилләр каршына,
Җилләр, дип, сәлам әйтегез
Җанкаем-җанашыма...

Зилә карашын читкә алып, башын чайкап куйды. Аннары:

—Өстәлеңдә тагын бер конверт бар, берьюлы ике хат җибәрәсенмени?—дип сорады.

—Анысы Зарага, бергә төшкән фотоларны салдым.

—Каяле, ничек чыккансыз икән! Конверты белән генә бир, үзем алып карармын!

“Менә бит, Зараның адресы,—дип уйлады Зилә.— Язып алырга кирәк... Кирәге чыгар, бәлки...”

* * *

“Менә тагын... Тагын мин мәкалә язасы урынга хат язам. Соңгы көннәрдә үзем яраткан язучыларның мәхәббәт турындагы хикәяләрен кабат алып укыдым әле. Купринның “Гранат кашлы беләзег”ен, Толстойның “Крейцер сонатасы”н, Лесковның “Мценск өязендәге леди Макбет”ын... Һәм берсе белән дә ризалашмадым. Бу әсәрләрдә чын сөю—фаҗига итеп, күп очракта һәлакәткә китерә дип тасвирлана. Йөгәнсез хисләр адәм баласын яхшыга илтми, дип раслый алар.

Атаклы язучылар белән бәхәскә керергә элегрәк минем башыма да килми иде. Ләкин менә хәзер алар белән килешмәдем. Чөнки сөеп куанам. Нинди зур бәхет, дөньяда син бар бит, син бар! Шушы хис белән очынып яшим, һәммәсен бик тиз эшлим, очраган бер кешегә елмаям, алар да миңа елмаеп карыйлар. Исән генә була күр һәм шатлык белән яшә!

Әйе, миннән син ерак, “Җиде туган” исемле йолдыз кебек. Төнге күк йөзеннән мин шул йолдызлыкны эзлим, табалмыйм... Галәмгә туктаусыз сигналлар җибәреп, ерак планеталарда яшәүче билгесез җан ияләреннән җавап көтүче сәер адәм кебек тоям үземне. Ни тели, нәрсәгә өметләнә ул? Җавап юк.

Минем хисләрем синең барыр юлларыңа нур булып сибелсен иде.”

—Рәшидә! Син тагын бикләнеп утырасың, ә! Телеграмма бар сиңа! Кулыңны куеп ал!

—Телеграмма?!

—Бие! Бие!

Ләкин Рәшидәнең биер хәле юк, тез буыннары йомшап төшкән.

Алтын шарчыкларга охшаган мимоза чәчәкләре төшерелгән зур, елтыр катыргыга гади генә сүзләр язылган: “Бәйрәм белән котлыйм. Бәхетле булыгыз! Куанып яшәгез! Газизҗан.”

—Мөмкинме?—дип кулын сузды Зилә.—Карыйм әле.

Аннары открыткага тиз генә күз йөгертеп алды да:

—Менә күрдеңме,—диде.—Җавап биргән!

—Минем хатларны алгандыр, дип уйлыйсыңмы?

—Мөгаен, алгандыр. Почтага барган бит, телеграмма салган. Анда хатларны сорап ала торган тәрәзә янәшә генә...

Зилә өстәлдәге кәгазь битен күреп алды:

—Ә син тагын хат яздыңмы?

—Яздым. Укыйсыңмы?

Беразга тынлык урнашты.

—Бу китаплар турында язмаска иде,—диде Зилә.

—Мин яхшыларын гына санадым әле.

—Тагын да начаррагы бармы әллә?

—"Сугышчы хатын" дигән хикәясендә Лесков бер апаның егерме ике яшьлек егеткә гыйшкын язган. Көлеп, мыскыллап! Менә карале син, укып кара!—Рәшидә сумкасыннан кызыл тышлы китап чыгарды.— Теге малай моның акчасын эчеп бетергән, үзен тотып-тотып тукмый икән. Ахыр чиктә, кеше әйберсен урлап, төрмәгә кереп утырган. Бу хатын, бичара, гыйшык зәхмәтеннән тәмам кибеп корыган! Тәрәзә төбенә башын бәрә-бәрә, нишләдең син бәгырем, нишләдең, дип үкерә. Көлке түгелмени?

—Ташла син моның ишене!—дип китапны читкә этәрде Зилә.—Тапкансың. Йосыф-Зөләйха кыйссасын укы әнә! Анда нәрсә диелгән? Зөләйханы мәхәббәт яшәртә! Аңа икенче тапкыр яшьлек килә. Алар кавышалар, озак еллар бәхетле яшиләр һәм гөл кебек балалар үстерәләр. Алар да икесе ике ил кешесе югыйсә! Менә кайда ул мәхәббәт! Чын, саф хисләр бәхет китерә. Сиңа да язмыш биргән зур бәхет бу! Кара үзеңә, кара йөзеңә! Кубага киткәндә сулып барган олы апа идең! Ә хәзер чәчрәп торган яшь хатын. Теге егет тә өр-яңадан туган кебек булгандыр, иманым камил. Син беркемгә дә зыян салмадың, беркемнең күңелен китмәдең. Син фәкать үзең бәхетле көннәр кичердең һәм тагын берәүнең тормышын яктырттың.

—Минем дә балам булачак бит... Мин буйга уздым, Зилә!

Зилә гаҗәпләнергә тиеш иде. Ләкин ул елмаеп кына җибәрде.

—Шулай буласы көн кебек ачык иде,—диде.—Хәзер инде хатларыңны болай килделе-киттеле теләсә кая җибәреп утыра алмассың. Нәкъ кешесенә барып ирешерлек итеп язарга кирәк.

—Ни сөйлисең син, Зилә?! Аңа бу хакта язып булмый... Башына әллә нинди уй килер... Үзең дә әйтәсең бит, һәр кеше үзенчә уйлый, дип. Ирем бар бит минем.

—Ләкин бала үз атасын белергә тиеш!

—Бәлки, кайчан да булса... Соңыннан...

—Болай булгач, мин ышанам: сез очрашачаксыз әле. Менә күрерсең: ул сине эзләп табачак.

—Ләкин безгә очрашырга ярамый! Ярамый...

—Бусы инде синең эшең генә түгел... Монда башка берәүнең хокуклары булачак.

—Бу дөньяга яңа бер җанны чакырып китергәнче, төптән уйларга, һәммәсен үлчәргә тиеш идем... Бер абынган идем бит инде!

—Беләсеңме, мондый очракларда минем әни нәрсә ди? Ул әйтә, туачак җан булгандыр, ди. Сөен! Бик зур бәхет бит бу!

Бераз тынып тордылар.

—Тагын шунысы... Бала атасыз түгел... Законлы ирең бар...

Монысын Зилә авырлык беләнрәк әйтте. Чыннан да, катлаулы мәсьәлә иде бу, бик тә четерекле...

—Әйе, мин аңа әйттем,—диде Рәшидә.

—Ә ул?

—Ул миңа, бик яхшы, ялгыз калмассың, диде.

— Андый иргә һәйкәл куярга кирәк!—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды Зилә.

—Көннәре санаулы икәнен белеп, әкрен-әкрен якынлашып килгән Газраилнең күзенә карап яткан кешенең эчендә ни кайнаганын кем белеп бетерсен? Кабер эргәсендә үлчәүләр бөтенләй башкадыр, мөгаен,—дип җавап бирде Рәшидә.—Мин аңа бөтен көчемне бирәм, ә ул миңе гаепләми.

—Ә Газизҗан? Аның белән булганда син бала туарын уйлаган идеңме?

—Юк, мин берни дә уйларга өлгермәдем... Берни дә... гүяки минем Кариб диңгезенең озын дулкыны эләктереп алды да, эчкә алып кереп китте...

—Шул-шул менә, акылны йөрәккә баш итеп куеп булмый, дип күптән әйтелгән инде!

Шулай диде Зилә, ә үзе эчтән генә уйланды:

"Зарага хат язып, Газизҗанның телефонын сорап алганымны әйтим микән әллә? Юк, алай яхшы булмас. Икәү арасына кысылырга ярамый. Газизҗанга үзем шалтыратыйм да, почтага барырга киңәш итим. Шулай яхшырак булыр. Үзләре аңлашырлар."

* * *

"Бүген беренче тапкыр бакчабызда булдым. Яз соңарып килде быел, пароходлар әле генә йөри башлады. Мин сиңа узган елларны язган идем инде: бакчабыз Идел аръягында безнең. Синнән аерылганнан соң дүрт тапкыр язлар килеп гөлләр чәчәк атты, дүрт мәртәбә чия-алмалар пеште. Дүрт тапкыр яфраклар саргаеп коелды, җирне кар юрганы каплады. Менә инде бишенче тапкыр ул бакчабызда карлар эреде. Ә минем күңелем түрендә гөлләр беркайчан да чәчәген коймый, анда кояш баемый торган бер оҗмах почмагы бар. Ачы тормыш җилләре кайсы яктан гына иссә дә, мин шул җәннәтемә кереп, ял алам.

Бу юлы да, һәр яздагыча, Иделнең салкын суына карадым—Кариб дингезенең күбекле озын дулкынын күреп, төнге шавын ишеткәндәй булдым. Синең кулың җылысын: "Беркая да җибәрмим!"—дигән сүзләреңне әйткәндәге татлы, кайнар сулышыңны тойдым. Дулкыннарга пышылдадым: "Мин аны яратам, яратам, яратам!"

Бакчабыздан ерак түгел, яр буенда текә кыя бар, түбәсендә ялгыз нарат җилләрдә бәргәләнеп утыра. Нәкъ без менгән кыя шикелле. Шул тау түбәсендә синең сының чагылып үткәндәй булды. Тагын тәкърарладым: "Мин сине яратам, яратам, сагынам!"

Соңгы вакытта дөньялар шундый тынгысыз. Илнең әле теге, әле бу тарафыннан хәвефле хәбәрләр килеп тора. Инде безнең арада да илләр чиге пәйда булды. СССР таркалгач, элек тыныч җирләрдә утлы-канлы давыллар купты, алар сине кайсы якка тартырлар икән?

Син гомереңнең иң матур чагына аяк басып киләсең. Мин синнән шулхәтле көнләшәм һәм синең өчен шулхәтле куркам. Тик нилэр көтә сине? Иң гүзәл сәнгать әсәрләреннән дә камилрәк, матуррак, сизгеррәк кулларың кайчан да булса кемгә дә булса зыян салырга күтәрелсә, мин моны мең чакрымнардан сизәрмен һәм йөрәгемә кан савар! Синең һәр бармагыңнан нур коела кебек тоела миңа һәм шулай булсын иде!

Минем бер танышым, атаклы табиб болай ди: "Кешеләрнең кылган изге гамәлләре матур җырга, гүзәл картиналарга тиң. Андый гамәлләр башкаларның күңеленә—ләззәт, тәненә сихәт бирә. Изге гамәлләргә соклану, алардан тәм таба белү—бик яхшы дару ул". Шундый гамәлләр генә кылырга насыйп булсын сиңа.

Минем бу хатымны учына алып кыс. Кулларыңа битемне куеп, бармакларыңны аерым-аерым үбә, дип күз алдыңа китер!"

—Һаман язасың, ә?—диде Зилә өстәлдә яткан хаттан башын калкытып.—Бишенче ел китте бит инде. Ниләр генә булмады. Ә син улыгыз туганын яздыңмы соң? Иреннең үлеп киткәнен?

—Тол калуымны белгертәсем килми. Ә улыбыз турында башта язарга сүз таба алмадым... Нәрсә дип языйм? Синең улың Горюхин Газизҗан Евгеньевич фәлән-фәләнчә үсә, дипме?

—Өч яшьлек сабыйга кем инде Евгеньевич дип дәшә. Чын дөресе малаеның чыраена язылган. Менә очрашырсыз, күрешерсез... Бер күрүдә танып алачак...

"Улы үсеп килгәнен әллә үзем язып җибәрим микән?—дип уйланды Зилә.—Яхшы булыр микән?.."

* * *

Коридорның аргы башыннан каршыга аның килгәнен күргәч, Рәшидәнең күңеле жу итте, тез буыннары йомшап китте. Ник алай? Редакцияләргә халык күп йөри, коридор буш тормый. Кара чәчле, кара свитер кигән ыспай гәүдәле бу ир кеше нәрсәсе белән сискәндерде соң аны?

Менә алар якынлаштылар... Чит-ят бер адәм. Рәшидә аның йөзенә туры карамый гына, керфекләрен аска төшереп, узып китте.

—Рашида ханум!..

Ул тукталып калды. Башын борып карарга куркып басып торды.

—Рашида ханум! Бу сез бит, әйеме?

Ул әкрен генә борылды.

—Әйе... Бу мин... Ләкин... без таныш түгел бит. Мин сезне хәтерләмим.

—Мин Ферганәдән. Сезгә тапшырасы әманәтем бар...

Рәшидә кулларын кая куярга белми уталады. Әманәт... Ләкин нигә бу адәмнең бераз карлыккан тавышы шушы хәтле төшенке? Шомлы хәтта!

—Әйдәгез, бүлмәгә керик.

Рәшидә ишекне ачты. Түр өстәлдән Зилә башын күтәрде, ишектән кергән кешене күргәч, аның да йөзе үзгәреп китте.

—Узыгыз, утырыгыз,—диде Рәшидә.—Танышыйк.

—Мин Фархад. Башкасы мөһим түгел.

Егетнең үткен карашы өстәлдәге фоторәсемгә төбәлде. Кара чәчле малай сурәте иде бу. Фархадның күзләрендә сорау галәмәте чагылып узды. Рәшидә кабаланып рәсемне алып кәгазьләр арасына төртте.

Егет сумкасыннан ак бау белән бәйләнгән төргәк чыгарды.

Рәшидәнең башы әйләнеп китте. Бу— аның хатлары иде.

Зилә урыныннан кузгалып, дәшми-тынмый гына бүлмәдән чыгып китте.

Рәшидә өстәлгә куелган төргәккә кагылырга куркып, хәрәкәтсез утыра иде. Ниһаять ул телен әйләндереп:

—Моны миңа тапшырырга ул үзе куштымы?—дип сорады.

Фархад, сумкасын рәтләштергәндәй, аска ук иелде. Пышылдап диярлек:

—Юк,—диде.—Үзе түгел... Ул өлгермәде.

—Ничек?..

—Әйтәсен әйтергә өлгермәде... Бу төргәк аның биштәреннән чыкты.

—Сез ни димәкче буласыз? Бу ни дигән сүз?

Рәшидә аның кара свитерыннан тотып алып селкергә теләгәндәй, урыннан торып, өстәл аша кулларын сузды. Фархад та торып басты.

—Әйе, ул юк инде... Мин сезгә аның соңгы сәламен китердем.

—Ничек алай?

—Ул минада шартлады.

—Нинди мина? Ферганәдә...

—Анда түгел. Без сугыш узган урыннарны минадан тазарта идек.

—Нинди сугыш? Кайда?

Фархад аның күзләренә туры карады, йөзе кырыс, хәтта каты иде. Сугыш бәрелешләрен узган, дусларының теткәләнеп, парә-парә булып тирә-якка сибелүләрен үз күзләре белән күреп бәгыре таш булып каткан ирләрнең карашына шундый тимер салкыны чыгадыр.

—Сезнең өчен шунысы мөһимме? Без җирне миналардан тазарта идек, аңлыйсызмы? Ул бик оста минер иде. Куллары алтын иде.

—Миналардан...

—Әйе, җирне сөрергә кирәк бит.

Урынсыз сораулар биргәнен, монын Фархадка ошамаганын Рәшидә бик сизә, ләкин зиһене таралган, фикере чуалган, ул фәкать бу егетне янында озаграк тотарга тели, шуңа күрә генә теленә беренче килгән сүзләр ычкына иде. Ниһаять, аның бәгырен бер нәрсә сызып узды:

—Ул бик газапландымы?

—Юк, ул берни сизми калды... Шартлау гына... Гаиләсенә кайтарып тапшырыр алдыннан, без аның әйберләрен карап чыктык. Һәм менә бу төргәкне алып калдык. Ул сезнеке.

—Ул сезгә минем хакта... сөйләдеме?

—Мин сезне ничек эзләп таптым соң?—Фархад өстәлдәге төргәкне икенче ягы белән әйләндерде.—Менә, монда адресыгызны да язып куйган.

Чыннан да, төргәкнең икенче ягында ят кәгазь бите кыстырылган, аңа "Казан, яшьләр газетасы" дип язылган иде.

—Бурычымны үтәдем, әманәтне тапшырдым,—дип, сыгылмалы хәрәкәт белән тураеп басты Фархад.—Шуның белән минем эш бетте.

—Туктагыз... Мин сезне каян таба алам?

—Ә нәрсәгә? Мин биредә үтеп барышлый гына. Шактый зур әйләнеш ясап кердем. Ә ул... гаиләсенеке, балаларыныкы... Хушыгыз.

Күренеп тора иде, бу егеткә Рәшидә ошамады. Газизҗанның сөйләве буенча, ул бөтенләй башка берәүне, гүзәл затны күз алдына китергән булгандыр.

Рәшидә урыныннан кузгала алмады. Куллары гына аның ихтыярын-

нан башка хәрәкәт иткәндәй, төргәкне чиште, өстә яткан кәгазьне алды. Анын эчке ягы язып тутырылган иде. Хәрефләрнең һәркайсы җиренә җиткерелеп, тигез, пөхтә итеп язылган. Рәшидә ручка тоткан кулны, алсу ахак тырнаклы, озын, сыгылмалы, кайнар, көчле бармакларны күз алдына китерде.

"Син мина беренче күрүдә үк күптән, бик күптән таныш кебек тоелдың. Әйтерсең лә, моннан мен еллар элек үк без бер-беребезгә бик якын, бик кадерле булганбыз, тик шушы гомер эчендә, бик кыска вакытка гына онытып җибәргәнбез. Менә хәзер очрашкач, һәммәсе хәтер түрендә янарды. Нигә мин шуларны сиңа әйтә алмадым икән? Әгәр дә без тагын теге кыя түбәсенә менә алсак, мин сине анын иң биек ташына утыртыр идем дә, үзем синең аяк очыңа сузылып ятар идем. Син Мисыр падишасы Клеопатра кебек, гүзәллегең һәм бөеклегең белән кояшлы күккә ашып күренер идең. Учыңны минем баш түбәмә куяр идең. Һәм минем бөтен гамьнәрем тау җиленә очып, күнелем мәнге бетмәс яшәү бәхете белән тулыр иде. Син елмаеп минем күзләремә карар идең... Елмайганда синең йөзең таң аткандагы кебек, әкренләп яктыра. Иң элек иреннәрең нурлана, аннары керфекләреннән дәртле якты сибелә, шуннан соң гына күз бәбәкләреңдә очкыннар уйный башлый. Шул чакта синең йөзеңә караудан да зуррак ләззәт юктыр һәм мин беркайчан да карап туя алмас идем.

Синнән тау җилләренең, ташны ярып чыккан миндаль агачының исе аңкый шикелле. Тауларда үткән балачагымның хушисен сендергәнсең кебек.

Син минем җанымны актарып ташладың. Анын иң тирән җирләреннән мин аңарчы белмәгән яктылык калкып чыкты. Һәм шул ук вакытта күкрәгемә көч-гайрәт, үз-үземә ышаныч инде. Бир кулыңны, наным! Синең кулың, затлы Димәшкъ кылычының тоткасы кебек уңайлы. Ул оясына кайтып кунган карлыгач кебек, учка очып керә шикелле.

Син һәрчак янымда минем, җанымда. Төннәрен ташлы, салкын җирдә ятканда, мин сине күз алдыма китерәм. Теге соңгы кичтәге кебек итеп кенә дә түгел, бөтен төрле рәвешләрдә һәм кыяфәтләрдә... Аннары бөтенләй хәлсезләнеп, көчсезләнеп, минем күкрәгемә башың салырсың кебек. Ә мин синең янында зур, ышанычлы, һәм көчле-гайрәтле...

Ә таң атып, кояш күтәрелә башлагач, үлән сабакларында чык тамчылары янә сиңа охшап җемелди. Шундый ак, пакь, чиста һәм сискәндергеч салкынча. Һәм шулай ук дөньяның яктысын үзләренә җыйганнар."

Хат язылып бетмәгән иде. Күрәсең, аны бүлдереп, кайсыдыр кырны миналардан тазартырга алып чыгып киткәннәрдер. Кемнәрнең туган җире булды икән ул?! Кемнәр туфрагына соңгы тапкыр куллары орынып, каны акты икән?

Бүлмәдә һава бетте, сулыш кысыла башлады. Рәшидә урыныннан кузгалып, коридорга, аннан лифт туктый торган мәйданчыкка чыкты, бер як стенаны биләп торган тоташ тәрәзә янына барып басты. Унынчы каттан караганда, шәһәр урамнары артында, урманлы ярлар арасында җәелеп яткан Идел күренә. Елга аръягындагы сөзәк таулар өстенә сирпелеп, шәфәкъ уты яна. Өзек-төтек болытлар карасу-кызгылт төсләргә манчылган. Офык сызыгы тирәсендә күк гөмбәзе ярылган кебек...

"Дөнья яраланган... Җәрәхәте ай-һай зур... "—дип уйлады Рәшидә.

## ЭПИЛОГ

Әнә ул, бөркет кебек, кыя түбәсенә менеп баскан. Нәрсә күрмәкче, ни эзли ул аннан—елга аръягындагы томан өртелгән яшел урманнар артыннан? Нигә аяк астына карамый?

—Сике-ер-р!—дип кычкыралар Идел уртасыннан.

"Тукта! Чиген!"—дияргә тели Рәшидә. Ләкин тавышы җил булып бәрелер дә, аны этәрер дип, сулыш алырга да куркып, тынсыз басып тора.

Аһ, күпме тапкырлар шушылай өнсез итте инде бу бала! Кечкенәдән җитәкләп урамга чыксаң, кулдан ычкынып кая да булса югалу ягын гына карый иде. Эзләп җаннар чыга торган иде.

Мәктәптә һаман әйтеп киләләр:

—Рәшидә ханым, бу сезнең малай түгел,—диләр.—Кешелек баласы ул, галәм кешесе. Күрегез дә торыгыз, сезнең янда утырмаячак, сәяхәтче булачак.

Күз төпләрендә чагылган тынгысыз ут, эчендә кайнаган хисләр аны һаман каядыр еракка, офыклар артына чакыра.

...Тауны әйләнеп менә торган сөзәк сукмак бар. Ләкин аннан озак барасы. Рәшидә ташларга абына-сөртенә үргә таба йөгерде. Куллары белән кызыл балчык кантарларына ябышып, өскә үрмәли башлады.

Үр текә, балчык тотрыксыз иде, ул бераз менә дә бәләкләрен, тезләрен сыдырып, кире шуып төшә. Шундук торып баса да, тагын үргә үрмәли:

—Балам... Бердәнберем... Газизем...

Ә дәртле тавыш Иделне иңләп, кыяның текә күкрәгенә бәргәләнеп, тагын-тагын кайтаваз булып яңгырый:

—Сике-е-ер!

*2002-2003 еллар.*

---

## КИЛӘСЕ ЕЛДА ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

"Асаф Зәкиевнең комсомол өлкә комитетына килеп эшли башлаган елы гына иде әле. Шәһәр яшелчә базасына кәбестә бушатырга барган җирдән кайтканда, һич көтмәгәндә, Суфия уенын-чынын бергә кушып: «Бик туңдык, әллә безгә кереп чәй эчеп алабызмы?»—дигән тәкъдим кертте. Өч егет, ике кыз бу тәкъдимне «ур-ра!» кычкырып каршылады. Бер кергәч җәелеп кенә чәй дә эчтеләр, Фазыйла апаларының бөркет күзе астында кайнар аш та ашадылар. Фазыйла өч егетнең өчесен дә бөртекләп, тикшереп утырды һәм иптәшләре таралгач Суфияга болай диде:

—Син бу Асаф дигән егетне күптәннән беләсеңме?

Анасының юкка гына сорамавын чамалаган кыз кызарынып:

—Һәй, авыл мокыты ич ул! Җитмәсә миннән дүрт яшькә кечерәк тә әле.

—Әткәңнең миннән алты яшькә икәнен онытма!.. Менә сиңа шул: иплә кенә ул малайны кулга ияләштер. Аннан күз күрер.

Бер ел дигәндә Асаф Суфияга өйләнеп, атаклы Кәримҗанның кияве булып бабай йортында яши башлады.

Кәримҗан Сәфәргалимовның өлкә комитетында эшләгән бик абруйлы чагы, биш баланың кайсы кайда, төшемле, матур урыннарга урнашкан, аралашкан, йөрешкән кешеләре дә менә дигән, сирәк кенә булса да мәҗлестә Үзе белән очрашкалыйлар.

Асаф Сәхипович шомарды, кашык-чәнечке тотарга өйрәнде, Кәримҗан ярдәме белән елдан-ел позициясен ныгытып, өскә үрли барды. Бәйрәмнәрнең берсендә, аерата тантаналысында, Суфия белән Асаф җизнәләре аркасында бик сирәк кешеләр генә эләгә торган, мөһим бер мәҗлескә эләктеләр. Мәҗлескә Үзе дә килгән иде. Шунда Үзе Асафка карап-карап торганнан соң йорт хуҗасыннан «Бу кем?» дип сорады. Аңа «Бүлектә инструктор булып эшли» диделәр. Үзенең кашы җыерылды. «Нигә инструктор гына? Куегыз Курамшинның урынбасары итеп!» диде. «Аның болай да урынбасарлары биш» диделәр аңа. «Яңа штат табыгыз, мин инструктор белән бер мәҗлестә утыра алмыйм ич!» диде катгый итеп Үзе...

Асаф Зәкиев министр урынбасары булды".

*Бу өзек күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы **Аяз Гыйләҗевның "Кылдан нәзек, кылычтан үткен"** исемле язылып бетмәгән романыннан алынды. Аны редакциябезгә мәрхүмнең хәләл җефете Нәкыя апа нәни генә кереш сүз дә язып китерде. Анда мондый юллар бар: "Карчык, мин бу әсәрне бик тирән мәгънәле әсәр булыр дип өметләнәм, савыгып җиту белән язып бетерермен",—ди торган иде Аяз. Әмма ул язылып бетмәгән көйгә калды. Соңгы айларда аның бу кулъязмасын алып елый-елый укып утырдым да: "Никадәрле гыйбрәтле вакыйгалар, мәгънәле фикерләр бар бу әсәрдә",—дип, "Казан утлары" журналына тәкъдим итәргә булдым. Журнал укучылар да бик яратыр дип уйлыйм..."*



## Әхмәт Рәшит

**И ЗАМАН!..**

### Каршылау идиллиясе

**Тып-тын әле һава аланы—
Очкычлар һәм боргалаклар тын,
Офык буйлап сыза таң—нурын;
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы—
Тып-тын әле һава аланы.**

**Очкычлар һәм боргалаклар тын.
Таң рәсемен ясыйм—ул гүзәл;
Катыштырмый гына чит сүзләр,
Әйт сурәтнең сихри чынлыгын.
Очкычлар һәм боргалаклар тын.**

**Офык буйлап сыза таң—нурын,
Көн туар да, гүләр бар алан—
Ярым кайтыр ерак юллардан,
Ярларыннан ташыр шатлыгым,—
Офык буйлап сыза таң—нурын.**

**Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы,
Күңелләрнең сүндер сагышын—
Татлы булсын безнең кавышу,
Мәхәббәтен сөйлә син аның—
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы.**

**Тып-тын әле һава аланы—
Очкычлар һәм боргалаклар тын,
Офык буйлап сыза таң—нурын;
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы—
Тып-тын әле һава аланы.**

---

Әхмәт РӘШИТ (1936)—*шагыйрь, публицист; "Таң илчесе", "Ике гасыр арасында", "Фидаиләр" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Кошлардан көнләшәм

Ак болытлар оча. Безнең дә бит
Болытлардан өстә бар очкан.
Ләкин хыял чикле: бу җиһанда
Җир белән Күк сирәк кавышкан.

Очар кошлар бездән бәхетлерәк:
Күкләр канат биргән, көч биргән—
Җитәкләшеп җитез җилләр белән,
И! тәм таба алар очудан.

Аэродинамика дигән фәнне
Үзләштергән алар гомерлек,
Ә без исә, уздырмакчы булып,
Әллә кордык, әллә җимердек.

Без очкычлар уйлап тапкан булдык,
Ракеталар менде галәмгә,
Тик металлга сеңгән энергия
Бик аз ярдәм итте адәмгә.

Без Кояшка Икар булып очсак,
Балавыз күк хыял эреде;
Әле ярый, егылып төшкән чакта
Сөякләрне җыйган—җир иде.

Без—табигать падишасы, диеп
Мактанудан юктыр файда да.
Мин карлыгач булып, лачын булып
Очар идем әллә кайларга.

Кошлар оча. Оча бар тарафка,
Язын—төньяк, көзен—көньякка;
Кошлар—иреклеләр. Тукталу—юк,
Чикләр буйлап читән корсак та.

Ак болытлар оча. Кошлар оча.
Кешеләр дә кайчак еш оча.
Тик нигә соң, менгезмәскә теләп,
Күк Җир белән һаман тартыша?

Чиксезлекнең чиген эзләр өчен
Җирдән Күккә юкса кем дәшә?!
Кимсетүем түгел кешеләрне,
Мин кошлардан фәкать көнләшәм.

## Паровозлар белән хушлашу

Кыр казлары кебек тезелгәннәр,
Кыр казлары кебек моңсулар...
Хәтерләтеп ерак яшьлегемне,
Ник кузгалды әле ымсулар?

Ник кузгалды иске сөенечләр,
Ник яңарды иске яралар?
Кая әле болай, кая әле
Тезелешеп китеп баралар?

Көпчәкләрнең тигез тыкылдавын
Соңгы тапкыр тоеп тимердә,
Паровозлар белән тимер юллар
Саубуллаша бакый гомергә.

Казаннарда инде пар көче юк,
Мартеннарга соңгы юл озын.
Ишетәм күк тимер чапкыннарның
Тәннәремә сеңгән ым-сүзен.

Себер якларыннан Төркестанга,
Төркестаннан кабат Себергә—
Каршысына авыр сынауларның
Минем ашкын яшьлек йөгергән.

Бу замана өчен без дә инде
Иске паровоз күк искедер—
Ә күңелгә һәммә хатирәләр
Ямансу хис бары өстидер.

Юл читенә басып карап торам,
Ә күңелдә шундый моң, сагыш.
Таныш паровоз күк сузып-сузып,
Ерак калган яшьлек, бир тавыш.

## Туплар тынып торганда

*Сугыш ветераннары истәлегенә*

Таң эленгән каен башларына,
Яңгыратмый бүген туп җирне;
Тик былбыллар сайрый үзәк өзеп,
Тик кәккүкләр саный гомерне.

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк—
Уйлар кочагында калыйм бер,
Еллардагы газиз туганнарны
Сагынып ла искә алыйм бер.

Яу кырында дуслар ятып калды
Әле кичә генә, таң тугач;
Йөрәгемдә әллә ничә яра—
Юат мине, юат, сандугач!

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк—
Тынлык тансык шомлы юлларда.
Сана, кәккүк, сана гомеремне,
Тик кайгылы хәбәр юрама!

Кайтасым бар туган якларыма—
Көтә мине газиз кырларым;
Исән калсам, илдәшләрем белән
Шатлык көен генә җырлармын.

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк—
Җиңү көнен күрер җир кайда?
Сагынадыр мине, сагынадыр
Кырлар алиһәсе тургай да.

## Соңгы юлга озатканда

*Үлгәннәрдән ирләр үч алмый.*
*Рәшит Әхмәтҗанов*

Ул көлми дә, еламый да инде—
Чыраенда салкын битарафлык;
Китеп бара теге дөньяларга,
Бу дөньядан инде тәмам арып.

Ул утлар һәм сулар кичкән иде,
Байтак иде орден-медальләре—
Мендәрчекләр ягына карый-карый
Күккә чөеп мактадылар аны.

Рәнҗеткәндер бәлки кемнәрнедер,
Кемнәргәдер гадел булмагандыр—
Изге гамәлен дә, гөнаһын да
Нәнкир белән Мөнкир язып алыр.

Тормыш юлын искә төшерәләр,
Табут тирәсендә тып-тын калып;
"Яхшы кешеме?.."—дип сорадылар,
"Яхшы иде..."—диде килгән халык.

Безнең хөкем—безнең хөкем инде,—
Үлгәннәргә бәя һәрчак уңай.
Онытабыз кайчак бер чынлыкны:
Соңгы сүзне әйтә фәкать Ходай.

## И заман!

Заманы шундый (Нишлисең?!),
Шәрехләпниләр языйм?!
Шулай да ахмакны "ахмак"
Дип тукый тору лязем.

Син "ак" дисең, ул "кара" дип
Гел үзенчә сукалар;
Дәлилләрме? Фәнниләрме?—
Аның өчен юк алар.

Ахмакка тинтәк ияргән,
Тинтәккә тиле-миле;
Әйтегезче: кай тарафтан
Исә бу афәт җиле?!

Монафыйклар басты илне—
Тыярмын, димә һич тә;
Бер үк бизмәндә үлчәнә
Фәрештә дә, иблис тә.

Язганда "Локман Хәким"ен
Исхакый атлы даһи,
Шундый көн килер заманны
Күздә тоткан, билләһи.

Без күрәсен, йә, кем күрсен—
Ходай, дибез, язгандыр;
Бу—кылынган гөнаһларга
Тарихи бер җәзадыр.

Заманга сылтарсың да бит—
Аны да фашлыйсы бар.
Намусың ваклап сатмыйча
Шул җирдә яшисе бар.



## Эльмира Шәрифуллина

### ЕЛ ӘЙЛӘНӘ ГҮЗӘЛ БУЛУ

### Читтә яшәүче татарлар җыры

Ерак илләрдән,
Торган җирләрдән
Кайтабыз сиңа , и гүзәл Казан!
Сагыну хисе,
Тартылу көче
Кузгата юлга, и гүзәл Казан!

Әллә язмышлар,
Әллә ялгышлар—
Иленә илткән безне ятларның...
Әмма син, Казан,
Гел нурлы Казан—
Изге Ватаны һәммә татарның.

Ана телебез,
Тамыр җебебез
Безне бер итә, безне зур итә.
Зирәк кызларың,
Гаярь улларың
Дан-дәрәҗәңне еракка илтә.

Күңел күзебез,
Дога-сүзебез
Төбәлгән сиңа, и гүзәл Казан!
Кайтып күрешсәк,
Сәлам бирешсәк,
Көч-дәрт алабыз, и гүзәл Казан!

### Мәхәббәтем чәчәк атты

Үләннәрдә чык тамчысы,
Үләннәрдә чык тамчысы—
Таң кызының күз яшьләре.
Төн егете, ник елаттың?
Төн егете, ник агыздың
Таң кызының күз яшьләрен?
Сорау бирә сердәшләре—
Ник коела күз яшьләре?

Гөлдә энҗе бөртекләре,
Гөлдә энҗе бөртекләре—
Таң кызының күз яшьләре.
Төн караңгы, уйлар якты,
Төн караңгы, уйлар якты,
Хәйран калды сердәшләре—
Алар шатлык күз яшьләре,
Алар шатлык күз яшьләре.

Төн караңгы, уйлар якты,
Төн караңгы, уйлар якты—
Мәхәббәтем, сөю хисем
Таң гөлендә чәчәк атты!

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА–*шагыйрә, "Яңгыр җиле", "Зәңгәр энҗе" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Кил, офык

Мин җирдә бары кунак...
Җитәрмен, дип, йөгерәмен,
Офык, син нигә ерак?

Дәүләтем—куыш-торак.
Ымсындыра зәңгәр җилең,
Офык, син нигә ерак?

Йөрәгем тора тырнап...
Колачымны җәеп чабам,
Кил, офык, үзең зурлап!

## Нурчишмәм

Карап торам, хәйран калам,
Суларына тәңкә салам,
Тәңкәле су—сучишмәм.
Көмеш суда чагыла нур,
Көмеш суда агыла җыр—
Җырчишмәм син, җырчишмәм.

Салкын суың кулга алам,
Тып-тып тамчың телгә тама—
Балчишмәм син, балчишмәм.
Тәннәргә сихәтең сеңә,
Җаннарга җылың йөгерә—
Җанчишмәм син, җанчишмәм.

Җирнең җәйге кочагында,
Кызның моңсу курчагыдай,
Чүгәлим, тик җир ишмәм.

Моңлансам да синең кебек,
Горур калам дәртең күреп,
Сүз тишсәм дә, сер чишмәм.

Көч-гайрәтең, кара, нинди,
Миндә дә ут, ялкын көйри—
Туган чишмәм, җирчишмәм.
Тибеп, бәреп чыгасың ич,
Актарылгач тонасың ич—
Сафчишмәм син, сафчишмәм.

Уйлап торам, хәйран калам,
Суларыңа тәңкә салам,
Тәңкәле су—сучишмәм.
Көмеш суда агыла җыр,
Көмеш суда чагыла нур—
Нурчишмәм син, нурчишмәм!

## Сөйгәненнән киткән ярлар...

Сөйгән яры белән кеше
Кыя-тауга тиң булыр.
Сөйгән ярсыз калган кеше
Моңсу булыр, ким булыр.

Сөйгәнеңнең сулышы да
Сихәт булыр, им булыр.
Сөйгәненнән киткән ярлар...
Фәхешләргә җим булыр.

## Бурыч

Ап-ак дөнья,
Яшел бизәк...
Кар түбәле тау—яшьлектә
Була сөзәк.

Кыш та кирәк,
Җәй дә кирәк:
Картлыгыңда яшел калу—
Ай-һай сирәк.

Зәмһәрир кыш,
Яшел—ылыс:
Ел әйләнә гүзәл булу
Синең бурыч!

## Йолдыз Хәлиуллин

# ДИПЛОМАТ ЯЗМАЛАРЫ

*Казандагы "Мәгариф" нәшрияты 2001 елда Йолдыз Хәлиуллинның "Восток глазами дипломата" дигән китабын бастырып чыгарды. Исеменнән күренгәнчә, китап рус телендә язылган. Күләме—15 табактан да артык, әмма тиражы бары тик 1000 генә данә.*

*Йолдыз Хәлиуллин—бик кызыклы шәхес. Ул биш-алты чит тел белә, татар дипломаты (мөселман) булганлыктан, унбиш елдан артык, нигездә, шәрекъ илләрендә хезмәт итә.*

*Йолдыз Хәлиуллинның әлеге китабын татарча тулысы белән журналыбызда чыгару мөмкинлеге булмаганга күрә, без аның аерым өзекләрен Марс Шабаевның иректе тәрҗемәсендә укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык.*

* * *

*Шәһәрдә авылныкы мин,*
*Авылда—шәһәрнеке.*
*Чит илләрдә йөргән чакта—*
*Туган газиз илнеке.*

Равил Фәйзуллин.

ЕГЕРМЕНЧЕ гасырның соңгы елын мин Алма-Атада Россия илчелегенең Казакъстандагы өлкән киңәшчесе сыйфатында каршыладым. Аңа кадәр дә байтак кына шәрекъ илләрендә унбиш елдан артык дипломатлык хезмәтендә булдым.

Шунысын да искәртеп китим: дипломатлар чит илләрдә эшләгәндә ике-өч төрле халәт кичерергә тиеш була. Үз ватандашлары арасында ул үз иле тормышы белән яши, үзе илчелек хезмәте башкарган илдә шул илнең гореф-гадәтләренә, тормышкөнкүреш шартларына яраклаша һәм, ниһаять, бик күп илләрнең вәкилләрен берләштергән дипломатлар арасында дипломатик корпус тормышы белән яши. Димәк, ничек кенә булмасын, илче-дипломат һәрвакыт махсус оешмаларның—"үзебезнекеләрнең", "читләрнең" һәм "бөтенләй безгә ят-дошман булганнарның" да сынаулы күзәтү карашларын тоеп, шуны һич тә исеннән чыгармыйча яшәүче бер шәхес ул. Әнә шул катлы-катлы тормышта әз генә хилафлык җибәрдеңме—бик тиз һәм гомерлеккә андый хезмәтеңнән хушлашасың. Шунлыктан, байтак кына шәхесләр, ул басымга чыдый алмый, сынып та киткәли.

Әнә шул күтәрә алмаслык "йөгемнән" котылып, әлеге хезмәтемнән отставкага китү белән, озын-озакка сузып тормыйча, үзебезнең Иске Кызыл Яр авылына кайтып киттем. Бары тик шунда гына соңгы кырык ел эчендә үземне беренче тапкыр чын мәгънәсендә иректе кеше итеп тойдым.

Нәкъ менә туган-үскән якларымны кайтып күрү мине шундый фикергә этәрде: болай еракта яткан тын татар авылыннан карап уйланганда, инде узып бара торган

гомернең бөтен "чатак-ботакларына" тыныч кына аек күңел белән карау бик кызык икән әй!

Чаж елгасы ярына терәлеп үк диярлек утырган безнең Иске Кызыл Яр авылы гаҗәп матур. Елга аръягында зур гына удмурт авылы Сарсак-Омга да бар. Безнең авылның "түбән очы" аларның язын су баса торган болыннарына барып төртелә. Елга исә, бераз түбәндәрәк кинәт кенә көньякка борыла да, авылның елга ярыннан утыз метрлар биектәрәк булган Шарламай тавын әйләнеп уза.

Әнә шул Шарламай тавыннан бер өч йөз метрлардадыр безнең төп йорт тора. Ул безнең нәсел-нәсәпнең бик борынгы оясы: шул ук нигездә бабам Хәлиулла йорты да булган, соңгысын уллары узган гасырның утызынчы елларында салганнар. Хәзер инде бирегә беркем дә яшәми, ә юкса әле тагын ике-өч дистә ел торырлыгы бар. Мин читтә йөргәндә ишегалды үзгәреп беткән, коебыз юкка чыккан, хәзер анда карлыганкура җиләге куаклары гына үсеп утыра. Пенсиягә чыккач, әтием утырткан алма-балан агачлары галәмәт булып үсеп киткән икән. Әмма аларны караучы-тәрбияләүче булмаган: кыргыйланып беткәннәр.

Янбакчада исә әле бабам үзе утырткан агачлар да сакланып калган. Андагы шомырт һәм юкә агачлары ел саен тирә—юньне хуш искә күмеп утыралар. Ул янбакчаның яртысын диярлек чия куаклары биләп алган.

Мин үзем атаклы "Сталин конституциясе"н кабул иткән 1936 елда колхозчы крестьян гаиләсендә туганмын. Дистә ярым елларым ваемсыз гына балачак бәхете белән әнә шул татар авылында үткән. Гаиләбез зур һәм тату иде: ашарга утырганда өстәл янына ун кешедән дә ким утырмыйбыз (әби, киленнәре белән өч улы, ике сеңелем белән мин). Өстәл тирәсендә һәркемнең үз урыны бар. Иң түрдә—өлкән абзыебыз Мулламөхәммәт, аның уң ягында—минем әтием Нурмөхәммәт, сул ягында—кече абзый Хуҗамөхәммәт. Дүртенче хөрмәтле урында—әбием, аннан соң инде яшьләре тәртибендә киленнәре—Зәкия, әнием Хаҗәр, Гүзәл. Иң кырыйда без—өч бала.

Әти-әниләрем һәм калган туганнарым турында тәфсилләп русча китабымда язган идем инде, биредә аларны кабатлап тормастан, "үгезне мөгезеннән алу" кирәктер, юкса сүз бик озынга китәргә мөмкин.

* * *

Такташ әйтмешли, минем "дөнья белән танышулар" газет-журналлар аша булды. Китаплар, ничектер, икенче чиратка калып тора иде. "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналының чираттагы санын зур түземсезлек белән көтеп алам, аны кат-кат укыйм. Сүз уңаеннан, әйтеп үтим—кайсы илдә генә булсам да, мин бу журналны яздырып ала килдем: Джакартада, Карачида, Бухарестта, Коломбода яки Катманduда һәрвакыт өстәлемдә яраткан журналым булыр иде. Бу мавыгуым 1965-1966 елларда беренче тапкыр чит илгә командировкага—Индонезиягә баруымнан башланды. Халыкара бәяләр белән алдырганда журналның бер саны миңа ун доллар чамасына төшә иде. Ә ул заманнардагы хезмәт хакым—айга бер йөз доллар гына! Җаны теләгән—елан ите ашаган, диләрме әле? Менә минем дә җаным-рухым "Казан утлары" журналын тели иде.



*Япониядәге «Тойота» компаниясе вице-президенты белән очрашу вакытында. Катманду, 1992 ел.*

"Газет-журнал чире" соңыннан илчелек хезмәтемдә бик ярап куйды миңа. Тышкы сәясәт ведомствосында хезмәт иткән елларымда эш сәгатьләрем һәр көнне иртәнге газетларны карап чыгудан башлана иде. Инде кырык ел шул гадәтемә хыянәт иткәнем юк. Мәскәүнең Смоленск мәйданындагы Тышкы эшләр министрлыгында үзәк аппаратта утыраммы, чит илләрдәге илчелек оешмаларында яки генераль консуллыкларда мы—һәрвакыт өстәлемдә газетлар булыр иде. Пакистанда эшләгәндә (мин анда ун елга якын хезмәт иттем) кирәкле мәгълүматларны эзләп һәр көнне 20-30 минут дистәләрчә Пакистан, Америка, Һиндстан, Россия газетларын карап чыгарга туры килә иде. Ул елларда бит әле бернинди миникомпьютерлар да, хәзерге электрон мәгълүмат чаралары да юк иде. Әмма ләкин Үзәк бик нигезле рәвештә бездән аналитик һәм вакыйгаи мәгълүматларны

таләп итеп кенә тора. Чөнки андый мәгълүматлар теге яки бу ил белән ике арадагы күпкырлы багланышларга кагылышлы карарларны кичекмичә кабул итү өчен бик кирәк була.

Шул уңайдан бер вакыйганы искә төшереп узыйм әле. Алтмышынчы еллар азагында Пакистанда эшләгәндә булды бу хәл. Мин СССР илчелегендә хезмәт итә идем. Советлар Союзы илчесе Михаил Васильевич Дегтярь, мине телефон аша кабинетына чакыртып алды да, бер атна вакыт эчендә махсус бер белешмә әзерләп бирергә кушты. Ул белешмәдә Пакистандагы сәяси тормышта оппозицион көчләр һәм партияләрнең нинди урын тотуларын күрсәтергә кирәк иде. Әгәр бу документны алданрак әзерләсәм, илче ул хакта үзенә телефоннан хәбәр итүемне сорады. Аннары М. В. Дегтярь тагын бер кечкенә мәсьәләне хәл итәсе барлыгын әйтте: аның өчен минем Йолдыз Нуриевич Хәлиуллин булуым сәеррәк тоела, ул "Йолдыз Нуриевич" дип әйтергә кыенсына икән. "Әгәр дә мин сезне русчага яраклаштырып, "Юрий Николаевич" дип йөртсәм, каршы килмәссездер бит",—дип тәмамлады ул үзенең сүзен. Мин, нәрсә әйтергә дә белмичә, шактый озак басып тордым. Илче мине ризалаштырдым дип уйлады булса кирәк. "Барыгыз, эшләгез",—дип сөйләшүгә нокта куйды. Минем эчемдә үпкә—рәнҗеш кайнаганын каян аңласын, ди, инде ул?

Мин ул сораган белешмәне ике көндә әзерләп бетердем. Илчегә телефоннан шылтыраттым:

—Миңнәхмәт Вәлиәхмәтович! Сез сораган белешмә әзер,—дидем.

Озак кына дәшми торганнан соң илче сорый:

—Ә кем белән сөйләшәм әле мин?

—Минем белән, иптәш илче. Сезнең исемегез һәм атагызның исеме минем туган татар телемдә шулай яңгырый,—дидем.

Ул телефон трубкасын шалт итеп ташлады...

Мин әле ул чакта дипломатлык баскычының иң түбән дәрәҗәсендә—бары тик атташе гына идем. Әлбәттә, илче белән шулай тупас сөйләшүем эзсез генә узып китмәде. М. В. Дегтярь миңа чираттагы дипломатик дәрәҗә—өченче секретарь дәрәҗәсен бирүне ике елга тоткарлады.

Шулай итеп, теге әрсезлегем кыйммәткә төшсә дә, мин үз дигәнемә ирештем—дипломатик компромисс-килешү табылды тагын. Шуннан бирле илче миңа "иптәш Хәлиуллин" дип кенә дәшә торган булды, ә мин аңа каршы "иптәш илче" дип кенә җавап бирә идем.

* * *

Балачакта минем өчен барлык кешеләр дә ягымлы-яхшы булып күренә иделәр. Үзара малайлар белән талашкан—әрләшкән чакларда да мин тизрәк ызгыш-талашны сүндерергә тырыша идем. Үсә бара торгач бу алсу томаннар эреп юкка чыкты. Кешеләрнең үзара тискәре-кире мөнәсәбәтләре, бигрәк тә ул дипломатлар арасында булса, миңа бик кыен була торган иде. Иң беренче шундый "дәресне" миңа Лев Скрябин—элекке тышкы эшләр министры В. М. Молотовның туганнан туган энесе күрсәтте. Ул үзе безнең илчелекнең Индонезиядәге вице-консулы иде. Ничектер бервакыт ул мине машинада аэропортка илтеп куярга булды, мин Явадан Калимантанга очарга тиеш идем. Бер сәгатьлек юлның буеннан-буена илле яшьләрдәге бу адәм катлы-катлы сүгенеп, кычкырынып барды. Чөнки шәрекъ илләрендә транспортның рәтле-башлы йөргәне юк. Дипломатлар вәкиле ачуын таксистларга, рикшаларга түгә, аларны, машиналарга утырган маймыллар дип, тетмәләрен тетә.

Илчелек—ул чикләнгән биләмә, анда хезмәт итүчеләрнең кире яки уңай сыйфатларын бик тиз ачып салалар. Тышкы яктан бер-берсенә тартылучы гаиләләр якыная, дуслашып китә. Әмма еш кына аларның аралары суына–бозыла. Кайберәүләр бу очракта үзләрен аклап, башкаларны яманлый башлый. Әле кичә генә дус булып йөргән иптәшләре турында төрле гайбәт тараталар, элекке дустының кемнәрдер турында бары тик аңа гына ышанып әйткән сүзләрен дә тышка чыгаралар.

Хатыным белән без андый "дуслыклардан" ерак булырга тырыштык, барысы белән тигез мөнәсәбәттә яшәдек. Чит илләрдә гадәттән тыш шартларда эшләгәндә, минемчә, шунсыз мөмкин дә түгелдер. Шул ук вакытта без үзебез булган илләрдә җирле халык арасыннан кирәкле кешеләрне табарга тырыштык, аларның милли гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карап, матур гына гаилә мөнәсәбәтләре урнаштыру ягын карадык. Без шундый кешеләр белән аралашудан күбрәк шатлык һәм рәхәтлек ала идек.

* * *

1951 елның җәендә җидееллык белем таныклыгымны кесәмә салып, туган өемнән чыгып киттем. Өйдә киңәш-уңаш иткәннән соң, армия хезмәтенә алынганга кадәр, миңа нинди дә булса һөнәр үзләштерергә кирәк, дигән карарга килдек. Вакыт кысан булганлыктан, мин урта белемле һөнәр генә сайлый ала идем. Нинди һөнәр

икәнен үзем хәл итәргә тиеш булдым, ә барасы җирем, әлбәттә, Казан иде. Мин төрле техникумнарга керү шартлары басылган барлык газеталарны тупладым. Казанда урта техник белем бирә торган техникумнар барлыгы 14 икән. Мин үземә техник-электрик һөнәрен сайладым.

Җидееллык мәктәпнең отличнигы булганлыктан, мине имтиханнарсыз гына Казан механика-технология техникумының электромеханика бүлегенә алып та куйдылар.

Техникум шәһәрнең бик матур бер почмагында—Кабан күле буенда урнашкан иде. Тулай торагы да янәшәдә генә. Мин шунда яшәдем.

Мин һәм минем кебек авылдан килгән курсташларым өчен иң авыры беренче елыбызның беренче семестры булды. Чөнки барлык фәннәр рус телендә укытыла, ә без русчаны әле ипи-тозлык та юньләп белмибез. Кая инде анда теоретик электротехника һәм югары математика фәннәрен русча өйрәнү! Шуңа күрә беренче сессия имтиханнарыннан соң ук татар мәктәпләреннән килгән отличникларның унбишеннән Илдар Сәетборһанов белән мин генә торып калдык. Илдар—Казан малае иде. Мин үземә шундый максат куйдым: беренче сессия имтиханнарын бары тик "яхшы" һәм "отлично" билгеләренә генә тапшырырга! Биш имтихан бирергә кирәк иде, минем өчен иң авыры, әлбәттә, рус теленнән диктант язу. Шунда бер-беребезгә ярдәм итешү турында янәшәмдә утыручы Герман Линсцер белән сүз куештык. Ул минем диктантымдагы хаталарны төзәтергә булды, ә мин аңа математика белән физика мәсьәләләрен чишәргә булышам. Безнең бу хезмәттәшлек уңышлы чыкты: диктанттан мин "яхшы", ә Герман "отлично" билгесе алды, ә математикадан, киресенчә, Германга—"яхшы", миңа "отлично" куйдылар.

Рус әдәбиятыннан имтихан бирергә мин "Евгений Онегин" поэмасыннан берничә өзек ятлап кергән идем, укытучыбыз Фаина Павловна Шкляева Пушкинның әдәби алымнарындагы үзенчәлекләре, аның уңышлары турында сорый. Һәр соравына берәр өзек кенә укып җавап бирә бардым. Җавапларымның күбесе куелган сорауга еш кына туры килмәсә дә, яттан сөйләвем Пушкин поэмасын тулысынча яттан белгән Фаина Павловнага уңай тәэсир итте, күрәсең. "Хәтерегезне рус классикасының иң яхшы әсәре белән баетуыгыз өчен сез "яхшы" билгесенә лаексыз",—диде. Шуннан соң мин рус телен тагын да тырышыбрак өйрәнә башладым.

Алга таба башка андый четрекле хәлләр булмады, хәтта соңгы ике елымны югары стипендия алып укыдым. Әмма икенче кимчелегем килеп чыкты: уртача гына укучылар рәхәтләнеп үзләренең сәләтләрен күрсәтә алган практик дәресләр миңа бер дә кызык түгел иде. Токарьлык эше, капиталь ремонт һәм асинхрон двигательне сүтеп урау кебек эшләрне бик авырлык белән генә "яхшы" билгесенә тапшырдым. Кыюсыз гына шундый нәтиҗәгә килдем: техник-электрик һөнәре минем өчен түгел икән...

Газетлардагы яңалыклар белән танышып баруым мине матбугатка этәрде. КПСС өлкә комитетының төп матбугат органы булган "Совет Татарстаны"нда зур булмаган берничә мәкалә һәм хәбәр бастырдым. Моның башлангычы Татар академия театрында "Галиябану" спектаклен караганнан соң булды. Без студентлар галеркасында—түшәм астында ук утыра идек. Күзем йөзләрчә пәрәвезгә чорналган люстрага төште. Мин аны янымдагы иптәшемә дә күрсәттем. Буфеттагы ыгы-зыгы, бер исерек тамашачының залдан кычкырынып утыруы һәм тагын кайбер кимчелекләр—һәммәсе тәнкыйть мәкаләмдә тезеп күрсәтелгән иде. Бүлмәдәшем Ибраһим бу гамәлемне буш эшкә хисаплады, барыбер басмаячаклар, диде. Ләкин мәкаләм басылып чыкты, әле алай гынамы соң?! Мәкаләмне КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлегендә укып тикшергәннәр, махсус карар да кабул иткәннәр. Театрда партия җыелышы да үткәрелгән. Йа, Хода, үз гамәленең шундый нәтиҗәләр китереп чыгарасын белгән булса, 16 яшьлек студент үзе сокланып йөргән талантлы артистларны бимазалар—борчыр идеме соң?!

Миңа айлык стипендиямә караганда өч тапкыр артыграк гонорар—каләмхак түләделәр.

Ибраһимны ресторанга чакырдым. Ул, моның ни өчен эшләнгәнлеген белмәгәнлектән, әдәп йөзеннән үзе дә бер "бишлек" кыстырып килгән, мин аның юка бумажнигын этәрдем дә, газеттагы мәкаләне күрсәттем, мәкалә астында икебезнең дә исем-фамилияләрне күреп, аның исе китте.

Шул көннән башлап миңа "язучылык җене" кагылды, кайда гына, нинди генә хәлләрдә булсам да, каләмгә тотына башладым. Армиядә хезмәт иткәндә, Мәскәүдәге үзәк газеталарда да берничә мәкаләм басылды. "Советская авиация" газетының беренче битендә үк Н-нче хәрби-техник частьнең офицерлары һәм солдатларының күтәренке хис белән Советлар Союзының беренче ясалма Җир юлдашына хезмәт күрсәтүләре турындагы мәкаләм чыкты. Ул мәкаләмә минем өчен гаять зур булган каләмхак түләделәр, аның акчасын мин бик кызык кына исраф иттем: атом-төш физикасындагы иң яңа тикшеренүләргә багышлап үткәрелгән ниндидер халыкара махсус фәнни конференциянең унтомлык басмасын сатып алдым. Шунысы гаҗәп, берничә ай эчендә мин ул томнарның барысын да укып та чыктым. Табигый ки, алардагы

терминнарның байтак өлешенә һәм югары математикадан китерелгән хисапсыз тигезләмәләргә минем тешем үтмәде, әйтерсең лә, аларниндидер чит-ят телдә язылган иделәр.

Төрле илләргә озаграк командировкаларга йөргәндә дә җирле матбугат белән элемтәгә керә идем. Бары тик Румыниядә үткәргән дүрт елым гына, Н. Чаушеску режимы чорына туры килеп, андагы матбугатка барлык чит ил кешеләренә, бигрәк тә дипломатларга юллар ябык иде. Иҗади яктан караганда, иң уңышлы елларым Пакистанда эшләгән вакытыма туры килә. Урду телендә язылган күпчелек чыгышларым гадәттә җирле хәбәрчеләр тарафыннан абруй-дәрәҗәле газетларда бирелә, кечке газетларда исә аларның кыскартылган яки үзгәртелгән вариантлары басыла иде. Минем өчен иң мөһиме шунысы булды: берничә журналда, шул исәптән, АПН басмасы "Тулу"да, Г. Тукай белән М. Җәлил шигырьләрен урду һәм инглиз телләренә тәрҗемә итеп бастырдым. Шулай ук татар прозасы аксакалы Әмирхан Еникинең дә бер хикәясен Пакистан дәүләт телендә бастыра алдым. Аксакалның үзе белән исә җитмешенче елларның ахырыннан бирле тыгыз элемтәдә идем. Миндә аның белән язышкан бик күп хатлар да саклана.

Техникумда уку еллары сиздермичә узып та китте. Без яшь белгечләрне бөтен Союз буенча таратырга тиешләр иде. 1955 елны техникум тәмамлаучыларга илнең Европа өлешендәге күп кенә зур шәһәрләргә—Киев, Рига, Кишинев, Ленинград, Таллин һәм башкаларга юллама алу мөмкинлеге бирелде. Балтыйк буе минем өчен чит ил кебегрәк тоелганга күрә үзем Риганы сайлаган идем. Ләкин Ибраһим Таҗиев Риганы аңа калдыруымны үтенде. Аның төп дәлиле шундый булды: сине тиздән армиягә алачаклар, ә миңа егерме сигез яшь инде, тормышымны көйләргә кирәк, бәлки, гомерлеккәдер, диде. Шуннан мине Молдавия яклары үзенә тартты—Бендеры шәһәренә барырга карар кылдым. Ул арада кая китү мәсьәләсен хәл итүгә курсташларым Михаил Нестеров белән Юрий Дадыкин килеп кушылдылар. Аларның, армиягә алынганчы, Кубань киңлекләрендә йөреп каласылары килә икән, мине дә шунда димләделәр. Күптән түгел генә "Кубань казаклары" дигән фильмны да кызыксынып—кызыгып караган идек. Краснодарның йон тукыма-постау фабрикасында нәкъ өч урын да бар икән. Шулай итеп, мәсьәлә хәл ителде дә куйды.

* * *

Шул рәвешле, без—өч яшь белгеч 1955 елның августында Краснодардагы йон тукыма—постау комбинатының төрле бүлекләренә эшкә килеп урнаштык. Бу комбинат илдә иң зурлардан санала. Краснодар янындагы бистәсе үзе бер шәһәрчек иде—торак йортлары, уку үзәкләре һ. б. бар. Комбинат директорындагы беренче киңәшмә истә калган.Аның фамилиясе Пушкин иде. Ул елны эшкә килгән белгечләр—инженерлар һәм техниклар йөзгә якын кеше иде. Безгә мөрәҗәгать итеп, Пушкин комбинатның киләчәге, икенче чираты төзеләчәге, яшь белгечләргә зур мөмкинлекләр ачылачагы турында озак-озаклап сөйләде.

Мине комбинатның иң зур производство бүлегенә—туку цехының электр җиһазларын ремонтлау мастеры итеп билгеләделәр. Унсигез яшьлек егет кул астында егермедән алып алтмыш җиде яшькә кадәр булган югары квалификацияле утызлап электромонтер бар иде. Тормышымда соңыннан беркайчан да шул кадәр кешеләр белән җитәкчелек итмәдем. Башкалар кебек, мин моңа омтылмадым да. Эшчеләремә беренче нарядларын ябуым истә калган. Алар эшләгән эшләрнең бер бөртеген дә төшереп калдырмаганыма иманым камил иде юкса. Нарядларны бухгалтериягә илтеп тапшырганчы, эшчеләремә укып күрсәттем. Алар авызларын ачып каттылар да калдылар—бу нарядлар буенча түләсәләр, хезмәт хаклары бик аз чыгасы икән. Шунда мин хезмәткә түләү тарифының тормыш чынбарлыгын исәпкә алмыйча гына төзелгәнен төшендем. Без барыбыз бергәләшеп нарядларны эшчеләр рәнҗемәслек итеп яңабаштан язып чыктык. Аларны язуның төп принцибын да шуннан соң аңладым. Һәр эшләнгән эшне дә бик нык арттырып язарга кирәк икән, шул чагында гына эшчеләрнең хезмәт хакы җитәрлек булачак. Моны бухгалтериядә дә беләләр, әмма каршылык күрсәтмиләр, күз йомалар. Чөнки башкача эшләү мөмкин түгел иде.

Краснодарда озак тормасам да, янә бер вакыйга хәтеремдә калган. Мин инде армиягә повестка кәгазе алган идем, комбинаттан берничә комсомол егетне Краснодар краe яшьләренең чираттан тыш конференциясенә җибәрделәр. Араларында мин дә бар идем. Конференциянең төп өлеше КПСС крайкомының беренче секретаре Д.Полянский чыгышы булды. Асылда, бу җыен шуның өчен генә оештырылган да иде. Крайкомның элекке җитәкчеләре эшен тетте дә салды ул. Янәсе, миллионер колхозлар төньяк төбәкләргә җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне бик югары бәядән сатып кына баеп беткәннәр. Яңа "кыю" түрәнең чыгышындагы төп нәрсә шул булды. Хәтта моны колхоз эшен рәтләп белмәгән без дә ачык аңлап утырдык, бу спектакль Кубаньдагы яңа җитәкченең бик булдыклы, кыю эшчәнлеген Мәскәүдә дә (дөресрәге, КПСС Үзәк

комитетында да) ишетсеннәр өчен генә уйналган иде.

Әйтергә кирәк, бу хикмәтле чыгыш үз нәтиҗәсен дә бирә, бик тиздән—бермеикеме елдан Д. Полянский реактив тизлек белән югары "сикерә". Аны РСФСР Министрлар Советы Рәисе итеп билгелиләр, соңрак КПССның Политбюро әгъзасы да булып ала. Аңа бәхет гел елмаеп кына тора, әйтерсең, табигать үзе дә булыша. Ул килгән елны Кубаньда зур уңыш җыеп алалар, барысы да шул кешенең оештыру сәләтенә генә бәйләнгән диярсең.

Д. Полянский белән беренче очрашудан соң егерме еллар үткәч, аның үзенчәлекле-кызыклы гына дәвамы да булды. 1974 елны СССРга Пакистан премьер-министры Зөлфикар Бхутто килү хөрмәтенә А. Н. Косыгин Мәскәүнең хөкүмәт йортында рәсми көндезге аш мәҗлесе үткәрде. Тәрҗемәче сыйфатында мин Д. Полянский белән янәшә утырам, ул инде СССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары һәм Политбюро әгъзасы иде. Безнең сөйләшә-сөйләшә ашау-эчүебез ике сәгатькә тартылды. З. А. Бхутто тырышып-тырышып СССРның финанс һәм техник ярдәме белән Карачи шәһәрендә зур металлургия комбинаты төзү мәсьәләсе турында сөйли. Советлар ягын Пакистанда тиешле чимал-тимер рудасы, коксланган ташкүмер булмавы борчый. Бу шартларда комбинат табышлы була алмас икәнлеге әйтелә. Пакистанлылар, анысы аларның үз эше, кирәк булса руданы Австралиядән, хәтта Бразилиядән дә китертергә була, бары тик аларда авыр индустриянең чын флагманы булырлык комбинат кына төзелсен, дип тәкрарлыйлар. Берничә йөз миллион долларга төшәрлек андый зур проект турында карар кабул итәр алдыннан бер-береңне капшапсынап карау—хөкүмәтара сөйләшүләр алып барганда гадәти күренеш. Алгарак китеп, шунысын да әйтим: елына бер миллион ярым тонна корыч коя ала торган ул комбинат Карачида минем күз алдымда төзелде. Пакистанлылар без биргән кредитны тулысынча яхшы сыйфатлы товарлар һәм доллар белән түләделәр.

Сөйләшү барышында мине гаҗәпләндергәне шул булды: Д. Полянский мәсьәләнең асылын бөтенләй белми икән, ул аптырабрак карап тик утыра. Сөйләшү ахырына таба Полянский Пакистан җитәкчесенә бик сәер генә сорау биреп куйды. Әле проектка да салынмаган комбинат турында "аның төзелеше нинди стадиядә хәзер?" дип сорады. Мәсьәләнең асылын белүче буларак һәм А. Н. Косыгинның ачулы күз карашын сизеп, мин бу уңышсыз сорауны башкачарак тәрҗемә иттем: янәсе, проект-эзләнү-тикшеренү эшләре нindирәк стадиядә әле? З. А. Бхуттоның мин шунда ук русчага тәрҗемә итеп биргән җавабын ишеткәч, А. Н. Косыгин тәрҗемәченең хәйләсен тотып алды һәм ишетелер-ишетелмәс кенә итеп Полянскийга аның бүгенге сөйләшүнең барышын йоклап үткәргәнлеген искәртте. Шундый җитди сөйләшүгә Д. Полянскийның бөтенләй әзерлексез килүенә мин бик гаҗәпләнгән идем. Ул хәтта үзенә бирелгән мәгълүматларны ачып-актарып та карамаган, сөйләшүләрнең барышын да тыңламый утырган икән.

Озакламый Д. Полянский югары хакимияттә дәрәҗәсен югалтты һәм Япониягә СССР илчесе итеп җибәрелде. Ул заманнарда андый зур дәрәҗәдәге партия эшлеклеләре өчен мондый гамәл сөргенгә җибәрелүгә тиң итеп карала иде. Д. Полянский Япониядәге нәселле һәм абруйлы дипломат Олег Трояновскийны алыштырды. Ә соңгысы исә Н. С. Хрущевның халыкара мәсьәләләр буенча элекке ярдәмчесе иде. О. Трояновский совет-япон мөнәсәбәтләрен җайга салуда аз хезмәт күрсәтмәгән иде югыйсә. Сүз уңаеннан, аның әтисе Александр Трояновский да утызынчы елларда Кояш чыгышы илендә СССРның илчесе булган. Димәк, улы Олег үзенең мәктәп елларын Япониядә үткәргән һәм анда илче булып кайткан.

Ярар, Краснодарга әйләнеп кайтыйк.

1956 елның Яңа елын каршылар алдыннан армиягә алынуым сәбәпле, мин ул шәһәрдән китеп бардым. Мине Сталинград өлкәсенең Морозовск шәһәренә озаттылар һәм, теләгем булмаса да, авиацион-техник училищега курсант итеп теркәделәр. "Техник-лейтенант" дигән хәрби дәрәҗәсе булуга да карамастан, мине армия офицеры карьерасы бер дә кызыктырмый иде. Ул минем ирек сөючән рухыма каршы килә, хәрби хезмәттә сукырларча дәрәҗәләргә буйсынып яшәүне җенем сөйми, болар минем холык-табигатем белән һич тә яраша алмый иделәр. Училищеда укый башлауның беренче көннәреннән үк мин гел генә аны ничек ташлап китү турында уйлана башладым. Училищеның политбүлек начальнигы урынбасары белән әңгәмә вакытында мин аңа үземнең әлеге уй-фикерләремне ачыктан-ачык әйтеп бирә алдым. Мин аңа үземне кайда булса да техник—электрик һөнәрем буенча файдалануны сорап мөрәҗәгать иттем. Бертуктаусыз шул юнәлештә кайгыртып йөрүем миңа бер фикердәш табарга ярдәм итте. Ул—Александр Рудь, шулай ук техник-электрик, нык-таза Урал егете, разрядлы самбист булып чыкты. Матур әдәби тел белән сөйләшә, югыйса офицер булырга бар яктан да килгән инде үзе. Әмма аның да, минем шикелле үк, һич тә андый теләге юк иде. Икәү бергәләп без тагын ниндидер бер начальникка кереп, безне үзебезнең белгечлегебез буенча хезмәт итәргә җибәрүләрен сорадык. Шулай йөри торгач, ниһаять, безнең бәхет басты: хәрби округ штабыннан безне Краснодар

краеның Новотитаров районындагы Копанское авылына җибәрергә диган боерык килде. Без телэгебез үтәлгәнгә бик канәгать булып, төрле транспорттан-транспортка күчеп, юлга чыктык. Юлыбызның бер ун чакрымлап соңгы өлешен җәяүләп кенә үттек. Аңа кадәр әле Елизоветинское авылының яңгын сүндерүчеләр өендә салам өстендә дә йоклап төн үткәрдек. Частька барышлый, Кубань сыер савучылары кышлагына да сугылдык, анда безне яңа сауган сөт һәм искиткеч тәмле ипи белән сыйладылар. Рәвешенә караганда, икмәкне дә ферманың үзендә генә пешерәләр иде булса кирәк.

Ул заманнардан соң, кем әйтмешли, күп сулар акты. Әмма Саша Рудь шушы көнгә кадәр минем күп булмаган дусларым арасында иң якыны, мин аның белән беркнинди авырлыксыз-нисез менә ярты гасыр диярлек дуслык элемтәләре тотам. Саша һәрвакыт эшчән-дәртле һәм башлап йөрүчән булды. Танышуыбызның беренче көннәреннән үк ул әйдәп баручы лидер, миннән берничә адым алданрак атлый һәм шул ук вакытта киң җилкәсе белән мине дә ышыклап-яклап торды. Шундый хәл миңа да ошый иде. Өстәвенә, мине оештыру һәм җәмәгать эшләре бер дә кызыктырмый. Бервакытта да җитәкче булырга омтылмадым, киресенчә, андый гамәлләрдән авырыксына идем. Аннары шунысы да бар, мәдәни һәм башка чараларга мин бары тик хатыныма шулай йөрү ошаганга күрә генә йөри идем. Шул ук вакытта, кайберләрен исәпкә алмаганда, һәрчак күңелемә, холкым-табигатемә якын гамәлләр белән генә шөгыльләнә килдем. Ул гамәл минем хезмәт бурычларыма керәме—юкмы—анысына бәйсез рәвештә һәм һәрвакыт диярлек хезмәт баскычларыннан күтәрелү мәнфәгатьләренә каршы килеп эшләнә. Мондый халәт миңа билгеле бер рухи канәгатьлек бирә һәм күпмедер дәрәҗәдә, кемнең дә булса ярдәменнән башка да, кешеләр арасында тотрыклы мөстәкыйльлеккә ирештерә. Ахыр чиктә, хәзерге тиз үзгәреп торучан социаль-сәяси вәзгыятьтә шундый бәйсезлек-мөстәкыйльлек миңа тормыштагы катлаулы хәлләрдә дә югалып калмаска ярдәм итте дип уйлыйм.

Солдат тормышы турында сөйләвемне дәвам иттергәнчегә кадәр, аңа мөнәсәбәтемне дә белдереп узыйм инде. Бервакыт Пакистанда эшләгәндә, мин тормышымның бу чоры турында хезмәттәшем Андрей Молочковка сөйләгән идем. Ул дипломатлыкка әзерләнгәндә җиде елымны юкка сарыф иткәнемне әйтте: дүрт ел техникумда уку һәм өч ел армиядә хезмәт итү, имеш, болар. Ул үзе икенче сыйныфта укыганда ук халыкара мөнәсәбәтләр институтына керәсен һәм, аны тәмамлап чыккач, СССР Тышкы эшләр министрлыгы системасында эшләячәген белгән, имеш. Аның минеке шикелле кирәксез чорлары булмаган да. Андрей борынгы Мәскәү дипломатлары гаиләсендә туып үскән. Аның ике абыйсы да Мәскәү Дәүләт Халыкара Мөнәсәбәтләр Институтын (МГИМО) тәмамлаганнар һәм тышкы сәясәт ведомоствосында эшлиләр икән. Әтиләре Ф. Ф. Молочков исә утыз елга якын СССР Тышкы эшләр министрлыгының протокол хезмәтенә җитәкчелек иткән. Ул заманда бу бүлек, ил җитәкчеләре белән аралашканда, аларга хезмәт күрсәтүче бердәнбер оешма була (хәзер һәр ведомствоның, шул исәптән хөкүмәт һәм президент администрациясенең үз протокол бүлеге бар). Миңа алтмышынчы еллар уртасында А. Н. Косыгинның Пакистанга рәсми визиты вакытында өлкән Молочковның үз эшен ничек төгәл башкарганын күрергә туры килде. Ф. Ф. Молочков шулай ук Дипломатик академиядә гаять кызыклы лекцияләр белән дә чыгыш ясый. Ул үзенең И. В. Сталин, В. М. Молотов, Н. С. Хрущев һәм илнең башка җитәкчеләре белән эшләгән чорындагы аерым вакыйгаларны да сөйли иде.



*Армия хезмәтендә. Краснодар, 1957*

Ләкин мин Андрейның сүзләре белән һич килешергә теләмәдем. МГИМОга укырга керергә ике ай гына калганда да, мин әле, гомумән, шундый ябык институтның барлыгын да белми идем. Шуңа күрә техникум да, армия дә, һичшиксез, минем өчен файдалы тормыш баскычлары булды. Нәкъ техникум авыл мәктәбен тәмамлаган үндүрт яшьлек үсмергә рус телен үзләштерергә ярдәм итте. Ә армия исә ул заманнар өчен иң яңа булган радиотехника буенча белемемне баетты. Бу өлкә бит теләсә нинди һөнәр иясе өчен дә кызыклы. Аннары армиядә хезмәт итү тормышка булган гомуми карашларымны гомерлеккә үз урынына утыртты, дөньядагы теләсә нинди вакыйгаларга принципиаль карарга, үземне үзем итеп танырга һәм танытырга тотрыклы хокук та бирде. Һәм иң мөһиме шул тагын—техникум һәм армия кешеләр белән ничек аралашырга кирәклеген өйрәтте, фикерләремне ныгытты, үзаңымны тирәнәйтте-киңәйтте.

* * *

Без Саша Рудь белән кечкенә генә авиацион-техник частькә эләктек. Бирбдәге төп объект солдатлар телендә "Круг" ("түгәрәк") дип атап йөртелә икән. Ул хөкүмәт самолетларына һәм башка оча торган объектларга ерак араларга очканда хезмәт күрсәтүче кыска дулкынлы пеленгатор станциясе булып чыкты. Безгә андый станцияләрнең илдә барлыгы өчәү генә—Архангельск янында, Мәскәү тирәсендәге Монинода һәм безнеке икәнлеге билгеле иде инде. Оча торган объектлардан тапшырылучы шифрланган радиосигналлар аша бу өч станция аларның төгәл координатларын теләсә кайсы вакытта билгели ала. "Круг"ның заманча иң яңа кабул итү һәм тапшыру станциясе бар һәм ул нурлы сигналлар күрсәтә торган зур экран белән җиһазландырылган иде.

Безнең турыдан-туры начальнигыбыз—ябыграк кына, өлкән яшьләрдәге техник—капитан. Аның үзе дә агарынганрак, авыру шикеллерәк иде. Ул безгә болайрак диде: "Безгә ышанып тапшырылган участок-араларны булдыра алган кадәр яхшырак карап-күзәтеп торырсыз. Иң мөһиме—часть командиры тарафыннан берниндә дә җитди ризасызлык һәм кисәтүләр булмасын". Барысы да бик гади һәм ачык аңлашыла иде. Начальнигыбыз эшне икебезгә бүлеп бирде, минем карамакта электр подстанциясе булды. Эш вакытымның төп вакытын мин шунда үзем начальник, үзем монтер һәм үзем җыештыручы булып үткәрә башладым. Озакламый Сашаны комсомол секретаре итеп сайлап куйдылар, мин аның политукулар буенча урынбасары булдым.

Кабатлап әйтәм, армия хезмәте минем шәхес буларак формалашуым өчен зур мәктәп һәм, тулаем алганда, тормышымның якты бер өлеше булып калды. Баштарак эч пошуларымны китапханәдән алган китапларны уку белән баса идем. Сәяси әдәбиятның бар булганы белән танышып чыкканнан соң, техник һәм фәнни әдәбиятны укырга тотындым. Менә кулымда академик Сифоровның "Теоретик радиотехника" дигән бик калын китабы. Шуны укып утырганда яныма часть командиры инженер-подполковник Виктор Федорович Иванов килеп керде. Ул күптән түгел генә Мәскәүдә хәрби инженерлар академиясен тәмамлаган кеше иде. "Китабыгызны укып бетергәч, миңа имтихан бирергә килерсез, квалификацияле радиомеханиклар кирәк безгә",—диде командир. Командирда әңгәмә-имтихан үткәннән соң, озакламый Саша белән миңа яңа бурыч йөкләнде. Без "Круг"та алмаш-тилмәш дежур радиомеханиклар вазифасын башкара башладык. Бездән алда хезмәт иткән алты радиомеханикны, нигездә, Үзбәкстан егетләрен каравыл взводына озаттылар. Алар бик канәгать булып китеп бардылар шикелле тоелды миңа. Саша яңа эшкә үзенә хас бер дәрт белән керешә. Ул үзебезнең мастерскойда аунап ята торган радиодетальләрдән бер радиоалгыч та ясап куйды. Моңа башкаларның исе китте. Үземнең практик гамәлләрдә йомшак икәнлегемне белгәнгә күрә, мин баш—аягым белән теориягә чумдым—күпблоклы пеленгатор җайланмасының бик катлаулы схемасын өйрәнергә тотындым. Тиздән мин схемаларны иркенләп укый башладым, аерым блокларның теге яки бу конструкцияләрендәге үзенчәлекләр турында офицерлар белән тиңләшеп, бәхәсләргә дә кушылып киткәли идем.

1957 елны "Круг"ны рәсми рәвештә җирнең ясалма юлдашларына хезмәт күрсәтүче объектлар исемлегенә теркәделәр. Безнең радистлар беренче юлдашны җибәргәнче, алдан ук аның "пип-пип" дигән сигналлары булачагын белә иделәр инде. Бөтен җайланма-җиһазлар, корылмалар бик җентекләп әзерләп куелды. 1957 елның 3 октябрьдән 4 октябрьгә каршы төнен без йокысыз үткәрдек, түземсезлек белән юлдашның сигналларын көттек. Һәм менә пеленгатор экранында алар ачык күренделәр, ачык ишетелә башладылар. Бу хезмәтебез өчен безнең күбебезне бүләкләделәр. Саша белән миңа ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамоталарын бирделәр. Аларга А. Шелепин үзе кул куйган иде.

Озакламый безгә дә КПСС Үзәк Комитетының 1957 елгы Октябрь пленумы кайтавазы килеп ирешә. Шул пленумда маршал Г. К. Жуков оборона министрлыгыннан азат ителгән һәм армиянең санын шактый кыскарту турында карар да кабул ителгән иде. Нәкъ шул көннәрдә мине партия әгъзалыгына кандидат итеп кабул иттеләр. Кабул итү Краснодардагы авиация берләшмәсе парткомы утырышында булды. Карт кына бер полковник (сугыш ветераны, күрәсең) миннән: "Маршал Жуковның төшерелүе турында солдатлар арасында нинди аңлату эшләре алып барырга җыенасың?"—дип сорады. Иң әүвәл мин "Правда" газетының беренче битендәге редакцион мәкаләдән берничә тәнкыйть җөмләсе әйттем. Аннары, үзем дә сизмәстән, бөек полководецның Ватан сугышы чорындагы зур хезмәтләре турында кайнарланып сөйли башладым. Шунда бер яшь кенә офицер мине кискен бүлдерде. Мин ирексездән карт полковник ягына карап алдым, аның хуплап баш кагуын күрдем. Әлеге пленумнан соң безнең хезмәт вазифаларыбызны бик нык тыгызладылар. Шул ук көннәрдә мине механиклар отделениесе командиры итеп билгеләделәр. Отделениедә җиде солдат бар иде: Грузиядән бер авыл егете Нодар Цациашвилли, Биробиджаннан бик кыюсыз-тыйнак яһүд Виталий Михальцевич, баһадир гәүдәле украин Василий Пугачев, грек Владимир Челпан, кыргыз Тулебаев, тәбәнәк буйлы бик хәрәкәтчән яһүд

Владимир Шнейдер, анысы Таганрогтан иде. Безнең мөнәсәбәтләрдә үзара ярдәмләшү һәм дуслык хөкем сөрде.

Штатлар кыскартылу сәбәпле, күп вазыйфалар үтәргә туры килгәнлектән, мин пеленгатор станциясенең материаль частен ныклап өйрәнергә мәҗбүр булдым. Мин инде агрегатларның тиз көйсезләнә торган урыннарын белә һәм аларны тиз генә төзәтә ала башладым. Блокларны ай саен көйләп-әзерләп кую кулдан эшләнә, эшемдә иң катлаулы һәм иң четереклесе санала иде.

Бервакыт командирның рөхсәтен алып, күрше авылга китеп бардым: солдатлар клубында авыл яшьләре белән бергәләп кичә үткәрү турында сөйләшергә-килешергә кирәк иде. Колхоз рәисе белән рәтләп сөйләшергә дә өлгермәдем, идарә янына зур тизлек белән командирыбызның "джип" машинасы килеп туктады. Шофер кәрә—кәрешкә "аттыра" башлады—миңа бик ашыгыч рәвештә объектка кайтырга кирәк икән, анда аппаратураның кайсыдыр төше көйсезләнә, беркем бернәрсә дә эшли алмый, ди. Объектка кайтып киттек. Аппарат залында командир җитәкчелегендә частьнең барлык офицерлары да җыелган. Офицерлардан кайсысыдыр колагыма пышылдый: хөкүмәт самолеты белән элемтә өзелгән—Н. С. Хрущевның Азия илләренең берсенә очышы икән. Бер радистның гаебе аркасында төп кабул итү аппараты сафтан чыкканлыгы ачыкланды. Дежур офицер аны запас радиоалгычка алыштырырга боерык биргән. Ләкин ун минуттан анысы да эшләми башлаган. Аппаратларның болай бозылу сәбәбен беркем дә аңлата алмый. Часть командиры мине агрегатның төп схемасы янына алып килде дә бозылу сәбәпләрен үзе ничек аңлаганлыгын кыска гына итеп әйтеп бирде. Аның фикере миңа кабул итү аппаратында "электрон агым"да нәрсәләр бозылганлыгын аңларга ярдәм итте. Тиз генә бишенче блокның барлык радиолампаларын алыштырып куйдым. Кабул итү аппараты тәгәл эшләп тә китте. Барысы да җиңел сулап куйдылар. Бу очрактан соң часть командиры миңа көн саен диярлек шалтыратып тора башлады, кайвакытларда "офицер дәрәҗәсе алырга теләгең юкмы?"—дип тә сораштыра иде.

Ләкин мин күптәннән инде алга таба укырга—белемемне күтәрергә карар кылып куйган идем. Катлаулы радиоаппаратура белән эш иткәндәге "уңышларымнан" үсенеп китеп, Казан авиация институтының радиотехника факультетына гариза бирмәкче булдым. Минем армия хезмәтем тик декабрь аенда гына тәмамлана, ә институтка кабул итү имтиханнары августта ук башлана. Шуңа күрә мин бу хакта командир белән сөйләшер өчен җай чыкканны көтеп йөри идем. Бәхетемә, бу мәсьәләне командир үзе кузгатты һәм минем карарымны хуплады. Ул шулай ук мине вакытымнан алда җибәрүне дә хәл итәргә вәгъдә бирде.

1958 елның май аенда Краснодарда хәрби подразделениеләр комсомол оешмаларының секретарьлары киңәшмәсе булды. Шунда хәрби округ политидарәсенең бер җитәкчесе чыгыш ясады. Ул запаска китүче активист сержантларга политидарә МГИМОга укырга кирәргә рекомендацияләр бирә ала, дип белдерде. Бу рекомендацияләр, КПСС өлкә комитеты рекомендацияләренә тиңләшеп, СССР МИДының ябык уку йорты булган МГИМОга керү имтиханнары тапшыру мөмкинлегенә юл ача икән. Безнең өчен бу гадәттән тыш яңалык булды, чөнки арабыздан беркемнең дә диярлек шундый махсус институт барлыгын беркайчан да ишеткәне юк иде. Аннары политидарәдән килгән полковник, бу хәбәр белән кызыксынучылар булса, аларга "алдан ук чит тел буенча кечкенә генә имтихан" үтәргә кирәк булачагын әйтте. Монысы шунда ук абитуриентлыкка "кандидатларның" бер ике дистәләбенең "кикриген шиңдерде". Саша Рудь мине гариза бирергә үгетли башлады. Мин, чит телләрне юньләп белмәвемне сылтау итеп, бик нык каршы тордым. Өстәвенә, мин инде үзем теләгән институтны сайлаган һәм бу хакта командир белән дә сөйләшеп куйган идем бит. Әмма Саша үҗәтләнеп үгетли һаман. Ул бик яхшы дәлилен дә тапты: МГИМОга имтиханнар июльдә башлана икән. Үтә алмасаң, документларны башка институтка да бирергә өлгереп була, диде. Аннан соң, армиядән китүне дә, августка калдырмыйча, июньнән үк эшләргә мөмкин. Кыскасы, ул мине тәки күндерде һәм без тиешле документларыбызны әзерләп тапшырдык. Менә чит телләр буенча әңгәмә-имтиханнар, ягъни капшап карау башланды. Безнең группада иң көчлесе мин булып чыктым. Һәрхәлдә, минем акы—токы гына немец телем белән "танышкан" офицер үзе шулай дип әйтте. Инглиз теле группасында Саша Рудь көчле, ә француз телен Левин дигән егетебез ерып чыкты.

Частька кайткач, командирыма киңәшмә нәтиҗәләрен сөйләп бирдем дә, МГИМО турында аның фикерен сорадым. Ул моны бик хуплады. "Бу нәкъ менә сез барырга тиеш юнәлеш. Ышанам, сез аны булдырырсыз",—диде. Шулай итеп, 1958 елның июнь ае ахырында без—Рудь, Левин һәм мин—өчәүләп Мәскәүгә китеп бардык. Иптәшләремнән аермалы буларак, Мәскәүгә минем беренче баруым иде.

***Соңгы бер ел эчендә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган зур күләмле ике китап дөнья күрде. Алар, нигездә, шагыйрь әсәрләре турында булса да, бу китапларда бүгенге әдәби хәрәкәт, бигрәк тә татар шигыре турында күпмедер дәрәҗәдә кызыклы фикерләр әйтелә, шагыйрьгә замандаш әдипләрнең иҗатлары анализлана, татар әдәбиятының үсеш перспективалары бәян ителә. Равил Фәйзуллинның 60 яшьлек юбилее уңае белән без бу санда шагыйрь Рәдиф ГАТАШ һәм галим Хуҗи МӘХМҮТОВЛАРНЫҢ әлеге китаплар турында язылган рецензияләрен урнаштырабыз.***


## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА—ЗАМАНДАШЛАРЫ

“Мәгариф” нәшриятында дөнья күргән бу китап үзенең полиграфик яктан матур эшләнеше белән дикъкатне, аннары күңелне җәлеп итә. Әйе, зур форматтагы калын басманың тышлыгы белән үк: ак, каты бу тышлык өстендә китап исеме уелган булса, сулда—астан өскә язылып, зуррак шрифтта бу исем русча да бирелгән (“Равиль Файзуллин. Современность. Творчество. Личность”). Димәк, ике теллелек принцибы бу китапта, андагы материалларда—мәкаләләр, эсселарда. Алар барлыгы алты бүлеккә аерып урнаштырылган, ләкин язылу-басылу хронологиясе буенча түгел!—укучы китапны теләсә кайсы бүлектән укый башласа да, шагыйрь дөньясына мөкиббән китмичә, аны бөтенләе белән күзалламыйча калмаячак—моңа иманыбыз камил. Үзенең кереш сүзендә бу китапны төзүче шагыйрь Зиннур Мансуров искәрткәнчә, “басмада заман фонында олуг Шагыйрьнең, кызыклы шәхеснең зур бер коллектив—җитмешләп автор тудырган җыйнама образы, иҗади портреты”. Бик күп материалдан—тау кадәр мәкаләләрдән, иҗади портретлардан, эссе-уйланулардан һ. б. нык сайлап кына төзелгән китап икән бу ... һәм, Зиннур Мансуров язганча, ул—“олуг Шагыйрьнең коллектив иҗат портреты булу белән бергә, шагыйрь яшәгән заман, замандашлары, шул чор рухы, шул чор фикер ияләренең уңышлары, ялгышулары, хыял омтылышлары. Мәкаләләрдә—үткән гасырның икенче яртысындагы татар әдәбияты, татар шигыре һәм тәнкыйте үсешенең үзгә бер кардиограммасы...” Китапны игътибар белән укыган һәркем үзе дә шагыйрьнә күңел белән яңарып, пакьләнәчәк һәм аның моңарчы күрелмәгән бер вакыйга-күренеш, кадерле басма булуына ышаначак. Чынлап та, булдымы безнең әдәбиятта, яки китап, басмачылык тарихында—татарда!—моңа охшаш бер вакыйга? Ерак гасырларны—китапсыз чорларны әйтеп тә тормыйбыз, ә узган егерменче йөздә? 1915 елда, бөек галимнең 100 еллыгына дип, бер төркем зыялылар каләме һәм байлар ярдәме белән дөнья күргән калын “Мәрҗани” мәҗмугасеме? Ул, әлбәттә, бик кадерле, кирәк басма... Әмма, безнең “кириллицага гашыйк” күзләр өчен түгел шул!—аны гарәп язуын камил белгән бәхетлеләребез генә укый (әлегә!)... Йә “Тукай турында замандашлары” кебек тансык

---

Коллектив. **Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес.**—Казан: Мәгариф, 2002.–495бит.

китапларны искә алыйкмы? Фатих Әмирхан, Такташ, Кутуй турындагыларны? Без аларның нинди купюрлар—төшереп калдырылган битләр, юллар, исемнәр белән "төзәтелеп" чыгуын бик яхшы беләбез—ул елларда мондый китапларның уртак язмышы шундый иде. Туксанынчы елларга кадәр Тукай, Җәлил кебек бөекләребез фотоальбомнары да политик яктан "нык әзерлекле" материаллардан гына тора бит. Гасыр ахырында дөнья күргән Х. Туфан, Һ. Такташ, С. Хәкимнәрнең инде яңача төзелгән альбом-китаплары (Рабит Батуллага ничек рәхмәт әйтми калып була биредә?!), әлбәттә, шагыйрь һәм шәхесне тулырак ачкан кадерле басмалар булып санала аладыр... Инде Җәлилебезнең дә бөтен



дәреслегендә тормышын, үз чорына бәйле җан әзләнүләрен чагылдырган шундый китабын күрсәк иде, иншалла! Әйтик, "Яшьлек мәхәббәтемә хатлар"ы да кергән итеп! Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылса кирәк: мондый характердагы китаплар мәрхүм классикларыбыз йә башка—политик бөекләребез турында гына була ала иде әүвәл. Алар яшәгән заман, әдәбият, шигърият дуслары, мәхәббәт һәм мөнәсәбәтләр дә шул олуг шәхесләр тирәсендә фон буларак чагылмый калмый иде, әлбәттә. Ә инде дөнья әдәбиятында бу—киңрәк, тулырак ачылган бай панорама! Алтмышынчы елларда поляк язучысы Ю. Хартвигның "Аполлинер" исемле биографик романын ничек шашынып укыганым хәтердә әле! Анда—егерменче йөз башы француз әдәбияты, сәнгате тормышы, эзләнүләр, Аполлинер башлаган авангардлык поэзиясе, Пикассо кебек рәссамнәр белән бәйләнеш... төрле агымнар, беренче бөтендөнья сугышы чоры атмосферасы, шул чорда мәхәббәт һәм көчле лирика үсеше... Гаҗәеп картиналар! Аннары укыган китапларда—бераз соңрак чор—шул ук илләге сюрреализм, Бретон, Элюар, Арагоннар, аларның үзара мөнәсәбәтләре, мәхәббәтләре (Гала, Эльзалар!), яки—Лорка, Нерудалар белән... сугыш алды Аурупа шигъре. Туксанынчы елларда—"көмеш гасыр" чоры шагыйрьләре Блок, Цветаева, Есенин һ. б. турында искиткеч бай мәгълүматлы, мавыктыргыч китаплар да дөнья күрде. Унтугызынчы йөз бөекләре турында А. Моруа язган атаклы кешеләр тормышыннан китапларны—Байрон һ. б. турында биографик романнарны әйтеп тә тормыйм инде! Ә иң соңгы укыган китабым—"Хемингуэй һәм ул сөйгән хатын-кызлар" дип атала.

Шулай да, әйткәнебезчә, исәннәр турында, бигрәк тә шагыйрьләр турында мондый китаплар аз, бик аз, йә—бөтенләй юк. Ә бит "үлеп үлемсезлек яулау—бердәнбер юл түгел тормышта"! Заманы башка, мөмкинлекләре зур, эшләгән эшне күрсәтү, томнар чыгару, исән чакта танылу, укучыларның, халкыңның яратуын да тою бәхетен биргән дәвер бу!

Менә шуңа күрә дә Татарстанның халык шагыйре, инде кырык елдан артык шигърьдә "ат уйнаткан" каләмдәшебез, исеме инде күп халыкларга да танылган күренекле замандашыбыз турында бу китап әнә шул яктан да кадерле: әйе, исән шагыйрь турында замандашлары язган җыелма мозаик "роман". Шагыйрь турында шагыйрәнә китап! Без биредә төзүченең тагын бер гыйбарәсен кулланабыз: "рухи һәм әдәби-иҗат генеалогиясен" чагылдырган китап. Анда шагыйрьнең шигърияттә бүгенге бәхәссез зур урынын тулаем чагылдырган язмалар да (бу бигрәк тә беренче бүлеккә карый), инде әйтелгәнчә, соңгы 40-50 елдагы әдәби хәрәкәт, шигърьне аңлау, аңлату тирәсендәге бәхәсләр, шул исәптән Равил Фәйзуллин шигъриятенә караш эволюциясе чагылышы, шагыйрьнең мәгълүм шигырь цикллары йә китаплары чыгу уңае белән бәхәсләр, яклау йәки өнәмәү, әмма иң мөһиме, новаторлык, яңа шигырь тирәсендә "кылыч уйнатулар" һәм, нәтиҗәдә, татар шигыренең яңа үсеш, яңарыш этаплары чагылышы.

Мәкаләләр арасында—иҗат портреты дип саналырдай саллы, этрафлы, күләмлерәкләре дә, кечкенә, әмма шагыйрь рухын, иҗат һәм шәхесне бербөтен итеп тоеп, тирәнтен аңлап язылган шигъри эсселар да, доклад-мәкаләләрдән өекләр, яки тиз генә "кызуында" язылган отклик-фикерләр дә бар. Авторларның—һәммәсенең дә—фотосы урнаштырылган. Һәм һәр бүлек башында шагыйрьнең дә үзгәрә "яшәрә" баручы сурәтләре озата бара укучыны, шигырьләреннән эпиграф итеп алынган юллары да уйландырачак. Моңа кадәр чыккан һәр китабы да югары басма культурасы, фәннилек (бу—бигрәк тә биштомлыгына—"сайланма"ларга карый) белән аерылып торган шагыйрьнең бу үзе турында китап та яңача, оригиналь һәм тирән эчтәлек белән төзелеш-композиция тәңгәллеге ягыннан да камил.

500 биткә якын күләмдәге бу басма—үзенә күрә Р. Фәйзуллин һәм Шигъриятебез

турында нәни бер энциклопедия тәэсире калдыра дисәк тә ялгышмабыздыр. Һәм бу "энциклопедия" авторларының һәркайсының үз алымы, үз стиле, рухы да чагыла—алар һәрберсе шагыйрь образын тудыруда үз сурәт-буяуларын, сүз-акылын, симпатия һәм каршылыкларын тулы гәүдәләндерә. Беренче бүлектәге мәкаләләр бу яктан аеруча характерлы: әйтик, мәрхүм Гариф ага Ахуновның "Яңарыш" исемле, эчтәлекле, шигырьне тирән тоеп аңлау, кайгыртучанлык, объективлык белән аерылып торган мәкаләсе юкка гына иң алга куелмагандыр: шигырь үсеше юлындагы һәр үзгәрешне, "Р. Фәйзуллин һәм аның буыны" китергән яңалыкны йөрәк белән кичереп, акыл белән үлчәп, еллар дәвамында язылган бер матур сәхифә ул! Принципиаль карашлар, шуңа тугрылык чагыла анда. Нәкъ менә Гариф ага язганнарда Шагыйрь образы—чор, шәхес төшенчәләреннән аерылгысыз: бу турыда ул кайта-кайта әйтә (1981, 1999 еллар). Өлкән әдипнең бу ышанычын "Сокланам" исемле мәкаләсендә тагын бер халык язучысы—Аяз Гыйләҗев тә үстерә, әйе, башкаларга васыять итә кебек. Аны бигрәк тә шагыйрьнең шәхесе, максатчанлыгы, уңганлыгы, чын булдыклы ир—ил агасы булуы сокландыра.

Ә инде әйбәт шагыйрь дә булган тәнкыйтьче, мөхәррир Наис Гамбәрнең "Шигъри дөньяга сәяхәт, яки 3 томлык фонында иҗади портретка штрихлар" исемле, үзе үк—китап эчендәге нәни бер китап булырлык, чын мәгънәсендә әдәби трактат-эссе саналырга лаек күләмле язмасында шагыйрь үзенчәлекләрен ачуда бик күп кызыклы эзләнүләр, фәнни гомумиләштерүләргә юлыгасың. "Шигъри дөньялар эзлим!" дип белдерә ул һәм шул юлдагы азимутын билгеләүдә ярдәм итүче "Казык йолдызлыгы"—Равил Фәйзуллин шигърияте булуын әйтә. Ә ни ул—Олуг Шигърият? Ул "шагыйрьнең чынбарлыкка үз мөнәсәбәтен белдерү җирлегендә туа; һәр олуг иҗат—шагыйрь җанының уй-кичерешләренең, яшәү рәвешенең, фәлсәфи һәм рухи эзләнүләренең ак кәгазьгә күчкән моделе; сүз-образлар ярдәмендә ясалган ихлас сурәте һәм җанга үзгәреп күчкән, хыялый тирәнлекләрдә яшәүче чынбарлыкны да чагылдырырга тиеш",—ди Н. Гамбәр. Бездә бу юлларны курсив белән язу теләге туа—өстәп ни әйтәсең моңа! Тәнкыйтьче исә Н. Гумилев сүзләрен дә китерә: "реаль чынбарлык—Күк булса, шагыйрь күңеле—шуны чагылдыручы Күл өсте"—дигән икән атаклы рус шагыйре, бер мәкаләсендә.

Р. Фәйзуллин—әнә шул үз дөньясын тудырган шагыйрь, дип раслый Н. Гамбәр һәм: "әдәбиятка җиңүче булып керде, тикшеренүче-эзләнүче булып, иманын раслап яшәде һәм яши" дияргә дә тулы җаваплылык ала. Мәкалә 1993-1995 елларда язылган. Шундый ук бик үзенчәлекле, кызыклы караш-билгеләмәләр—һәр язганында оригиналь, туры сүзле, хис-фикердә шәрран-яра, хәтта дуамалрак Айдар Хәлимнең "Хакыйкатькә шагыйрь туры керә" исемле мәкаләсендә (шунсы кызыклы: һәркем шагыйрь турында язганында үз уйларына, үз "декларация-манифест"ларына да җирлек таба, җавап эзли!). Айдарча катгый һәм экспрессив фикерләр, күзәтүләр... Шагыйрьнең башлангыч, яшьлек чоры иҗатына карата әйткәннәре дә кызыклы—әйе, "Көрәшчеләр", "Гадиләргә гимн" чорына карата үз фикерләре аның: "Чакырулы-кычкырулы шигырьләребез булды... Күрәсең, бу вакыттагы казабыз милли юлдагы чалулавыбыздан киләдер... Фәйзуллин "кычкыруында да ул кичергән планетар эзләнүнең чагылышы иде ул. Такташның Фәйзуллин үрнәгендә икенче кабатланышы иде". Яки: "...үзенең ачышларын традицион шигырьдә ясады... халыкчанлыкның нечкә, оста сәясәтчесе (моны Айдар гына әйтә ала! Р. Г.) булып калды. Равил безнең барыбызны да "шулай мөмкин икән" дигән фикергә ышандырды. Аның җиңел кулы белән гипотеза еш кына аксиомага әйләнде... аның шигъриятен, башка дистәләгән шагыйрьләребезнең иҗатын тәфсилләп ачып салган тәнкыйть китаплары, монографияләр булмавына бик тә үкенәм. Аһ, күпме сер аларда, аһ, күпме сер бездә!" (1996 елда язылган бу мәкалә безнең буынның—үз "лидер"ына, бәлки, соңлабрак бирелгән бәяседер? Мондый сүзләр язарлык "тел ачкычлары" бездә юк иде әле яшь чакта. Үз вакытында мондый сүзләрне беребез дә, хәтта Айдар Хәлим үзе дә язмады шикелле... Хәер, ул чакта Айдар читтәрәк—Уфада яши иде шул!)

Ә менә бездән егермеләп елга соңрак туган, яңа буын нинди сүзләр таба алды икән? Равилнең әлеге Айдардай аңлаучысы, ихлас, талантлы энесе Ркаил Зәйдулла шагыйрьнең "Сайланмалар"ына язган кереш сүзендә "Идел бит ул, киң бит ул" дигән җыр-гыйбарәне кулланып, Р. Фәйзуллинның иҗат дөньясын, аның тирәнлеген яңача үлчи, халыкчан сурәтләргә таяна: "Бу юл—халык бәгыренә таба юнәлгән... Егерменче еллардан соң татар шигърияте, үзенең табигый агышыннан бүленеп, ялгыш юлга кереп киткән иде. Хәрби терминнар ... политика... Ә Р. Фәйзуллин халыкның моң-сагышына уранып, дөньяга чыга. "Минем тормышым нәрсә соң ул?"—дип сорый һәм:

*Боекса, бөек халкымның*
*күңелен юатумы?—*

дип, җавабын да әйтә.

"Идел—шагыйрьне халык белән бәйли", ди Р. Зәйдулла. Р. Фәйзуллинда "Идел атрибутлары"н да күрсәтә: "пристань, паром, нәни утраулар, акчарлаклар килүе". "Идел ага. Бергә агабыз"—дип, фәлсәфи, шигъри тонда тәмамлый ул. Әйе, төрле буыннар, төрле уй-агымнар! Сизәм: Китапта шактый саллы сүзне шигырьдә бездән соңрак килгән, безне өйрәнгән, күзәткән "энекәшләр"—хәзер инде илленең теге ягындагы талантлы каләмдәшләребез әйтмәдеме икән? Наис Гамбәр дә—шул буыннан иде, ә аның шәриктәше Марсель Галиев янә бер "китап эчендә китап"—"кысалы кыйсса романы" тудырган! Әйе, аның язмасында—бөтен бер буынның шигъри легендасы, Равил Фәйзуллинның исә беллетристика катыш кабатланмас бер портреты... Эссе остасы булган Марсель үзенә хас бер юмор аралаш ярату хисе белән яза, ләкин анда сентиментальлек юк, күе шигъри буяулар, үтемле чаралар астында бик җитди фикерләр, гыйбрәтләр җыйнамасы бу! Ә шагыйрь сурәте—калку, рельефлы, хәтта кимчелекләре белән дә ягымлы, кызыклы, хәрәкәттә,спортчылар омтылышы кебек дәрт-чәм белән, ярышта, беркадәр американча, әлеге Хемингуэйлар яшәешенә якын халәттә, суперменчарак бирелә... Роберт Миңнуллинның кыска гына мәкаләсе дә шагыйрьнең олылыгына ышанып, аның үсеш этапларын тоеп, ихтирам белән язылган: үзе дә ил агасы булып үскән депутат-шагыйребез киң уйлый, иңләп, үлчәп сөйли—халык мөнбәрендәге колоритлы сирәк шәхесләрне барлап, байлыгыбызга сөенә ул. Ә мәрхүм Тәүфикъ Әйди, бөтен гомере буе татарның олуг кешеләрен дөнья буйлап эзләп, табып, барлап яшәгән әдип, Равилгә карата уен да нәкъ үзенчә сүзләр белән әйтә белгән: "...Равил әсәрләрен татар шигърияте үрнәге итеп, теләсә кайсы милләт вәкиленә тәкъдим итәргә, шул әсәрләр аша аларга фаҗигале үсеш юлы узган халкыбыз рухын танытырга мөмкин"—диген ул.

Ә өлкәнрәк замандашы Рахмай Хисмәтуллаңың: "Мин Равилне татарның иң батыр рухлы кешеләренең берсе дип саныйм" дигәне? Ул, хәтта, шагыйрь турында "атаклы кешеләр тормышы" сериясеннән китап язарга да ясканып йөргән" икән...

Икенче бүлек исә шагыйрьнең китаплары басылып чыгу уңае белән вакытында дөнья күргән—каләмдәшләре, тәнкыйтьчеләр һәм галимнәрнең матбугатта басылган мәкаләләреннән тупланган. Еллар узгач, аларны искә төшереп, янәдән уку шулай ук кызыклы, гыйбрәтле. Әйтик, беренче китабы "Аҗаган"га дусты Ренат Харис рецензиясе (1966 елда "Казан утлары"нда басылган). Акыл белән, чама белеп, профессиональ югарылыкта язылган мәкалә ул. Ренатча рациональлек, үз сүзенә ышанып, дәлилләп сөйләү. Артык нык бәяләү, тилереп хуплау да сизелми—без-яшьләрдә шундый халәт иде ул чорда: яшьлекнең үз кануннары, үз хисе! Ә менә аксакалыбыз Фатих ага Хөсни, күбебезне Казанда һәм үзәк матбугатта хуплап, янып, сөенеп кычкырып белдерүдән тайчанмаган яшь йөрәкле әдип, "Мәрмәр" китабы басылгач, "Мәрмәр чүки безнекеләр" (1969) исемле үзе үк шигърияте буяулы мәкаләсен язып чыккан... Баштан ук Равилгә игътибарлы булган Сибгат ага Хәким дә шагыйрь иҗатына хуплау фикерләрен төрле—1973, 1976, 1978 елларда язган этрафлы мәкаләләрендә чагылдырып, аңа зур бәя бирә—шигърият үсеше юлларын алдан күреп, тоеп, аңлап, хәерхаһлык белән язылган алар! Ул да, артык хискә бирелмичә, саран гына тәгъбирләрдә уен ача, әмма фикере-симпатиясе анык, остазларча...

Мөхәммәт Мәһдиев һәм Равил Фәйзуллин мөнәсәбәтләре дә баштан ук бер-берен яхшы аңлап, иҗатын-талантын хөрмәт итеп яшәүнең бер мисалыдыр. Әйтик: шул ук "Мәрмәр" чорында ук үз карашы, симпатиясе, шагыйрь талантына ышанычы булуын раслаган мәкаләсе.

Туфан Миңнуллин һәм Мансур Вәлиев та, "Наз" китабы дөнья күргәч, үз сүзләрен "югары трибунадан" әйтәләр: беренчесе сөенеп, хуплап язылган әдип фикере—хисси отклик булса, икенчесе яшьрәкләр исеменнән, мөгаен, тәүге этрафлы зур мәкалә, 60 еллар шигыренә карата кызыклы күзәтүләрен заманча проблемалар белән бәйләп, яңа буын шагыйре Равил Фәйзуллин поэтикасын, фикри һәм иҗтимагый яңалыгын ачу, аңлату тәҗрибәсе булды ("Безгә ак болыт булу язмаган шул", 1973.). Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев, Равил Рахманилар да—әнә шул юлда, төрлесе төрле елларда, төрле китапларга карата һәм гомум иҗат юлын аңлап, җитди хуплау сүзләрен әйтәләр: күренә ки, яшьрәк буында да—яңа шигърият барышы турында фикер үзгәндә—Фәйзуллин югарылыгы, аның эволюциясе.

Бу бүлеккә—шагыйрьнең "Сәйдәш" поэмасына карата үзенең акыллы сүзләрен

язган музыка белгече Зәйнәп ханым Хәйруллина мәкаләсе һәм атаклы рәссам Әхсән Фәтхетдиновның матур фикерләре, күзәтүләре белән кызыклы язмасы да кергән. Бер сүз белән аларны Музалар туганлыгы чагылышы дияр идек. Әхсәннең быел "Мәйдан" журналында шагыйрьгә язган кайбер хатлары басыла башлау да—шуның бер күренеше... Аурупа шагыйрьләренең рәссамнәр, композиторлар белән олуг дуслыгы кебек ич бу!

Шагыйрь Марс Шабаев—безне өлкәннәр һәм үзенең буыны белән ялгап, хәтта ки килештереп, яшьләрне, бигрәк тә Равилне беренче адымнарыннан ук хуплап, остазлык дәресләре биргән шагыйрь. Ул үзенең холкына, симпатияләренә, яңа шигырь өчен көрәш дәртенә, гомумән, шигърияткә төрле стильләрен аңлый, яклый торган эзләнүчән яшьлегенә тугры калган: "Шагыйрь гаме—ил белән" исемле, Р. Фәйзуллин "Сайланмалары"ның өч томлыгын укыгач язган мәкаләсендә әнә шул елларга янә кайтып, ул—шагыйрьнең үсеш юлларын, этапларын билгели, сөенеч-горурлыгы белән уртаклаша.

Олуг галимнәребез Миркасыйм Госманов, Нурмөхәммәт Хисамов, Фатих Урманче, тәнкыйтьче-әдип Тәлгат Галиуллиннар да шагыйрь иҗатына һәрчак игътибарлы булдылар, табигый, бу китапта да аларның мөбарәк куллары язган җитди хезмәтләре—язмалар бар. Н. Хисамов, мәсәлән, борынгы шигырь белгече күзлегеннән шагыйрьнең ерак бабаларын—шигъри геннар белән килгән рухи тамырларын табып, барлап, анда Сәйф Сараи, Дәрдмәндләр дәвамын күреп, Шәрекъ һәм Гәребнең синтезын тоеп сөенсә, фольклорчы галим Ф. Урманче бу зәминне, илаһи кылларны шагыйрьнең иҗатында халык иҗаты һәм дини мифлар, мәңгелек сурәтләр коды аша билгели, миллилек дәвамын, шуннан килгән олуг сыйфатларын ача. М. Госманов шагыйрьнең "сайланма"сыннан публицистика томнарына тукталып, милләт үсеше, дәүләтчелек, китапчылык, рухи мәдәният һәм химаячелек, бүгенге вазгыять һәм әдәбият мәсьәләләрен күтәрә. Т. Галиуллин исә шулай ук шагыйрьнең публицистикасына анализ ясап, бу иҗатның киңлеген, заман белән нык бәйләнгәнлеген яза, шагыйрь интересларының, зур әдип-шәхесләргә хас булганча, киң һәм тирән булуын раслый.

Галимнәр һәм шагыйрьләр... Үзе үк уйландыра торган янәшәлек бу—бигрәк тә милли мираска, әнкә телебез шигъриятькә уртак караш та, мәхәббәт тә, аның борынгылыгы һәм үлемсезлеге турында ышаныч та ул!

Өченче бүлек—бөтенләй башка фикерләр, хәтта контрастлар белән аерылып тора шикелле: көрәшле дөнья хатирәсе дияр идек без аны. Башында шагыйрьнең бер шигыреннән алынган юллар:

*Балачактан туры*
*без көрәшкә кердек.*
*Бездән көлделәр,*
*без кайтарып көлдек.*

Әйе, бу бүлектә—яңа шигырь, иректә шигырь һәм Равил Фәйзуллин тирәсендә бәхәсләр, дискуссияләр (60 елларда узган ул полемиканы күпләр хәтерлидер!), төрле каршылыклы фикерләр, шигырьнең яңарыш һәм шуны аңлау юлында сүз көрәштерүләр, хәтта "аталар һәм балалар" проблемасы—кыскасы, кызыклы бер шигъри чор елъязмалары! Бу бүлек Хәсән Туфанның—Равилнең 1965 елда дөнья күргән "Нюанслар иле" исемле атаклы, төрле шау-шуларга сәбәпче булган мәгълүм циклы турындагы мәкаләсе белән башлануы да үзенчәлекле. Әйе, аксакал шагыйрь, үзе дә чын новатор булып башлап, Такташ белән бергә яңа шигырь тудыручы, тормышта һәм иҗат эволюциясендә күп үзгәрешләр, төрле мәктәпләр йогынтысы кичергән Туфан ул чакта безнең буынның "яңа шигыре"н танымады, "Юкны эзләмәскә, барны үстерергә!" дип язып чыкты. Хәер, аңа кадәр әле әдип Нурихан Фәттахның 1965 елның язында иректә шигырь турында мәкаләсе—"бомба" булып шартлады, аннан шагыйрь Әнвәр Давыдовның җавабы чыкты. Һәм китте, китте...

Зәет Мәҗитов кушылды бу бәхәскә, янә Марс Шабаев, Хатип ага Госман, Флүн Мусин һәм башкалар... Дискуссия, киңәеп, ике-өч елга сузылды, ул инде "Шигырьдә Тукай, Җәлил традицияләре"н үстерү яссылыгына күчте шикелле; берара Равил үзе онытылып та куйды кебек. Әмма бу бәхәсләр, иҗаты тирәсендә барган сүз-полемика яшь шагыйрьне чыныктырды гына ... хәтта чын шагыйрь, җитди ир итте! "Аҗаган" китабыннан соң дөнья күргән "Монологлар һәм диалоглар" (1967) һәм "Мәрмәр" (1969) китапларында, мөгаен, яңача, өлгергән шагыйрь Равил Фәйзуллин иде инде—моны яшьтәшләреннән, һаман "әтәчләнгән" үзем кебек "Дон Кихот"лардан бигрәк, өлкәннәр һәм тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре тиз сизеп алды. (Беренче бүлекләрдә без аларның язганын күрдек инде). Бу

урында минем дә үз күзәтүләрем белән уртаклашасым килә. Әйе, бу елларда зур шагыйрь буларак, Равил, аның шәхесе, иҗтимагый йөзе, характеры-холкы, яшәү рәвеше, максатлары тәмам ачыкланды шикелле. Башта глобаль мәсьәләләргә кереп, дөньяви һәм мәңгелек сурәтләр белән эш иткән шагыйрь (бу урында аның 1966 елда язган "Карт һәм шагыйрь" исемле кызыклы шигыре искә төшә), без көтмәгәндәрәк, үзенең милли тамырларын ачты: үзебезнең төрки-татар шигыренең чын традицияләре, хәтта формалары да муллан икән бит аңарда һәм фольклор нигезе дә нык икән! Һәм бик актив, хәтта фанатикларча үз юлына, максатына бирелгән, шул юлга шигъри җанын гына түгел, физик тәнен дә (Рахметовтай!) әзерләп ныгыткан көчле шәхес тә! Мөмкинлекләреңне белү, барлау, "барлыгыңны раслау" омтылышлары. Бу—безнең карашка чамасыз үсеп, кайчакта эгоцентризм кебегрәк тә тоелмады микән?

Дусларына да бу холыкка, бу темпларга, ярыш дәртенә, җиңүгә омтылышка көйләнгән яшәүгә, гел актив иҗатка күнегү кыенрак булмады микән башта? Бу бит, дөресен әйткәндә, татарда без укып, белеп, күреп өйрәнгән шагыйрь сурәте түгел иде. Монда романтикага, ниндидер фаталь шагыйрь язмышына, хәтта "пәйгамбәрлек"кә дә урын калмый иде кебек! Каләмдәшләренең—дусларының—сәерсенеп караулары булмады түгел, бәхәсләр дә, чәкәләшүләр дә ят түгел иде яшьлеккә... Роберт Әхмәтҗанның бу китапка кергән "Әгәр без дә эндәшмәсәк..." исемле мәкаләсе дә нәкъ шул чорда, шул настроениеләр белән язылмадымы икән ("Гадиләргә гимн" китабына (1972) рецензия дип басылса да)? Ләкин инде шагыйрьнең буыны ныгыган, ул—Җәлил премиясе лауреаты, иң яшь шагыйрь буларак төрле съездларда катнашу, СССР буйлап сәяхәт, делегация җитәкчесе сыйфатында чит илләргә чыгу, язучыларның Әлмәт бүлеген җитәкләү, Татарстан Язучылар берлегенең рәисе урынбасары булып эшләү; Мәскәүдә һәм башка республикаларда, чит телләрдә китаплар, публикацияләр; 200 томлык "Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе"ндә шигырьләре басылган иң "яшь бәхетле" булу һ. б.—кыскасы, бүген без белгән шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе тормышының тулы канлы үсеше—инде аның "пигы" иде бу еллар! Аннан инде—35 яшьтә Г. Тукай премиясенә лаек булу, бераз соңрак (1999 елда) Татарстанның халык шагыйре исеме бирелү шатлыгын кичерүгә таза-сау йөрәк, бәдән кирәктер шул. Шуңа да бу чор иҗатында тән саулыгы турында шигырьләре күп аның!

Әйе, "таза-сау тәндә тир, мунча түшәмендә—пар тамчылары" сурәте якын аңа. Ләкин, Фатих Урманче яратып кулланганча, "Равил моны яхшы белә" дип, өстисебез килә: борынгылар, бигрәк тә безнең төрки-татар бабайлар "тән үстерү" кебек шөгыльне генә дә бик хупламаганнар, ә рух, җанны үстерү—иң зур хыял булган! Шулай: шагыйрьлекнең, җан әзләнүләренең, халыкка юлның да төрлесе бар, мөгаен... Әлеге, "бердәнбер юл түгел тормышта" дип язган Равилне дә җан, рух әзләнүләре һич тә читләп үтми, әлбәттә. Халык гаме, Дәрдмәндчә моң, тарихи сурәт-сүзләр, борынгылар акылына таяну—алар да Равил шигыренең икенче канаты, "җилпешләре авыр" очышы.

Җитмешенче еллар ахырында—инде алай шау-шулы резонанс алмаса да!—яңа шигырь һәм Равил Фәйзуллин поэзиясе тирәсендә дә яңа бер полемика-бәхәс туып алды, дөресрәге, тәнкыйтьче, галим Ибраһим Нуруллин белән шигърият турында әңгәмәсендә Равил үзе аны, башкаларны бәхәскә тартты бугай... Бу—Мостай Кәримнең татар шигырендә "икенче шартлау"ны ачкан фикерләре белән Р. Фәйзуллин турында язмасыннан, моңа карата Нил Юзиев мәкаләсеннән соң булды шикелле. Аннан Хатип Госман мәкаләсе басылды, башкаларныкы... Кыска шигырьләр турында бәхәс ачылды. Инде Фәйзуллин буыны шагыйрьләрен укып, аны "дәррәү таныган" яңа буын—Зиннур Мансур, Фәиз Зөлкарнәй, Газинур Морат, Мөдәррис Вәлиевләр дә үсеп, ныгып җитте—кыскасы, шагыйрьнең олпат урыны ачыкланган, ул—үсештә иде.

Күршеләргә дә безнең бу дискуссияле-шаулы шигърият тормышы яхшы таныш булган икән: әнә Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев болардан хәбәрдар икәнен күрсәтеп, түбәндәгеләрне әйтә: "Әгәр дә туктаусыз яңару әдәбият үсешенең төп ихтыяҗы икән, бу ихтыяҗ көчле талантлар таләп итә икән, алтмышынчы-җитмешенче еллардан башлап, татар шигъриятендә бу тарихи бурычны башкару күп яктан Равил Фәйзуллин өлешенә төште",—ди ул. "Януыңны халыкларның күмәк тануы кирәк" дип язган шагыйрь бу бәягә риза-мәмнүндер, шаять.

Ә китаптагы дүртенче бүлек—тоташы белән!—шул тануга, шагыйрьнең илнең могътәбәр сүз осталары мәҗлесендә лаек урынын билгеләүгә дәлил була аладыр. Русча язылган мәкаләләр, монография саналырлык хезмәтләрдән өзекләр, хәтта китаплардан аерым өлешләр тупланып бирелгән анда. Арадан—татар шигъriяте үсешенә үтә игътибарлы, безнең буынга гел җылы, аталарча мөнәсәбәттә булган Мостай Кәрим мәкаләсен

рәхмәт хисләре белән аерым искә алып китәсе килә.

Шуны да әйтергә тиеш саныйм: яшь Равилнең (20-22 яшьлек, Маяковскийча әйтсәк, яшь "матур чагы"нда!) иҗатын, зурлыгын башта русча язучы әдипләр, шагыйрьләр күреп алып, әүвәл Мәскәүдә, үзәк газеталарда "сүз-ут җибәреп", аннан Казанда таныттылар. Бу сүзем ялгыш булмас, чөнки ул еллардан Р. Мостафин, Р. Кутуй, Ф. Хөсни, Ә. Бикчәнтәев, Р. Солнцев мәкаләләре бүгенгедәй истә. Бу затлардан кайберләре берничә мәкалә язып, төрле елларда үз фикерен белдереп торган икән. Ә инде русның үзеннән Н. Беляев, В. Солоухин, О. Шестинский, Вад. Дементьев мәкаләләре шагыйрьне үз вакытында тирән аңлап, киң масса укучыга тәкъдим итүләре белән әһәмиятле. Чуваш А. Хузангай, удмурт Ф. Васильев, латыш А. Веян, украин А. Губарьлар язган мәкаләләр дә тугандаш әдәбият вәкилләренең татар шигъриятенең күренекле шәхесләрен нәкъ үз күреп, аңлап язулары белән кадерле. Шуны ук инглиз, төрек телләрендә дөнья күргән антологияләрдә дә тоеп, сөенеч кичерәсең. Ә инде олуг галимә, әдәбиятларны, сәнгатьләрне, жанрларны комплекслы өйрәнүче әдәбият белгече Й. Г. Нигъмәтуллинаның "Запоздалый модернизм в татарской литературе и изобразительном искусстве" китабының бер бүлеге—бүгенге шигърият турындагы өлеше—И. Юзеев, Р. Гаташ һәм Р. Фәйзуллин иҗатларына багышлана. Шуннан алынган, Равил турындагы зур, бик кызыклы концепцияле өзекне (Мәңгелек һәм Тынлык фонында лирик герой халәте!) бу китаптан да укып сөендек (Ә хезмәт элегрәк кытайча, алманча да басылган иде)...

Бишенче бүлектә—шагыйрьгә багышланган шигырьләр (Н. Нәҗми, Р. Харис, Р.Мингалим, М. Әгъләм, Ә. Рәшитов, Р. Миңнуллин, З. Мансуров һ. б.)—барлыгы 26 тезмә һәм 6 үртәмеш-пародия кертелгән. Бу да китапта шагыйрь хакында яңа бер сүз!

Алтынчы бүлектә исә шагыйрьнең өч графикада (гарәп, латин, рус имлясында) басылган кредо-шигыре; конкрет даталар белән бирелгән "тормыш һәм иҗат юлы сәхифәләре", басылып чыккан китаплары (татар һәм рус телләрендә басмалар) исемлеге; "Шагыйрьнең иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге" дип аталган үзе үк бер китап булырдай библиографик хроника һәм авторлар турында белешмә дә урын алган. Болар бар да—фәннилек, югары китап культурасы, үзе үк бер шигърият күренеше.

Әле күңел "исемнәр күрсәткече" булуын да тели: йә, нинди генә исемнәр, шәхесләр искә алынмый бу китапта! Хәтта фоторәсемнәр дә күбрәк булса, нур өстенә нур булыр иде. Сирәк китап бит бу, уникаль басма... Соңгысы булмасын дип телик аны—милләт тормышында яңа сәхифәләр ачыла торсын, яңача, оригиналь басмалар мәйданга килсен—ә шан-шәрәфкә лаек шагыйрьләребез дә, сәнгать, фән, мәдәният әһелләре дә бар безнең.

Шул горурлык хисе белән, Такташ әйтмешли, "хисләремнең тиле дулавы"н, ниһаять, туктатырга тиеш табам. Бигайбә!

**Рәдиф ГАТАШ**
Июль-август, 2003.

---

# ШИГЪРИЯТНЕҢ ТИРӘН ТАМЫРЛАРЫ

Күптән түгел фольклорчы галим Фатих Урманченың "Борынгы миф һәм бүгенге шигырь" дигән гаять кызыклы тикшеренүе дөнья күрде.[1] Китапның исеме үк кызыксыну уята. Чыннан да, бик борынгы ыруглык җәмгыятенең тулы бер идеологик системасын тәшкил иткән мифология белән бүгенге зур үсеш-күтәрелешкә ирешкән татар шигърияте арасында нинди мөнәсәбәт-бәйләнешләр булырга мөмкин соң?

Китабының "Мәсьәләнең асылы. Төп мәсьәлә" дигән бүлегендә автор бу сорауга методологик яктан ачык һәм төгәл итеп җавап бирә. Билгеле булганча, сәнгатьнең барлык

---

[1]Фатих Урманче. **Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш.**—Казан: Школа, 2002, 260 бит.

төрләре, шул җөмләдән тел-сүз иҗаты да, борынгы мифология җирлегендә яралалар. Шигъри әсәрләр иң әүвал телдән иҗат ителеп, күп гасырлар дәвамында халык хәтерендә сакланып килаләр, яттан сөйләү, җырлау юлы белән башкарылалар. Ягъни, поэзиянең күп кенә сәнгатьчә үзенчәлекләре, сюжет-мотивлары, сурәт-образлары, символлары, яңашалекләре нәкъ менә халык авыз иҗатында формалаша. Алар соңрак фольклордан үсеп чыккан язма шигърьнең дә тотрыклы сыйфатлары, традицияләре булып әвереләләр. Шул рәвешчә, профессиональ поэзиянең тамырлары халык иҗаты аша борынгы мифологиягә барып тоташа.

Дөрес, кырыс совет чынбарлыгы, социалистик реализм кысалары шагыйрьләргә әле күрсәтеп үтелгән традицияләрдән файдалану мөмкинлекләрен бик нык чикләде. Узган йөзнең алтмышынчы елларында "Хрущев җепшеге" белән үзен сиздерә башлаган һәм сиксәненче елларның икенче яртысында, бигрәк тә туксанынчы елларда нык үсеп киткән үзгәртеп кору, сүз һәм вөҗдан иреге туу гына безнең шагыйрьләребезгә борынгы мәҗүсилек һәм ислам мифологиясенең поэтик арсеналыннан киң файдаланырга юл ачты.




Димәк, күзәтелә торган китапның төп проблемасын язма шигъриятнең халык иҗаты белән бәйләнешен өйрәнү тәшкил итә. Ләкин моны ничек эшләргә? Кол Галидән алып санаганда, поэзиябезнең тарихы сигез гасырын тутырып килә ләбаса! Шуңа күрә дә автор тикшерү материалын бүгенге шигърият белән чикли. Ләкин аның талантлы вәкилләре дә шактыйга җыела бит. Бер китапка һич сыйдырырлык түгел. Ф. Урманче монда да отышлы юл сайлый: ул үзәккә бер зур фигураны куеп, эзләнүләрен шуның иҗаты буенча алып бара. Китапка "Татарстанның Халык шагыйре Равиз Фәйзуллин иҗатына бер караш" дигән өстәмә исем бирелү башта ук әнә шуны искәртеп куя. Әйе, бу күренекле шагыйрьнең иҗаты—хәзерге татар милли шигъриятенең иң бай һәм җитди бер өлеше. Аның кырыклап китабы дөнья күргән! Хикмәт саннарда гына да түгел. Шагыйрь иҗатының җитлеккән дәвере җәмгыятебездәге яңарыш чорына туры килде, алай гына да түгел, ул бу чорның туасын алдан тоеп, көтеп алды, аның хәбәрчесе булды. "Равил Фәйзуллин иҗатын өйрәнү—бүгенге татар поэзиясенең асылын аңлау юнәлешендә җитди адым ясау дигән сүз",—дип, Ф. Урманче үзе дә моңа басым ясап күрсәтә. Әлбәттә, конкрет күзәтүләр алып барганда, ул Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Зөлфәт, Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләм һ. б. зур шагыйрьләрнең иҗатларына да мөрәҗәгать итә.

Китабының инде атап үтелгән беренче бүлегендә үк автор теоретик һәм методологик мәсьәләләрдән конкрет анализга күчә: анда "Җил тамырын кисәр кылыч юк" һәм "Вакыт кына мәңге тантанада" дип исемләнгән ике бүлекчә урын алган. Моны бик табигый хәл дияce килә. Чөнки Җил дә, Вакыт та дөнья мифологиясенең мәңгелек персонажлары. Алар анда күп төрле, еш кына бөтенләй капма-каршы вазифалар да үтәп йөриләр. Бу—Равил Фәйзуллин әсәрләрендә дә шулай икән. Шагыйрь моны үзе дә махсус күрсәтеп үтә:

*Җилләр шатлык алып киләләр,*
*Җилләр картлык алып киләләр,*
*Җилләр диннәр алып киләләр,*
*Җилләр чирләр алып киләләр...*
*Җилләр алар шундый: теләсәләр—*
*Әллә ниләр алып киләләр!*
*Җил—Вакыт ул, белми тынычлык!*
*Җил тамырын кисәр кылыч юк!*

*1966*

Игътибар иткәнсездер, китерелгән өзектәге "Җил—Вакыт ул" афоризмы тирән фәлсәфи мәгънәгә ия. Халык мифологиясендә Вакыт үзе гадәттә табигать (кыш—яз—җәй—көз) һәм гомер (туу—яшәү—үлем) кебек аерым өлешләргә бүленә, аның уңай һәм тискәре сыйфатларга ия булуы күрсәтелә. Шигъриятенең асыл хасиятләре белән борынгы мифологиягә һәм философиягә бик якын торган Равил Фәйзуллин әсәрләрендә Вакытның да күп төрле фәлсәфи-мифологик үзенчәлекләре чагылыш табуын монография авторы

ышандыргыч мисаллар белән күрсәтеп бара (битараф Вакыт, Вакыт—тарих, Вакыт—фаҗига, Вакыт—Алла, Вакыт—чукмар, Вакыт—ашыктыручы, мәңгелек Вакыт һ. б.)

Равил Фәйзуллин шигъриятe башлангыч чорыннан ук халык иҗатының борынгы мифология, әкият, дастан кебек җитди традицияләренә таянып үсте. Шуңа күрә дә Фатих Урманче үзенең монографиясендә бу проблемага "Әкият-дастаннардан килгән могҗиза" исемле махсус бүлек багышлый. Автор бик хаклы раслаганча, төрле әкияти-дастани-мифологик сюжетларга, мотивларга, образларга мөрәҗәгать иткәндә шагыйрь беркайчан да аларны кабатлап чыгу белән чикләнми, бәлки һәркайсының серле-сихри мәгънәсен тагын да киңәйтә, тирәнәйтә. Шушы фикерне дәлилләү өчен автор Р. Фәйзуллинның "Карт һәм Шагыйрь" әсәренә аеруча җентекле анализ ясаган. Мәсәлән, шунда очраучы "Билгесезлек иләндә" тәгъбиренә кагылып, автор бозай яза: "Бирерә сүз "теге дөнья", соңгырак чорлар карашлары буенча—Җир асты патшалыгы турында баруы үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк. Тик, безгә билгеле булган фәнни мәгълүматлар буенча, бер генә халыкта да "теге дөньяны Билгесезлек Иле дип атау юк. Бу—шагыйрь Равил Фәйзуллин үзе уйлап тапкан һәм һичшиксез уңышлы әкияти-мифологик гыйбарә".

Ырутлык җәмгыяте мифологиясендә, төгәлрәге шул борынгы чорларның халык авыз иҗатында Җиһан, Күк, Кояш, Җир, Ай, Йолдызлар кебек образлар һәм аларда бәйле күзаллаулар киң кулланылган булырга тиешлеге шик-бәхәс уятмыйдыр. Әлбәттә, аларның әдәби-эстетик функцияләрендә җитди генә үзгәрешләр дә булгандыр, хәлбуки әлеге космогоник образлар бүгенге шигъриятебезнең дә сәнгати арсеналында зур урын алып торалар. Р. Фәйзуллин иҗатында исә андыйлар аеруча күп. Һич очраклы хәл түгел, Ф. Урманче үз монографиясендә әлеге мәсьәләне яктыртуга "Илаһи Күк белән киңәшеп", "Һәркемнең үз Кояшы", "Ай янында якты Йолдыз" дип аталган өч бүлек багышлый. Бу бүлекләрдә галим уннарча мифологик сурәтләргә, төшенчәләргә, афористик тәгъбирләргә, исем-атамаларга шагыйрь тарафыннан нинди мәгънә-эчтәлек салынган булуы хакында нечкә һәм тирән анализ бирә, еш кына аларның этимологиясенә, килеп чыгышына караган экскурслар ясап бара, моның өчен төрки-татар чыганакларына гына түгел, ә борынгы Шәрекъ, Европа халыклары мифологиясенә һәм этнографиясенә дә мөрәҗәгать итә. Бу урында, озынгарак сузылса да, бер мисал китереп үтү кызыклы булыр.

Ф. Урманче тикшеренүләре күрсәткәнчә, Р. Фәйзуллин шигъриятендә Кояш образлы күп төрле хәтта капма-каршы вазифалар башкара. Ул, беренчедән, яз, мәхәббәт, якты, бәхетле, шатлыклы тормыш, илаһилык символы булып килсә, икенчедән, кайгы-хәсрәтне, фаҗигане гәүдәләндерә: күз яшендә Кояш нурының чагылуы, канлы Кояш, кара Кояш...

*Планета—Җирнең карыны—*
*Ут оясы, тамуг, җәһәннәм!*
*Кара Кояш анда!*

Кара Кояш образының килеп чыгышы борынгы Шәрекъ мифологиясенә барып тоташа. Индуизмның кайбер мифларына нигезләнгән әсәрләрдә Кояш караңгы, кара, хәтта кап-кара төстә гәүдәләндерелгән. Бу образ зур бәхетсезлек, еш кына үлем белән рәттән куелган. Мондый карашлар борынгы Вавилонда, Анатолиядә, Мисырда, грек мифологиясендә дә таралган була. Билгеле, хәзерге шагыйрьләрнең мондый мифларны белүләре мәҗбүри түгелдер. Алар әлеге образларны традициягә таянып кулланалар. Кара төс кайгы символы буларак язма әдәбият әсәрләрендә дә бик күптәннән очрый. Инде мифологик образның чыганагы, йола-ритуалы, легендасы белән таныш булу иҗатчыга да, укучыга да аны тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Ф. Урманче монографиясенең мондый чыганакларга гаҗәп бай булуын, галимнең киң эрудициясен, чын шигъриятне нечкә сиземләү сәләтен канәгатьләнү белән билгеләп китәсе килә.

Табигать һәм шигърият хакында сөйләгәндә, аңлашыла ки, кошлар дөньясыннан алынган сурәтләмәләргә һәм персонажларга тукталмау мөмкин түгел. Күзәтелә торган китапта да "Сайрамачы, былбыл, ник сайрыйсың" дигән кызыклы бүлек бар. Анда Р. Фәйзуллин иҗатында һәм гомумән бүгенге татар поэзиясендә еш очрый торган Сәмруг, Һомай, Феникс кебек мифик кошлар яки Аккош, Кәккүк, Козгын һ. б. ш. реаль кошларның мәҗүсилек карашлары белән өретелгән образлары җентекләп анализлана.

Татар мифологиясе төп ике өлештән тора. Аларның беренчесен—мәҗүсилек карашлары, икенчесен—Ислам мифологиясе тәшкил итә. Үзгәртеп кору нәтиҗәсендә вөҗдан ирегe торгызылгач, халкыбызга үз динен тоту өчен мөмкинлекләр тудырылгач, бу рухи яңарыш шигъриятебезгә көчле ташкын булып килеп керде. Монографиясенең "Иман

нуры белән рухланып" дигән бүлегендә Ф. Урманче соңгы елларда иҗат ителгән һәм Ислам тәгълиматы, мифологиясе белән сугарылган күп санлы шигъри әсәрләргә тукталып үтә. Монда да иң зур акцент хәзерге татар поэзиясенең төп тенденцияләрен чагылдыручы Р. Фәйзуллин иҗатына ясала.

Китаптагы бүлекләрне күзәткәндә без аларның һәркайсы нигездә конкрет бер мифологик персонажга (категориягә, мотивка һ. б.) багышлануын, ә анализ өчен төрле елларда язылган төрле-төрле шигырьләр файдаланылуын күрдек. Сигезенче бүлектә исә эш башкачарак тора. Анда бары тик бер әсәрнең—зур күләмле, тирән мәгънәле "Сәйдәш" поэмасының мифологик нигезләрен барлык аспектлардан карап ачыклау максаты куела. Табигый ки, без биредә алдагы бүлекләрдә карап үтелгән мифологик мотивларның шактый күбесе белән яңадан очрашабыз (туу—үлем) үлемсезлек, рух, җан, җил, вакыт, кояш, ай, йолдызлар, кара урман, ак күгәрчен, әҗәл, сират күпере, фәрештә һ. б., һ. б.). Хәлбуки, бу гади кабатлану түгел. Бөек композиторның олы, катлаулы, каршылыклы, бәхетле һәм фаҗигале тормыш-иҗат юлын тасвирлау, бәяләү фонында әлеге мифологик сурәт-образлар бөтенләй яңа мәгънәләр хасил итәләр, фәлсәфи яңгыраш алалар. Ф. Урманче моның бик отышлы мисалларын еш китереп бара:

*Илаһи зур талант өстәвенә*
*сирпеп торган аннан затлылык!*
*Күңелендә Кояш булса гына,*
*чәчеп була илгә яктылык.*

Яки:

*Киләчәккә таба ага Вакыт.*
*Туу-Үлемнәрең ни аңа!*
*Яшәү—Мәгънә диеп үйлана тик*
*Кеше дигәннәре дөньяда.*

Равил Фәйзуллин олы шагыйрь генә түгел, ул абруйлы әдәбият белгече, тәнкыйтьче, үз шигъри мәктәбен тудырган остаз. Аның теоретик фикерләре, башка әдипләр иҗаты турындагы уйланулары, мәкалә-рецензияләре матбугатта махсус томнар булып дөнья күрделәр. Ф. Урманче үзенең китабын IV томга язылган киң планлы рецензия белән тәмамлый.

"Борынгы миф һәм бүгенге шигырь" монографиясен автор үзе "фәнни-популяр очерклар" дип тәкъдим итә. Әдәби осталык җәһәтеннән аңа "Шигърият дәресләре" яисә "Шагыйрьнең иҗат лабораториясенә сәяхәт" кебек исемнәр дә ятышып торыр иде. Хезмәтнең төп кыйммәте шунда: галим язма поэзия һәм халык авыз иҗаты (тегәлрәгеаның борынгы мифологик катламы) арасындагы бәйләнешләрне чын фәнни-теоретик нигездә һәм заманыбызның зур шагыйре иҗаты өстендә җентекләп тикшереп чыккан. Әйе, шигъриятебезнең иң тирән тамырлары мәҗүсилек һәм Ислам мифологияләреннән үк килә, сүз сәнгатенең гаять бай хәзинәләре мифологиядә, туган телебездә саклана. Шагыйрьләргә, каләм әһелләренә аларны эзли, таба һәм файдалана белергә генә кирәк. Бу хакта халык үзе дә ачык әйтә:

*Тел дигән дәрья бар,*
*Төбендә энҗе-мәрҗән бар.*

*Белгәннәр чумып алыр,*
*Белмәгәннәр коры калыр.*

**Хуҗи МӘХМҮТОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

*Казанның 1000 еллыгына*

# ХАНЛЫК ЧОРЫНДА КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ФОРТИФИКАЦИЯСЕ

Бу тема тарих фәнендә өйрәнелмәгән диярлек. Урыс елъязмаларында «гаҗәеп» һәм «һичкем ала алмаслык» дип күрсәтелгән урта гасыр болгар-татар башкаласының уникаль ныгытмалары, һичшиксез, төрле яклап җитди тикшеренүләргә лаек. Каланың диварларын, машларын, капкаларын һәм табигый киртәләрен хәтердә янарту Казанның ул чагындагы мәйданын һәм топографиясен күз алдына китерергә мөмкинлек бирер иде. Кызганычка каршы, XVI гасыр Казанының ныгытмалары турында хәбәрләр күп түгел—болар урыс елъязмалары һәм шул чорда яшәгән, Казанны күргән кешеләрнең язма истәлекләре. Шулар арасыннан—«Казанны буйсындыру турында хикәят» (авторы—1552 елда Казанны штурмлауда катнашкан, алдынгы бер цивилизацияне вәхшиләрчә юкка чыгарган канлы-фаҗигале вакыйгаларны үз күзләре белән күргән урыс хәрби башлыгы Андрей Курбский) исемле чыганак тикшеренүче өчен аеруча кыйммәтле һәм ышанычлы булып тора. Ханлык башкаласының топографиясен сурәтләүдә абруйлы мәгълүматлары һәм урта гасыр шәһәренең фортификациясен өйрәнү өчен әһәмиятле ориентир булуын искә алып, без бу мәкаләбездә шушы чыганактан ярыйсы ук күләмле цитата китерәбез: «Дүртенче көнне без Казан крепостена, зур, киң, тигез һәм бик матур болыннарга чыктык һәм шунда гаскәр белән Идел елгасы буена урнаштык. Һәм бу болыннар шәһәргә кадәр бер мильдән артыграк арага сузыла, тик крепость һәм шәһәр Иделдә тормыйлар: алар астында Казан исемле елга, шуның исеменнән шәһәр дә аталган. Әгәр Иделдән карасаң, ул зур тауга урнашкан, ә ногай ягыннан, Кама елгасы һәм Арча кыры дип аталган яктан аңа тигез җирдән киләсең... Һәм менә без Казанга килеп җиттек, ул һичкем ала алмаслык урынга урнашкан: аннан көнчыгыштарак Казан елгасы ага, көнбатышта—бик сазлыклы һәм үтеп чыга алмаслык Болак елгасы. Ул шәһәр яныннан ук агып, почмактагы маш яныннан Казан елгасына коя. Ә үзе Кабан дип аталган ярыйсы ук дәү күлдән агып чыга, бу күл белән шәһәр арасы ярты чакрым. Әгәр кичү өчен яраксыз булган бу елганы үтсәң, күл һәм шәһәр арасында Арча кыры ягыннан бик текә һәм менү өчен җайсыз булган тау торыр. Һәм шәһәр тирәли, шушы елгадан алып Казан елгасы янында ук урнашкан Черек күлгә кадәр тирән чокыр казылган. Ә Казан елгасы ягыннан тау шундый биек, аңа күз салуы да кыен. Шунда крепость, патша сарае һәм бик биек таш мәчетләр тора... *(Курбский А. Казанны буйсындыру турында князь Курбскийның хикәяте // Казанны буйсындыруның 350 еллыгына карата...—122 бит.)*

X—XIII гасырларда ук Казан, Идел Болгариясенең төньяк-көнбатыш җирләренең илбасар урыс князьләренә каршы форпосты буларак, уникаль саклану корылмалары системасын булдырган. Борынгы ныгытмалар чокырлардан, туфрак өемнәре-валлардан, вал өстендәге таш диварлардан, күпер алды корылмаларыннан торганнар. Чокырларның киңлеге якынча 14 метрга, тирәнлеге 4-4,5 метрга җиткән. *(Калинин Н. Ф. Борынгы заманнардан алып XVII гасыргача Казан тарихы. Докторлык диссертациясенең кулъязмасы. // ТФАның Г. Ибраһимов исемендәге ИЯЛИ архивы. Фонд 8, оп. 1, сак. бер. 202).* Валлар да ярыйсы ук биек булып (туфрак өемнәренең нигез киңлеге 12 метр, биеклеге 2 метр), ишелмәсен өчен, шәһәр ягыннан агач беркеткечләр белән ныгытылган булган. Валлар өстендә ак таштан эшләнгән дивар торган. Балчык-известь измәсендә күтәрелгән, үлчәмнәре

50х30х30 һәм 60х30х30 см.лы тупас блоклардан торган диварларның киңлеге 4,5 метрдан да ким булмаган. Мондый таш стеналар Идел Болгариясе шәһәрләрендә билгеле түгел. Алтын Урда чорында Казанның таш диварлары җимерелә, валлар җир белән тигезләнә (җучи ханнары, билгеле булганча, үзләренә буйсынган илләрдә крепостьлар төзүне тыйганнар).



*Казан XVI гасырның I яртысында. Н.Ф. Калинин реконструкциясе.*

Казанда саклану ныгытмалары кору эшләре интенсив темплар белән XIV гасырның ахырында, әле башкала булганчы ук, башлана һәм XVI гасыр урталарына ул куәтле крепость булып җитешә. М. Худяков, Казан белән Болгарны геостратегик яктан чагыштырып, болай дип яза: «Казанның урыны, Идел һәм Кама елгаларының кушылган җирендә үк яткан Болгарга караганда, җайсызрак, әмма табигый яктан Казан ныграк ныгытылган. Болгар кебек үк, ул Иделдән ярыйсы ук еракта, елганың сул, болынлы ярында урнашкан. Шәһәрнең болай урнашуы аның оборонасы өчен гадәттән тыш файдалы шартлар барлыкка китерә, бигрәк тә урыслар килә торган яктан: дошманга Иделне кичәргә һәм сазлыклы тигезлек буйлап биек тауда урнашкан крепостька килеп җитәргә кирәк булган. Шәһәрнең табигать тарафыннан иң ныгытылган өлеше нәкъ урыслар ягына карап тора...» *(Худяков М. Г. Казан ханлыгы тарихыннан очерклар.—Казан, 1990.—25 бит.)* Әйе, табигый-топографик шартлар Казанның оборонасын көчәйтүдә зур роль уйныйлар. Идел елгасының сул яры үзәнендәге Казансу тамагында биек террасада урнашкан ул болгар-татар башкаласы Казан. Бу террасаның өчпочмаклы калкулыгы көньяк-көнчыгышка таба күтәрелә һәм киңәя бара, шунда Кремль урнашкан һәм посад башланган. Урыс тарихчысы К. Воронцов, «Яңа Казанны төзүче, татарларның, бу илгә юлны бик борынгыдан белгән урыслар белән бәрелешүләре котылгысыз икәнен алдан күреп, шушы нигездә Казан өчен каты каршылык күрсәтеп була торган бик тә уңайлы урынны сайлаган», дип язды *(Воронцов К. Урыслар яулап алыр алдыннан Казанның тарихи-топографик очеркы.—Казан, 1890.—2 бит).* Шәһәр урнашкан бу калкулык чокырлар, сызалар, кинәт өзелгән текә ярлар, төшеп-төшеп киткән җирләр һәм тирән тарлавыклар белән киселеп беткән булган. Бу турыда П. Заринский болай дип язды: «...Казанның тау чылбыры... һәр якта эрегән кар һәм яңгыр сулары агымы тәэсирендә төрен һәм юнәлешен үзгәртә торган чокырлар белән киселеп беткән» *(Заринский П. Борынгы Казан очерклары, күбесенчә XVI гасырныкы.—Казан, 1877.—7 бит).* Кремль калкулыгындагы табигый чокырлар шәһәрнең ныгытмалары системасында (тулыландыручы) өлешләр булганнар. Чыганакларда еш телгә алынган чокыр—Тажик чокыры—Кремль урнашкан борынны хәзерге Кремль урамы урнашкан калкулыктан аерып торган. А. Курбский, 1552 елда Казанны өч өлешкә бүлеп: «шәһәрнең ике өлеше, тигезлектәге кебек, тауда урнашкан, ә өченче өлеше, упкындагы кебек, түбәнлектә. Ә Болак стенасыннан алып якынча шәһәр уртасына һәм шәһәрнең түбәнге өлешенә кадәр аркылы шактый ук зур чокыр ята» ди. Тажик чокыры Болак тамагыннан башланып, крепостьның көньяк-көнбатыш ягыннан төньяк-көнчыгышка, Кара күл батынкылыгына барып тоташа язган. Бу ясалма канау 15 гасырда Казан посадының чиге булып торган, шуннан агач ныгытма үткән *(Курбский А. Бөек Мәскәү кнәзе тарихы.—СПб, 1842.—38 бит).* Тажик чокырының 1552 елның 2 октябрендә, Ватан өчен барган сугышның соңгы стадиясендә оборона әһәмияте яхшы билгеле: урыс гаскәрләренең Хан сараена бару юлында киртә булып, шундагы кан коюлы тигезсез сугышта татар халкының иң зыялы егетләре—Кол Шәриф һәм аның шәкертләре берсе дә калмыйча шәһит китәләр. Икенче зур чокыр хәзерге Ирек мәйданыннан башланып, Пушкин һәм Татарстан урамнары буйлап Тукай мәйданына кадәр җиткән. Бу чокырның сул ермаклары Некрасов, Щапов һәм Галактионов урамнарына сузылган. XVI гасырда посад чиге шуннан үткән. Казан Дәүләт Университетының төп бинасы районындагы

чокыр турында 1565—1568 еллардагы язу-теркәү кенәгәсе хәбәр итә: «...острогтагы иске татар каберлегендә кече капкалар торган яр буенда, чокырның Болакка караган ике ягы да укчыларга су өчен бирелде» *(Татарстан АССР тарихы буенча материаллар. 1565—1568 еллардагы Казан шәһәренең язу кенәгәләре.—Л., 1932.—45 бит).* Бу чокырга карап бистә ныгытмасы һәм Ногай капкасы торган. Югары террасаның төньяк-көнчыгыш сөзәклегендә тагын бер зур чокыр башланган, ул, көньякка таба күтәрелеп, Кремльнең көнчыгыш читен әйләнеп, көнчыгышка борылган. Бу чокыр Кремль калкулыгын Арча кырыннан аерып торган, монда елъязмаларда еш телгә алынган Ак, Черек, Мунча һәм Кара исемле ясалма күлләр җәелеп яткан. Урыс гаскәрләренең бу яктан Казанга (бер генә тапкыр) һөҗүм итүләре унышсыз була—күлләрдә һәм сазлыклы җирләрдә сугышчыларның күпчелеге батып үлә. Хәзерге Чернышевский, Бауман, К. Нәҗми, Астрономическая, З. Космодемьянская, Жуковский һ. б. урамнарда, К. Фукс бакчасы җирендә, Горький исемендәге паркта, Арча зиратында шәһәр оборонасы өчен әһәмиятле булган чокыр-канаулар булган һәм алар шәһәрнең катлаулы фортификацион системасының кирәкле элементлары булып торганнар.

Төньяктан шәһәр дошман һөҗүменә бирешмәс булган: мул сулы Казансу үзенең тирән сөзәк чокырлары, чоңгыллары һәм упкын-баткаклыклары белән крепостьның текә сөзәклеген чикләгән. Елганың уңъяк яр буйлары төньякка таба дистәләрчә чакрымнарга сузылган ерып чыга алмаслык куе кара урманнар белән капланган булган. Язгы ташкыннарда Казансуның сулары Кремль калкулыгының итәгенә хәтле менгәннәр, су киткәч, монда күп санлы күлләр, агым-кушылдыклар һәм тиз генә кипми торган сазлыклар барлыкка килгән. Урта гасыр сугышлары чорында мондый сазлыклы-баткак урыннар дошманның хәрәкәт итүенә нык комачаулык иткән. Казанны камаганда полкы белән Казансуның артында (хәзерге Яңа Савин районының көньяк җирләре—элеккеге Гривка һәм Кәҗә бистәләре) торган А. Курбский болай дигән: «Безгә тигез урында, зур сазлыклар эчендәге болыннарда торырга туры килде. Алдыбызда биек тау башында крепость торганлыктан, андагы туплардан без бик кыенлыклар күрдек. Беренче яңгырдан соң ук бу түбәнлектәге коры җирләр сазлыкка әйләнде һәм дымлылык белән тулды.» Шунысын да өстәп әйтергә кирәк, Кремльнең төньяк текә сөзәклеге Казансудан 20-24 метр югарыда тора. Бу елга Федосеев һәм Батурин урамнары тирәсендә Кара күл системасына кергән озын култыклар һәм кече күлләр хасил иткән. Шәһәрдән 6-7 чакрымда җәелеп яткан Иделнең сазлыклы болынлы тугае һәм боргаланып аккан Болак елгасы Казанны көнбатыштан саклаганнар. «Ләмле һәм кичеп чыга алмаслык» Болакның озынлыгы 2,25 чакрым булып, ул шәһәр урнашкан яссы калкулыкларның көньяк һәм көньяк-көнбатыш итәкләрен юган, Түбәнге Кабан белән Казансуны тоташтырган. Болак озынча күл булып, казанлыларның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә кечкенә суднолар йөзә торган елгага әйләндерелгән. Аның урта агымында 2 метр тирәнлектә су торган, балык йөзгән *(Мингазова Н. М., Котов Ю. С. Казан күлләре (тарихи очерк).—Казан, 1989.—48 бит).* Елганың ике яры буйларында чишмәләр күп булган. Габделлатыйф һәм Мөхәммәд Әмин ханнар чорында Болакның фортификация әһәмиятенә нык игътибар бирелә: аның үзәне тирәнәйтелә һәм тигезләнә, яр буйлары чистартыла һәм ныгытыла. Елганың крепость янындагы агымының ләмле халәте, безнеңчә, ясалма рәвештә, фортификация максатында булдырыла (Черек Болак). Н. Калинин Болакның Казан өчен икътисади һәм хәрби әһәмияте турында болай дигән: «Константинопольдәге Алтын Мөгез—Пера һәм Галат өчен; Сити һәм Лондон өчен Темза; Гудзон елгасы Бруклин һәм Йорк өчен, (Болак—Р. С.) елгасы ярларының Казан өчен әһәмияте шундый ук түгелме соң?» *(Калинин Н. Ф. XVIII гасыр Казаны.—Казан, 1929.—9 бит).* Унайлы коры җир юлларының аз булуы аркасында Идел-Казансу-Болак су маршруты ханлык башкаласы өчен төп хәрби һәм сәүдә артериясен үтәгән. Кечкенә судноларның Болактан Кабанга менү ихтималы булуын да истә тотарга кирәк.

Болак артында Патша болыны дип аталган, язгы ташуларда су астында кала торган болын җәелгән, ул сазлыклар, дистәләгән елгалар һәм күлләр белән тулган булган. Эчке Казан елгасы (урыс документларында ул «Ичка» дип бирелгән), Патша, Чыпта (хәзерге тимер юл вокзалы скверы), Саф, Прилуцкое күлләре шактый ук мул сулы һәм зур булганнар. Эчке Казан елгасы белән Кабан күлләре арасында куе, кара урман башланган, ул Түбән Кабан күленең каршы як ярыннан барып, Арча урманына кушылган *(Трофимов В. Казанга поход, аны камау һәм алу.—Казан, 1890).*

Арча кыры ягыннан шәһәр табигать тарафыннан йомшак ныгытылган булган. Бу кыр хәзерге Ирек мәйданы тирәсендә тигезлек булып, көнчыгышка таба төрле формадагы һәм тирәнлектәге чокырлар белән ергаланган булган. Арча каласына таба кара урман башланган: «...посадка көнчыгыштан Арча исемле кыр килеп кушыла, ул зур һәм матур, аны буйлап шәһәр астына Казан елгасы ага, шул ук кырда Кабан исемле күл боргаланып ята» *(Казан тарих һәм мәдәният һәйкәлләрендә.—Казан, 1982.—186 бит).* Бу кырга каршы шәһәр ныгытмаларының иң биек һәм калын диварлары, тирән чокырлы һәм күперле нык капкалары куелган булган, алар турында сүз түбәндә дәвам итәр.

Казан ханлыгы башкаласының үзәге булып Кремль торган. Ул шәһәр ландшафтының баш доминантасы саналган. Монда идарә, гореф-йола, сәүдә үзәкләре формалашкан, административ учреждениеләр һәм монументаль төзелешләр-сарайлар, мәчетләр һ. б. тупланган. Күп гасыр буена ул барлык тирә-якны үзенә тартып торган. Биек, текә тау башында урнашкан Казан кремле дәүләт хакимиятен гәүдәләндергән, үзенең төс-кыяфәте белән тирә-яктагы халыкта, аның дусларында һәм дошманнарында билгеле бер социаль-психик караш формалаштырган, үзе белән исәпләшергә мәҗбүр иткән. Кремльнең нык ныгытмалары-диварлары һәм манлары Казанның архитектура силуэтын барлыкка китергән, посадта, бистәләрдә һәм авылларда яшәүчеләргә илаһи абруй һәм хакимият белән йогынты ясап торган. Фортификацион корылмаларның көчен һәм матурлыгын күзәтү машлары һәм мәчетләрнең биек манаралары тулыландырган. Куәтле, йөз һәм нык диварлар, табигать үзенчәлекләрен исәпкә алып басу ягына чыгарып төзелгән машлар һәм капкалар, андагы бруствер тишекләре, төрле биеклектә урнашкан бойницалар якын һәм ерак араларда төрле юнәлештә дошманга каршы сугыш алып барырга мөмкинлек биргәннәр. Кремль һәм посадларның оборона системасы элементларының зирәк рәвештә бер-берсе белән бәйләнгән булуы шәһәрне периметры буенча актив саклауны булдырган, аны көчле дошман яулы ала алмаслык крепость иткән.

Урыс тарихчысы М. Богдановский язганча, XVI гасыр уртасында Казан эченә вак таш, елга комы һәм ләм тутырылган имән бүрәнәләрдән эшләнгән кура белән уратып алынган булган: «Татар Казанының стеналары—шәһәрнеке һәм посадныкы—имәннән эшләнгән, тарас итеп үрелгән һәм аның эченә елга комы, таш һәм балчыклы ләм тутырылган; бу тышкы һәм эчке ягы агач стена каркасы эчендә бетон корылма кебек булган, артиллерия снарядлары бу корылманы берничек тә үтәли тишеп чыга алмый иделәр» *(Богдановский М. 7060—7061 елларда (1552) Казанны камауның инженер-тарихи очеркы.—СПб, 1898.—10 бит).* Ныгытмалар шахмат тәртибендә төрле биеклектә, урыны белән аркылы бәйләнгән тышкы һәм эчке стеналардан корылганнар. Стеналарның өске өлеше крепость алдында яткан урынны саклау максатында эшләнгән булган—анда ыргытучылар һәм укчылар урнашкан. Аларны дошман утыннан ышыклау өчен 140 см. биеклектә юка агач стена куелган. Стеналарның һәм машларның иң өске өлешендә укчылар һәм сакчылар ике яки дүрт сәзәкле түбәләр белән ябылган мәйданнарда урнашканнар. Кремль стеналарының биеклеге кайсыбер урыннарда 8,5 метрга житкән, ә калынлыгы 4 белән 9 метр арасында тирбәлгән. Арча кыры ягындагы диварның калынлыгы 15 метрга житкән. Крепость стеналары алдында (кайсы очракта артында) 8 метрдан алып 21 метрга кадәр биеклектә жир валлары өелгән, шунда шәһәрне саклаучыларның блиндажлары корылган булган. Блиндажлар алдында тирәнлеге 15 метр киңлеге 6 метрлы чокырлар казылган булган. Стенаның эчке ягыннан чокырларга «Патша китабы»нда «оялар» дип йөртелгән потерннар чыккан, казанлылар чигенгәндә шушы ояларга—тишекләргә кереп юкка чыкканнар. Стеналар өстендә урысча «облам» дип йөртелгән брустверлар урнашкан, алар түбә астында булып, шунда һөҗүм итүче дошманга ыргыту өчен бүрәнәләр сакланган. Өске стеналарда шәһәрне саклаучыларның туплары урнаштырылган булган (бу урыннарда стенаның киңлеге 19 футтан (5 м. 80 см.) ким булмаган.

Кремль стеналары турында аерым әйтергә кирәк. Казан тарихчысы М. Рыбушкин, урта гасыр Казанының ныгытмалары турында түбәндәгеләрне искәрткән иде: «Крепость стеналарының нигезе кыргый таштан булуы аларның табигый булуыннан битәр ясалма икәнлеген исбатлый» *(Рыбушкин М. Казан шәһәренен кыскача тарихы.—Казан, 1849.—70 бит).* Урыс чорындагы «таш стена татарларның элеккеге таш стенасы урынында күтәрелгән», дип күрсәтә С. Шпилевский. Археолог Ф. Хужин,

XIII гасырда монголлар тарафыннан җимерелгән таш ныгытмалар XIV гасырның икенче яртысында яңадан тергезелгән һәм Казан ханлыгы чорында үз функцияләрен үтәгәннәр, дип раслый. Кремль калкулыгының көнчыгыш битендәге таш дивар известь эретмәсе белән кушылган ташлардан һәм эре кирпечтән торган. Стенаның киңлеге 250 см., биеклеге 320 см. калкулыкка таба бераз (40-50 см.) авышып тора. Бу диварның XVIII гасыр урталарына кадәр үз функциясен саклавы билгеле. Археологлар фикеренчә, хәзерге кремль стеналарының чынлап торып өйрәнелмәве аркасында бу корылмаларның Иван IV чорында төзелүе аксиома булып кала. Диварларның ханлык чорыннан ук килүе, ә урыс патшасының соңгы сугышта җимерелгән урыннарны гына төзәттерүе турында яңадан-яңа фактлар барлыкка килә. Дөрес, Н. Калинин тарафыннан беренче булып әйтелгән бу гипотеза тикшеренүләрне таләп итә *(Шпилевский С. М. Казан губернасының борынгы шәһәрләре һәм башка болгар-татар истәлекләре.—Казан, 1877.—461 бит; Болгар шәһәрләрен археологик өйрәнү: Җыентык // редколл. Ф. Ш. Хуҗин һ. б.—Казан, 1999.—18 бит; Ситдиков А. Г. Борынгы Казанның саклану корылмалары // Урта гасырлар Казаны: барлыкка килүе һәм үсеше. Халыкара фәнни конференция материаллары.—Казан, 1997.—22-33 битләр; Хуҗин Ф. Ш. һ. б. Борынгы Казан: археологик тикшеренүләрнең кайсыбер нәтиҗәләре һәм перспективалары // Тарихчылар һәм замандашлары карашларында борынгы Казан.—Казан, 1996.—423-424 битләр)*. Безнең уйлавыбызча, 1552 елда 22 яшьтәге Иван патшаның Кремль стеналарын күреп гаҗәпкә калуы беренче чиратта Казан крепостеның таш стеналары белән бәйле. XVI гасырның урталарында урыс шәһәрләренең күпчелеге агач ныгытмалардан торган, ә «ярым күчмә-ярым кыргый татарларның» крепосте ак таштан эшләнгән булсын әле!

Оборона системасында аеруча әһәмиятле рольне посад стенасындагы керү-чыгу юлы булган 9 маш-башня һәм берничә күзәтү (дозор) машлары уйный *(Казан тарихы. 1 нче китап.—Казан, 1988.—31 бит)*. Шәһәр урнашкан урынның катлаулы топографиясеннән чыгып машлар бер-берсеннән 70 м.дан алып 240 м.га кадәрге арада урнаштырылганнар. Алар стена алдын һәм өстен буйга утка тоту өчен эшләнгәннәр. Машлар дүртпочмаклы буралар булып, стена өстеннән берничә метр югарырак һәм берничә каттан торганнар. Түбәнге этаж тар крепость капкасы булып хезмәт иткән; кайсыбер очракларда шунда кораллар, тормыш өчен кирәк-яракларны саклаганнар; уртанчысы сугыш барышында крепость стенасының оборонасын ныгыту өчен файдаланылган; иң югарыгы кат сакчылар өчен торак хезмәтен үтәгән һәм 4 сөзәкле түбә белән ябылган. Машлар алдындагы чокырлар өстендә күперләр яткан, аларның күтәрелмәле булулары турында хәбәрләр юк. Машларның эчке капкалары тышкыларына карап тормаган, аларның буталчык итеп урнаштырылуы тышкы капкадан бәреп кергән дошманны авыр хәлгә куйган. Капкалар борыслар белән тышланган булган.

Посад ныгытмаларының калдыклары КДУ ның физика корпусы һәм Дәүләт архивы бинасы арасында табылган. Болар—киңлеге 15-20 м. һәм биеклеге 3-4 м. чамасындагы туфрак өемнәре—валлар. Чокыр һәм вал формасындагы ныгытмалар Лобачевский, Дзержинский урамнарында һәм Пассаж бинасы тирәсендә өйрәнелгән.


Шәһәр оборонасының тышкы сызыгы буларак, посад дошманның һөҗүмен беренче булып кабул иткән, аның кысрыклавын тоткарлаган һәм Кремльгә сугышка хәзерләнергә мөмкинлек биргән. Казан ханнары XVI гасырның беренче яртысында посадны ныгытуга игътибарны көчәйткәннәр. Габделлатыйф хан 1500 елда шәһәр тирәли ныгытма—отрог төзетә, 1530 елда, Казанга урысларның зур һөҗүме янагач, Сафагәрәй хан әмере белән шәһәр периметры буенча тирән һәм киң чокыр—канаулар казыла, биек итеп валлар өелә.

Озын һәм калын имән бүрәнәләрдән торган посад стенасы «таулар, чокырлар һәм текә урыннар буйлап» Кремльнең көнбатыш стенасыннан алып, Болакның уң ягы буенча Университет урамына кадәр, аннан К. Маркс урамы белән барып Кремльгә тоташкан (XVI гасыр Казаны чикләренең, стеналарының, машларының һәм капкаларының урыннарын билгеләү шартлы рәвештә генә бирелүен искәртәбез). «...Казан шәһәре бигрәк тә нык, ике елга—Казан һәм Болак арасындагы биек урынга урнашкан, озын һәм юан имән бүрәнәләрдән торган җиде кат стена белән уратып алынган: стена эченә елга ләме, вак таш салынган, стенаның Казан һәм Болак елгалары ягыннан калынлыгы өч сажин, бу урыннардан шәһәрне алып булмаслык... барлык яктан да шәһәр нык стеналар һәм су белән чолганган, бары Арча кырыннан

гына ана үтеп була, тик ул яктагы стенаның калынлыгы 7 сажинга житә һәм аның алдында бик тирән һәм киң канау казылган...» *(ПСРЛ, т. XIX.—119-120 битләр).* Дөрестән дә, посад стенасын 7 буын-звенога—урысча «прясло»га бүлеп була (ике маш арасындагы агач стена «прясло» дип аталган). Беренче буын—крепостьның көнбатыш өлешендә урнашкан Түбән капкасыннан (бу капкадан Түбәнге посадка иң кыска юл булган) көньяк-көнбатыш юнәлештә Болакка кадәр, Аталык капкасына чыккан (Аталык капкасының урыны 1 Май мәйданыннан төшкән юлның Бауман урамы белән кисешкән ноктасы дип санала. Бу капкадан юл Болак тамагындагы пристаньнарга юнәлгән.). Икенче буын Болакның уң як яры буйлап Кырым капкасына кадәр дәвам иткән (К. Нәҗми һәм Островский урамнары кисешкән урын). Бу капка Кырымга карап торган, аннан башланган юл Болак артына, Кораеш бистәсенә, Иделгә илткән. Өченче буын көньяк-көнчыгыш юнәлешкә борылып, Бауман урамын кисеп үткән һәм Түбән Ногай капкасына килеп терәлгән (Бауман һәм Университет урамнары кисешкән урында). Бу капкадан Ногай юлы башланган, ул юл Кабан күле буйлап хәзерге Спартак, Һади Такташ урамнары белән көньякка, Ногай жиренә юнәлгән. Астрономическая һәм Профсоюз урамнары чатындагы Тукай чокыры өстендә Югары Ногай капкасы торган. Бу буын Университет тавына әле генә югарыда күрсәтелгән тирән һәм киң Тукай чокыры буйлап күтәрелеп, Хан капкасына барып туктаган (Лобачевский һәм Кремль урамнары чаты, Университет тавыннан Ленин бакчасына төшә торган сөзәклек башы). Дүртенче буын төньяк-көнчыгышка таба барып (Ленин бакчасының түбәнге өлешеннән, Пушкин һәм Галактионов урамнары кисешкән районда) Пушкин урамы буйлап Ирек мәйданына менгән. Бу мәйданда, Пушкин һәм Маркс урамнары чатында, хәзерге М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры районында Арча капкасы торган, бу капкадан юл шәһәрне Арча юлы, Арча шәһәре һәм Себер белән бәйләгән. Арча юлы ике олы чокыр арасындагы тигезлектән барган. Бишенче буын Тельман һәм З. Космодемьянская урамнары буйлап барган, Тельман урамы уртасындарак Кәбәк (Кабак, Кайбат) капкасы торган. Н. Калинин капканың урынын Касаткин урамындагы чокыр тирәсендә дип, аның посадның төньяк-көнчыгыш өлешенең Казансу яр буйлары белән элемтәсе өчен әһәмиятле булуын күрсәтә. Алтынчы буын Нагорный урамы буйлап барган. Жиденче буын, төньяк-көнчыгышка таба борылып, Сбойливый капкасына килеп тоташкан. Бу капканың төгәл урыны турында тарихчыларның фикерләре төрле. С. Шпилевский, 1565—1568 еллардагы язу-теркәү кенәгәләренә таянып, аның урынын Никольский (Пятницкий) чиркәвенә каршы, дип яза. Н. Калинин капканы Тажик чокырындагы Дмитриев капкасы белән тәңгәлләштерә һәм бу капканың Кремльдән Казансуга чыгу өчен жайлы булуына басым ясый: «Алабуга капкасыннан чыгу юлы, беренчедән, бик текә, икенчедән, Хан сарае янынан үткәнгә, моннан кереп-чыгу юлы тыелган да булуы бик мөмкин. Бу урында чокыр буйлап сөзәк юл үткәнен дә әйтергә кирәк, мондый хәл дә хәрәкәтне, билгеле, тоткарлаган.» Шулай итеп, Н. Калинин Сбойливый капкасын Кремльнең төньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш белән элемтәсе өчен «иң шәп капка», дип саный. П. Заринский бу капканы Черек (Поганый) күлләр инкүлегендә дип күрсәтә, С. Алишев та капканың шушы күлләр районында булуын әйтеп, ханлык Казаны капкаларының урыны турында карашларның бәхәсле икәнен искәртә *(Алишев С. Х. Казан шәһәре историографиясе буенча чыганаклар.—Казан, 2001.—50 бит).*

Кремль стенасындагы капкалар—Алабуга (Елбугины, Ильбугины—Елга буйга капка түгелме икән?)—Казансуга каршы төньяк-көнчыгыш диварда, дүртпочмаклы Воскресенское машына туры килә; Нургали капкасы—хәзерге Тайницкие дип аталган капкадан ерак булмаган, крепостьны Болак тамагындагы пристаньнар белән тоташтырган, шуннан Мәскәүгә юл тотканнар; Олы капка (Большие)—хәзерге Спасск капкасыннан ерак булмаган; Түбән һәм Сбойлы капкалары турында югарыда әйтеп үтелде («Сбойливые» исеме бу капканың Черек күлләр суы буенда урнашканга татарның «Су буйлы» атамасыннан алынган булуы ихтимал). Кремль һәм посад стеналарындагы капкалардан олы юллар—урамнар башланган: Беренче магистраль юл—крепость һәм Югары посадны тоташтырган, Хан һәм Ногай капкаларына барган юл. Бу юлдан ике якка—Кара күл чокырына һәм Болакка таба тыкрыклар төшеп киткән. Икенче Магистраль юл—Кара күлләр чокыры буйлап Казансу ягына барган урамнар—юллар, алардан тыкрыклар көнчыгышка, Арча (К. Маркс) урамына күтәрелгән. Өченче олы юл Аталык капкасыннан Ногай капкасына барган (хәзерге Бауман урамы), андагы тыкрыклар Югары посадка һәм Болакка илткәннәр.

Н. Калинин XVI гасыр уртасындагы Казанның Кремль мәйданын 29127 кв. м., посадларныкын 1074456 кв. м. итеп күрсәтә. Шәһәрнең гомуми мәйданы 1103583 кв. м. килеп чыга. Посадның мәйданы крепостьныкыннан 37 тапкырга зуррак булган. Шушы саннар ул чорда Казанның Көнчыгыш Европада иң эре шәһәрләрнең берсе булуын исбатлый. Табигать тарафыннан һәм казанлыларның осталыгы белән ныгытылган татар башкаласы хәтта Явыз Иванның да гаҗәпләнү катыш мактаулы бәяләмәсенә лаек булган. Казан диварларын карап йөргән урыс патшасы «Стеналарның биеклеген, ныклыгын һәм гадәти булмаган матурлыгын күреп гаҗәпкә калды» *(ПСРЛ, т. XIX.—119 бит).* Билгеле, Европа шәһәрләренә (шул исәптән урыс калаларына да) хас булмаган Көнчыгыш стилендәге таш мәчетләрнең күккә омтылган биек манаралары, хан һәм аксөякләрнең сарайлары, «хәйран калган күп кеше капкалары», мавзолейлары Казанга кабатланмас үзенчәлекле төс биреп торган.



*Сөембикә манарасы. Э.П. Турнерелли (1813—1854 елдан соң) гравюрасы.*

Казанның фортификация системасында аерым урынны тайниклар—җир асты юллары алып тора. Бу юллар турында беренче булып А. Курбский һәм «Патша китабы»нда искә алына: «Биек маш һәм җир асты юллары астына казылды, алар (казанлылар—Р. С.) шуннан бөтен шәһәргә су алалар иде, шунда йөгерме дәү мичкәләрдә дары куеп шартлаттылар». «Патша китабы» татарларның Казан елгасыннан Нургали капкасы янында «тайник»лары бар, аңа җир асты юлыннан йөриләр», дип хәбәр итеlә. Урыс тарихчысы Н. Спасский түбәндәгеләрне язган: «Сөембикә манарасы астындагы яшерен җир асты юлыннан башка 1872 елда Спасс монастыре белән хәрби училище арасында яшерен чишмәгә алып баручы икенче бер юл табылды. Шундый ук җир асты юлы император Александр II һәйкәле өчен нигез казыганда крепостьтан Кунак йорты юнәлешендә табылды... Җир асты юллары 3 ирләр гимназиясе бакчасыннан Кабан күленә барган юлда, төрмә замогы бинасыннан (элек анда татар посадының машы торган) Казансуга барган җирдә беленде. Аларның барысының да чыгышы—XVI гасыр татарныкы» *(Спасский Н. Туган илне өйрәнү буенча очерклар.—Казан, 1913.—245 бит).* Кремль тавындагы җир асты юлларының күплеге турында урындагы риваятьләргә таянып, Н. Загоскин шәһәрнең бу өлеше ханлык чорында җир асты юллары белән киселеп беткән, дип ассызыклап үтә. Бу җир асты юллары, күрәсең, крепостьтан якын-тирәдәге капкаларга, чокыр-канауларга, сулыкларга чыккан.

XVI гасыр ханлык Казанының реаль силуэтын тулы итеп күзалларга тарихи чыганакларның бик аз булуы киртә булып тора. Шәһәрнең ул чордагы фортификациясе турында язма, картографик, рәсем һәм башка чыганаклар сакланмаган. Шушы эпохада язылып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән аз санлы төрки-татар әдәби әсәрләрендә Казан турында, аның топографиясе һәм фортификациясе турында мәгълүматлар юк диярлек. Бу чордагы шәһәр, аның ныгытмалары турындагы мәгълүматны күпчелеге тенденциоз булган урыс елъязмаларыннан һәм тарихи әдәбиятыннан алабыз. Башкалабызның меңьеллыгын каршылаганда урта гасыр шәһәрен һәм аның тирә-ягын өйрәнү өчен киң масштаблы һәм төрле яклы (беренче нәүбәттә тарихи археологик) тикшеренүләр җәелдерелергә тиеш. Тарих тузаны астына калып югалган мәшһүр бер цивилизациянең башкаласы, һичшиксез, җитди өйрәнүләргә лаек.

**Ринат СОЛТАНОВ.**

# XX ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ЙОРТ–НИГЕЗ ОБРАЗЫ ҺӘМ МИЛЛИ ЭСТЕТИКА

Татар әдәбиятында тарихи-мифологик дәверләрдән бирле сакланып килгән, халык тормышын, аның яшәү фәлсәфәсен чагылдырган образ-символлар бик күп. «Йорт-нигез» образы исә, әнә шундый архетип образлар рәтенә керә.

Бу хакта төрле халыкларның төрле буын вәкилләре кызыклы күзәтүләр ясаганнар. Мәсәлән, рус әдәбиятчысы И. Б. Роднянская: «Йорт» кебек аерымланып, төрле яклап киртәләнеп алынган традицион ябык пространство модельләре [...], матур әдәбиятта элек-электән «дөнья моделенең» төгәл һәм аңлаешлы билгесе булып санала»,—дип яза *(Роднянская И. Встречи и поединки в типовом доме / Север.—1980. № 9.—С. 107).* Безне кызыксындырган символ турында татар язучысы Галимҗан Гыйлманов та: «Һәр йорт, өй-нигез—Тәңре дөньясының кечкенә моделе кебек»,—ди. Галим Т. Цивьян, мәсәлән, өй образының кеше һәм дөнья мөнәсәбәтләрендәге бик күп мәсьәләләрне яктыртырга ярдәм итүен әйтә *(Цивьян Т. Дом в философской модели мира // Учен. записки Тартус. ун-та.—Тарту: Изд-во ТГУ, 1978).* Люсьен Февр исә, өйнең кеше тарафыннан төзелеп, ахырдан шул кеше өчен гаҗәп әһәмияткә ия булуы турында искәртә. Фрейд, Юнг кебек философ-психологлар шулай ук, йорт образын шәхеснең эчке дөньясының якты бер маягы итеп күрәләр. Кыскасы, бу хакта фикеребезне галимә Г. С. Левинская сүзләре белән йомгакласак, өй образы тормыш-көнкүренеш темасына язылган бик күп әдәби әсәрләрнең төп үзәге, кеше язмышын билгеләүче бер чыганак ул! *(Левинская Г. «Дом» в художественном мире Юрия Трифонова // Филологические науки.—1991.—N 2.—С. 3).*

Татар әдәбиятында исә, бу образны без фольклор әсәрләрендә үк очратабыз. Әйтик «Идегәй» дастанында мондый юллар бар:

*И Идел йорт, Идел йорт!*
*Идел эче имин йорт,*
*Атам кияү булган йорт—*
*Иелеп тәзем кылган йорт;*
*Анам килен булган йорт—*
*Иелеп сәлам әйткән йорт...*

Аңлашылса кирәк, биредә, һәм гомумән, фольклор әсәрләрендә «йорт» образы—ил, халык, туган җир, дәүләт мәгънәсендә килә.

Халык авыз иҗатында чагылыш тапкан ил, халык мәгънәләре, «йорт» образының үзәк мәгънәсе буларак, язма әдәбиятта да сакланып кала, үсеш ала. Шуның белән бергә яңа вариацияләр дә барлыкка килә. «Йорт» образына, аның детальләренә аеруча актив мөрәҗәгать итү реалистик проза үсеше заманына туры килә. Әйтик, беренче реалистик роман авторы Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәрендә—Хисаметдинның йорты үзе кебек җыйнак, чиста, Шәриф Камалның «Козгыннар оясында», «Уяну», «Сулган гөл», «Бәхет эзләгәндә» кебек хикәяләрендә—«йорт-нигез» геройларның эчке дөньяларын ачып бирүче образ да. Фатих Әмирхан хикәя-повестьларында, Мәҗит Гафури хикәяләрендә һәм башка бик күп әдипләребезнең әсәрләрендә ул төп образларның берсе булып килә.

Гомумән, әдәбиятыбызда «йорт» образы аша, аны тасвирлаудагы үзенчәлекләр аша милли эстетиканың үзгәрүен күзалларга мөмкин.

Әдәби әсәрнең көчле типологик, гомумиләштерү сыйфатына ия булуын искә алганда, аерым бер «йорт» образы мисалында зур дөньяны күрә алабыз. Мисал өчен XX гасыр әдәбиятының өч вакыт аралыгына туры килгән өч әсәрен алыйк. Без сайлаган әсәрләрнең һәммәсе дә авыл тормышын чагылдыра. Моның сәбәбе аңлашыла да. Милли культура, милли традиция, милли эстетика нәкъ менә авыл җирлегендә саклана. Шуна күрә милли культура турындагы уйлануларыбызны шушы авыл тормышын тасвирлаган, халыкның яшәү рәвешен чагылдырган әсәрләр аша алып барсак, дөрес булыр кебек.

Әсәрнең беренчесе—XX гасыр башындагы тормышны чагылдыра. Ул—Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясе. Икенчесе—Фаил Шәфигуллинның «Өй салуның ние бар?» повесте. Әсәр сугыштан соңгы 50-60 еллар татар авылын күзалларга мөмкинлек бирә. Өченчесе—Ринат Мөхәммәдиевнең «Истәлек өчен—Гыйлемханга» әсәре; ул XX гасыр азагын, ягъни 80-90 еллардагы татар авылы тормышын ача.

«Сөннәтче бабай» әсәрендә «йорт» образына тирән һәм катлаулы мәгънә салынган. Әлеге образның функцияләре төрле. «Йорт» сурәтендә, иң әүвәл, Сөннәтче бабайның портретын күрәбез: «Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде». Такта белән ябылган түбәсе—битен-йөзен, түбә кырыйларыннан үскән үләннәр—таралмаган сакалын, тәрәзәнең яшәргән пыялалары—яшьле күзен, тышкы яктан сыланган күк балчык—киемнәрен хәтерләтә. Охшашлык турындагы фикер әсәрдә кат-кат ассызыклана: «Монда һәр нәрсә Сөннәтче бабайга охшаган. Сөннәтче бабай үзе дә һәр нәрсәгә охшаган иде». Кыскасы, Сөннәтче бабай һәм йорт образлары тәңгәл куеп карарлык. Шуны да искә алыйк, Сөннәтче бабай әсәрдә сөннәт традициясен гәүдәләндерүче. Димәк, авторның сүз сөреше буенча барсак, «йорт образында без Сөннәтче бабай образын күрәбез, ә Сөннәтче бабай образында—сөннәт йоласы гәүдәләнешен табабыз. «Дөресте генә,—дип яза Гаяз Исхакый,—Сөннәтче бабай шул Сөннәтче бабай үзе генә түгел иде: ул шул киемнәре берлән, шул өе берлән шул үткен чалгы пәкесе берлән, шул әллә ничә кат кәгазьгә төргән череге берлән бергә Сөннәтче бабай иде. Бөтен авыл халкы шуны шулай уйлый, авыл халкы шуның шулай икәнлегенә ышана иде». Әсәрдә Сөннәтче бабай сөннәт атрибутларыннан аерылгысыз. Сөннәтче бабайлы булу бу авыл өчен шул дәрәҗәдә гадәти, күнегелгән күренеш, хәтта бу йоланың кайчан, ничек башланганын беркем дә белми. Авылда бабайның яшен дә белүче, исемен дә хәтерләүче юк. Аны бары тик Сөннәтче бабай дип кенә беләләр. Бабай шул дәрәҗәдә борынгы, аны Газраил дә оныткан дип фаразлыйлар. Бу авылда Сөннәтче бабай белән бергә, бернинди хәвеф-хәтәргә карамыйча сөннәт традициясе дә яши. Мәсәлән, көчле янгын вакытында авылның бик күп өйләре янганда—сөннәтче бабайның йорты исән кала. Ә әсәрдә йорт образы белән Сөннәтче бабай образы аерылгысыз, дидек. Йорт—исән, димәк, халкыбызның гореф-гадәтләре, йола-кануннары яши. Әлеге авыл образында исә Г. Исхакый аерым татар авылын гына түгел, бәлки бөтен бер милләт тормышын күрсәткәндер. Сөннәтче бабай образында сөннәт йоласы белән бергә сөннәтле халык образы чагылыш таба.

Сөннәтче бабайның йорты хуҗасының тышкы кыяфәтен хәтерләтсә, аның эче—эчке дөньясын гәүдәләндерә. Сөннәтче бабайныкы гына түгел, ә бәлки халыкның рухи дөньясы әнә шундый пөхтә, чиста-матур булырга тиеш. Димәк, сөннәтле булу—мөселман кешесенә күптән хас күренеш. Сөннәт физик сәламәтлекне, шул ук вакытта халыкның чисталыкка, сафлыкка булган омтылышын күрсәтүче билге дә. Пакь күңелле халкыбыз сөннәт традициясен буыннан-буынга тапшырып, саклап килгән. Сафлык, матурлык кебек сыйфатлар халкыбызның күңел түрендә йөргән. Моны йорт образына бәйле рәвештә, икенче бер образ-символ—сөннәт пәкесе ачыклап килә. Ул йортның иң түрендә, мәртәбәле урынында саклана.

Әмма гасырларны кичкән сөннәт традициясе, төрле авыр елларда да исән калган шундый кануннар—аңсыз кешеләр тарафыннан юкка чыгарылырга да мөмкин икән. Бу очракта, Сөннәтче бабайның ике хатынын чагыштырып карау урынлы булыр. Сөннәтче бабай белән аның беренче хатыны Гөлйөзем әбинең яшәү рәвешен карасак—әдәп-әхлак, чисталык, иманлы булуның югары үрнәкләрен күрербез. Гөлйөзем әби Сөннәтче бабайга һәръяклап ярдәм итүче, сөннәт эшенә зур хөрмәт белән караучы акыллы хатын. Икенчесе исә булдыксыз, шапшак, мәгънәсез хатын-кыз буларак күз алдына килеп баса. Әмма, иң әүвәл, без аның тышкы пычраклыгы артына сыенган рухи караңгылыгын, наданлыгын күрергә тиешбез. Чисталык, гүзәллек символы—сөннәт пәкесенә кара куллар, гамьсез җаннар орынгач, буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәт юкка чыгу хәлендә кала. Яшен дә, исемен дә беркем-хәтерләмәгән йөзьяшәр Сөннәтче бабай да үлеп китә, йорт та

җимерелә. Гуя, уйланыгыз, әнә шундый битараф, мәгънәсез, тәрбиясез кешеләр тарафыннан матур йолаларыбыз юк ителә, дип кисәтә кебек безне әдип. Чыннан да, XX йөз башы татар тормышы өчен бик тә әһәмиятле этап, янарыш этабы бу. Милли аң уянган, милли кыйммәтләрне барлаган вакытта, милли азатлык өчен көрәш башлаганда, халкыбызның гүзәл сыйфатларын саклау бурычын куя Гаяз Исхакый.

Фаил Шәфигуллинның «Өй салуның ние бар?» повесть-трилогиясе татар авылының сугыштан соңгы елларын эченә ала. Салам түбәле йортлар, ачлык, фәкыйрьлек, шуның өстенә чиксез салымнар. Илне җимерек хәлдән чыгарыр өчен халык алны-ялны белми фидакарьләрчә эшли. Әмма эшләгәннәренә бер тамакларын туйдырырлык та ашлык тими.

Әсәр сораудан башлана: «Өй салуның ние бар?». Әмма сүз гади йорт турында гына бармый. Мансур Вәлиев үзенең бер мәкаләсендә нәкъ шушы мәсьәләгә туктала. «Өй салу... Татар егетләре өчен бу—зур эш, егетлекне раслый торган эш. Биредә тагын шунысын да онытмау зарурдыр—безнең яшь язучы егетләребез үзләренең юл башларында иң элек өй салу, куыш кору, баш өстендә түбә булдыру турында уйланалар. Безнең язучыларыбыз сәнгать серләрен өйрәнгәнче, ул хакта уйлана башлаганчы, иң элек үз тормышларын корып җибәрергә тиешләр. Эти йортыннан фатиха гына алып чыгып китеп, барысын да үзләре корырга тиешләр алар! Тормыш кору дигәнең, шулай итеп, безнең язучы егетләргә үтә дә таныш, үтә дә билгеле нәрсә!

Фаил Шәфигуллинның повесте дә әнә шул хакта—яшь бер егетнең үз тормышын кора башлавы турында» *(Вәлиев М. Күңелнең көткәне.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1984.—141 б.).* Күргәнебезчә, «йорт» образы әсәрдә—тормышның нигезе мәгънәсендә килә. Ә тормыш нигезе тиз генә, җайлы гына төзелми шул. Аеруча, әсәрнең баш герое Рәсим кебек саф күңелле гадел кешеләр тарафыннан. Язучы андыйларның дөньяга җайлаша алмавын, үзләре тырыш, намуслы булсалар да, бәхеткә ирешәлмәүләренә басым ясый. Рәсим күпме генә талпынса да, үзенә нигез кора алмый.

Фаил Шәфигуллинның әсәрләрендә «өй» образы, символ буларак, һәр өч кисәктә дә күренә. Йорт—Рәсим өчен әтисеннән калган мирас. Аны әтисе үз куллары белән салган. «Үзенчә матур итеп салган иде дә бит, мәрхүмкәем, бу йортны. Үзе балта остасы булгач, бизәкләп-сырлап эшләде. Яна чагында кызыкмаган кеше юк иде дә соң... Тузды шул...»,—дип әйтә торган була Рәсимнең әнисе *(Шәфигуллин Ф. Өй салуның ние бар?—Казан: Тат. кит. нәшр., 1991).* (Күрсәтелгән мисаллар шушы җыентыктан алынды.)

Яна йорт салу уе повестьның буыннан-буена сузылган. Әмма язмыштан-узмыш булмаган кебек, Рәсим ни генә кылып карамасын, кайларга гына чыгып китмәсен, һаман да шул иске йортка әйләнеп кайта.

Рус язучысы Ф. Абрамов, «авыл прозасы»ның күренекле вәкиле, 1978 елда «Йорт» әсәрен дөньяга чыгара. Биредә дә йорт символик мәгънә алган. Ул үзендә тарихи хәтерне, кешеләрнең алдагы буыннар каршындагы җаваплылыгын гәүдәләндерә. Тарихи хәтер дигәннән, Фаил Шәфигуллин әсәрендә бу образга бәйле түбәндәге логик тезмә барлыкка килә. Йорт ул тормыш нигезе, әмма бу йорт инде искергән, димәк, тормыш нигезенең дә җимерек булуына ишарә ясала. Яшьләр, Рәсимнәр буыны ярык тагарак янында, иске, җимерек нигездә утырып калган. Шулай булгач, ата-бабаларыбызның матур киләчәк, бәхетле тормыш өчен сугышып, кан коеп йөрүләре юкка булган түгелме соң? Рәсимнең—сугыш чоры балаларының, олылар белән беррәттән, ач килеш, тырышып-тырмашып колхозда эшләп йөрүләре, Ерак дингездә балык тоту флотилиясендә чын авыл егетләренә генә хас үҗәтлек белән хезмәт күрсәтүләре нигә кирәк булды? Ил өчен, халык өченме? Соң Рәсим, аның әнисе дә һәм алар шикелле башка бик күп гади кешеләр дә шул халыкның вәкилләре түгелмени? Ни өчен алар бәхетсез? Ни өчен алар өлешсез? Фаил Шәфигуллин «йорт» образына мөнәсәбәтле рәвештә, әнә шундый бик күп актуаль сораулар уята алган. Кешене изүдә совет системасы шартлары капитализм системасыннан ким булмаган. Рәсим образы, аның язмышы моның ачык мисалы. «Йорт» образы—әлеге сорауларны һәм уйлануларны үз тирәсенә җыючы нокта.

Әсәрнең ахырында Рәсимнәр йорты, икенче бер герой, Рәсимнең яшьтәше Хәбирнең өе белән чагыштырыла. Хәбир Рәсим кебек түгел. Аның рухи халәте бөтенләй бүтән. Рәсимнең эчке дөньясын яктыртучы сыйфатлар һәм детальләр: күрше кызы Тәслимәгә саф сөю хисләре; гармунга, җырга мәхәббәт—илаһи дөньяга, мон-рух дөньясына карый. Хәбир, кирәк икән, дуслыкка да, мәхәббәткә дә хыянәт итә ала. Аның эш-гамәлләре белән фәкать җирле хисләр идарә итә. Бу аерманы

«йорт» образы бик ачык күрсәтә. Шуңа күрә бу ике геройның йортлары да ике төрле. «Хәбирләр йорты тагын да биегрәк булып, коймалары исә адәм үтеп керә алмаслык стена булып, каралты-куралары ныгытма почмакларындагы манараларга охшап күренә иде...»

Хәбирнең йорты үзе кебек текә, әмма матур түгел. Бу йорт күңелдә соклану уятмый. Автор сурәтләгәнчә, Рәсимнәрнеке «курчак йорты», аларның йортына «кызыкмаган кеше» юк иде заманында. Димәк, йорт та Рәсим кебек эчке асылы белән матур. Әмма иҗтимагый-сәяси шартларга бәйле рәвештә Рәсимнең күңеленә салынган матур «йорт» идеясе материальләшә алмый.

Рәсим дингезләрдә йөргәндә, Хәбир жайлы гына эшкә дә урнашкан, хан сарае кебек йорт та салдырып куйган. Ахыргы өзектә герой уйчан, боек хәлдә күренә. Геройның бу халәтенә дә «йорт» образы аша карыйк әле. Тормышта Рәсимгә хыянәт белән дә йөзгә-йөз очрашырга туры килә. Һәрвакыт йөрәгендә йөрткән Тәслимәнең Хәбиргә кияүгә чыгуын авыр кичерә ул. Шулай да сынмый, төрле ваклыклардан өстен булып кала. Күңеле еласа да, акылы белән Тәслимәне яхшы аңлый Рәсим. Бай нигезгә, тормышны үз кулында тота белгән кешегә кияүгә чыга бит ул. Ә Рәсимнең утка ташланып, хезмәттәшен коткарып калган «Батырлык өчен» медале бар да, ялгыз әнисе белән бергә картайган, «бер яккарак кыйшаеп, кар каплаган түбәсен кышкы төссез һавада чак-чак кына күтәреп» торган йорты бар. «Рәсим аны-моны дәшмәде, ишек капкаларын тавышсыз гына ачарга тырышып, урамга чыкты. [...] Тәслимәнең шул караңгы йортта, шул биек койма артында яшәвенә күңеле ышанырга теләми, ышанасы да килми иде Рәсимнең...» Егетнең мәхәббәте, якты йолдызы булган Тәслимә шул караңгы йортка бикләнеп калган. Рәсим кебек шәхесләрнең язмышы, Хәбир кебек мәкерле кешеләр кулында, күрәсең. Аның күңеле төшенке, хыялы барып ирешә алмаслык еракта. Ләкин бөтенләй үк сынмаган, үзенә хас хыяллары да, өметләре дә бар.

Үзәккә алынган «йорт» образы тормыш, заман, җәмгыять төшенчәләрен ачыклап килә. Үзәк герой «йорт» образы белән тыгыз бәйләнештә яши. Бу бәйләнеш аеруча Рәсимдә, шулай ук Хәбир язмышында чагыла. Геройның эчке дөньясы зур дөнья фонында нәкъ менә «йорт» образы аша ачыла. Һәм нәкъ шул йорт образына мөнәсәбәтле рәвештә аларның үзләренең бу дөньяда, җәмгыятьтә тоткан урыннары билгеләнә.

Ринат Мөхәммәдиевнең «Истәлек өчен—Гыйлемханга» повестенда XX гасырның 80-90 еллары турында сүз бара. Шушы елларда башлаган үзгәртеп кору сәясәте иҗтимагый активлыкның да, милли хәрәкәтнең дә жанланып китүенә этәргеч бирә. Еракта яшәүче татарлар да милли тарих белән кызыксына башлый, туган якларына тартыла. Татарларның ватаннарына әйләнеп кайту очраклары күзәтелә. Без тукталган әсәрнең төп герое дә әнә шундый язмышка ия. Яшь вакытында ул авылыннан чыгып киткән, туган җирдә тамак туйдырырлык булмагач, ерак шахтага барып эшкә урнашкан. Әмма тамыры читтә төпләнсә дә ят туфракны үз итә алмаган. Гомере буе туган ягын сагынып яшәгән. Шактый гомере узып өлкәнәйгәч, Гыйлемхан, җитди карарга килеп, туган авылына кайта.

Авыл үзгәргән: зур йортлар үсеп чыккан, житеш хуҗалыклар күбәйгән. Гыйлемхан башта тышкы үзгәрешләрне генә күрә, ләкин тора-бара үзгәрешләрнең күпкә тирән—рухи катламда икәнен аңлый. Бу үзгәрешләрнең сәбәбен, аларның татар авылы тормышына нинди тәэсир ясаганын «йорт» образы, аның детальләре ачыклап бирә.

Авылда ямь юк. Элек Нурлы Алан авылы күз явын алырлык чәчәкләп-чуклап «чигелгән» тәрәзә йөзлекләре, кәрнизләр, ай-йолдызлы капкалар белән балкып торган. Автор билгеләве буенча: «...авыл урамы—матурлык чыганагы, үзенә күрә күргәзмә залы, сынлы сәнгать музее вазифасын үтәгән». Хәзер исә матур дип әйтерлеге юк. Берничә дистә ел эчендә авылның йөзе бөтенләй икенче төс алган. Халык күңелендә матурлыкка, гүзәллеккә, сәнгатькә омтылыш кими бара. Күңел тупаслана. Тәрәзә читләрен, кәрнизләрне челтәрләп ясау түгел, кульяулык та чикмиләр хәзер. Ә бит матурлыкка омтылу, үзен яшәгән дөньяны сәнгатьчә бизәү татарларга бик тә хас сыйфат. Хәтта башка халык вәкилләре моны ассызыклый. Мисал өчен, Иван Грозныйга хезмәт иткән рус кнәзе А. М. Курбскийның Казан ханлыгы җирләре буенча сәяхәт кылгач язылган хатыннан бер өзек китереп үтик: «дворы княжат их и вельможей зело прекрасны и воистину удивления достойны» *(М. Худяков. Очерки по истории Казанского ханства, 1990.—215 б.)*. Милли киемнәрне карыйк. Аяк очыннан алып баш түбәсенә хәтле чәчәккә төренеп йөргән бит безнең әбиләребез. Туфракка, җиргә басып йөргән аяк киемнәренә: чүәк, читек,

башмакларына кадәр чигүле-бизәкле булган бит аларның. Хәзер исә, менә шул борынгыдан килгән, гасырларны кичкән сәнгатьлелек юкка чыгарга тора. Геройның уйлары автор фикерләре белән бергә үрелеп бара. Байлык, муллык белән генә бармый дөнья. Булсын алары, алары да булсын, әмма алар матурлыкка киртә түгел, мәйданга әверелсен. Матурлыкның урыны түрдән булырга тиеш» *(Мөхәммәдиев Р. Истәлек өчен—Гыйлемханга / Ак кыялар турында хыял.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1995).* (Күрсәтелмәгән мисаллар шушы җыентыктан алынды.) Күңелләрне мөлдерәтерлек хисләр биргән «матурлык турында уйларга, матурлыкка сокланырга авыл кешесенең вакыты калмый хәзер, диләр». Әмма, техника кешегә ярдәмгә килгән заманда, күп эшләрне машина башкарып, алар тизрәк тә, җиңелрәк тә эшләнгәндә, киресенчә, буш вакыт көннән-көн артырга тиеш иде кебек. Кыскасы, автор әйткәнчә, «матурлыкка вакыт түгел, табигый ихтыяҗ кирәк», дигән нәтиҗә белән килешмичә мөмкин түгел.

Повестьта тәрәзә йөзлеге мәгънәви символ буларак алына, геройның фикеренчә, тәрәзәләр—ул шушы йортта яшәүчеләрнең йөзе, әлбәттә, ул матур, гүзәл булырга тиеш. Производство сәясәтен, мал-табыш процессын үстерү һәм бөтен игътибарны шуңа гына юнәлтү халык күңелен тәмам хәерчеләндереп, ярлыландырып килә. Авыл йортының бизәкләре югалу, матурлыгы җуелу әнә шуны күрсәтеп тора. Бу урында без Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» әсәрен искә төшерә алабыз. Биредә дә «йорт» детальләренә мөрәҗәгать итү күренә, мәсәлән «чорма» мәгънәви символ буларак аңлашыла. Элек чормага йортка бәрәкәт, мул тормыш теләп иң изге ризык—ипи эленгән булса, яңа заманда бер ярты аракы элենә башланган икән.

Гыйлемханның атасы балта остасы булган. «Нинди бизәкләр—чәчәк-кош, ай-йолдызлар сурәте чигеп эшли иде ул»,—дип сагынып искә ала улы аны. Улы үзе дә шул һөнәрне ярата, авылга кайткач та шул эшне дәвам итәргә, яңартырга алына. Бу очракта Ф. Шәфигуллин әсәрендәге кебек матурлык традициясенең буыннан-буынга күчкәнен күрәбез. Әмма социаль үзгәрешләр аркасында бу гадәтләр бетүгә дучар ителгән.

Кыскасы, әсәрдә «йорт» образы гаять мөһим вазифа үти. Тәрәзә, тәрәзә йөзлеге аеруча символик әһәмияткә ия. Тәрәзә эчке дөньяны олы дөнья белән бәйләп торучы чара. Йорт хуҗаларының рухи дөньяларына алып керүче юл да. Йортта яшәгән кешеләрнең дөньяга карашларын чагылдыра. «Йорт» образы аша халыкның фикерләү рәвеше, милли эстетиканың үзгәрүе күренә.

Беренче әсәрдә без матурлыкка куркыныч янаганын, чисталыкка, пакьлеккә алып баручы традициянең куркыныч астында калганын күрдек. бу очракта, без әдәп-әхлак тәрбиясе, мәгърифәт нуры җитмәүне сәбәп итеп санадык, һәр гүзәл традициянең яклауга, игътибарга мохтаҗ икәнен аңладык. Икенче һәм өченче әсәрләрдә исә, ата-бабадан мирас булып калган гореф-гадәт яңара, хыялдагы матурлыкның тормышка аша алмавын күрдек. Сәбәпләр, әлбәттә, һәм социаль, һәм сәяси җирлектә. Совет системасының барлык кешеләрне дә стандартлаштыру, бердәм калыпка буйсындырып яшәтергә тырышуы—кешенең яшәү фәлсәфәсен дә схематиклаштыра, примитивлаштыра килде. Совет идеологиясеннән ваз кичкәч тә, кешегә эш аты, эш колы итеп карау дәвам итә. Авыл җирлеге бары тик мал, ашлык җитештерүче төбәк итеп кенә карала. Матди ихтыяҗларны гына хуплау, шәхеснең иҗади үсешен чикли. Соңгы әсәрдә матурлыкка, сәнгатьлелеккә чит бер нәрсә, кирәксез, бушка вакыт уздыру итеп карау тенденциясенең үсеш алганы ачык күренә. Авыл җирлегендә әнә шундый үзгәреш баруы, милли эстетиканың түбән тәгәрәве аяныч. Бу үзгәрешләрнең авыл җирлегендә баруы аеруча аянычлы. Чөнки авыл милли мәдәниятебезне саклаучы төп төбәк. Халык авыз иҗаты да нәкъ менә биредә туып, яшәп, сакланып, яңарыш кичереп тора. Телебез өчен дә авыл оазис вазифасын үти.

Йомгак ясап әйтсәк, телгә алынган әсәрләрдә «йорт-нигез» образы бу үзгәрешләрне ачык күрсәтте. Шулай да, киләчәктә, татар әдәбиятында халыкның рухи дөньясын чагылдыручы «йорт» образын төзек, матур, мәһабәт итеп һәм аның белән турыдан-туры бәйләнешле геройны көчле шәхес итеп күрергә язсын иде!

**Раушания ШӘФИГУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

*Игътибар!*

## ДИСКУССИЯ: «БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ»

XX гасыр азагында һәм XXI гасыр башында кешелек дөньясының һәм икътисади, һәм рухи тормышында гаять тирән үзгәрешләр барлыкка килде. Элеккеге СССР җирлегендә—без яшәгән җәмгыятьтә—алар аеруча кискен һәм үзенчәлекле чагылыш тапты. Күп дистә еллар буе яшәешебезнең асылын тәшкил иткән икътисади тотрыклылык бетү белән бергә, әхлак критерийлары да сизелерлек какшады, сәяси ориентирлар үзгәрде. Моңарчы халыкның «уртак малы» саналган мөлкәт таланды, таратылды, бүленде; ясалма интернационализм кысаларына куып кертелгән, әмма асылда канәгатьләндерелмәгән милли ихтыяҗлар милләтара мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнүенә китерде, хәтта гражданнар сугышы учаклары хасил булды, яңа буыннарны тәрбияләүдә иҗтимагый идеаллар алышынды... Шул ук вакытта, җәмгыятьтә демократия чалымнары да үсеш ала башлады: сүз һәм вөҗдан иреге, ил-дәүләтләр арасындагы «тимер чаршау»ның алып ташлануы, шәхси инициативага өстенлек бирелү әнә шундый уңай күренешләрдән саналырга хаклы.

Менә шушындый катлаулы, байтак язмышларны ботарлап ташлаган, хәтта катаклизмнарга кадәр барып җиткән җәмгыятьтә әдәбиятның, анығрак әйткәндә, матур әдәбиятның роле кимеде түгелме? «Әдәбият—тормыш көзгесе» дигән шигарьне өлге итеп алган күбебез өчен табигый борчылудыр бу. Моңа кадәр без әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда иң төп факторларның берсе дип инанып килдек. Хәзерге вәзгыятьтә бу чыннан да шулаймы? Гомумән, әдәбиятның үзендә нинди процесслар бара? Сораулар күп. Без, бу очракта, әдәбият, тәрбия чарасы буларак, үз миссиясен югалтмаган дигән фикердә торып, мәсьәләнең бер ягына игътибарны юнәлтмәкче булабыз.

**—Бүгенге татар әдәбиятының (соңгы 20 еллар) каһарманнары кемнәр?**

**—Аларда яшьләр күңелен яуларлык нинди сыйфатлар бар?**

**—Язучыларның бу каһарманнар образын ачып салуда уңышлы һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт? Гомумән, ихтирамга лаек олы язмышлы шәхесләр тиешле дәрәҗәдә чагылыш табамы?**

Әлбәттә, сорауларның формулировкаларын теге яки бу төсмердә үзгәртебрәк тә куярга мөмкиндер, әмма сөйләшү-әңгәмәгә чакыруның мәгънәсе бер: бүгенге татар әдәбиятында «безнең заман герое».

Әдәбиятыбызның бөтен жанрларын да иңләргә тиешле бу сөйләшүдә язучылар, тәнкыйтьчеләр һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынган киң катлам укучылар актив катнашырлар дип өметләнәбез. Сөйләшүне 2004 елның гыйнварында башлап җибәрү күздә тотыла.

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ОНЫТТЫРЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Егерменче гасыр башында татар милли әдәбиятын үстерүгә, янартуга үзенең әсәрләре белән лаеклы өлеш кертеп тә соңга таба илдә урнашкан тоталитар режим һәм шовинистик сәясәт аркасында әдәби мирасы күләгәдә кала килгән татар әдипләре арасында Шәһит Әхмәдиев исеме дә бар.

Күптән түгел галимә Ф. Ибраһимова төзеп Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган “Язмыш” җыентыгына аның “Хан кызы” исемле повесте һәм хикәяләре кергән.




Ш. Әхмәдиевнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр, хезмәтләр күп түгел. 1930 елда дөнья күргән хикәяләр җыентыгына XX йөз башында төпле тәнкыйть мәкаләләре белән танылган Хөснетдин Кәримов язган кечерәк күләмле сүз башында, алтмышынчы еллар “җепшеклеге”ндә нәшер ителгән сайланма әсәрләренә урнаштырылган Сафа Сабировның “Язучы һәм публицист” исемле мәкаләсендә кайбер чыгармалар белән аның әдәби эшчәнлегенә күзәтү ясала. И. Нуруллин, Г. Халитләрнең фәнни-гыйльми тикшеренүләрендә чор әдәбиятының үсеш закончалыкларына нисбәтле әдипнең аерым хикәяләре, йә булмаса Ш. Әхмәдиевнең исеме тезис рәвешендә аталып китә.

Әдипнең тууына түгәрәк даталар уңаеннан басылган С. Сабиров, М. Мөлеков, М. Мөхәррәмов, М. Сәйдәшева һ. б. ларның язмаларында, мәкаләләрендә Ш. Әхмәдиевнең инкыйлаби, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә бәя бирелә. Күренә ки, Ш. Әхмәдиевнең әдәби эшчәнлеген соңгы елларда әдәбият фәне ирешкән казанышлар ноктасыннан яктырту, татар әдәбияты тарихында аның урынын билгеләү соралып тора.

Ш. Әхмәдиев кыска гомер юлында шактый катлаулы, авыр һәм үз заманы өчен олы, иҗтимагый идеалга буйсындырылган, мәгънәле тормыш үтә. Ул 1888 елның 29 декабрендә Чистай өязе Татар Ялтаны авылында туа. Башлангыч белемне шул авыл мәдрәсәсендә ала. Әтиәнисе вафат булып, бик иртә ятим кала. Унбер яшьлек малай, туган авылыннан Оренбургка китеп, Вәли хәзрәт мәдрәсәсенә укырга керә һәм үз көнен үзе күрә башлый. Уфадагы “Галия” мәдрәсәсендә белем алганда Г. Ибраһимов белән таныша. Шушы көннән башлап Ш. Әхмәдиев белән Г. Ибраһимов арасында дустанә, иҗади дуслык урнаша. Аларның биографиясенә күз салсак, уртак яклар шактый: бер үк мәдрәсәләр, гасыр башында күтәрелгән шәкертләр хәрәкәтенә кушылып китүләре, мәдрәсә белән араны өзүләре, университетка укырга керү омтылышлары... Икесе дә социалист-революционерлар партиясенең идеяләрен яклыйлар

Шәһит Әхмәдиев. **Язмыш: хикәяләр, экиятләр.**—Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.—160 б.

һәм соңыннан социал-демократлар, большевиклар фиркасенә кушылып китәләр.

Ш. Әхмәдиев 1910 елда Казанга килә. Шул заманда чыккан газета-журналларда хәреф җыючы, корректор, тәрҗемәче, хәбәрче булып эшли. Беренче әсәрләре дә 1912-1913 елларда матбугат битләрендә басыла башлый. Әдипнең иҗат гомере дә озын түгел, үз эченә 1912-1917 еллар арасын ала. Ул кече проза жанрында яратып эшли: хикәя, нәсер, парча, очерк, хат, әдәби яктан эшкәртелгән әкиятләр, балалар өчен язылган әсәрләр...

Марксистик-ленинчыл идеяләргә чын күңелдән инанган Ш. Әхмәдиев Октябрь борылышларыннан соң, инкыйлаби үзгәртеп корулар белән рухланып, үзенең бөтен көчен, энергиясен һәм сәләтен Казан губернасында гына түгел, Урта Азиядә дә Совет властен урнаштыруга, халык мәгарифе эшләрен җайга салуга багышлый. 1930 елның августында озак дәвам иткән каты авырудан соң 42 яшьлек Ш. Әхмәдиев Казанда үлә.

Ш. Әхмәдиев татар әдәбияты идея-эстетик эзләнүләр, яңа сыйфат үзгәрешләре кичергән чорда яза башлый. Күләме зур булмаган әдәби мирасында ул үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәрә. Аның иҗаты, бер яктан, Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Ибраһимов һәм башкаларның әдәби-эстетик карашлары белән уртак. Икенче яктан, милли прозага унынчы елларда килгән Г. Сөнгати, М. Гали, М. Хәнәфи, Г. Рәфикый, З. Бәшири, Г. Рәхим, Г. Газиз, С. Җәләл, С. Рахманколый һ. б. яшь буын әдипләре белән берлектә Ш. Әхмәдиев татар әдәбиятына күпмедер яңалык та алып килә. Шуңа күрә әдип иҗатында үзенә кадәрге әдәби традицияләрне, XX йөз башы Яңарыш чорының үзенчәлекләрен, Рус-Аурупа әдәбиятларының да парлаклы йогынтысын күрергә мөмкин. Аның әдәби эшчәнлеге жанр байлыгы белән генә түгел, идея-тематик киңлеге, иҗат принциплары, сурәтләү алымнары, чараларының төрлелеге белән дә аерылып тора.

Милли әдәбиятта бай традицияле хатын-кыз темасын гәүдәләндергән "Суга баткан килен" (1912) хикәясе белән ул әдәбиятка килеп керә. Әсәрдә мәгърифәтчелек әдәбиятына хас аң-белем, тәрбия, әхлак мәсьәләләренә басым ясалуны, вакыйга барган шәһәр, авылның тулы исемен әйтмичә баш хәрефен кую алымын, сентиментализмга хас ачы хәсрәтле күз яшьләрен, аһ-зарларын күзәтергә мөмкин. Хатын-кызның хокуксызлыгы, Кәлимәнең комсыз, рәхимсез ата корбаны булып биш йөз сумга сатып җибәрелүе, аның авыр фаҗигале язмышы мәсәләләрен күтәрү бу әсәрне Я. Вәлинең "Ачлык кушты", М. Гафуриның "Ачлык ел яки сатлык кыз", А. Таһировның "Сатылган кыз" әсәрләренә аваздаш итә. Хикәя реализмының Леонид Андреев тарафыннан иҗат ителгән "Асылган җиде кеше" әсәре тәэсирендә үлем карары чыгарылган кешенең рухи кичерешләре, физик халәтен тасвирлау күренешләре белән баетылуы авторның үз иҗатында кызыклы экспериментлар ясавы хакында сөйли. Милли чынбарлыкта хатын-кыз хокукларын, азатлыгын, тигезлеген яклаган "Татар кызына" нәсере дә шушы темага багышлана. Романтик эстетика атрибутларыннан хатын-кыз, мәхәббәт культына бәйле геройларның күңел дөньясын "Сүз истигъмал итмәдем" ("Ышанычын акламау") хикәясе тасвирлый. "Шагыйрь моңая" нәсерендә исә яшәүдән гайрәте чигеп, өметсезлеккә бирелгән ялгыз геройның экзистенция баскычындагы хискичерешләре "исемсез көй", "исемсез кайгы", "канатсыз һәм рульсез көймә", "иге-чиге күренмәгән диңгез", "хәйләле, мәкерле дусдар", "билгесезлек", "ялгызлык" кебек модернистик иҗат юнәлешенә хас алымнар, сурәтләр ярдәмендә күрсәтелә. Ниһаять, аның эчке дөньясында үзгәреш барлыкка килә: күңелендә бөтен нәрсәгә мәхәббәт туа, мәхәббәт көйләрен сайраучы сандугач аның яшәешенә мәгънә өсти.

Ш. Әхмәдиев иҗатында милли зыялылар тормышын сурәтләү кызыл җеп булып сузыла. Бу тема яшәүнең әхлакый һәм фәлсәфи мәгънәсен эзләү мәсьәләсе белән кушылып китә. Шушы юлда татар зыялыларының төрле типлары тудырыла. Яшәү мәгънәсен, идеалын милләткә хезмәт итүдә тапкан, үз көчэнергияләрен, теләк-омтылышларын балалар укытуга, ач, фәкыйрь, авыл балаларына белем бирүгә багышлаган мөгаллимнәр, мөгаллимәләр, яшьләр тормышы, бу юлда аларны сагалаган авырлыклар, кимсетүләр "Мөгаллим", "Хат һәм җаваплар" әсәрләрендә сурәтләнә. Мәсәлән, Ш. Әхмәдиев беренче хикәясендәге вакыйгаларны бәян итүчедән мондый сүзләр әйттерә: Милләте-

безнең истикъбале (киләчәге) сезнең кебек эшлекле, каһарман мөгаллим вә мөгаллимәләргә баглы икәнен хәтердән чыгармагыз; сезнең бөтен читенлеккә түзеп, сызганып эшләвегез генә безгә өмет бирә. Сез милләтнең мәгънәви тамыры: сез нык булсагыз, анын яфрагы яшел, чәчәге матур, җимеше татлы булыр. Яшәгез, татарга файдалы затлар!"—дип аларның көнелләрен күтәрергә тырыштым". Әмма әдип яшьләр арасында милләт файдасына кулыннан бер тиенлек эш кылмәгәннәре барлыгына да ачынып, борчылып яза, аларны "сәрхүшләр" дип атый. Күренә ки, авторның әсәрләрендә милли идеал мәсьәләсе яктыртыла, анын фәлсәфи һәм әхлакый нигезләре ачыклана. Тарихи темаларга мөрәҗәгать итеп "Хан кызы", "Сөенбикә" әсәрләрен иҗат итүе дә шушы мәсьәләнең башка яссылыкта чагылышы булса кирәк.



Алда әйтелгәнчә, Ш. Әхмәдиев иҗаты чорның иҗтимагый, сәяси, фәлсәфи фикереннән, заманның актуаль мәсьәләләреннән, татар халкының рухи, әдәби ихтыяҗларыннан аерылгысыз. Совет әдәбият белеме тарафыннан "үткән тарихны идеаллаштырган" һәм әдипнең "тайпылышы" буларак бәяләнгән "Хан кызы" повесте шушы фикерне раслый.

1921 елда анын 20000 тираж белән тагын бер кат басылып чыгуы, әсәрнең популярлыгы, югары әдәби-эстетик кыйммәте, татар милләтенең күнелендә торган урыны турында сөйли. 1911-1912 елларда, мәгълүм булганча, татар зыялылары, әдипләре сыйнфый көрәш мәсьәләләреннән вакытлыча баш тартып, милләтнең матди, икътисади хәлен ныгыту, мәдәниятен, мәгарифен күтәрү юлында бергәләшеп хезмәт итү максатын алга алалар. Татар халкының үткәненә йөз белән борылу, милли мәсьәләләрнең калкулануы, милли хәтернең янаруы, милли тарихны яктыртуга игътибар арту, милли үзаңның үсүе ул елларда дәүләтчелек идеясенең яна сыйфат алуы, үткәндәге дәүләтебезне сагыну хисләре белән бәйле иде. Хөр мөстәкыйль дәүләт төзү идеясе милли зыялыларның гаменә, изге максатына әйләнә. Шушы максаттан Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Н. Думави, М. Гафурилар белән бергә Ш. Әхмәдиев тә үз әсәрендә Болгар чорын гәүдәләндерүгә алына. Бу повесть болгарчылык мотивларын сурәтләгән бүтән әдипләрнең әсәрләреннән күләменең зурлыгы, эпиклыгы, күтәрелгән мәсьәләләрнең җитдилеге, фикри-мәгънәви тирәнлеге белән аерылып тора.

"Хан кызы" повестенда Идел, Чулман, Нократ, Агыйдел сулары буенда урнашкан, байлыгы, матурлыгы, халыкларының яхшы тормышы, укымышлылыгы белән ерак илләргә, чит патшалыкларга даны таралган Болгар иле сурәтләнә. Анын башкаласын Болгар шәһәре, "Алтын кала" да диләр. Ил белән Алмас хан идарә итә. Тыныч, рәхәт тормышлы Болгар иленең, Алмас ханның бер борчуы бар—ханнар ханының ир баласы юк. Шулай да, ханның яраткан хатыны, гыйбадәтче Ахак аңа Гөлбикә исемле кыз бүләк итә. Шулай матур гына яшәп ятканда илгә, кавем өстенә афәт килә. Җил-давыл чыгып, көн бозыла, үләт авыруыннан халык, терлек кырыла башлый. Җитмәсә, урыс кнәзе Болгар иленә яу белән килергә җыена дигән хәбәр дә алына. Төрле гыйбадәтләр кылу, "изге түбә"гә чыгып теләүләр ясауга карамастан, Болгар иленең хәле үзгәрми.

Көннәрдән бер көнне Алмас ханга Изге атаның шундый сүзе килеп ирешә. Гөлбикәнең үзе яраткан Ак юргасын Тәнреләр хакына корбан чалдырып, итен кавемгә ашатырга, тиресен юлда беренче күренүчегә бирергә кирәк. Изге атаның кушканы тормышка ашырыла, әмма хәл яхшы якка үзгәрми, анын өстенә хан сараен, илне олы кайгыга салып, Гөлбикә авыруга сабыша. Нинди генә эшгамәл кылсалар да, кызның хәле көннәнкөн начарлана. Хан авыр кайгы-хәсрәттән, ачы сагыштан үз юанычы, шатлыгы булган Гөлбикәне сәламәтләндерүчегә кызын кияүгә бирәчәге турында фәрман сала. Ислам динендәге Багдад иле сәяхәтчеләре, табип укымышлылары Габдулла белән Габдрахман кызны дәвалауга алына. Кин маңгайлы, кара шомырт күзле, кара чәчле Габдуллага Гөлбикә бер

күрүдә гашыйк була. Төрле үләннәрдән ясалган дарулар, Аллага гыйбадәт кылу, пәйгамбәрләргә салаватлар әйтү анын хәлен яхшырта. Кыз терелгәч, хан үз сүзендә торып, аны Габдуллага кияүгә бирә. Мона кадәр күп Тәңрегә табынган Болгар иле акыллы, зирәк Изге ата, Тукбай мирза ярдәмендә халык, кавем, ризалыгы белән Ислам динен кабул итә һәм анда манаралары болытка житеп торган мәсҗедләр, мәдрәсәләр салына, Багдад хәлифәтләреннән галимнәр чакыртыла, Идел-йортта азан тавышлары яңгырый башлый.

Беренче карашка, автор бу повестьта Алмас ханның кызы Гөлбикә тормышын, анын язмышын гына сурәтли кебек. Әмма Ш. Әхмәдиев анда татар милләтенең яшәеше, киләчәк язмышы өчен гаять житди мәсьәләләр күтәрә.

"Хан кызы" повестенын сюжеты нигезенә тарихи хезмәтләрдә теркәлеп калган фактлар салынган. Шулай ук әдип тарафыннан Болгар дәүләтенең Ислам динен кабул итүен чагылдырган риваять, легендаларның әдәби эшкәртелүе дә мөмкин. Аерым алганда, автор Ш. Мәржанинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр, Казан, 1989) хезмәтенә таянган булса кирәк. Болгар дәүләтенең Ислам динен кабул итүе хакында күп төрле фаразлар, фикерләр яши. Ш. Мәржани Хисаметдин Мөслиминең "Тәварихы Болгария" китабында теркәлеп калган бер фактны китерә. "Болар Болгарга килеп, табиб сурәтендә йөреп, күп авыруларның савыгуына ярдәм иттеләр. Айдар хан кызы Туйбикә паралич белән авырып, табиплар аны дәвалаудан гажиз иделәр. Вәзир патшага: "Шәһәребездә гарәпләрдән өч табиб бар, дәвалауда тиндәшсез осталар икән",—дип хәбәр бирде. Патша аларны үз янына чакыртып алдырды. Алар, патшанын ислам динен кабул итүен шарт итеп, кызын дәвалап терелттеләр. Хан һәм анын халкы мөселман булдылар һәм жамигъ мәчет салдылар. Хәзрәте Зөбәер бине Жәгъдә имам булып, хөтбә укыды" Тарих һижри 12(634) ел—куй елында, рамазан аенын 12 сентябрендә, 24 нче хутта сәхабәләр халыкны мөселман кылдылар. Унике елдан сон ике сәхабә Мәдинәи мөнәүвәрәгә кайтып китте. Ханзал исә Болгарда калып, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда вафат булды, төрки телгә бик оста иде".

Күренә ки, повестьта сурәтләнгән вакыйгалар Ш. Мәржани теркәп калдырган мәгълүматларга купмедер күләмдә туры килә.

Әсәрнен экспозиция өлешендә Болгар иленен зурлыгы, жир-суларынын, урман-болыннарынын байлыгы турында хәбәр ителә. Халыкнын бай матур тормышы, болгарларнын әхлакыйинсани сыйфатларыннан тугрылык, кунакчыллык, укымышлылык та әйтелә. Болгар дәүләте, анын эчке төзелеше, тышкы мөнәсәбәтләре, рухи, мәдәни бәйләнешләре, чит мәмләкәтләр белән алыш-биреше, сәүдә итүе турында зур урын бирелә.

Болгарларнын күрше халык, кавемнәр белән дус, тату яшәве, тынычлык сөюе, әмма ил иминлегенә куркыныч янаганда, анын бәйсезлеге өчен дошман яуларына каршы көрәшкә бергәләшеп күтәрелергә әзер торуы турында болай языла: "Болгарлар үзләре һәрвакыт сугышырга, чит илләргә һөжүм кылырга яратмасалар да, үзләренә каршы ук, сөнге күтәргән дошманнарны бик усаллык белән кире кайтаралар иде, чөнки аларда корал, сугыш кирәкләре бик яхшы эшләнә иде". Хәтта күрше кавемнәр көчле Болгар иленә сыенып, буйсынып яшәүне алдын күрәләр, дошман килгән чакта бу илне яклау, саклау юлына басалар: "Кара Идел, Чулман, Вятка, Агыйдел сулары буенда төрле чит халыклар, кабиләләр: "Матур, тыныч тормыш болгарларга, тик шуларга буйсынып торуда гына",—дип беләләр. Әгәр читтән дошман килсә, артык көч, батырлык белән тыныч ил өчен сугышалар. Ш. Әхмәдиев тарихи чыганакларга таянып, Болгар дәүләтендә игенчелек, бакчачылык, аеруча һөнәрчелекнең алга китүен яза. Илдә житештерелгән затлы, нәфис әйберләрнең үз халкыннан артып калганы Византия, Кытай, Багдад, Төркия илләренең базарларына чыгарылуы, алар белән рус, поляк, чех кавемнәренең дә кызыксынуы әйтелә. Болгар сәүдәгәрләренең зур ихтирам белән каршы алынуы, сәүдә әйберләренең сатып алучы күнеленә хуш килүе, ягъни Болгар иле товарларынын югары бәяләнүе ассызыклана. Анлашыла булса кирәк: әсәрдә дәүләт бәйсезлеге, халык иминлеге өчен көрәш, сугыш, дәүләт буларак таркалу тасвир ителми. Идел-Йортнын матди һәм рухи байлыгы, Болгар дәүләтенең чәчәк аткан чоры күрсәтелә. Автор Алтын каланын тыныч, гадәти тормы-

шын, гореф-гадәтләрен, төрле шатлыклы вакыйга бәйрәмнәрен, тәнреләргә ышанулары белән бәйле йолаларын, теләүләрне гәүдәләндерә.

Шулай да автор повестьның эчке конфликтын, сюжет үстерелешен тәэмин итүче бер вакыйгага мөрәҗәгать итә. Алмас ханның ир баласы булмау үзен борчыган кебек, ил халкының да олы гаменә әверелә; иҗтимагый янгыраш ала. Алмас хан урынына кем утырыр, ил белән кем идарә итәр? Ш. Әхмәдиевнең уй-теләкләре, аны борчыган мәсьәләләр, повестьның төп идеясе хан кызы Гөлбикә, аның белән бәйле вакыйгаларда, төп каһарман Алмас хан образларында сәнгатьчә гәүдәләндерелә. Татар халкының яшәешендә, аның иҗтимагый тормышында, рухи, мәдәни хәятында һәм патша самодержавиесенең гасырларга сузылган милли колониаль изүенә каршы торып, милләт инкыйразын булдырмауда хәлиткеч роль уйнаган Ислам динен кабул итү вакыйгасы сурәтләнә. Алмас хан—тарихи шәхес. Автор ханның образын тасвирлаганда, Урта гасыр татар әдәбияты традицияләренә, дастани башлангычка хас арттыру, зурайту алымына мөрәҗәгать итә. Ул унай сыйфатларны үзендә туплаган камил зат буларак укучы күз алдына бастырыла: "Алмас хан үзенә башка артык яратыла иде, чөнки ул бик тугры сүзле, гүзәл холыклы, моның өстенә кече күңелле хан иде". Аның акыллы, намуслы, гадел булуы әсәрдә кат-кат әйтелә. Халык аны яратып "сөекле хан, изге оста, ханнар ханы" дип, теленнән төшерми. Шулай итеп, урта гасыр әдәбиятының төп мәсьәләләреннән исәпләнгән гадел хөкемдар проблемасы яна сыйфатта XX йөз башында да үз актуальлеген югалтмый, киресенчә, яна иҗтимагый, сәяси шартларда тагын да калкулана төшә.

Хөкемдар һәм халык проблемасына нисбәтле рәвештә ил, кавем белән идарә итүдә Ш. Әхмәдиев ханның хәлиткеч сыйфатларыннан гаделлеккә, тугрылыкка басым ясый: "Аның каршында барлык халык, барлык кеше бер иде. Хөкем тугры, биләргә ирек бирми, һәр җирдә дөрес хөкем йөртә". Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга нисбәтле, автор Алмас хан турындагы күзаллауларын тулыландыра, киңәйтә. Хәтта аның бердәнбер кызына булган чиксез мәхәббәте, туганлык, кан-кардәшлек мөнәсәбәтләре, ил, кавем язмышы турындагы гамьнәренә киртә була алмый. Ил өстенә килгән афәтне, бәхетсезлекне туктату, халык хәлен җиңеләйтү өчен, хан Гөлбикәнең юанычы, куанычы булган Ак юрганы Тәнреләргә корбанга чалдыра. Ул сабыр, тәҗрибәле, киңәш-табыш итеп эш кылуны алдын күрә. Болгар иленең аксакаллары, руханилары, мирзалары, биләре сүзенә колак сала. Авыр чакта, дәүләт өчен әһәмиятле, халык язмышы белән бәйләнешле мәсьәләләр хәл итәргә кирәк булганда, уйлап, киңәшләшеп эшләү юлын сайлый. Аның киң күңеллелеге, мәрхәмәтлелеге башка дингә, дин әһелләренә мөнәсәбәттә дә чагыла: ул аларны рәнҗетми, эзәрлекләми, хөрмәт белән карый. Хәтта үзе ышанган, инанган, фикри-рухи таяныч булган Изге ата, Тукбай мирзаларның, ата-бабалардан калган күп тәнрелектән баш тартып, Ислам диненә, бер аллалыкка күчүләрен акыл белән кабул итә. Аның зирәк акылы, күрәзәчелеге болгар-татар халкы тарихында иҗтимагый, сәяси, рухи, мәдәни әһәмияте искиткеч зур булган Ислам диненә мөнәсәбәттә, аны кабул итү вакытында тагын бер кат сынала. Кешелек тарихында канкойгыч сугышларга, зур бәла-каза, рухи бәхетсезлекләргә китергән иман, дин алмаштыру Болгар илендә Алмас ханның инсани сыйфатлары ярдәмендә халык, кавем ризалыгы белән тыныч, гадел шартларда тормышка ашырыла. Болгар иле күп аллалыктан бер аллалыкка күчеп, "Алланың барлыгына һәм берлегенә һәм ислам диненең хаклыгына" ышана.

Ш. Әхмәдиев шушы унайдан дини мәсьәләләрне дә күтәрә, биредә әдипнең ислам диненә, аның көченә, Коръәнгә мөнәсәбәте дә чагыла: "...мөселман динендәге бер Аллага ышану һәм анар кылынган пакь гыйбадәтләр, манаралары күккә калкып торган матур мәсҗедләр көннән-көн аның күнелен йомшарталар; көннән-көн ислам диненә мәхәббәт арттыралар. Болгар илендәге төрле тәнреләргә ышанулар, аларга кылган теләүләр, Ислам дине белән үлчәп карагач, бик түбән, бик кызыксыз булып калалар. Ислам галимнәренең сүзләренә, киңәшләренә дә колак сала, шулай итеп, аның күнелендә акрынлап: "Чын Тәнре, тик ислам Тәнресе, чын дин дә Ислам дине дигән иман үзеннән үзе туа". Күренә ки, биредә авторның дини-фәлсәфи карашлары, бер аллалыкны яклавы гәүдәләнеш таба. Күп аллалык, Тәнреләргә ышану Болгар иленең рухи, дәү-

ләти ихтыяҗларын канәгатьләндерми башлый, аның көчсезлегенә басым ясала. Чит мәмләкәтләр, кавем-кабиләләр белән тыгыз бәйләнештә яшәгән дәүләтнең урынын, дәрәҗәсен күтәрү, рухи, икътисади, сәяси мөнәсәбәтләрне ныгыту максатларында да Ислам динен кабул итү зарури була.

Алмас ханның кызы Гөлбикә исемле. Бу урында Г. Исхакыйның "Олуг Мөхәммәд" (1947-1948) драмасындагы төп герой Олуг Мөхәммәднең хатыны да Гөлбикә булуын искәртеп китү урынлы. Безнең карашыбызча, бу уртаклык очраклы хәл түгел, чөнки Алмас хан белән Олуг Мөхәммәд образларының сәнгати гәүдәләнешендә дә, эш гамәлләрендә дә ике әсәрне бергә бәйли торган җепләр шактый. Хан кызы Гөлбикәне, аның тормышын, яшәү рәвешен, язмышын, аның белән бәйле вакыйгаларны тасвирлаганда, әсәрнең романтик стиле тагын да куәтләнә. Аның матурлыгы Урта гасыр татар, Шәрык әдәбиятлары традицияләрендәгечә тасвирлана. Бу табигый, чөнки Гөлбикә—унынчы гасырда яшәгән болгар кызы. Аның тышкы гүзәллеген чагылдырган юлларда болгарчылык мотивларын билгеләү кыен түгел: "Сигез-тугыз яшьләренә җиткәндә, аның көлтә кебек бөдрә кара чәче бөтен аркасын каплап биленнән арта иде. Аның озын керфекләре, чем кара күзләренә үз атасы, үз анасы да текәп карый алмыйлар иде. Аның кызыл җиләк кебек пешеп торган иреннәрен, балкып торган яңакларын күрүгә, сөяргә муаффикъ булган сарай әһле үзен дөньяда бәхетле саный. Аның йөзенә илаһи серле нур сипкән кебек иде: нинди үткен көчле күз дә аңар күтәрелеп карауга җинелә, караңгыдан кояшка каршы чыккан кебек була иде". Әсәрдә аның матурлыгы гадәти матурлык кына түгел, болгар кавеме аны, зурлап һәм сокланып, "Тәнре кызы" дип йөртә. "Гөлбикәнең тал чыбыгы кебек матур, нәфис сыны, балкып торган йөзе, матур күзләре, дулкынланып торган чәчләре" аны күргән кеше күңеленә уелып кереп кала. Хан кызы Гөлбикәнең кием-салымы, тышкы кыяфәте дә аерым купшылык, болгар кызларына хас зиннәтлелек белән тасвирлана: "Аның башында мирза угълан, бәк кызларыныкына охшамаган ак каурыйлар утыртып, чын ташлар белән бизәп бетергән калпак; аягында энҗе кашлар утырткан башмак; өстендә күбрәк вакыт алтын камәр белән җиңел генә кыскан ал яисә саргылт ефәк күлмәк була иде". Автор аны бер урында йөзләрчә болгар кызлары арасында аерылып торган "йөзек кашы"на тиңли. Гөлбикәнең тормышы, яшәү рәвеше, холкы, атка булган мәхәббәт белән үрелеп тасвирлана.

Ат болгар-татар халкының гомерлек юлдашы, таянычы, көче, юанычы булган. Ул аны изгеләштергән. Ак төстәге юрга ат "Хан кызы" повестенда да романтик-шартлы мәгънәгә ия. Үсеп буй җиткән Гөлбикә уртача гәүдәле, көлтә койрыклы, зур матур күзле, киң мангайлы, юаш кына ак биясен бик ярата, аның атка мөгамәләсе автор тарафыннан аерым җылылык белән тасвирлана. Киң сахралар гизәргә чыгар алдыннан, ак юрганы "бик әйбәтләп юалар. Койрыгын, ялын, маңгай чәчен үреп, тугып, мең төрле нәрсә белән чобарлап бетерәләр. Алтын авызлыклы йөгән, алтын өзәнгеле һәм чын ташлар белән бизәлгән хәтфә ияр, киң ефәк күкрәкчә һәм билдәмәләр" кигертәләр. Повестьның башлам өлешендә өстенлек иткән салмак хикәяләү, сәяхәтнамә жанр сыйфатларыннан ил, кавем белән таныштыру, мәгълүмат, гыйлем бирү стиле, әсәргә Гөлбикә образы килеп кергәч, арткы планга чигә, матур әдәби стиль өстенлек алып, вакыйгалар да киеренкеләнеп китә, конфликтның табигый үстерелеше барлыкка килә. Илгә, кавемгә килгән афәт, үләт чире, аның өстенә Болгар дәүләтенә каршы урыс кнәзенең сугышыу белән килүе турында хәбәр алыну болгар халкының Алмас ханның тирән психологик кичерешләре белән тасвирлана. Вакыйгалар ханның шатлыгы, юанычы булган Гөлбикә тормышы белән үрелеп бара. Ул үз иленә, хан йортына килгән авырлыкны, язмыш аның алдына куйган сынауларны акылы, сабырлыгы, зирәклеге белән җинеп чыга. Гөлбикәне тышкы матурлык кына түгел, күркәм холык, намуслылык, киң күңеллелек тыйнаклык кебек сыйфатлар да бизи. Гөлбикәнең хан сараен, Идел-йортны олы кайгыга салып авырган вакытта үзүзен тотышы, сабырлыгы, Багдад табибы—гарәп егетенә мәхәббәте, сөю хисләрен йөгәнли белүе, атасы Алмас ханның ил алдында әйткән сүзен истә тотып, Габдулла кияүгә чыгарга ризалыгын бирү күренешләрен тасвирлаган урыннар укучыда матур тәэсир калдыра.

Повестьта ярдәмче персонажлар булган Тукбай мирза, Изге ата, Ахак төп

каһарманның характер сыйфатларын тулырак ачуда, әдипнең әйтергә теләгән уй-фикерләрен, әсәрнең төп идеясен сәнгатьчә гәүдәләндерүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Мәсәлән, Тукбай мирзаның "чиксез күркәм холыклы, гакыллы, тугры сүзле кеше" булуына басым ясала. "Алмас хан да аны ярата. Үзенең иң ышанычлы олугъ киңәшчеләреннән саный". Шундыйларның икенчесе— "илнең иң зур руханиларыннан булган, бар гомерен гыйбадәттә, теләүдә уткәргән карт Изге ата". Ана шулай ук тугрылык, зирәк акыл, күрәзәчелек хас.

Әдәби әсәрдә шул чор чынбарлыгыннан алынган болгар кавеменең гореф-гадәтләрен, йолаларын, этнографиясен, бәйрәмнәрен күрсәтүгә зур урын бирелгән. Тәңрегә багышланган теләүләрдә, багышлауларда, корбан чалуларда, халыкның уй-теләкләре, өмет-ышанычлары чагылу белән беррәттән, дөньяны, табигатьне аңлау, танып-белү, аларга тәэсир итеп, халык, дәүләт, Изге хан файдасына үзгәртергә тырышулары, омтылышлары да урын ала. Хан кызы Гөлбикәнең беренче елмаюы, утыра башлавы, беренче әйтелгән сүзләре, тәүге адымнары һ. б.лар уңаеннан уткәрелгән зур шатлык туйлары, бәйрәмнәре, атлар чабыштыру, көрәшләр, җырлар әйтү, курай уйнау, думбра чиртү кебек җырлы-биюле уеннар Болгар иленең бай рухи тормышы, фольклоры турында сөйли.

Әсәрне Урта гасыр татар әдәбияты, Шәрык классикасы белән бәйле торган җепләр повестьның сәнгатьчә эшләнешендә, сурәтләү алымнары чараларында, тел бизәкләрендә дә күзәтелә.

Хан кызы Гөлбикәнең гүзәллеген, тышкы кыяфәтен, буй-сынын, киемнәрен тасвирлаганда, Ш. Әхмәдиевнең үзеннән алдагы чор әдәбиятының традицияләренә, эпитет, метафора, чагыштыруларга мөрәҗәгать итүе турында сүз булды. Әсәрнең төп вакыйгасына ишарә ясаучы Гөлбикәнең төше һәм аны юраугa зур идея-эстетик мәгънә салына: "Аны (бүрек-колпак—Г. Т.) сиңа Багдад иленнән Тукбай мирза алып кайткан имеш. Ул бик матур иде: башка кия торган җире кул яссуы чикле түгәрәк. Эче ал ефәккә бөтергән. Тышы сөт күк ак. Маңлай тугърысында ут кебек яна торган кашы бар. Аның өстендә бизәкле, киң, озын кавырсыннар бар. Бүрекнең өсте кызыл ефәккә бөтереп, иң очта сары алтын чугы бар иде". Хан кызы күргән төшне Изге ата юрый һәм ул күрәзәчелек белән Болгар дәүләтенең зур үзгәрешләр алдында торуын әйтә.


"Хан кызы" әсәрендә сан символикасына мөрәҗәгать итү дә бар. Автор Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында кулланылган җиде санын, Алмас хан йортына олы кайгы ингәч, аның зурлыгын, хис-кичерешләр тирәнлеген, сарай кешеләренең өмет-ышанычларын тулырак ачу өчен файдалана. Җиде санының могҗизалы көченә ышанудан, хан кызы Гөлбикәгә багышлап: "Изге түбәдә җиде ак тәя, җиде ак ат, җиде ак куй, җиде ак кәҗә, җиде сыер корбан чалалар". Әсәрнең тел-стиле салмак, телсурәтләү чараларына бай, халыкның җанлы сөйләм теленә якын. Персонажларның теле "Болыт артында кояш бар, төн артында көн бар" кебек мәкальәйтемнәр белән баетылуы алдагы фикерне куәтли төшә.

Югарыдагы күзәтүләр Ш. Әхмәдиев әдәби мирасының XX гасыр башы яңа татар әдәбиятын идея-эстетик яктан баетуда, стиль ягыннан төрләндерүдә, жанр мөмкинлекләрен киңәйтүдә билгеле бер роль уйнавын күрсәтә. Аның иҗаты бу чор әдәбиятының алтын баганалары Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камаллар мирасы белән аерылгысыз булган кебек, әдәби эшчәнлекләре унынчы елларда башланган хикәячеләр Г. Газиз, М. Гали, Г. Рәхим, К. Хәнәфи һ. б. ларда күзәтелгән әдәбиэстетик эзләнүләр белән дә тыгыз бәйләнгән. Хатын-кыз, мәхәббәт, зыялылар тормышының, яшәү һәм үлем, динифәлсәфи мәсьәләләрнең гәүдәләнеше, аларны сәнгатьчә тасвирлауда автор стиленең үзенчәлеге, каләменең яңалыгы Ш. Әхмәдиевнең татар әдәбиятында үз юлын табуы турында сөйли. Милли әдәбиятта тарихи тема тууга да әдип лаеклы өлеш кертә.

**Таһир ГЫЙЛАҖЕВ,**
*Казан дәүләт университеты доценты.*

# ТЫЛСЫМЛЫ АЧКЫЧ

Соңгы елларда Татарстан һәм, гомумән, татар халкы тарихын күпьяклы фәнни өйрәнү, киң колачлы гыйльми һәм археологик эзләнүләр тормышка ашырыла, моңа кадәр тупланган фәнни мәгълүматны системалаштыруга омтылыш ясала башлады. “Татар энциклопедик сүзлеге”, биш томлы “Татар энциклопедиясе”нең беренче томы басылып чыгу әнә шул гаять киң колачлы эшчәнлекнең гамәли чагылышы ул. Татар һәм урыс телләрендә зур тиражлар белән фәнни һәм фәнни-популяр китаплар, югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслекләр, уку ярдәмлекләре зур тиражлар белән чыгарыла. Югары академик кимәлдә, дөнья фәне казанышларына таянып башкарылган бу хезмәтләр халкыбызның бик борынгы заманнардагы, урта гасырлардагы яшәү рәвешен, татар халкынын формалашуын, милләт буларак оешуын һәм, ниһаять, татарларның дөнья тарихында тоткан ролен анык күзалларга мөмкинлек бирә. Ул китапларга аерым тукталып тормастан, бу юнәлештә башкарылып килгән икенче бер мөһим юнәлешкә дә игътибарны юнәлтәсе килә. Анысы—аерым төбәкләр, районнар һәм шәһәрләр, һәм хәтта тарихыбызда сизелерлек урын тоткан аерым авыллар тарихын җентекләп өйрәнү. Бу эшкә, гадәттә, туган якларына җаны-тәне белән гашыйк җанатар-энтузиастлар, һәвәскәр тарихчылар, язучылар һәм журналистлар алына. Аерым кимчелекләре дә булуга карамастан, ул китаплар тулаем халкыбыз, дәүләтчелегебез тарихын өйрәнүгә билгеле бер өлеш кертәләр һәм, табигый ки, үсеп килүче яшь буында туган җиргә мәхәббәт тәрбияләүдә алыштыргысыз зур роль уйныйлар. Моннан берничә еллар элек туган як тарихы белән кызыксынучылар кулына Апас, Әлки, Зәй, Алексеевск, Саба, Актаныш һәм башка районнар тарихын чагылдырган саллы-саллы китаплар килеп кергән иде инде. Аларның кайберләре районның үткәненә һәм бүгенгесенә кагылышлы мәкаләләр, фәнни язмалардан тупланган җыентыктан гыйбарәт булса, кайберләре колачлаган мәгълүматларының тулылыгы, аларны билгеле бер системага салырга омтылу җәһәтеннән чын мәгънәсендә энциклопедик төсмер ала. Соңгылары рәтендә мин әле күптән түгел генә басылып чыккан “Мөслим төбәге. Тарихи сәхифәләр” җыентыгын да күрсәтер идем.




Кайсы ягы белән белән игътибарны җәлеп итә соң бу хезмәт? Беренчедән, китапта районның гомуми физик-географик характеристикасы киң чагылыш таба. Икенчедән, “Чал тарихниләр сөйли”, “Районның археологик истәлекләре”, “XVI-XVII гасырларда демографик процесслар”,

Әхмәдулла Әхмәтгалиев. **Мөслим төбәге.** Тарихи сәхифәләр. Яр Чаллы, 2003, 232 бит.

"Мөслим һәм башка кайбер авылларның барлыкка килүе", "Халыкның шөгыле, төбәкнең икътисади хәле" кебек бүлекләрдә төбәк халкының тарихы борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр Татарстанда яшәгән халыкларның уртак язмышы фонында һәм алар белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Шуның белән бергә, китапта мәгърифәт һәм мәдәният үсешенең төрле этаплары, халыкның көнкүреше, районда туып-үскән күренекле шәхесләр, житәкче кадрлар, авыллар, предприятиеләр һәм оешмалар турында да тулы мәгълүмат табарга мөмкин.

"Һәр төбәкнең үзенә генә хас кабатланмас табигате, тарихы, халкының матур традиция-йолалары, күркәм шәхесләре була,—дип яза китапның кереш сүзендә район хакимияте башлыгы Ришат Хәбипов.—Күптәннән сыналган чынбарлык—тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк, үткәнне белмичә торып, киләчәкне корып булмый. Алдагы тормышыбыз өметле, киләчәк буын ышанычлы булып үссен дисәк, без халкыбыз үткән юлны тирәнтен өйрәнергә бурычлы. Гасырлар буена тупланган бай мирасны һәм тәжрибәне үзләштереп без асылыбызга кайтачакбыз. Әлеге байлыкны халкыбызга, балаларыбыз һәм оныкларыбызга тапшыру—безнең изге вазифа. Менә шул зарурияттан чыгып, районыбыз тарихына караган хезмәтне халыкка житкерүне кирәк дип таптык".

Нинди байлык, нинди мирас һәм нинди тәжрибә турында сүз бара соң? Миңа калса, беренче чиратта сүз рухи мирас, рухи байлык турында. Чөнки кешеләрдән, алар тудырган әнә шул байлыктан башка бернинди ижтимагый тарих була алмый. Беренче карашка Мөслим районы әллә ни зур да түгел. Татарстанның ерак көнчыгышында 1466,2 квадрат км. жир биләгән төбәктә бүгенге көндә 23,2 мең чамасы халык, нигездә, татар милләте вәкилләре яши. Гомумтатар халкының аерылгысыз бер өлеше булган мөслимлеләр уртак татар мәдәниятенә, әдәбиятына, фәненә, икътисадына кемнәрне биргән? Мөслимлеләр бүген кемнәр белән горурлана, кемнәрне яд итә?

Мөслим дигәч тә, нишләптер, минем колагымда халкыбызның сөекле жырчысы, Мөслим кызы Зифа Басыйрованың кабатланмас моңлы, бер үк вакытта дәртле һәм яшерен сагыш сизелеп торган үзенчәлекле тавышы, ул гына жиренә житкереп башкара белгән "Мөслим" жыры янгырый башлый, күз алдыма Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган "Зәңгәр шәл" спектаклендә якташыбыз Наил Әюпов тудырган онытылмас Булат образы килеп баса, күңелем төпкелләрендә Яна Сәет егете шагыйрь Зөлфәтнең шигъри юллары уяна:

Тел ачылгач әйтә алсаң: "Әни!"—дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: "Әти!"—дип,—
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң: "Әни!"—дип,
Соң минутта әйтә алсаң: "Әти!"—дип,—
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

Ә мөслимлеләрнең чыннан да горурланыр якташлары күп, бик күп икән бит! Аларның барысын да саный китсәң гаять озын бер исемлек хасил булыр иде. "Советлар Союзы Каһарманнары Илдар Маннанов, Петр Днепров, Гыймазетдин Вәжетдинов, Дан орденнарының тулы кавалеры Бадыйк Салихов, Социалистик Хезмәт Каһарманнары Зәкария Кашапов, Лотфулла Мусин, фән һәм сәнгать эшлеклеләреннән фән докторлары Марсель Вәлитов, Васыйл Гайфуллин, Гегель Гәрәев, Марсель Бакиров, Хатмулла Габдуллин, Флүн Мусин, Борис Тимеркәев, Равил Шәймәрдәнов, Альберт Галләмов, Дания Заһидуллина кебек галимнәр, шагыйрь һәм язучылардан Зөлфәт, Фоат Садриев, Флүс Латыйфи, Харрас Әюпов, Факил Сафин, Наис Гамбәр, Шәмсия Жиһангирова, спортчылардан СССР чемпионнары Виктор Шадрин, Фәиз Хужин һәм башка күренекле якташлары белән мөслимлеләр хаклы рәвештә горурлана",—дип яза район хакиме Ришат Хәбипов.

Китапта күпләр өчен ачыш булып янгыраралык сәхифәләр байтак. Мәсәлән, 1938 елның сентябрендә Каенсаз авылы кешеләре басуда эшләгәндә коточкыч күкрәү һәм шартлау белән жиргә метеорит төшү күренешенең шаһитлары булалар. Бу метеорит СССР Фәннәр Академиясе тарафыннан

махсус хисапка алына һәм аңа "Каенсаз" исеме бирелә. Фән өчен гаять кыйммәтле бу табылдык дөньяда иң сирәк очрый торган метеоритлардан санала икән. Ык буенда табылган мамонт сөякләре, борынгы гигант мөгезборынның баш сөяге һәм башка сирәк табылдыклар да Мөслим музеенда кадерләп сакланалар. Мөслим якларындагы халыкның чал тарихын раслаучы телсез шаһитлар да байтак. Ык елгасының уң як ярындагы калкулыкларда урнашкан Иске Вәрәш авылында XIII гасырга нисбәт ителгән борынгы каберлекләр, Шуган авылы янындагы калкулыкларда табылган Пьянобор һәм Кушнаренко чорына караган чакма, бронза һәм тимер эшләнмәләр, Иске Чакмак авылы янындагы борынгы каберлек әнә шундыйлардан. Шөкер, болары сакланып калган. Ә бит күпме тарихи мирас, матди һәм рухи истәлекләр юкка чыга бара. Әйтик, Катмыш авылы янындагы борынгы зиратта бик матур язулы, зәвык белән эшләнгән кабер ташлары бар иде. Алар әле узган гасырның 70-80 елларына кадәр исән иде. Хәзер аларның эзе дә калмаган, юкка чыккан, таралган. Менә шундый истәлекләргә кадерле мөнәсәбәт булдыру, тарихның һәр сәхифәсенә изгеләрчә караш булдыру өчен дә кирәк бу китап. Һәм ахыр чиктә, киләчәк буыннар өчен дә кирәк бу китап!

Кыскасы, хезмәтнең авторы—тарихчы энтузиаст Әхмәдулла Әхмәтгалиев гаять тә кирәкле һәм мөһим эш башкарган. Әлбәттә, аңа һәвәскәр тарихчылар, укытучылар, музей хезмәткәрләре һәм район хакимиятенең дә зур һәм эшлекле ярдәме тигәндер. Шулай булмаса, бу кадәр саллы эшне башкарып чыгу өчен бер кеше гомере генә дә житмәс иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, дистә еллар буе бөртекләп җыелган кадерле ядкарьләр, ниһаять, бер түбә астына тупланып, кызыксынучан һәм зирәк укучы кулына барып иреште. Туган якларына—Мөслим төбәгенә битараф булмаган һәр кеше бу хезмәтне үзендә булдырырга тиеш дип саныйм мин.

Китап яхшы кәгазьдә, югары полиграфик эшләнеш белән "Чаллы типографиясе" дәүләт унитар предприятиесе басмаханәсендә нәшер ителгән. Төсле рәсемнәрдә бирелгән Мөслим ягының кабатланмас матурлыгы, табигать күренешләре китапны тагын да тәэсирлерәк, затлырак итә. Аның тиражы 3000 данә. Редакторы күренекле язучы, Мөслимдә яшәп иҗат итүче Фоат Садриев. Дөрес, беренче коймак төерле була, дигәндәй, әлегә хезмәттә кайбер төгәлсезлекләр, булган кадәр мәгълүматның тулаем ачылып житмәве, тел кытыршылыклары кебек кайбер житешсезлекләр дә юк түгел. Әмма алар гына гажәеп зур энциклопедик бу хезмәтнең тулаем кыйммәтен киметә алмый. Бусы—беренче чирканчык алу гына дип беләм. Киләчәктә исә ул тагын да баетылып, төзәтелеп, эшкәртелеп кабат басылачак. Монысына иманым камил. Чөнки мөслимлеләр үз якларына гашыйкларча мөкиббән киткән затлардан. Туган якларына багышлап иҗат ителгән йөзләрчә җырлар, шигырьләр, хикәяләр һәм зур күләмле әдәби әсәрләр дә шуны раслый. Зөлфәтнең мәгълүм шигырен аз гына үзгәртеп (моның өчен мине шагыйрь гафу итәр дип уйлыйм) болай дип язар идем мин:

Чит җирләрдә мактаналсаң: "Мөслим!"—
дип,
Соң сулышта әйтә алсаң: "Мөслим!"—
дип,—
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган илең әнә шул булыр...

Татар халкының уртак язмышына дучар ителгән мөслимлеләр дә иксез-чиксез Рәсәйнең, БДБ илләренең төрле якларына сибелгән бит. Бу китап аларны бер-берсенә якынайтучы, туганлык җепләрен яңартучы, тоташтыручы тылсымлы ачкыч та булып тоела миңа. Хәер, гомумән, Татарстан тарихы, аның географиясе белән кызыксынучылар өчен дә "Мөслим төбәге" китабы файдалы һәм кызыклы кулланма була ала.

**Флүс ЛАТЫЙФИ.**



Qөrən tatar telendə
Коръән татар телендә

# 49—ХӨҖҮРӘТ (БҮЛМӘЛӘР) СҮРӘСЕ

**Хөҗүрәт сүрәсе 18 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Исеме дүртенче аятьтәге хөҗүрәт—бүлмәләр сүзеннән килә.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, иманлы адәмнәр! *(Сүздә һәм гамәлегездә)* Аллаһның вә Рәсуленең алдына чыкмагыз. Аллаһ каршында *(гөнаһлы булудан)* куркыгыз. Шик-шөбһә юк, Аллаһ ишетеп, белеп торучы. **(2)** Әй, иманлы адәмнәр! Пәйгамбәрегез янында тавыш күтәрмәгез. Бер-берегезгә кычкырып бакырган кебек, Пәйгамбәргә каты тавыш белән эндәшмәгез. Юкса, сез үзегез дә абайламастан, гамәлләрегезне юкка чыгарырсыз. **(3)** Аллаһ илчесе янында салмак тавыш белән сөйләшүчеләрнең, һичшиксез, Аллаһ тарафыннан саф мөселман булуы сынала. Андыйларга ярлыкау һәм олуг әҗер бар.

4. *(Мөхәммәд)* өй диварлары аша сиңа акырып эндәшкән бәндәләрнең күбесе моны (бу әдәпсезлеген) аңламый.

*(«Житмеш кеше җыелышып, өйлә вакытында Пәйгамбәр янына килде. Пәйгамбәр үз бүлмәсендә иде. Тыштагылар: «Ий, Мөхәммәд! Чык безнең янга-а!»—дип акырдылар».*
Али Тургут тәфсиреннән.)

**5.** Әгәр алар син чыкканчы сабыр итеп көтеп торган булса, әлбәттә, үзләре өчен бик яхшы булыр иде. Аллаһ—ярлыкаучы һәм мәрхәмәтле кичерүче.

**6.**Әй, иман китергән кешеләр! Әгәр дә шикле кеше сезгә берәр хәбәр китерсә, ул хәбәрнең хакмы, юкмы икәнлеген тикшерегез. Юкса, абайламастан, бер төркем халыкка зыян китерерсез дә, соңыннан үкенеп йөрерсез.

**7.** Шуны белеп торыгыз, сезнең арада Аллаһның илчесе бар. Мөһим эшләрне ул сезнең теләк белән генә башкарса, сез кыен хәлдә калган булырсыз. Аллаһ сезнең күңелләрегезгә иман сеңдерде, иман нуры сезне биләп алды. Көфер эшләрне, әшәкелекне, *(Хакка каршы)* гыйсъянны сезгә харам итте. Тугры юлга басканнар менә шундыйлар булыр. **(8)** Бу—Аллаһның нигъмәте, юмартлыгы. Аллаһ—гыйлем иясе вә хакимдер.

**9.** Мөселманнар ике төркемгә аерылып, сугыша калсалар, аларны татуландырыгыз. Берсе башлап гаделсез һөҗүм итсә, Аллаһ кушканча гамәл кыла башлаганга чаклы, шул якка каршы сугышыгыз. Игә килсәләр, гаделлек белән араларын җайлагыз. Һәм һәр эштә гадел булыгыз. Шик юк ки, Аллаһ гадел гамәлләрне сөя. **(10)** Мөселманнар үзара кардәш. Шулай булгач, кардәшләрнең арасын җайласагыз вә Аллаһтан *(җәзасыннан)* курыксагыз, ярлыканырсыз, Аның рәхмәтләренә ирешерсез.

**11.** Әй, мөэминнәр! Бер төркемегез икенчесен мыскыллап көлмәсен *(кимсетмәсен)*. Бәлки, алар *(мыскыллаучыдан)* күпкә яхшыдыр. Хатыннар да хатыннардан көлмәсен. Бәлки, алар күпкә яхшыдыр. Бер-берегезне гаепләмәгез. Бер-берегезгә әшәке кушаматлар такмагыз. Иман китереп тә, әшәкелек кылу яман гадәт. Тәүбәгә килмәгәннәр рәхимсез залим була.

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**12.** Әй, иманлы кешеләр! Уйдырмаларның *(гайбәт, имеш-мимешләрнең)* күбесеннән ваз кичегез. Аларның байтагы гөнаһ. Кешенең серен сатмагыз, шымчылык кылып, бер-берегезнең гаебен *(тырнак астыннан кер)* эзләмәгез. Берегез икенчегезнең артыннан *(яман)* сөйләп калмасын. Үлгән тугынының итен ашап, кеше тәм табармы? Бу нәҗес бер гамәл булыр иде. Шулай булгач, *(бу харамнарны кылып, гөнаһка батудан)* Аллаһтан куркыгыз. Шик юктыр ки, Аллаһ тәүбәләрне кабул итә һәм ярлыкый.

**13.** Әй, адәм балалары! Хактыр ки, Без сезне бер ир, бер хатын итеп ялрттык. Бер-берегез белән аралашыгыз дип, сезне кавемнәр вә кабиләләргә аердык. Хактыр ки, гөнаһ кылудан курыккан кеше Аллаһ каршысында иң олы абруй казаныр. Шөбһәсездер ки, Аллаһ барысын да белеп, барысыннан да хәбәрдар булып тора.

**14.** Бәдәви гарәпләре:
—Иман китердек,—диде.
Әйт син аларга:
—Сез: иман китердек, димәгез; буйсындык, дип әйтегез. Иман сезнең күңелегезгә кереп урнашмады бит әле. Аллаһка вә аның илчесенә итагать итсәгез, Аллаһ казанышларыгызны киметмәс. Аллаһ—юмарт ярлыкаучы, миһербанлы кичерүче.

**15.** Бары тик Аллаһка вә аның Рәсүленә иман китергәч, икеләнеп калмаган, Аллаһ юлында малың вә җанын кызганмаенча көрәшкән кеше генә хак мөселман була. Менә шундыйлар *(эштә)* гадел, сүздә тугры кешеләр.

**16.** Әйт син:
—Сез *(үзегез дә ышанып бетмәгән)* динегезгә Аллаһны өйрәтергә алындыгызмы? *(Юньләп иман китермәгән башыгыздан, иман китердек дип, Аллаһны алдарга азапланасызмы?)*—диген. Аллаһ күкләрдә булганнарны да, Җирдәгеләрне дә белеп тора. Аллаһ бөтен нәрсәне дөресе белән белеп торучы.

**17.** Алар:
—Ислам динен кабул итүебез синең файдаң, мәнфәгатең өчен,—дип фараз кыла.
Әйт син:
—Минем күңел булсын өчен генә мөселманлыкны кабул итмәгез. Гадел кешеләр икәнсез, шуны белеп торыгыз: әгәр иманыгызда нык торсагыз, сезне тугры юлга юнәлтеп, Аллаһ сезнең үзегезгә мәнфәгать кылыр,—диген.

**18.** Шөбһәсез ки, Аллаһ—күкләрнең вә Җирнең серләрен белүче. Аллаһ—кылмышларыгызны күреп торучыдыр.

# 50—КАФ (КАФ) СҮРӘСЕ

**Каф сүрәсе 45 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. «Каф» хәрефе белән башланганга күрә, исеме дә Каф дип йөртелә.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1, 2, 3.** Каф. Изге Коръән исеме белән әйтәмен ки, үз араларыннан Пәйгамбәр килгәнгә алар аптырап калды. Кяферләр әйтте:
—Бу гаҗәп *(адәм әйтеп, адәм ышанмаслык)* эш,—диделәр.—Үлгәннән соң, туфракка әйләнгәннән соң *(тагын терелачәкбезме)*? Бу акылга сыймый торган бер эш.

**4.** Туфрак аларның тәннәрен ничек итеп ашап бетергәнен бик яхшы беләбез. Яныбызда бөтен нәрсә язылып саклангaн Китап бар.

**5.** Хакыйкать *(Коръән)* килгәч, алар аны ялганга чыгарды. Шуңа күрә дә алар нишләргә белми, аптырап калды да.

**6.** Күккә карамыйлармы соң алар? Аны ничек итеп бина кылдык, бизәдек. Бер генә чатнаган урыны да юк—камил иттек. **(7)** Җирне ничек итеп хасил иттек, өстенә тауларны беркеттек вә һәртөрле *(җенестән)* үсемлекләр үстердек.

**8.** Аллаһка юнәлгән кешеләрнең күңел күзе ачылсын һәм гыйбрәт алсыннар дип, шулай кылдык.

**9.** Без Күктән бәрәкәтле яңгырлар яудырып, бакчалар, бәндәләремә ризык булсын дип, *(урып алырлык)* иген үстердек. **(10)** Биек хөрмә агачларында тезелеп киткән мул җимешләр җитештердек. **(11)** Янә шул яңгыр суы белән үле туфракка җан өрдек. *(Терелеп)* кабердән чыгу да нәкъ шулай булачак.

**12, 13, 14.** Алардан алдагылар да—Нух кавеме, Расс бәндәләре, Сәмуд, Гад, Фиргавен, Лут һәм Әйкә халыклары да, Тубба кешеләре дә—барысы да пәйгамбәрләрнең үгетләрен ялганга чыгарды. Һәм шул сәбәпле алар Мин вәгъдә иткән газапка дучар булды. **(15)** Беренче тапкыр *(күкләрне, Җирне, Адәмне)* юктан бар иткәндә мохтаҗлык кичердекме, юкса *(яңадан барлыкка китерергә дә куркып торабызмы)*? Хәер, алар яңадан яраттылышка (терелүгә) ышанмый. **(16)** Хактыр ки, Адәмне Без яраттык. Нәфесенең аңа нинди вәсвәсә пышылдаганын да беләбез. Чөнки Без аңа муен тамырыннан да якын торабыз.

**17.** Адәмнәрнең уң ягында *(савапларын)* һәм сул ягында *(гөнаһларын)* гамәлләрен язып баручы ике фәрештә бар. **(18)** Кешенең авызыннан чыккан бер генә сүз дә күзәтүче тарафыннан язылмый калмый. **(19)** Көннәрдән бер көнне үлем иләслеге килер. Синең гомер буе качып йөргән нәрсәң шул *(әҗәл)* булыр. **(20)** Сур быргысына өрелер ки, бу да кяферләр өчен вәгъдә ителгән *(җәзаның чынлыкка ашу)* Көнедер. **(21)** Менә шул Көнне һәр кеше әйдәүчесе һәм шаһитләре белән бергә килер. **(22)** Әйтелер ки:

—*(Дөньяда)* син болардан хәбәрсез идең. Менә өстеңнән пәрдәне алдык. Син хәзер үткер карашлы булдың *(ни кылмышларыңны ачык күрерсең, шәт!)*. **(23)** Аның юлдашы *(фәрештә)* әйтер ки:

—Менә янымда *(язулы китап)* әзер тора. **(24, 25)** *(Адәмне алып килгән әйдәүче белән сакчыларга боерылыр)*:

—Кирегә сукалаучы бөтен кяферләрне, бар көчләре белән игелеккә каршы торганнарны, залимнәрне, *(Аллаһ хөкемнәрен)* шиккә алганнарны, һәр азгынны җәһәннәмнең иң хәтәр янган уртасына атыгыз! **(26)** Аллаһка тиң *(хәтта Аллаһтан өстен)* күреп әйберләргә табынган мөшрикләрне икегез ике ягыннан тотып, иң хәтәр янган утка атыгыз. **(27)** Аркадашы шунда телгә килер:

—Йа, Раббым, аны мин аздырмадым. Ул үзе Хактан ерак китеп адашкан иде.

**28, 29, 30.** Аллаһ әйтер:

—Каршымда гауга куптармагыз! Мин сезгә алдан ук (гөнаһ кылмагыз, Ахирәттә җәза алырсыз дип) тәһдид (кисәтү) күндермәдемме? Минем янымда сүз көрәштерелмәс. Әмма Мин бәндәләремә гаделсез залим дә түгелмен. Ул Көнне җәһәннәмнән сорарбыз:

—Йә, тулдыңмы инде?—диярбез. Ул:

—Тагын берәрсе бармы? *(Булса—керт, урыным җитәрлек)*,—дип җавап бирер.

**31.** Саф мөселманнар өчен җәннәт ерак булмас, якынайтылыр. **(32, 33, 34)** Аллаһка юл тоткан һәр кешегә, Аллаһ куйган чикләрне һәм хөкемнәре узмаганнарга, Үзен күрмәгән килеш тә Раббының җәзасыннан курыккан адәмнәргә вә ихлас күңелле кешеләргә вәгъдә ителгән җәннәт менә шушы булыр. Анда иминлек илә керегез. Бу үлем янамаган мәңгелек көннәрнең башы булыр. (35) Анда ни теләсәгез шул бар. Хозурыбызда тагын да мулрак.

**36.** Болардан алда тагын да куәтлерәк тормышлы ничәмә-ничә кяфер токымнарын Без юк иттек. *(Әҗәлдән качып котылыр урын эзләп, алар бер урыннан икенчесенә күчеп йөргән булсалар да, җәзабыздан)* качып котылу мөмкин эшме?

**37.** Менә бу хикмәтләрдә күңеле сизгер булган, *(Аллаһ сүзенә)* игътибар илә колак салган кешеләр өчен сабак алырлык шәйләр бар.

**38.** Шунысы да Хакыйкать галәмәтедер: Без күкләрне, Җирне вә икесе арасындагы бөтен нәрсәләрне алты *(дәвер)* көн эчендә яраттык һәм бу эш безнең өчен һич тә йончылырлык булмады.

*(Яһүдләр: Аллаһ алты көн буена күкләрне, Җирне юктан бар итә-итә хәлдән тайды, шуңа күрә, ул җиденче көнне, шимбәдә тәхете өстендә аяк бөкләп ял итте, дип ялган тараттылар. Аятьнең соңгы җөмләсе шуларга ишарә.*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**39.** *(Ий, Мөхәммәд)* аларның *(кяферләрнең нахак)* сүзләренә түз. Кояш чыккан вакыттан алып, батышына чаклы булган арада Раббыңны хуплап, тәсбих әйт (намазларны калдырма). **(40)** Төннәрен сәҗдәләреңнән соң да Аны зикер ит. **(41)** Ул Көнне *(Кыяматтә)* якын урыннан ишетелгән тавышка *(Сур быргысына)* колак сал. **(42)** Ул Көнне кешеләр Сур тавышын, һичшиксез, ишетәчәк. Менә *(каберләрдән)* чыгыш Көне шул булыр. **(43)** Җан алучы да, җан өрүче дә, әлбәттә, Без булырбыз. Кайтарылыш та фәкать Безнең янга булыр. **(44)** Ашыгып өскә чыксыннар өчен, ул Көнне Җир ярылып ачылыр. Барыгыз да бергә тупланыр. Бу эш Безгә бер дә кыен түгел.

**45.** Аларның *(кәфер)* сөйләгәне Безгә бик яхшы мәгълүм. Син аларны *(дингә)* ирексезләүче түгелсең. Кисәтүләремнән курыкканнарга Коръән укып, вәгазь сөйлә.

# 51—ЗАРИЯТ (ТАРАТУЧЫЛАР) СҮРӘСЕ

**Зарият сүрәсе 60 аятьтән тора. Зарият сүзе җилне аңлата. Ләкин тәрҗемәчеләр вә тәфсирчеләрнең күбесе аның таратучы дигән мәгънәсен ала.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1,2,3,4,5,6.** Туздырып таратучы вә су тулы яңгыр болытларын йөртүче, көймәләрне җай гына йөздерүче һәм яңгырларны яудыручы җилләр белән ант итәмен ки: сезгә вәгъдә ителгән, исәп-хисап өзү Көне—Кыямәт, һичшиксез, киләчәк.

**7,8,9.** Төрле юллары *(орбиталары)* белән хәрәкәт итүче җисемнәре булган Күк исеме белән әйтәмен ки, сез—мөшрикләр, каршылыклы-гаугалы фикердә торасыз. *(Хак иманнан)* йөз чөерергә теләгән кеше йөз чөерәчәк.

**10.** Ялганчыларга әче каһәр төшсен! **(11)** Алар кара наданлык эчендә калган җаһилләр. **(12)** Җәза Көненең кайчан киләчәге турында сорарлар. **(13)** Ул Көнне алар утка атылачак. **(14)**—Җәзабызны татыгыз! Аның тиз килүен көткән идегез—менә шул инде сез ашыктырган җәза.

**15, 16.** Шик юк ки, Аллаһка каршы чыкмаганнар Раббы биргән җәннәтләргә кереп, чишмә яннарында утырачак. Алар фани дөньяда игелек кылган шәхесләр булыр. **(17)** Төннәрен аз йоклаганнар. **(18)** Сәхәр вакытларында ярлыкау сораганнар. **(19)** Мохтаҗлар һәм юксыллар өчен малларыннан өлеш чыгарганнар. **(20)** Иманнарында нык рух белән торганнар өчен фани дөньяда аятьләр *(Коръәннең хаклыгына дәлилләр)* китердек.

**21.** Вә дәхи сезнең үзегезнең *(тән вә рух)* төзелешегездә дә моңа дәлилләр бар. Шуны да күрмисез! **(22)** Галәмдә дә ризыгыгыз вә сезгә вәгъдә ителгән башка нәрсәләр бар.

**23.** Күкнең вә Җирнең Раббысы булган Аллаһ исеме белән әйтәмен ки: бу *(Аллаһның хикмәтләре)* сезнең үзара итагать белән сөйләшеп утырганыгыз кеби, чынбарлыктыр.

**24.** *(Мөхәммәд)* Ибраһимнның шәрәфле кунаклары турындагы хәбәр сиңа килеп ирештеме? **(25)** Алар Ибраһимнның өенә керде, сәлам бирделәр. Ибраһим аларның сәламен алды һәм эченнән генә:

—Болар чит-ят кешеләр,—дип уйлады.

**26.** Ул тиз генә өйдәгеләре янына кереп, *(кыздырылган)* симез тана ите алып чыкты. **(27)** Кунакларның алдына куеп:

—Бәлки, авыз итәрсез?—диде. **(28)** Шулай диде дә, үзе куркуга калды.

—Курыкма,—диде кунаклар һәм:

—Синең углың *(Исхак)* туачак,—дип аннан сөенче алдылар.

**29.** *(Ибраһимның)* хатыны үз чыраена суга-суга:

—Мин кысыр хатын бит *(карчык башымнан каян килеп мин бала табыйм)*!—дип кычкырды. **(30)** Кунаклар:

—Шулай,—диделәр.—Раббың шулай боерды. Аллаһ—хикмәтләр иясе, барын да белүче.

**31.**—Инде башка йомышыгыз ни иде?—диде Ибраһим. **(32,33,34)**

—Без гөнаһка баткан кешеләр янына җибәрелдек,—диде кунаклар.—Аларның өстенә таш яудырырга дип килдек. Бу ташлар хәттин ашканнарның башына төшәр өчен Аллаһ тарафыннан тәгаенләнгән. **(35)** Шушы сәбәп илә Без анда булган мөэминнәрне *(Лутның гаиләсен)* чыгардык. **(36)** Әмма Без анда бер генә мөселман гаиләсен үз йортында күрдек. **(37)** Аллаһның җәзасыннан курыкканнар өчен Без анда тамга *(ишарәт)* калдырдык.

**38.** Муса вакыйгаларында да сабаклар бар. Без аны ап-ачык дәлилләр белән Фиргавен янына җибәрдек. **(39)** Фиргавен бөтен токымы белән бергә *(иманнан)* йөз чөерде:

—Бу *(Муса)* бер сихерче, күз буучы яки акылдан язган бичарадыр,—диде. **(40)**

Ниһаять, Без аны да *(Фиргавенне)* гаскәре белән бергә диңгезгә батырдык. Соңыннан *(Җәза килгәч)* ул бик нык үкенде.

**41.** Гад халкының һәлак булуында да сабак алырлык гыйбрәтләр бар. Ничек итеп алар өстенә дәһшәтле һәлакәт—давыл җибәрдек. **(42)** *(Ул шундый бер өермә иде ки)* юлында ни очраса, шуны куптарып алып, урынында көл белән туфрак кына калдырып китте.

**43.** Сәмуд халкының язмышы да бик гыйбрәтле. Аларга:

—Вакытыгыз чыкканга чаклы рәхәттә яшәп калыгыз,—дип әйтелде.

*(«Сәмуд халкына җибәрелгән пәйгамбәр Салих, тәүбәгә килсеннәр өчен, халкына өч көн мөддәт бирә. Шул вакыт эчендә алар тәүбә итмәсә, җәза күрәчәкләр, ди».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**44.** Раббының әмереннән чыгып, бозыклыкта хәттин аштылар. Көпә-көндез аларны коточкыч зилзилә һәлак итте. **(45)** Алар аягөсте кала алмады. Ярдәмчеләре дә булмады.

**46.** Байтактан әүвәл Нух кавемен дә һәлак иттек. Алар хәттин ашкан фасикъ кавем иде.

**47.** Без кодрәтебез илә Күкне чиксез киң итеп ясадык. Бездә тиңе булмаган куәт, чиксез кодрәт бар. **(48)** Җирне дә Без түшәк шикелле ясадык. Без бик оста ясаучы. **(49)** Барысын да пар-пар итеп ясадык (ир белән хатын, Җир белән Күк, Кояш белән Ай, иңкүлек белән таулар, диңгез белән коры җир, тормыш белән үлем, татлы белән әче, яктылык белән караңгылык, яхшы белән яман). Болар турында яхшылап уйлап карасагыз, бер нәтиҗәгә килерсез, шәт. **(50,51)** Шулай булгач, әйткел:

—Барыгыз да Аллаһка сыеныгыз. Дөресе шул, мин сезне *(Аллаһның)* газабыннан сакларга тырышучы, *(гөнаһ эшләмәгез, иман китерегез, дип)* кисәтүче бер илче буламын,—диген.—Башка бер генә уйдырма тәңрегезне дә Аллаһка тиң куймагыз. Хактыр ки, мин сезне кисәтер өчен, Аллаһ тарафыннан күндергән Пәйгамбәр буламын.

**52.** Әүвәлге заманнарда халыкларга килгән пәйгамбәрләр арасында кяферләр, мөшрикләр тарафыннан: сихерче яки тилергән, дип мыскыллы көлкегә күтәрелмәгән бер генә пәйгамбәр дә юк. **(53)** *(Бу рәнҗетүле сүзләрне)* алар бер-берсенә нәселдән-нәселгә васыять итеп калдырамы? Юк, алар кавемнәре белән хәттин ашкан азгын халык иде. **(54)** Шулай булгач, *(Рәсүлем)* син алардан йөз чөер. Алар өчен син инде шелтә алмассын. **(55)** Син *(Коръән белән)* вәгазеңне дәвам ит. Вәгазь мөэминнәргә файда китерер.

**56.** Мин җеннәрне дә кешеләрне дә: бары тик Миңа сәҗдә итсеннәр, дип яралттым. **(57)** Мин алардан ризык сорамыймын. Миңа ризык ашатуларын да теләмимен. **(58)** Хактыр ки, ризыкны бирүче, чиксез кодрәт иясе—Мин Үзем—Аллаһ!

**59.** Хактыр ки, гаделсез золымчылар өчен, әүвәл яшәп һәлак булган тиңдәшләренә тигән газап насыйп булыр. Әлегә *(Кыямәтне)* ашыктырмый торсыннар.

**60.** Аларның *(кяферләрнең)* башына төшәчәк дип, вәгъдә ителгән ул Көн коточкыч булачак!

## 52—ТУР (ТАУ) СҮРӘСЕ

**Тур сүрәсе 49 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Тур—Аллаһ Тәгаләнең хәзрәти Муса белән сөйләшкән тауның исеме.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Тур тавының исеме илә **(2)** юка тирегә язылган **(3)** битләрдән торган Китап илә **(4)** мәһабәт Кәгъбә исеме илә **(5)** чиксез Күк йөзе белән **(6)** вә туп-тулы диңгез исеме белән әйтәмен ки, **(7)** чыннан да, Аллаһның җәзасы, һичшиксез, бер иңәчәк. **(8)** Аны берәү дә кире кага алмас. **(9)** Ул Көнне Күк йөзе тетрәнеп, чайкала башлар. **(10)** Таулар урыннарыннан кубарылыр. **(11, 12)** Ул Көнне нәҗес белән уйнаучы ялганчылар күргәнне башкаларга күрергә язмасын. **(13)** Ул Көнне алар җәһәннәм утына төртеп төшерелер. **(14)** *(Һәм аларга)*:

—Менә сез ялганга чыгарган ут шушы булыр,—дип әйтелер. **(15)**—Бусы да бер сихер генәме? *(Моның сихер түгеллеген)* күрмисезме? **(16)**

—Керегез шунда! Түзәлсәгез, түзәсез. Түзә алмасагыз—сезгә барыбер. Сез бары тик кылмышларыгызның җәзасын татыйсыз.

**17.** Хактыр ки, саф мөэминнәргә җәннәтләр эчендә нигъмәтләр булыр. **(18)** Раббы биргәннәрдән авыз иттереп, аларны Аллаһ хәтәр җәһәннәмнән саклар. **(19, 20)** Рәт-рәт булып җәннәттә тезелгән йомшак канәфиләргә кырын ятканнарга әйтелер:

—Игелекләр кылганыгызга күрә рәхәтләнеп ашагыз, эчегез!

Без аларга зур күзле хур кызлары бирербез. **(21)** Иман китереп, токымнары да шул иманда булганнар да бар. Без аларның нәселләрен дә үзләренә иярттек *(оҗмахка керттек)*. Кылган гамәлләреннән һични дә киметмәдек. Һәркем үз гамәлләренең тоткыны. **(22)** Аларга җаннары ни теләсә шундый җимеш, ит ризыклары мул бирелер. **(23)** Анда касәләр алмашу булыр. Буш сүзләр анда булмас һәм вәсвәсәгә тартылу да булмас. **(24)** Сәдәф савытларда сакланган энҗе кебек, үсмер-егетләр аларның әтрафында булыр. **(25)** *(Җәннәттәгеләр)* бер-берләре белән күрешеп, *(хәл-әхвәл)* сораштырырлар. **(26, 27, 28)** Алар әйтер:

—Чыннан да, без моннан әүвәл *(фани дөньяда)* гаиләбез белән Аллаһның җәзасыннан куркып яшәдек. Менә Аллаһ безгә мәрхәмәтле булып, Сәгадәткә ирештерде. Ул безне сәмумнан *(җәһәннәмнән)* коткарып калды. Хактыр ки, без моннан әүвәл дә Аңа гыйбадәт кыла идек. Шик юк ки, Ул—миһербанлы вә ярлыкаучы.

**29.** *(Мөхәммәд)* син вәгазьләреңне дәвам ит. Син Раббыңның химаясе аркасында сихерче дә, дивана да түгелсең. **(30)** Юкса, алар:

*—(Мөхәммәд)* ул—*(җенле)* шагыйрь,—диделәр.—Без аңа һәлакәт килгәнен көтеп торачакбыз. **(31)** Әйт син:

—Көтегез,—диген.—Сезнең белән мин дә көтәрмен. **(32)** *(Мөхәммәд турында җенле шагыйрь, сихерче, дип)* аларга үз акыллары әйттерәме? Әллә алар азгыннар төркеменнәнме?

**33.**—*(Мөхәммәд)* үзеннән чыгарып сөйли ул вәгазьләрне,—диләр. Хәер, алар барыбер иман китермәс. **(34)** Алайса, хаклы булсалар, алар да шуңа охшаш, ичмасам, бер сүз китерсеннәр. **(35)** Әллә алар үзләреннән-үзләре барлыкка килдеме? Әллә алар үзләре юктан бар итә аламы? **(36)** Әллә соң күкләр белән Җирне алар юктан бар иттеме? Хәер, алар *(Аллаһның кодрәтенә)* ышанмый. **(37)** Яки Раббың хәзинәләре алар

кулындамы? Яиса хөкем алар кулындамы яки алар җиңелү белмәс кодрәтлеме? **(38)** Әллә соң аларның *(Куккә менә торган)* баскычлары бармы? Шул баскычтан менеп, алар *(фәрештәләр сүзен)* тыңлый аламы? Тыңлый алсалар, алар моңа дәлил китерсен. **(39)** Яки Аллаһның кызлары бармы? Сездә угылларымы? **(40)** Әллә син *(Мөхәммәд, вәгазьләрең өчен)* алардан хак сорыйсыңмы? Шул сәбәпле алар авыр бурычка баттымы? **(41)** Яки яшерен китап алар кулында булып, ул китапны алар язамы? **(42)** Әллә алар сиңа бер-бер тозак корырга уйлыймы? Ләкин ул кяферләр үзләре корган тозакка үзләре төшеп харап булачак. **(43)** Яки аларның Аллаһтан башка тәңреләре бармы?

Аллаһ алар тиңләштерә торганнардан өстен.

**44.** Әгәр дә Күкнең бер өлеше аларның башына төшә башласа, алар: —Бу берсе өстенә икенчесе менгән болытлар гына,—дип әйтер.

**45.** Башларына афәт килгән Көнгә чаклы син аларга кагылма инде. **(46)** Ул Көнне алар корган тозаклар һичбер файда китермәс. Аларга ярдәм итүче дә булмас. **(47)** Хактыр ки, золымчыларга моннан башка да газап әзерләнгән. Ләкин аларның күбесе моны белми.

**48.** Син Раббыңның хөкемнәрен сабырлык илә көтеп тор. Әлбәттә, син һәрвакыт күз уңыбызда торасың. Йокыдан торып, Аллаһны мактап, үз вакытында тәсбих әйт. **(49)** Төннең бер өлешендә *(ахшам, ясту намазларында)* вә йолдызлар сүнгәннән соң *(сабах намазында)* тагын тәсбих әйт.

## 53—НӘҖЕМ (ЙОЛДЫЗ) СҮРӘСЕ

**Нәҗем сүрәсе 62 аятьтән тора Мәккәдә иңгән. Нәҗем -йолдыз дигән сүз. Беренче аятьтәге «нәҗем» сүзе тәрҗемәләрдә һәм тәфсирләрдә күбесенчә «атылган йолдыз», «баеган йолдыз», «сүнгән йолдыз» дип бирелә, әмма Хәмут Йазыр китабында Коръән нуры турында бәян ителә. Валерия Пороховада: звезда, летящяя с небосклона, диелгән. Фикеребезчә боларның һәммәсе дә дөрес тәрҗемә, шулай булгач, без Йазыр бәй белән Валерия ханым нөсхәләрен кушып, менә болай гамәл кылдык.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Атылган йолдыз исеме белән ант итеп әйтәмен ки: **(2)** тугры дустыгыз *(Мөхәммәд)* тугры юлдан язмады вә азмады. **(3)** Һәм ул артык кызып, һавалы сөйләшмәс. **(4)** Ул вәхий ителгәннәрне генә сөйләр. **(5)** Аны куәтле вә өстен сыйфатлы *(Җәбраил)* өйрәтте. **(6)** Мәһабәт, күркәм сурәттә **(7)** ул *(Җәбраил)* офыкның биеклегендә пәйда булып, **(8)** аңа якынайды һәм җиргә төште. **(9)** Аралары ике җәя озынлыгы, хәтта аннан да якынрак иде. **(10)** Ул Аллаһның илчесенә *(Мөхәммәдкә)* вәхий ителгәнне тапшырды.

**11.** Аның *(Мөхәммәднең төшендә)* күргәннәрен күңеле ялганга чыгармады *(аның төше рас килде). (Кяферләр)* хәзер инде сез аның күргәненә каршы *(ялган дип)* көрәшә башладыгызмы? **(13, 14,15)** Хактыр ки, *(Мөхәммәд)* икенче тапкыр аны Сидрәтүл Мунтаһа агачы янында күрде. Кайсыдыр ки, ул агач җәннәтүл Мәъва янында үсә **(16)** Сидрәтүл агачы балкышлы пәрдә *(үзенең яфраклары)* белән капланган иде. **(17)** Мөхәммәднең күзе камашмады, карашы читкә тайпылмады. **(18)** Хактыр ки, ул Раббының иң бөек аятьләреннән *(дәлилләреннән)* бер өлешен күрде.

*(«Сибрәтүл Мунтаһа Гарешнең, ягъни Аллаһның тәхете янында үсә торган бер агач. Сидрә—гарәп чиясе, дигән сүз. Мөхәммәде Рәсүлулла мигъраҗда Сидрәдән дә югары галәмгә аша. Бу чикне, Сидрәдән соң аргы таба фәрештәләр дә, бүтәннәр дә узып китә алмый. Җәбраил мигъраҗга ашкач, Мөхәммәдкә әйтә: «Менә, бу Сидрәтүл Мунтаһа булыр»,—ди. Җәннәтүл Мәъва -фәрештәләр һәм шәһидләрнең тупланып яши торган урыны».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**19.** *(Әй, кяферләр)* сез Лат белән Узза *(исемле сыннарыгыз)*ны күрдегезме? **(20)** Яки өченче потыгызны—Мәнатны да күрдегезме? **(21)** Димәк, ир угланнар—сезнеке, кызлар Аллаһныкы булып чыгамыни инде? **(22)** Алай булса, бу бер дә гадел эш

булмас иде. *(Лат, Узза, Мәнат—уйдырма алиһәләр, хатын илаһлар.)*

**23.** Бу потлар сезнең аталарыгыз таккан исемнәрдән *(уйлап чыгарган сурәтләрдән)* башка берни дә түгел. Алар хакында Аллаһ һичбер дәлил иңдермәде. Алар бары тик хыялый фараз вә нәфес һәвәслегенә бирелгәннәр. Гәрчә үзләренә Раббы тарафыннан тугры юл күрсәтүче килде.

**24.** Кеше һәр теләгәненә хуҗа була аламы? *(Юк!)*

**25.** Ахирәт тә, фани дөнья да—Аллаһныкыдыр.

**26.** Күкләрдә ничәмәничә фәрештә бар. Аларның шәфәгате, теләге Аллаһ рөхсәтеннән башка һичкемгә файда бирмәс. **(27)** Ахирәткә ышанмаганнар фәрештәләрне хатын-кызга саный. **(28)** Гәрчә бу хосуста аларның һичбер мәгълүматы юк. Алар бары тик фаразларга гына таяна. Фараз исә һичшиксез, Хакыйкать белән ярыша алмый. **(29)** *(Мөхәммәд)* шуңа күрә син Аллаһны зикер итүдән баш тарткан һәм дөнья тормышыннан башка һични теләмәгән кешеләргә якын барма. **(30)** Менә аларның ирешергә теләгән гыйлемнәре шул кадәр генә Шик юк, синең Раббың, әлбәттә юлдан язганнарны бик яхшы белеп тора. Тугры юлга басканнарны да яхшы белә

**31.** Күкләрдә вә Җирдә булганнарның барысы да—Аллаһныкыдыр. Аллаһ яманлык кылганнарга, кылмышларына күрә -җәзалар, игелек кылганнарга бөек әҗер бирер.

**32.** Вак-төяк хаталары булып та, зур гөнаһлардан вә әдәпсезлекләрдән ерак торганнарны, белеп тор, Раббың юмарт ярлыкар. Туфрактан яралтканда да, сез анагыз карынында ятканда да сезне иң яхшы белүче—Аллаһ. Шуңа күрә артык масаеп, пакь күренергә тырышмагыз. Аллаһ яманлыклардан сакланганнарны яхшы белә

**33.** *(Аллаһтан, иманнан)* баш тарткан кешене күрдеңме син? **(34)** Аз гына *(хәер-садака)* биреп, соңыннан саран булганны? **(35)** Яшерен серләрнең ачкычы *(Коръән)* аның янында гына. Гаҗәп, шуны да күрми. **(36)** Мусага бирелгәннәр белән ул таныш түгелме икәнни? **(37)** Янә Ибраһимга иңдерелгән сәхифәләргә язылганнан хәбәрдар түгелме икәнни?

**38.** Хактыр ки, һичбер гөнаһкяр башка кешенең гөнаһларын үз өстенә ала алмый. **(39)** Белеп тор, и адәм баласы, кешегә үзе кылмышларыннан башка һичбер нәрсә йөкләнмәс. **(40)** Аның кылмышларына киләчәктә бәя биреләчәк. **(41)** Ахырда кылмышларына күрә ул әҗерен дә алачак. **(42)** Шик юк ки, соңгы кайтарылыш Аллаһ хозурына булыр. **(43)** Хакыйкатән, көлдергән дә, елаткан да—Ул. **(44)** Җан өргән дә, җан алган да—Ул. **(45, 46)** Шунысы хак, аналыкка атылган мәнидән ир һәм хатыннан гыйбарәт парлары яралтты. **(47)** Шик юк, яңадан терелү дә Аның ихтыярында. **(48)** Баеткан да, хәзинә биргән дә—Аллаһ. **(49)** Хактыр ки, Шигъра *(Сириус)* йолдызының Раббысы да—Аллаһ.

*(«Ата Эт йолдызлыгындагы Шигъра (Сириус) йолдызы иң якты йолдызларның берсе. Аның зәңгәрсу яктылыгыннан мәҗүсиләр һәм куркып, һәм сокланып яшәгәннәр, Аллаһ, диеп, шул йолдызга табынганнар».*

Валерия Порохова тәфсиреннән.)

**50.** Хактыр ки, Гад кавемен Ул һәлак итте. **(51)** Сәмудларны да исән калдырмады. **(52)** Тагын алдарак бик тә рәхимсез залим һәм бик азгын Нух кавемен да **(53)** *(Халкы гөнаһлы)* шәһәрләрнең астын өстенә китерде. **(54)** Күрәчәкләрен башларына иңдерде. **(55)** Инде Раббының нигъмәтләреннән кайсысына шикләнеп карыйсыз? **(56)** Менә бу *(Мөхәммәд)* алда килгән пәйгамбәрләр белән рәттән торучы Пәйгамбәрдер.

**57.** Якынлашырга тиешле Кыямәт якынлашты. **(58)** Ләкин Аның кайчан киләчәген Аллаһтан башка һичкем белмәс. **(59)** Хәзер инде сез бу сүзгә *(Коръәнгә)* гаҗәпләнәсезме? **(60)** ***(Коръәннән)*** көлүен көләсез, *(җәза килер дип)* еламыйсыз. **(61)** Сез кара наданлык эчендә калачаксыз. **(62)** Аллаһка сәҗдәгә китегез—гыйбадәт кылыгыз.

# АВЫЛДАШ

Башлангыч сыйныфларда укыганда ук безнең авылдан Зәйнәп Бәширова дигән шагыйрә чыкканлыгын ишетеп белә идем. 1956 елда "Татар поэзиясе антологиясе"ндә аның шигырьләре басылып, безнең Балтач (совет чорында Юлсубино булып киткән) авылында туып-үсүе турында язылганын күргәч, тагын да горурланыбрак киттем: "Исеме әнә нинди затлы, калын китапларга кергән кешеләр дә күктә яралмаганнар икән лә бит, тырышсам, мин дә шагыйрь була алачакмын!" дигән ышаныч тагын да ныгый төште. Кызыксына торгач, аның исән-сау икәнлеген, заманында Казан рабфагын, Мәскәү университетының журналистика факультетын тәмамлап, "Эшче" газетасында эшләвен, нәшриятта һәм шәһәр китапханәләрендә җаваплы вазифалар башкаруын белдем. 30 елларда Нижгар мишәрләре ягында чыккан "Октябрь коммунасы" газетасының редакторы да булып эшләгән ул. Еллар үткән саен исеме антологияләргә кергән шагыйрәне күрәсе килү көчәйде генә. Ни әйтсәң дә, авылдашлар бит. Җитмәсә, әтисен—Хуҗа мулла бабайны күреп тә беләм әле—безнең өйдә әллә ничә кат булганы да бар—ә менә атаклы кызын һаман күрә алган юк!



Исәя төшеп, Казан университетында укый башлагач, Зәйнәп апа турында мәгълүматым, әлбәттә, күпкә артты. Профессор Хатип Госман да үз лекцияләрендә аның исемен телгә алгалый иде. 30 елларда Г. Кутуй, Такташлар белән якын аралашып йөргән, революция "казанышларын" күпләргә караганда ныграк аңлаган "авангард яшьләр"нең берсе булган, гаилә һәм әхлак мәсьәләләрендә гасырлар буе килгән кануннарга төкереп (исегезгә төшерегез: "өйкибарм"чылар, ягъни—өйләнмәүчеләр, кияүгә бармаучылар хәрәкәтләре булган "әбиезм" заманнары бу!), "долой стыд!" төркемнәрендә актив йөргән... Менә бит кем булып чыккан безнең Хуҗа мулла кызы Зәйнәп Бәширова! Шаярма, безнекеләр бер тотынсалармы...

1965 елда үземнең дә нәниләр өчен рәсемле беренче китабым чыкты. Мин моны Зәйнәп апа Бәшировага—Жуковский урамындагы фатирына да юлладым. Танышуны китаптан башлау хәерле булыр дип уйлаганмындыр инде. Янәсе, яшь авылдашыгыз да, тегенди-мондый гына малай түгел, студент булса да,—инде китап авторы! Озакламый бер-ике җөмләдән торган җавап хаты да алдым. Әмма иркенләп күзгә-күз карашып очрашуга һаман җай чыкмады. Өйләнеп җибәрдем, ел ярым чамасы солдатта йөреп кайттым, аннан Әлмәткә эшкә киттем... Шулай да, Казанга килеп айлап-айлап Язучылар берлегендә эшләгән 69-70 елларда күреп-таный башладым мин Зәйнәп апаны. Ул—Бауман урамындагы татар ашлары йортына төшке ашка йөри иде. (Әлеге бина хәзерге кебек түгел, кыяфәте белән бүтән рәвешле иде ул вакытта, аны 70 еллар башында үзгәртеп салдылар. Хәзер хосусый оешмалар кулына күчеп, милли ашлар йортының рухы да калмады инде анда... Бу йортның шөһрәтле чагы шагыйрь Шәйхи Маннур исеме белән дә нык хәтердә калган. Ул анда еш килә иде. Аш-суга бик нәзберек, бөртекчел, күпмедер дәрәҗәдә вакчыл һәм холыксызрак булганга күрә, ашханә пешекчеләре һәм хадимәләре аннан бик өркеп торалар иде.) Матбугат йорты белән күрше генә булганлыктан, ул ашханәгә

төшке ашка сирәк булса да мин дә йөргәли идем. Шулай бер көн йөзгә-йөз дигәндәй очраштык без Зәйнәп апа белән. Кул биреп күрештек. Ул да мине, теге бүләк китаптан тыш, бераз ишеткәләп белә булып чыкты. Беркавым әңгәмәләшеп тордык. Сүзне туган авыл турында, аның балачагы хатирәләренә борыбрак сөйләшеп карадым. Чөнки туган авыл—дөньяның иң гүзәл җире иде әле минем өчен (кайбер төсләр тоныкланып, хисләр бераз тупасланса да,—хәзер дә шулай). Әмма ул минем сүзләргә бер дә кабынып китмәде. Йөзендә дә хисләнү, дулкынлану әсәре юк, ниндидер салкын битарафлык. Сүземне дәвам итеп, мин ана конкрет тәкъдим ясадым.

—Зәйнәп апа. Сезнең авылга кырык еллап инде кайтканыгыз юк икән. Әйдәгез, бергәләп кайтып киләбез—авылдаш ике шагыйрь кайта, янәсе!—Кул астында ялтырап торган кара "Волга" да бар. (Мин ул вакытта, әйткәнемчә, Язучылар берлегенең җаваплы секретаре булып эшли идем.) Җилтерәтеп кенә кайтып киләбез?



—Юк! Кайтмыйм!— диде ул кистереп.

—Нигә? Сез шунда туган, авылыбыз чишмәләренең суын эчкән, чыклы чирәмнәрендә тәпиләп чабып йөргән. Әти-әниегез шунда күмелгән. Кем белә, көне килгәч, Сезне дә шул туфрак тартыр, бәлки?

—Юк, энекәш! Әйткәннәрең сентиментальлек кенә. Без—атеистлар. Без—коммунистлар. Чын коммунистка Җир шарының теләсә нинди ноктасында күмелсә дә, аңа барыбер!

Менә сиңа вәт җәме! Дөресен әйтим, бу минутта мин, өнсез үк димәсәм дә, шактый ук югалып калдым. Ул үз сүзләрен шактый көчле тавыш һәм ниндидер бер эчке инану белән әйтте. Хөкем карарын игълан итүчеләрдә, кайбер лекторларда була шундый тавыш. Һаман күз алдымда: ап-ак чәчле, йомры гәүдәле, юантык аяклы 70 яшьләрдәге бер татар карчыгы. Кайчандыр исеме мәгълүм шагыйрә! (Соңрак белдем: Зәйнәп апа заманында Гадел Кутуйның хатыны да булган икән... 1928 елда Гөлшат исемле кызлары да туа. Ул әле бүген дә исән-сау, гомере буе диярлек экономист булып эшләгән. Шулай итеп, атаклы Гадел Кутуй безнең авылның кияве булып чыга бит әле!)

Алдагы елларда ара-тирә, әйле-шәйле генә очрашып, баш кагып дигәндәй сәламләшсәк тә, бүтән әңгәмә корып сөйләшергә насыйп булмады. Дөресрәге, теләк тә булмады. Ә баштарак теләк-ниятләр бик зурдан иде. Ул яшәгән заман рухын күбрәк беләсе, шул чор шәхесенең эчке дөньясын аңлыйсы, табынган идеалларының безгә яраклыларын күңелгә күчерәсе, үстерәсе килгән иде!.. Татар акылы төштән соң дигәндәй, хәзер соң инде... Без соңарырга иярләнгән халык шул...

Зәйнәп апа Бәширова 1984 елның җәендә вафат булды. Аны Яңа Бистәдәге татар зиратына җирләделәр.

Менә бу язмамны язып утырам да уйлап куям: хурлап язмадыммы авылдашымны? Мин аны, асылда, белмәдем дә бит. Чынында кем булган ул? Үз заманының каһарманымы, әллә бер корбанымы? Ходайның бәхетлесеме, әллә үги бәндәсеме? Мулла баласы булуыннан ваз кичкән бер гыйсъянчымы? Соңгы сәгатьләрендә иреннәрендә нинди сүзләр тибрәнгән икән?.. Авыр туфрагы җиңел булсын!

Ә 1986 елда чыккан "Совет Татарстаны язучылары" дигән белешмә китапта (төзүчесе Рәис Даутов) аның тормышына һәм иҗатына билгеләмә рәвештә язылган мондый юллар бар: "Азатлыкка чыккан халыкның бәхетле киләчәге хакына яшьләрне иҗади хезмәткә, көрәшкә чакыру, ленинизм идеяләренең мәңгелек булуын раслау, шуңа тирән ышаныч—З. Бәширова шигырьләренең төп пафосын, рухын билгели". Яки, әдәбият галиме М. Гайнуллинның аның турында әйткән сүзләрен искә төшерик: "Зәйнәп Бәширова иҗатында социалистик революция азат иткән хатын-кызларның горур тавышы яңгырый" (*"Совет әдәбияты", 1963, 8 сан*). Әйе, совет хакимияте һәм партия идеологиясе чоры бәяләмәләре бу. Ә без, иманнар яңартып, социаль тетрәнүләр кичереп, XXI гасырга кергән буын (һәм бездән соң килүчеләр) XX гасыр башында шагыйрә дип телгә кергән З. Бәшированың иҗади-иҗтимагый эшчәнлеген ничек дип бәяләргә тиеш булабыз соң?

Алдымда Зәйнәп апа Бәшированың гарәп имласында чыккан бәләкәй күләмле

шигырь китаплары. "Очкыннар" (1921), "Көрәш җырлары" (1923), "Яшь инкыйлабчы җырлары" (1923). Монысына шул заманда популяр булган рус җырлары—"Молодая гвардия", "Кузнецы", "Мы поколение живое" һ. б. җырларның тәрҗемәләре тупланган). Авылдашым китапларыннан җаныма ятышлы, рухыма иш шигырь юллары эзлим. Таптым дип авыз тутырып әйтә алмыйм, бар булган язмаларыннан кайбер мисаллар китерик:

*Яшьлегемдә кош кебек читлектә тоткын иттеләр,*
*Якты дөньяга чыгармый күкрәгемне черттеләр...*
*Ә хәзер инде азат, мәңге азат мин эшчемен,*
*Күкрәгем гайрәтле, дәртле, мин иманлы көчлемен.*

*("Татар кызы")*

* * *

*Әнә, анда ерак түгел, күрәсезме*
*Балкып тора нурга чумган кызыл байрак.*
*Әнә, чиксез халык агыла шунда таба—*
*Ил яктырткан кызыл нурга таба.*

*("Кызыл байракка таба")*

* * *

*Көйлә Туган илнең шатлыкларын,*
*Алда якты көннәр көткәнен,*
*Әкрен-әкрен шулай ярлы илдән*
*Ямьсез, караңгы көннәр үткәнен.*

*("Көзге жил".)*

* * *

*Ленин үлмәде...*
*Ул мәңгегә—"без!"*
*"Без" белән бергә яши!*
*Мәңгегә үлмәс.*
*Ленин бүген,*
*Ленин иртәгә!*

*("Үлем юк Ленинга".)*

Мисалларны күбрәк тә китерергә мөмкин. Ләкин моңа ихтыяҗ юк. Китерелгән шигырь юлларына комментарий да кирәкми. Аңлашыла. Гомумән, шул чорда иҗаты зур шагыйрәләр дип кемнәрне атый алабыз? Гыйффәт туташ? Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффарияләр? Яки Заһидә Байчурина? Иҗатының ихласлыгы, элгәррәк булуы белән аерылып торган Газизә Сәмитова? Тагын да ераккарак китеп уйланып карыйк: без белгән күп гасырлы татар шигърияте тарихында шагыйрә-алиһә дип санарлык бервр зур шәхес бармы? Булганнардыр алар, фаҗигале тарихыбыз аркасында гына онытылганнардыр дип уйлыйсы килә. Әгәр булмаганнар икән, ерак бабаларыбызга, буыннарыбызга оят. Куелган четерекле сорауның икенче ягы да бар. Хатын-кыз кайсы заманда да хатын-кыз инде ул! Табигатьнең төп миссиясе анарда—шагыйрьне дә, батырны да, хакимне дә ул тудыра. Хатын-кыз үзенең кемлеген онытса, гомеренең финалы үкенү белән томалана. Шагыйрьләр язмышы да чыгарма була алмый. Хәзер татар шигъриятендә беренче адымнарын ясаучы кыз балалар шактый. Алар да уйлансыннар иде: шигырь—синең язмышыңны, әллә үзеңнең яшьлегеңне, дәртеңне, хислегеңне күрсәтеп алу гынамы? Икенчесе—үтәр, ә беренчесе—язмышың булса, нишләрсең?..

Күптән түгел генә 85 яшьлек әтием—Габдрахман Фәйзуллин авыл зиратында Зәйнәп Бәшированың әтисе Хуҗахан Габдрахманов каберен тәртипкә китереп язулы такта куйды. Савап өмет итеп түгел, күңелемә тынычлык өчен тәртипләдем ул каберне, диде әтием. Безгә дә, бүген исән язучы-шагыйрьләргә дә гыйбрәт өчен әдәбият әһелләренең каберләрен ешрак яд итү савап булыр иде. Шул исәптән шул заманның символы һәм корбаны булган шагыйрә Зәйнәп Бәширова каберенә дә. Беренче чиратта, мин моны үземә әйтәм.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*1998-2003*

*Безнең календарь*

## Риза Ишморатның тууына 100 ел

Татар драматургиясенең күренекле вәкиле, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Риза Фәхретдин улы Ишморатов 1903 елның 1 ноябрендә хәзер Башкортстанга керә торган Янавыл районы Бәдрәш авылында туган. Булачак драматург башта үз авылында, аннары «Янбарыс» мәдрәсәсендә һәм Савыштагы русча-татарча земство мәктәбендә башлангыч белем ала. 1916—1918 елларда укуын Минзәләдә һәм Уфаның «Госмания» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. 1920 елда Уфадагы педагогик курсларны тәмамлагач эчке иминлек гаскәрләрендә хәрби хезмәткәр, аннары Актаныш төбәгендә укытучы һәм Минзәләдә тәрбияче булып эшли.

1923 елның көзендә Р. Ишморат Казанга килә һәм театр техникумына укырга керә, 1926 елда, аны тәмамлагач, Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли. Шушы елларда аның драматургия өлкәсендәге иҗат эшчәнлеге башлана. Тәүге тәҗрибәләреннән булган «Йокы патшалыгында» (1926), «Өтек философ» (1926) исемле сатирик комедияләрен ул, режиссер буларак, сәхнәгә үзе куя.

1927—1930 елларда Р. Ишморат Ленинградта театр сәнгате буенча Югары курсларда укый һәм Казанга кайтып 1931—1940 елларда яңадан Татар дәүләт академия театрында эшли. Драматург буларак Риза Ишморат нәкъ менә шушы елларда танылa, аның «Пожар» (1929), «Мәдинә» (1930), «Тургай» (1932), «Ил өчен» (1936), «Ватан» (1938), «Гөлзадә» (1940) исемле драмалары төрле театр сәхнәләрендә кат-кат куелып, тамашачыларның мәхәббәтен казана.

Ватан сугышы елларында Р. Ишморат «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасында башта хәрби корреспондент, аннары газетаның җаваплы редакторы сыйфатында Воронеждан алып Берлинга кадәр авыр сугыш юлы үтә, Берлиндагы урам сугышлары вакытында авыр яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен ул күп санлы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Драматург сугыш чорында «Дошман лагеренда» (1941), «Ватан кызлары» (1941), «Кайту» (1942) пьесаларын иҗат итә. Ә сугыштан соң Р. Ишморат тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә. Аның «Якты юл» (1947), «Шайтан таягы» (1954), «Үлмәс җыр» (1955), «Шаулыйлар дулкыннар» (1964), «И мөкатдәс моңлы сазым» (1982) һ. б. әсәрләре драматургның иҗат юлында күренекле урын тоталар.

Риза Ишморат шулай ук публицистикада һәм әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшләгән әдип.

Әдип 1996 елның 28 октябрендә арабыздан китте.



*Үткән гасыр зыялылары. Язучылар (сулдан унга) Әмирхан Еники, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Минский. Казан. 1958 ел.*



*Ике Шамил: шагыйрь Шамил Анак (алгы планда) һәм композитор Шамил Шәрифуллин. Казан. 1980 ел.*



*Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган шигъри бәйрәмдә шагыйрь Роберт Миңнуллин чыгыш ясый. Тукай-Кырлай авылы. 1986 ел.*



*Шәхес культы елларында төрмә-сөргеннәрне кичкән татар әдипләре: сулдан унга— язучы Сөббух Рәфыйков, шагыйрь Хәсән Туфан, язучы Ибраһим Салахов. Озак еллар үткәч янә Казанда очрашу. 1956 ел.*



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен артистларның якын дусты иде. Сулдан унга—жырчылар Рафаэль Ильясов, Зилә Сөнгатуллина, Мөнир Якупов, Мәхмүт Хөсәен, музыкант Рәгъде Халитов, жырчы Хәдичә Гыйниятова. Уфа. 1979 ел.*

*Юмор-сатира*

# Тәлгать Нәҗмиев

## САБА МӘЗӘКЛӘРЕ

### Кач, тотам бит!

Шәмәрдәндә бүрек тегеп сатуның «чәчәк аткан» заманында тимер юл линиясе милиционеры булып Галәветдин Сәләхетдинов эшләгән. Ул елларда станциядә бик күп поездлар туктаган, вокзалда ресторан гөрләп эшләп торган. Бүрекне вагоннар тирәсендә тышта да, эчкә дә кереп сатканнар. Милиция бу спекулянтларны (ул чорда алар шулай санала иде) тотарга тиеш булган.

Ничек тотасың инде?! Бөтенесе дә таныш, бер бистәдә яши торган кешеләр бит. Әле, юк-юк та, бүрек әйбәт сатылганы ресторанга «ым» каккалый.

Галәветдин ага бүрекчеләрне бөтен көченә кугандай итә икән. Тегесе әкрен чапса, каты итеп арт ягына тибә дә, шыпырт кына:

—Чап инде, тотам бит,—дип әйтә торган булган ди...

### Планлаштырып тибү

Рәис Миннеханов район хакимияте башлыгы булып эшли башлагач, Сабада спортка караш үзгәрде. Барлык клублар, мәктәпләр, спорт заллары ныклы контрольгә алынды, инвентарьләр бирелде, инструктор штатлары артты, стадион, ял паркы танымаслык яңартылды.

Район житәкчеләре белән планлаштыру сишәмбе көнгә—кичке сәгать алтыга күчерелде. Узган атнага анализ ясап, алдагысына бурычлар куйгач, барыбыз да спорт костюмнарын киеп, хакимият бинасы каршысында гына урнашкан мәдәният йортының спорт залына керәбез...

Анда мәхшәр. Яу кыры, дип уйларсың. Чынлап уйныйлар... Күзлекләр очып-очып китә. Кайберәүләр аны дүрт-биш тапкыр төзәттерделәр... Аксаклап йөрүчеләр дә булды. Кая тибәселәрен чамалап бетереп булмый...

Дөрес, кайбер шома егетләр дә юк түгел. Эш дәверендә бик ачулары килгән нәчәльствоны чамалап, алдан планлаштырып тибүчеләр дә булды бугай. Исемләп язмыйм. Гөнаһысы кирәк түгел.

Шулай җәй көне үзара сөйләшеп утырабыз. Беренче урынбасар Таһир Шәрәфиевнең сүзе, ничектер, шул футболга барып тоташты.

—Фәлән-фәләнечнең ике аяк арасына типкәннәр иде, сыны каткан. Мин дә быел әбизәтельно уенга керәм, әйбәтләп әйтеп тә аңламый торган ике-өч кешенең... арт ягына тибәсем бар...

### Ашауга карап

Алагаем зур икән ул «Пирамида» диган мәдәни-күңел ачу үзәге... «Служба безопасности» «капка»сын үттем генә дигәндә, сызгырган тавыш ишетеп, өндәү билгесе кебек үрә баскан егетләр кире чыгып керергә мәҗбүр иттеләр. Кесәмдәге

ачкыч бәйләмен күрсәтергә туры килде, җыелган һәр кешене бүләк тә көтә икән. «Барс-Медиа» фирмасы чыгарган кассеталарны бушка тараттылар. Безнең халык бушлай дигәндә мәтәлеп китә бит инде ул. Ике-өч тапкыр барып алучылар да булды бугай...

Залга үтәбез. Утлар-лазерлар күз явын ала. Йомшак утыргычлар, ике якта да зур экран. «Бөтен юллар Римга илтә» дигәндәй, кай якка атласаң да буфетларга килеп төртеләсең. Андагы бәяләргә кесәң генә чыдасын! Бер шешә су 67 сум тора, 25 сумга бер стакан сок та эчә аласың. Бушаган стаканны кулыннан алып китү өчен дә махсус егетләр басып тора.

Концерты шәп узды. Сәхнәдәге артистларның йөзе начар күренсә, экраннан карый аласың... Тәнәфестә атаклы баянчылар Кирам Сатиев белән Рөстәм Вәлиев халыкны ут чыгарып биеттеләр.

Кыскасы, бик җылы тәэсирләр белән кайттык без «Пирамида»дан.

...Икенче көнне каләмдәшем, Балык Бистәсендә чыга торган «Авыл офыклары» газетасы редакторы, шагыйрь Вазыйх Фатыйхов шылтыратты.

—Хәлләр ничек?—ди бу.

—«Пирамида»да булдык бит әле...

—Ничек соң анда?

—Шәп. Ашау-эчү ягы гына кыйммәтрәк.

—Буфетка кердегезме?

—Юк!

—Нәрсә ашадыгыз соң?

—Сабадан күкәй пешереп алып барган идек. Шуны әрчеп ашадык.

## Олы хәсрәт

Куйбышев исемендәге колхозны байтак еллар җырчы Сөләйман Йосыповның бертуган энесе Фәрит Даутович җитәкләде.

Шул чорда дуңгыз фермасының мөдире Мәхмүт абый була. Коты алынып, Фәрит Даутович фатирына шылтырата:

—Эшләр харап безнең, иптәш прсидәтел. Мин юри-мырый гына түгел, чынлап торып, җанымны кая куярга урын таба алмаганга, аптыраганнан шылтыратам җиде төн уртасында. Райкомдагылар сизсә, безнең икебезне дә асып куячаклар! Выгобыр бирәчәкләр. Үләсемне белсәм дә мондый хәл күрермен дип башыма китермәгән идем. Беттек, кычкырып яндык, адәм хурлыгына калдык, Фәрит Даутович, хет каравыл кычкыр!

—Әйтсәң әйт инде. Нәрсә булды?—дип кайтарып сорый йокысыннан айнып бетә алмаган рәис.

—Нәрсә булсын?! Бер дә чамаламыйсынмыни? Кичә синең белән сокланып карап киткән идек бит әле, шул—тупырдап торган күп балалы ана дуңгызыбызга күз тидергәнбез—егылып үлгән бит!

## Тозлы кыяр суы

Гомер буе Тукай исемендәге колхоз фермасында терлекче булып эшләүче Хажинур атлы кешене КПСС членлыгына кандидат итеп алу мәсьәләсе көн үзәгенә килеп баса.

Авылдагы коммунистлар гомуми җыелышта үзен «поддержать» итәләр. Әллә ни сораулар биреп тормыйлар, чөнки файдасыз икәнен беләләр.

Ә менә парткомиссия дигән җирдә—җиз иләктән үткәргән кебек итәләр үзен. Сорау өстенә сорау яудыралар. Хажинурның бик исе китми үзе. Җилкәсен җыерып, ыңгырашкан шикелле генә итеп куя. Бик аптырагач, берсе:

—Һиндстаннан нәрсә кертәләр?—дип сорый.

Шуны да әйтә алмый бит.

Партком секретаре Илдар Низамов (хәзер Теләче районы хакимияте башлыгы) бик уңайсызлана. Ул бит аны яхшылап, лаек итеп әзерләп алып килергә тиеш иде. Бераз сораугa якынрак китерү өчен: «Иртә белән нәрсә

эчәсең сон?»—дип пышылдый Илдар Мөхәммәтович.

Чәй дип әйттерәсе килә.

—Тозлы кыяр суы түгелме?—дип, Хаҗинур парткомиссия әгъзаларыннан үзе сорап куя.

## Беткәнмени...

Язучы Вахит Имамов Балык Бистәсе районы редакциясендә эшләгәндә, дәрте котырып торган егерме ике яшь вакытта, бик чибәр кыз белән таныша. Бервакыт редакциягә терәлеп торган гүзәл Чулман елгасы буенда—Совет урамы буйлап йөргәндә, әллә каян килеп чыккан биялэй кадәр генә болыт лачма итеп китә боларны.

Кыз дер-дер килә, очкылык тота башлый. Нишләсеннәр инде, эш бүлмәсенә керәләр. Юеш күлмәк ачык төстәге чүпрәк белән тышланган урындыкны пычратмасын өчен, утырыр алдыннан аска гәзит төпләме куялар.

Әмма... газетада кыз баланың утырган эзе төшеп кала бит. Житмәсә, бер куштаны шуны ул еллардагы редактор—юморга бай, Харис Әшрәфҗановка житкерә.

Редактор мәһабәт гәүдәле бүлек мөдирен кабинетка чакыра һәм салмак кына, бик житди итеп сүз башлый:

—Вахит, моннан соң, эш сәгате беткәч, бүлмәгә кызлар алып керсәң, астына «Правда» газетасы салма. Беткәнмени сиңа «Азат хатын» йә «Крестьянка» журналы!

## Бөкмеш Каюм

Байлар Сабасының иң өлкән картларының берсе—Габделкаюм ага Нәҗметдинов Әлмәндәр яшенә якынлашып вафат булды. Ул—бөтен гомерен кооперация эшенә багышлаган кеше. Әле без белгәндә дә кибетләрдә ревизия ясап йөрде, ягъни «лавочная комиссия» әгъзасы иде.

1930 еллар башында япь-яшь Каюмны Казанга—белем күтәрә торган курсларга җибәрәләр. Шунда иптәшләре арасындагы бер әңгәмә вакытында ул:

—Бездә Бөкмеш дигән авыл бар. Исеме каптырма бөгүче һөнәрчеләр хөрмәтенә кушылган, тарихи чыганакларда волость буларак искә алына,—дип ычкындырган һәм соңыннан ник әйткәненә бик үкенгән.

Чөнки курслар тәмамлаганчы аңа үз исеме белән эндәшүче булмаган...

## Тоз һәм кул

Илһам Шакиров Саратов шәһәрендә бик яхшы концерт бирә. Кем әйтмешли, жырлый-жырлый хәлдән тая. Ул алкышлар... Соңыннан милли-мәдәни мохтарият әһелләре бик яхшылап банкет оештырып, сыйлап таң алдыннан гына поездга озаталар.

Икенче көнне халык жырчысының йөрәге чәнчи, күңеле сыкрый, башы гөжли.

—Бер-бер төрле нәрсәң юкмы?—дип сорый ул якташ баянчыбыз Нәжип Бәдертдиновтан.

—Бар,—дип бер яртыны суза Нәжип.

Шуннан Илһам Шакиров:

—Син, туган, ачып та бир инде. Бүген минем кул тоз сибәргә генә ярый бит,—ди.

*Укучы сүзе*

## Рәхмәттән соң кечкенә төзәтү

Мин үзем гомер буе мәктәптә эшләп, татар теле һәм әдәбиятын укыттым. Хәзер лаеклы ялда булуыма карамастан, вакытлы матбугатта чыккан яңа әсәрләр белән танышып барырга тырышам.

«Казан утлары» журналының жиденче санында язучы Зәки Зәйнуллинның «Йәнбикә» хикәясен яратып укыдым. Ул минем чабаталы булса да якты балачагымны, саф күңелле яшьлегемне, бер-берсенә ифрат та игътибарлы, дустанә мөнәсәбәттә булган авыл кешеләрен—ата-аналарыбызны хәтергә төшерде. Керсез табигатьнең аеруча нечкә сурәтләнгән төшләрендә күзләремә яшь тә тибеп куйды. Бу хикәя мина тагын бер ягы белән бик тә ошады. Сер түгел, Башкортстанда татар халкына каршы барган кысым турында барыбыз да беләбез. Ул хакта күп сөйләнелә, күп языла. Әмма бу фетнәви чуалышта тастан юынтык су белән баланы чыгарып ыргыту куркынычы да барлыкка килде шикелле. Ягъни Башкортстандагы күңелсез вакыйгалар турында сөйләгәндә, без моны телибезме-теләмибезме, бу теманың караңгы күләгәсе мондагы ямьсез хәлләргә бөтенләй катнашы булмаган бер гамьсез гади башкорт кавеменә дә төшә башлый кебек... Нәтиҗәдә безнең бер-беребездән ерагаю куркынычы килеп туа. Татар-башкортның кайчандыр бер халык булып исәпләнүен, алар арасындагы гасырлар буе сыналган туганлыкның имгәтелә алмас дәрәҗәдә ныклыгын, бу күренешләрнең вакытлы икәнлеген, аларның үтәчәген белеп житкермәгән кайбер кешеләр Башкортстан житәкчелеге кылган явызлыкларны башкорт халкына күчерә һәм аның турында объектив булмаган фикер йөртә башлый. Мондый очракларны философлар сан сыйфатка күчә, дип аңлата бугай. Кыска гына итеп әйткәндә, бу теманы куерта-куерта без милләтләрне якынайтасы урында тагын да ерагайтабыз, үткән бергәлекне дә онытабыз. Халыкта «Шикләнгән шикләнә, чикмәнен бөркәнә» дигән бик тә гыйбрәтле мәкаль бар.

Зәки Зәйнуллинның бу хикәясе без бөркәнә башлаган шикләнү чикмәннәрен алып ташлап, татар белән башкорт бергәлегенең һәм бердәмлегенең онытыла барган туганлык сәхифәләрен ача. Шуның белән язучы Гаяз Исхакыйның «Башкорт бәхете», Әмирхан Еникиның «Курай» хикәяләрендәге якты сагышны хәтергә төшерә. Башкорт халкының Зәлифә әби, Кәлимулла бабай кебек вәкилләренең тере образларын тудыруга ирешә.

Авторның сурәтләве матур, төгәл дип әйтер идем. Менә мисал. «Безнең базарга сатарга дип бер чиләк май алып киләләр иде. Базарларда иң тәмле май, ул чакларда, башкорт мае санала иде. Чөнки ул—гөбе мае. Сепарат каймагыннан басып (бәлки биредә «басып» урынына «язып» дигән сүз урынлырак булган булыр иде) ясалмаган, ә гөбедә «төшерелгән». Ул май тәмле генә әчкелтем булып тора. Яңа «төшкән» майны яссы итеп, берәр кадаклы итеп түгәрәклиләр. Чиләктәге чишмә суына тутыралар. Ибракайдан Эстәрлегә килеп житкәнче дүрт чишмә бар. Шул чишмәләр янында туктаган саен чиләктәге суны алыштыралар. Базарга чиләктәге май салкын чишмә суы эчендә сакланып килә...»

Бу юлларны укыганда безнең балачагыбыз чelлләләрендәге салкын ташкелэтләр, карбазлар, салкын әйрәннәр, катык каткан умачлы ашлар күз алдына

килә. Әгәр дә мин язучы булсам, кулдан язылган майның тәмле әчкелтем булуы турында сөйләгәндә «әйрәне язылып бетмәгәнгә күрә тәме әчкелтем булган» дип әйтер идем. Тагын бер мисал. «Тот, улым! Кәлимулла бабаң кашыгы бу! Синең картатаң Гыйниятулла минем атаем Исәнбайга уникe кашык, дүрт тустак бүләк иткән иде. Шул тустакларның берсе әле дә бар. Алдында, катык салган. Көн дә шунардан ашыйм. Бик саклап тотам. Ә кашыклар икәү генә калды. Югалмасыннар дип, чүлпыларым янына салып куйдым...»

Менә шундый матур әсәр тудырганы өчен рәхмәт әйтәсе килә язучыга.

Әмма анда күңелне кырып торган бер үкенечле төгәлсезлек тә җибәрелгән. Аны бәлки игътибарсыз да калдырырга мөмкин булыр иде. Әмма ярамый. Ни өчен дигәндә, автор бу әсәрен киләчәктә бәлки үзенең китапларында, сайланма әсәрләрендә, җыелма томнарында чыгарыр. Аннан, тугандаш башкорт халкы вәкилләре әсәрдәге бу төгәлсезлекне күреп, татар милләте вәкиле булган язучыны «башкортны, аның тарихын, сәнгатен» белмәүдә гаепли алмасын. Аннан, бу төгәлсезлекнең чыганагын яхшы белеп тә, игътибарсыз калдыру безне, Идел буе-Урал алды татарларын, һич кенә дә бизәмәгән булыр иде.

Зәки Зәйнуллин әсәренең башыннан азагына кадәр «Йәнбикә» дигән «башкорт халык җыры» турында сөйли. Әсәргә исем дә шушы җырдан чыгып бирелгән. «Йәнбикә» җыры төп лейтмотив булып әсәрне ярып үтә. Язучы төзәтсен иде: «Йәнбикә»—һич кенә дә башкорт халык җыры түгел. Ул реаль, әле дә исән булып, Уфада яшәгән талантлы композитор Шамил Кульбарисов тарафыннан башкорт халык җырларына шулай оста тәңгәл китерелеп, «алдаткыч дәрәҗәдә» оста стильләштерелеп язылган конкрет җыр. Аның сүзләрен милләте белән татар булып, гомер буе башкорт әдәбиятына хезмәт иткән, моннан бер генә ел элек дөньяны ташлап китеп барган шагыйрь Рафаэль Сафин язган. Бу—Р. Сафинның «Йәнбикә» драмасының төп каһарманы Йәнбикә авызыннан җырлана торган җыр. Заманында, житмешенче-сиксәненче елларда, бу җыр бик тә танылып китеп, Башкортстан радиосыннан көн саен диярлек башкарыла иде, әле дә бик еш башкарыла.

«Йәнбикә» җырын хикәядәге вакыйгаларны бәйләп торучы сюжет җебе итеп алып, әсәрнең азагында автор Зәлифә әбинең җырны үзе үлгәнче, ягъни 1967 елның декабренә кадәр җырлап киләнүе турында сөйли. Бу һич кенә дә тарихи дөреслеккә туры килә алмый, чөнки ул чакта әле яшь драматург Рафаэль Сафинның «Йәнбикә» драмасының премьерасы Башкорт Академия драма театры сәхнәсендә 1973—1974 еллар сезонында гына дөньяга чыкты.

Фикеремне куәтләү өчен Башкортстан китап нәшриятының шул елларда чыгарган берничә җыр җыентыгын актарам. «Беззең йырзар», Башнәшер, Өфө, 1975, 421 бит—«Йәнбикә («Йәнбикә» драмаһынан), Р. Сафин һүззәре, Ш. Кульбарисов музыкаһы. Янә: «Йырлайык, дустар», Башнәшер, Өфө, 1977, 80 бит—»Йәнбикә» («Йәнбикә драмаһынан), Р. Сафин һүззәре, Ш. Кульбарисов музыкаһы. Янә: «Йырзар», Башнәшер, Өфө, 1984, 384 бит—«Йәнбикә («Йәнбикә драмаһынан), Р. Сафин һүззәре, Ш. Кульбарисов музыкаһы...

Житкәндер. Мондый хәлләргә артык аптырарга кирәкми. Сәнгать дөньясында шушына охшаш «саташулар» очрап куя алар. Язганда игътибарлырак булырга, хата китә икән, вакытында төзәтә белергә генә кирәк. Синең хатаң сине генә түгел, башкаларны, хәтта милләт кадәр милләтләрне саташтырмасын.

Биредә башкорт өммәте өчен бер татарның җыр сүзләре язуы, икенче татарның ана көй язуы, өченче татарның «башкортса» җырлап, аңа ит кундыруы (мәшһүр Илфак Смаковны күздә тотып әйтәм), дүртенче татарның Казанда, моны бераз гына бутап, хикәясенә халык җыры итеп кертеп җибәрүенә кинәк тукталып, теләгән хәлдә фельетон итеп тә язып булган булыр иде. Әмма бу инде бөтенләй икенче тема һәм икенче ызан.

Лирик геройның Кәлимулла бабайдан калган ике кашыкның берсен дә үзенә алмавы да күңелне сәерсендерә, әлбәттә. Шулай ителгән хәлдә, ул хикәянең сәнгати тәэсир көчен арттырган булыр иде.

Гомумән алганда, яхшы хикәя иҗат иткәне өчен язучыга зур рәхмәт.

**Рәүф ГАБДЕРӘФЫЙКОВ**,
*Башкортстан, Дүртөйле шәһәре.*

## Юк, өметләр өзелмәсен иде шул!

Мин хатын-кыз әдибәләребезнең әсәрләрен кызыксынып укып барам. Уңышларына сөенәм, кимчелекләренә көенәм. Аларның әсәрләрендә үзләренә хас мөлаемлык, йөрәкләрне тетрәндерә торган тирән хисләр сине биләп ала. «Казан утлары»ның быелгы 5 нче санында Гөлчәчәк ханым Галиеваның «Өзелгән өмет» исемле повесте басылды. Мин аны йотлыгып, бер сулышта укып чыктым.

Аның темасы да, язылыш стиле дә, теле дә мөлаем, матур. Әсәрнең героинясы Талия чын матур, нәфис зат, ләкин язмышын уйлап житкермичә, ялгышкан кыз булып, шуның белән өмете өзелгән нәфис ханым булып күз алдына килеп баса. Әлбәттә, хатын-кыз тирән хислерәк була һәм сөйгәненең ялгышын, кылган хыянәтен гафу итә. Ә нигә Ахиярны да, Талиянең үзен дә башкачарак итеп бирмәскә иде, нигә баланың да, ананың да өметен өзмичә, аларны саклап калмаска иде авторга? Бу әсәрне укыгач, тормышында ялгышуга юл куйган, ә аннары нык үкенгән җилбәзәгрәк хатын-кызда да өмет уяныр иде. Уйланыгыз әле, Гөлчәчәк ханым, бәлки Ахиярның гафу итүе Талиягә дә сабак булыр, гаилә тормышының матур дәвам итүенә өмет уятыр, киләчәктә ул Ахиярның саф мәхәббәте алдында баш ияр, алай гына да түгел, ул аны янадан тугандай итәр. Укучыда исә: карале, ә бит болай булып китүе дә мөмкин, дигән уй туар иде. Укыганда күңелдә җылы хисләр уяткан Ахияр белән Талиянең бәхетенә куандырыр, үзенең тормышында да сабак булыр иде кебек. Шулай бит? Сындырып ташлавы бик җиңел, ялгавы, эзсез ялгануга ирешүе бик катлаулы. Моның өчен зур рухи көч кирәк. Ә бит безнең бүгенге чорда җимерелгән гаиләләр күбәя бара, аны туктату, һич югында киметү зарур гамәлдер. Күпме ятим балалар, ялгыз аналар йөрәкләрне телгәли? Уйлап җиткермичә, бик җиңел генә өйләнеп, шулай җиңел генә аерылышуларны чикли торган, яшьләребезне ныграк уйланырга этәрүче, кабаланып, җимереп ташлаулардан сакларга өндәүче әсәрләр кирәк безгә.

Гөлчәчәк ханым тетрәндергеч күренешләрне оста тасвирлый. Мәсәлән, аның «Барсам» *(«К.У.» 2002 ел, 12 сан)* хикәясе моның ачык мисалы. Хисләрне тирән итеп бирә белү зур осталык таләп итә бит. Мин бу әдибә ханымга киләчәктә дә тирән хисләрдән качмыйча, аларны тетрәндергеч итеп бирә алуын, күңелләрдә тетрәндергеч хисләр уятуын, кыенлыкларны җиңеп чыгучы әдипләр кебек иҗат итү сукмагыннан тайпылмавын телим. Уңышлар сезгә, Гөлчәчәк ханым! Мине сезнең кебек әдибәләрнең татарыбызда туа торуы куандыра.

**Фирдәвес БОЛГАРСКАЯ,**
*Казан.*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2004 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. **«Казан утлары»ның индексы—73210**, ярты елга язылу бәясе 90 сум 60 тиен.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания)

Количество комплектов:

на 2004 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ____ руб. ____ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ____ руб. ____ коп. | |

на 2004 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклана торган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ. б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.

Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.

---

## Авторлар игътибарына

***Кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:***

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
7. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
8. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### РЕСПУБЛИКА КӨНЕ—ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

30 август. Тарихи көн—Республика көне. Татар халкының Сабантуй шикелле, иң төп бәйрәмнәренең берсе. Бу бәйрәмне башкалабыз, республика халкы белән бергәләп, югары дәрәҗәдә билгеләп үтте.

Татарстанга бик күп кунаклар—чит илләрнең дипломатик вәкиллекләре җитәкчеләре, журналистлар килгән иде. Алар да шушы матур тантаналарның шаһитләре булды, бәйрәм чаралары арасында төрле эшлекле очрашулар, сөйләшүләр узды.

Бәйрәм республиканың һәм Казанның төрле мәйданнарында барды. Төп вакыйгаларның кайберләре турында мәгълүматлар.

* * *

Казанда узган тантаналарның иң мөһиме Үзәк стадионда иде. Россия укучыларының I җәйге спартакиадасында катнашкан һәм финалга узган яшүсмерләрне Татарстан Президенты М. Шәймиев котлады. Россия Президенты В. Путинның Татарстан халкына бәйрәм котлавын ирештерде.

Үзәк стадиондагы тантанада М. Шәймиев Халыкара Олимпия комитетыннан Хуан Антонио Самаранч котлау телеграммасын укыды. Тантанада Татарстан халкын һәм кунакларны Россия Федерациясе Дәүләт спорт комитеты рәисе В. Фетисов бәйрәм белән котлады. Укучыларның I җәйге спартакиадасын оештыруда башлап йөрүчеләргә рәхмәт белдерде. Президент М. Шәймиевне махсус медаль белән бүләкләде.

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданга меннәрчә кеше җыелган иде. Монда иртәдән үк бәйрәм тантанасы башланды. Республикабызның танылган сәнгать әһелләре чыгыш ясады, аларны яшь һәм өлкән яшьтәге һәвәскәрләр алыштырды.

Бу тантананы Казакъстанның Кормангазый исемендәге дәүләт халык уен кораллары академия оркестры ачып җибәрде, мәйданга җыелган тамашачыларга казакъ һәм татар моннарын ирештерде.

«Уйнагыз гармуннар!» дип аталган республика фестивале дә шушы мәйданда дәвам итте.

Г. Камал театры янындагы мәйданда Татарстан Президенты М. Шәймиев җыелган халыкны Республика һәм Шәһәр көне белән котлады, Россия Президенты котлавын һәм Россия төбәкләре җитәкчеләренең бәйрәм уңаеннан җибәрелгән котлауларын ирештерде. Татарстанга күпсанлы илләрнең Россиядәге дипломатик вәкилләре килүен әйтеп, моның республикабызга зур хөрмәт күрсәтү факты икәнлеген Президент горурлык хисе белән билгеләп үтте.

Дипломатик вәкиллекләр исеменнән Швеция Корольлегенең Россиядәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе Хенрик Свен Хирдман Татарстан халкын бәйрәм белән котлады.

Аннары Президент М. Шәймиев «La Primawera» оркестры җитәкчесе Рөстәм Абязовка һәм язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинга 2003 ел өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе дипломнарын тапшырды.

* * *

Казанның үзәгендә урнашкан Тукай һәйкәле янында «Бу юлларны сиңа багышлыйм, сөекле Казан!» дигән шигъри бәйрәм узды. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачып җибәрде. Шигъри бәйрәмдә шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләм, Лена Шагыйрьҗан, Флера Тарханова, Галимҗан Гыйльман, Рәмис Аймәт, Әхмәт Рәшит һ. б. катнашты, күренекле артистлар чыгыш ясады. Баянда танылган артистларыбыз Кирам Сатиев һәм Фәрит Хатыйпов уйнады.

* * *

Республика бәйрәмендә Татарстанда Чиләбе өлкәсе көннәре дә мәгълүм әһәмияткә ия вакыйга булды. Бәйрәмгә Чиләбе өлкәсе губернаторы П. Сумин җитәкчелегендә зур делегация килде. Аның составында өлкә җыены рәисе В. Давыдов, Чиләбе шәһәре башлыгы В. Тарасов, Көньяк Урал сәүдә-сәнәгать палатасы президенты Ф. Дегтяров, Көньяк Уралның зур сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре, Чиләбе өлкәсенең Татар конгрессы рәисе Р. Гыйбадуллин, Чиләбе һәм Курган мөфтие Г. Шакаев, җәмәгатьчелек вәкилләре бар иде.

Шушы уңайдан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты «Татарстан Республикасында, Чиләбе өлкәсендә милли-

мәдәни сәясәт» дигән темага «түгәрәк өстәл» оештырды.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Мәгълүм булганча, 1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә халкыбызның каһарман уллары—унбер җәлилченең гомерләре өзелә. Һәр елның шушы көнендә 12 сәгатьтә башкалабызның 1 Май мәйданында патриот-шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләрнең барельефлары алдында хәтер җыены үткәрелә.

Искә алу тантанасының билгесы да мемориалга чәчәкләр кую һәм бер минут тын торудан башланды. Хәтер җыенын кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачты һәм алып барды. Тантанада шагыйрьләр, эзтабар-әдипләр, музей хезмәткәрләре, М. Җәлил исемендәге республика бүләгенең быелгы лауреатлары һәм, әлбәттә, сәнгать осталары—Рафаэль Мостафин, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Вәлиев, Чулпан Зариф (Төркия) Римма Казакова (Мәскәү), Айрат Арсланов, Рабига Сибгатуллина, Бакый Зыятдинов, Илсөяр Сөнкишева һ. б. чыгыш ясады.

Хәтер җыенында Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Мәдәният министры Илдус Тарханов катнашты.

## ДУМА БИНАСЫ ТӨЗЕЛӘ

Казанда тиздән Шәһәр Думасы ишекләре ачылачак. Хәзер Батурин урамы ягыннан мэриягә янәшә тагын бер йорт төзелә. Ул Шәһәр Думасы бинасының беренче чираты булачак. Төзүчеләрнең документларында әлеге корылма әнә шулай атала. Аны быел көз тапшыру планлаштырылган. Шәһәр Думасы йортының икенче чиратын торгызуга төзүчеләр 2004 елда керешергә ниятли. Бинаның өченче чиратын төзү дә каралган. Киләчәктә Батурин урамындагы йортлар да төзекләндереләчәк. Нәтиҗәдә шәһәр хакимияте комплексы Кремль скверыннан башланып, Миславский урамында тәгәлләнәчәк.

## ТАГЫН БЕР КҮПЕР БУЛАЧАК

Казан төзүчеләре Казансу елгасы аша дүртенче күпер төзүгә керешә.

Әлеге күпер хәзерге йөзмә күпердән 500 метр ераклыкта (компрессор заводы ягына таба) салыначак. Ул асылма күпер булачак. Татар-Информ агентлыгына шәһәрнең транспорт һәм элемтә комитетыннан хәбәр иткәнчә, күпер чит илләр технологиясе белән салыначак. Объектны төзүгә средстволар федераль бюджеттан бүлеп биреләчәк. Корылманы Казанның 1000 еллыгына файдалануга тапшыру планлаштырыла.

## ЮБИЛЕЙЛАРГА БАГЫШЛАНГАН КИТАП

Санкт-Петербургның «Славия» нәшриятында тарих фәннәре докторы Е. Резван җитәкчелегендә «Татарлар Санкт-Петербургта. 300 еллык тарих» («Татары в Санкт-Петербурге. 300 лет истории») исемле китап басылып чыкты.

Ул ике юбилейга—Санкт-Петербургның 300 һәм Казанның 1000 еллыгына багышлана. Китап профессорлар Т. Смирнов, З. Сикевич, журналистлар Р. Теләшов һәм Ә. Гафурова, Татарстан Республикасының Санкт-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендәге вәкаләтле вәкиле Ш. Әхмәтшин, татар җәмгыяте активистлары Ф. Нәҗмиева, Т. Тайсин, Ф. Тәһаветдинов һәм Петербург музейлары хезмәткәрләреннән торган авторлар коллективы тарафыннан язылган.

Китап Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаковның укучыларга мөрәҗәгате белән башланып китә һәм бик бай бизәлгән. Аның бик күп рәсемнәре һәм фотодокументлары Дәүләт Эрмитажы, Россиянең этнография һәм Казандагы дәүләт музейларыннан, Санкт-Петербургның үзәк архивыннан алынган.

## ҮЗӘК УРАМДА «ЙОЛДЫЗЛАР АЛЛЕЯСЕ»

Казанның Бауман урамында моңарчы күрелмәгән истәлекле вакыйга булды: анда «Йолдызлар аллеясе» барлыкка килде. Күренекле җырчылар Илһам Шакиров һәм Әлфия Афзалова тантана кунаклары иде. Матбугат йорты каршында аларның исемнәре язылган йолдызлы мәрмәр плитә куелды. Тантанага Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Казан шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары Ә. Тутаева килде. Зилә Вәлиева: «Татар җырларын саклап килгән, аны яңа баскычка күтәргән Илһам абый белән Әлфия апа моңа бик тә лаек»,—дип билгеләп үтте. Ул ике күренекле җырчыга «Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен данлыклы йолдыз» дипломнары тапшырды.

И. Шакиров, Ә. Афзалованы сәхнәдәшләре—Р. Ибраһимова, М. Сөнгатуллин, М. Галиев, З. Фәрхетдинова, З. Билалов, А. Галимов, И. Сафин һ. б. котлады.

## ЯМЬЛЕ ҖӘЙ ХАТИРӘСЕ

XIV Татар яшьләре көннәре «Борис Полевой» теплоходында үткәрелде. 150 дән артык делегат бөтен Россия киңлекләреннән җыелган иде. Фестивальдә катнашучыларның маршруты Болгар һәм Алабуга, Чаллы һәм Чистай шәһәрләре аша узды. Яшьләр көннәрен ТР Яшьләр һәм спорт министрлыгы һәм «Идел» Яшьләр үзәге оештырды.

Программа шактый киң колачлы һәм төрле иде: шагыйрьләр, язучылар, Татарстандагы газета-журнал редакторлары, дин—

һәм җәмәгать эшлеклеләре белән очрашулар, татарларның тарихы һәм мәдәнияте белән якыннан танышу...

Әлеге көннәрнең максаты да тарихны, мәдәниятне тирәнтен өйрәнүгә, регионара элемтәләрне ныгытуга юнәлтелгән иде.

## «СӘЙДӘШ АЛАНЫ»НДА БӘЙРӘМ

Мәшһүр композитор Салих Сәйдәшевнең якты истәлеге халык күңелендә җуелмас хатирә булып саклана. Аның иҗатын тәкъдир итү максатыннан менә инде дүртенче ел рәттән Сәйдәш ял итәргә яраткан Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында җыр бәйрәме уздырыла. Быелгы бәйрәмне мәдәният министры Илдус Тарханов һәм районның хакимият башлыгы В. Г. Осянин ачып җибәрде. Татарстан халык депутаты, драматург Туфан Миңнуллин, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, һәм башка бик күп татар зыялыларының композиторны җылы итеп искә алулары, Әлфия Афзалова, Зилә Сөнгатуллина, Хәмдүнә Тимергалиева кебек талантларыбызның чыгышлары тамашачылар күңелен яулады. Г. Камал театры директоры Шамил Закиров оештырган концерт Сәйдәшнең гүзәл иҗат үрнәкләре: музыкаль драмаларыннан өзекләр, инструменталь әсәрләре, романс һәм җырлары, шулай ук аңа багышланган шигырьләр белән бизәлгән иде.

Әдәби-музыкаль бәйрәмне танылган журналист, шагыйрә Флюра Низамова алып барды.

## ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

Август ахырында Татарстан Кемерово өлкәсе җитәкчеләрен кабул иткән иде. Рәсми сөйләшүләр барышында фән һәм сәнгать өлкәсендә генә түгел, ә бәлки мәдәни багланышларны да үстерү буенча даими эш алып барырга карар кылынды. Шуның нәтиҗәсе буларак, сентябрь башында Кемерово өлкәсендә күренекле рус шагыйре Василий Федоровка багышлап уздырылган Бөтенроссия әдәби бәйрәменә Татарстан Язучылар берлеге делегациясе дә чакырылды.

Кемеровода һәм В. Федоров туып-үскән Марьевка авылында үткән бу әдәби бәйрәмдә Татарстан вәкиле булып шагыйрә, Г. Державин исемендәге премия лауреаты Лилия Газизова катнашты.

## КАЗАН МУЗЕЕНА БҮЛӘК

Санкт-Петербургның танылган рәссамнары Татарстанның дәүләт сынлы сәнгать музеена рәсемнәрен бүләк итте. Шул уңайдан, 10 сентябрьдә музейда тәкъдир итү кичәсе үтте. Күргәзмәдә 29 рәссамның 200 дән артык нәкыш, графика, сынлы сәнгать хезмәтләре урын алган иде. Бу акция Санкт-Петербургның 300 еллыгына багышланды.

Әлеге рәссамнар 1994 елда Санкт-Петербургта заманча сәнгать академиясе оештырган иде. Алга таба бу хәйрия акциясендә тагын бик күп танылган рәссамнар катнашырга тиеш. Бу вакыйга элемтәләрне ныгытырга һәм кечкенә шәһәр музейларында заманча сәнгать коллекцияләрен булдырырга ярдәм итәчәк.

## ТАТАРСТАН КИТАПЛАРЫ—МӘСКӘҮДӘ

Мәскәүнең «Пролетарская» метро станциясе янындагы «Библиосфера» кибетендә Татарстан китапларын сату буенча стенд ачылды.

Хәзер Мәскәү татарларына һәм Татарстанда нәшер ителгән китаплар белән кызыксынучы һәркемгә биредә күңелләре теләгән басманы—матур әдәбият, сүзлек һәм белешмәләр, уку әсбаплары сатып алу мөмкин булачак.

## ҮЗ РЕЖИССЕРЛАРЫБЫЗ БУЛЫР

Быел «Яңа гасыр» телеканалы Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты белән берлектә «Телевидение һәм кино режиссерлары» әзерли башлаячак.

Әлеге яңа бүлек җитәкчеләренең берсе—«Яңа гасыр» телекомпаниясенең иҗади мәсьәләләр буенча генераль директоры урынбасары Миләүшә Айтуганова. Булачак режиссерлар теоретик белемнәрне университетта алачак, ә практиканы «Татарстан—Яңа гасыр»ның студияләрендә һәм монтажлау бүлмәләрендә узачаклар. Әлеге белгечлек буенча беренче төркем студентларының җитәкчесе—танылган телережиссер Дания Гаязова.

## МУЗЕЙГА—10 ЕЛ

Арчаның әдәбият һәм сәнгать музеена нигез салынуына 1 августта 10 ел тулды. Арча ягы республикага күп танылган шәхесләр үстерде. Музей Г. Курсави, Г. Тукай, Ш. Күлтәси, М. Галәү, Г. Баширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, Ә. Галиев кебек язмышлары Арча белән бәйләнгән дистәләгән күренекле әдәбият-сәнгать, фән эшлеклеләренә багышланган. XVIII—XX гасырларга караган экспонатлар арасында Г. Камал һәм Г. Тукайның шәхси әйберләре, документлары, Ш. Күлтәсинең кул таягы, Ш. Мәрҗанинең язу әйберләре һәм башка кыйммәтле ядкярләр бар.

## ИҖАТ ЙОРТЫ ЯҢАРТЫЛДЫ

Сентябрь башында Мәдәният министрлыгы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры җитәкчелеге инициативасы белән Васильево санаториясендә иҗат йорты ачылды.

Әлеге бина XIX гасыр ахырында танылган әдипләр, татар матбугаты наширләре Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәниләрнең җәйге ял йорты буларак төзелгән. Бинага куелган тактада: «1900—1916 елларда биредә күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре Г. Тукай,

Ф. Әмирхан, Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Коләхмәтов. Г. Болгарская, В. Мортазин-Иманский, Н. Сакаев, К. Тинчурин булды һәм иҗат итте», диелгән. Әлеге яңартылган иҗат йортында беренчеләрдән булып ветеран-артистлар: Ш. Биктимеров, В. Минкина, Р. Хәйретдинова, А. Галиева, Ә. Гобәйдуллин һәм башкалар ял итә башлады.

### ТАРИХЫБЫЗ ХАКЫНДА

Сөембикә ханбикә турында байтак әдәби әсәрләр язылды. Аның исеме белән бәйле атаклы манара да язучылар һәм галимнәр тарафыннан игътибардан читтә калмый. Габбас Мөхәммәтшиннең (ул озак еллар Татарстан мәдәният министрлыгында эшләде) «Сөембикә манарасының җиде баскычы» дигән китабы нәкъ шул хакта.

Әлеге китапта Сөембикә манарасы тарихы һәм татарның коллыктан чыга алмавының төп сәбәпләре яктыртыла. Автор үзе аны Казан тарихына гына түгел, рус дәүләтенең барлыкка килүеннән алып бүгенгесенә кадәрге чорны колачлаган күп кенә чыганакларны өйрәнү, эзләнүләр нәтиҗәсендә туган тарихи-публицистик очерк дип атый.

### ИГЕЛЕК ГАМӘЛ

Язучы Кояш Тимбикова якташларына кыйммәтле бүләк—дөнья әдәбияты классик әдипләре, татар һәм рус язучылары әсәрләреннән торган китаплар җыелмасын тапшырды. Шулай итеп, Чистай районының үзәк китапханә фонды меңнән артык китапка ишәеп, тагын да баеп төште.

### РӘССАМ МИРАСЫ

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә милләттәшебез, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Париждагы Халыкара сәнгать үзәге әгъзасы Бәхтияр Табиевның шәхси күргәзмәсе булып үтте.

Рухы белән чын татар булып калса да, рәссамның картиналарында казакъ табигате өстенлек итә, ул таулар матурлыгын һәм далалар киңлеген нечкә зәвык белән тасвирлаган. Бәхтиярны юкка гына дала җырчысы дип атамаганнар. Аның картиналары табигатькә, кешеләргә, бөтен тереклеккә рәхим-шәфкать хисләре белән өртелгән. Кайбер тәнкыйтьчеләр аны Ван Гог белән чагыштыра. Рәссамның картиналары Третьяков галереясында үзенең лаеклы урынын алган, аны Австралиядә, Франциядә, АКШ һ. б. илләрдә дә беләләр.

Кызганычка каршы, ул киләчәккә корган иҗади планнарын тормышка ашыра алмыйча, кырык дүрт яшендә вафат була.

### ПРЕЗИДЕНТ РӘХМӘТЕ

Күп еллар намус белән эшләгән һәм Татарстанда журналистиканы үстерүгә лаеклы өлеш керткән өчен:

«Сөембикә» журналының элеккеге баш редакторы, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы **Ихсанова Венера Фәиз кызы**, «Казан утлары» журналының элеккеге җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы **Ихсанова Ләбибә Фәиз кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр.

Август аенда шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Рәшит Әхмәт улы Шиһапов** 66 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчете.
*Н. Исмәгыйлев фотосурәте.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Дамир Гарифуллин.


# ЯҢА КИТАПЛАР

Дамир ШӘРӘФЕТДИНОВ. **Татар барда—Сабан туе бар.**—Казан: "Гасыр" нәшр., 2003. —480 б. Тиражы—1000 данә.




Тарих фәннәре кандидаты, язучы-журналист Дамир Шәрәфетдинов озак еллар буе Сабан туе бәйрәменең тарихын өйрәнде, бу хакта матбугатта байтак хезмәтләр бастырды. Бу яңа китап шул эзләнүләрнең дәвамы, күркәм нәтиҗәсе. Китапка кереш сүз язган **академик И. Таһиров** (ул китапның **фәнни мөхәррире** дә) әйткәнчә, "галимнең бу хезмәте тирәнлеге һәм эшләнеше ягыннан халык бәйрәме тарихын өйрәнүдә яңа бер этап булып тора". Чыннан да бу китапта татар халкы бәйрәм культурасының йөзек кашы булган һәм милләткә хас мөһим сыйфатларны чагылдырган Сабан туеның тарихи тамырлары, аның үсеше, камилләшүе, XIX-XX гасырлардагы үзенчәлекләре һәм хәзерге торышы, бәйрәмнең тәрбияви ролен күтәрү мәсьәләләре бәян ителә.

Тарихи фактларга һәм иллюстрацияләргә бай бу китап, белгечләрне генә түгел, татар халкының йолалары, гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре белән кызыксынучы киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итәр дип ышанабыз.




Әнәс ХӘСӘНОВ. **Җырым—ал җилкән:** Шигырьләр. —Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. —127 бит. Тиражы—3000 данә.

Әнәс Хәсәновның алты бүлектән торган бу китабына Ил-җир, Ватан-ана, мәхәббәт, чордашларыбыз язмышы турындагы уйлануларын эченә алган шигырьләре, җырлары, шулай ук сатирик әсәрләре тупланган. Китапка язган кереш сүзнең шагыйрь Әхмәт Гадел китап авторы турында болай ди: "Саф татарча, җылы, гади сөйләмле, һәммә кеше күңеленә дә үтеп керерлек итеп яза ул шигырьләрен".

Китапның мөхәррире—**Х. Әюпов**, рәссамы—**Ф. Хәсъянова.**



# ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Татар әдәбияты зур югалтуга дучар булды. 20 августта озакка сузылган каты авырудан соң Татарстанның халык шагыйре **Гамил Гыймазетдин улы Афзалов** вафат булды.

Г. Г. Афзалов 1921 елда ТАССРның Актаныш районы, Такталачык авылында туа. Әти-әниләре белән Магнитогорск шәһәренә күченеп килгәч, шагыйрь бередә тулы булмаган урта мәктәптә, шуннан соң Троицк шәһәренең педагогия техникумында белем ала. Авыру сәбәпле, ул яшәү һәм эшләү урынын еш кына алыштырып торырга мәҗбүр була, әмма һәркайда иҗатка, шигърияткә тартыла. Халык белән тыгыз элемтәдә булу аның иҗат үсешенә уңай йогынты ясый. Шагыйрьнең үзенчәлекле шигырьләре акрынлап эчтәлекле, актуаль, теле яңгыравыклы, халыкчан була бара.

Г. Афзалның шагыйрьлек таланты узган гасырның 50-70 елларында аеруча нык ачылды. Ул утыз елдан артыграк иҗат эшчәнлеге дәверендә 30 дан артык шигъри җыентык бастырып чыгарды, аларның иң уңышлылары рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителде.

Гамил Афзал—татар поэзиясендә яңа традицияләргә нигез салучы да. Шагыйрь сатирик жанрга лирик яңгыраш бирде, ана ирония, халык сөйләменең үткенлеген, зирәклеген өстәде. Шул ук вакытта шагыйрьнең әсәрләре тирән фәлсәфи мәгънәгә, югары гражданлык хисенә ия булулары, вакытны бик оста тою, зирәклеге белән аерылып тора. Г. Афзал киң колачлы иҗатчы булды. Ул укучыларның киң катлавына күп кенә кыска юмористик һәм сатирик хикәяләре, эпиграмма, фельетон, балладалары белән дә мәгълүм. Гамил Гыймазетдин улының, әйтик, «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары», «Газинур», «Гөлмәрьям», «Очрашу» кебек шигырьләрен композиторлар музыкага салды һәм алар бик популяр булып әверелде. Бу җырларны профессиональ җырчылар да, халык та бик яратып башкара. Шагыйрь 1977 елда «Айлы кичләр» дигән шигырьләр җыентыгы һәм «Борылам да карыйм» дигән шигырьләр циклы өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. 1991 елда аңа республикабызның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелде. Соңгы 40 елда Гамил Гыймазетдин улы Әлмәттә яшәп иҗат итте, бередә җирле язучылар оешмасын булдыруга үзеннән күп көч куйды.

Гамил Афзал хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге өчен «Почет билгесе» ордены, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Ул шулай ук Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татар халкының талантлы улы Гамил Гыймазетдин улы Афзаловның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

**М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миңнеханов, Ф. Х. Мөхәммәтшин,**
**Ә. С. Гобәйдуллин, З. Р. Вәлиева, И. Г. Тарханов,**
**Р. Ф. Әбүбәкеров, Ф. Г. Галимуллин, Р. Г. Фәйзуллин,**
**И. Г. Юзеев, Ш. Г. Галиев.**

Индекс 73210



Дамир Гарифуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)